
# КАЗАН УТЛАРЫ

4.1989





## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ

**26 апрельдә шагыйрьнең тууына
103 ел тула**

**(1886—1913)**

*А. Тимергалина рәсеме*

# КАЗАН УТЛАРЫ

АИЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

1989

4

(798)

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН


## *Бу санда*


ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XI СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

**Ышаныч зур!** *Иҗади секцияләр җитәкчеләре белән әңгәмә* . . . 3

ПРОЗА ҺӘМ ПОЭЗИЯ

Р. МӨХӘММӘДИЕВ. **Кенәри — читлек кошы.** *Роман* . . . 13
Н. ДӘҮЛИ. **Гаепләү сүзе.** *Шигырь* . . . 134
Р. ГАТАУЛЛИН. **Остаз турында.** *Шигырьләр* . . . 136
Р. ГӘРӘИ. **Минзәлә шигырьләре** . . . 140
И. ГЫЙЛӘҖЕВ. **Тынлык эчтәлеге.** *Шигырьләр* . . . 143

ПУБЛИЦИСТИКА

Ә. РӘШИТОВ. **Намусыңнан сора** . . . 144
Ф. ГАЛИЕВ. **Авылым гадәтләре** . . . 150

И. ТАҺИРОВ. **Кем ул Солтангалиев?** . . . 163

РЕПЛИКА

И. МИҢНЕХАНОВ. **Бәяне дөрес бирик** . . . 174

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

Э. КУДРЕЦКАЯ. **Шагыйрьнең тылсымлы мохите** . . . 175

ГӘРӘП ӘЛИФБАСЫ НИГЕЗЕНДӘ ТАТАРЧА УКУ-ЯЗУ

**Сигезенче дәрес** . . . 179

ТАТАР ХАЛЫК МУЗЫКА УЕН КОРАЛЛАРЫ

Р. ГЫЙЛӘҖЕВ. **Думбра һәм саз** . . . 183

Н. ХАНЗАФАРОВ. **Галим архивы — хәтер сандыгы** . . . 187

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**Р. Рәхимовның тууына 50 ел** . . . . . . . 189

**Культура тормышы көндәлеге** . . . . . . . 190

**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*

РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
ӘХӘТ ГАФФАР
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
ТУФАН МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РӘФЫЙК НӘФИКОВ
НУРИХАН ФӘТТАХ
РИЗВАН ХӘМИД
НИЛ ЮЗИЕВ
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

## В ЭТОМ НОМЕРЕ

Навстречу XI съезду писателей Татарии: на вопросы редакции отвечают руководители творческих секций.
Роман Р. МУХАМАДИЕВА «Львы и канарейки».
Стихи Н. ДАУЛИ, Р. ГАТАУЛЛИНА, Р. ГАРАЯ, И. ГИЛЯЗОВА.
«Публицистика». Выступление А. РАШИТОВА «Спроси у совести»; Окончание книги председателя колхоза «Искра» Арского района Ф. ГАЛИЕВА «Обычаи моей деревни».
Статья доктора исторических наук, профессора И. ТАГИРОВА об известном общественном и партийном деятеле 20-х годов М. Султангалиеве.
«Реплика». Письмо читателя И. МИННЕХАНОВА.
«К истории культуры». Статья Э. КУДРЕЦКОЙ «Волшебный мир поэта».
«Навыки чтения и письма на основе арабской графики». Занятие 8-е.
«Татарские народные музыкальные инструменты». Р. ГИЛЯЗОВ знакомит читателей со способами изготовления домры и саза.
Статья Н. ХАНЗАФАРОВА посвящена деятельности искусствоведа Х. Губайдуллина.
«Наш календарь». 50 лет со дня рождения поэта Р. Рахимова.
Дневник культурной жизни.
На наших обложках: искусство оформления книги; вид Казани во время весеннего разлива. Репродукция с линогравюры английского художника XIX века Э. Турнерелли.

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары — 53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

Җаваплы секретарь *Флүс ЛАТЫЙПОВ*
Техник редактор *Р. Сөләйманова*. Корректорлар *Т. Сибгатуллина*, *Г. Салихҗанова*.

Производствога бирелде 2.02.1989 ел. Басарга кул куелды 21.03.1989 ел. ПФ 05120. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 77049. Заказ Б-55. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1989 ел.

# ЫШАНЫЧ ЗУР!

**Татарстан язучыларының XI съезды алдыннан «Казан утлары» журналы редакциясе иҗат союзыбызның секция җитәкчеләренә түбәндәге сораулар белән мөрәҗәгать итте:**

**1. Үзегез эшләгән жанрның хәзерге хәлен ничек бәялисез!**

**2. Аның якын киләчәген ничек күзаллыйсыз! Бу жанрны үстерү өчен нинди конкрет мөмкинлекләр күрәсез!**

**3. Татарстан язучыларының XI съездына нинди өметләр баглыйсыз!**

**Түбәндә секция җитәкчеләренең җавапларын урнаштырабыз.**

**Марсель Галиев**, проза секциясе җитәкчесе:

1. Була бит шулай: акыл җитмәслек киңлекләргә җәелгән океан-диңгезләр, меңәр яшьлек затлы агачлар, мәңге кар түбәле мәрмәр кыялар күреп, шаккатып кайтасың да, йомшак чирәмле тыйнак тауларга, яры күренеп торган тын күлләргә, сандугач җыры белән сулаган урманнарга бөтенләй башка күз белән карыйсың... Җаның, кан тибешең, уй-хыялың белән бәйләнгән туган җирең манзарасы бөтенләй үзгә, кадерле, газиз икән бит. Матурлык чагыштыруда ачыла. Әдәбиятта да шулай. Артык иялашкәнгә, янәшәдәгене күреп бетермичә, еш зарланабыз ахрысы. Әгәр, читтән килеп, исеме яңгыравыклы берәр шәхес: «Әнә бит сездә нинди шәп әсәрләр бар!»— дисә, нишләп без аны элегрәк күрмәдек икән, дип шаккатырбыз шикелле. Чыңгыз Айтматовның «Җәмилә» повестен Луи Арагон күтәреп чыккач кына таныган сыман...

Әйе, үз-үзебездән читкәрәк китеп, әдәби мирасыбызны барлап карасак, язучыларның ике съезды арасында гына да дистәгә якын роман, повесть, хикәя табарга була. Аларның чын мәгънәсендә эстетик югарылыкта язылганын исбатларга мөмкин. Дөрес, бүгенге укучы утызынчы елларга багышланган публицистиканы, «сарай әһелләре» тормышы турында язылганнарны егылып укый. Әгәр бу тема еллар буена әзлекле рәвештә ачылып килгән булса, мондый ажиотаж дәррәү купмас иде. Нишлисең, аңыбыздагы бушлыкны тутыру өчен без, артка карап, үткәннәргә йөгерәбез. Шул чорның асылына барып җиткәч, без кире борылачакбыз. Кеше яңадан гадәти тормышны чагылдырган әсәрләргә иләчәк. Күңел табигый матурлыкка, ягымлы моңга сусаячак.

Утызынчы елларда язылган әдәби әсәрләргә бүген инде башкача каравыбыз да табигый. Төшенчәләр үзгәрә. Ялган оптимизм белән сугарылган, тормышны аллы-гөлле төсләргә манып күрсәткән роман-повестьлар бүгенге мәгълүмат фонында чылтырап уалдылар. Ата-бабаларыбыз башыннан үткән фаҗигаләрне без, яңабаштан, үз иҗатыбызда чагылдырырга тиешбез.

Алтмышынчы-җитмешенче елларда, объектив торгынлык хөкем сөргәндә, актуаль темалар кузгатылып, әдәбият-сәнгатьтә кешене эш атлары дәрәҗәсенә җиткереп сурәтләү хөкем сөрде. Трагедия, юмор-сатира жанры югары дәрәҗәгә җитә алмыйча, кәрлә килеш калды. Нәтиҗәдә, берничә буын укучылар мәрхәмәтлелек, кеше хәленә керә белү, соклану, тетрәнү, фикерле көлә белү кебек җанны сугара торган хисләрдә тәрбияләнүдән мәхрүм калдылар. Каты бәгырьлелек каян килә, дибез. Намус, тугрылык кебек кешене кеше иткән әхлак нормаларының үзгәртүен фәкать әдәбият-сәнгатьтән генә күрсәк, хата булыр иде. Моның сәбәпләре тирәндәрәк...

Ә шулай да... Ә шулай да прозабызда соңгы берничә дистә ел эчендә язылган, дулкыны кеше күңеленең асыл ярларына каккан лирик әсәрләр бар. Аларга Вакыт җиле кагылмас диган ышанычта калыйк.

2. Проза — халыклар язмышын киләчәккә илтүче елъязма буларак, әдәбиятның тоткан дәрәҗәсен, юнәлешен билгеләүче төп жанрларның берсе. Үткәнне, бүгенгене һәм киләчәкне колачлаучы канаты киң булганда гына проза жанры билгеле бер халыкның бай әдәби мирасын тәшкил итә. Салават күперенең бер очы ерак дәверләргә төшсә, икенче очы бүгенге тормыш дәрьясына тоташа. Шушы гармонияне саклап, тарихи темага язучылар да, заман темасын күтәрүчеләр дә уртак максат куеп, әдәбиятка хезмәт итә.

Күңел ишегенә ишекләр киң ачылган бер чорда бездән политик уяулык, иҗат активлыгы сорала. Тауга карап тау булып булмый инде, безгә шулай да ярый дип, максатны кечерәйтеп караулар да сизелә кайчагында. Чын әдәбиятның түшәме — бер. Ул кышлак әдәбияты, республика, илкүләм, аннары инде дөньякүләм әдәбияты кебек басалыкларга бүленми. Яхшы әсәр өчен региональ чикләр юк. Без бер кояш астында яшибез. Бүтән халыкларга хас трагедия, бәхет-шатлыклар, уй-хыяллар, фидакарьлек, мәрхәмәт һәм шәфкатьлелек — һәммәсе дә безне чолгап алган яшәештә чагыла. Вакытлы җитешсезлекләрне купайтып, иртәгә хәл ителәсе мәсьәләләр тирәсендә ваклыклар белән әвәрә килү — әдәбиятның дәрәҗәсен күтәрми. Публицистика өлешенә кермичә, дәвамлы проблемалар кузгатып, кеше җанының үтә нечкәлекләрен кыю вакыйгалар аша чагылдырганда гына әдәби әсәр үз көчен яулый алачак.

Бүгенге проза эчтән тектоник үзгәрешләр кичерү белән бергә тышкы тәэсирләрдән дә, әдәбият һәм сәнгатьнең бик күп төрләре йогынтысында да яңарыш кичерә. Кино, драматургия, нәгышлы сәнгать — гомумән, безне чолгап алган сурәтле, образлы, мәгънәле дөнья прозага яңа сыйфатлар өсти. Вакытның кадерен белгән укучы каршында маҗаралылыктан чыгып, фикри тыгызлыкка, сүз егәренә ирешкән проза мәйданында табигый сайланыш бара. Язмышлар өчен язмышлар, вакыйга өчен вакыйга, сюжет өчен сюжет кына түгел, ә Кешенең югарыгы этажы — баш миенә дә очкын кабыза торган тирән эчтәлекле фәлсәфи проза бүген алгы планга чыга. Җирдә ничек яшибез?— дигән сорау куйган проза мифик алымнар кулланып, Кешенең мәҗүси сабыйлыгын һәм мең еллар буена туплаган әхлакый һәм эстетик акылын бергә кушып, Вакыт һәм пространство чигендә мәһабәт тормыш агачы калкыта. Кеше һәм дөнья турында яңа сүз әйтеп, шушы көчле агымга без ничек кушыла алырбыз — анысын дәвер күрсәтер.

3. Язучының тәхете — язу өстәле. Керсез кәгазь каршында ул, Вакыт белән бергәбер калып, Әдәби тормыш кора. Әлбәттә, илдә барган һәммә вакыйгалар, иҗтимагый үзгәрешләр дә иҗат кешесенең йөрәге аша уза. Алда көтелгән зур форумда әдәби хәрәкәтебезгә бәйләп, республикабызның экономик, культура хәле турында да зур трибунадан торып бәян ителер дип уйлыйм. Халкыбызның киләчәге, теле, гореф-гадәте, тарихына караган чыгышлар да турыдан-туры безгә кагыла. Мине бигрәк тә республикадан читтә яшәүче татарлар язмышы борчый. Республика чикләре билгеләнгәнче үк, борын-борынгыдан корган нигездә яшиләр ич алар. Казанның мәдәният нуры аларга төшәме, тавышыбыз барып җитәме?— бу җитди мәсьәләләрнең берсе. Ут күршебез, тугандаш Башкортстан җирендә яшәүче татарларның рухи халәте нинди? Кайбер төбәкләрдә хәтта «Казан утлары» журналын алдыруга махсус киртәләр куелуны, китапларыбызның барып җитмәвен ничек аңларга? Мең-мең сорау... Казанда милләтебезнең исеменә күләгә төшерергә тырышып, болгар этнонимы турында сүз куертуларның төбендә ни ята? Бер халык та аралашмыйча, кан кушмыйча, кытай стеналары эчендә генә яшәмәгән. Татардан чыккан күпме шәхесләр, рус белән кушылып, дәүләт эшлеклеләре, зур язучылар, галимнәр, гаскәр башлыклары булып киткән. Безгә исем тирәсендәге беркатлы шаукымнан азат булып, халкыбызның чын, объектив тарихын аңларга вакыт. Татарлар ничә гасыр буена Россиянең иминлеген яклап утка-суга кергәннәр. Моны белү миндә горурлык уята. Әгәр мин, татар исемен үзгәртеп, икейөзлегә әйләнсәм, рухым сынган, хәтерем тапталган хәлдә атам-анам кабере каршында нинди җавап тотар идем микән?

Урта гасырларда барган көрәш-сугыш, җир биләүләрдән бер халык та читтә калмаган. Символ дәрәҗәсенә җиткереп, бары тик бер дошман эзләү, бөтен каралыкны берьяклы өю — олы халыклар тарихын бизәми. Үткән гасырлардан канлы таплар гына эзләмичә, бер-беренә ярдәм кулы сузып яшәү турында, чыккан конфликтларның төбендә нинди сәбәпләр ятканын ачыклап язарга иде.

Татар ханнары һәм рус князьләренең «Мой брат» дип язышкан ярлык һәм хатларына гына күз салсаң да күп нәрсәләр ачыклана. Тарих ялганны кичерми, дөреслек барыбер калкып чыгачак...

Менә шундый һәрьяклы уйлар белән киләм мин съездга. Зурдан кубып, барысын да уртага салып сөйләшсәк, алга кичектергесез бурычлар куйсак, бу съездан без яңа рух алып, бердәм теләктәшлектә киләчәккә атларбыз дип уйлыйм.

**Рәдиф Гатауллин**, поэзия секциясе җитәкчесе:

1. Поэзия жанрының хәзерге хәлен канәгатьләнерлек, хәтта әйбәт табам дим икән, мин моны ышанып әйтәм. Бу ышаныч — шигъриятебез турындагы соңгы еллардагы бәхәсләр, аңа атылган уклар һәм ул алган яралар, утлы-бозлы фикерләр, мәкаләләр һәм әдәби чыгышлар яктылыгында да — шул ук кала. Нигәме? Шигъриятнең, әйтик, аның соңгы еллардагы продукциясенең бик күп кимчелекле яклары да булсын, аңардан «бизү» очраклары да табылсын, аерым шагыйрьләр иҗатында «төшү», «ваклану» һ. б. күренешләр дә очрасын ди, әмма чын шигърият, аның югары дәрәҗәдәге чын җәүһәрләре дә исән ләбаса! Әйе, каршылыклы фикерләр уятырлык сәбәпләребез дә бардыр; шигырь китапларының «зыяны» яки рентабельле булмавы турында мәңгелек «дәрес» сүзләр дә хактыр бәлки; китап сәүдәсе кешеләренә җиңел сулап куярга да җай ачыладыр... үзебез дә артык үшәнләнеп, китапны һәм шигырьне пропагандалауга бөтенләй игътибар бирмичә, тынычланганбыздыр. Бардыр... Әмма әлеге ышаныч та яши бит әле. Ул, мөгаен, шигъриятебезнең тарихи зурлыгына, бай традицияләренә бәйле инанудыр; ә бәлки үзебезнең чорда шигыребезнең һич инкарь итеп булмаслык югары культурасына, башка әдәбиятлар белән икеләнмичә янәшә куярлык исемнәре, әсәрләре барлыгына ышанычтыр? Һәм аны фамилияләр, әсәр исемнәре санамыйча да дәлилләп була дип уйлыйм мин... Хәер, шигъриятне тирәнтен белеп, өйрәнеп, аңлап, иң мөһиме, аны чын мәгънәсендә яратып язган белгечләребез бу бурычны моңа кадәр әйбәт кенә башкардылар кебек.

Нигәдер, аларның күбесе соңгы елларда барган, шул исәптән «Казан утлары» битләрендә урын тапкан бәхәсләргә генә катнашмыйча калдылар. Гаҗәп хәл: бүгенге поэзиябезгә югары бәяне үзебезнең тәнкыйтьчеләр түгел, тугандаш әдәбиятлар вәкилләре: рус, башкорт, чуваш һ.б. әдипләре бирделәр — М. Кәрим, Н. Нәҗми, Вл. Солоухин, Вад. Дементьев, А. Хузангай кебек авторитетлы исемнәрне искә алу да җитәдер. Ә инде үзебезнең классиклардан Сибгат Хәкимнең «Яшә, борчулы җаным» исемле китабы бүгенге татар шигыренең зурлыгына, дәвамына, киләчәгенә чын ышаныч гимны һәм безгә васыять булып яңгырый бит! Журнал битләрендә барган бәхәс чын-чыннан шигырь китапларына да игътибарны юнәлтер, бәлки... Гәрчә, бу бәхәс шигырьдән сүрелдерә дип раслаучылар да бар. Алар да хаклыдыр... Битарафлар гына булмасын; шигырь турындагы сөйләшүне киләчәктә безнең мәдәният, туган тел язмышын кайгырту дип кабул итә күрсен укучы. Гомумән, шигърият турында сөйләшү — аерым кимчелекләр турында сөйләшү генә дә булырга тиеш түгелдер (графоманнар турында яки «уртакуллар» турында бөтенләй искә алмау — үзе үк үтергеч чара, бәлки?!), киресенчә, зурлыкны күрсәтүче исемнәр, әсәрләр турында сөйләшү, традицияләрне барлау яхшырак түгелме? Бөтенсоюз матбугатында барган бәхәсләргә, журналлар, группалар талашына механик рәвештә генә кушылмыйбызмы? Нәрсә генә дисәк тә, шигырьне төрле укучы төрлечә аңлый. Хәтта безнең башка жанрда язучыларыбызга да ул, барыннан да бигрәк, җиңел жанр, «аш тәмләткеч», яки настроениең булганда әдәби ләззәт алу өчен бер чара, хәтта ки, мораль-дидактик нәсихәт формасы; берәүләргә ул туган тел, халык, нигез, тарихны яратуны раслаучы декларация, поэтик декламация... Әгәр дә талантлы шагыйрь булып, бер-бер фәнни һәм эстетик карашларның бәхәсендә көчле иллюстрация дә бирер булса, менә бу — «чын шигырь»... Бу мәсьәләдә бик өстә яткан, сурәтсез, «туры» әйткән фикерләр дә эстетик «файда»га хезмәт итә ала! Икенчеләр исә тулы канлы, күп яклы, бүгенге катлаулы чорны тирән аңлаучы һәм аңлатырга үз шигъри көче, җегәре — интеллектуаль үз фикере, оригиналь һәм халыкчан чаралары белән бай поэтикасы булган шигъриятне яклый... Бәхеткә каршы, мондый шагыйрьләребез дә бар. Димәк, шигъриятнең хәле дә начар түгел!

2. Шигъриятебезнең якын киләчәге... Югарыда әйтелгән, чын шигъри культура тәрбияләүгә мөмкинлек биргән сыйфатларны саклап үстерергә кирәк. Чын мәгънәсендә асыл мирасыбызны үзләштерү, өйрәнү, аны пропагандалау юлында эшләргә кирәк. Бу җәһәттән «Татар поэзиясе антологиясе»нең яңасы зур ярдәм була алыр иде — аның тизрәк дөнья күрүен көтәргә кала. Безгә, шагыйрьләргә дә, шигърият мәсьәләләрендә нык таләпчәнлек, югары критерийлар белән эш итү кирәктер. Югыйсә, без секциядә дә һаман «әлифба» белеменнән уза алмыйбыз: башлап язучыларның, яшьләрнең китап кульязмаларын тикшерү, иҗат обзорлары һ.б. Әмма поэтика, осталык мәсьәләләре сирәк тикшерелә, бәхәсләр, диспутлар булмый. Әлбәттә, теоретик мәсьәләләр, аерым жанрларга караган докладлар тыңлана, фикер алышу була, аксакалларыбыз иҗат тәҗрибәсе белән дә уртаклаша... Әмма секция эшендә яңа чаралар кирәклеге дә — күптән өлгергән мәсьәлә...

Шигырьгә булган мөнәсәбәт тә — хәзер инде туган тел үсеше, аның даирәсенең киңәю яки тараюы, матбугат яки нәшрият мөмкинлекләре, укучыга барып җитү белән бәйле рәвештә, гомумхалык, гомум ил эше итеп каралырга тиештер. Яңарыш, үзгәреш чорында бигрәк тә... Шигъриятне пропагандалау да — зур мәсьәләләрдән саналырга

тиеш. Бу — аның энтузиастларына да бәйле. 60 елларда шигырьнең шундый тугры рыцаре, ихлас хадиме — шагыйрьләрнең якын дусты, хәзерге танылган прозаик һәм драматург Роберт Батулла иде. Безнең буын шагыйрьләрен пропагандалауданиләр генә эшләмәде ул: әдәби кичәләр дә, радио, телевидение тапшырулары да оештырды, сәхнә-концертларын да файдаланды. Без аңа гомерлек рәхмәтле. Ә шагыйрьләргә — шәхси кире мөнәсәбәтләрдән өстен булып, зур идеаллар, бурычлар белән яшәүне теләргә кала. Бүгенгенең үзенә хас калку шигъри атрибутларын табып, тормышның Блокча «тулы гармонияле музыкасы»н тыңлый һәм яңгырата алсак икән! Һәм үсешебез дә гомумчаралар, кем әйтмешли, барыбызны бердәй сөйри торган гомум «чана»лар белән генә дә бармастыр; зур шәхесләр, интеллектуаль багажлы, югары омтылышлы шагыйрьләр тәрбияләнсә икән: болар өчен ныклы милли җирлек, шәхси активлык, барыннан да элек хакыйкать тарафдары була белү дә кирәктер. Бүгенге үзгәрешләр чоры кемнәрне шундый итеп чыныктырыр, кемнәр әнә шундый биеклеккә күтәрелер, күрербез...

3. Республикабыз язучыларының XI съездыннан поэзиябез өчен конкрет нәрсәдер көтү... бәлки сәеррәктер. Шулай да бу жанр турында да тирән, тәфсилле сөйләшү булыр, бәлки, дигән ышаныч та бар. Ә поэзиянең үсеше — аны аңлау, аңлату, пропагандалау, яшәве өчен шартлар булдыру — димәк ки, гомуммохит, югары таләпчәнлек һәм җаваплылык тойгысы белән аерылгысыз. Ә бу — барыбызның да бурычы. Һәм мин шигърияtнең алга таба үсешенә, шанлы дәвамына зур ышаныч баглап калам...

**Рөстәм Мингалимов,** драматурглар секциясе җитәкчесе:

Татар язучыларының X-XI съездлары арасында безнең йөрәкләребез аша күп кенә үзгәрешләр дулкыны узды. Тормыштагы мондый үзгәрешләр, борылышлар драматургияне читләп уза алмый. Хәтта алар — нәкъ менә драматургия, нәкъ менә театр азыгы дисәк тә хата булмас.

Т. Миңнуллин, А. Гыйләҗев, И. Юзеев, Р. Хәмид бу съездны да зур эшләр — яңа әсәрләр белән каршылыйлар, әсәрләре сәхнәләштерелде; тик секция утырышларында укылмаган, язмышларына секция тәэсире тимәгән пьесаларның исемнәренә һәм саннарына хәзер тукталып тормау дөрес булыр дип карыйк. Турыдан-туры театрларга мөрәҗәгать итеп Ә. Гаффар, Ф. Садриев, Р. Мингалим, Р. Бохараев һәм башкаларның пьесалары куелды. С. Шәкуровның секциядә уңай бәяләнгән «Саф күңелгә тап төшми» исемле драмасы уңыш белән сәхнәдә бара.

Әдәбият тормышына килгән яңалыклар Р. Батуллага драматургиябез өлкәсендә сөенечле вакыйгага ясарга, Габдулла Тукай турында заманча яңа сүз әйтергә мөмкинлек бирде. Бу әсәрне укыгач, драматурглар секциясе утырышы ясаган нәтиҗә шундый иде.

Бюро члennары өметле күренгән авторлар белән кат-кат эшләделәр, әсәрләрен кат-кат укыдылар, файдалы киңәшләр бирделәр. Ә тагы ни кирәк? «Секция ул иҗат остаханәсе!»— диярге дә була... Шулаен шулай, әмма заманнар үтә тора һәм иҗат секцияләренең хәле зур үзгәрешләр кичерә. Бүген секциягә әсәр китергән язучы — югары белемле, дөнья драматургиясе белән, сәхнә теориясе белән таныш, кыю. Иҗади киңәшләрне тиз аңлый, килешсә — аны кабул итә, килешмәсә, каршы катгый дәлилләр китерә һәм секциядән практик ярдәм көтә. Аңа көчен сынау, киләчәктә осталыгын үстерү өчен сәхнә кирәк. Ә драматурглар секциясенең сәхнәсе юк. Дөрес, фәкать үз мөмкинлекләреннән файдаланып, кемнәрнеңдер әсәрләрен театр сәхнәләренә күтәрә алган А. Гыйләҗев, Р. Батулла кебек язучылар бар. Әмма алар да бит һәр өметле яңа әсәрне сәхнәгә чыгара алмый, аларның да үз театрлары юк. Секция көче дә яңа авторны берәр режиссерга тәкъдим итеп караудан ары узмый. Тәкъдим итү — әсәр сәхнәләште дигән сүз түгел. Әсәрне әле театрда күпмедер эшлисе була. Ә хәзерге театр автордан әзер әсәр көтә. Театрларыбыз саны аз; күрәсең, әзер әсәр табарга мөмкинлекләре бардыр. Шулай итеп, драматургиягә килергә омтылган яңа исемнәрнең күңелләре суына бара, алар сәхнә әсәре язудан читләшә, бу — татар драматургиясенең бүгенге куркыныч чире. Соңгы елларда гына да секция игътибарын җәлеп иткән, ләкин театр афишаларында урын алмаган исемнәр байтак булды. Мәсәлән, секция утырышында А. Расих «Һәлакәт» дигән тарихи пьеса укыды. Әлеге кимчелекләре дә булуга карамастан, бер театр алынган очракта, камиллеккә ирешә, тамашачыга тәкъдим ителә ала иде ул. С. Батталның «Ирексездән десантчы» һәм тагын ике әсәре 3-4 ел секция папкасында адашып йөрделәр. Алар да театр эшләгәндә камилләшерлек иделәр. С. Шәмсинең дә шундый язмышлы әсәре бар. Г. Зәйнашеваның «Сандугачлар сабан туе» да сәхнә тапмыйча югалып ята.

Инде моннан ун ел элек башлап язучы саналган, Мәскәүдәге әдәбият институтын уңышлы тәмамлаган, соңгы дүрт елда секциягә дүрт пьеса тәкъдим итеп караган Хә-

мис Һудин өметсезлеккә бирелеп, Казаннан ук китте кебек. Ә бит сәхнәгә куярлык әсәрләре бар иде. Бу фикерне бигрәк тә аның «Кышкы суык төндә», «Курорт идиллиясе» дигән пьесаларына карата әйтергә мөмкин. Шул әсәрләре сәхнә күрсә, ул, рухланып, алардан мөһимрәкләрен дә язар иде, инде Язучылар союзына да алынган булыр иде.

Ф. Дунайның, Х. Нигъмәтуллинаның укып-тикшерүләрдә уңай бәяләнгән пьесалары да сәхнә күрү бәхетенә ирешмәделәр.

Драматургия жанрына язучылар унарлап түгел, берәрләп килә. Алар өчен секция беренче мәктәп булса, театр — икенче зур мәктәп. Театр мәктәбен үтми торып яңа драматург формалаша алмый. Безнең төрле юнәлештә эзләнү алып бара торган режиссерларыбыз аз, чөнки театрларыбыз күп түгел. Кайчандыр Татарстаннан башка өлкәләрдә эшләгән, татар драматургиясен үстерүдә мөһим роль уйнаган күчле театрлар — бүген ябык. Мәйдан тарлыгы драматургларның иҗади рухын төшерә, секция тормышын сүндерә. Соңгы елларда Д. Вәлиев, Ә. Гаффар драматургиядән бөтенләй читләштеләр. Сәхнәгә уңышлы гына омтылыш ясаган М. Мәһдиев, М. Галиев, Р. Кәрами кебек язучыларыбыз да бу омтылышларын туктаттылар. Шулай булгач, пьеса язарга теләп кулына беренче кат каләм алган яшьләрнең хәле үзеннән үзе аңлашыла. Аларга үсү мөмкинлеклеге юк дәрәҗәсендә.

Әлбәттә, ике съезд арасында уңышларыбыз да булды дип, ниндидер әсәрләр санарга, секция тәкъдиме белән Язучылар союзына керде дип бер-ике фамилия күрсәтергә, Ф. Бәйрәмова, Р. Гыйззәтуллин, М. Гыйләҗев кебек яңа исемнәрнең театр афишаларында урын алуларын әйтергә була. Тик хәлебез мактанырлык түгел, заман каршында, башка зур халыклар янәшәсендә үсешебез әкрен. Театрларыбыз югалтулар кичерә. Әлегә табыла килгән тамашачы зәвыгын үстермибез. Югары зәвыклы тамашачылар арасында татар драматургиясенең киләчәгенә шикләнеп караучылар күбәя.

XI съездан соң драматурглар секциясе һәм театрлар дуслыгы ныгыр, бәлки театр яңа әсәр укыганда секция вәкилләре, язучылар яңа пьеса укыганда театр вәкилләре катнашыр — бу тулаем үсешкә этәргеч булыр дип ышанасы килә. Без тагын бер нәрсәне истә тотарга тиеш: күрше халыкларның бөек әсәрләрен сәхнәләштерә белсәк тә, Кәрим Тинчурин геройларын мәңге сәхнәдә яшәтергә уйласак та, афишаларда исемнәре хаклы рәвештә өзлексез балкыган авторларыбызга тезләнеп табынсак та — татар драматургиясе һәм театры шушы исемнәр белән генә дә яши ала дигән фикергә тәрәлеп калмаска иде. Безнең драматургия яңа тавышка, яңа исемнәргә бик мохтаҗ!

Яшь авторларны үстерү максатыннан чыгып, бәлки, театрларыбыз киләчәктә планнан тыш — тәҗрибә спектакльләре куйгалау гадәте алыр? Фәкать яңа әсәрләр кую юлы сайлаган эксперименталь театрлар тумасмы?

Республикабыздагы Халык театрларының саны кырыкка җитә. Алар әлегә драматургиябезгә яңа исемнәр китерә алмыйлар, чөнки инде сәхнә күргән һәм китапларда чыккан әсәрләрне генә кабатлыйлар. Халык театрлары яңа автор ача алсын өчен, Татарстан культура министрлыгы ул театрларга әсәр тәкъдим итү, уңышлы пьеса язган яңа автор белән килешү төзеп, аңа түләү мәсьәләсен кайгыртырга тиеш.

Чаллы кебек куәтле шәһәребездә яңа театр утлары кабынуын зарыгып көтәбез... Әнә шундый теләкләребез тормышка ашмаса, татар драматургиясенең заман көткән дәрәҗәдә баруы икеле.

**Марсель Зарипов,** очерк һәм публицистика секциясе җитәкчесе:

1. Бер генә жанр да тулаем әдәби хәрәкәттән башка яши алмый, үсә алмый. Шуңа күрә очерк һәм публицистиканы да әдәбиятыбызның көзгесе дип, юк, алай гына да түгел — аның хәле ниндилекне бик төгәл күрсәтүче зурайткыч пыяла дип әйтергә мөмкин.

Соңгы елларда, җәмгыятьтәге үзгәртеп кору процессына бәйле рәвештә, бу жанрда күпмедер җанлану күзәтелә күзәтелүен. Байтак кына каләм осталарыбыз публицистик кайнарлык белән тормышның актуаль мәсьәләләрен күтәреп чыгалар. Ләкин шулай да очерк һәм публицистика бүгенге көннең алгы сызыгына чыкты дип әйтергә әле иртәрәк. Республикабыз язучылары әле һаман очерк һәм публицистика китапларын аз иҗат итәләр. Аларның эзләнү һәм тикшеренү даирәләре дә шактый тар, кечкенә. Язучыларның үткән съездыннан соң Рафаэль Мостафин, Илдар Низамов, Самат Шакир һәм Гөлшат Зәйнашевалар үз китапларын чыгардылар. Тагын бер матур һәм безнең әдәбиятта сирәк була торган күренеш — танылган язучыларыбыз Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев һәм Марсель Галиевләр атаклы «Гигант» совхозы директоры, Социалистик Хезмәт Герое Нәҗип Зыятдинов турында бергәләп әсәр иҗат иттеләр. Хәзер бездә һава хәленә сылтап акланырга яраталар — ә менә Н. Зыятдинов елның-елында тотрыклы рәвештә югары уңыш алып килә. Үз күршеләреннән ике-өч мәртәбә югарырак та уңыш алалар әле бу совхозда! Менә шундый җитәкчеләр күбрәк булса, без, бил-

геле, ашлыкны чит илдән сатып алмас идек, ә аларга үзебез озатыр идек.

Тормышның үзеннән алып язылган мондый әсәрләргә ихтыяҗ бик зур. Ләкин безнең әдипләр очерк язганда ирексездән диярлек башкарырга туры килә торган андый «кара эш»тән куркалар, күрәсең. Ә бит бу «кара эш» — тормышны, андагы теге яки бу проблеманы тирәннән өйрәнү дигән сүз. Менә шушылай тирәннән өйрәнмичә генә повесть яисә роман язарга утыруны бер дә хуплыйсы килми. Ышанычлы разведкасыз, нык-лап тикшерүсез алга бару мөмкин түгел бит. Безнең әдәбиятта ерак һәм якын үткәнебезне төрле яктан яктыртучы әсәрләр күп, ә менә бүгенгенең һәм шулай ук бик якын иртәгәбезнең зур проблемаларын үткен итеп күтәргән җитди әсәрләр азрак. Ә бит иртәгәге көнгә юнәлеш тотмаган әдип — канатсыз кош сыман ул!

Безнең язучылар тормышының үткен мәсьәләләрен күтәреп матбугатта, радио һәм телевидениедә еш чыгыш ясыйлар. Әмирхан Еники, Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев, Рафаэль Мостафин, Барлас Камалов, Флүс Латыйпов, Тәүфикъ Әйди, Мансур Вәлиев — менә шундый сугышчан каләм ияләреннән башка республикабызның көндәлек матбугатын күз алдына да китереп булмый. Безнең төп газетабыз «Социалистик Татарстан» битләрендә генә дә соңгы елларда язучылар 300 мәртәбәдән күбрәк чыгыш ясаганнар. Ләкин борчый торган як та бар. Әле һаман бездә мактау рухы шактый көчле, бигрәк тә бер-беребезне мактау. Без хәзерге чынбарлыгыбыздагы борчыган күренеш һәм тенденцияләрне җитди итеп өйрәнүгә көчне күбрәк салсак иде.

2. Иң әүвәл — Сүз булган... Кешеләрнең рухи һәм физик көчләрен бергә туплаучы, оештыручы сүз булган... Минем уйлавымча, безнең язучылар еш кына әнә шул алтын тәгъбирне истән чыгаралар. Ә бит аларның матбугаттагы, радио һәм телевидениедәге чыгышлары, тискәре күренешләрне ышандырырлык итеп тәнкыйтьләүләре яисә конструктив уңай программа тәкъдим итүләре бик мөһим дәүләткүләм чараларның нигезе була алыр иде. Күп кенә рус язучылары безгә бу яктан үрнәк күрсәтәләр. Мисал өчен, Сергей Залыгин Түбән Обь елгасы үзәнлеген су басудан саклап калды, хәзер бирәдән күпләп нефть алына. Можаев, Аграновский, Иващенко, Стреляный, Черниченко һәм башка кайбер әдипләр көрәше исә промышленностьта, авыл хуҗалыгында һәм фәндә яңача, заманча карашларның җиңүе өчен җирлек булмадымыни?!

Үзебезнең республика матбугатына игътибар итегез дә, «Хатлар эзеннән» рубрикасына күз салыгыз әле. Язучылар күтәргән тәкъдимнәргә, тәнкыйтькә җавап биреләме аларда? Юк бит! Июнь аендагы кар кебек, январьдагы яңгыр сыман — бик тә сирәк була бу. Ә сәбәбе нидә микән? Әйдәгез, үз-үзебезгә дә тәнкыйть күзе белән карарга өйрәник: безнең фикерләү дәрәҗәбез шактый түбән түгелме?! Публицистик язмаларыбыз да оптимистик рухта гына.

Роман авторларын әйтеп тә тормыйк. Безнең күп кенә публицистик чыгышларыбызда да бүгенге барлык бәлаләрнең башы итеп бары тик үткән чор гына күрсәтелә. Янәсе, тормыштагы барлык җитешсезлекләргә, дефицит күп булуга, бәяләр югары булуга, акчаның бәясе нык төшүгә — барысына да бары тик Сталинның шәхес культы гына гаепле. Мәсәлән, М. Мәһдиев «Социалистик Татарстан»да басылган бер мәкаләсендә авыллар бушап калуны, кибетләрдә талоннар керүне һ.б.ларның барысын да үткәннәр белән һәм бигрәк тә Сталин белән генә бәйли. Әлбәттә, Сталинда һәм аның системасында гаеп бар, ләкин моны әйтү белән генә тулы  хакыйкать әйтелде дип уйларга ярамый. «Юлбашчыбыз һәм остазыбыз» үлгәннән соң да инде тулы бер буын үсеп җитте. Ул буын хәзер төп йөкне тартып бара. Сталин үлгәннән соң, Хрущевның чирәм җирләрне күтәрүенә кадәрге чорда, кибетләрдә килосы бер сум утызар тиенлек итнең иркен ятуын да искә төшерик. Ә Горбачев исә илне талоннар белән, кыйммәтле кооператив колбасалары белән кабул итеп алды.

Бөтен гаепне бары тик үткәнгә генә сылтап язган авторларга бүгенге ялкау һәм пошмас җитәкчеләр, әлбәттә, рәхмәт кенә укыйлар. Чөнки җитешсезлек күп булу алар гаебе түгел булып чыга бит! Үткән чор гаебе бит!

Әгәр дә без бүгенге тормышка, эшләрнең оештырылу дәрәҗәсенә канәгатьсезлек белдерәбез икән — биредә язучылар үзләре дә читтә кала алмыйлар. Чөнки алар — кеше күңеленең инженерлары буларак — торгынлык һәм аңа кадәрге елларда буш куык чәчеп, хәзерге җәмгыятьне, кешеләрне, без үзебез хәзер ошатмаган социаль күренешләрне тудырыштылар. Алар инициативасыз һәм оешмаган кешеләр тәрбияләделәр, үз илләрен кризис алды хәленә җиткергән кешеләр үстерделәр. Шуңа күрә, бүгенге һәм иртәгәге дөрес үсеш юлларын эзләү, табарга тырышу, язучылар алдында аеруча мөһим мәсьәлә булып тора.

3. Съездан нәрсә көтәмме? Беренчедән, әдәби процесска төрле яктан үлчәнгән, объектив анализ бирүне. Икенчедән, фикер йөртүдә һәм нәтиҗәләр ясауда җаваплылыкны. Өченчедән, съездда әдәби амбицияләр урын алмасын иде, без башкаларга карата гына түгел, ә барыннан да бигрәк үзебезгә карата таләпчән булсак иде.

**Роберт Миңнуллин,** балалар әдәбияты секциясе җитәкчесе:

Торгынлык елларында иң кимсетелгән, игътибардан иң читтә калган социаль катлам, мөгаен, балаларыбыз булгандыр. Җәмгыятьнең, җәмәгатьчелекнең битараф мөнәсәбәте балачакның бөтен өлкәләренә дә кагыла.

Бүгенге мәктәпне генә алыйк. Күпме шаулаштык, карарлар чыгардык, пленумнар уздырдык... Файдасы гына булмады. Күпме өметләр баглаган мәктәп реформасы да барып чыкмады. Мәктәп әле дә кризис хәлендә. Балаларыбызның сәламәтлеген саклау да коточкыч түбән дәрәҗәдә — балалар үлеме буенча безнең илебез «иң алдынгы» илләрнең берсенә әйләнде. Ятим балалар проблемасы турында әйтеп тә торасы юк. Балаларга эстетик, музыкаль тәрбия, художество тәрбия бирү ярлгы хәлендә генә. Бигрәк тә авылларда... Шушылар фонында, билгеле, балалар әдәбияты да бик үкялтырамагандыр.

Аннары балалар әдәбияты бездә бары тик энтузиазмга гына нигезләнгән. Элек тә шулай булган, хәзер дә. Балалар өчен язу татар әдәбиятында гомер-гомергә мәртәбәгә исәпләнмәгән. Хәтта Тукайның балалар өчен язуына да сәерсенеп караганнар бит замандашлары. Бу — тәнкыйтьчеләрнең мөнәсәбәтендә дә, китаплар чыгарганда да, Язучылар союзы җитәкчелегенең битарафлыгында да ачык чагыла. Докладларда, чыгышларда балалар әдәбияты күбрәк «һәм башкалар» рәтендә йөри. Союзга кабул иткәндә дә шундый ук күренеш күзәтелә.

Әйтик, бер-ике китап чыгарган яшь шагыйрьләр турында без җае чыкса, чыкмаса да, шауларга тырышабыз. Тәнкыйтьчеләр дә чат ябыша аларга. Трибунага кунаклаган өлкән шагыйрьләр дә тизрәк «ачарга» тырыша яшь талантларны. Союз җитәкчесе дә артларыннан гына сөеп йөртә. Кыскасы, имезлек кенә каптырмыйбыз шул берничә яшь иптәшкә. Һәм дөрес эшлибез. Шундый игътибарлы мөнәсәбәт булганда гына әдәбиятны үстерергә мөмкин. Ләкин, әгәр дә чын гадел булыйк дисәк, шундый ук игътибар башкаларга да булырга тиеш. Шул исәптән, балалар өчен язучыларга да. Алар бар! Алар язалар, китаплар чыгаралар! Аларны укыйлар! Мин аларны санап та китә алам. Рәхим итегез: Рафис Корбанов, Раушания Низамова, Ләбиб Лерон, Гайсә Гатауллин, Вакыйф Нуриев, Рәниф Шәрипов, Рафаэль Газизов, Рафис Гыйззәтуллин... Балалар әдәбиятының киләчәге — алар кулында.

Әмма балалар әдәбиятына, ничек кенә авыр булмасын, безнең язучыларыбызның күпчелеге намус белән иҗат итте. Н. Исәнбәт, Ш. Галиев, Л. Ихсанова, Ш. Рәкыйпов, Х. Халиков, Ф. Шәфигуллин, Батулла, Ф. Яруллин кебек абруйлы исемнәр үзләре үк күп нәрсә турында сөйли. Бөтенсоюз аренасына чыккан шигъриятебез бар. Йөзне кызартмаслык повесть-хикәяләр языла тора. Шуларга Т. Миңнуллин, Н. Дәүли, Р. Харис пьесаларын да өстәсәк? Барысын бергә тупласаң, шактый бай хәзинә туплана түгелме соң?

Соңгы вакытта Казан үзенең группировкалары белән ил күләмендә «яңгыраш» тапты. Бу феномен да — өлкәннәрнең балаларга булган битараф мөнәсәбәтләреннән килеп туган күренеш. Гәрчә, безнең язучыларыбыз Казанның бүгенге үсмерләр проблемасына моннан берничә еллар элек үк игътибар иткәннәр иде инде. Моңа мисал итеп, А. Гыйләҗевнең «Күзгә күз», Л. Ихсанованың «Милиционер малае» повестьларын китерергә була. Кызганыч, А. Гыйләҗев повестена ул вакытта кара ягылды, Л. Ихсанова повестена игътибар итүче булмады. Бүгенге яшьрәк прозаиклар К. Кәримов белән Р. Бәшәров повестьларында да шундый ук проблемалар күтәрелә. Әсәрләр языла тора, аларны вакытында күрә белергә генә кирәк.

Менә шуңа күрә дә мин Җ. Тәрҗемановның: «Соңгы елларда Татарстан китап нәшрияты укучы балаларның үз тормышын чагылдырган бер генә яңа повесть, поэма, пьеса да бастырып чыгармады, бер генә фәнни-художестволы, маҗаралары яки фантастик әсәр дә тумады, нәниләр өчен бер генә яңа әкият тә язылмады, укучыларны туган табигать кочагына да алып кермәдек»,— дигән сүзләр белән берничек тә килешә алмыйм. Йә ул безнең балалар әдәбиятын аңламый, йә аның бер китап та укыганы юк.

Балалар әдәбияты, балаларның үзләре кебек үк, ярдәмгә мохтаҗ. Дөрес, без бүген туган тел язмышы, мәктәпләрдә татар телен һәм әдәбиятын укытуның хәле, балалар бакчаларында татарча тәрбия турында күп сөйлибез, күп язабыз. Борчылган булабыз, гаепләләрне эзлибез. Һәм табабыз да. Гаепне үзебездән генә эзләмибез. Ә бит боларның барысында да безнең үзебезнең шактый саллы өлешебез бар. Бар шул, бар! Бу проблемалар балалар әдәбиятына да турыдан-туры бәйле.

Менә бүгенге картина. Татар балалары кызыксынып укырлык бизәкле китапларыбыз юк икән. Балалар бакчаларында җырларлык җырлар язылмаган. Нәниләр өчен язылган шигырьләребезнең күбесе, турысын гына әйткәндә, халтура. Татар мәктәпләре өчен дәреслекләр җитми. Аеруча Татарстаннан читтә яшәүчеләр өчен. Ничә еллар инде балалар китапларына, балалар җырларына, әдәби әсәрләргә, дәреслекләргә бернинди дә конкурслар уздырылганы юк.

Мин инде язучыларның ничәнче съездын зур өметләр белән көтеп алам. Быелгы съездыбыз да әдәби тормышыбызга әллә ниләр алып килер кебек. Ни дисәң дә, үзгәрешләр, яңалыклар, ачышлар заманы. Съездда шулай ук балалар әдәбияты турында да, туган телебез язмышы, халкыбызның бүгенгесе һәм киләчәге турында да олыдан кубып сөйләшү булыр дигән өметтә калам.

Билгеле, һәркемнең үз борчулары, үз мәшәкатьләре. һәрберебезне иң элек үз китапларыбыз, үз гонорарыбыз, әдәбияттагы үз урыныбыз, абруебыз кызыксындыра. Аннары инде, әгәр дә вакыт, энергия, теләк калса, укучы, халык турында да кайгыртуыбыз мөмкин. Тик минә андыйларыбыз күп түгел шул. Шуңа да карамастан, съездда язучыларыбыз шәхси мәнфәгатьләреннән, көндәлек мәшәкатьләрдән өстенрәк булырлар дип ышанам. Әдәбият, әдәбиятның киләчәге, аның язмышы мәктәптән, балалардан, яшь буыннан башлана. Әгәр дә балалар язучылары гына түгел, гомумән, язучылар коллективы шушыны аңласа, киләчәгебезгә якты өметләр белән карарга мөмкин. Әгәр дә халкыбызның, димәк, әдәбиятыбызның да, гомерен озайтыйк дисәк, шушы хакыйкатьне онытмасак иде без.

**Флүн Мусин,** әдәби тәнкыйть секциясе җитәкчесе:

1. Минемчә, аерым кызыклы гына чыгышлары булса да, татар әдәби тәнкыйте гомумән алганда хәзерге үзгәрешләр чорында үз позициясен ачыклый алмыйчарак тора. Ул нәрсәдер көтә кебек. Үзәк тәнкыйтьтә шау-шулар, группалар арасында көрәш көчәйсә, бездә бертөрле тынып тору сизелә. Бу жанрда җанлану әллә ни күзгә ташланмауда бездә тәнкыйть фикеренең һаман моңа кадәр урнаштырылган кысалардан чыга алмавын, аңа плюрализм җитмәве дә үз ролен уйный ахры. Тәнкыйтьчегә без һаман хөкем чыгаручы вазифасын гына йөклибез, фикерләү төрлелегеннән качабыз, бәхәсләшә белмибез кебек тоела.

Әдәби тәнкыйтьнең соңгы елларда ничектер тыныбрак торуының яки үз тавышын әллә ни ишеттерә алмавының тагын бер сәбәбе — хәзер төп игътибарның әдәбият тарихына, мираска юнәлтелүе белән бәйләнгән, күрәсең. Белгәнебезчә, үзгәртеп кору заманы гомумән тарих һәм мирас мәсьәләләрен бермә-бер актуальләштерде, алар киң җәмәгатьчелекне ныклап уйландыра башладылар. Табигый, әдәбият белгечләре дә хәзерге вакытта күбрәк шушы мәсьәләләр белән мәшгульләр.

2. Әдәби тәнкыйтьнең якын киләчәген мин аның фәннилек юлыннан үсәчәгендә күрәм. Чөнки күпьеллык практика күрсәткәнчә, фәннилек тәнкыйть өчен бик кирәк. Мондый сыйфаттан мәхрүм булу тәнкыйтьчегә гомум әдәби хәрәкәт яки аерым әсәр турында төпле фикер йөртергә комачауларга мөмкин, кайчак нигезләнмәгән, очраклы бәяләмәләрнең хасил булуына китерә. Мәгълүм ки, хәзер әдәбият тарихын да, аның хәзерге хәлен дә хәбәрдарлык рухында яңача карау һәм бәяләү сорала. Биредә дөрес позиция сайлау өчен әдәбиятчыларга һәм тәнкыйтьчеләргә беренче чиратта фәннилек кирәк. Бу сыйфат алар өчен әдәбият диңгезендә үзенә бер компас булып торырга тиеш. Монда тагын фән белән практиканың, әдәбиятчы белән тәнкыйтьченең хезмәттәшлеген көчәйтергә кирәк. Алар бер-берсенә бик күп нәрсәдә ярдәм итә алалар.

Шулай да тәнкыйть жанрын җанландыру, үстерү күбрәк яңа кадрлар әзерләү белән бәйләнгән. Әйтергә кирәк, бу — байтактан әдәби җәмәгатьчелекне борчый торган мәсьәлә. Күпме вакытлар инде безгә әдәби тәнкыйтьчеләр җитмәү, аларның саны елдан-ел кими бару, алмаш бик аз булу турында сөйлибез, әмма сүздән эшкә күчә алмыйбыз. Әдәби тәнкыйть өчен яңа кадрлар әзерләүне бездә профессиональ тәнкыйтьчегә яшәү мөмкинлеге булмау бермә-бер кыенлаштыра. Тәнкыйтьче кайдадыр эшләргә, күпчелек вакытын башка төр эшләргә сарыф итәргә мәҗбүр. Шул ук вакытта тәнкыйтьченең хәзер коры практик кына була алмавын, аңа фәнни яктан да чарлану кирәклеген тагын бер басым ясап әйтәсе килә. Минә шундый тәнкыйтьчеләрне әзерләргә, аларга иҗади шартлар тудырырга, минемчә, кутәрелә торган бер мөһим мәсьәләне хәл итү, ягъни бездә махсус әдәбият институты булдыру зур өлеш кертә алыр иде. Андый институтта заман әдәбияты мәсьәләләре белән шөгыльләнә торган махсус группа оештырып, аның сотрудникларына агымдагы әдәби хәрәкәттә актив катнашуны планлаштырырга булыр иде. Аннан соң тәнкыйтьче хезмәтенә түләү мәсьәләсен яңадан карыйсы бар. Гамәлдәге гонорар ставкалары нәшриятта бу хезмәтне кимсетелгән хәлгә куялар. Гәрчә әдәбиятның иң авыр һәм җаваплы жанры булса да, тәнкыйтьче материаль яктан прозаиктан яки шагыйрьдән түбәнрәк дәрәҗәдә тора.

3. Республика язучыларының XI съезды әдәбиятыбызның ике съезд арасындагы торышы турында гадәти һәм күнегелгән бер сөйләшеп алу гына булмасын, стереотип отчет төсен алмасын иде. Ул әдәби тормышыбызда чыннан да вакыйга булсын, әдәбият-

ның, аның аерым жанрларының үсешенә йогынты ясардай эшлекле һәм үтәлерлек чаралар планлаштырсын иде.

**Владимир Корчагин**, рус язучылары секциясе председателе:

Республикабызда яшәп иҗат итүче рус һәм рус телендә иҗат итүче татар язучылары төрле жанрларда эшлиләр. Алар арасында прозаиклар һәм шагыйрьләр дә, драматурглар һәм публицистлар да, шулай ук тәрҗемәчеләр дә бар. Үткән съездан соң алар үзләренең 40 тан артык китапларын чыгардылар. Моннан тыш әле актив иҗат итүче яшьләребез дә байтак. Соңгы елларда алар да үз әсәрләрен аерым китап итеп һәм «Заман көзгесе» («Зеркало времени» — 1986 ел), «Яз иде...» («Была весна» — 1987 ел), «Горизонт» (1988 ел) исемле күмәк җыентыкларда бастырып чыгардылар. Тәрҗемәчеләребез тырышлыгы белән татар язучыларының күп кенә күренекле әсәрләре дә рус телендә дөнья күрде.

Ә шулай да язучыларыбызның соңгы еллардагы иҗатында иң күңеллесе шул — алар заман таләбенә җавап бирерлек күп эшләр башкардылар. Мәсәлән, Д. Вәлиев белән И. Киндер республикабыздагы яңарыш хәрәкәтенә багышлап «Чакыру» («Зов») исемле күмәк җыентык туплап чыгардылар. Г. Паушкинның «Осталар» («Мастера»), Д. Вәлиевнең «Межлаук урамындагы изге җан» («Меценат с улицы Межлаука»), М. Скороходовның «Кара аргамакта» («На черном скакуне»), И. Киндерның «Беренче орден» («Первый орден») һәм М. Зариповның «Юлдагы сынау» («Испытание в пути») китаплары да үзләрендә чорның кайнар сулышын чагылдыралар. Укучы бу әсәрләрдә гадәти булмаган яңа геройлар белән очраша, гаделлек һәм кешелек гүзәллеге өчен көрәш күренешләрен күрә һәм җәмгыятебезнең үткән проблемалары белән таныша.

Билгеле, әле болар барысы да башы гына. Тормышта һәм иҗатта яңарыш рухын көчәйтү буенча әле рус язучыларының да күп эшлиселәре бар. Яңа шартларда яшәүче замандашыбыз күңелен, аның психологиясен тулырак аңлау өчен дә әле нык тырышырга кирәк безгә.

Татарстан язучыларының XI съезды безнең бу омтылышларыбызга яңа дәрт өстәр, алда торган бурычларны тирәннәнрәк тоярга ярдәм итәр дип ышанабыз. Илебез күләмендә бара торган зур үзгәрешләргә Татарстан язучылары керткән иҗади өлеш тагын да зуррак булачак!

**Кыям Миңлебаев**, әдәби тәрҗемә секциясенең җитәкчесе:

Әдәби тәрҗемәнең хәле безнең республикада беркайчан да кызыгырлык булмады. Гәрчә әдипләрнең күбесе үзенең иҗаты башланган дәвердә тәрҗемә белән мавыгып караса да, байтагы бу хезмәтнең энә белән кое казу икәнен бик тиз абайлап алды, башка жанрга авышуны кулайрак санады. Беркайчан хупланмаган әлеге жанрда тыйнаграк, сабыррак затлар гына торып калды. Оригиналь әсәр дип аталсын өчен генә урта кул повесть яки роман язучылардан үзгә буларак, тәрҗемәгә үзләренең гомерләрен багышлаган әдәбиятчылар бервакытта да рәхмәт ишетмәделәр. Хәер, моңа өметләнүче дә булмады. Аларның бар ниятләре — татар укучыларына дөнья әдәбияты, рус әдәбияты классикасыннан, күп милләтле Совет илендә иҗат ителгән иң әйбәт, иң камил, иң күренекле, иң гыйбрәтле әсәрләрне үз ана телебездә онытылып укырлык дәрәҗәгә җиткереп тәрҗемә итү, рәхмәт сүзен укучылардан ишетү. Дан-шөһрәткә сусаган язучының әдәби тәрҗемә өлкәсендә чиләнүен күргәнем юк. Бу өлкәдә фәкать бал кортларыдай тырышып-тырмашып, халыкка файда китерү, әдәбиятыбызны баету хыялы белән яшәүчеләр генә эшли. Әнә шул фидакарь хезмәт нәтиҗәсендә бүгенге көнне әдәби тәрҗемә зур камиллеккә иреште. Әмма аңа Язучылар союзы идарәсе яки нәшрият тарафыннан караш яхшырмады дип әйтү генә аз булыр, әдәби тәрҗемәгә мөнәсәбәт көннән-көн начарлана. Татар әдәбиятын югарыда әйтелгән урта кул повесть-романнар белән чикләп-киртәләп куюу, үткәннең һәм бүгенгенең камил әсәрләрен тәрҗемә иттерми генә, халык яратып укыган, бөтен бер буын әдәбият сөючеләрне тәрбияләп үстергән китапларны да кабат чыгармау, оныттыру политикасы алга сөрелә. Югыйсә әдәби тәрҗемәнең бүген гаҗәеп биек үрләр яулап алганлыгын таныргa, моңа укучылар белән бергә сөенергә генә иде инде...

Дустым Әбрар Кәримуллинга: «Син берүзең әллә ничә кешелек эш эшләдең, хезмәтең белән син үзеңә һәйкәл салдың. Әмма үзең үлгәч, ул һәйкәлне постаментка күтәреп куярлык шәкертләрең юк»,— дигәнем бар. Һәркем үзе эшләгән өлкәдә киләчәктә эшне дәвам итәр өчен шәкертләр үстерүне кайгыртырга тиеш. Беркем рәхмәт әйтмәгән, хуплап каршыламаган жанрда — әдәби тәрҗемәдә бу бигрәк тә кирәк. Гәрчә камиллекнең чиге булмаса да, бүгенге казанышлар дәрәҗәсен түбән төшермичә сакларлык, аны тагын да югарырак күтәрә алырлык яшь кадрларны тәрбияләп үстерү — безнең

бурыч. Бу өлкәдә бездән алда армый-талмый эшләүчеләр — С. Әдһәмова, И. Гази, А. Шамов, С. Фәйзуллиннар — яшьләргә ачык чырай күрсәткәнне гомердә дә онытырга хакыбыз юк. Алмаш тәрбияләүнең хәзергә әле сүздән ары китә алганы юк бугай.

Әйтик, минем шәкертләрем арасында Г. Муллаева, И. Миңнеханов, Ф. Тарханова һ.б. гаять өметле егетләр-кызлар бар. Алар гадирәк, җиңелрәк тәрҗемәләр эшләп үзләренең сәләтләрен күрсәттеләр дә инде югыйсә, әмма аларны хуплап каршыларга, фидакарь хезмәткә фатиха бирергә бик үк алай атлыгып торучы күренми. Бер генә мисал. Галия Муллаева, әдәби тәрҗемәне гомерлек хезмәте итәргә хыялланып, В. Богомоловның 70-80 битлек кенә повестен тәрҗемә итте. Секция утырышында бу хезмәт югары бәя алды. Өлкәннәрнең җылы сүзенә рухланып, яшь тәрҗемәче тагын да көчлерәк дәрт белән яңа әйбер эшләп ташлады. Күләме белән әллә ни зур булмаса да, Д. Гранинга «Клавдия Вилор» исемле повесте өчен СССР Дәүләт премиясе бирелгән иде. Героиняның Ватан сугышы елларында искиткеч зур батырлык эшләвенә, нинди генә сынауларда да сынмавына сокланып, ихлас яратып эшли яшь ханым һәм үзенең хезмәтенә «Комиссар хатын» дигән исем бирә. Ләкин 4-5 ел буенча ике кулъязманың икесе дә читтә кала килә.

Яшь тәрҗемәчеләргә мондый караш булганда, безнең буынга алмаш килмәячәк, бездән соң вакуум хасил булып, аны тиз арада халтура тутырачак.

Әдәбиятыбызны башка халыклар теленнән әйбәт тәрҗемәләр исәбенә киләчәктә дә баетуны күздә тотып, мондый тәкъдим кертәм:

1. КДУ һәм КДПИ студентларын башлангыч курсларда ук әдәби тәрҗемә теориясе белән таныштырып (хәзергә бу эш университетның фәкать милли мәктәпләр өчен рус теле бүлегендә генә алып барыла, моңа татар телен һәм әдәбиятын махсус өйрәнүче студентларны да тартырга кирәк), өметлерәк күренгәннәрен аерым группага яки түгәрәккә туплап, теорияне дә, практиканы да ныклап үзләштерәсе иде.

2. Ана телен әйбәт белгән егетләрне-кызларны, әдәби тәрҗемә теориясен үзләштергәннән соң, бүтән республикаларга — университетларга стажировкага җибәрәсе иде. Алар анда халыкның телен, гореф-гадәтләрен өйрәнеп, шул әдәбиятны турыдантуры безнең телгә тәрҗемә итәр иделәр.

3. Тәрҗемә өлкәсенә килүче яшьләрнең китаплары тоткарланмасын иде.

XI съезд һәр жанрда эшләүчегә якты перспектива булдырган тәкъдирдә, безнең әдәбиятның киләчәге сүздә генә әйбәтләнеп калмыйча, эштә дә әйбәтләнер иде.

# ПРОЗА

## Ринат Мөхәммәдиев

# КЕНӘРИ — ЧИТЛЕК КОШЫ

РОМАН

### 1



Мәһабәт гәүдәле, урта яшьләрдәге бер ир-ат килеп баскан иде аның каршына:

— Дөньяны каргыйсызмы, туташ?..

Асия дәшмәде, гүя ул аны бөтенләй ишетмәде.

— Дөнья матур. Каргамагыз дөньяны...

Бермәлгә югалып калды Асия, ни дип җавап кайтарырга да белмәде. Бәлки, гомумән, дәшмәскә, ишетмәгәнгә сабышырга кирәк булгандыр? Ялгыз хатын-кызга, юк сүзен бар итеп, сагыз кебек ябышырга йөргән ир-атларны беренче генә очратуы түгел ләбаса.

Хәер, бу ир андыйларга охшамаган кебек. Әле иртән, аэропортның иркен һәм бөркү залына килеп кергәч үк, ничектер кинәт кенә игътибар иткән иде Асия аңарга. Пөхтәлеге, кием-салымы, сабыр кыяфәте һәм, гомумән, үз-үзен тотышындагы сәер бер горурлыгы, тәкәбберлеге белән күпләрдән аерылып тора иде ул. Дәүләт эше белән бер-бер җитди командировкага баручы, яисә кайтып килүче булса кирәк дип, үзалдына уйлап та куйган иде әле. Инде менә ике сәгать чамасы ул, урыныннан да кымшанмыйча, ниндидер төсле рәсемнәр төшерелгән чит ил журналлары актарып утырды. Берәүгә дә күз салмады, дәшмәде, үзен эшлекле кешеләргә генә хас рәвештә җитди тотты. Бу берәр чит ил кешесе яисә бер-бер дипломат, журналист кебегрәк кешеме икән әллә, дип тә уйлаган иде Асия. Тегенең журнал белән мавыгуыннан файдаланып, эшсезлектән, туйганчы күзәткән иде үзен. Шул рәвешле, каршысында басып торучы бу ир-атны ишетмәмешкә, күрмәмешкә салышу мөмкин булмаган кебек үк, аны бер-бер дорфа сүз әйтеп кире бору өчен дә сәбәп юк иде. Ә ул үзе һич тә борылып китәргә җыенмый, мөлаем елмаеп, тик басып тора Асия каршында. Үзен элеккечә үк горур, тыныч тота. Телендә дә шул ук сүзләр:

— Туташ дим, каргамагыз сез аны, дөньяны.

Ниһаять, гаҗәпсенү катыш кызыксыну белән башын күтәрде Асия:

— Нигә дип каргыйм ди? Әлегә дөньядан зыян күргәнем юк.

Күзләре бер мизгелгә очрашты.

— Алай икән,— диде әлеге ир.

---

Ринат МӨХӘММӘДИЕВ *(1948) — язучы, филология фәннәре кандидаты, «Беренче умырзая», «Ак кыялар турында хыял», «Истәлек өчен Гыйлемханга» кебек повестьлар, проза һәм әдәби тәнкыйть китаплары авторы. Казанда яши.*

— Әйе, менә шулай...

Асия аның аяк уртасындагы мускулы тартышып алуын, ирен читләрендә чагылып киткән чарасыз елмаюны сиземләп калды. Нәрсә аңлаткандыр ул елмаю, шулчак мөлаем бер җылылык сирпелгәндәй булды үзеннән. Ирексездән, янә кызыксыну биләп алды аны: «Кем икән бу кеше? Ул аңа ни әйтергә тели? Бер-бер җитди сүзе бармы?.. Әллә башкалар сыман, эш юклыктан, вакытын кая куярга белмичә, бераз теленә салынып алу гынамы исәбендә?..»

Аягын аяк өстенә атландырып, итәкләрен тарткалап куйды ул. Әмма тыңлаусыз итәк — үзенекен итте. Ир-атның ниятен, максатын аңларга теләп, Асия чираттагы мәртәбә күзләрен югары күтәрде.

Залдагы чит-ят күзләр дә игътибар юнәлтеп өлгергән иде инде үзләренә. Сәгатьләр буе, ни эшләргә, кая барып сөялергә белми иза чигеп йөрүчеләр өчен ир белән хатын-кызның танышуыннан да хикмәтлерәк тагы нинди тамаша табарга мөмкин соң?..

Ике як-ягында янәшә утырган өлкән яшьтәге хатыннарның күз читләре белән үзенә таба карангалап алуын тойды Асия. Сул яктагысы, алдына гәҗит җәеп, әле генә тамак ялгарга керешкәне, хәтта авызына капкан йомыркасын чәйнәүдән туктап торды. Менә бит, аларга да бер кызык табылды үзенә күрә. Кабып алган ризыгын йотарга онытып җавап көтәләр аңардан. Ничек итеп җибеп төшәргә, җавапсыз калырга мөмкин шундый чакта?

— Зарланмагач — әйбәт. Бәхетлесез, димәк?..

— Зарлана алмыйм,— диде Асия, чит-ят күзләрнең арткаптан-арта баруын чамалап. Тәкәббер елмаерга да онытмады. Хатын-кызны мондый очракларда урынлы-урынсыз гаеп ташлаулардан азат итә торган тәкәбберлек иде бу.

— Ә мин сезгә бик урынлы бер тәкъдим белән, туташ.

— Тыңлыйм...

— Ачыккансыз. Мин сезне ресторанга чакырам.

— Рәхмәт, таныш түгел ир-атлар белән ресторанга йөрү гадәтем юк.

— Ә мин...— ир-ат бер мәлгә туктап калды. Әллә фикерен үзгәртте, әллә сүз таба алмый торды, аңламассың.— Мин ялгыз йөрергә күнекмәгән.

— Ай-һай, бер дә харап икәнсез...

— Мин шаярмыйм, туташ, чын күңелдән чакырам!..

— Чын күңелдән баш тартам, рәхмәт!

— Сез мине дөрес аңламадыгыз, туташ.

— Аңладым. Әнә, кемне дә булса башка берәүне чакырыгыз.— Асия як-ягына ым какты. Әлеге каныгудан туя башлаган кебек иде инде ул.— Залда кеше шыгрым тулы ич, башка берәүне чакырыгыз.

Аңлашылдымы дигәнне аңлатып, иреннәрен турсайтып куярга да онытмады: шуның белән сүз тәмам, янәсе. Иңбашына аскан нәни сумкасын иплә генә ачып, аннан мода журналын тартып чыгарды. Тезгә-тез салынган аякларын алмаштырып куйды. Итәген тартты, тегесе янә тыңламады. Янәшәгә салып куелган пальтосын барлагандай итте. Һәм, бернигә дә исе китмәгән кешедәй, инде таушалыр хәлгә җиткән журналын яңабаштан актарырга керешге.

Аның саен кымшанмады ир-ат. Бу хатынның үзенә алай ук битараф түгеллеген чамалап өлгергән кебек иде инде ул. Кирәксә-кирәкмәсә турсаеп алган иреннәр, күзләреннән бөркелгән юмарт елмаю, берөзлексез тынгысызланып торган кул-аяклар шул хакта сөйли түгелмени?!. Ир-атларны үтәдән күрүләре белән мактана торган хатыннар була. Бик ихтимал. Әмма алар бер нәрсәне — ир-атның да, үзенә күрә, шактый күзәтүчән халык булуын онытып җибәрәләр. Әлеге ирнең дә кире борылырга, чигенергә уенда да юк иде.

— Кемне чакырыйм икән,— дип, киңәш сорагандай, тәкәббер муенын суза төшеп, як-ягына карангалап алган булды ул.— Соң, алай бул-

гач, апа, әллә сез барасызмы? — дип, тез өсләренә гәҗит җәеп тамак ялгап утырган өлкән яшьләрдәге хатынга мөрәҗәгать итте.

Авызына дәү итеп капкан йомыркасын әле дә булса чәйнәргә онытып, тамаша кылып утырган авыл хатыны шаяруны аңламады.

— Юк, юк,— диде ул һәм, кабалана төшеп, авызындагы ризыкны тумылдатып чәйнәргә кереште. Бер-ике тапкыр йотып, бушана төшкәч, дорфа гына өстәп тә куйды.— Безнең ристораннарга җөрер чак үткән. Тамагым да тук, бер кабар җирем дә юк...

— Бар, кызым, ашауның ояты юк. Чакырган җиргә бар, куган җирдән кит дигән борынгылар,— дип, сүзгә Асиянең икенче ягында утырган хатын да килеп кушылды.— Тешләрем булса, бер дә баш тартмас идем әле. Үзем керер идем. Теш протезым гына өйдә калган...— дип, үзалдына рәхәтләнеп кеткелдәп үк җибәрде.

Күпме гомер янәшә утырып та, бер авыз сүз алмашмаган хатыннарның да сүзгә кушылуы, үзе тирәсендә сүзнең шулай куерып китүе ошамады, билгеле, Асиягә. Йә, ни житмәгән иде инде сезгә дигән сыман, янә күз чите белән сөзеп, каршысында кадакланган кебек басып торган ир-атка карап алды. Һәм шунда, аның карашынча, инде күптән үпкәләп яисә уңайсызланып китеп барырга тиеш тоелган кешенең күзләренә текәлде... Куе кашлар астындагы тирәнлектән ике көлтә коңгырт-кара нур сирпелгән. Бу битараф караш түгел. Шаяру, уйнау гына дисәң... Түгел! Үз-үзенә ышанычы, горурлыгы, мин-минлеге ташып торган кеше икән ич аның каршысында! Мунча себеркесе яфрагы кебек ябышкак бәндә булырга охшамаган бу... Бәлки бер-бер житди сүзе, уртаклашасы килгән фикере булгандыр, дип уйлап куйды ул үзалдына. Әмма күңелендә калкынып алган бу үзгәреш-икеләнүләрне йөзенә, күзләренә чыгармады. Дәшмәде, элеккечә үк битараф калганлыгын аңлатырга теләп, күзләрен генә читкә борды.

— Мин кереп урын ала торам. Көтәм...— диде кырыс, ләкин шул ук вакытта әчкерсез һәм ягымлы да тоелган калын тавыш. Тирән сулыш алып, ипле генә борылды да тәвәккәл адымнар белән китеп барды. Кире борылып карамады.

Үзалдына мыскыллы елмаю белән озатып калган иде аны Асия: «Бер дә харап, янәсе... Егерменче гасыр Дон-Жуаны... Каян килгән!.. Торган да артыннан йөгергән ди берәү...» Әмма шулай да, кайсыдыр яклары белән ошаган, үзенә җәлеп итеп өлгергән иде аны бу ир. Өстәвенә кызык та әле бераз... Кайчан һәм кайда тагы шундый җай чыгып торыр, бер мәзәк итеп кенә тыңлаганда ярар иде үзен...

Күңеле тартмады Асиянең. Әмма шулай да, шактый ук көттереп булса да, керде ул ресторанга. Иртәнгә чәйдән соң инде байтак гомер узган иде. Тагы күпме көтәсе дә мәгълүм түгел — буран. Самолетның кайчан очасын, белсә дә, бер алла гына белә бит әле. Димәк, барыбер тамак ялгап алу турында кайгыртырга кирәк булачак... Әлбәттә, беркадәр кызыксыну да үзенекен итте булса кирәк. Чыннан да, кызык ич: ни әйтергә тели икән ул аңарга, нияте нинди?.. Юк сүзен бар итеп бәйләнергә, вакыт узсынга бер күрүдә гашыйк булган ир-ат роле уйнарга җыенучымы? Әллә... Кем белә бит аны, карап торышка болай житди кешегә охшаган ич.

Ишектән күренүгә үк, урыныннан торып, кунакчыл хуҗадай мөлаем елмаеп каршы алды аны ир-ат:

— Бик вакытлы кердегез... Рәхим итегез, хәзер кайнар аш китерерләр,— дип, урын тәкъдим итте.— Күңелегез дә күтәрелер, җылынырсыз...

— Рәхмәт, мин туңмадым. Ачыкмадым да... Мин болай гына... Бераз утырам да чыгармын.— Әллә каян пәйда булган уңайсызлануын, тартынуын күпме генә яшерергә тырышса да, булдыра алмады, бер дә урынсызга кыбырсынырга кереште Асия. Гомер булмаган хәл — үз-үзен кулга ала алмый газапланды. Үзенең нинди хата җибәрүен, нинди уңайсыз һәм мескен хәлдә торып калуын ресторан ишегеннән атлап кергәч, өстәл

артына килеп утыргач кына аңлады. Бераү чакырды дип, таныш-белеш булмаган ир-ат артыннан, аны эзләп, ресторанга килеп керсен инде... Азмы-күпме горурлыгы калган хатын-кыз шулай итә аламы?! Ничек һәм нәрсә уйлап керде соң ул монда?.. Бу кадәрле дә җиңел акыллылык күрсәтер икән!.. Үз-үзен танымады, үз-үзенә нәфрәтләнде, гарьләнде Асия. Ләкин сер бирергә дә ярамый, соң иде инде, атлыйсы адымнар атланган... Шуны сизеп алуданмы — йөзендә ясалма елмаю нурлары кабынды аның.

— Ә сез дулкынланмагыз!.. Тынычланыгыз, тынычлан... Бүре түгел мин, ачыккан булсам да, бер юлга калдырып торырмын. Ашарга җыенмыйм үзегезне...

— Кем әйтте аны?! Кем дулкынлана? Мин бик тыныч. Миңа монда ошый. Дулкынланырга җыенганым да юк, уйлаганым да...— дип, гаҗәпләнүен җиткерергә ашыкты Асия. Әйткән сүзләренең җегәрен күтәрергә теләп, каян алдыгыз мондый сүзне дигән сыман, иңнәрен җыерып куйган булды, балкып елмайды. Ә күңелендә үз-үзен битәрләүдән туктамады: «Йә, нигә җебеп төштең!.. Ир-ат күргәнең юкмы?.. Авыз ачып сүз әйткәнче үк үтәдән күреп торалар үзеңне...»

— Үз-үзегезне дә битәрләмәгез алай, кирәкми!

Кычкырып көлгән булды Асия:

— Сез нәрсә, күрәзәчеме әллә? Күрәзәче булсагыз, бу юлы ялгыштыгыз, хаталандыгыз, иптәш.

Әмма күңелендә үз-үзенә булган ачу, нәфрәт арта төште. Адәм көлкесе ич, авызыңны ачмас борын, үтәдән күреп торсыннар үзеңне.

— Юк, мин күрәзәче түгел,— дип, җитди сүзгә күчте ир-ат.— Коньяк китертимме, шампанмы? — һәм эчкерсез, матур итеп елмаеп алды.— Күрәзәче булсам, сорап тормас идем, шулай бит?..

— Ә миңа барыбер.

— Димәк, акны?..

— Үзегезгә карагыз. Мин берсен дә эчмим.

— Менә монысы инде дөрес түгел... Очрашу хөрмәтенә бер рюмка гына булса да капмаган кеше юк.

— Димәк, бар.

— Бераз гына... Шушы буранлы көнгә үч итеп кенә?..

— Рәхмәт, мин җавап бирдем,— диде Асия. Соңгы җавап хәтта үзенә дә ошап куйган иде. Ниһаять, тынычланды булса кирәк.

Яннарына официант килеп басты. Ир-атның авызыннан чыккан һәр сүзне, кош тоткандай, үзенең кәгазенә теркәп барды. Һәм җәһәт кенә китеп югалды.

— Ә сез миңа ошыйсыз... Әле иртән үк, аэропортка килеп кергәч үк игътибар иттем мин сезгә,— дип, иркенләп сөйләшергә, комплиментлардан ятьмә үрергә кереште ир-ат.

Матур сүзнең хатын-кызга ошаганын һәркем белә. Әмма хатын-кыз, ул сүзләргә мөкиббән китеп, аларның табигатен, максатын аңламый дип уйлаучылар нык хаталана. «Ошыйсыз...» дигән сүзеннән үк аңлады, юнәлешне ачык тоемлады Асия.

— Күргән булсагыз соң!.. Шуннан ни була инде?

— Хәтта, гомеремдә беренче кат рейсны торкарлаган буранга рәхмәт укыдым.

— Һәм шул гомердән бирле мине эзәрлекләп йөрдегезме?..— дип, ирен читләренә тәкәббер елмаю төсмере чыгарды Асия. Чөнки хәзер аңа барысы да аңлаешлы һәм табигый тоела башлаган иде инде.— Буранга шатланган кешене күргәнем юк иде әле.

«Туташ үз-үзен кулга алды. Ирек куйсаң, сүзгә дә шактый төртмәле күренә икән үзе... Әмма беренче һәм иң кыен адым ясалган. Калганы инде, спортчылар теленда әйтсәң, «икенче сулыштан» тора. Хәзер, чама белеп кенә, дилбегәне кулдан ычкындырмый гына, алга таба кыймылдый башларга вакыт...» — дигән уй үтте ир-атның башыннан.

— Зинһар өчен, көлмәгез,— дияргә ашыкты ул.— Минем үзем дә сәер һәм көтелмәгәндә булды бу. Моңа, иң элек, сез үзегез гаепле. Белмисез генә, шундый матур һәм килешле атлап бара идегез... Һәм карашыгыз тагы, күзләр... Яшен ташы китереп суккан кебек булды...

Күтәрелеп, Асиянең күзләренә карап куйды ул. Көтмәгәндә очрашкан ике караш, бер-беренә тартылып, берара аерыла алмый тордылар. Аларның бу карашып торуы уен идеме, әллә инде шушы уеннарын чынга алып мавыгу идеме — моны алар хәтта үзләре дә аңлап өлгермәде булса кирәк. Шулай да, сынашу озаккарак сузылгач, иң элек Асия карашын читкә борырга мәҗбүр булды. Ни сәбәпледер, аның зәңгәр күзләре кысыла төште, ирен читләре тартышып-тартышып алды.

— Бөтен игътибарым сездә, тыңлыйм,— диде ул шундук, үзенең әлеге йомшаклыгын танырга теләмичә.

Ә күңелендә өстәл аша гына каршысында утырган ир-атка соклану туган иде: «Ә бит буй дисәң буе бар, төс дисәң — төсе. Мавыктыргыч итеп сөйләшә белә, киемнәре... Килешмәгән җире юк».

— Көләргә ашыкмагыз. Үзегезгә сокланып һәм хөрмәт белән караган кешедән көлү яхшы түгел, шулай бит?..

— Шулай бит...— аның урынсыз сүзен кабатлаудан тәм табып, янә үртәп алды Асия.

— Көләсез,— дип кенә җавап кайтарды ир-ат. Хатын-кызның төртмәле сүзе, әлеге очракта, үз итә төшүнең хәбәрчесе икәнлекне яхшы аңлый иде ул. Эчкерсез һәм ышанып сөйләшүеннән туктарга уенда да юк иде. Бераз уйга калып торды да үзалдына елмаеп алды. Сөйләргәме, сөйләмәскәме дип икеләнә калган иде булса кирәк. Дөресрәге, шул хакта иллюзия тудырып маташуы булды бу.— Каршыгызда утырганда — сизендегезме икән — мин берөзлексез, күзем сезгә төшкән саен, сокланып туймадым. Күңелемнән шигырь юллары кабатлап утырдым...

— Кызык,— дип куйды Асия, чынлап та тыңларга әзер икәнлеген төшендереп. Үз гомерендә әле берәүнең дә аңарга багышлап шигырь чыгарганы, шигырь сөйләгәне юк иде бит әлегәчә.

— ...Тез өстенә тезен куйган,
Алып булмый күзне шуннан.

Шул ике юлны кабатладым берөзлексез. Башка бер очракта, беләм, бу сүзләр соң дәрәҗәдәге мәгънәсезлек булып кына тоелырга мөмкин. Әмма сезнең каршыда утырганда — сәнгать!.. Есенин һәм Такташларың бер читтә торсын...

— Ә сез, хам гына түгел, шагыйрь дә икән ич болай булгач,— дип бүлдерде аны Асия. Дөрес, үзенә атап чыгарылган юллар ярамаслык түгел иде кебек. Үзенең өстенлеген һәм матурлыкларын, һәммә башка хатын-кызлар сыман, ул да яхшы белә иде.

— Ялгышасыз,— диде ир-ат һәм канәгать елмаеп алырга да өлгерде.— Мин шагыйрь түгел. Хәтергә генә төште, ишеткәнем бар иде... Чынлап та, күз явын алырлык чибәр идегез, матур утыра идегез... Хатын-кызның ярты гүзәллеге — аякларында. Әйе, мин моны ихластан әйтәм.

Йөзен чытып алган булды Асия — кем каршында утырам мин, янәсе. Аэропорт буенча яңгыраган чираттагы белдерү-хәбәр тукталырга мәҗбүр итте бу юлы ир-атны: «Уфа — Казан маршруты буенча... рейс... табигать шартларына бәйле рәвештә... тагы дүрт сәгатькә кичектерелә...» Ир-ат башын чайкап куйды. Ә Асия, коты очкан кеше сыман, башына ябышкан булды. Чынлыкта исә һәр икесе бу хәбәрне колак читләреннән генә уздырган кебек иде.

Күзләре шул мәлдә кабат очрашты. Йөзләренә, ирен читләренә сизелер-сизелмәс кенә елмаю чалымнары кунып узды.

Ул буранлы көнне шундук хәтердән сызып атарга, онытырга кирәк иде Асиягә. Уфадагы буран Уфада калырга, Казанга ияреп кайтмаска тиеш иде дә бит...

Буранлы көн үтте. Буранлы февраль еракта калды. Тик күңелдә кузгалырга иткән буран гына утыра алмады. Әледән-әле, бөтенләй уйламаган-көтмәгәндә, зилзиләләр кузгатып уяна да җанын әрнетә, иркенләп яшәргә, тотынган эшен күңел куеп эшләргә ирек бирми аптырата буран. Табигатькә ни?!. Табигать бер җилләп-давыллап ала да тына. Күңелдә, җанында кузгалмасын икән ул буран...

Яшәвенең мәгънәсе югалды Асиянең, көне — көн, төннәре төн түгел. Эшкә килсә, кулы эшкә бармады. Өйгә кайтып, өендә ямь таба алмый газапланды. Иптәш кызларының җыен юкны бар итеп сөйләшкәненә, һәр ике сүзнең береннән үзләренчә кызык табып көлешкәннәренә эче пошты аның. Корыны бушка кайтарып үзенә дәшүчеләргә чытык йөз белән җавап бирде. Юкка гына да кәефе кырыла торган булып китте, башкаларның кәефен кыруны да бар дип белми башлады. Бер сүз белән әйткәндә, кинәт кенә танымаслык булып үзгәрде дә куйды Асия. Турысын әйтеп сөйләшергә күнеккән Сания апасы әйтмешли, әллә шунда җен алыштырды үзен...

Шәһәр үзәгендәге беренче класслы ательеда тегүче булып эшли Асия. Монда күлмәк яисә костюм тектерү — күпләрнең хыялы. Мода артыннан калышырга теләмәгән хатын-кыз, бу ательега якынлаша башласа, кыбырсынырга керешә; ә инде ателье ишеген ачып, тупсадан атлап үткәндә — һич арттыру булмас — андый хатын-кызның тыны кысыла. Шуңа да әлеге ательеда эшләүчеләрнең дәрәҗә югары санала шәһәрдә, директорың да, министрың да бер читтә торсын. Кайда эшләве хакында кызыксынучыларга: «Йосыф — Зөләйха»да эшлим»,— дип җавап бирсәң, тегеләре инде, кагыйдә буларак, тел шартлата, «О-о-о!» — дип тә өстәргә онытмый.

Әнә шундый гадәти булмаган ательеда гади бер тегүче булып эшли Асия. Эш урыныннан канәгать, үзенең монда эшләве белән горурланып яши. Чөнки матур һәм модалы киемгә дефицит арта барган, әмма матур һәм килешле итеп кисеп-тегүчеләр, әҗәл даруы сыман, бик азаеп калган бер чорда — сиксәненче елларның башында — мондый урында эшләү килде-китте кеше булу түгел ул. Кешедә акча да җитәрлек. Ихтыяҗ һәм талым да бар. Ә кибетләр, складлар үтмәс товар белән тулган. Алгы ишектән кереп рәтле-башлы кием алам димә. Андый кием булса да, бары тик арттан, йә булмаса астан сатыла. Шундый чорда ателье ишекләренә барып капланмыйча, кая барасың?! Ательелар кыйммәткә тегә һәм шуның өстәвенә әле йә җиңе, йә бер балагы кыскарак чыга киемнең. Менә шунда инде «Йосыф — Зөләйха» искә төшә. Әйе, анда тегәләр. Ни гаҗәп: киемнең җиңе дә, балагы да тигез чыга әлеге ательеда. Тик тагы шунысы бар: анда да теләсә кемгә түгел, аерым кешеләргә генә тегәләр...

Кемгәме? Бу сорауны йә бик иртә картайган, йә артык соң туган кешеләр генә бирә торгандыр. Ә без беләбез һәм шундый җиңел сорауга да җавап таба алмый торучылардан хәтта көләбез дә әле. Кемгә булсын? Таныш-белеш һәм дус-иш өчен тегәләр «Йосыф — Зөләйха»да. Ә инде алардан да элгәрерәк кирәкле һәм кирәге чыгардай кешеләр житешә. Дөньяның аның, җүләр кеше әйтмешли, кирәге бетеп торганы юк. Кул — кулны, ике кул битне юа дигәннәре хак бит ул. Асия моның дөреслегенә үз тәҗрибәсендә ышанды. «Йосыф — Зөләйха»да эшли башлавына әле әллә ни күп вакыт үтмәсә дә, мондагы дөньяның җаена төшенеп килә инде...

...Әйе, барысына да шул буранлы көн гаепле. Менә әле хәзер дә,

ак буранны хәтерләткән туй күлмәгенә җөй салып утырганда, онытылып уйга калды ул... Уфа аэропорты. Халык белән шыгрым тулы зал. Каршысында гамьсез генә журнал актаргалап утырган ир-ат... Күз алдыннан китми йөдәткән мизгелләр... Буран. Бөтен әйләнә-тирәсен, бар дөньясын, күз алларын, хәтта күңелен буран — ап-ак буран урап алган.

Чү, колак төбендә аның тавышы яңгырый түгелме:

— Кызык бит, ә... Танышуыбызга санаулы минутлар гына, ә сез миңа иң якын кешем сыман тоела башлагансыз... Балачактан җитәкләшеп килгән дустым диярсең. Ә чынлыкта исә без — нибарысы кичектерелгән самолетның гади пассажирлары...

Берара дәшми-тынмый гына барды алар. Рәт-рәт булып тезелеп киткән ак каеннар ышыгында салынган тар сукмак очсыз-кырыйсыз кебек иде. Бәлки анда бернинди сукмак та булмагандыр әле. Шәһәр читендәге аулак каенлыкта шундый буран вакытында нинди сукмак булыр икән?.. Гаҗәп, гүя такыр юлдан атлап барган алар, сукмак юклыгы абайланылмаган. Котырынып искән җил авазы колакта эленеп калган бары. Өермә булып йөзгә, күзләргә килеп сыланган, әрсезләнеп куенга үтеп кергән ак җил һәм кар бөртекләре кайнар дулкын булып кына тоелган. Югыйсә, җүнле хуҗа урамга этен дә чыгармаслык күз ачкысыз буран булган. Үтә күренмәле юка оек-колготкидан көе буранга барып чыксын һәм шул буранның салкынлыгын тоймасын инде, ә...

Җылы һәм ышык аэропорт залында тар тоелды микәнни соң аларга?.. Күз алдына китерү мөмкин түгел хәтта: ничек инде үз ирегең белән буран кочагына, япан кырга чыгып китәргә кирәк? Унҗиде-унсигездәге яшь җилкенчәкләрмени?!

Басылырга уенда да булмый котырынган буранны кыл урталай ярып, кинәт Асиянең каршысына чыгып туктап калды ул.

— Ир кеше өчен иң кыены, иң авыры нәрсә икәнлеген беләсезме?

Күзләрен кыса төшеп, баш чайкады Асия, җавабы шул булды. Бүрегеннән кар коелды, керфекләренә кунган бәс салкынлыгы өтеп алды шунда. Башка берни хәтерләми.

— Белмисез шул. Сезгә җиңел... Ә ир-ат шул сорауны кайчан һәм ничек җаен туры китереп бирергә икән дип иза чигә.

Асия, башын күтәрә төшеп, бәсле керфекләрен ачты. «Тыңлыйм, йә, биреп кара соравыңны. Ул нинди хикмәтле сорау икән?» — дип әйтүе иде бу аның. Каршысында басып торган ир-ат ышыгында җил юк, буран да тынып калды. Кеше түгел, гүя җилкән иде ул. Шундый әзмәвергә сокланмыйча мөмкин идеме соң?! Аның киң иягенә, сәламәт кызыллык белән тулышкан йөзенә, көзге усак яфракларыдай тырпаеп торган колакларына күз салырга өлгерде ул. Сулышыннан, һәр хәрәкәтеннән тазалык, гайрәт һәм көч ташып тора иде бит аның. «Таянып җилкә... ышыкланыр ир...» дигәннәрен күп мәртәбәләр ишеткәне бар иде. Күрәмсең, аның кебекләр хакында әйтелә торган сүзләрдер...

— Үзебез таныштык та кебек инде,— дип, тын гына сөйләргә кереште ул.— Ә чынлыкта бер-беребезнең исемен дә белмибез... Исемегезнең дә матур буласын чамалыйм чамалавын. Ничек уйлыйсыз, бәлки танышырга вакыттыр инде безгә?..

Тартынып, олы үтенече, гозере булган кеше сыман уңайсызланып сөйләшә иде ул. Ә җитдилек, оялчанлык бермә-бер килешә үзенә.

— Шул булдымы авыр сорау? — дип, рәхәтләнеп көлеп җибәргән иде ул чакта Асия.— Ай-һай авыр сорау икән... Шуны сорар өчен буранлы япан кырга алып чыктыгызмы?..

— Авыр сорау...— дип кабатлады җилкән сыман калкып торган ир-ат. Ә үзе тагы да җитдиләнә төште.

— Исемем Асия булыр. Йә, тагы нинди сорауларыгыз бар? Тартынмагыз, бирегез, бир сорауларыгызны — берочтан һәммәсенә җавап бирәм.

Шул чактагы теленә салынулары өчен менә хәзер генә кыенсынып

куйды ул. Хатын-кызга үз-үзен житди һәм итагатьлерәк тотканда да зыян итмәс иде бит. Малай-шалай белән сөйләшкәнмени, бер теленә хуҗа була белмәгән...

Халык белән шыгрым тулы залда үз-үзенә ышанычы ташып торган, уңайсызлануны белмәгән ир-ат шунда әллә нидән генә чарасыз калып торды. Моны ачык тойды Асия, хәтта тавышы үзгәрде аның, һәм сүзе алдыннан тирән итеп сулыш алды:

— Асия... Асия... Мине Арслан дип белерсез.

Үз-үзеннән уңайсызланган кешедәй тик басып торды ул аның каршысында. Уң кулындагы бияләй-перчаткасын салып, Асиянең якасына кунган карларны сыпырып-сыпырып төшерде. Шунда, очраклы рәвештә генә, кайнар бармаклары белән аның муенына кагылып үтәргә тиеш иде ул. Аннан: «Күшеккәннәр түгелме, җылытырга кирәк үзләрен»,— дип, алсуланып янган бит очларын үзенең дәү уч төпләре белән капларга җөрьәт итәргә... Бусы да барып чыкса, тора-бара тагы да кыюлана төшеп, көтмәгәндә Асиянең билләреннән кысып алырга, иреннәренә тартырга...

Әмма барлык ир-егетләр дә сүз берләшкәндәй бер тәртиптә башкара торган бу кыланышларны ул кабатламады. Асия өчен көтелмәгән хәл иде бу — шуңа да гайре табигый тоелды... Ә теге традицион күренеш, билгеле инде, хатын-кызның үпкәләве, яисә артык батыраеп киткән ир-атның яңак төбенә менеп төшүе белән үк тәмамланырга тиеш иде.

Ялгышкан булып чыкты Асия. Арслан атлы ир-ат башкаларга охшамаган иде. Үз дәрәҗәсен белеп кенә сөйләшүе, хатын-кызга мөнәсәбәттә игътибарлылыгы белән җәлеп итте дә бугай инде ул аны. Бит урталарыңны җылытам дип тә үрелмәде, иреннәрең күшеккән дип тә юхаланмады, бер мәртәбә карга да төртеп екмады ул аны. Көрт ерып, тын гына, иплә генә янәшәсеннән атлады. Әледән-әле каршысына чыгып, аны салкын җилдән каплады.

— Асия...— дип кабатлады ул, аның исеменә кат-кат игътибар итеп.— Исемегезнең нинди мәгънә йөрткәнен беләсезме соң?

Телен йоткан идеме әллә Асия, бу юлы да баш чайкау белән генә җавап кайтарды. Үз исеменең нинди дә булса мәгънә аңлату ихтималы турында уйлап та караганы юк иде аның. Исемме? Исем!

— Асия... Дәвалаучы кыз, тынычландыручы, юатучы дигәнне аңлата сезнең исем.

— О-о-о,— дип, чаяланып көлгән иде Асия. Ул ясалма көлүе нигә кирәк булды икән тагы...— Сез зур белгеч икән. Хатын-кыз исемнәре белгече...

— Ялгышасыз,— диде ул, үртәлми генә.— Минем Асия исемле сеңелем бар. Шуңардан хәтергә кереп калган.

Буран басыла төшкәнне чамалапмы, әллә аякларына салкын йөгерә башлаган идеме — алар кире борылдылар. Аэропортка кайтып җиткәнчегә кадәр бер-беренә ләм-мим дәшмәделәр кебек. Уртак сүз булмаган, уртак тел табылмаган, күрәсең.

Шул вакытта сөйләшеп китә алмауларының серен әле менә хәзер, байтак вакыт узгачтын гына аңлый алды кебек Асия. Чын ихластан сөйләшергә, танышып аңлашырга омтылган ир-атка гел киресен тукып торган лабаса ул. Үзенең ни сөйләгәнен, нигә елмайганын, нәрсәдән шулай эче катып көлгәнен абайламаган. Хәер, моның сәбәпләре дә бардыр, әлбәттә. Соңгы араларда мондый очрашу-танышуларга юлыкканы булмаган аның. Билгесезлек, әчке бер тынгысызлык һәм дулкынлану да тәэсир иткәндер. Арслан — хатын-кызны битараф калдыра торган ир-атлардан түгел... Хәер, әйтәсе әйтелгән, көләсе көленгән, терсәкне тешләп булмый ич инде.

Алар аэропорт залына кире әйләнеп кергәндә, Казанга очу рейсын игълан иткәннәр иде инде. Самолеттагы урыннары янәшә туры килмәде. Хәер, Арслан үзе дә моңа омтылмады булса кирәк. Ничектер шулай

килеп чыкты, әллә кешедән, әллә бер-береннән уңайсызландылар, кешечә хушлаша да алмадылар. Ә Казанга килеп төшкәч, Арсланны чәчәк тоткан ике хатын-кыз каршы алды. Асиягә борылып кул да изи алмый калды ул хәтта. Самолеттан ерак түгел генә көтеп торган җиңел машинага утырып китеп бардылар... Менә шул китүдән суга төшкәндәй юк булды әлеге дә баягы сәер Арслан.

Арслан китте. Асиянең кайда һәм кем булып эшләвен, адресын, хәтта фамилиясен дә белмичә китеп барды ул. Ә инде хәзер, күпме генә эзләсә дә, ул аны таба алмаячак. Кем белә, бәлки эзли дә торгандыр... Әмма ничек һәм каян эзләргә, ничек табарга тиеш соң ул аны? «Уфа аэропортында бергә самолет көткән Асия, син кайда?..» — дип, урам уртасына чыгып кычкырсынмы? Әлбәттә, күпме генә эзләсә дә, ул аны таба алмаячак. Кызганыч... Ә бәлки ул Асияне чынлап та эзли торгандыр? Шулай уйлана, шулай уйлап үртәлә иде Асия бу соңгы көннәрдә...

Кызык шул тормыш дигәнең... Юлга чыксаң, әллә ниткән күрмәгән-белмәгән кешеләр белән очраштыра, таныштыра ул сине. Ә үзең көткән, үзең эзләгән белән — бер шәһәрдә, бер урамда яшәсәң дә — кайчак очраша, кавыша алмый иза чигәсең. Гомерең узып киткәнен дә шулай сизми, абайламый калуың бар. Кызганыч, кызыклы ир-ат иде Арслан. Андыйлар хакына утка керсәң дә үкенерлек түгел, кулын сузып, аргы ярда көтеп торса — кыл буйлап дәрья кичәргә мөмкин... Кызганыч...

Кем белә, бәлки язмыш мәрхәмәтледер алар өчен. Бүген булмаса, иртәгә, кайчан да булса бер очрашырлар да әле. Тик кайчан — бер елдан, ун елданмы?.. Хисләр суынгач, маңгайга җыерчыклар иңгәч... Ул тикле гомер узгач, алар бер-берен танымаячаклар да. Арслан да аны эзләр-эзләр һәм өметен өзәр, онытыр. Вакытка бирешмәгән хәтер, вакытка бирешмәгән хис булмас.

Ә менә Асия аны таба ала. Тели икән, бүген үк, менә хәзер үк. Бик җиңел генә таба ала. Уфада самолетка утырту башлангач та, янәшәсеннән узып барышлый, Арслан аның кулына кечкенә кәгазь кисәге төртеп киткән иде. Асия әлеге кәгазьне шундук уч төбенә кысып йомарлады. Бөгәрләнгән кәгазь кисәге, ничектер, кесәгә тыгылган да шунда сакланып калган булып чыкты. Ул хәзер аның эш өстәлендәге тартмада саклана, һәм әнә шул нәни генә кәгазь кисәге ике кешенең очрашу-очрашмавын хәл итәргә сәләтле. Чүп савытында урын табарга тиеш булган кәгазь тылсымлы бер көчкә ия хәзер. Ләкин... Асия һичкайчан һәм һичбер вакытта да үзе беренче булып ир-атка шалтыратачак кеше түгел... Шалтыратсын да ди... Аргы якта кырыс тавыш ишетелгәч, йә, ул ни дияргә тиеш? «Бу мин, Асия... Арслан атлы кеше сез буласызмы? Минем сезне күрәсем килә»,— дияргәме? Юк, ул бервакытта да ир-ат халкына беренче булып шалтыратачак кеше түгел. Хәзер түгел, кыз вакытында да егетләрне юллап телефон трубкасына үрелмәде.

Шулай уйлады Асия. Шулай уйлап, үртәлә-үртәлә, үзен юата килде. Әмма мартның шулай ук бер җиңелчә буранлы көнендә, урамдагы телефон будкасы янында туктап, кесәсеннән әлеге телефон язулы кәгазьне чыгарды. Каушап, ашыгып, кабаланып, номерны җыйды.

— Тыңлыйм сезне...— телефоннан ниндидер хатын-кыз тавышы ишетелгәч, Асия тагы да каушабрак калды. Шактый дәшми торгач кына:

— Миңа Арслан кирәк иде...— дип чак әйтә алды.

— Арслан Сәхипович киңәшмә үткәрә,— дип җавап бирде тавыш һәм кырыс кына сорап куйды.— Сез аның кеме? Ни йомыш белән шалтыратасыз? Арслан Сәхиповичка ни дип тапшырырга?

Асия дәшмәде. Телефон трубкасын әкрен генә урынына элде дә урамга чыкты. Урамда буран уйный иде әле. Асия кулындагы телефон язулы кәгазьгә, гаҗәпләнгәндәй, озаклап, аптырап, нишләргә белмичә карап торды. Аннан соң, кинәт бер карарга килеп, әлеге кәгазьне кисәкләргә ертып ташлады. Ертып ташлады да ашыгып китеп барды. Әйтерсең, әле генә үзе шалтыраткан телефон будкасыннан тизрәкераклашу

аны ниндидер бер ояттан, яман эштән, ямьсез нәрсәдән алып китә, коткара сыман иде.

Күңелдәге буран да тынган кебек иде инде...

### 3

Гадәти бер эш көне иде. Ательенең кабул итү бүлмәсендә утыручы кыз, Асияне үзе урынына калдырып, кич якынлашып килгәндә ашыгыч рәвештә каядыр китеп барды. Кеше белән сөйләшү-аралашудан һәрчак бер ямь тапкан Асия өчен моның берниндә кыенлыгы да юк иде. Бик теләп риза булды.

«Йосыф — Зөләйха»га, буй җиткән кызын ияртеп, мәһабәт гәүдәле, урта яшьләрдәге ханым килеп керде. Пөхтә һәм нәзакәтле үзе. Ишектән күренүгә үк, аның андый-мондый гына клиент түгеллеген абайлап өлгерде Асия. Өстендәге киемнәре шул хакта сөйли. Баш киеменнән аягынача — иллә булган, күзгә чалынган нәрсә табалмассың. Хатын-кызның йөрәк итен ашый андыйлар. Ә өстендәге туны — гүя ай яктысында елкылдашкан көмеш-тәңкә кар бөртекләреннән — затлының да затлысы.

Соклануын чыгармаска тырышып, иплә генә утыруында булды Асия; исең киткән икән иске чикмәнгә, янәсе, күргән бар... Ә менә көнозын көнбагыш ярып утырган, мөрәҗәгать итүчеләргә тырт-мырт җавап кайтарудан башка эш тапмаган смена башлыгын кинәт алыштырып куйдылармыни... Ашалган-ашалмаган дип тормады, көнбагышны алдына җәелгән газетасы-ние белән җәт кенә чүп чиләгенә шудырып төшерде дә аягүрә торып басты. Шул арада көзгегә күз салып, авыз читләрен сыпыргалап алырга, итәкләрен тартып куярга, маңгай чәчләрен тәртипкә китерергә өлгерде. Иллә дә өлгер, уңган икән ләбаса... Ишектән керүчеләрне балкып, яктырып каршы алды ул. Бу хәлне күргәч, бермә-бер арта төште Асиянең кызыксынуы.

Смена башлыгы — үз дәрәҗәсен гадәттә яхшы белгән хатын — кулын суза, билен бөгә төшеп, мөдир кабинетына таба озата китте үзләрен. Ул да түгел, талгын тынлыкта изрәгән бүлмә һәм ишекләргә җан керде. Бик җаваплы заказлар гына кабул итә торган кисүчеләр иңсәләренә үлчәүләрен салды, кәгазь-каләм тоткан цех мөдирләре хәрәкәткә килде. Кеше-кара күзенә чалынмый торган төргәк-төргәк материаллар күтәреп — берсен җилкәсенә салып, икенчесен култык астына кыстырып — склад мөдире арлы-бирле йөгерергә кереште. Көне буе ак гөмбә сыман урыныннан кузгалмый утырган, сораучыларга да: «Ул юк, киңәшмәдә»,— дип җавап бирергә боерган ателье мөдиренең дә итәгенә ут капты диярсең... Чыгымчылаган ат сыман, юк эшен бар итеп, берничә кабат кабул итү бүлмәсенә чыгып урап керде. Әйтер сүзе, бәйләнер сәбәбе булмаса да, очраган һәр кешегә бармагы белән янап узды, алсу канәфер сыман итеп буялган калын иреннәрен бөреп-бөреп, тәртипкә чакырды. Түзмәде, соңгы чыгуында Асия янына да килеп китте:

— Син нигә утырасың әле монда?..— дип, кырыс кына пышылдады. Җавап көтеп тормады, бармак янады.— Кара аны, юкка-барга кысылма. Күкрәгеңне болай киереп утырасы булсаң...

Бер урында тукталу кая, чыгымчылаган ат ич ул — башлаган җөмләсен тәмамларга да онытып, кире кабинетына кереп йөгерде.

Кәефе китмәде Асиянең — гадәти хәл. Мөдирнең сәер гадәтләренә күптән ияләнгән, күнеккән инде алар. Тикшерү-фәлән килсә, йә булмаса зур житәкчеләрдән берәү кагылып узганда, шулай бер җилгереп ала да, аннан тынычланып, кире үз эзенә кайтып төшә ич ул.

Хәер, мөдирнең тагы бер сәер гадәте бар икән бит әле: яшь, чибәр хатын-кызларны күралмый. Дөрес, чибәрлеккә аның үз карашы — йомры һәм тазалыкка тиенгән туташларга бермә-бер кыенгарак төшә. Ә инде бизәнеп-ясанып һәм матуррак итеп киенеп тә килгән чагың булса, рә-

хим-шәфкать көтмә. Барыбер бер кимчелегеңне таба. Тапмый икән, болай гына, бер сәбәпсезгә дә төртмә сүз әйтми уза алмый. Бу коллективта мөдиргә үпкәләү гадәте юк, елмаюдан башка тойгы уятмый аның тешләп-чеметеп узулары. Асиянең дә әлегедәй «тәмле сүз»ләрне беренче генә ишетүе түгел. Соңгысы да була күрмәсен... Мөдирләре бәйләнүдән туктаса, чаярак хатыннарның хәтта моңарга эче поша, аңарга үпкә белдерергә дә күп сорамыйлар:

— Нәрсә, Әнзия Закировна,— диләр,— төсем, кыяфәтем качканмы әллә?— диләр.

Ә мөдирнең исә авыз ерыла, турсаеп барган җиреннән балкып куя, ташлагыз инде шуны дигән сыман, кулын селтәп, җәт-җәт китеп бара. Дөрес булса, яшь чакларында иллә дә кәттә хатын булган диләр үзен. Шул кәттәлеге аркасында гына тормышка чыгарга өлгерми калган, «чибәр туташ» булып йөри торгач, сизми дә калган яшьлеге узганлыкны, «әбигә» әверелгән. Әйтеп кара әби дип, ишетсә яисә җиткерсәләр — тетмәңне тетәр, тузганак итеп очырыр...

Хатын-кыз өстенлек иткән коллективта «чыбыксыз телефон» аеруча яхшы эшли торган була. Әллә ни арада хәбәр таралып, кабул итү бүлмәсенә кереп-чыгып йөрүчеләр саны артканнан-арта барды. Яңалык иң ерак почмактагы цехларга да барып ирешкән булып чыкты.

— Тунын шәп диләр, күрдеңме?— дип пышылдады кемдер Асиянең колагына.

— Кем соң ул? Нинди хатын?..

— Универсаль база директорының хатыны!.. Шуны да белмисеңме, ну-у-у, Ася?!.

Ул да түгел, мәһабәт ханым үзе кебек үк тулы гәүдәле, кышка кергән тай сыман төз һәм нәзакәтле яшүсмер кызын ияртеп, яңадан кабул итү бүлмәсенә әйләнеп чыкты. Култык астына үтә дә серле төргәк кыстырган ателье мөдире әлеге дә баягы Әнзия Закировна янәшәсеннән атлый иде.

— Машина килгәнме?.. Карап кер әле,— дип бармак төртте ул каршыларына кыяр-кыймас муенын сузып якынлашкан смена башлыгына.

Тегесе исә, әйтерсең, шул боерыкны гына көтеп торган, ай күрде, кояш алды — урамга чыгып керде:

— Килмәгән, Әнзия Закировна.

— Әйбәтләп карадыңмы?

— Бик әйбәтләп карадык, Әнзия Закировна.

— Ярар, бераздан тагы чыгып керерсең.

— Бераздан тагы чыгып, тагы бик әйбәтләп карап керермен, Әнзия Закировна...

Медер-медер үзара ниләрдер хәбәрләшеп алды мөдир белән кунак. Яңадан кабинетка әйләнеп керү уңайсыз булгандыр, болай вакыт узсынга гына дип, күргәзмәдә торган киемнәрне, килеп-китүчеләргә тәкъдим ителә торган «ширпотреб» тукымаларны караштырырга керештеләр. Һәр тукыма янына килеп тукталыш ясаган саен, мәһабәт ханымга серле караш ташлап елмайган булды мөдир. «Бу нәрсә инде сезнең өчен»,— янәсе... Кулын гына селтәми.

Нәзакәтле ханым йөзенә ул-бу чыгармады, Әнзия Закировнага охшатып, борынын да җыермады. Үз дәрәҗәсен белеп кенә, бик кызыксынган атлы булып, ни күрсәтсәләр, шуны мавыгып карап йөрде. Хәтта күрсәтүчеләрнең, алардан да болайрак, читтән күзләп торучыларның күңелен күрү өчен, матур-матур сүзләр дә әйтеп куя иде әле.

Яшүсмер кыз өлкәннәргә охшатып икейөзлеләнә алмый иде, чәшке тиресеннән тегелгән туны җиңен сыпыргалап, бер читтә тик басып торды. Әнисенең берничә кат: «Кара әле, кызым...»— дип әйткәннәренә дә чытык йөз белән җавап кайтарды.

Ә инде тора-бара мәһабәт сынлы кыз ияләшә төште булса кирәк, үзенә каныгып торган әнисенә турысын гына әйтте дә салды:

— «Йосыф — Зөләйха» дигән буласыз... Бик харап икән! Монда йөргән заказчикларын әйтер идем. «Импорт»ка житәме соң!..

Ателье мөдире, кызның күнелен күреп, рәхәтләнеп кычкырып көлде. Үзенең кайда һәм кемнән, кемнәр каршысында көлүен онытып көлде. Бер дә көлми диләр, көлә белә икән ләбаса Әнзия Закировна да...

Кызның әнисе исә, иреннәрен ачып, бер-берләренә кысылган ап-ак тешләрен һәм, аңлашылса кирәк, алтын аңкавын күрсәтеп алды: «Телеңне тешлә»,— дип әйтүе иде бу аның. Күренеп тора, зәвыклы һәм нәзакәтле генә түгел, сабыр һәм тыйнак та була белә икән үзе. Аны күреп тә сокланмау мөмкинме икән... Игътибарны жәлеп итү генә түгел, балкып, үзенә тартып тора. Асия аның һәр хәрәкәтен, һәр сулышын диярлек күздән ычкындырмыйча, тоеп, күзәтеп утырды. Сокланып, көнләшеп күзәтте ул аны: бар бит бәхетле кешеләр!.. Тынычлыгын, үзүзенә булган ышанычын гына кара син аның... Үзен күзәтүчеләр ишек саен, ярык саен булуын белгән хәлдә дә ни гомер ипле генә басып тора, кабаланмый, кыбырсынмый. Урынсыз сүз, жайсыз хәрәкәт юк, ризасызлык чалымнарын һич күрсәтми, берөзлексез һаман балкыпмы балкый... Хәер, нигә дип соң әле ул үзен башкача тотсын икән?!. Нинди борчуы бар да, өендә ние житешмидер дип уйлыйсыз аның?... Юк, көнләшми булдыра алмады Асия бу хатыннан.

Кабул итү бүлмәсендәгеләр кинәт жанланып куйды. Киереп ачылган ишектән ательега ниндидер ир-ат кереп килә иде. Керүчене иң элек күреп алган ателье мөдире, үзен белешмичә, алга таба сөрлегеп куйды:

— О-о-ой, Сәхипович!.. Көттереп кенә киләсез, Сәхипович...

— Ну, әтием, без монда целый сәгать көтеп торабыз,— дип, буй житкергән кыз да шыңшып алды.

Бүлмә йөзеп китте. Берсен икенчесе уздырып ыгы-зыгы килгән кешеләр гүя томан артында калып эределәр. Тәрәзәләр дулкын сыман жыерылып, куырылып куйды. Утырган жиреннән авып китүдән куркып, күз аллары караңгыланган Асия ике кулы белән өстәл тактасына ябышты...

Колак төбендә умарта күчемени — әллә быжылдыйлар, әллә безелдиләр, һәммәсенең телендә бер үк сүзләр:

— Сәхипович...

— Арслан Сәхипович...

Арслан! Асия утырган өстәл шулай урнаштырылган иде: ишектән кергән һәр кеше бу өстәл артында утыручы белән шундук йөзгә-йөз туры килә. Әмма Арслан — әллә күрмәде-искәрмәде, әллә күреп тә танымады — Асиягә игътибар бирмәде. Ишектән кермәс борын ук сырып алганнар иде инде үзен. Кемнең нәрсә дигәнен, кем ни әйтергә теләгәнне, белсә дә, алла үзе генә белгәндер. Ләкин мөдир тавышын башкаларныкы белән бутау мөмкин түгел:

— Әйдәгез, Арслан Сәхипович, әйдәгез, кабинетка рәхим итегез. Чәйләп, кофелап алырбыз...

— Какой-такой кабинет... Күпме көтәргә була... целый сәгать...

— Юк, юк, чәй эчерми жибәрде юк Арслан Сәхиповичны... Жибәрәм диме соң?

Ни эшләргә белмәде Асия, япан кыр уртасында берьялгызы калгандай хис итте үзен. Әллә үзәк өзгеч салкын жил исә, әллә баш түбәсендә үк эленеп торган кояш нурлары көйдерә — аңламассың. Яшеренер, ышыкланыр урын булса икән... Тора-бара хәтта кулларын куяр урын, күзләрен текәр нокта таба алмый иза чикте ул. Ник бер хәйлә, моннан чыгып котылу өчен ник бер жай күренсен шунда! Үч иткәндәй, ыгы-зыгы һаман да арткannan-арта гына бара. Ә ул түзә... Әмма озакка түгел, болай дәвам итә алмый. Арсланның карашы башка тарафка төбәлгәнен көтеп алды да, кул астына эләккән беренче кәгазьне тотып, урыныннан кузгалды ул. Тегү-кисү цехларына илтә торган ишек артына кереп югалды.

Кире әйләнеп кайтканда, кабул итү бүлмәсе бушап калган иде инде.

Әмма тынлык белән хозурланыр өчен ара калдырмадылар Асиягә. Ялт итеп, янына Әнзия Закировна килеп җитте.

Олыгаеп килгән, әмма шул олыгаюы белән һич килешә алмыйча үзүзен дә, әйләнә-тирәсендәгеләрне дә тинтерәтеп бетергән, гаилә бәхетеннән мәхрүм ялгыз хатын-кызларны күргәнегез бардыр. Яшьлекләре, иратны җәлеп итәрлек матур чаклары узуны аеруча тирән, нииндидер сәер тетрәнү белән кичерә торган хатыннар була. Кулында дан-дәрәҗә, кесәсендә акча, өстендә кием-салым, фатиры, бакчасы дигәндәй, тагы әллә нинди шартлары, мөмкинлекләре бар. Нибарысы бер нәрсә — яшьлек һәм шул яшьлек белән бергә тән матурлыклары узган. Кайтмаска, мәңгегә ташлап киткән шул яшьлекләре өчен алар үзләрен түгел, башка, яшьрәк хатын-кызларны гаепле саный, санау гынамы, күралмый башлый. Әйтерсең, нәкъ менә шулар аның яшьлеген урлаган, матурлыгын тартып алган.

Өстенә ташкын булып кубарылып килгән, болыт сыман тәрәз яктысын томалап куйган мөдир каршысында берьялгызы торып калды Асия. Килә-килешкә, зәһәр елмаюын тыя алмый, кинаяле рәвештә эчен бушатырга кереште Әнзия Закировна:

— Нәрсә?!— дип аваз салды иң элек. Һәм калтыранган иреннәрен бөреп-бөреп, дәһшәтле кыяфәт алды.— Нәрсә анда, күзләреңне тасрайтып чыгып утыруың гына җитмәгән идеме?! Биек үкчәләр киеп, тып-тып китеп барган буласың... Нечкә билеңне, йомры сыйракларыңны күрсәтергә булдыңмыни? Ходаем, ул кара капроннарыңны киеп килмәсәң, игътибар итмәсләр дидеңме, эчең поштымы?.. Ул арт саннарыңны шул тикле уйнатмасаң канә, чабышкы ат түгелсеңдер ич! Ай, җаным, ай, харап бит, ә?! Кара син аны, кемгә нәфесен сузып маташкан була...

— Рәхмәт,— дип бүлдерергә ашыкты Асия. Юкса, әллә ниләр ишетүең бар.— Рәхмәт, Әнзия Закировна!..

Күзләреннән яшь бәреп чыкты, тамагына авыр төер утырды аның. Үзенең кыяфәте, торып китеп баруы белән мөдирнең кәефен кырганлыгы, Арсланның үзен күреп калган булу ихтималы турында да уйларлык хәлдә түгел иде Асия бу минутта.

## 4

Икенче сменадан кайтканда ательеда эшләүче хатын-кызлар, гадәттә, кичке урамга төркем-төркем булып чыгалар. Вакыт шактый ук соң, шәһәр урамнары бушарга өлгергән була. Ул кичтә Асия берәүне дә көтеп тормады. Көндезге очрашу вакытында талпынып калган күңеле һаман булса утыра алмыйча, каядыр ашкына иде әле аның. Андый чакта ялгызың гына калудан да кулайрак ни булырга мөмкин?

Март башы... Бер карасаң, кыш әле дәвам итә, бирешергә исәбе дә юк. Әмма иске таш диварлар белән әйләндереп алынган борынгы шәһәр уртасында да инде яз сулышы, яз рухы һәрдаим сиземләнеп тора. Күзләрдән дә элгәрерәк күңел тоя шул үзгәрешне. Шуңа җилкенсенә, шуңа тынгысызлана ул, әнә. Яз галәмәте...

Ә күз алдында һаман да бер үк вакыйгалар — бүгенге очрашу. Күргән-ишеткәннәрен ничәнче кат барлый икән инде ул... Нигә барлый, нигә оныта алмый ул бу очрашуны?! Бәхеткә ирешкән ул гаиләгә аның нинди мөнәсәбәте бар? Арслан хакында уйларга, үзенә сәлам бирү түгел, күз төшереп алырга да вакыт тапмаган ир-атны искә алу нигә кирәк?..

Иң зур тәэсир ясаганы, әлбәттә, көтмәгәндә ательега килеп кергән һәм күпләрне аягүрә бастырган ханым иде. Үзенең тышкы кыяфәте һәм киемнәре белән генә түгел, барыннан да элек, тыныч һәм тәкәббер горурлыгы, әллә каян сиземләнеп торган, күзнең уңын алырлык маһабәтлеге белән җәлеп итте бугай ул игътибарны. Җитмәсә, Арсланның хатыны булып чыкты тагы. Бу соңгысы аның күңелендәге кызыксыну, көнләшүләр-

не бермә-бер, юк, дистә мәртәбәләр арттырып җибәрде.

Ә Арслан?! Айдан килеп төштеме ул? Җир астыннан калыктымы? Әллә язмышның Асияне сынау өчен махсус оештырган бер-бер хикмәте булдымы?.. Ә Энзия Закировна?.. Ателье мөдиренең беркем каршында да ул дәрәҗә коелып төшеп, ярарга тырышканлыгын күргәне юк иде Асиянең. Арслан шундый мәртәбәле кунакмы?! Көненә дистәләгән зур-зур житәкчеләр, дәрәҗәле кешеләр һәм аларның хатыннары, туганнары, уллары-кызлары йөри «Йосыф — Зөләйха»га. Керәләр һәм, кабул итү бүлмәсендә тоткарланмый гына, ишекләре кызыл күн белән тышланган кабинетка узалар. Идән астында йөргән күселәр сыман, кеше-кара күзеннән яшеренеп, кыштыр-кыштыр киләләр, пыш-пыш сөйләшәләр, майталалар, хәл итәләр... Һәм, ничек килеп кергән булсалар, шулай ук тавыш-тынсыз гына үз юллары белән китеп тә баралар...

Ә Арслан?! Арслан шулардан да өстенме? Нинди хикмәтле өстенлек икән ул? Үзе генә түгел, хәтта хатыны, үсмер кызы да башкалардан аерылып тора аның. Мөдирне елмаерга, бил бөгәргә мәжбүр иткән, бөтен ательены аякка бастырган нинди хикмәт, дәрәҗә икән ул? Арслан... Арслан Сәхипович...

Үзәк урам белән бераз баргач, автобус тукталышына илтүче тын тыкрыкка борылды ул. Уйлары һаман бер тирәдә... Ләкин күп китәргә өлгермәде, янәшәсендә генә музыкаль аһәң белән машина кычкыртканны ишетеп, сискәнеп тайпылырга мәжбүр булды. Борылып карасa, ул атлап барган тротуарга елышып ук, ак «Волга» килеп туктады. Асия аңымоны уйларга да өлгермәде, машинаның арткы ишеге ачылып китте һәм, иелә төшеп, аннан зур гәүдәле ир-ат килеп чыкты. Арслан?!. Әле яңа гына үзенең мажаралы образы, буй житмәс дәрәҗәсе белән Асияне таң калдырып киткән Арслан аның каршысында басып тора иде.

— Асия,— диде ул, көтелмәгән очрашудан каушый калган хатынга якынлашып.

— Арсла-ан?..

Гүя Асия түгел, аның җаны дәште бу исемне. Зиһененә килеп өлгермәгән иде әле ул. Бер-беренә сүзсез генә карашып тордылар. Тын һәм аулак тыкрыкта алардан башка ник бер җан иясе булсын! Баш очындагы баганадан төшеп торган тоныk яктылык та сулыш алмый торды, машина һәм шофер таш сынга әверелде. Алар икәү генә... Гүя, гомер буе бер-берен эзләп, юксынып яшәгән гашыйклар очрашты. Сүзләр артык, сүзсез дә аңлаешлы бәхет мизгеле кебек иде бу.

Ни дәшәргә, нәрсәдән башларга белми байтак торды бугай алар. Серле тынлык шактый дәвам итте. Аяклар тораташ сыман хәрәкәтсез, хәтта сулыш алырга да кыймадылар кебек. Ә күзләр, магнитланган сыман, бер-береннән тайпылмады. Шунысы гаҗәп: сузыла төшкән бу тынлыкны өзеп дәшүче Асия булды:

— Арслан,— диде. Бу юлы инде рухы түгел, үзе дәште.— Син нишләп йөрисең монда?

— Ә син?..— дип, сорауга сорау белән җавап кайтарды ир-ат. Шунда куе кара мыек читләреннән йөзенә ягымлы һәм җылы елмаю таралды.

Бу ягымлы җылылык Асияне сискәнергә мәжбүр итте.

— Минме,— дип, кабаланып, ялганда тотылган кеше сыман җавап бирергә ашыкты ул.— Эштән кайтышым, Арслан...

— Ә мин сине каршы алырга килдем, Асия. Рәхим ит машинага!

Икеләнеп торырга урын калдырмаслык тәвәккәллек белән кулын сузды Арслан. Асия, таеп егылудан курыккан кешедәй, үзенә сузылган кулларга тотынды.

## 5

Шәһәр кызы иде Асия. Ул Казанда үсте. Ата белән анага бер бала иде. Бердәнбер булгач, ярату, иркәләүләрсез генә дә булмагандыр. Эти-

се — елгачы, Идел-Кама буйлап төрле калаларга йөк ташучы баржада капитан ярдәмчесе. Әнисе — укытучы, шәһәр үзәгендәге мәктәпләрнең берсендә завуч, ягъни укыту эшләре бүлеге мөдире. Аңлашылса кирәк: Асия — яхшы гына хәлле гаиләдә үскән кыз. Сораганын — бирделәр, теләгәнен — сатып алырга омтылдылар. Әтисе дә, әнисе дә «юк» дигән сүзне ишеттермәскә тырыштылар бердәнбер кызларына. Укытучы гаиләсендә үскән бала буларак, заманына күрә яхшы гына тәрбия дә алды.

...Тәрбия алды дидем дә, үз-үземне ялганда тоткандай, уйга калдым бит әле. Нәрсә соң ул тәрбия? Моны безнең замандашлар ничек аңлый? Һәм ата-ана халкы бу хакта ничегрәк фикер йөртә?.. Нәрсә дисен, алай итмә, болай ит, ди инде ул үзенең баласына, анысы ярамый, монысы да ярамый, ди. Һәм шул рәвешле бик күп «ярамый»ларны тезеп киткәчтен, яхшы булып үсү өчен нәрсә эшләргә кирәклекне аңлата. Ата-ана сүзен тыңларга кирәк икән. Бу кадәресе хак сүз, дөрес анысы. Ә ата-ана ни таләп итә, ни куша соң? Бүген болай, иртәгәсен тегеләйме?.. Вакытында утырып аша, вакытында ятып йокла, дәресеңне хәзерлә. Кызганычка каршы, тәрбия дигәнебез еш кына шуңа кайтып кала...

Ярар, бусын куеп торыйк, сүз Асия хакында бит әле. Елгачылар хәлен аңлатып торасы да юк, һәркем белә: иртә яздан кышка кергәнче су өстендә алар. Өйгә, гаиләгә әллә нигә бер сугыла икән, анысына да бик канәгать. Шуңаргадыр, әтисе көттереп, сагындырып әллә нигә бер килеп чыга торган кунак кебек кенә хәтеренә кереп калган Асиянең. Ул өйдә булган көннәр онытылмас һәм кабатланмас бәйрәмгә әверелә торган иде.

Ишектән килеп керүе була, кызын, дәү кочагына алып, шап-шоп аркасыннан сөяргә керешә. Гөбедән чыккан калын тавышы белән үзе көлә, үзе куанып сөйләнә:

— Әй, кызым!.. Менә бит нинди дәү булып үскән минем кызым,— ди.

— Чү, баланы гарип итәрсең, ипләбрәк... Сагынган икән берәү, харап икән!.. Бала бит ул, ипләбрәк,— дип, яннарына әниләре йөгереп килә.

— Ул да әтисен сагынган, шулай бит, ә, кызым?..— дип сөйләнә ата. Ул, гомумән, бала белән сөйләшә дә, уйный да белми, шап-шоп сөя генә белә. Кызын янә бер кат түшәмгәчә чөеп ала да идәнгә төшерә.

— Баланы куркытасың бит!.. Идәнгә килеп төшсә,— дип, тагы әнисе арага килеп керә.— Нәрсә геройланасың, эчеп кайттыңмы әллә?.. Бала янына килергә оялыр идең!..

Елгачының нервлар нык, колак та салмый ул бу сүзләргә. Кызы белән әвәрә килә, үзе һаман кет-кет көлә. Ул да түгел, оныта язганмын дигән сыман, кабаланып, кесәсенә тыгыла, аннан кипкән балык тартып чыгара. Кызына Идел күчтәнәче.

— Менә бит, кызыма нинди тәмле балык алып кайткан идем...

Шул тикле зур балыкны берүзенә ышанып тапшырсыннар инде — кыз, онытылып, балыкны күзәтә. Сак кына аның көмешсыман тәңкәләреннән сыпыра, тешләмәсен дигәндәй, авызларына ягылып-ягылып ала.

Ананың кайгыртучан тавышы ишетелә:

— Бирмә дидем бит шул балыгыңны!.. Тамагына кылчыгы кадалсын дисеңме?!.

Ата белән баланың үз сүзләре:

— Әти, әти, син анда Су анасын күрмәдеңме?

— Ник күрмәсен!.. Балыкны бит сиңа Су анасы үзе бирде. Асия зур, тәти кыз булып үссен диде...

— Балыгыңны ал дим...— бусы инде янә әниләре тавышы.— Бер-бер хәл булса, син түгел ич, мин утырам больничныйда...

Кыз балыкның канатларыннан сыйпый, койрыкларын күзәтә. Күр инде, әтисе нинди олы бүләк алып кайткан аңарга.

— Су анасы Асияне ярата, шуңа да ул аңар балыкның кылчыксы-

зын жибәргән, шулай бит, кызым!— дип, янә кызының аркасыннан сөеп куя ата. Берочтан әниләре күңелен дә тынычландыруы.

Асиянең әтисе ачуланышу, кемгә дә булса үпкәләүнең ни икәнлеген белми иде. Әнисенең берөзлексез тәртелеп, өйрәтеп торуларын да күңеленә якын алмый гына колак читеннән үткәреп җибәрә. Еш кына уенын-чынын бергә кушып: «Безнең әни — укытучы, шулай бит, кызым? Ә укытучының иң яратканы нәрсә? Өйрәтү — шулай бит, кызым? Мәктәптә — укучыларны, өйгә кайткач, синең белән минне өйрәтә ул, шулай бит, кызым?..»— дип әйтергә ярата. Бу сүзләрне хатыны үзенең өйрәтүләре белән теңкәсенә төшкәч әйтә торган булгандыр ул. Нишлисең, профессиональ гадәт, эштә генә калмый, өйгә дә ияреп кайта, күрәсең. Әйтик, слесарь эшендә тимер-томыр игәүли ди, мисал өчен. Буш вакыты булса, өендә дә бер-бер нәрсә ясарга, игәүләргә керешә инде ул. Һөнәре шундый! Укытучы да игәүли. Кемне булсын, ирен игәүли өйгә кайткачтын...

Бик ешаеп янсә чамадан ашып китсә, иң изге теләк-омтылышлар да кайчак кире нәтиҗә бирә, янсә бөтенләй көлке чыганагына әверелә. Асиянең әнисе дә шулай. Гомере буе, хәтта пенсиягә чыккач та, әлеге гадәтен — берөзлексез өйрәтеп тору, һәр сүздән кимчелек табу, һәр кылган эшкә төзәтмә кертүдән арына алмады. Башкалардан күбрәк моның белән ул үз-үзен газаплады. Шуңадыр, аның нәрсәдәндер күңеле булып куанган, борчусыз гына яшәп, уен-көлке сөйләшеп үткәргән сәгатьләре сирәк булгандыр. Һәрхәлдә, Асия хәтерләми иде әнисенең андый чакларын. Кайчан карама, нәрсәдәндер канәгать түгел, нидер җитеп-җитми кебек иде аңарга. Ни икәнлеген ачык кына ул үзе дә белеп бетерми торгандыр.

Әтисенең дә күңелсезләнеп, кая барып сугылырга белми йөргән чаклары хәтерли Асия. Бигрәк тә кыш көннәрендә... Бар дөнья чистарып, ап-ак төскә төренә. Тик аның әтисе генә сула, үз эченә бикләнә кыш житкәч. Берәүгә дә, хәтта кызына да дәшмәс була, үзалдына берөзлексез ниләрдер уйлап йөри. Бер урында гына утыра алмас була, әле анда, әле монда барып төртелә. Ике бүлмәле шәһәр фатирында, ирегеннән мәхрүм ителеп, читлеккә ябылган кошчык сыман хис итәргә керешә үзен, ни эшләргә белми изалана. Коридорга, баскыч мәйданына чыгып та озак-озак торып керә, берөзлексез папирос төтәтә. Елганы, Идел һәм Каманы сагына ул шулай. Боз астында калган зәңгәр дулкыннарны юксынып үрсәләнә.

Ә Асиянең әнисе моны күрми һәм аңларга да теләми. Ничек инде көнозын эшсез йөреп тә шулай йончырга мөмкин әзмәвердәй ир-ат?.. Мәктәбеннән кайтып керүе була, болай да аптыраган-йөдәгән ирен битәрләргә керешә:

— Коридорны гына түгел, бөтен өйне тутыргансың папирос сасың белән,— ди. Мәктәптә туалетка качып төтен өргән кызлар-егетләрнең ачуын аңардан ала.

Үсеп килгән, инде күп нәрсәләргә үзе җавап табарга өйрәнеп баручы Асия генә аңлый алмый әнисен: нигә ачулана, нигә дип гел орышып тора ул аның әтисен?.. Болай да кәефе юк ич аның. Шундый тыныч, ипле кешене ничек рәнҗетергә кирәк?!

— Әтием,— дип дәшә ул аңарга өйдә икәүдән-икәү генә калган чакларында.— Нигә сине әни гел ачуланып тора. Ә син җавап та бирмисең?..

— Ярат канга, кызым, ратканга,— ди әтисе, кызының шомырт-кара чәчләреннән сыйпап.

— Ярат канга ачуланалармы?..

— Һәркем үзенчә ярата, кызым. Берәүләр яратуны җылы сүз, ягымлы караш белән белдерсә, икенчеләр — орыша, өйрәтергә керешә.

— Яраткан кешеңне ачуланмыйлар, әти!

Үсеп килгән кызының инде бала-чага түгеллеген тоеп, аның үз фикере булуына ихлас куанып куя ата. Әмма уендагы телендә түгел:

— Бала-чага гына бит әле син, кызым...

— Беләсең килсә, эти,— дип, тагы да җитдиләнә төшә кыз һәм, бертын икеләнеп торганнан соң, ишетмәсәң ишет дигән сыман, әйтеп сала.— Беләсең килсә, мин җиденче класста укыйм инде. Һәм безнең класстагы күп кенә кызларның йөргән егетләре дә бар...

Чәч төпләренәчә чымырдап куя атаның. Ул бит әлегәчә кызын сабый бала итеп кенә күрергә, сабый итеп кенә сөяргә күнеккән. Ә ул, әнә, нәрсә ди.... Башка сыймаслык сүз сөйли. Үзеңне шул бала урынына куеп карау, үзеңнең дә аның яшендәге чакларыңны хәтергә төшерү кирәклеге хакында уйлап та карамыйсың андый чакларда. Моннан ун ел, биш ел элек ул синең өчен нинди бала булса, хәзер дә шул хәлендә, шул гадәтләре, шул ук холкы белән калган булырга тиеш дип фикер йөртәбез. Һәм алданабыз, ничек кенә алданабыз әле, ничек кенә хаталанабыз без — ата-аналар. Балаларыбызның үскәнен күрмибез. Чөнки үзебез һаман бер урында, бер үк мәшәкать, бер үк ыгы-зыгылардан арына алмыйча иза чигәбез. Вакытның дилбегәсен ычкындырып, үзебез ыгы-зыгы килеп йөргән арада, тормыш үзе дә туктап торадыр сыман тоела безгә. Әюгыйсә, алардан бераз алгарак та чыгып фикер йөртү, үсү, акылга кирә бару кирәк иде дә бит... Юк, өлгермибез, баланың бүгенгесен, ә күп очракта үткәнен генә кайгыртып, хәстәрләп, аны иртәгәсе көнгә хәзерләү хаҗәте хакында онытып куябыз.

Әти кеше ни дияргә белми телен йотып кала. Әнә ич, кая үк барып чыкты аларның бу сөйләшүе. Тел очына килгән сорау тел очында торып кала. Ул хакта сорау кая, уйларга да куркыныч. Ничек итеп бердәнбер кызыңа, әлегәчә сабыйга чыгарып йөргән балаңа: «Синең дә юкмы соң йөргән егетең?»— дип, авыз күтәреп сүз әйтергә мөмкин?

— Нигә сорамыйсың, этием?— дип әйтеп куймасынмы шунда кызы. Гүя ул этисе күңелендә талпынган сорауны үтәдән күреп торган.— Сора инде, «Синең дә бармы егетең?»— дип сора...

Телен йоткан ата, әйе-әйе, җавап бир, дигән сыман баш кагудан башканы белми. Күз карашыннан ук аңлый аны кызы:

— Ләкин бер шарт белән, этием, ир кеше була белсәң генә. Әнигә — ләм-мим.— Серенең ни дәрәҗәдә әһәмиятле икәнлеген белгертергә теләп, иреннәренә аркылы бармак куя.— Әнигә әйтсәң, ахыры яхшы бетмәячәк. Йә үзе, йә мине... Менә шулай, этием.

Кыю булса да, оялчан әле аның кызы, колак яфраклары, бит урталары алсуланып чыккан әнә. Бу хакта сөйләшү җиңел түгел кызга, әмма серләшми калу, бүлешми калу тагы да кыенрак.

Этисе педагогикадан мәгълүматлы кеше түгел. Җавапсыз калу, телен йоткан кебек терәлеп тору да килешми:

— Әниең укытучы бит, кызым... Аның белән киңәшергә иде.

— Безнең әниме?..— дип, этисенең икеләнү катыш сүзләренә гаҗәпсенә кызы.— Ул аңларга да теләмәячәк. Беләсең килсә, эти, тугызынчыунынчы класс кызларының да теңкәсенә тия ул шул егетләр өчен.

— Булмаганны!..— дип гаҗәпсенгән була ата. Кызының хәленә керә, янәсе.

— Син безнең әнине белмисең генә... Ул аларның ата-аналарын чакырта мәктәпкә. Директорга алып керә... Тәртипләренә дүртле куйдыра... Кызларга күз салган малайлар — хулиган, малайлар белән дуслашкан кызлар — җиңел акыллы, тәрбиясез аның өчен.

— Әниең укытучы, кызым. Ул күбрәк белә...

— Аларның тәрбия ысуллары искергән инде. Ул ысулларны чүплеккә атарга вакыт. Беләсең килсә, этием, бу хакта газеталарда язалар хәзер.

Алай димә, кызым! Укытучы укытучы булып калыр, барыбер. Чүплек башына чыгарып атарга ашыкма.

— Ихластан гына әйт әле, эти, син үзең укытучылар сүзен гел генә тыңладыңмы?.. Бер дә сүзләреннән чыкмадыңмы? Әйе, дисәң дә ышан-

мыйм, эти. Чөнки син миңа охшаган, синең дә күңелеңдә ireккә, азатлыкка омтылу бар...
Ирексездән елмаерга мәҗбүр була ата:
— Үзеңә охшаган дисең инде...
— Әйе, кызык килеп чыккан,— кыз да үзалдына көлгәндәй итеп ала. Әмма озакка түгел, логика көчле үзенең.— Ярар, сүз ул хакта түгел иде. Укытучылар дидек, эти...
— Безме, кызым,— дип уйга кала ата.— Без укытучыларны аллага тиң күрә идек: алар икмәк, бәрәңге ише ризык ашамый да торганнардыр дип күз алдына китерә торган идек. Без үскәндә, укытучыдан да олырак кеше юк иде авылда, кызым.
— Ха...— дип көлә бу юлы кыз.— Укытучыдан да зуррак кеше юк... Башка җирдә сөйли күрмә, эти. Көләрләр...
— Акыллы кеше көлмәс, кызым.
— Ишеткәнем бар,— дип, сөйләп бетерергә ирек куймый, этисен кырт кисә кыз. Әңгәмә сагышын искә төшерә.— Әниемә әйтмәм диден, эти, килештекме?!.
Кызын таный алмыйча хәйран калын торган ата килешүен белгертеп баш кага.
— Алай булгач тыңла, эти: егетем бар. Унынчыда укый. Спорт белән шөгыльләнә... Бокс! Хулиган түгел. Буе озын...
Ата кеше, ниһаять, колагы ишеткәннәрнең чын хакыйкать булуына төшенеп, айнып китә:
— Спорт белән шөгыльләнүе, хулиган булмавы әйбәт анысы, кызым. Тик, иртәрәк түгелме соң әле?.. Унынчыда ук укы дисең үзен.
— Соң, эти, моның ни гаебе бар?.. Үзебезнең класстан булмас бит инде. Аларның әле буе да юк, тавышлары да көчекнеке шикелле чыелдап кына чыга,— дип елмаеп җибәрә кыз. Ә бер мизгелдән, җитдиләнә төшеп, өстәргә ашыга.— Кызлар бит, эти, иртәрәк өлгерә. Егет белән кыз арасында өч яшьтән сигезгәчә аерма булу табигый диелгән китапта да...
Кызы җиденче классны тәмамлаган елны ата белән ике арада әнә шундый сөйләшү булып алган иде. Бу сөйләшү аларның үз араларында гына калды.
Шулай да Асия әнисеннән гел куркып, сагаеп яшәде. Һәр көн, һәр сәгатьтән хәвеф көтте ул. Кыя-тау түбәләренә күпләп җыелган кар кебек, хәвеф баш очында гына эленеп тора сыман иде. Чөнки ана белән кыз өйгә дә, мәктәпкә дә бер үк сукмактан йөриләр. Бер ялгыш сүз, бер очраклылык та җитәчәк...
Унынчы класста ата-аналар җыелышы узган көннән башланды ул зилзиләләр. Шулай кирәк табып, Асиянең әнисе — мәктәптә укыту эшләре бүлеге мөдире — ата-аналар янына укучыларның үзләрен дә чакырткан булган. Көн тәртибендә тәрбия мәсьәләләре: унынчы класста укучы ике кыз Үзәк парктагы дискотекага йөри икән. Үзләре генә түгел, егетләр белән! Бәхетсезлекләренә каршы, кичен урамга һава суларга чыккан завучның үзенә тап булган бу кызлар. Егетләре дә янәшәдә генә булган. Кыскасы, әнә шундый «акылга сыймас һәм баш бетәрлек» хәлгә тарыган Асиянең әнисе. Һәм бер җыелышта:
— Оялсалар икән, ичмаса... Житәкләшкән кулларын да ычкындырмый, янәшәмнән узып киттеләр. Егет дигәннәренең авызларында сигарет!.. Йә, кем белә аларның төн уртасында нишләп йөргәннәрен?! Ничек оят түгел сезгә, кызлар? Үзегезнең әле мәктәп укучылары гына икәнлегегезне онытырга ярыймы шулай?!.. Әле ком-со-мол-лар! Оят!.. Бөтен мәктәп өчен оят! ЧП ич бу!..— дип кызып-кызып сөйләгәндә, ул, сулышына буылып, су агызып эчү нияте белән, пыяла графинага үрелә.
Гөнаһ шомлыгы, нәкъ шул вакытта, башын салындырып арткы рәтләрдә утырган кызларның берсе сүз кыстырып куя:
— Сез иң элек үз кызыгызны белегез! Үз кызыгызны!..

Стаканга су агызып торган җирдән графина төшеп китә яза завучның кулыннан. Колагы ишеткәннәрдән күз аллары караңгыланып ала:
— Нәрсә булган, нәрсә... минем кызыма?
— Сез аның үзеннән сорагыз... Ә бездә эшегез булмасын!
— Минем кызыма... Минем кызыма...— дип кабатлый завуч бер үк сүзләрен. Фикер җебе тәмам чуала.
Ә теге усал телле «тәрбиясез кыз» шул арада урыныннан сикереп тора да ишеккә юнәлә, класс ишеген шапылдатып япканга кадәр:
— Мин киногa киттем. Егетем көтә...— дип тә өстәп җибәрә.
Укыту эшләре бүлеге мөдире телен тешли. Моңарчы үз кызы өчен уңайсызланып, бер почмакта посып утырган ата-ана, чарасызлыктан, кулларын кая куярга белми, аптырашта кала:
— Менә шундый инде ул. Шундый... Бер сүз әйтеп булмый үзенә... Мәктәпне, завучны да санга сукмагач...
Шул кечне мәктәптән кайткач та Асиянең әнисе, йөрәген тотып, креслога бөгелеп төште. Өйдә нинди сүзләр әйтелүе, нинди җил-давыл кузгалуы хакында сөйләп тору артык, болай да аңлашыла булса кирәк... Кызның да хәлләр бигүк шәптән түгел иде. Дөресен әйтүнең, әнисе белән сер уртаклашуның файдасыз икәнлеген белгәнлектән, ялганга керешергә мәҗбүр булды. Әнисенең күзләренә туры карап, икмәк белән, аның үз исеме белән үк антлар бирә-бирә ялган сөйләде кыз. Күңелендә гөнаһсыз сер булып кына саклана килгән хисләр, шулай итеп, әрнүле һәм ямьсез бер ялганга әверелде дә куйды. Ана белән үсмер кыз арасына ялган керде. Мәңгелек туң кебек һичкайчан да эремәячәк, кимү түгел, вакыт узган саен артканнан-арта гына барачак салкынлык иде бу. Хәвефле салкынлык...
— Беркайчан да егетләр белән йөрмәм, әни, тынычлан, зинһар, тынычлан гына,— дип гозерләде, вәгъдәләр бирде Асия. Синең өчен газиз әнкәң һуштан язсын инде... Сөтләп чәй ясап китерде, маңгаена үзенең кайнар уч төбен куеп торды кыз.— Беркайчан да, әнием... Син борчылма гына, ярыймы, борчылма, әнием.
Ялган вәгъдәләрнең хакыйкатькә караганда күп мәртәбәләр шифалырак икәнлегенә инанып алган кыз бала, теленә ни килсә, шуны сөйләде. Әнисенең җанын тынычландырды...

## 6

— Курыкмыйсыңмы?— дип, ярым пышылдап сорап куйды Асия.
— Кемнән?.. Нәрсәдән?
— Сүз чыгудан. Гайбәт таралудан.
— Бүредән курыккан — урманга йөрми, Асия.
Хатынның назга тулышкан ирен читләрендә елмаю төсмерләнеп алды:
— Онытa язганмын, арыслан бүредән ник курыксын инде. Шулай бит, ә, Арслан?!.
— Бүредән генә курыкмыйбыз анысы...— Арслан, иелә төшеп, Асиянең ярым йомык күзләреннән үбеп алды. Үзенең бернидән курыкмавын расларга омтылгандай, канәгать чырай ясады.— Шөкер, дөнья дилбегәсе үзебезнең кулда...
Сокланып, тынычлыгы һәм үз-үзен тотышыннан һәрдаим сизелеп, күренеп торган көч, гайрәтенә таң калып күзәтте аны Асия. Ир-атларның бик сирәкләрендә генә очрый торган мөлаемлык, эчкерсезлек тапты ул аңарда. Елмаюлары ни тора, теләсә кемне сихерләргә, телсез-өнсез калдырырга сәләтле үзе... Әле хәзер дә, серле кысыла төшеп, иң элек күзләре яктырып китте, бер мәлдән шул җылы яктылык бөтен йөзенә таралды, ирен читләренә һәм ап-ак тешләренә күчеп, елмаюы тоташ бер балкышка әверелде. Үзенә килешеп торган кара мыек чылгыйлары дуга сы-

ман бөгелеп-бөгелеп ала елмайган чакларында. Назга йомшак булган хатын-кыз күңеле түгел, боз булса — боз да эреми калмас иде шул чагында... Әнә кай яклары белән үзенә җәлеп иткән, үзенә тарткан икән аны Арслан.

— Ә үзең, Асия?.. Болай качып-посып йөрүне әйтәм, сиңа уңайсыз түгелме соң?

— Янәшәмдә син булганда — дөнья мәшәкатьләре онытылып тора, Арслан. Син чын арыслан кебек...

— Безне арыслан ясаучы — сез, Асия, чибәр хатын-кызлар...

— Шулай да, сиңа шундый тиз ияләшәм бугай мин, Арслан. Үзем дә аңламыйм — нигә?

Үзен мактаганны кем яратмый. Ә Арслан, гомумән, үз-үзенә битарафлардан түгел. Хатынның әлеге сүзләрен ишеткәч, йөзенә чыккан канәгать елмаюын яшерә алмады ул. Асиянең колак читләреннән сак кына сыйпап куйды.

— Мин барында берәү дә сине кыерсытмас. Син сөяр, сөелер өчен генә тугансың, Асия...

— Шулаен шулайдыр да...— дип, чуалган уйларын җыя алмыйча, тагы да Арсланга сыенарак төште хатын. Рәхәт тә, җиңел дә иде аңарга бу минутларда. Хисләрдән ташып торган күңеле шундый көчле һәм кайгыртучан кеше белән очраштырган язмышына рәхмәт укый. Бары тик аны кайгырта, аның өчен янган утка керергә дә әзердер сыман иде бу ир-ат. Игътибарлы... Ә бит үзе шул ук вакытта нинди дәрәҗәле, җаваплы зур эштә дә эшли. Ир-атны, хатын-кызга мөнәсәбәте һәм тышкы кыяфәте өчен генә түгел, кайда, нинди урында утыруына да карап хөрмәт итә, ярата-сөя торган заман ич хәзер...

— Берни турында уйлама, хафаланма, килештекме, Асиям...

Ул аңар «Асиям» дип дәште. Бу кадәрле игътибар һәм үз итүгә җавапсыз калу мөмкинме?!. Ә колак төбендә соң дәрәҗәдә ягымлы һәм якын тоелган тавыш, кайгыртучан сүзләр:

— Борчылма, юкса маңгаеңа җыерчыклар чыгар... Шундый шома, йомшак маңгай, алсу бит очлары... колак очларыңача — аккош мамыгыннан. Иякләрең... Мин барында сиңа беркайчан да җил-янгыр тимәс, Асия... Ишетәсеңме?.. Сиңа, әнә шулай дәшми генә, күзләреңне йомып яту килешә... Син әле үзеңнең бәяңне белеп бетерми торгансыңдыр... Ә, Асия? Нигә дәшмисең?.. Дәшмә. Сиңа дәшмәү шундый килешә!.. Син сөелер өчен генә тугансыңдыр, Асия!..

Җавап бирү түгел, уйларга, фикер йөртергә дә иренеп, тынсыз-хәлсез калып тыңлады аны Асия. Арсланның бу сүзләре әле моңарчы, бу көнгәчә бернинди талант ияләре дә тудыра алмаган серенада сыман иде. Ул серенаданың моңы да, көе дә — ярымпышылдауның үзендә. Колак аша түгел, бәгыре аша, җаны-тәне аша тоя иде сыман ул бу серенаданы...

— Әллә йокладың да инде? — Арслан, янә аның баш артыннан, чәчләреннән ягымлы гына сыйпап алды.— Йокла, Асиям, йокла... Сиңа килешә...

Йоклый диләрме соң!.. Күзләрен зур ачып, үзенең уяу булуын хәбәр итеп алды хатын. Дөрес, дәшәр сүз дә, дәшәр көч тә тапмады үзендә. Тирә-юньне биләп торган тынлык, җәйнең рәхәт салкынлыгы, чыршынарат такталардан аңкып торган чәер исе һәм әлеге дә баягы серенада гына изрәтте ич аны. Шушы мизгел мәңге-мәңге дәвам итсә дә, һичкайчан талчыкмас, күзләренә йокы кермәс иде.

Тынлык — бәхет һәм әкият ул. Бишектәге сабыйлар сыман, бар дөньяларны онытып торып, бәхет сиртмәсе — тынлыкта тибрәнде алар. Каядыр янәшәдә генә урман шаулады... Тук та тук килеп тукран ниләрдер санау белән мәшгуль булды. Бәхет сәгатьләрен санавы идеме икән? Иренеп кенә кошлар сайраштырды. Каядыр кереп качкан бер чикерткә дөнья матурлыгын мактап туймады...

Чикерткә арып хәлдән тайгач кына, алар урнашкан ике катлы дача өенең беренче катында җай гына ишек ачылды. Сискәнеп, калтыранып алды Асия: кем булырга мөмкин? Җавап, янсә юату сүзе ишетергә өметләнеп, Арсланга текәлде.

— Каравылчы ападыр,— диде ул, йокы аралаш мыгырданып.— Кофе китергәндер.

Шул сүзләрнең дөреслеген раслап, аскы катта чынаяк челтерәшкән аваз яңгырап алды. Ул да түгел, берәүнең сак кына атлап йөргәне, тагы ниндидер савыт-сабалар кузгалганы ишетелеп калды. Килүче озак тормады, кергән чагында ук күрсәткән саклык белән, үзе артыннан ишекне кысып, китеп тә барды.

— Кофе...— дип кабатлады Асия үзалдына. Әчәсе килүдән түгел, болай гына әйтүе иде. Башын юрган астына яшереп, баягы тынгысызлыгыннан котылмакчы булды. Шик-шөбһәләрен тиз генә куа алмады.

— Туңдырамы әллә? — Арслан сизгер һәм игътибарлы. Йокы аралаш чагында да аны кайгыртудан туктамый, Асияне үзенәрәк тарта төшә.

— Миңа салкын түгел.

— Тунгансың ич. Әнә ничек калтырыйсың,— дип, мыеклары белән колак артларына сак кына кагылып, иркәләп алды ул Асияне.

— Туңмадым... Мин болай, уйланып кына ятам, Арслан.

— Хәзер, мин аска төшеп менәм,— дип, ипле генә урыныннан кузгалды Арслан. Чөйдә эленеп торган халатны иңсәсенә салып, түбәндәге катка илтүче бормалы, тар баскычка юнәлде. Инде яртылаш күмелеп, күздән югала дигәндә, бик азга тукталып алды да, үрелә төшеп, артыннан карап-озатып калучы Асиягә каш сикертте. Ә мыек читләрендә үзүзеннән канәгать һәм шаян елмаю.— Кара аны, яхшылап ябынып ят. Мин югында пәри егетләре урламасын үзеңне...

Арслан күмелүгә үк, җәт кенә урыныннан сикереп торды Асия. Берьялгызы нишләп ятсын соң ул монда?! Як-ягына карангалап алгач, урындык аркасына эленгән ирләр күлмәгенә төште күзе, шуны киеп тә куйды. Ирләр күлмәге халат түгел, әлбәттә, шулай да ул аның гәүдәсендәге оялчан урыннарны капларга ярап куйды. Бармак очларына гына басып, ул да баскыч буйлап түбәнге катка ашыкты. Асиянең үзе янына кай арада һәм ничек төшеп җиткәнен абайламый да калды Арслан. Төшкән уңайга, сиздерми генә атлап килде дә, йомгакка ташланган уенчак мәче баласы сыман, веранданың ачык тәрәзәсе каршында тәмәке тартып торган ирнең муенына сикерде ул. Гүя шампан шәрабыннан түгел, бәхеттән әйләнә иде аның башы. Әйтерсең, ул унҗиде-унсигездәге акылын җуйган бер кыз бала; әйтерсең, мәңгелеккә сайланган яры янында. Әйтерсең, үз аякларында атлап түгел, бәхет канатларында җилпенеп очып йөргән фәрештә иде ул.

Арслан да югалып кала торганнардан түгел. Әллә ни арада авызындагы сигаретын тел очына әләктереп ачык тәрәз аша тышка төкерде дә канатларын җилпегән фәрештәне кулына күтәреп алды һәм өй эченә алып керде. Чырык-чырык килде, дөньясын оныткан сабыйдай шаярасы, уйныйсы килде Асиянең. Бөтен гәүдәсе белән Арсланның гайрәт тулы беләкләренә уралды.

Шаяруга шаяру белән җавап кайтарасы килде Арсланның да. Әмма табигыйлектән ерак иде аның мәҗбүри кыланышлары. Онытылып әүмәкләшү, үртәләшү, дөньясын онытып шаярышу өянәге кузгалган Асиягә иярә алмады ул. Күбрәк аны тынычландыру, җайлау белән мәшгуль булды. Башка чара тапмаганнан, табын әзерләү мәшәкатен сәбәп итеп, җигелмәгән тайдай уйнаклаган ярының кочагыннан атылып чыкты:

— Тәртип бозма, ярыйммы,— дип янаган булды ул аңарга.— Юкса үзеңне почмакка бастырырмын...

— Мин риза,— дип, йомшак креслодан янә сикереп торды хатын. Маңгаена төшкән, күзләрен каплаган чем-кара чәчләре арасында чуала-

ныи, берөзлексез чырык-чырык көлде.— Почмакка басарга да риза! Әмма бер шартым бар — янәшә бассак кына...

Арслан һаман житдиләнгәннән-житдиләнә генә барды. Акылга сыешмас гажәп бер хәл бит ул: иң элек ир-ат акылыннан чыгар дәрәжәгә житеп юхалана. Инде икесе дә бер халәткә керде дигәндә генә, ул житдиләнеп кала, эшлеклегә әверелә, юкка-барга исе китмәс булып әверелә. Үзе белән дөньясын онытып шаярырга, акылсызланырга әзер булган хатын-кызга исе китә аның, ачыктан-ачык белдермәсә дә, каныгуларына кәефе кырыла.

Үзен монда хужа итеп хис иткән Арслан табын әзерләү мәшәкатьләрендә булды. Кофе янына суыткычтан коньяк шешәсе менеп утырды, шоколад сузылып ятты.

— Яхшы яшисез,— дип, суыткычка таба ишарәләде Асия, анда тулып торган төрле затлы ризык һәм эчемлекләргә исе китеп. Урыныннан сикереп торып, Арслан янәшәсенә килеп басты. Ир-ат әллә чынлап та абайламады үзен, әллә күрмәмешкә салышты. Вакытлыча гына чагылып алган бу битарафлык хатынга да сизелеп калды. Айный төшеп, үзен тоташ дулкын, өермә итеп йөрткән хисләрен басарга тырышты. Өстендәге ирләр күлмәгенең итәкләрен тарта-тарта, өстәлнең аргы ягындагы йомшак креслосына таба борылды. Утырды. Үпкәләргә уенда да юк иде. Як-ягына ялт-йолт каранып алгач, сүзсез торуны өнәмичә, сорау бирергә ашыкты:

— Миңа монда ошый. Бу өй синекеме?

Ир-ат аңар күтәрелеп карады. Елмаеп та алды әле хәтта. Ягымлы итеп елмаерга тырышты.

— Монда синеке-минеке юк, Асия. Барысы да үзебезнеке.

— Кем инде ул үзебез дигәнең? Сер булмаса, әлбәттә...

— Нигә сер булсын, сер түгел. Бу — сәүдә работникларының ял базасы.

— Димәк, сатучылар ял итә?..— дип, гажәпсенеп, як-ягына карангалап алды Асия.— Уйламассың...

— Сәүдә...— ул сатучылар гына түгел.

— Кемнәр?..

— Сатучының урыны — прилавка артында, ярминкәләрдә. Монда нишләсен сатучы?!.

— Ә монда кем?

— Без, Асия! Без — син һәм мин. Шул житмәгәнме?..

— Аңлашылмый,— дип, як-ягына карануын дәвам итте хатын. Әйтерсең, әле яңа гына килеп кергән дә ишек тупсасыннан үтүгә үк хәйран калган.

— Сиңа күңелсезме? — дип сорамый булдыра алмады Арслан. Кунагының кинәт кенә кызыксынучан булып китүе ошап бетмәде бугай аңа.

— Без югында, башка чакта кемнәр була?

— Йорты гына булсын, кунак өзелми ул. Әле монысы, әле тегесе, төрле тикшерү, комиссияләр, дигәндәй. Беткәнмени...

Хатын, аңлашылды дигәнне белдереп, башын какты.

— Димәк, без монда икәү генә?

— Каравылчы хатынны хисапка алмасак, әйе.

— Икәү генә...

— Шул житмәгәнме?.. Бу дөньяда без, гомумән, икәү генә түгелмени?

— Әйе, икәү генә. Син дә мин генә, Арслан.

Моңарчы алар бер-беренә кара-каршы, зур өстәлнең ике ягында утыралар иде. Янә йөрәге кош булып талпынды Асиянең, тынгысызланып торып басты ул. Өстәл читләп Арсланга таба юнәлде. Башын бераз артка ташлап, тәлгәшендә пешкән чия сыман иреннәрен сузып, серле томанга уралган күзләрен кыса төшеп, чак-чак кына чайкап һәм чайкалгалап якынлашты ул аңарга. Аның һәр адымы, һәр хәрәкәте теләсә

кемне акылдан җуйдырырлык тоташ сер, тән һәм җан балкышы иде. Уртачадан бераз калкурак буйлы бу яшь хатын йомарлаган май сыман икән ич. Түгәрәк тә, сылу да, тыгыз да, бер үк вакытта нәфис тә үзе. Әле беренче кат кына күргән сыман, сокланып, хәйран калып күзәтте аны Арслан. Шундый гүзәллек каршында битарафлык күрсәтүдә үз-үзен гаепләп, әрләп алырга да өлгерде.

Бу карашны Асия дә сизмәде түгел, әлбәттә. Аермачык сиздe һәм нәтиҗә ясарга да өлгерде: авызлык күрмәгән яшь тай сыман уйнаклап килгән көйгә Арсланның кочагына ташланды ул. Кайнар ташкын булып сарылды...

Байтак гомер узды. Икәү генә серләштеләр... Берәүгә дә ул серләрне, ул сүзләрне тыңлау, чит-ятлар колагына чыгарып селкү хокукы бирелмәгән. Берәүгә дә...

— Бу дөньяда син дә мин генә... икәү генә булсак иде, Арслан! — Асия пышылдады. Колак салу мөмкин булган беренче сүз аның авызыннан чыкты бу юлы.

— Чынлыкта да шулай ич, без монда икәү генә. Башка һичкем юк, икәү генә...

— Шулаен шулай да...

— Син — бәхетле. Мин — бәхетле. Тагы ни кирәк?!.

— Һәрчак шулай булсын иде ул. Икеңә бер бәхет булсын иде, аерым-аерым түгел.

— Кара инде, син моңая да беләсең түгелме соң?.. Хафаланма, сиңа хафалану килешми...

— Мин уйланам гына... Һәрчак менә шулай яшәсәң икән аны... Урман... дача... син һәм мин генә...

— Син теләсәң, һәрчак шулай булыр: урман, дача һәм без икәү.— Канәгать елмаеп җавап кайтарды Арслан. Үзе өчен шундый хатынның җанын фида кылырга да әзер булуы ошый иде аңа.

— Шулай булса икән...— уфтанып, өметсезлек белән әйтелде болары.

— Ә нигә шулай булмаска, бу бит үзебездән — синең, минем теләктән тора. Шулай ич, Асиям-җаным?!.

Бертын, ни дияргә белми, дәшми торды Асия. Җаны-тәне белән Арсланга елышты ул. Аның йөрәк тибешен, тамырларындагы кан хәрәкәтен тойды. Үзләрен очраштырган очраклылыкка чиксез рәхмәтле иде ул.

Бу чираттагы сырпалану-назлануны нигә юрарга да белмәде Арслан. Шулай да җавапсыз торырга ярамаганлыкны яхшы тойды:

— Әйе, үзебездән тора. Башкаларның бездә эше юк.

Арслан авызыннан чыккан һәр сүзне йотлыгып тыңлаган җиреннән башын калкыта төште хатын. Аңарга, дөрес сөйлисеңме, ихластанмы дигәндәй, сораулы карашын төбәде.

— Үзебездән генә дисең?

— Шулай булмый...

— Ә хатының?

— Причем монда хатын?..

— Акыллы һәм зифа икән хатының.

— Акылның, зифалыкның монда ни катнашы бар?! Ташла әле, җыен юк-бар турында сөйләшмик.

— Кем ул юк-бар, хатыныңмы?

— Ул хакта сүз кузгатуны әйтәм... Җитәр,— үзенә табарак кыса төште ул Асияне.— Катырма башыңны! Кемдә юк ул — хатын? Исең киткән!

— Сине бары үземнеке, үземнеке генә итәсем килә, Арслан.

— Соң,— дип, мыек читләп яшертен елмаеп алды ир-ат. «Әнә, кая бөгәргә маташа. Мин уйлаганча ук беркатлы түгел ахры...» Ә тел башкача сөрде.— Синеке ич. Теләсә нишләт, синеке. Ашама гына...

— Ә ашасам?

— Ашарга ашыкма, әле яшисе бар. Яшәп каласы...

Тагы ни диярга, күңелен борчыган нәрсәләр хакында ничек сөйләшергә, ничек аңлашырга белми онытылып торды Асия бертын. Шундый житди нәрсәләр хакында ничек инде уйнап-шаярып кына сөйләшергә мөмкин?.. Бер үк вакытта Арсланның кыен сораулардан, шома балык сыман, шуып кына чыга белүе дә җәлеп итте аны. Ул ялганламый, алдашырга, тормышка ашмаслык вәгъдәләр белән күмәргә җыенмый аны. Ир-ат иң элек житди рәвештә уйланырга, бары шуннан соң гына җавап кайтарырга тиеш түгелмени? Ә Асиянең үзенә шундый сорау бирсәләр?.. Аның да үз гаиләсе — ире һәм улы бар. Алар хакында уйламый гына җавап кайтара алыр идеме соң ул үзе?! Аның ир хатыны һәм ана булуы хакында Арслан да белә, чамалый торгандыр, бәлки. Ләкин сүз гена кузгатмый бу хакта. Ул хакта сүз кузгатып, аны кыен хәлгә куюдан уңайсызлана булса кирәк. Хәер, Арсланның, гомумән, аның эше, гаиләсе, кайда торуы һәм ничек яшәве хакында сүз кузгатканы юк. Ничек аңларга моны?..

Юк, Асия өчен ул сорауларның кирәге юк. Әмма Арсланның кызыксынмавы сәер. Ничек инде, үзең өчен якын һәм кадерле булган кешенең хәле, гаиләсе хакында шул гомер берни кызыксынмый түзәргә кирәк! Соң чиктә, күңел булсын өчен генә дә сораштырырга була торгандыр иң. Әллә ул аны гаиләсез, ата-анасыз бер мескен, җиңел акыллы ялгызак хатын-кызга чыгарамы?..

Уендагы теленә кучеп, кинәт, шул хакта сүз башлавын хәтта үзе дә сизми калды:

— Арслан, нигә син минем гаилә хәлем, ирдә булу-булмавым белән кызыксынмыйсың?

— Барыбер түгелмени? — Җавап җиңел һәм бик гади икән иң.

— Ирдә булу-булмавым барыберме? — дип кайтарып сорады Асия һәм үз колакларына үзе ышанмады.

— Барыбер,— дип кабатлады Арслан, ирен читләренә төшеп торган мыек чылгыйлары белән аның муенын, колак артларын иркәләргә керәште.

**Муен** тирәсендә йөргән мыеклы борынны үзеннән читкә тибәрәсе килде Асиянең. Беренче тапкыр Арсланның иркәләүләренә битарафлык күрсәтте. Күзләрен зур ачып, сораулы карашын югары күтәрде:

— Ничек ул — барыбер? Ничек алай була?..

— Шулай,— дип, берни булмагандай канәгать елмайды ир-ат.

— Ә яратам дигәнеңне, иркәләүләреңне ничек аңларга?

— Ничек бар, шулай итеп. Туры мәгънәсендә... Мин бит гаиләңне түгел, сине, үзеңне яратам, Асия.— «Яратам»ны авырлык белән генә, әйтергәме, әйтмәскәме дигәндәй генә ычкындырды ул. Андый сүзне, башкалар кук, уңга-сулга сибә торган ир-ат түгел иде, күрәсең.— Ирең булу-булмау — анысы синең эш. Миңа кагылмый ул кадәресе...

— Шулай да... Сиңа барыбер булырга тиеш түгел. Минем...

— Әйттем иң, кирәкми, Асия. Минем өчен болар әһәмиятсез.

Шул рәвешле, барын уртага салып аңлашырга әзер булган, ниһаять, җай һәм ара тапкан хатынга сөйләп бетерергә ирек куймады ул. «Минем ирем һәм улым бар. Синең — хатының һәм кызың... Арабызда дүрт кеше!» — дип сөйли башлаган иде Асия. Арсланга шуларны аңлатып, аңардан бер-бер киңәш алырга иде исәбе. Ярдәм итсә, ул гына ярдәм итәр кебек тоела иде аңарга. Юкса, бу рәвешле озак дәвам итә алмый. Алдашып, качып-посып сөешәсе килми аның алга таба. Чын мәхәббәт өчен чит-ят булырга тиешле ялган-йолган купме дәвам итәргә мөмкин?! Мәхәббәт чын һәм ихлас, эчкерсез булсын өчен, сөешүчеләрнең тулы азатлыгы шарт түгелмени?!. Кесә карагы сыман ялт-йолт карангалап, яшереп, урлап очрашуларның иртәме-соңмы барыбер ахыры булачак иң. Җан тынычлыгы һәм намус чисталыгына ни җитә?!.

Намус... Нәрсә сөйли, нигә искә ала Асия бу сүзне?.. Намус хакында сүз катарга хакы бармы соң аның?! Бар!.. Ник булмасын, ул ярата иң. Газапланып, әрни-әрни ярата ул Арсланны. Аерылышкан мизгелдән үк сагына башлый, булачак очрашуларын көтеп яши. Бары тик аның хакында уйлана, урамнардан аны эзли, узган бер машинага, ул булмады микән дип, текәлеп кала... Ничек газапланып, ни дәрәҗәдә өзелеп яратканын үзе генә, бары тик үзе генә белә Асия. Ә аны берәү дә аңларга теләми һәм аңламаячак микәнни? Бер кеше, бары ул гына аңлар кебек тоела иде. Бүген менә күпме гомер көткән, кичектереп килгән сорауларын бирергә җөрьәт итте ул аңарга. Тыңларга теләмәде. Аңларга теләмәде...

Шулай да гаепләмә соң ул? Шушы хәленнән дә намусын буямый чыгу юлы бармы аның өчен? Намус... Бу хакта уйланырга, фикер йөртергә хакы бармы аның?.. Ялгышмыймы? Ялгыша икән, нидә хаталана?.. Сораулар... Сорау өстенә сорау. Ник берсенә ачык кына, төгәл генә җавап биреп, җавап табып булса икән. Бар дөньяны, дөнья белән бергә үз-үзеңне алдап, бу рәвешле озак яшәп булмас...

— Арслан...— дип дәште, Арсланны иңсәләреннән тотып җилтерәтте Асия. Шул сорауларының берсенә генә булса да җавап бирүен үтенмәкче иде.

Арслан дәшмәде. Арслан йоклый иде. Чалкан борылып ятты да гырларга кереште Арслан.



## 7

Уку җәһәтеннән әнисенең йөзенә кызыллык китергәне булмады Асиянең. Төннәр буе китапларыннан аерылмый утырса утырды, әмма «өчле»-не көндәлегенә кертмәде. Дөрес, табигый ихтыяҗ, чын ярату һәм кызыксыну белән уку түгел, ә бәлки үзенә күрә бер хезмәт, алынган йөкләмәләрне үтәү кебегрәк нәрсә иде бу аның өчен.

Ә шулай да мәшәкатьләр чыгып кына торды. Әйтик, кызлар үскән гаиләдә кием-салым һәм мода дигән нәрсә теңкәгә тиеп аптырата торган була. Асия сигезенче классны тәмамлыйсы язны шәһәрдә вельвет чалбар модага керде. Классларындагы берничә кыз әллә ни арада тапты һәм кия дә башлады шул чалбар дигәннәрен. Ит чабучы кызы Рамилә күз өстендәге кашка әверелде иң элек. Аннан соң бу чалбарга әнисе партиянең шәһәр комитетында дәрәҗәле хезмәттә булган Юлия житеште. Бераздан — тагы берничә кыз... Шул көнгәчә бер-береннән артык аерылып тормаган кызлар кинәт икегә бүленделәр дә куйдылар. Вельвет чалбар киеп алганнары — мәктәптә булсын, урамда булсын — үзләренә күрә аерым бер каста тәшкил итеп, күкрәкләрен киереп, борыннарын чөеп йөрергә кереште. Вельветлылар һәм вельветсызларга бүленде кызлар. Егет булырга ният итеп йөргән малайлар да күбрәк шул чалбар киеп алган кыз-кыркын тирәсендә бөтерелә, шаяргалый торган булып китте. Моңа кадәр, мәктәптә булсын, анда барганда-кайтканда булсын, Асиядән бер адым калышмый тагылып йөри торган Рамилә, чалбар киеп алгач, һич тартынусыз, аңардан читләште, үзе кебек кәттәрәк кызларга тартыла башлады. Ә инде очраклы рәвештә юллары туры килсә, сүз кием-салым тирәсендә булды.

— Үзең завуч кызы, үзең фирменный чалбар да кимисең,— диде ул көннәрдән беркөнне.

Күзгә бәреп, һичнинди тартынусыз-нисез, сүзне чалбардан — Асиянең иң авырткан җиреннән башлады Рамилә. Кәеф кырылу гынамы соң, тәннәре эсселе-суыклы булып китте Асиянең, җен ачуы чыкты. Җавапсыз калып буламы шундый чакта?

— Чалбар кәкре аяклы кызлар өчен генә, чалбар кияргә яратмыйм,— диде ул.

Рамиләнең дә, үз чиратында, колак очларына кызыллык йөгерде — авырткан урынына кагылдылар. Ләкин ул да заман баласы иде шул, ис китмәгән кыяфәт ясап, елмаерга иткән булды.

— Җаным-Асенька,— дип, араларында бернинди төртмә сүз әйтешү булмаган сыман, уртак темага күчте ул.— Игътибар иттеңме икән, менә Юлькада ул... чалбар. Фирма-а! «Маде ин уса», беләсең килсә. Чуклары елык-елык итеп тора, артында алтын йөгертелгәндәй ялтыраган калайлары бар. Чалбар дисәң дә чалбар, Асенька-җаным...

— Синеке дә матур ич,— дип, көнчелектән хафаланган иптәш кызын юаткан булды Асия. Берочтан үз-үзен дә тынычландыруы иде. Кая инде аңарга — гади укытучы кызына!.. Ә югыйсә, әллә ниткән «фирма»лысы түгел, иң гадәтие генә булса да түбәсе күккә тияр иде Асиянең. Гомергә кибет киштәләрендә тузан җыеп яткан, һичкемгә кирәге чыкмаган вельветлар да су төбенә олаккандай юкка чыккан иде шул ул көннәрдә.

— Фирмага житәме соң?! — дип, үзенекен итте, хыялыннан кире кайта алмый аптырады иптәш кызы. Асия дә чын-чынлап кызыксынып китте:

— Юлькадан сорамадыңмы, каян алды икән?

— Кибеттән түгел, билгеле...

— Базарданмы?

Шул соравы белән классташы каршында көлкегә кала язды Асия.

— Юля кебекләр базардан түгел, базадан ала.— «База» сүзенә аерым басым ясап әйтте кыз.— Базадан... һәм беренче проба!

Мөгаен, бу Асиянең «база» сүзен тәүге кат ишетүе булгандыр. Шәһәрдә шундый урын барлыгы уена да кергәне юк иде аның әлегәчә. Һәм шул көннән бу сүз аның өчен изге мәгънә аңлата башлап, буй житмәс бер биеклек сыман тоелуы да сер түгел иде. Ә инде, еллар узгач, үзенең шундый базада эшләүче бер-бер кеше белән танышу ихтималын башына да китерә алмагандыр ул.

Сигезенче класста укыган Асия бертын дәшми генә атлады. Рамиләнең әллә ниләр белүенә исе китеп барды. Шулай да әлеге серле төшенчә, иптәш кызы аерым бер тәм һәм мәгънә белән искә алган «база» сүзе күңеленнән китмәде аның. Бераздан, горурлыгын җиңеп булса да, кире кайтарып сорарга мәҗбүр булды:

— Ерактамы? Кайсы шәһәрдә соң ул база дигәнең?..

Укытучы кызларыннан көлү җае гел-гел чыгып тормый, форсатыннан файдаланып, рәхәтләнеп көлде Рамилә:

— Шуны да белмисеңме?!. Кайда булсын, һәр шәһәрдә булган кебек, безнең Казанда да бар ул. Бөтен дефицит товар шунда кайта. Шуннан таратыла!..

Түбән карап, үзалдына уйга бирелеп барды Асия. Әнә ничек икән, чит шәһәрләргә барып йөрисе түгел, үз шәһәрләрендә бар икән ич база... Моның шулай булуы куандырды аны хәтта.

— Анда чират бик зур була микән? — дип, уена килгән сораунны бирми кала алмады ул.

Рамиләгә ни?! Рамиләгә шул гына кирәк. Үзенең өстенлеген, бу өлкәдә үзенең күпкә мәгълүматлырак булуын танып, кеткелдәп үк көлеп җибәрде.

— Беркатлы да соң инде син, Асия... Шуны да белмисең! Базада чират тормыйлар. Зур житәкчеләр... һәм блатлы кешеләр генә килеп ала товарны базадан. Иң элек — «беренче проба», аннан — «икенче», «өченче». Һәм шуннан соң — төрле таныш-белеш, туган-тумачалар китә.

— Ә «проба» дигәнең нәрсә? Беренче проба...

— Беренчесеме?.. Ул хакта уйлап башыңны катырма, Асия! — Зур сер уртаклашкан сыман, пышылдауга күчте кыз. Як-ягына карангалап алды.— Беренче пробаны сәүдә кешеләре һәм тагы... шәһәрнең иң олы житәкчеләре, шуларның хатыннары ала, диләр...— Янә як-ягына күз салып алды Рамилә.— Ирләренең служебный «мотор»ларына утырып ки-

ләләр дә выжлап кына керәләр ди ишегалдына. Үзләренә, кызларына ни кирәк булса, шуны төяп кайтып китәләр икән. Каршыларына база директоры үзе чыга да, ни сорасалар да, «пожалыста-пожалыста» гына дип тора ди...

— Каян беләсең?

— Юля сөйләде.

— Кызык... Чынлап та, кызык нәрсәләр сөйләдең бит әле син, Рамилә. Чит ил киноларындагы кебек.

— Әйе, буржуйларың бер читтә торсын, шулай бит?!.

— Безнең кебекләрне кертмиләрдер инде анда, алай булгач, ә?

— Тот капчыгыңны! Көтәләр ди анда... синең белән мине.

— Ә бит җәмгыять белемендә нәрсә диелгән?!. Тигезлек дип язылган.

— Укытучы кызы!..— дип, пырхылдап көлде Рамилә.— Китапка ни язмаслар!

— Китап түгел, дәреслек! — дип, җитди төзәтмәсен кертергә ашыкты укытучы кызы.

— Дәреслек...— бу сүзне дә шундый ук чытык елмаю белән кабатлады, тирән итеп сулыш алды Рамилә.— Базамы?.. База ул, беләсең килсә, җаныкаем Асенька, база — ул тормыш! Юк, Рамилә сөйләгәннәргә барыбер ышанып җитмәде Асия. Ничек инде безнең җәмгыятьтә шундый законсызлыкларга юл куелсын ди? База — тормыш, имеш. Булмый торсын әле! Җитәкче кешеләр турында да шулай уйлап ялган сөйли Рамилә. Юлия кебек кызлардан көнләшкәнгә генә шулай сөйли торгандыр әле!

Шундый уйлар белән үз-үзен тынычландырды ул. Ә күңеленнән, колак төбеннән иптәш кызы сөйләгән яңалыклар китми аптыратты. Зур тимер капка артында урнашкан әлеге базаны күз алдына китерде, аның складларында тау-тау булып өелеп торган затлы вельвет чалбарларны, шул чалбарларны алмага килгән дәрәҗәле кешеләрне һәм ике сүзнең берендә «пожалыста-пожалыста» дип торган база мөдирен күргәндәй булды.

Асияне матур уйларыннан бүлеп, тротуар читенә ап-ак «Волга» машинасы килеп туктады. Үзалларына онытылып барган классташлар, берьюлы сискәнеп, читкә тайпылдылар.

— О-ой, кызлар!..— дип, яман бәхетле елмаеп, машинадан нәкъ менә Юлия үзе килеп чыкмасынмы! Әйе, тәненә сыланып торган үтә затлы вельвет чалбар, бераүнең дә төшенә кермәгән алсу кофта кигән бу сылу кыз — гомере озын булыр — әлеге дә баягы Юлия — аларның классташлары иде. Колагында елык-елык килеп торган асылташлы көмеш алка, бармаклары саен дип әйтерлек йөзек, беләгендә беләзек — карап торсаң, тәмам күз камашырлык...

Ак машинадан төшкән Юлия асылташларыннан да болайрак балкып исәнләште. Шул арада, ачык ишек аша, руль артында утырган чал чәчле агайга да кул изәргә өлгерде:

— Көтеп тормагыз, дядя Коля, җәяү генә кайтырмын.

— Ярый, Юлия, сау бул,— дип җавап кайтарды рульдәге абзый.— Иртәгә музыкаң сәгать ничәдә бетә әле синең?

— Төп-төгәл өчтә, дядя Коля.

Үзе артыннан ачык калган ишекне ябып тормый гына, классташлары белән китеп барды Юлия.

— О-ой, кызлар! — дип, җай гына үкчә биетеп барган көйгә, әле бер, әле икенче кызга борылды, уртаклашасы килгән яңалыкларыннан, хисләреннән буылыр дәрәҗәгә җитеп килгән икән.— Беләсезме, минем каян кайтып килеш?

Кызларның һәр икесе зур кызыксыну белән аңа текәлде.

— Әнием белән Үзәк универмагка бардык. Ой, кызлар, күрсәгез

икән андагы хикмәт, андагы товар! Директорлары да яшь кенә бер егет икән, ну-у, ничәләрдәме?.. Ну-у, шул бер кырыклар тирәсендә... Шул директор, беләсегез килсә, йөгереп кенә йөри... Әле бер дефицит, әле икенчесен тәкъдим итә. Во, закачаешься!.. Импорт.. Италия!.. Франция!..

— Сөйлә, ни саталар? — дип, түземсезләнде Рамилә.

— Кем сата?.. Нәрсә сөйлисең, Рамилә? — дип, борынын җыерып куйды Юлия.— Чыгардылар ди, саттылар ди сиңа. Тот капчыгыңны, залга чыгарырлар... «Беренче проба»га әнине чакырганнар.

— Башкаларны кертмиләрме?..— дигән сорау өзелеп төште тәкатьсез калып тыңлап барган Рамилә авызыннан. Асияне дә борчыган сорау шул иде.

— Ник кертмәсеннәр ди! Барыгыз да керегез, универмаг тәнәфессез эшли.

Сораулы карашын бер — Асиягә, бер Юлиягә текәп алды икеләнә калган Рамилә. Киттек дип әйтүче булса, шул минутта ук универмаг тарафына йөгерәчәк. Кызык ич...

Кеткелдәп көлеп җибәрде Юлия, Рамиләнең беркатлылыгыннан көлүе иде әлбәттә:

— Беләсең килсә, Рамилә, универмагның сәүдә залларын күргәнем дә юк минем. Ишекләре кай якка ачылганын белмим. Арткы якта бер нәни генә служебный ишеге булыр универмагның. Дәү-дәү кешеләр шул ишектән керә, беләсең килсә... Һәм кулларын кесәгә тыгып кына кире чыгалар. Ә товарны...— Юри, пауза ясап, классташларына сынап карап торды Юлия.— Ә товарны йөкчеләр машина багажнигына гына чыгарып сала. Менә шулай, кызлар...

Тыңлаучылар ни дисен, телләрен тешләп барудан башка чаралары юк, билгеле. Рамилә булып, ул да сүзсез калды. Сөйләгәннәренең нинди тәэсир ясавын чамалап өлгергән Юлия, бермә-бер җанланып, тагы да мавыгыбрак сөйләргә кереште:

— О-ой, кызлар!.. Күрсәгез иде, кызлар... Мин креслода гына утырган булам. Аякны аякка атландырдым да утырам... Исем китми, янәсе... Үземнең күзләрем йөгерә, югыйсә барысын да аласы килә. Теге симпатичный директор әле бер босоножка алып килә, әле икенчесен... Үрелеп аякларыма кидерә. Кулы калтырый тегенең, колаклары кызарып чыкты. Әни сизмәгәндә генә миңа күз кысарга иткән була әле тагы... Ә үзенең баш түбәсендә тамчы да чәч калмаган. «Монысы ошыймы соң?» дигән була. Мин — баш чайкыйм, ноль внимание... Эзли торгач, иң соңгысы итеп кенә шундый нәфисен алып килде... Ой, кызлар, баш әйләнерлек менә. «Менә монысы, дим мин тегеңә, бара, төрегез». Әни шатланды. Әнидән бигрәк симпатичный директор үзе шатланды. Мәктәпкә киеп килгәч, менә күрерсез әле, кызлар, шаклар катарсыз...

Көлешә-көлешә сөйләшеп килгән кызлар кинәт туктап калдылар, Юлиянең карашы төбәлгән тарафка текәлделәр. Алар узып барган ишегалды читендәге подвал каршында зур гына чират тезелгән иде. Шул чиратның очында, шешә тутырылган дәү сетка күтәреп, талчыбыктай сузылган үсмер малай басып тора.

— Күрегез әле, кызлар, күрегез, безнең Алик түгелме соң?..

Үзенә төбәлгән өч пар карашны чиратта торучы үсмер дә абайлап өлгерде. Уңайсызланып, әле бер якка, әле икенче якка борылды, нишләргә белмәде. Һәм, чигенә төшеп, чиратта торган бер әби артына кереп посты. Кызларның классташлары Алик иде бу. Асия яхшы белә: ул көн аралаш шулай шешә тапшырырга килә. Ә кайтышлый ипи һәм сөт кибетләренә кагыла. Әтисе төрмәдә аның. Ә әнисе... үз ишләре белән җыйнаулашып, көн-төн аракы эчә. Шулардан калган шешә хисабына, үзен генә түгел, алты яшьлек сеңелесен дә туендырып торырга мәҗбүр Алик.

— Җыен эчкече арасында шешә тапшырып йөрмәсә,— дип борынын

җыерып алды Юлия.— Ничек оялмый ул?!. Үзе комсомол да бит әле тагы...

Юлиянең сүзләрен хуплаучы да, аңарга каршы төшүче дә табылмады. Юлларын дәвам иттеләр. Юлия генә, бераз үткәч, кире борылып, шундый тәкъдим кертте:

— О-ой, кызлар, карагыз әле, карагыз! Безнең Алик ояла да белә икән бит. Үзе кеше артына поскан, үзенең муены тырпаеп тора... Безне күзәтә ул. Әйдәгез, болай итик: өчәүләп янына җитәкләшеп барыйк та, «Исәнме, Алик...» — дип күрешик үзе белән. Ни дип җавап бирер, нәрсә дияр икән?.. Кызык ич, ә, кызлар?!.

Тәкъдименең никадәр көтелмәгән булуыннан дәртләнеп, хәтта кулларын чәбәкләп, торган җирендә сикергәләп куйды кыз. Юлия белән Рамилә, чырык-чырык көлешеп, классташлары Аликны оялтырга китеп бардылар. Бу шаяруның ахыры яман булуын чамалапмы, болай да күптән өйдә булырга тиешле Асия, классташлары белән хушлашырга да кирәк тапмыйча, ашыгып, кайтыр юлга борылды. Шунысы үкенечкә калды, ниятләреннән кайтырга өндәмәде ул аларны, юлларына аркылы төшмәде.

Баштанаяк «фирма»дан киенгән Юлия Аликның каршысына ук барып басты, малайның күзенә текәлде. Рамилә аның ышыгындарак калды. Гәүдәсе сорау билгесе сыман сыгылып төште үсмер малайның, кулларын, кулындагы шешә тулы сеткасын кая яшерергә, кайсы кулына күчерергә белми иза чикте... Ә кызларның уйларында да юк китеп бару, малайның ничек өзгәләнүен, аңарга бик тә уңайсыз икәнлекне күрмиләр түгел, югыйсә. Күрәләр... Ә китмиләр. Аларга кызык. Килгәч-килгәч, берсүзсез борылып китеп булмый бит инде, Юлия үзенең комсомол секретаре икәнлеген искә төшерде:

— Иртәгә дәрескә киләсеңдер бит? — диде.

— Ну-у,— дип кенә җавап бирде Алик, сеткасын кулдан-кулга күчереп куйды.

— Дәресләрдән соң комсомол җыелышы була. Онытма...

— Ну-у,— диде малай, ипле генә итеп борын тартты.

— Взносың да түләнмәгәндер әле?

— Ну-у...

— Җыелышта сөйләшербез,— диде дә, иярә килгән Рамиләне үзе артыннан калдырмыйча, кырт борылып, зур эш кырган сыман китеп тә барды Юлия.

Ай-һай сылу яшьләр үсеп килә дип, үзалларына сокланып уйлап калгандыр чиратта торучылар...

Алик кына мәктәпкә дә, комсомол җыелышына да килмәде иртәгәсен. Гомумән, мәктәптә күренмәде ул башка. Берәүнең дә, хәтта укытучыларның да исе китмәде моңа. Әти-әнисе дә әллә кем булмагач, шулай тиеш сыман кабул ителгәндер инде. Мәктәпне ташлаган, кайдадыр, ниндидер һөнәр училищесында укый башлаган, диделәр тагы бер елдан... Шуннан ары, Аликны искә алучы, аның язмышы белән кызыксынучы булмады да кебек...

Ә теге көнне Асия туп-туры өйләренә кайтты. Дөньяның шулай тигезсез булуына кәефе кырылып, җаны әрнеп, үксеп-үксеп елыйсы, туйганчы елап бушанасы килә иде аның. Ник һәркем дә Юлия кебек бәхетле түгел — үзе теләгәнне киеп, теленә ни эләкте шуны сөйләп йөри алмый? Ни кисә, шул килешә аңарга, ни сөйләсә — дөрес. Укытучылар булып, алар да аның кимчелеген күрми, күрсәләр — күз йомалар. Алгы рәттә ул утыра, аңарга ышаналар, аны сайлыйлар, аны мактап туймыйлар... Нигә соң бу дөньяда Алик кебекләргә яшәве кыен?.. Намуслы, эшчән, сабыр егет иде, югыйсә. Аның гаебе нидә, әти-әниләр өчен нигә бала җавап бирергә тиешле?!. Юлдан язган ата-аналарның балалары да газап чигәргә, кимсенергә, кыерсытылырга тиешлеме? Эх, Алик, Алик... Шундый кызганыч булып тоелды ул Асиягә... Кулыннан килсә, Юлия кебекләрдән ул Аликка һичбер авыр сүз әйттермәс иде... Кулыннан килми —

Юлия белән янәшә туры килдеме, телен йота, сөйләшмәс булып кала.

Теләгән чакта еларга да хокукы юк ич аның. Кайтып, караватка капланды булды, артыннан ук әнисе кереп житте:

— Китәсең дә югаласың, китәсең дә олагасың, кайда йөрисең син, кызый?!. Синең өчен имтиханнарыңа кем әзерләнер?

— Юлия әзерләнсен, әнә!.. Белсә дә, белмәсә дә — бишле куясыз,— дип, күңелендәге рәнжүне берьюлы чыгарды кыз.

— Син башкаларны күрсәтмә. Үзеңне бел, кызый! — Ана бераз басыла төште. Сүзнең кая юнәлгәнен чамалап өлгерде булса кирәк.

Ана күңеленең йомшарып алуын кыз да сизеп алды. Сизеп алды һәм үз файдасына аударды.

— Имтихан да имтихан... Башка сүз белмисең шул син...— дип, иренен турсайтты, канәгатьсезлеген белгертергә ашыкты.— Кызлар анда вельвет чалбар киеп йөри. Минем алардан кай җирем ким?! Завуч кызы дигән исемем генә бар...

— Алырбыз, кызым, алырбыз сиңа да.

— Ничек? Каян алырсыз?!

— Анысы — минем эш, кызым. Сиңа имтиханнарыңны бишкә генә биреп чыгарга кирәк әле иң элек.

Ана — укытучы кеше, гел юктан гына имтиханнары алдыннан дулкынландырырга теләми кызын. Башка чак булса, кем белә, өлкәннәр белән ничек сөйләшергә кирәклеген өйрәтер иде ул аңар. Юмалау сүзләрен кызганмады, башыннан сыйпады, иркәләп тә алды хәтта кызын. Һәм, ялгызын гына калдырып, кухня якка чыгып китте. Бер уйласаң, чынлап та, урынсызга хафаланмый икән ич аның кызы, уйлана, дөреслек эзли. Шул рәвешле каршылыклар белән көрәшә-көрәшә, яңа шәхес формалаша. «Дөрес түгелмени,— дигән уй үтте тәҗрибәле укытучы башыннан.— Нигә дип әле эти-әниләренең кем булуы, кайда һәм нинди дәрәҗәле урында утыруына карап, балалар да төрле-төрле язмышка юлыгырга тиешләр?! Макаренко булсын, Ушинский булсын, хупламыйлар ич мондый шартларны... Тәрбия эшендә тигезлек, дөреслектән башка мөмкин түгел. Бер гаделсезлек күрдеме, ул баланы инде иманга кертермен димә — күптәнге хакыйкать!.. Җаваплы эш башында утыручылар онытмасын иде бит бу хакта. Уйласыннар иде, тәрбия эшендә күпме югалтулар кичерәбез без шул килде-китте чүпрәк-чапрак, тәм-том аркасында. Булса — һәркемгә тигез, булмаганы шулай ук уртак булырга тиеш түгелмени?.. Яшьлектә бераүнең дә үзен башкалардан ким-хур итеп күрәсе, таныйсы килми. Шул эчтән генә яну-көю, кимсенүләр түгелмени бөтен начарлыкның башы?.. Кимсенү — көчсезне ялганга өйрәтә, урлашу юлына илтә. Үз эченә бикләнеп кичерүләр зәгыйфь тамырлы үсмерне кешелексез итә... Тигезсезлек — берәзлексез кимерә, эчтән ашый, актара сәламәт яшь җанны... Үзенең укытучылык иткән гомерендә аз очратмады ул моның гыйбрәтле мисалларын... Бердәнбер кызының хәленә керүдән хәтта күз яшьләре бөреләнеп алды ананың.

## 8

Арслан белән очрашасы көннәрен, сәгатьләрен көтеп ала алмый газапланды Асия. Ул чакырса, көннең, тәүлекнең теләсә кайсы сәгатендә, шәһәрнең теләсә кайсы төбәгендә очрашырга әзер булып яшәде... Эштә хәленә керүче бар. Ателье мөдире Әнзия Закировнаның мөнәсәбәте тамырдан үзгәрде дә куйды. Бәйләнүләреннән туктады. Ул гынамы, авызыннан сүз чыкмас борын ук, «Рөхсәт, Асенька», «Рәхим ит, Асенька», «Аңлыйм, аңлыйм, ихтыярың, Асенька»,— дип кенә җавап бирә хәзер мөдир. Осталыгы үскәндерме-юкмы, тегүче буларак та дәрәҗәсе күзгә күренеп алга китте. Классын күтәрделәр, үзен махсус заказлар буенча

эшли торган цехка күчерделәр. Клиентлары да хәзер килде-китте генә түгел... Ачыктан-ачык һичкемгә сүз катмаса да, чамалый иде Асия: бу үзгәрешләрнең сәбәбе универсаль база мөдире Арслан Сәхиповичка бәйле. Аның бетмәс-төкәнмәс дан, дәрәҗә һәм гайрәтеннән шулай итеп Асиягә дә өлеш чыга башлады.

Ә өйдә?.. Әйе, Асиянең гаиләсе дә бар бит әле. Турысын гына әйткәндә, өйдә — ул үзе хуҗа, бу тарафтан үзенең теләк һәм омтылышларына каршылык күргәне юк иде әле аның. Бары да Асия дигәнчә булырга тиеш, тәртип шулай куелган. Уңга-сулга карамастан, ни теләсә шуны эшләргә күнеккән яшь-чибәр хатын бит ул. Өйдә аны яраталар, аңа ышаналар, һәм аны тәүлекнең теләсә кайсы вакытында көтеп каршы алучы бар.

Һәр яңа көн туган саен, үз гаиләсеннән ерагайганнан-ерагая баруын тоеп, үзендә барган шул үзгәрешләр белән килешеп яшәде Асия. Тулай торактагы шырпы кабы сыман кысан бүлмәләре хакында искә дә алып торасы юк. Хәер, күңелендә ул кысан бүлмә дә, анда үзен көтеп торган ире һәм улы да түгел әле аның. Хәзергә күзләре — тәрәзәдә, эш кайгысы да качкан үзеннән. Тагы санаулы гына минутлардан соң, сәгать өч тула. Өчләр тирәсендә аны алмага машина килергә тиеш.

Вакыт дигәнең сәер ич ул. Кайчак аның ничек узып киткәнлеген дә сизми, абайламый каласың. Ә син көткәндә, сиңа кирәккәндә, ул ташбакадан да болайрак кыймылдый, гүя туктап тора. Бүген дә сәгать өч тулганны көтү үзе бер гомер иде.

Ниһаять, көткән сәгать җитте. Өч тулды... Дүртенче китте. Кул сәгатенең секунд күрсәткече, ялкау чикерткә сыман, теләр-теләмәс кенә алга таба сикергәләвен дәвам итә. Өч тулып бер минут... Өч тулып ике... Өч... Гүя Асияне без өстенә утыртканнар. Әллә? Әллә соң килми калырга җыенамы? Бер-бер кичектергесез мәшәкате килеп чыкканмы? Күңелсезлек, бәла-каза була күрмәсен! Аягөсте йоклап, юкка-барга соңарып йөри торган ир-ат түгел Арслан. Ни булды, нәрсәгә юрарга? Сәгать угы инде тәмам кабаланырга, сөрлегергә үк кереште түгелме?..

Тагы күпме вакыт узгандыр, хәтерләми, бөтен әйләнә-тирә тоташ саташу, тоташ чыңга әверелеп бара иде бугай инде. Кинәт, биек үкчәләре белән дөнья яңгыратып, бүлмәгә Әнзия Закировна килеп керде.

— Асенька,— дип дәште ул әйләнә-тирәдәгеләргә дә ишетелерлек итеп. Күрше бүлмәләргә дә яңгыраган булырга тиеш аның тавышы.— Асенька, әйдә, җыен... Сине профсоюз киңәшмәсенә чакыралар. Эшеңне калдырып тор, профсоюзлар — коммунизм мәктәбе! Андый киңәшмәләргә соңга калып йөрү килешми.

Үзе җитди һәм эшлекле итеп, бөтен цехны яңгыратып сөйләшә иде мөдир, ә башкалар күрмәгәндә, Асиянең үзенә генә аңлаешлы итеп, елмаю катыш күз кысып алырга да өлгерде. Шул бер карашына горурлык та, үз-үзенә ышаныч һәм канәгатьлек тә сыешкан иде аның: «Шәп килештерәмме, янәсе, әнә мин нинди... Әнзия Закировнаның кадерен белергә кирәк.» Ни генә әйтсәң дә, ателье мөдире — шәп конспиратор. Кирәк икән, берьюлы җиде-сигез хатын-кызның күз карашын, нәрсә уйлаганын күреп, чамалап, колачлап өлгерә. Берьюлы сигезенә сигез төрле ым, караш, мәгънә җиткерергә сәләтле.

Асия дә төшеп калганнардан түгел:

— Ой, Әнзия Закировна... Нигә аны алданрак әйтмәдегез. Мин бит, ни-и, җиңелчә, чалбардан гына килгән идем. Профсоюз... дисез инде алайса? Башка бүтән берәүне җибәрәсезме соң әллә?..— ди.

— Юк-юк, атап чакырганнар!

— Атап чакырганнар?.. Бер мин генә дигәнме? Әллә ничек ич болай, уңайсыз димме...

Әйе, килештерепме-килештерәләр! Гомумән, мин үзем болай уйлыйм: хатын-кызның күпчелеге ана карынынннан ук артист булып туа торгандыр ул. Уйныйлар ич, әнә...

Әйе, тартынды Асия, нык кына уңайсызланды: «Тартынусыз-нисез генә ничек инде тиктомалдан, көпә-көндез эшне ташлап китәсең... Анналары бит әле бу цехта мин генә түгел, миннән башка да хатын-кыз житәрлек... Аларның да барасы килмиме?..»

— Бар инде, бар, Асия! Чакырган жиргә бар, куган жирдән кит, дигән бит халык,— дип тә өстәп куя шунда хатыннардан берсе. Илләдә мәгәр киң күңелле, кешелекле һәм кайгыртучан бит ул безнең халык — сокланып туймассың аның шундый гадәтләренә. «Нигә?», «Ни сәбәпле?» дигән сорауларны аны әле яңа гына кузгата башладылар.

Коллектив сорый икән, ничек инде коллектив сүзен тыңламаска мөмкин?.. Теләр-теләмәс кенә як-ягына карангалап алды Асия. Инде әллә кайчан хәстәрләп тотырып куелган нәни сумкасын аркасына алып атты да урыныннан торды:

— Әллә ничек иң, Әнзия Закировна...

— Хафаланма, Асенька, хафаланма... Сиңа ничек тә килешә, Асенька,— дип, аркасыннан сөеп алган булды мөдир. Сүз тыңлавың өчен рәхмәт, янәсе. Үзе булып каласы килүдәнме, берочтан аз гына шаяртып алырга да өлгерде.— Кара аны, Асенька, профсоюз активистлары үзеңне урлап калмасыннар!

— Хушыгыз, кызлар...

— Хәерле юл, Асия...

Ул нинди профсоюз киңәшмәсе? Коллективка аягы керсә дә, башы кереп житмәгән Асиянең профсоюз киңәшмәләренә ни мөнәсәбәте бар — болары хакында цехта калучылар арасыннан ник берәве уйлап карасын икән шунда?! Мөдир кеше әйткән икән, димәк, дөрес сөйли. Дөрес сөйләмәсә дә — закон. Уйладың ни дә уйламадың ни; сорадың ни дә сорамадың ни — барыбер ул дигәнчә булачак. Нәрсә, сездә алай түгелмени?.. Булмас, ышандыра алмыйсыз, билләһи дим.

Һәркем үзалдына уйлап, исәп-хисап итеп тә куя бит әле аны: Асия яшь, шуның өстенә әле чибәр дә, үз-үзенең бәясен, чамасын белә торган хатын. Сер түгел иң: тегендә-монда сайлаганда янсә чакырганда, хатын-кызның чибәррәкләренә жирәбә төшүчән була. Хәер, нигә соң әле моны мин сөйләп торам?.. Гомер-гомергә шулай килгән бит инде ул, әйтерсең, бер бүген генә. Тапкансың диярсез шаккатыр, искитәрлек яңалык...

Жиңел машина Асияне билгеләнгән урында көтеп тора иде. Шофер гына түгел, Арслан үзе дә килгән иде бүген.

— Шашлыкка! — диде ул, янәшәсенә кереп утырган Асия белән исәнләшергә дә өлгермичә. Күрәсең, бу — берочтан шоферга бирелгән әмер дә иде булса кирәк.

«Волга» машинасы, зур тизлек алып, шәһәр читенә таба элдерде. Светофорлар каршысында тукталсалар туктадылар, туктамасалар юк, дигәндәй: шофер эшнең ашыгыч икәнлеген чамалап алган иде. Урам аша чыга башлаган жирдән, өсләренә куып килгән машинадан өркеп, кире тайпылырга мәжбүр булган кешеләр, Аккош күлләренә таба элдерепмә-элдертүче бу машина артыннан ниләр уйлап, гөман кылып калды икән шул көнне?! Бу машина ашыгыч һәм жаваплы бер-бер житди эш янсә дәүләт йомышы белән шулай ашыгадыр дигән нәтижә ясаган булсалар кирәк. Арткы утыргычтагы почмакка посып, тәкатьсез яшүсмерләр сыман бер-береннән аерыла алмый үбешеп барган ир-ат һәм хатын-кызны абайлаучы булмагандыр, әлбәттә. Шундый кызу эш өстендә — авылда урак башланган көннәр, завод-фабрикалар айлык план үтәү мәшәкатьләре белән көнне — көн, төнне төн дип белмәгән чакта — дәүләт эше белән булмый, тагы кая шулай кабаланып ашыгырга, куаларга мөмкин машинаны?!

— Нигә сорамыйсың,— диде Арслан, чак-чак сулыш алып.

— Нәрсә хакында? — дип гажәпсенеп куйды хатын, саташып йокыдан уянган сабый сыман берни аңламыйча.

— Кая барабыз, дип...

— Ә миңа барыбер!

— Синең белән Җир читенә олагырга да риза ич мин, Арслан.

Мондый сүзләрдән соң, әлбәттә, беразга дәшми торырга кирәк. Юл мәшәкатьләре белән мавыккан шофер да арткы рәткә төбәлгән көзгесенә күз төшермәскә тырышты...

Арсланның әледән-әле олылап искә алырга яраткан якын кешесе Лев Беляловичның шәһәр читендәге ял урыны — үзләренә ияреп әйтсәк,— «Мәхәббәт ярымутравы»на ашыга иде машина. Юлның ике ягындагы кара урман сыман, серле — Асия өчен таныш булмаган урын һәм кешеләр белән очрашу көтә үзләрен. Арсланның сөйләвенә караганда, дәрәҗәле һәм аерым бер хөрмәткә лаек затлар гына чакырыла икән анда. Бу хакта аның күп мәртәбәләр сөйләгәне бар.

— Лев Белялович көтәдер... Яхшы килеп чыкмады. Соңга калабыз,— дип, әледән-әле сәгатенә каранды Арслан. Болай да ашыккан шофер кат-кат куалады. Күпме гомер бөтен игътибарын җәлеп итеп килгән, бохар песиедәй йомры, йомшак тәннәре белән янәшәсендә сырпаланып туймаган Асия хакында да онытып торды хәтта. Димәк, сәбәбе бар. Хатын-кыз күрдем дип, бар дөньясын онытучы ир-атны Асия үзе дә алай артык өнәп бетерми иде.

Лев Белялович... Бу исемне йөртүче кеше байтактан кызыксыну уяткан иде Асиядә. Һәм аңарда әлеге ир-атны бер генә мәртәбә булса да күрү теләге артканнан-арта барды. Андый-мондый гына кеше булмаса, шул дәрәҗәдә җан атар идемени соң аның өчен Арслан?!

Асияне Лев Белялович белән таныштыру — бу Арсланның аңарга ышанычы, димәк, зур өметләр баглавы дигән сүз. Әлегәчә бит ул Арсланның үзен генә белә иде. Бүген, ниһаять, дәрәҗәле остазы һәм иң якын танышлары белән очраштырачак. Шәһәрдән ераклашкан саен, дулкынлануы арта барды Асиянең. Бүгеннән башлап Арслан белән үзе арасындагы мөнәсәбәтләрнең бөтенләй башкача һәм җитди төс алачагын хатын-кыз сиземләве белән сиземли иде ул.

Лев Белялович... Кем ул? Нинди көч һәм сыйфатлары белән ул үзенә шундый мәртәбә, хөрмәт казанган?.. Хәтта Арслан булып Арсланны дулкынландырырга, кабаландырырга, тынычлыгын югалтырга мәҗбүр иткәч, ул нинди кеше икән ул?!. Кемнең дә булса җавап бирүен түгел, бу сорауларга үз күзләре белән күреп, ышанып җавап табарга тели иде Асия. Лев Белялович кебек дәрәҗәле һәм олы хөрмәткә лаек кешеләрне күргәне, очратканы юк иде бит әле аның. Күрешкәнчегә кадәр үк сокландырып, үзенә җәлеп итеп һәм беркадәр курку катыш сагаеп үк тора иде аның образы...

Казан — Мәскәү юлыннан куып килгән машина, кинәт тизлеген киметә төшеп, көтмәгәндә кискен борылыш ясап, сул яктагы урманга, вак таш түшәлгән тар тыкрыкка каерды. Тоташ стена сыман калкып торган наратлык рәхәт бер урман җиләслеге, ылыс һәм сагыз исе белән каршы алды аларны... Шул тар гына юл буйлап, эз бутап, агач араларыннан боргаланып йөргән хәйләкәр төлке сыман урап-урап уздылар да күл читендәге ачыклыкка килеп чыктылар. Аккош күленең эзләп-эзләп тә таба алмаслык аулак бер читенә кереп торган ярымутрау иде бу. Күл читендәге биек наратлар артына биек койма белән уратып алынган ике катлы мәһабәт бина елышкан. Янәшәсенә үк килеп юлыкмый торып, табарлык та, абайларлык та түгел үзен. Шактый ук югары тизлектә куып килгән машина тимер капка каршысына килеп туктап калды.

Әйләнә-тирәдә бер мизгелгә шомлы тынлык урнашып алды. Шофер җансыз калды; Арслан, югалыбрак тордымы, шулай ук кузгалырга-кузгалмаска белми уңлы-суллы каранды. Асиянең күңелендә исә, шом түгел, яңа очрашулар һәм бәйрәм көтү киеренкелегеннән туган тынгысыз тынлык иде.

Ул да түгел, капканың аргы ягында — җир астыннан үсеп чыктылармыни — бозау кадәр ике овчарка пәйда булып, берсен икенчесе узды-

рырга теләгәндәй котырынып өрергә кереште. Моңарчы ул этләр кайда булган, нигә машина килеп туктагач ук өрә башламаганнар — һич аңларлык түгел... Этләрнең берсе бәйдә түгел иде булса кирәк — арырак, аякларын киң җәеп куйган да, урыныннан ыргыла-ыргыла ярсуын белә. Икенчесе — бәйдә, тимер капка төбенә үк килеп, муенчагына бәйләнгән чылбырларын чәйнәрдәй булып котырына, башын чайкый. Бәйдән ычкына-нитә калса, һичшиксез, машинаң-ниең белән бергә ботарлап атарга да күп сорамас... Асиягә дә шом керде, тәне буйлап эсселе-суыклы агым йөгереп узды. Үзең дә югалып калдың түгелме, син кая алып килдең мине, дигәндәй Арсланга текәлде ул.

Ә Арсланга исә, киресенчә, этләр пәйда булгач җан керде. Муенын горур тотып, ишекне ачты да тышка чыгып басты. Костюмын сыпыргалап куйды, бик җентекләп галстугын хәстәрләде; хәтта, үзенең дулкынланмавын, тыныч икәнлеген расларга теләп, сызгыргалап та алды әле. Шуннан соң гына, йөзенә елмаю чыгарып, Асиягә кулын сузды:

— Әйдә, Асия, чык. Машинада утыру бик ошап китте ахры үзеңә...

Сак кына урман туфрагына басты Асия. Этләр тагы да котырыныбрак өрергә керешкәндәй булды. Ә кеше-караның заты да күренми.

— Син мине кая алып килдең, Арслан?

— Балалар пансионатына — дип елмаерга итте Арслан. Әмма Асия күреп тора: аның үзенең дә күңелендәниндидер тынгысызлык бар, киеренкелек. Тик белгертергә генә теләми ул аны, яшерә.— Ял итәргә килдек, Асия... Шашлык белән сыйланырга!

Елмайды елмаюын, ә каршы алырга чыгып кул сузучы һаман да күренми. Сәгатенә кат-кат карап алды Арслан. Сабырлыгын җуеп, капкага таба да якынлашырга итеп карады. Этләрнең берсе бәйдә түгел иде ич — килүченең ниятен шундук аңлап, дәү-дәү сикереп, капкага таба ыргылды. Карап карыйк, кем-кемне, дия иде, кисәтә иде сыман ул гүя...

— Җенемә олакканмы соң бу?!.— дигән сүз күңеле төреннән чыкты Арсланның. Ярдәм өмет иткән сыман, һаман сәгатенә каранды.

«Кемне тирги ул?»— шул сорау калыкты Асиядә. Монда Лев Белялович дигәне ялгызы гына була микәнни? Алай димәгән кебек иде ич!.. Кем олаккан, кемне тирги икән Арслан? Капка төбенә чыгып каршы алырга тиешле кеше кем икән соң ул?

Ачык тәрәз аша башын тыгып утырган шофер телгә килеп алды:

— Сигнал биримме әллә?

— Кирәкми! Кайда икәнлегеңне онытасың!..— Арслан кырыс та була белә икән бит!

Бераздан кайдадыр, шыгырдап, ишек ачылганы ишетелде. Этләр, әмер бирелгәндәй, шундук өрүләреннән туктадылар, башларын кире борып, читкә тайпылдылар. Койма читендә ак кирпечтән салынган нәни генә сарайчык бар икән, шыгырдап ачылган ишек моңарчы Асиянең күзенә ташланмый торган шул корылманыкы булып чыкты.

Ничек шыгырдап ачылган булса, шундый ук тимергә-тимер ышкылган аваз чыгарып ябылды сарай ишеге. Киерелә-сузыла чыккан ир-ат капкага якынлашты. Ашыкмый иде ул, кабаланмады да, җай гына атлап килүен белә. Шулай да хәрәкәтләрендә ниндидер сәерлек бар үзенең, тигез җирдә юк-юк та бер абынып-сөртенеп алгандай итте. Койрыкларын кысып тынып калган этләренә күз дә салмады. «Бу нинди сәер дөнья икән — этләре — эткә, кешесе кешегә охшамаган...»— дигән уй үтте боларны сәерсенеп күзәтеп торган Асиянең күңеленнән.

Кеше туктамады, ашыкмады, капкагача үз җае белән килде дә, башын да күтәреп карамыйча, шалтыр-шолтыр китереп, тимер капканың бикләрен ачарга кереште. Һаман да күзен ала алмый күзәтә иде аны Асия. Чалыш-чолыш адымнары белән генә түгел, көтелмәгән һәм кискен хәрәкәтләре белән дә хәйран калдырган иде ул аны. Бигрәк тә түбән иелгән башын чайкап куюы сәер тоелды, чыгымчылаган атка охшатып башкара иде ул әлеге хәрәкәтен. Ул гына да түгел, әледән-әле, умартачы

бабасы яныннан кайтып килгән малай сыман телен чыгарып, аскы һәм өске иреннәрен ялаштырып ала... «Әллә, ходаем, Лев Беляловим дигәне шушымы?..»— дип уйлап куйды Асия. Шомланып, Арсланга табарак елышты, сораулы күзләрен аңарга төбәде:

— Бу кем?.. Ул нигә шундый?

— Җантимер! — диде Арслан, җавапны коры тотты. Аның бу җавабында Асия «Җыен юк-бар белән кызыксынма, җаный, сиңа боларны белүнең һич кирәге юк», дигән киная тойды.

Әмма, кызыксына башлаган икән инде, хатын-кызны ярым-йорты җавапларың белән генә канәгатьләндерермен дип уйлама. Урынлымы-урынсызмы бу кызыксыну — ул барыбер канығуыннан тукталмаячак. Асия дә әлеге җаваптан канәгать түгел иде, билгеле. Мондагы серлелек һәм сәерлеккә җавап тапмады ич әле ул.

— Җантимер?! — дип кабатлады ул Арсланның артыннан ук.— Нәрсә, аның исеме шундыймы?..

— Исеме дә, җисеме дә шундый!

— Моны ничек аңларга инде?

— Туры мәгънәсендә!

Ниһаять, елак көчек сыман чыелдап, тимер капка ачылды. Җантимер дигәннәре, капка бигеннән аерылырга теләмәгән сыман, арт ягы белән чигенә-чигенә, тышкы якка чыкты. Капка бигеннән аерылды, янәшәсендә үк басып торган ир-ат белән хатынга әле һаман күтәрелеп карарга ашыкмады. Аларны читләп үтеп, шофер янына узды. Иелә төшеп, тәрәзәдән башын чыгарып әмер көтеп утырган шоферга аның ни әйткәнен Асия, әлбәттә, ишетмәде.

— Уникедә! — диде ул аңарга. Нибарысы бер сүз әйтте һәм шундук читкә тайпылды.

Машина, хуҗасын урман уртасында калдырып, шундук үкереп-сызгыртып китеп тә барды. Тәгәрмәчләр астыннан атылып чыккан коры нарат күркәләре генә як-якка сибелеп калды.

Сәер кеше читләп-читләп кенә Арслан янәшәсенә килеп басты. Әллә Арслан шулай кушты, әллә үз-үзеннән шулай килеп чыкты — Асия башка якка тайпылырга мәҗбүр булды... Ниһаять, әлеге кеше, башын күтәреп, Арсланга күзләрен текәде, иреннәрен сабыр гына ялаштырып алды. Иләмсез авызын ерып көлгәндәй итте. Кырыс һәм шомлы идеме аның бу елмаюы, кунакчыл һәм юмартмы — читкә тайпылырга мәҗбүр булган Асия түгел, текәлеп үк торган Арслан үзе дә аңламагандыр. Ә теге кеше каршысында торган Арсланга бер генә сүз пышылдады:

— Пароль?

Ничек моңарчы онытып торганмын соң дип, үз-үзен битәрләгән сыман кабаланып, кесәсенә тыгылды Арслан. Куен кесәсенә... Портсигардан бераз кечкенәрәк булган картон тартма тартып чыгарды да Җантимергә сузды.

Шунда гына, ниһаять, сәер кешенең дә йөзенә, хәрәкәтләренә җан керде. Юкса, әлегәчә, җанлы кешедән бигрәк, тимер роботны хәтерләтә иде сыман ул. Куанычын уртаклашкан кебек, Асиягә дә күз салып алды. Телен чыгарып, җәлт кенә ирен читләрен ялаштырды. Шул рәвешле, үзенә әлеге тартманы алып килгән Арсланга гына түгел, аның юлдашы булган хатын-кызга да рәхмәтле булуын белгертте. Моңарчы күзгә чалынмаган, ни гомер йокымсырауда булган кеше уянган иде аңарда гүя.

Шулай да кунакларны үзе артыннан әйдәргә ашыкмады әле ул, кабалана башлап, кулындагы тартма белән мәш килергә кереште. Нияте — тартманың эчендә ни икәнлекне тикшерү — барлау. Бер-берсенә бәрелүдән тартма эчендә ниндидер пыялалар челтерәшеп алды. Ниһаять, картон тартманы нинди саклык белән иплэп ачкан булса, тагы олырак игътибар, кадер-хөрмәт белән иплэп кенә ябып куйды Җантимер. Һәм, җиргә егылган кош баласын кире оясына күтәреп куйгандагы саклык белән, куенына шудырды.

Башка чарасы юк — сәер кешенең һәр хәрәкәтен исе-акылы китеп, хәйран калып күзәтеп торды Асия. Күп булса, утыз-утыз биштән узмаган ир-ат булырга тиеш иде ул. Әмма нык таушалган, сөрсегән. Уртачадан калкурак буй, какча гәүдә; кыркыр вакыт узып, инде шактый ук кадерсезләнергә өлгергән колхоз сарыгының йоны сыман бөдрәләнеп торган чәч. Байтак гомерләр тарак күрмәгәнгә булса кирәк, чәч көдрәләрендә — пәрәвез җепселләре, нарат ылыслары. Кием-салымын яманларлык түгел. Әмма соңгы елларда үтүк күрмәгәнлеге күзгә бәрелеп тора. Бер уйласаң, ул гадәти дә кебек. Колхоз базары, вокзал һәм шешә тапшыра торган урыннарда еш очратырга була мондый кием кигәннәрне. Шулай да, башкалардан ул нык кына аерылып та тора. Әлеге кешедәге сәерлекнең серләре хакында, аның кыяфәте һәм үзен тотышындагы хикмәтләрне әле күп тапкырлар кайтып-кайтып хәтерләр, нәтиҗә ясарга омтылып карар Асия. Шулай да ул аны төгәл генә аңлый алмас. Акылга тулмаган дияр идең, моңа ул аз гына да ишарә ясамады. Исерек түгел. Мәгънәсез бер тинтәккә дә охшамаган. Әмма кеше дип тә әйтеп булмый үзен, гүя робот... Төшләренә керде ул аның, күз алдыннан китми йөдәтте. Күзләре... Әйе, бар хикмәт күзләрендә иде булса кирәк аның... Күзләре тоныκ шешә пыяласы төсендә түгелме соң аның?! Аяк астында яткан пыяла ватыгы сыман ук җансыз һәм хәрәкәтсез. Ул, гомумән, үз күзләренә үзе хуҗа түгел иде сыман. Үе бер җирдә булса, карашы — икенчедә... Үзе алар белән янәшә басып тора, ә җаны башка дөньяда, күзләре башка тирәлекне барлый.

Капканы бик көттереп, шактый ук зарыктырып кына ачты Җантимер. Юл буе ашыгып килгән, әле дә булса берәзлексез сәгатенә карангалавын дәвам иткән Арслан, ни генә булмасын, ашыктырырга кыймады аны, җаена гына торды. Иң элек үзе атлап керде Җантимер, аннан, ым кагып кына, килүчеләргә әмер бирде. Ә этләр бая ук туктап калган хәлләрендә тик күзәтеп торалар, өрмиләр дә, кымшанмыйлар да. Күзләре генә, елык-елык килеп, һәр адымга, һәр хәрәкәткә бәя биреп тора. Җәягә тартылган ук сыман алар. Шунда Җантимердән бер-бер әмер, боерык була-нитә калса, кемнең-кем икәнлеге белән хисаплашып тормыйча, өскә сикерәчәкләр һәм өзгәләп атачаклар.

Арслан Җантимердән калышмады, ә Асия Арсланнан бер адым калмыйча, аңа тагылып ук барды. Шундый иркен, матур табигать кочагында аның хәрәкәтләре өчен мәйдан шул дәрәҗәдә чикләнгән иде ки, башка сыйдырырлык, күз алдына китерерлек түгел. Артта калса — этләр, алга омтылса — анда Җантимер...

Ә дөнья матур. Дөнья шундый матур... Исең китәрлек! Көн кичкә авышканда җилсез чакта нарат урманы бер әкияткә әверелә ич ул. Өстәвенә — янәшәдә генә күл. Аккош күле. Күкрәкләрне кытыклап, җанны әсәрләндереп торган ылыс һавасы.

Атлап барган сукмакларын ике яктан чәчәк түтәлләре озатып бара. Шул туры аллея аларны болдыр баскычлары агачтан бизәлеп эшләнгән мәһабәт таш бинага алып килде. Төзелеш эшләре тәмамланып бетмәгән идеме,— бер читтә пөхтә генә өелгән кирпеч һәм төзүчеләр җайланмасы — баскычлар сыенып тора. Бинаның ишекләре имәннән булып чыкты. Ул имән ишекләрнең дә ачкычлары сәер кеше Җантимер кесәсендә иде. Ачкыч дигәннән, кай кесәсенә генә кагылмасын, анда челтерәшеп ачкычлар аваз сала, бу кешенең бөтен кесәләре һәм эче-тышы тоташ ачкыч һәм йозаклардан гыйбарәт кебек иде. Бу юлы да ашыгуның ни икәнлеген белмәде Җантимер. Иплe генә итеп, кирәкле ачкычны барлый, муенын боргалый, як-ягына карана, ә күзләре — хәрәкәтсез.

Имән ишекнең йозаклары бер-бер артлы ачыла башлагач, иркен итеп сулыш алды Асия. Ниһаять, этләрдән һәм әлеге сәер холыклы кешедән арынып, ул җаны теләгән кеше — Арсланы белән генә калачак. Лев Беляловнч дигәннәре килми калган иде, күрәсең... Әлеге өмет белән ул инде әйләнә-тирәгә дә иркен, аек караш ташлый ала хәзер. Бу бина чын-

лап та зәвык белән төзелгән күренә. Ишегалды да шундый ук тәэсир калдыра икән. Нәкъ балалар бакчасындагы кебек, монда да — таганнар, гөмбәчекләр. Ком өемнәре өстендә, очраклы рәвештә генә балаларның кулыннан төшеп калган сыман, уенчык көрәкләр, чиләк, машина һәм тракторлар аунап ята. Баш очында йөзьяшәр наратлар чайкала, урман гүя шул рәвешле күкрәк киереп сулыш ала. Күл читенә таба да һәр ике яктан ямь-яшел чирәм түшәлгән уен мәйданчыклары сузылган. Тагы аеруча күзгә ташланганы — чәчәк түтәлләре. Монда алар шулкадәр күп, балалар бакчасы түгел, ә җәннәт бакчасы диярсең... Арслан белән бергә чакларда гомер булмаган хәл: үзенең улын искә алып куйды Асия. Балаң менә шундый бакчага йөрсә, әлегедәй җәйге пансионатларга барып ял итсә икән ул... Чын-чынлап сокланып, көнләшеп күзәтте Асия әйләнә-тирәсен, үзенең сабые шул матурлык кочагында уйнап, йөгереп йөри иде диярсең. Дөньядагы бар матурлыктан, муллыктан үз балаңа да өлеш чыгару, шул матурлыкны аңарга күрсәтү, аныкы итү кебек кайгыртучанлык хисе чит түгел икән ич аңарга да. Бала түгел, үзең йөгереп китәрсең әлеге чәчәк түтәлләре белән уратып алынган ямь-яшел сукмаклар буйлап. Чын әкияти манзара...

Әмма бер мәлдән аның яшел сукмаклар буйлап йөгереп уйныйшаяра башлаган карашы кара тимер капка янында телләрен асылындырып, сагаеп калган бозау кадәр ике овчаркага барып төртелде. Һәм шундук сискәнеп куйды. Тагы бер мизгелдән, очраклы рәвештә, Җантимернең тонык пыяла төсендәге җансыз күзләренә текәлеп тетрәнеп алды. Ай-һай, бигрәкләр дә сәер яратылган бу дөнья...



## 9

Әнисенең төп максаты кызын югары уку йортына кертү иде. Эти кеше дә каршы түгел. Әйтегез, кем үзенең баласын бәхетле итеп күрергә теләми? Ә монда ата һәм ана бердәнбер кызларын кайгырта. Ул елларда югары белемнең дәрәҗәсе шактый ук зур иде. Белеме, югарылыгы бармы-юкмы — югары белемле генә булсын! Шуңа да югары уку йортына укырга керү чын-чынлап бәхеткә таба беренче адым санала торган иде. Улын яисә кызын кайсы да булса бер институтка кертү максаты белән авылдан соңгы сыерын сатып килгән ата-аналар хакында да ишетергә туры килгәне бар. Институт дигән исеме генә булсын, теләсә кайсы уку йортына риза була иде күбебез... Керү имтиханнары вакытында өчлегә тарыгач, конкурстан узмасын белеп алган кайберәүләр: «Поезд астына ташланам», — дип, тимер юл вокзалына таба да йөгерделәр. Нишлисең, һәркемнең бәхетле буласы килә иде шул. Аерым кешеләрнең генә түгел, һәр заманның үзенә күрә бәхетне аңлау үлчәүләре була икән. Бәхеткә һәм кайчакта бәхетсезлеккә дә каршы, ул үлчәүләр биш-ун ел саен алышына торалар...

Үз бәхетен табарга, бәхетле булырга Асия дә каршы түгел иде. Кемнең бәхетле буласы килмәсен! Асия дә бу хакта күп уйланды, күп ватты башын. Укырга риза, ләкин кая барырга? Кем булырга?.. Нинди уку йортын сайларга?.. Күпме генә уйланмасын, кабаланып эзләмәсен, җавабы ачыкланмаган, әзер түгел иде әле Асиянең.

Вакыт көтми. Вакыт, гомумән, көтүнең ни икәнлеген дә белми икән бит ул. Июнь ахырларында ул өлгергәнлек аттестаты алды. Ә июльдә инде, кәгазь-документларны әзерләп, кабул итү комиссиясенә илтеп тапшырырга да кирәк иде. Август башыннан — керү имтиханнары. Ун ел мәктәптә уку дәвамында кузгатылмаган, ачыкланмаган мәсьәләләрне, шул рәвешле, атна-ун көн эчендә хәл итеп куярга кирәк.

— Медицина институты,— диде әнисе.

— Укытучы булса да ярар,— диде әтисе.

— Медицинский! — дип кабатлады әнисе.

Әтисе дәшмәде, кесәсеннән папиросын эзләргә кереште.

— Медицинский,— дип кабатлады ана, аның дәшмәвен үз файдасына юрап.

— Юк,— диде, моңарчы тын торган кыз.— Мин бармактан кан алганда да нишләргә белмим, куркам... Бармыйм медицинскийга!

— Курыксаң — күзеңне йомарсың!

— Йоммыйм да, бармыйм да...

— Соң, алай икән, башка бер-бер институтны сайлап карарга кирәк,— дип сүзгә кушылырга, ике якны килештерергә талпынып карады әти кеше.

— Мин үстердем баланы һәм мин хәл итәм. Ике сөйләшмибез — медицина институтына барасың, кызым...

— Юк, әни, мин уколдан да куркам,— дип, еларга җитешеп ялварды кыз, аңлатырга тырышты.

— Укол ясамассың! Аның өчен, әнә, медсестралар бар. Врач булып, ак халатлар киеп, кулыңны кесәгә тыгып кына, чистада, җылыда йөрерсең, кызым. Аннары, кызым, безне дә уйла инде син. Олыгайган көнемдә бар авыруларымны син карап, хәстәрләп торырсың. Мәктәптә ми черетә-черетә гомерем буе хыялландым, кызым, Асия...— дип, исемен дәшеп, чәчләреннән үк сыйпап үгетләде ана.

Кыз анага охшый диләр:

— Юк, әни, юк дигәч — юк! Хет үтер, врач буласым юк!

— Соң, ярар, анасы, бетмәгән ич, башка һөнәрләр дә бар,— дип, әти кеше дә янә сүзгә кушылырга итенеп карады. Кызын врачлыкка укытуга ул үзе дә каршы түгел иде түгелен. Әмма нишлисең, күрәсең: ничек терәгән аягын. Ул бит яхшы белә: хатыны да, кызы да үз белдекләре белән, үз сүзләрен сүз итеп яшәргә өйрәнгән. Ә монда, берсен алып, берсен куярлык түгел, ана белән кыз бәхәсләшә. Ул булмый, кем килештерергә тиеш араларын?.. Юк шул! Балага тәрбияне — биш яшькәчә, хатынга — өйләнгәч тә беренче биш көндә генә бирергә мөмкин дип, юкка әйтми торганнардыр...

Әйе, бала тәрбияләү өчен шактый зур ара — биш ел гомер бирелә икән ата-ана өчен. Ә без шул биш елны, чын-чынлап тәрбия эше белән шөгыльләнәсе урынга, аның капризларын тыңлап, йомшак җирләреннән сөеп, авызына кәнфит каптырып, ни сораса — шуны табып үткәрәбез. Бала гына бит әле... Нинди тәрбия? Үсә төшсен, аннары да соң булмас кулга алырга дип, үз-үзебезне алдап, тынычландырып яшәвебезне дәвам иттерәбез. Юк шул, без баланы түгел, бала безне тәрбияли, үзгәртергә, үзенә ничек кирәк булса — шулай үзгәртеп корырга керешә икән...

Хатын мәсьәләсендә, турысын әйтергә кирәк, мин зур белгеч түгел. Шулай да биш көн дигәннәре хак булса кирәк. Бер уйласаң, биш көн ул нәрсә?.. Шул биш көн кайберәүләрне гомер буе йөгертә, кол ук дип әйтмим, гомерлеккә характерсыз, ихтыярсыз итә. Чөнки әлеге дә баягы теге биш көн эчендә мөнәсәбәтләр ачыкланган була, «власть» бүленеп бетә. Биш көнгә үк сузыла микән әле, Кышкы сарайны алган кебек, штурм белән алалар ул властьны... Миңа ышанмасагыз, үзегез хәтерләп карагыз: нәрсә ул өйләнгәч тә беренче биш көн, ай булса, ярты ел булса — бер хәл. Ир-ат үлеп гашыйк булган, гыйшкыннан үзалдына исереп, сөйгәнен кулда гына күтәреп йөргән шул шикәрле-баллы биш көндә бөтен язмышың хәл ителсен инде?! Дөреслек кайда?!

Иренең килештерергә теләп әйтелгән сүзләренә хатын җавабы кыска булды:

— Елганны бел!.. Без бит сине йөзәргә өйрәтмибез...

— Соң, шулай инде, шулай,— дия алды, әгәр шулай әйтергә яраса, «гаилә башлыгы». Һәм, папиросын бармак очларында тәгәрәтеп уа-уа, баскыч төбендәге мәйданчыкка чыгып китте.

— Бердәнбер кызымны кайда укытырга кирәклекне мин үзем дә

белермен! — кебек сүзләр озатып калды аны.— Юкка баш катырма, эти-се, ат дагалаганда — бака ботын кыстырмый торган иде...
— Ә мин барыбер врач булмыйм!
— Булырсың!
— Теләсәң кая барырга әзер, врач чыкмый миннән, әни. Хәтта «пед»ка барырга да риза...
Ачуыннан, сүзен сүз итә алмавыннан, тешен кысып елмаеп алды ана, укытучы булырга да ризалашырга торган кызыннан көлде. Укытучы итә-ме соң?!. Бердәнбер кызын үзе кебек укытучы итәргәме?!. Юк!.. Врач бу-ла! Тормыш өйрәтә ул... Уколдан курка, имеш... Курыкмагаең!..
Шулай дип фикер йөртте ана. Хәер, аны да аңларга кирәк. Олыгай-ган көннәрендә үз кызының, газиз баласының, дәрәҗәле врач булып, яннарында: «Әни, хәлең ничек?.. Бер-бер җирең авыртмыймы, әнием?» — дип бөтерелеп йөрүен кем теләмәс икән... Бары изге омтылыш, изге нияттән чыгып кына фикер йөртә ләбаса ул. Күңеленнән, хыялында күп-тән фәрештә итеп күрә иде бит инде ул үзенең кызын. Шуңа да, үтенеп сорыйм, гаепләргә җыенмагыз ананы?!.
Күз яшьләре кипте. Сүзләр онытылды... Документларны медицина институтына илтеп тапшырдылар. Әнисе белән бергә таптадылар инсти-тут юлын. Имтиханнар киртәсен дә уңышлы гына узды. Ана кешенең күзенә йокы кермәде ул көннәрдә, көнен — көн, төнен төн дип белмәде, институт ишеге төбеннән китмәде. Имтиханнар нәтиҗәсендә өлеше бул-гандырмы-юкмы — анысын үзе генә белә.
Студент булды Асия. Сүзен сүз итүдән күңеле булган әнисе аны сабый чакларындагыдан да болайрак кайгыртып яшәргә кереште. Соң-гы арада, әнисе сүзен тыңлап, медицина институтына кергәч, кызның дәрәҗәсе һәм мөстәкыйльлеге дә бер башка артып китте.
— Әйдә, әнием, болай килешәбез,— диде ул көннәрнең берендә.— Мин сиңа эти түгел. Һәм аның хәлендә калырга җыенмыйм. Моңа кадәр гел синеңчә барды дөнья... Инде тыңла, әнием, үз дигәнемчә дә яшәп карыйсым килә. Мәктәптә укыганда, берөзлексез: «Укы, укы»,— дия килдең, үз кызыңа башкаларның бармак төртеп күрсәтүләреннән курыктың. Мин сине аңладым, хәлеңә кердем. Чынлап та, минем әни завуч бит әле, аңарга эшендә кыенлык китермим ди-ди тырыштым. Булдымы?.. Булды, әни!.. Сигезенче класста укыганда бер егетне ошат-тым. Әйбәт егет иде, әле дә оныта алмыйм мин аны. Ул да минем өчен үләргә әзер иде. Безнең җитәкләшкәнебез дә булмады аның белән. Очрашканда, бер-беребезнең күзенә күтәрелеп карарга уңайсызлана, ояла идек. Хәзер генә аңладым: без яратышкан булганбыз аның бе-лән. Сиңа бу ошамады. Сабый балага санап, мине почмакка бастыр-дың, ә үзең чәч йолкырга җитештең... Хәтерендәме, әнием? Хәтерендә!.. Ул чакта да хәлеңә кердем — чөнки мин завуч кызы идем, завуч кы-зына яратырга да ярамый... Төннәр буе еласам еладым, аны уйлап, акылдан язар хәлгә җиткәнем булды, әнием, әмма ул егеткә сәлам бирмәдем башка. Ул да, миңа ачу итеп, Юлия белән танцага йөри башлады... Инде менә институтта укыйм. Ме-ди-цин-ский-да!..— бу сүз-нең һәр иҗегенә басым ясады ул.— Тагы син дигәнчә булды. «Соңгы тапкыр гына булса да, тыңла, кызым»,— дидең. Тыңладым... Инде менә шулай, әнием... Мин моңарчы син дигәнчә яшәдем, үземнең принцип-ларыма хыянәт итеп килдем. Инде бүген шуны җиткерергә кирәк са-ныйм: миңа унсигез тула. Паспорт — кесәдә. Яшьтәш кызларым кияүгә чыга, әнә... Ә мин — һаман син дигәнчә. Болай дәвам итә алмый, әнием, җитте. Үз дигәнчә яши башлыйм!.. Өйрәтүләреңне туктат!.. Һәм кысыл-ма! Килештекме, әнием?!.
Телсез-өнсез калып тыңлады ана. Дөньясын онытып, үз колакла-рына үзе ышанмыйча тыңлады. Бүлдерү кая, сөйләп бетергәчтен дә әле байтак кына авызын ачарга кыймый торды. Тоташ бер саташу кебек иде ич болар. Әйтерсең берсе дә аның кызы авызыннан чыкк[а]н

сүзләр түгел. Әйтерсең лә аның бердәнбер кызын җен алыштырып куйган да, шул — ананың түземлеген сынап карарга булган.

— Кызым...— диде дә, ничек дәвам итәргә белмичә, тотлыгып торды ул бертын.— Мин сине аңлый алмыйм, кызым.

— Нәрсәсен аңламыйсың?.. Яхшы аңлыйсың, әнием!.. Аңлаешлы итеп сөйләдем ич,— дип, сүзендә аяк терәп торырга әзер икәнлеген белгертте кыз. Утырган җиреннән торып ук басты.— Мин бала-чага түгел, дидем. Үзем өчен үзем җавап бирәчәкмен. Шулай итәрбез, ярыймы, әнием!

Һәр сүзенә басым ясап, иреннәрен кысып, теш арасыннан аваз чыгарып сөйләде Асия. Карышыр урын калдырмаска тырышты.

Кайсы ананың бердәнбер кызы авызыннан шундый сүзләр ишетәсе килсен?! Әнием, дип, ни эшлим икән дип, киңәшеп, синең өчен җан атарга әзер булып, өзгәләнеп торган балага җитәме соң?.. Бер уйласаң, шулай. Ләкин, үзе белән килешмәстәй шартлары да юк түгелме соң әле аның? Анысы дөрес, кызыбрак китте. Ул бит үзенә мөстәкыйльлек кенә дәгъва итә түгелме?.. Моңа кадәр борчу китергән бала түгел, инде үсеп кеше булды дигәндә генә ялгышмас, боерган булса... Анага бит шундый уй һәм гөманлаулар белән үз-үзен тынычландырырга да форсат калган иде. Бәхәсләшеп тормады, әйтер сүзләрен кичектереп торырга мәҗбүр булды. Колак төбендә кызының һәр сүзе, ул сүзләрнең әйтелү интонациясе яңгырап торса да, тыела белде. Бу юлы да сүздә генә калыр дип өмет итте.

Чынлыкта исә хәлләр ул уйлаганча җиңел генә, гади генә булмаган икән. Асия буй җиткән кыз иде инде. Кемгә охшап шулай алгандыр табигатьтән — урамда кара-каршы очрашкан егет-җиләнне сискәндерерлек төс-кыяфәт иде үзендә. Узып киткәчтен гәүдә-сыны комсыз карашларны иңге-миңге китерә торган. Ә инде тагы да яманрагы — Асия үзенең чибәрлеген белә!.. Табигать биргән матурлыгы булып та, шуны үзе тоемлап өлгермәгән кыз белән, үз матурлыгыннан тәм табып, хозурлану ләззәтен татырга өлгергән хатын-кыз арасында шактый аермалык бар. Җир белән күк арасындагыдай зур аерма бу. Гашыйк булып өйләнеп үк куючылар өчен, беренчеләре — күктән төшкән бәхет, икенчеләре — кыямәт, беренчеләре — яшәү, иминлек булса, икенчеләре — йокысыз төн, авыруга сабышачак йөрәк һәм иртәме-соңмы аерылышу вәгъдә итә.

Кайберәүләр, гомер итеп тә, үзенең нинди икәнлеген аңлап, тоеп житкермәскә мөмкин. Ә Асия әнә, унсигезе тулар-тулмас чактан ук кем булуын аңларга өлгергән. Белеп алган икән, бу хакта инде бер генә көн, бер генә сәгатькә дә онытып, исеннән чыгарып тормаячак ул хәзер. Әби булгачтын да көзгедән аерылмас. «Мин матур» дигән ышаныч — күңелгә кереп оялаган чир, корт сыман ул. Үзенә дә аз кыенлык, борчулар китермәс бу чир, әмма ул теләсә-теләмәсә дә моңардан һичкайчан арына алмас.

Төптәнрәк уйлый калсаң, бит боларның һәммәсе өчен иң элек ир-ат халкы үзе гаепле. Матур икәнлегенә ышанган хатын-кызга комплимент һәм матур сүзләр явып кына тора. Әйтми торсаң, авызыңнан тартып ала ул аны, чөнки хатын-кыз шул матур сүзләр белән туенып, рухланып яшәргә күнеккән. Килешмәүче булса, үзе сынап карасын: чибәрлегенә ышанган, чибәрлеген игълан итеп йөргән хатын-кыз ул ят карашларны үзе чакыра, үзе аулап, сизеп йөри, әйдәп уза. Үзе әйди, үзе, борылып, авыз суын корытып карап калучылардан көлә дә әле. Үтеп китүче тоймый, сизми дип уйлаучы булса — ялгышма! Итәк чабуына тагылып барган карашны тоймый калалармы соң!..

Август урталарында Асия институтка кабул ителүчеләр исемлегендә иде инде. Шундый чакта кем инде бердәнбер баласын ялга җибәрми кала? Асиянең күптәнге хыялы тормышка ашты — әтисе эшләгән йөк баржасында Идел буйлап сәяхәткә чыкты ул.

Экипажда ничә ир-ат булса, һәркайсының күзе үзендә булуны тойды кыз иң элек. Дөресен әйтергә кирәк: әлеге игътибар аның үзенә дә ошый иде. Ир-ат халкы белән якынлашканда, бигрәк тә узып киткәчтен, гәүдәләрен боргалап, күзләрен уйнаткалап үтәргә тырышты. Кызык ич... Теге беркатлыларга шул җитә кала, аны-моны уйламастан, сукыр черки сыман ябышырга гына торалар. Аеруча җәйге практикада булган яшь матросларның күзен яндырудан тәм тапты ул. Ни әйтсә дә күтәрәләр, куганны да белмиләр, эштән бушадылармы — аны эзәрлекләргә керешәләр. Телгә остараклары кызык сөйли, сөйләү сәләтеннән мәхрүмнәре исә, йә көче, йә акылы, белгән-ишеткәннәре белән шаккатырмак була. Шәһәргә ялга кайткач үзләренең магнитофон язмаларын тыңларга чакырды алар, төсле музыкалары белән хәйран калдырырга вәгъдә бирделәр.

Матрослар — яшь егетләр. Аларның шулай булуы бер дә гаҗәп түгел, билгеле. Ә беркөнне аны үзе белән машина залына механик алып керде. Кызык ич, барын да күрәсе, беләсе килә иде Асиянең. Башта зур-зур тәгәрмәчләре әйләнеп торган, пешкәкләре хәрәкәтләнгән двигательләрне күрсәтеп йөрде беренче карашка тыйнак кына күренгән шул абзый; аннан, уйламаган җирдән, аның биленнән кысып кочаклап алмасынмы!.. Ул гынамы әле, кызны егарга итенеп, тилергән кешедәй үбәргә үрелде. Кырыкка җиткән, ә акылы юк — авызы ни сөйләгәнне колагы ишетмәс булды:

— Күзне яндырып йөрисең,— ди.— Нигә син шулай матур соң?— ди.— Без яшь чакларда нигә синең төсле чибәрләр булмады икән ул... Минеке бул. Ни теләсәң, шуны табып бирермен,— ди.

Асиягә кызык. Күңеле булганчы, рәхәтләнеп көлде генә башта.

Ә абзыйның күзе тонган, куллары тик тормый башлады. Телгә дә оста икән, сибепме-сибә акылсыз-матур сүзләрен.

— Көлмә,— ди.— Кеше ишетер... Әтиеңә җиткерерләр... Син шундый сылу булганга мин гаепле түгел бит инде,— ди.— Кичен минем каютага керерсеңме? Керсәң, үзеңә төсле рәсемле чит ил журналлары күрсәтермен,— ди.

Шаккатырмакчы була. Тапкан ис китәрлек нәрсә, чит ил журналлары, имеш... Андый гына журналларны җиденче класс малайларында да күргәне бар ич Асиянең. Күзеннән яшьләр тәгәрәп чыкканчы көлде ул. Үз каюталарына кайтып, механикның кулларыннан май таплары төшеп калган аксыл-зәңгәр күлмәген салганда, бая ишеткәннәрен хәтерләп, янә туктый алмый көлде. Тәки каныккан иде бит, «Әти килгән, әнә, ишекне кага...»— димәгән булса, тиз генә котыла да алмас иде әле Асия. Сагыз кебек бит... Күр инде, муеннарын кызартып бетергән бит, аю! Ә теле бер дә харап үзенең: «Җаным!» дип тә җибәрә, «Жигули»е[4] барлыгын, дачасы, кассада хатыныннан яшереп җыйган ничә мең акчасы барлыгын да сөйләп чыкты. Сораучы булса икән. Акыллы диген инде шуны... Үзенең хатыны һәм ике баласы бар диләр бит әле... Алар турында сөйләми, тәмам егет булган...

Ярар, анысы калып торсын — беткәнмени җыен карт-коры... Тагы да кызыграк бер вакыйга искә төшеп тора әле: мыеклы бер матрос белән ярты төн уртасынача йолдыз санап чыкканнан соң, иртән булды. Әтисе кичтән вахтада иде, иртән каютада йоклап калды. Иртәнге кояш нурларында иркәләнәсе килеп, палубага чыкты ул. Иң ерактагы аулак почмакка барды да, одеал җәеп, кызынырга ятты. Китап та алган иде кулына, кызыгын тапмады. Артык акыллы язылган. Акыл сатучыларның китапларын да, үзләрен дә өнәми ул. Йокымсырап кителгән... Берзаман, башын калкытса, ни күрсен: капитан рубкасыннан үзенә бинокль төбәлгән. Хәйран калды Асия: капитан акыллы кеше, чәчләренә күптән чал кергән, әтисеннән өлкәнрәк хәтта — аны күзәтә. Йөзе белән шул тарафка борылып, озак кына күзәтеп ятты Асия — капитан биноклен аңардан алмады. Кыз үзенә кул болгап сәлам биргәч

кенә бинокльлен читкә алды, яр буйларын күзәтергә керешкән булды.

Әнә шундый тамашаларга юлыкты Асия Идел буйлап бер атнага сузылган сәяхәт вакытында. Хәер, барысын да искә, хәтергә дә алып бетерерлек түгел, алган тәэсирләренең иге-чиге юк иде... Ә ир-ат халкының барысы да бер иш дигән сүз хак икән, моңарга ул үзе инанды. Әле бит этисе шунда, араларында йөргән чакта булган хәлләр болар, качып-посып кына... Әгәр дә этисе янәшәдә булмаса?! Ул очракта ни эшләгән булырлар иде икән, кара инде син аларны!..

Ничек кенә булмасын, үзенә төбәлгән чит карашларны күргән, тойган саен, йөзенә нур иңә, йөрәге җилкенеп куя, күңеленә ташкын булып дәрт тула иде Асиянең. Урлап булса булсын, сокланып карыйлар ич, барыбер. Башка берәүгә түгел, аңарга карап сокланалар...

## 10

Җантимер аларны ишек катында озатып калды, эчке якка хәтта күз дә салмады ул. Алар үтү белән, ишекләрне ябып, тышкы яктан бикли калды. Чыршы-нарат такта белән сырлап төрелгән, сагыз исе аңкып торган киң, иркен зал аша түргә уздылар. Бинаның эчке ягы да зәвык белән һәм бар урыны җиренә җиткереп эшләнгән күренә. Баш очында кыйммәтле люстралар. Аяк астында тоташ затлы келәм. Стеналарны рәссамнар ясаган табигать күренешләре, этюдлар, натюрмортлар бизи. Әмма шунысы гаҗәп: монда абсолют тынлык иде, шылт иткән аваз юк. Ә бит, Арсланның әйтүенә караганда, монда Лев Беляловна кына түгел, тагы башка кунаклар да булырга тиешле. Тик бу хакта Арсланның үзеннән сорарга кыймады Асия. Аңардан калышырга теләмичә, салмак кына атлавын белде.

Ниһаять, озынгарак сузылган коридор буйлап бинаның иң аргы башына килеп җиттеләр. Уңга борылдылар... Йомшак күн белән тышланган зур ишеккә барып төртелделәр. Ишек шул дәрәҗә калын һәм биек иде ки — әйтерсең ул шпаллардан ясалган — бикле булмаса да, аны көч куеп, авырлык белән генә ачты Арслан. Шунысы гаҗәп: алар янә урман эченә, якты һәм ачык һавага килеп чыктылар.

Атлар-атламас булып туктап калды Асия. Бермәл як-ягына гаҗәпләнеп һәм сокланып карап торды. Кая килеп чыктылар соң әле алар? Бина эче дисәң, бина түгел — күктә ачык-зәңгәр киңлек һәм шул киңлеккә омтылып үскән наратлар чайкала. Урман аланы дип тә әйтерлек түгел, чөнки ул як-яктан таш койма сыман биек диварлар белән уратып алынган. Каршы якта, шактый ара узгач, куе булып үскән куаклык башлана. Куаклыкның аргы ягында ниндидер зәңгәрлек шәйләнә, димәк, бу күл өсте булырга тиештер... Үзенә күрә бер кышкы бакча булып чыга түгелме соң! Әмма монда бары да табигый. Күккә ашкан чыршынарат агачлары, талчыбык һәм сирень куаклары артыннан аксыл-зәңгәр томан сыман шәйләнеп торган күл, ачык һәм аяз зәңгәр күк... Кеше хыялы, төзүчеләрнең фантазиясе ниләр генә уйлап тапмый да нинди генә хикмәтләр корып куймый. Үз күзләре белән күрергә туры килмәгән булса, кемнеңдер сөйләгәннәре буенча гына, бу хикмәтле урынны күз алдына китерергә фантазиясе дә җитмәгән булыр иде Асиянең.

Диварлар артында яшерелгән әлеге урман аланының уртасында учак янып тора. Шул учак тирәсендә берничә кеше кайнаша. Килүчеләрне иң элек илле-илле бишләр тирәсендәге ир-ат күреп алды. Уртачадан кыскарак буйлы иде ул, өстәвенә чамадан тыш таза. Бит алмалары — гүя кабартылган шар, корсак дигәне дә шактый ук мул күренә. Яннарына якыная торгач, тарап куйган чәчләре астында посып яткан пеләше дә ялтырап алды. Ә йөзгә — ачык чырайлы, күзләре йөгерек, утлы күмер сыман әллә каян балкып көлеп тора. Хәрәкәтләре дә, яшенә, килеш-килбәтенә карап түгел, шактый кискен, җиңел тоелды.

— Арысланнар!— дип дәште ул, тирә-ягында әвәрә килеп йөргән ир-атларның игътибарын җәлеп итәргә теләп. Кулындагы кисәү агачына таяна төшеп, гәүдәсен дә онытмады.— Карагыз әле, күрегез, кияү белән кәләш килә.

Учак тирәсендәгеләр, мәшәкатьләрен куеп торып, килүчеләргә таба борылдылар. Кайсы — ым, кайсы нинди дә булса бер хәрәкәт ясап, Арслан белән Асияне сәламләде.

Әлеге көтелмәгән очрашудан — бәлки озак көттереп килгән очрашу дисәк, дөресрәк булыр — бермәлгә югалыбрак торган Асиянең беләгеннән йомшак кына тотып, учакка таба баруын дәвам итте Арслан. Ул тыныч, күңеле күтәренке. Борынга су ягыннан искән ипле җил белән көл исе, кайнар күмер исе килеп бәрелде. Сәламләшү тәмам дигәнне аңлатып, ир-атларның берсе, мөгаен, арада иң яшедер, бер учлам шампур күтәреп арырак торган өстәлгә таба китеп барды.

Башлап сүз катучы тагы, әлеге дә баягы, шул түгәрәк ир-ат булды. Әле исемен, кем булуын да белмәгәнгә, күңеленнән, Асия аңар кушамат тагарга өлгергән иде — «Түгәрәк». Чөнки аны күргәч тә телгә килгән беренче сүз, беренче чагыштыру иде бу.

— Йә, Арслан, таныштыр, безне дә таныштыр инде яңа кәләшең белән,— диде «Түгәрәк», кунакчыл хуҗаларга гына хас елмаю белән каршы атлый төшеп.

«Кәләш» дигәндә, аның «яңа» дип ачыклык кертүенә дә игътибар итте Асия. Кайсы хатын-кызның яңа яисә иске буласы килсен икән. Яңа икәнен, үзенә кадәр кемнәрдер булганын белгән тәкъдирдә дә, ул үз-үзенә «мин — бердәнбер» дигән ялган уйлап таба. Кемнең үз-үзен рәнҗетәсе, кимсетәсе килсен икән. Соң чиккә җитеп юмартланган туташлар да үз бәһасен төшермәскә кыр талаша торган заман хәзер. Ә Асия алардан күпкә ерак, ул дәрәҗәсен, үзенә бәяне яхшы белә... «Яңа кәләш» дигәннәрен искә алса да, сабырлыгын җуймады, сер бирмәде ул әлегә. Каприз күрсәтергә, көйсезләнергә иртәрәк иде шул аңар. Хәер, икенче уйласаң, дәшүдән ни файда — ямьсезләнәсең генә... Тагы бит, ул телиме-юкмы, дөньяда хакыйкать дигән нәрсә дә бар әле. Шуны гына аңламаслык хатын түгел ич ул.

Арслан исә, кабалана төшеп, бер адым читкә тайпылды да танышларына мөрәҗәгать итте:

— Таныш булыгыз — Асия! Минем...

Соңгы алмашлыкны сизмичәрәк ычкындырды булса кирәк, «минем» дигәчтен дә, ничек дәвам итәргә белмичә, төртелеп калды. Кеме соң әле ул аның? Дусларына аңлаешлы, әмма Асияне дә үпкәләтми торган итеп ничек аңлатырга?.. Хәер, болай да, сүзсез генә дә аңлаешлы иде, югыйсә. Ул төртелеп торган арада, үзен коткардылар, ихтыяҗ юкка да чыгып куйды:

— Таныш булыйк, Лева,— дип, каршысына ук килеп баскан «Түгәрәк» Асиягә кулын сузды. Көч-гайрәтен күрсәтергә теләгәндәй, йонлач куллары белән озак тотып торды ул Асиянең бармакларын.

— Борис...

Бусы туры, мәһабәт төз гәүдәле ир-ат иде. Өстәвенә тыйнак та булырга охшаган. Күренеп тора, итагатьле. Хатын-кыз буларак, аның бу сыйфатларын Асия шундук бәяләп өлгерде. Ничек кул бирүенә карамастан, көчле һәм гайрәтле булуы да килеш-килбәтенә чыккан. Яше дә шул кырыкның аргы ягына йөз тоткан булырга тиеш. Әмма ул әле күзгә ташланырлык, һәрхәлдә, хатын-кыз игътибарын тиз җәлеп итә торган заттан.

— Капкаев!— дип, яшь малайларча чаяланып кулын сузды өченчесе. Уртача буйлы бу кешене кайдадыр күргәне дә бар кебек иде аның. Бәлки шулай тоела гына торгандыр, еш очрый торган кыяфәт. Ә гомумән, күзгә ташланырдай, алай артык хәтердә калырлык берни дә юк иде аның тышкы кыяфәтендә. Шулай да үзенең серле караш

ташлап күяз елмаюы, исемен түгел, фамилиясен әйтеп күрешүе белән, кызыксыну уятып өлгерде ул Асиядә. Тагы шунысы гаҗәп тоелды, фамилиясе алай бигүк татарча яңгырашка ия булмаса да, саф татар телендә дәшеп, картларга охшатып, ике кулын сузып исәнләште Капкаев.

— Сезнең исемегез ничек соң?— дип сорарга җөрьәт итте сүзсез торудан кыенсынган Асия.

— Капкаев,— диде тегесе янә. Һәм, шаян гына күз кысып, көлеп үк җибәрде.

— Менә таныштык та...— дип күтәреп алды янәшәдә генә торган «Түгәрәк». Әле һаман да Асия каршысында күзләрен мөлдерәтеп елмаеп торган Капкаев читкә тайпылырга мәҗбүр булды.— Әйдә, Асенька, өеңдәгедәй хис ит үзеңне. Кунак бул!.. Белеп тор — егетләрнең иң асыллары гына җыелган монда.—«Түгәрәк» тә үз чиратында шаяртып алырга кирәк тапты.— Хәтта Капкаевтан да курыкма, ярыймы, Асенька!

Ир-атларга әллә чынлап та кызык булып китте, әллә «Түгәрәк» авызыннан чыккан һәр сүзгә шулай игътибар күрсәтү кабул ителгән гадәт идеме, һәммәсе бер булып көлешеп алдылар. Үзенә булган игътибардан күңеле җилкенеп алган Капкаев исә, җыелырга өлгермәгән калын иреннәрен тагы да җәебрәк ватык пластинкадай кабатлап куйды:

— Капкаев!..

Башкалар ничек кабул иткәндер аның бу кыланышын — һәркем үзе генә белә. Әмма үзенә игътибар булу Капкаевка ошый иде булса кирәк. Бар дөньясы белән балкып, янә елмаеп куйды ул. Һәм шул арада, яшь егетләргә хас бер елгырлык белән, Асиягә күз кысып алырга да өлгерде. Шуннан соң гына, өстәл өстендә калдырган шампурларын кулына кире алып, эшлекле кыяфәт белән җәт-җәт атлап, учак янына китеп барды.

Ул әйләнеп килгәч, «Түгәрәк» аның иңенә кулын салды:

— Яле, Капкаев, кунаклар хөрмәтенә берне җырлап та аласыңмы әллә?!

Үтенүдән бигрәк, боерык сыман яңгырады бу сүзләр. Капкаев та ике уйлап тормады, һич кыенсынусыз, кулындагы шампурларын янәшәдә торган Бориска тоттырды да кесәсеннән нәни генә авыз гармуны тартып чыгарды.

Барган идем Әсмаларга,
Кер чайкый басмаларда.
Барыбер сөям шул Әсманы,
Колактан ассалар да...

Җырлаганда тавышы матур гына чыга икән Капкаевның. Шактый ук моңлы итеп, халык көе «Наласа»га туры китерә иде ул бу сүзләрне. Тыңлаучылардан да элегрәк, дөньясын онытып, үзе көлеп җибәрде ул. Аңарга кушылып башкалар да елмайды, кул чаптылар.

— Капкаев... Ә, Капкаев,— дип бүлдерде бәхетле тамашачыларны «Түгәрәк».— Сүзләрен бозып җырладың ич. Татар булмасам да, аңлыйм — бозып җырладың!

— Капкаев,— дип кабатлады җырчы. Бу аның күңеле булганда искә ала торган бердәнбер һәм иң яраткан сүзе иде, күрәсең.

Аның җырлавы Асиягә дә кызык тоелды.

— Капкаев,— дип дәште ул, үзе дә сизмәстән.— Мөмкин булса, тагы җырлагыз әле?

— Дама сорый,— дип җөпләп куйды «Түгәрәк» тә.

Ике дә уйламый, янә авыз гармунын кычкыртып куйды Капкаев һәм тагы да дәртләнебрәк җырлап җибәрде:

Барган идем Әсмаларга,
Кер чайкый басмаларда.

Барыбер сөям шул Әсманы,
Колактан ассалар да.

Сүзләре шул ук булып чыкты җырның, Асия башкачаны көткән иде. Елмаюлар, канәгать кул чабулар да — шул ук. Капкаевның күңеленә тулган шатлык кына бермә-бер мөлдери төшкән.

— Булдырасың, Капкаев!.. Молодец,— дип үзен мактап та алгач, тәмам күңеле булып, учакка таба йөгерде. Ни өчен һәм кая баруын да оныткан иде булса кирәк, чөнки шашлык ясар өчен кирәк булачак тимерләре Борис кулында калган иде.

— Ярар, монысы булды,— моңарчы бер читтә ипле генә тамаша күзәтеп торган Арслан телгә килеп, «Түгәрәк»кә мөрәҗәгать итте.— Лев Белялович, нигә болай үзегез генә соң әле сез? Кенәриләрегез кая димме?..

Рәхәтләнеп, күңеле булып тагы көлеп алды «Түгәрәк». Чын күңелдән, ихластан көлә һәм шул көлү үзенә ифрат дәрәҗәдә килешеп тора иде аның. Онытылып көлгән чакта хәтта матур гына ир-атка әверелеп китә сыман тоелды ул Асиягә.

— Ну безнең Арслан Сәхипович сөйләшә дә белә соң,— дип әйтеп куйды ул шул килешле көлүе аралаш.— Кенәриләр диме?.. Нәфис сары кошларга тиңли ич безнең сеңелкәшне... Сайрар кошка тиңли!— Бу чагыштыруны беренче кат ишеткән атлы булып, Асиягә карап сөйләде ул боларны. Сүз ахырында аның үзенә дә мөрәҗәгать итеп алды.— Арслан Сәхиповичны әйтәм, Асенька, сине дә шундый тәмле теле белән караткандыр. Шулаймы?

Сүзен әйтеп бетергәнче үк, башын артка ташлап, көлә дә башлады тагы үзе. Бары шунда гына аның эчкерсез булып сөйләшү һәм көлүендә ясалмалык төсмерләре булуны тоемлады Асия. Әмма йөзенә чыгармады моны. Арслан мактап әйтелгән сүзләр белән килешүен белгертте.

— Әйе, Лев Белялович...

— Безнең кенәриләр белән кызыксынасың инде алайса?.. Алар су коеналар,— дип, иң элек Арсланга җавап кайтарды «Түгәрәк» һәм янә, игътибар күрсәтеп, Асиягә борылды.— Теләсәгез, Асенька, сез дә су керә аласыз... Барыгыз, йөзегез рәхәтләнеп.

— Рәхмәт, Лев Белялович... Коенасым килми әлегә...

— Ул нинди сүз, Асенька, нинди сүз?!. Бар, рәхәтләнеп ял итәрсең, берочтан безнең сеңелкәшләр белән дә таныша торырсың.

— Кыстамагыз, Лев Белялович, рәхмәт!— дип, кыенсына төшеп җавап кайтарды Асия, үзе Арсланга карап куйды.— Аннан, монда су коеналар дип белмәгән дә идем...

— Аңладым, Асенька,— дип җанланып китте «Түгәрәк».— Ул ни дигән сүз ул! Кеше-кара килеп чыкмый монда, борчылма. Су коену өчен «форма номер один»нан да кулайрак нәрсә юк ул!.. Бар инде, бар, оялма, Асенька,— дип, үзенекен итәргә теләп, күлгә таба сузылган тар сукмакка таба ишарәләде Лев Белялович.— Анда мунча булыр. Киемнәреңне шунда калдырырсың. Халатлар бар...

Буйсынмый чарасы калмаган иде Асиянең, кулы белән генә этми, әнә ничек үгетлиләр ич үзен. Шулай да, иң элек, тугрылыклы хатын сыман, Арсланга күз салып алды ул. Аның да бу киңәшне хуплавын күргәч, кыюсыз адымнар белән күлгә илтүче сукмакка борылды. Хәер, кыюсыз дигәч тә, коелып төште дигән нәтиҗә чыгарырга ярамас. Ипле генә итеп, үз дәрәҗәсен белеп атлады ул. Борылып карамаса да, үзе артыннан күзәтеп калучыларның карашын тоймады түгел. Әнә ич, телләрен йотканнармыни, берсе бер авыз сүз дәшми... Бераздан, Капкаев булды булса кирәк, ир-атлардан берәве тел шартлатып алды һәм үзалдына «әттәгенәсе!..» дип такмакларга итенеп калды.

...Күл ягыннан хатын-кыз тавышы, көлешкән-чыркылдашкан авазлар ишетелеп тора иде. Учак урыныннан күтәрелгән кайнар рәшә белән

аланга яңа өлгергән шашлык исе таралды. Үзара нидер киңәшкән, хәбәрләшкән сыман, моңарчы кайдадыр күзгә чалынмый гына посып яткан шешәләр серле челтерәшеп куйды. Өч тарафтан таш стена белән ышыкланган тын аланга урман күләгәсенә сузылып ятты.

Ниһаять, чырык-чырык көлешә, үзара нидер серләшә-серләшә, әллә ни арада танышып, уртак тел табарга өлгергән хатын-кызлар — кенәриләр төркеме кайтып керде.

— Йә, кызлар, су ничек анда, су?..— иң элек аларга игътибар итүче янә Лев Белялович булды. Аның һәр эштә һәм һәр мизгелдә үзен монда хуҗа итеп хис иткәнлеге әллә каян күренеп тора иде. Хәер, моны ул үзе дә яшереп маташмый иде кебек.

— Рәхмәт, Лев Белялович... Яхшы... Бик әйбәт...

— Су — май кебек,— диештеләр кызлар.

Ә араларында иң яше — кыска итеп киселгән чәчләренә бантик та тагып җибәрсәң, үзен әле мәктәп укучысы итеп кабул итәргә мөмкин булган чая кыз — менгән шәптән кинәт кенә төркемнән аерылды да, «Түгәрәк»нең муенына ташланды, кочагына кунаклады. Башкалар өчен бу яңалык түгел иде, күрәсең, Асиядән тыш берәү дә бу тамашага игътибар итмәде.

— Ну, Лева... Ну, Лева!.. Әллә сагынмагансың да инде?!.— дип, көйсезләнгән сабый сыман, «Түгәрәк»нең сирәк чәчләреннән сыйпарга керешә кыз.— Ну, Лева... Нигә төшмәдең инде? Ә мин, синең өчен, яңа купальник киеп килгән идем... Ну, Лева...

— Йә, инде, матурым, йә, үпкәләмә,— дип акланды «Түгәрәк», кызның юка ирененнән үбеп.— Башка алай итмәм, матурым... Җитди сүзләребез бар иде... Үпкәләмә, ярыймы, матурым.

— Яңа купальник киеп килгән идем...

— Соңыннан, матурым, соңыннан күрсәтерсең.

Юка һәм җиңел гәүдәле булуына да карамастан, «Түгәрәк»кә кызны күтәреп тору кыен иде булса кирәк. Ул аны, җаен китереп, иплә генә аягына бастыру ягын карады. Ә кенәриенең исә, тынычланырга, хәлгә керергә исәбендә дә юк, ашарга сораган песи баласыдай сырпалануын белә:

— Лева?.. Ә, Лева... Син мине бөтенләй сагынмагансың инде әллә?..— дип, иреннәрен «Түгәрәк»нең ачык изүеннән ташып чыккан йонлач күкрәгенә терәп каныгуын дәвам итә.

— Ничек сагынмаска?!. Сагындым, матурым, сагындым. Йә инде, йә, сабыр итик, ярыймы...

— Ну, Лева!.. Син гел шулай — сабыр итик тә сабыр итик,— дип, үпкә белдереп, иреннәрен турсайтып алды кенәри. Ә сырпалануын дәвам итте.

...Кенәриләр. Арслан авызыннан чыккан бу сүз беренче ишетүгә үк сәер тоелган иде Асиягә. Ул хәтта аңарга үпкәле караш та төбәп алган иде бит әле. Чөнки, телисеңме-юкмы, шулай килеп чыга, бу очракта Асия үзе дә кенәриләр исәбенә керә. Кенәриләр... Кем җим бирсә, ярма сипсә — шуның иңбашына кунып, шуның күңелен күрә торган кошчыклар. Тапкан бит сүзен, шул җилбәзәк кошларга тиңләмәсә... Баксаң, Арслан хаклы булган икән бит. Су буена төшеп, кызларның үзләре белән очрашкач, танышкач та, шундук Арсланның әнә шул сүзен искә төшерде Асия. Бигрәк тә әлеге җыйнак гәүдәле кыз, үзенең әрсезлеге белән дә, килеш-килбәте белән дә кенәрине хәтерләтә сыман иде. Аның үз исеме дә бар, билгеле. Берәүләре Гуля дисә, икенчеләре Гөлсинә дип дәшә иде аңарга.

Әмма ул, үзенең Гуля да, Гөлсинә дә түгеллеген расларга теләгәндәй, кенәри сыман, берөзлексез сикергәләвен, чырык-чырык килеп сырпалануын белде. Хәтта мәҗлес күрке булырга күнеккән «Түгәрәк»кә дә башкалар белән аралашырга ирек бирмәде, аның бөтен игътибарын үзенә җәлеп итәргә тырышты... Уйнапмы-уйный, гашыйклыктан

акылын җуярга җитешкән кыз булып кылана түгелме? Югыйсә, күл читендәге комда чакта, башкаларга авыз да ачтырмый, үзенең шәһәрдәге романнары хакында сөйләп шапырынды. Яшь кенә егетләрне үзенең ничек итеп кызык иткәне, ни рәвешле берәм-берәм төп башларына утыртып китүе белән мактанды. Левасын искә да алмады... Асия аны әллә берәрсенең нярә килгән кызымы икән дип тә уйлап куйган иде... Алай да бу кенәри, теле сөйләгәннәрдән чыгып кына нәтиҗә ясасаң да, дөньяның ачысын-төчесен татырга өлгергән һәм шактый ук тәҗрибә дә туплаган булырга ошый... Үзалдына: «Кем белән килгән икән бу?» дигән сорау куеп, шул соравына: «Капкаев!»— дип җавап тапкан иде Асия. Чөнки үз-үзләрен тотышлары белән бер-берсенә туры килә иде алар. Ялгышкан булып чыкты...

Гуля-Гөлсинә һаман үзенекен итте. Күр инде, Левасын юан, йөзьяшәр наратка сөяп куйган да, күз карашы белән телгәләпме-телгәли тегенең бәгырен. Чын гашыйклар да болай булдыра алмас, әнә ничек килештерә... Томшык сыман очлайтып-бөреп алган юка иреннәре белән чукыпмы-чукый «Түгәрәк»нең алмадан да алсурак бит уртасын...

Соңгы вакытларга кадәр бөтен күргәне, аралашканы гаилә һәм эш урыны белән чикләнгән иде бит Асиянең. Бу дөнья, әлеге хикмәтләр чын-чынлап яңалык иде аның өчен. Шуңа, телиме-теләмиме, әледән-әле күз салып торды ул әлеге тамаша тарафына. Көнләшеп тә түгел, нәфрәтләнеп тә түгел, гади бер кызыксыну белән күзәтте. Бу дөньяның кемнәре генә юк, әнә ничек яшәүчеләр дә бар икән!..

Янәшәсенә Арслан килеп басканлыкны тоймый да калган иде ул.

— Йә, Асия, ничек — сиңа монда ошыймы?— дип пышылдады ул Асиянең колагына.

— Матур урын... Беләсең ич, табигатьне мин яратам.

— Ә кешеләр?.. Минем дуслар сиңа ошамадымы?

— Кызыклы кешеләр,— диде Асия һәм, күтәрелеп, Арсланның ягымлы күзләренә җавап кайтарды.

— Кызлар ничек?.. Кызлар чит итмәдеме үзеңне?

— Кенәриләрме?— дип, янә күзләренә текәлде ул аның. Бу юлы инде шелтә катыш елмаю тоемланды аның карашында.

Ә Арслан аның үзенчә үпкә белдерү, төртелергә теләвен аңламадымы, аңларга теләмәдеме — сорауга туры мәгънәсендә җавап бирде:

— Әйе, кенәриләр ничек?

— Хатын-кызга шундый мөнәсәбәттә дип уйламаган идем мин сине...

— Нинди мөнәсәбәт?

— Кимсетеп, мыскыл итеп карыйсыз...

— Киресенчә, Асия! Кенәри — сайрар кош...

— Кенәри дисеңме? Әйе, кенәри — бәхетле кош. Ә аларның берсе минем танышым булып чыкты...

— Кайсы?

— Юлия. Ул — минем классташым.

— Менә ничек?! Тау белән тау гына очрашмый диләрме әле?.. Ул да бәхетлеме?

— Булмаска, ул туган көненнән үк бәхетле кыз!

— Бәхетлеләр...— дип, суза төшеп кабатлады, килешүен белдерде Арслан да.— Монда һәркем бәхетле. Һәм һәркем бәхетне үзенчә аңлый. Капкаев әйтмешли, бу — бәхет һәм мәхәббәт ярымутравы, Асия.

— Мә-хәб-бәт?!.— бу сүзнең мәгънәсен аңларга теләгәндәй, һәр иҗегенә басым ясап кабатлады Асия. Чынлап та, нәрсә соң ул мәхәббәт? Ул әллә шундый буламы икән? Арсланны очратканга кадәр ялгышып кына да мәхәббәтнең ни икәнен татып караганы юк иде кебек ич аның. Мавыгулары да булды, иргә дә чыкты... Ә мә-

хәббәт башка булырга тиеш сыман тоела иде аңар.

Мәхәббәт хакында тәпле итеп уйлар вакыты да булмады ич аның. Кияүгә чыкты да дүрт стена арасында бикләнеп калды. Ни күргәне, кемнәр белән аралашканы булды соң аның?.. Соңгы өч-дүрт елы кызыксыз бертөрлелектә үтеп киткән ич аның. Өйдән — эшкә, эштән — өйгә. Бар белгәне шул!.. Ә элгәрге елларда үзе теләгәнчә яшәргә әнисе ирек куймады. Ата-ана янынннан китеп ирек алырмын дип уйлаган иде, ялгышкан булып чыкты!.. Арслан очрамаган булса, дөньяның матурлыгын, табигатьнең гүзәллеген, мәхәббәтнең ни икәнлеген белми картаясы булган.

Шул рәвешле, үз уйларына үзе бирелеп, җаны-тәне белән назга сусап, Арсланга сыенды ул. Толымнарын Арсланның киң күкрәгенә яшерде. Биленә сарылган көчле куллар югарыга таба тартты аны, аяк очларында гына эленеп калды Асия. Дөнья мәшәкатьләре оныттылды, хәтта бер мәлгә баш очындагы мәһабәт наратларның шавы тынып торды... Монда берәүнең дә башкаларда эше юк, һәркем үзаеры, һәр пар үзалдына бәхет эзли, бәхет таба шулай...

— Шашлык әзер... Житди эшләрне ташлап торыйк бераз,— дигән аваз ишетелде. Күзләрен ачты Асия — учак тирәсендә кайнашкан Борис тавышы икән бу.

Карыннары ачкан булгандырмы, әле генә һәркайсы үзаеры дөньяда кайнашкан парлар, репетиция вакытында режиссерның һәр сүзенә буйсынган артистлар сыман, рольләреннән чыгып, учакка таба талпынып куйдылар.

Ул арада Капкаев моңарчы күзгә чалынмый гына бер читтә торган картон тартмалардан төргәк-төргәк сый һәм ашамлыклар чыгарырга керешге. Аңарга ярдәм итеп Юлия кайнашты. Моңарчы күзгә артык чалынмыйча, иплә генә үзенең Борисы тирәсендә чуалган, карап торышка алагаем тулы һәм тыгыз килеш-килбәтле күренгән дүртенче кенәри дә хәрәкәткә килде. Алсуланып торган бит алмалары, якты зәңгәр күзләре, кершән һәм сөрмәләре хәлен белешеп, нәни көзгегә текәлеп торды ул иң элек. Аннан тулы иреннәрен барлап, кайгыртып алды. Бары шуннан соң гына көзгесен кесәсенә тыкты һәм, вакыты җиткән үрдәк сыман килешле атлап, табынга таба китте. Ә өстәл сый-хөрмәт, нигъмәтләрдән сыгылып тора иде.

— Ну, Лева, минем бер дә ашыйсым килми иде әлегә,— дип, өстәл янына иң соңгы булып, теләр-теләмәс кенә Гуля-Гөлсинә якынлашты. Югыйсә, әле күл читендә чакта ук: «Ашыйсы килә, шашлык исе килмиме әле, кызлар?»— дип, кыбырсый башлаган иде үзе.

— Үз вакытында ашый да белергә кирәк, матурым, сабыр ит...

— Ну, Лева... Син гел шулай, сабыр ит тә сабыр ит, дисең... Күпме була сабыр итәргә!

Нәкъ шул вакыт Капкаев чыгымчылап торган кенәриенең кулына шәраб тулы бокал китереп тоттырды:

— Капкаев...

— О-о-о, Капкаев!— дип, кулларын чәбәкләп, баскан җирендә ихлас куанып сикергәләп куйды кыз.— Кайсын алырга белмәссең — шәрабнымы, Капкаевнымы? Ха-ха!..

Лев Беляловичяйнәшәсендә торган кыз белән артык шаярышып, әңгәмә корып торырга кыймады Капкаев. Шулай да, кеше-кара күрмәгәндә, кызның үзенә генә күз кысып алырга өлгерде һәм иләмсез зур ачылып алган авызыннан елмаю да бүләк итте. Никадәр генә кыргый тоелмасын, үз кыланышлары үзенә килешле иде Капкаевның.

Ул арада байтактан бирле инде борын тишекләрен кытыклап торган шашлыктан Асиягә дә өлеш чыкты. Икенче кулында — вак ләйсән яңгыр яугандагыдай тамчылары сикергәләп-биеп торган шампан шәрабе.

Зур вакыйга, җаваплы эшләр алдыннан гына була торган тынлык урнашып алды урман аланында.

— Хөрмәтле дусларым,— дип бокалын югары күтәрде «Түгәрәк».— Бу беренче тостны, тарихи тостны мин, якын дусларым, сезнең өчен, шәһәребезнең эшлекле һәм булдыклы ир-атлары — чын арысланнар һәм аларга бәхет, шатлык китерүче гүзәл кызлар — кенәриләр өчен күтәрәм!..

— О-о-о!..— диеште кызлар.

— Лев Белялович әйтсә әйтә инде ул!..

— Ух, минем Левам!— дип, үз-үзен белешмичә, басып торган урынында тыпырдап куйды Гуля-Гөлсинә. Җәт кенә үрелеп, үбеп алырга да өлгерде үзен.

— Әйдәгез, дусларым, сезнең хөрмәткә!— дип кабатлады Лев Белялович. Үзенең шул дәрәҗә уңыш казанган тостыннан соң бер мәлгә онытылып калган дусларына куәт иңдерүе һәм рәхмәтен җиткерүе иде бу аның.

Сүз артыннан сүз, тост артыннан тост кабатланды. Учактагы күмер бер сүрелде, бер дөрләп алды... Яшь бәрән итеннән хәзерләнгән шашлык өлгереп кенә торды. Капкаевның картон тартмалары эченнән чыккан шешәләр, бушана барып, бер-бер артлы куаклыкка табан тәгәрәште. Башта беркадәр тартынып, читенсенебрәк торган Асия дә үзләште. Үзара кайнашкан, болганышкан арада элеккеге классташы Юлия белән дә берничә авыз сүз алмашып алырга өлгерде алар.

— Су буена төшкәч, мин сине танымадым башта, шундый үзгәргәнсең,— диде беренче булып дәшкән Юлия.— Чын заман хатыны булгансың. Арсланның үзен кулга ияләштерүең белән котлыйм!..

Рәхмәтен җиткергәч, берочтан үзен байтактан кызыксындырып торган сорауга да җавап алырга ашыкты Асия:

— Сине бик танылган профессорга чыккан дигәннәр иде, дөрес булмадымыни, Юлия?..

— Бу ярымутрауда ул хакта сөйләшмиләр, андый сораулар белән тинтерәтмиләр, Ася,— дип пышылдады Юлия. Һәм әйләнә-тирәдәгеләр өчен, болар бер-бер мәзәк хәл сөйләшә икән дигән иллюзия тудыру максаты белән, кычкырып көлеп тә алган булды.

— Аерылыштыгызмы?— дип сорамый булдыра алмады Асия, үзе дә аңарга охшатып көләргә итте.

— Аерылышмадым... Гөрләтеп яшибез, Ася!

Бер-беренә карашып елмаеп алган булдылар янә.

— Ничек алай?

— Дөнья матур ич, Ася. Һәм иркен дә... Күңелең генә киң булсын...

— Аңламадым... Син һаман да бәхетле икәнсең, Юлия.

— Рәхмәт, Ася!— нотага карап көй башкара диярсең — тагы шул ук эчкерсез һәм ясалма елмаю.

— Иргә чыгуың дөрес, димәк?— дип, бераздан янә кабатлап сорамый булдыра алмады Асия.

— Дөрес, Ася, дөрес...— дип, елмаеп алды Юлия һәм дәвам итте.— Ә шулай да иргә караганда ирек кадерлерәк.

Текәлеп карамаса да, янәшәсендәге Юлияне сокланып күзәтте Асия. Гомер-гомергә сокланды, көнләшеп яшәде ич ул аңардан. Аның кебек киенгән кеше юк иде. Әле дә, әнә ничек, кенәриләр арасында күзгә кереп аерылып тора ул үзенең кием-салымы белән...

Бераз кабып та алгач, авызы тәмам ерылып киткән Капкаев якынлашып килә иде яннарына. Кочагы киң җәелгән... Асиягә карап кеткелдәп көлеп торган җиреннән аны Юлия дә абайлап алды һәм йомшак беләкләрен күбәләктәй җилпеп каршысына атылды.

— О-о-о, Капкаев — минем арысланым!

— Капкаев... үзе...

Таһир белән Зөһрә яисә Йосыф белән Зөләйха мәхәббәте бар икән боларда диярсең... Шулай көтмәгәндә кавышу, очрашуларына

ничек куанышканнарын күрсәң, исең китәр, бер дә харап...

Мәхәббәттән исереп, сөешеп туймас чакларында кинәт Асиягә таба борылды Юлия:

— Менә, Ася, минем арысланым — Капкаев шушы була.— Аннан үзенең бәхет диңгезендә йөзеп йөргән арысланына мөрәҗәгать итте.— Ә бу чибәр ханым — минем классташым — Ася.

— Капкаев...— дип, бая беренче кат танышкандагыдай майлы күзләрен кысып куйды ир-ат.

— Без танышлар инде, Юлия,— диде Асия һәм ирексездән уйлап куйды: бу иләмсез зур авызлы, калын иренле ир-ат, җорлыгын, тапкырлыгын күрсәтергә теләп, берөзлексез үз фамилиясен кабатлап торуы белән тәмам саруны кайната. Шушы бәндәне Юлия ничек кочаклый, үбә ала икән?!.

Асиянең уйларын сизгән сыман, Юлияне биленнән кысып кочаклаган көйгә, читкә тайпылды Капкаев. Тегесе карышмады, чырык-чырык көлүен генә белде.

Берьялгызы торып калды Асия. Шул ялгызлыгы белән килешергә теләмичә, талдан үрелгән креслога җәелеп утырып җитди әңгәмә корган Арслан белән Лев Беляловнч янына таба китте. Әйе, күмерләре көлгә әверелеп барган учак каршысында алар икәү генә иде. Ә сары кенәрине хәтерләткән Гуля-Гөлсинә икенче бер читтә торган креслога чумып, мес-мес йокыга талган.

— Безнең белән тигез эчә... Ул гәүдәгә күпме сыйсын, әле дә ничек түзә,— дип, кенәриенә таба ымлап сүз сөйләп утырышы иде «Түгәрәк»нең. Билгеле; бу сердәше булган Арсланның үзе өчен генә әйтелгән сүз булгандыр, яннарына якынлашып килгән Асияне күрми иде әле алар. Асия караңгыда, ә алар ут каршында, яктыда.

— Тәртибе начар, барып чыгачак бу. Кичә дә йокламагандыр... Шәһәрне аркылыга-буйга иңли диләр.

— Тәрбияләргә кирәк үзен...

— Ха-а-а,— дип көлеп алды «Түгәрәк». Кулындагы сигаретын берничә кат тирән итеп суырды да утка тотып атты.— Тәрбияләргә дисең инде?.. Теге, ничек әле, сезнең татарлар ничек әйтә әле. Ана сөте белән... Хәтердән чыккан, ничек соң әле?

— Ана сөте белән кермәгән — тана сөте белән кермәс, диләр.

— Дөрес әйтә халык! Ул тәрбиядән узган инде.

— Үзегез беләсездер...

— Очырырга вакыт үзен, хушлашырга.

— Хәер, сез хаклы, шеф! Кенәри озак яшәми, алышынып торулары хәерле,— дип, мыек астыннан гына елмая төшеп, киңәш итеп куйды Арслан. Өстәп тагы нидер әйтте. Әмма аның соңгы сүзләрен ачык кына ишетмәде Асия.

Әлбәттә, бу хәлдә кеше сүзен тыңлап тору килешә торган хәл түгел. Шуңа, бер карарга килеп, кыю адымнар белән туры атлап, ир-атлар каршысына чыгып басты ул. Ә тегеләрнең исә моңарга артык исләре китмәде — серле генә елмаешып бер-берсенә карашып алдылар.

— О-о, Асенька!.. Асенька, рәхим ит безнең янга,— дип, урыныннан торып ук басмаса да, кымшана төшеп урын тәкъдим итте «Түгәрәк».

— Рәхмәт, Лев Беляловнч!

— Сездән рәхмәт ишетүем белән бәхетлемен, Асенька... Әмма үзегезгә бер шелтә ясарга рөхсәтме, Асенька?..

— Тыңлыйм, Лев Беляловнч, рәхим итегез.

— Сез, Асенька, Арслан Сәхиповичка ничек дип дәшәсез?..

Уңайсызланып түбәнгә карап алды Асия, тартынып куйды:

— Арслан дип...

— Менә бит, Асенька, нинди мәрхәмәтсез сез миңа мөнәсәбәттә. Нинди тигезсезлек! . Аңа — Арслан, ә миңа — Лев Беляловнч. Бу бит яхшы түгел, Асенька. Беләсезме нәрсә, миңа шушы ярымутрауда чакта

гына булса да арыслан дип дәшегез, ярармы?! Лев — арыслан дигән сүз! Шулай бит, мин дөрес сөйлимдер бит, шулаймы, Асенька?..

Килешүен белгертеп баш какты Асия. Кызык булып китте аңарга: әлегәчә уена да кереп карамаган — Лев белән Арслан адашлар икән ләбаса.

— Без генә дә түгел, монда — һәркем арыслан. Һәм һәркем үзен арыслан итеп танытасы килә,— дип, үз сүзләреннән үзе үк тәм табып, авызларын балкытып сөйләп китте «Түгәрәк».— Арыслан — искиткеч, сокланырга лаек җәнлек ич ул! Гайрәтле дә, көчле дә, матур да үзе, кемнең арысланга тиң буласы килмәс... Ә инде сезнең кебек гүзәл хатын-кыз авызыннан «арыслан» яисә «арысланым» дигән сүз ишетү, ул теләсә кайсы ир-атның иң олы хыялы, Асенька. Шуңа күрә әйтәм, Сәхипович кына түгел арыслан һәм Сәхипович белән мин генә дә түгел... Борисның да арыслан буласы килә. Капкаев булып Капкаев та арыслан саный үзен. Күргәнсез ич, әнә нинди кенәри эләктергән. Үзегезгә генә әйтәм, аның кенәрие бик югары даирәләр белән бәйләнештә!.. Шулай итеп, Асенька, килешәбез, ярыймы — Лев Беляловичны онып! Арысла-а-ан! Без монда һәммәбез — арысланнар! Арысланнар һәм кенәриләр!..

## II

Хәтерлисездер, безнең Асия үз вакытында медицина институтына укырга да кергән иде бит әле. Ничек итеп әле кайчан гына врач булырга җыенып йөргән бу кыз ательега барып чыккан да тегүче булып киткән диярсез. Зинһар, сабырсызланмый торыйк, боерган булса, барысы да аңлашылыр.

Медицина институтында яхшы гына укый башлаган иде Асия. Беренче семестрны хәтта бары тик яхшы билгеләренә генә биреп чыкты. Бу көнне зур түземсезлек белән көтеп алган ананың, билгеле инде, башы күккә тиде. Еллар буе саклап, хәстәрләп җыйган акчасына, шушы уңай белән, кызына пардан алтын алка һәм йөзек бүләк итте.

Беренче курсны да уңышлы йомгаклап чыкты кыз. Бу юлы да буш итмәде үзен әнисе — алтын чылбыр-муенса. Шул рәвешле, бер-берен аңлап, җайлашып һәм килешеп, матур гына яшәүләрен дәвам иттерделәр.

Студент халкының әле аның ике ай чамасына сузыла торган җәйге ялы — каникуллары да була. Берәүләр Кара диңгез ярында кызына, икенчеләр төзү отрядлары белән эшкә юнәлә шул җәйге айларда. Ә Асияләр группасындагы кызларны исә Әстерхан якларына карбыз һәм помидор җыярга җибәрделәр. Хәер, иптәш кызлары белән бергә барырга үзе теләк белдерде Асия, үзе ният итте.

Ният итте итүен дә, тик әнисенә ничек шул хакта әйтергә икән дип, байтак вакытлар җай эзләп, баш ватып йөрде. Чөнки белә: аңардан рөхсәт алу җиңел булмаячак! Китәсе көннәрне бармак бөгеп көтте югыйсә, ә киңәш-табыш итү сәгатьләре кичектерелә килде. Кыюлык һәм тәвәккәллек җитенкерәмәде. Ә инде әлеге хәл өйдә мәгълүм булгач, анда, әйтик, мондыйрак сөйләшү-аңлашу купты:

— Әстерханга?..

— Әйе, Әстерханга!

— Син ничек, минем белән килешми торып, шулай җиңел генә хәл итеп куясың?

— Паспорт — кесәдә. Мин үз-үземә хуҗадыр лабаса...

Шул рәвешле, эредән генә хәл итмәкче кыз. Барып чыкмады. Ана кешене исә, кызының шундый тәкәбберлеге тагы да чыгырыннан гына чыгарды.

— Каян килгән, каян килгән... Хуҗа булган ди берәү!.. Бармыйсың дигәч, бармыйсың, кызым!

— Без бит бөтен группа белән, үзем генә түгел...

— Барсыннар... Группа түгел, институт белән барсыннар. Анда минем ни эшем бар?! Үз кызыма мин үзем хуҗадыр лабаса.. Килмешәклеккә чыгарып җибәрдем юк!

Әнисен аңлыйсы килеп тә аңлый алмады кыз. Көләргә дә, еларга да белми аптырады. Ул аның карышасын белә иде белүен, әмма бу кадәрле дә нык торыр дип башына китермәгән иде. Институт исеме белән бәйле вакыйгаларга бишкуллап риза була иде ич моңа кадәр. Кунакка барса да, дискотекага чыгып китсә дә, институт белән бәйләп алдашса, үтә иде әлегәчә.

— Әй, әни, әйтеп тә куясың инде син, «килмешәклеккә» дисеңме?!. Ничек оят түгел, үзең укытучы, завуч та бит әле. Медицинскийга димләүче дә үзең булдың... Без бит студентлар отряды белән помидор һәм карбыз җыярга барабыз,— дип, башка яктан да килеп карады кыз.

— Бармыйсың дигәч, бармыйсың! Җир читенә чыгарып җибәрергә, аннан сине бар дип көтәргәме, юк дипме?..

— Юк-бар сүз сөйләмә инде, әни... Туйганчы карбыз ашыйбыз да кайтып та җитәбез бит инде без!..— Шул рәвешле, ялвару-үгетләүгә күчеп, сырпаланып та карамакчы булды кыз. Барып чыкмады, үтмәде.

— Карбызны өйдә ашарсың!— Булды җавап.— Базардан үзем ташып торырмын,— дип, чебен кугандагыдай, башка бер сүз ишетәсе килмәгәнне белгертеп, селтәнеп куйды ана.

— Башкалар әле төзү отрядлары белән җәй буена да китteләр... Син генә инде...

— Кеше баласы өчен мин җавап бирмим!

— Әни-ием...,— дип, яңабаштан юмаларга керешеп карады кыз.— Уйлап кара әле син?!. Ничек итеп мин группадашларымнан аерылып калыйм?.. Институттан кусалар?.. Син бит укытучы кеше, әнием.

— Җибәрәсем килми шул, кызым,— дип, күз читләрен сөртеп алды ана да, кызының ягымлы сүзләреннән күңеле йомшарып китте.

— Мин сиңа хат язып торырмын, әнием,— тәмам сырпаланырга ук керешмәк булып карады кыз.

Барып чыкмады, булмый дигәч — булмады инде.

— Институтыңа үзем барырмын. Авыру әнисен калдырып китмәсен, ди-ди аңлатырмын...

— И-и-и, әнием,— диде кыз йомшак кына. Әнисен чын-чынлап кызганып та куйды бугай тагы үзе. Әмма сүзеннән кайтырга да исәбе юк, кая ул!— Барам дигәч, барам! Кеше көлдереп йөрмә инде, ярыймы, әнием...

— Күңелем сизә, җүнлегә ашкынмыйсың, кызым. Өйдән мин сине чыгарачак түгел барыбер.

Ана белән кыз бәхәсләшкән арада, үзалдыма уйланып куйдым. Мин ни дияр идем икән? Кыз яисә ана урынында башка бер-бер ир-ат булса ни дияр иде икән?.. Белмим, ә шулай да без — ир-атларны бик тиз сындырырлар иде кебек.

Ниһаять, бәхәсне дәвам иттерүнең урынсыз икәнлеген тәмам төшенгән Асия, үпкәләгән кыяфәт ясап, үз бүлмәсенә кереп бикләнде. Әнисе исә, сындырдым, күндердем кызны, дигән нәтиҗәгә килеп, тынычлап чәй эчү максаты белән, кухняга юнәлде. Өстәл хәстәрләде, күңеленнән генә фикер йөртте ул: «Әтисе дә җәйнең җәй буена өйгә кайтып керми... Инде, үз ирене белән, пешкән алма сыман тулып торган, буй җиткән кызын да елга порты читендә озатып калсынмы? Алай да нык торды әле... Тиле уйларын баш күтәрүгә үк тамырдан кисә бармасаң, җиңәрсең, бар, аларны... Әнә ничек матур, зифа булып үсеп җиткән аның кызы... Җаена куйсаң, ай күрде — кояш алды дигәндәй, абайламый да калырсың. Хәзер бит аның ир-ат һәм егет-җиләннәре дә, тилгән сыман, кайчан һәм кайсын эләктерим икән дип кенә эзләнеп йөри...»

Кызының тавыш-тынсыз гына шулай үз бүлмәсенә кереп бикләнүенә тәмам күңеле булган иде ананың. Еласа — елар, елап үсә кызлар, бер туктар әле. Акылына килгәчтен, үзе үк рәхмәт әйтәчәк бит ул әнисенә...

Ә Асия? Аның хәлләре ничек, ул ниләр уйлый иде икән соң шул мизгелдә?! Кыз, шулай итеп, группадашларыннан аерылып, берүзе шәһәрдә калырга ризалашып та куйды микән?

Дөресен әйткәндә, бер дә карбыз яисә помидор җыясы килүдән атлыгып тормый иде ул Әстерханга. Ул бардымы, бармадымы — өлгергән уңыш басуда калмаячак. Калса да, утырып елаучы булмас. Колхозныкы ич ул, әллә авыл халкының колхоз малына ничек караганлыгын белми идеме?!. Үз бакчасындагы бәрәңгесе исән-аман базга керсә, колхозныкы шунда ник кар астында калмый. Аңа карап кына ач та, ялангач та калмый бит ул авыл кешесе... Ярар, соң чиктә калдырмасыннар, җыеп та алсыннар ди. Барыбер, ул уңышның күп өлеше йә шунда басуда калып өшиячәк, йә шәһәрдәге яшелчә базаларында череп таркалачак. Авыл җирендә үсмәсә дә, колак һәм күз бар ич. Елның-елында көздән яшелчә хәзерләү планын шул тикле процентка арттырып үтәдек, гектарыннан шул тиклем уңыш чыкты, узган елгыдан шул тиклегә күбрәк бәрәңге, суган, яшелчә салынды, дип шапырыналар да... Карап торсаң, яңа елга кергәнче үк кибеттә өшегән яисә черек бәрәңге сатарга керешәләр. Бераздан анысы да юкка чыга, витриналарга океаннар артыннан килгән грейпфрут тезеп куялар. Бер быел яисә узган ел гына булган очраклы хәл түгел, ул белә-белгәннән шулай ич... Әстерхан помидорларын да шул ук язмыш көтә. Яртысы юлда чери, икенче яртысы — склад белән кибет арасында...

Ул якларын яхшы чамалый иде Асия. Китәсе килүе карбыз ашыйсы килүдән дә, уңыш җыю дигән изге омтылыштан да түгел, өйдән ычкынырга җай чыгып торудан. Әнисенең көннәр буенча, алай итмә, болай ит, кая барырга җыенасың, барма, диеп өйрәтеп торуларыннан туйган, тәмам гаҗиз булган иде ул. Өйдән ерак китеп, үз-үзеңә тулы хуҗа булу, чын иреркнең ни икәнлеген вакытлыча гына булса да татып карау омтылышы ашкындыра. «Юк инде, әнием, гел синеңчә генә булмый торсын әле. Китәм дигәч — китәм! Үз сүземне сүз итәр өчен генә булса да китәм инде хәзер. Гел-гел син дигәнчә генә булмый торсын әле...»— дип кабатлады ул күңеленнән. Елау кая, ул хакта уенда да юк, кеше-кара күрмәгәндә елауның ни мәгънәсе бар?!.

Ә әнисе биш минуттан биш минутка аның ишеге янына килә дә, кызын кайгыртып китә: «Кызым, тынычлана күр, зинһар дим, борчылма, кызым...»

Юлга чыгу хакында ләм-мим сүз катмады ул башка. Әнисе өйдә юк чакларны туры китереп, кирәк-яракларны барлый, хәстәрли йөрде дә, сәгате килеп җиткәч, игълан итте:

— Хуш, әнием, исән-сау яшә! Сәгать ярымнан теплоход китә, хат язармын,— диде.

Борчулы көннәр күптән онытылды, барысы да мин дигәнчә хәл ителде, дип санап йөргән ана телсез-өнсез калды. Башка чара таба алмады, ишек катына барып, тәрегә кадакланган Гайса сыман, кулларын-аякларын як-якка ташлап, аркылы басты:

— Үзем исән чакта, һичкая җибәрмим,— диде.— Кызым, акылыңа кил,— дип юмаларга да омтылып карады.

— Хакың юк, мин читлектәге кош түгел,— дип чәчрәде Асия.

— Читлектә дә түгел... Җибәрмим дә... Син — минем кызым!

Ә инде аркасына рюкзак асып каршысына килеп баскан кызының күзләрендә иман юклыкка тәмам ышангач, җәт кенә тышкы якка чыгып, ишекне ике кат йозакка шартлатып бикләп куйды ана.

Асия үз әнисен белми түгел. Соң чиктә, мондый борылышка да әзер иде ул... Үзенең чарасызлыгын белгертергә теләп, еламсыраган аваз белән ишекне эчке яктан йодрыклап бераз төйде дә, аяк очларына басып,

көннең-көн буена ачык торган балконга юнәлде. Түбәнгә күз ташлап алды — биек, баш әйләнерлек. Хискә бирелеп торыр ара да юк, җәт кенә балкон читендәге тимер капкачны ачты. Бу тишекнең янгын сүндерүчеләргә керәге чыгадырмы-юкмы, әмма Асия кебекләр өчен ярап куя икән... Текә тимер баскыч буйлап алтынчы каттан бишенчегә төште. Рюкзак та үзеннән калмады. Башка чак булса, балкон читеннән карап торырга да куркыр иде, ә бүген тәвәккәллегенең чиге юк.

Аскы каттагы күршеләренең балкон тәрәзәсен кагарга керешге ул. Күршеләр дип, анда ялгыз эчкече бер абзый яши. Хатыны әле узган атнада гына, балаларын ияртеп, авылга әти-әниләренә кайтып китте. Күргәндә-очраганда танымаган-белмәгәнгә сабышып йөргән күрше генә булса да, бәлки ярдәм итәр дигән өмет бар иде Асия күңелендә. Хәер, аңарга нәрсә, балкон ишеген ачып кертергә дә өй ишегеннән чыгарып җибәрергә генә ич. Өйдә генә булсын...

Тәүлекнең бу вакытында, Асиянең чамалавына караганда, алкаш күрше өйдә булырга тиеш. Чөнки әлегә аракы кибетләре бикле. Мондый ирләр өйдән чыкмый әле. Кая барсын, кибет ачылмыйча торып, шешәдәш дуслары да килеп аптыратмый торгандыр — файдасыз ич... Мондыйлар өчен якты көн аракы-вино сата торган кибет ишекләре ачылган сәгатьтән башлана. Көнозын, идән астында шым калып посып яткан амбар күселәредәй, үз сәгатьләре сугып, «ишекләр» ачылганны көтеп яталар да сәфәргә...

Ялгышмаган булып чыкты Асия. Күрше озак көттермәде, сукранасукрана, балкон ишеген ачарга килде. Балконда кеше булуына, ул кешенең кем икәнлегенә исе китми генә ачып кертте Асияне. Үтә күренмәле пыяла ишек артында кем торуын да абайламады, өй ишеген ачып, көтелгән кунагын каршы аламыни!.. Йоклап яткан чагы булган — тезенә кадәр төшеп торган озын балаклы чуар трусиктан тыш, өстендә берни дә юк. Чәчләре тузгыган, шәрә иңбашлары өшегән алма сыман бөрешеп калган. Ярымачык күзләр тәмәке төтенедәй тонык томан артында. Үз хәле хәл иде, кыскасы...

Ачып керткәчтен дә Асиягә күз салмады ул. Карлыккан тавыш белән:

— Запас юк,— диде. Һәм, керсәң кер инде дигән сыман, борылып китеп тә барды.— Баш авырта...

Алкаш күрше кухня ягына юнәлде. Чәйнек капкачларын шалтыршолтыр китереп, бер-бер эчәр нәрсә эзләү белән мәшгуль булды.

Аңардан бераз калыша төшеп, рюкзагын авырлык белән генә өстерәп, ишек катына таба якынлашты Асия. Әмма ишек тоткасына кулы тиеп, җаны тынычлангач, бермәлгә туктап хәл алды. Гомер аралашмаган күршеңнең балконыннан кер дә ишегеннән чыгып кит — рәхмәт тә әйтмә, имеш. Сәер ич, уңайсыз да... Ни әйтергә, нәрсә диярга белми туктап калды ул. Берочтан ишекнең аргы ягында кеше-фәлән юклыгын да ачыклау иде теләге — сагаеп, колак салып торды.

Ул арада, чәйнек төбендә калган кичәге куе, салкын чәйне йотып, шәмәхә төскә кергән күз кабакларын уа-уа, күршесе ишек катына якынлашты. Асияне күргәч, хәйран калды. Чигәләрен уып алды — өнемме бу, төшемме, янәсе.

— Менә сиңа, мә... Асенька түгелме соң? Асенька... Күрше...— Көткән кунагын каршы алгандагыдай итеп ике кулын киң җәеп алды алкаш күрше.— Әйдә, кер, Асенька... Кер, түрдән уз...

— Кердем ич... Инде чыгарга вакыт,— диде кыз һич шаяртусыз. Шаярту кайгысы идемени соң аңарда.

— Әйдә уз, Асенька... Уз, тупсада тормыйлар инде... Үсми калуың бар,— дип инде тәмам ачыла төште алкаш күрше, әлеге көтелмәгән очрашуга куанычын яшерә алмыйча.

Йөзләренә җан кергәндәй булып китте аның. Әйе, хәтта, әнә, елмаерга, шаяртырга да итеп карады. Тик бер нәрсә хак — ул Асиянең каян

ничек килеп керүен әле һаман да аңлап бетерми иде. Күзләрен угалый торгач, ниһаять, йокысыннан да тәмам уянып җитте булса кирәк. Үзенең кыяфәтеннән уңайсызланган кебек, озын балаклы трусигын югарырак тарта төшеп, артка чигенде ул.

— Мин хәзер, Асенька, хәзер киенәм, яраймы... Бер генә минуточку... Ә син түрдән уз.— Үзе чигенә, үзе Асияне кыстарга, юатырга итенә.— Болай ишек катында тору килешмиме бит инде, Асенька...

— Рәхмәт,— дип, тартынып куйды кыз. Берочтан янә күз чите белән ишек тоткасын барларга онытмады. Әллә ничек, уңайсызрак та килеп чыкты ич, акланырга да итенеп карады.— Мин бит болай гына, әнидән качып кына... Сез аңарга әйтә күрмәгез, яраймы.

— Мине кемгә санныйсың, Асенька...— дип, колагы ишеткәннәрдән үзенчә нәтиҗә ясап, тагы да җанлана төште алкаш күрше.— Монда булган — монда калыр, Асенька. Әйдә, әйдә, курыкма... Әйтәмме соң?.. Мин бит сине күптән беләм. Син узып киткәндә, һәрчак артыңнан борылып карап калам, Асенька...

Шул чакны, үч иткәндәй, аргы яктагы күршеләрдән берәү өенә кайтып керде, ачкычларын чылтыратып, ишек ачарга керешге. Бер-бер карчык иде, күрәсең, ишек катында озак, бик озак кайнашты ул... Баш исән чакта, чыгып шылырга кирәк, дип торган Асия, шуны көтеп, тоткарланырга мәҗбүр булды.

Алкаш күрше аның саен Асияне элек-электән белгәнлеге, күзәтеп йөргәнлеге хакында сөйләнде.

— Син, Асенька, ышанмыйсыңдыр да әле... Билләһи-газим дим менә, авылдагы карт әнием белән ант итәм... Ипидер дим, сине күргәч, җөрәк кысып-кысып куя торганые... Һаман ышанмыйсың син... Соң, ни белән ант итим соң тагы... Әйтсәм әйтим, Асенька, сине күзәтә-күзәтә, муеннарым кәкрәеп бетте инде. Ни белән ант итим, ничек ышандырыйм икән?..— дип, әйтер сүз таба алмый хәйран озак баш ватып торды ул. Туган әнисе, ипи белән ант итте ич инде. Алардан да кадерлерәк тагын ни табарга мөмкин? Тапты!— Ну, алай булгач, Асенька, берәүгә дә алай дип ант иткәнем юк иде әле. Беткән баш — бетсен: вермут заты, портвейн тамчысы күрмим алайса... Сине кочаклап бер җокласам, үлсәм дә үкенмәм дигән идем, Асенька!..

Янә түбәнгә шуышкан озын балаклы трусигын тартып, күтәреп куйды күрше. Иреннәрен ялап-ялап алды.

Ә ишек аръягындагы теге карчык һаман кыштыр-кыштыр килә иде. Асиянең бит әле исән-аман чыгып котыласы гына түгел, елга портына да соңгармый төшеп җитәсе бар.

— Ашыга идем шул,— дигән сүзләр чыкты авызыннан.

— Аңладым, Асенька, аңладым,— дип янә дә җанланып китте алкаш күрше. Бер-бер нәрсә искә төшереп булса кирәк, кош тотарга җыенган мәче сыман җайлы гына атлап, кухняга таба китте. Суыткычын бер ачты, бер япты — нидер табарга тели иде, таба гына алмады. Һәм, ниһаять, еларга җитешкән сабый сыман, сукранып ук куйды.— Беткән... Тамыры корган... Жу-у-ук...

Ә ишек артындагы карчык әле булса кереп китә алмый газаплана ишегеннән. Үзалдына сукрана-сукрана, кемнәрнедер сүгеп, орышып та алды инде, ачылган ишеген япмый да япмый һаман. Алкаш күрше инде, кухнясының башын аякка әйләндереп, чыгып та килә.

— Тапмадым... Әллә кая гына куйган идем кебек тә бит, тапмадым. Кыюлык өчен әйбәт була иде дә бит. Син мине ачуланма инде, яраймы, Асенька... Бу саран икән дип әйтә күрмә, яраймы, Асенька?!.

— Рәхмәт,— дип, тартынып, ике ут арасында торып калды Асия. Атап дәшәргә, күршесенең исемен дә белми икән тагы үзе.— Сез мине дөрес аңламадыгыз, абый...

— Аңламыйммы соң?.. Дөрес аңладым, Асенька, дөрес... Шулай да, таба алган булсам, зыян итмәгән булыр иде әле... Ярар алай булгач,

әйдә кер инде, ишек катында тормыйлар бит инде...— дип, кулларын сыпыргалап, иреннәрен ялый-ялый, каршысына якынлашты ул аның.

Шулчак «шап» итеп аргы якта ишек ябылды. Эшнең кай тарафка китеп барганын чамалап өлгергән Асия, ялт кына рюкзагын өстерәде дә чыгу юлында булды. Сул беләгеннән тотып алган алкаш күрше дә карышмады артык, җибәрергә мәҗбүр булды кулын. Үзалдына мыгырданып калды:

— Соң, үзең кергәч кенә дип әйтүем... Алайса, үзеңә кара, Асенька, җокы да туймаганые әле. Үзеңә кара...

## 12

Эше белән әллә ни кинәндермәсә дә, Әстерхан якларыннан матур гына йөреп кайтты Асия. Дөрес, кайтыр көннәр алдыннан гына үзенә күрә бер күңелсезлек тә булып алды. Хәер, күңелсезлек дисәң дә инде, яшь чакта андый гына хәлләр булмый тормый.

Барып төшкән көннәрендә үк танцыда бер егет белән танышып алган иде ул. Үзләре кебек үк, колхозга ярдәмгә килгән шофер. Уртача гәүдәле, төптән ныгып үскән таза егет. Күзләре чем-кара, утлы күмер сыман, елык-елык килеп торалар... Телгә дә күршегә керә торганнардан түгел: ике сүзенең берсе — мәзәк. Урынлы-урынсызга төчеләнеп, кирәксә-кирәкмәсә «рәхим итегез», «гафу итегез» дип юхалана торган интеллигент түгел инде. Күрүгә үк ошатты аны Асия. Гомумән, шаян һәм елгыр егетләрне ярата торган иде ул.

Шофер егет үзен эшкә илтеп куйды, кичен каршы алды. Ә караңгы төшкәч, иркен кабинага икәү генә кереп утыралар да Идел буена, күлләргә элдерәләр. Икәүдән-икәү генә кыргый үрдәкләрне сискәндереп су коенулары дисеңме, кочак-кочак төнбоек чәчәкләре, ай нурында сикерешеп уйнаган балыклар, йолдызлы зәп-зәңгәр күк йөзе. Бар табигать — аларныкы, дөньяның, Идел киңлекләренең бар матурлыгы алар өчен генә иде ул көннәрдә...

Айлы кичләр йолдызлы зәп-зәңгәр төннәргә тоташты. Ә зәңгәр төн, сабырсызланып, офыктан алсу таң нурларын каршы алды. Әлеге шофер егеткә шулкадәр тиз ияләште ул. Шаярып кына, вакыт узсын өчен, болай гына дип башланган очрашулар, чын-чынлап мавыгуга әверелеп китте. Күптәннән белгән сөешеп туймас ярлар диярсең... Әйтерсең лә бер-берсе өчен туган иде алар бу дөньяга. Мәңге-мәңге менә шулай дәвам итәр, бергә булырлар төсле тоела иде.

Әнә шул айлы-йолдызлы кичләрнең берсендә шофер егет Асияне шашып-котырынып үпте, көчле кулларында кысып, кайнар сулышы белән эретте. Үзе берөзлексез:

— Минеке бул!.. Минеке бул, Асия! Мин сине барыбер үземнеке итәм!..— дип кабатлады. Инде бөтенләй эреп, онытылып барган бер вакытта Асия кинәт кенә, мөгаен, монда эшкә килгәннән соң беренче тапкырдыр, әнисен искә төшерде, аның борчулы йөзен, хәвефле карашын күз алдына китерде, тавышын ишеткәндәй булды. Һәм ул, үз-үзен ниндидер хәвефтән сакларга омтылып, егетнең кочагыннан котылырга тырышты, талпынды, тартышты, бар көченә карышты. Ләкин әллә нинди аңлашылмас бер өстен көч аны яңадан эретте, яңадан изрәтте һәм татлы газап эчендә калган Асиянең тавышы күл буен яңгыратты:

— Ән-и-е-м-м!..

Чыклы үлән өстенә ятып, озак үкседе, озак елады Асия. Бу төндә үз яшьлеге белән саубуллашуын тоеп, үртәлеп, үрсәләнеп, нәрсәнеңдер инде мәңгегә китеп баруын, кире кайтмаслыгын сизеп елады ул.

Шофер егет аны юатмады...

Иртәгесен аерылышабыз дигән кичтә Асия аңар үзенең тел очын-

да торган соравы белән мөрәҗәгать итте:
— Китәр көн дә җитте...— диде ул, егетне җитди сөйләшүгә әйдәп.
— Шулай икән,— диде егет. Артык исе китмәгәнлеген күрсәтте.
— Алга таба ни эшләрбез икән инде?..
— Яшәрбез,— булды җавап. Һәм, Асиянең күңелен күтәрергә теләп, шундук өр-яңа анекдот та сөйләп алды. Сөйләп бетермәс борын, гадәтенчә, иң элек үзе көләргә керešте...
— Ничек яшәргә, аерым-аерыммы?
— Бер үк Кояш астында, ха-ха!..
— Аерылабыз, димәк?
— Ни сөйлисең, Асенька?.. Ул нинди сүз ул, аерылабыз, имеш... Һәркайсыбыз да мөстәкыйль кешеләр ич без!
— Иртәгә мин юлга чыгам...
— Мин дә монда калырга җыенмыйм.
— Мин — Казанга. Ә син?
— Ә мин — Әстерханга, ха-ха...— Асиянең моңсу күзләренә төшеп торган чәч учламын күтәреп, сыпыргалап куйды егет, сүз җаена чиратгагы мәзәген дә сөйләп алды.— Беләсеңме, бер кыз үзенең иптәш кызларына егетен алдавы турында сөйләп мактана икән. «Тәки алдадым бит теге Шурикны, адәм мәсхәрәсе иттем»,— ди икән. «Ничек алдадың соң, ничек итеп? Сөйлә әле?!»— диләр икән иптәш кызлары. Бу әйтә икән: «Алдадым! Йоклавын йокладым аның белән, әмма кияүгә чыкмадым үзенә!»— ди икән. Менә вәт!
Асия дә елмаерга итте, үз-үзен басып торган моңсулыктан арынырга кирәк иде аңарга да. Әмма син дигәнчә генә булмый шул ул андый чакта. Күңелдәге — телдә:
— Китәрсең дә онытырсың әле?..
— Онытa белү — сәнгать, дип әйтеп әйткән ди синең кебек гыйлемле бер кеше, Асенька... Ха-ха...
— Онытa белү — сәнгать,— дип, аның сүзләрен кабатлады, күңеленнән сөзеп уздырды кыз. Чынлап та, мондый сүзне кайчандыр, кайсыдыр китапта укыганы бар иде кебек аның. «Оныту — хәтерсезлек дигән сүз, ә хәтерсезлек — сәнгать булып чыга, димәк... Нинди зур мәгънәсезлек!»— дип уйлап куярга өлгерде ул күңеленнән.
— Безнең эштә оныта да белергә кирәк, Асенька.
«Безнең эштә» дигәне сәер тоелды егетнең. Кызны сискәндереп җибәрде аның бу сүзләре. Өстәвенә, көлмәде дә бит әле ул бу юлы, димәк, чын күңелдән әйтелде бу сүзләр: «Безнең эштә...»
— Нинди «эш» ул? Аңламадым, аңлат зинһар?!.
— Ярар. Асенька, ярар инде...
— Шулай да?
— Нәрсә, без синең белән гомерлеккә дип йөргәнмени? Нишләтәсең, без — очраклы рәвештә генә очрашкан кешеләр. Шулай булгач, ничек очрашкан булсак, шулай ук, каефләрне кырмый гына аерылыша да белергә кирәк, Асенька. Без командировкага килгән кешеләр генә ич... Ә командировка — эш! Шулай бит, ә?..
Логикасыз түгел иде егет. Сүзләренең очы-очка ялгана. Кыз да аңлый боларның шулай икәнлеген. Аңлавын аңлый, ә күңелне, яралы күңелне ни эшләтмәк кирәк?
— Ә оныта алмасак? Оныта алмасам нишләргә?
— Җитәр инде, Асенька, кеше көлдермә әле!.. Соңгы сәгатьләрнең кадерен җибәрәсең ич. Кил, мондарак кил инде тагын бер...
— Хәтерендәме?— диеп сискәнеп куйды Асия һәм аның кочагыннан балык сыман шуып чыкты.— Хәтерендәме — син өйләнәм, бергә булырбыз, дигән идең?..
Егеткә тагы да кызыграк булып китте, шаркылдап көлде ул, чалкан ятып тәгәри-тәгәри көлде... Һәм, форсаттан файдаланып, өйләнешү хакында өр-яңа мәзәк тә сөйләп алды.

— Жүнле нәрсә булса, өйләнү-язылышуларны «брак» димәсләр иде аны. Брак заманы түгел ич, «знак качества» заманы хәзер, Асенька!

Үзенең җорлыгына, тапкырлыгына хәйран калып, янә бер кат тәгәрәп көлеп алды.

— Очрашкан көнне үк: «Минеке буласың, бирәүгә дә бирмим. Кире Казаныңа җибәрмим мин сине»,— дигән идең...

Әйе, бу сүзләр дә Асия авызыннан чыкты. Яшел чирәм өстендә дөньясын онытып тәгәрәп-уйнап яткан егет алдында үз-үзен түбәнсетүе хакында уйларга арасы булмады аның. Иртәгә аерылышалар ич, әйтелмәгән, әмма әйтәсе килгән сүзләрнең чиге юк.

Егет тә хәтерсез түгел. Үзенә кирәген ул да хәтерли.

— Ә үзең, үзеңнең ни дип җавап биргәнеңне оныттыңмы? Укыйсым бар, дидең. Сезнең Әстерханыгызда нәрсәм калган, дидең... Оныттыңмыни? Син әйттең ич бу сүзләрне!

— Син соң, син үзең ни дидең: «Казанга җибәрәмме соң?— дидең.— Мин ике сөйләшмим, әти-әниеңә хат кына җибәрәбез, монда каласың»,— дидең...

— Дисә соң... Син бит калмыйм дидең. Телеңне чыгарып көлдең дә бит әле, оныттыңмы?..

Кызга авыр иде болай сөйләшү. Шаяртыр, бер-береңне үртәү белән вакыт уздырыр чакмыни? Иртәгесен иртүк юлга чыгар чак җиткәч, бу искә алу, үртәшүләрнең ни кирәге бар?!.

— Тукта әле, шаярмыйк әле,— дип дәште ул, егеткә текәлеп карап.

— Соң, утырып елыйк алайса,— диде егет, күп уйлап тормастан. Үз җавабының тапкыр килеп чыгуыннан күңеле булып, кеткелдәп алды тагы. Кызның чәчләреннән сыйпавын дәвам итте.

— Ничек син шулай көлә аласың?

— Телисеңме, сине дә көлдерәм. Өр-яңа анекдот сөйлимме?..

— Сөйли күрмә,— дип, өстенә ишелергә торган хәвефтән саклангандай аның авызын томалады кыз.— Сөйләмә, кирәкми.

Егет дәшмәде. Һәм көләргә дә базмады. Бертын икесе дә тынлыкка колак салып утырдылар. Кайдадыр, таллыклар аръягында, чупырдашкан үрдәкләрдән тыш һичбер җан иясе аваз бирмәде... Авыр сүзләр ишетү җиңел түгел, тынлык исә — тагы да авыррак. Асиянең бәгыре янә тел тибрәтте:

— И-их, син,— диде ул, ихластан кәефе китеп.— Шундый сүзләр белән шаярмасаң?!.

— Нинди сүз?!— Чынлап соравы иде бу шофер егетнең, ул хәтта тынгысызланып алды.

— Бирәүгә дә бирмим... өйләнәм, дидең.

Бу сүзләрне кыз, аңарга түгел, үз-үзенә искә төшергәндәй бер гамь белән кабатлады.

— Соң, Асенька, кызык икән син!— дип, янә елмаерга итте егет. Әмма бу юлы бигүк уңышлы барып чыкмады аның елмаюы.— Чынлап та, кызык син... Соң, үзең уйлап кара, андый чакта әйтелә инде ул. Әллә ниләр вәгъдә биреп атасың. Ир-ат бөтен биргән вәгъдәсенең яртысын гына үтәсә дә, күптән коммунизм булыр иде Җир йөзендә... Беренчесе һәм соңгысы да мин түгел. Нишлисең, Асенька,— диде һәм, чарасыз икәнлеген аңлатып, тирән сулыш алып куйды.— Бергә кочаклашып утырганда бирәү дә «мин өйләнгән» дип әйтми торгандыр инде.

— Син бит өйләнмәгән?!.

— Хатын бар! Кызга — өч яшь...

Асия дәшмәде. Каршысында уен-көлке белән көн иткән җилбәзәк егет түгел, ә гаиләле ир-ат булуын шунда гына аңлады ул. Ә моңа кадәр шаярган, анекдотлар сөйләгән уенчак егет юк инде. Әйтелгән сүз, бирелгән вәгъдә, иркә һәм назлар — һәммәсе уен гына булган. Әйе, уен!

Казанга кайтып җиткәнче бирәү белән дә аралашмады, һичкемгә



*А. Тимергалина рәсеме.*

үзе башлап дәшмәде, дәшүчегә җавап кайтармады Асия. Әйтерсең, айлар дәвамында болында, утрауларда уйнаган, уйнап, назланып туймаган күбәләкнең канатын, берьюлы ике канатын кискәннәр иде. Җор телле, тәвәккәл һәм кыю Әстерхан егетен ул чынлап та ошаткан иде, күрәсең. Егетнең: «...Үзең уйлап кара, андый чакта әйтелә инде ул. Ир-атлар биргән вәгъдәнең яртысы гына үтәлә торган булса да, Җир йөзендә әллә кайчан коммунизм булыр иде...» — дигән сүзләре колак төбеннән китмәде аның. Кем белә, Әстерхан егетенең әлеге сүзләрендә чынлап та хаклык булгандыр, бәлки?!.

Бәхетенә каршы, дөньяга, ир-ат халкына башка һичкайчан елмаеп карый алмам диеп антлар биргән, уйга чумып кайткан Асиянең бу халәте озакка сузылмады. Казан портына кайтып, теплоходтан төшкәч үк рәхәт, җиләс һава килеп бәрелде аның йөзенә. Әйтерсең, бар борчу һәм кичерешләр Идел өстендә җиңелчә чайкалып торган ак теплоходта калды... Алай да оныту дигән сәләт бирелгән әле кешегә!

## 13

Якынлашып килгән көзнең чалымнары һәркайда күзгә ташланып тора инде. Көннәр җылы һәм көләч булуга да карамастан, җәй буе кояш нуры һәм яңгыр тамчылары белән иркәләнгән яфракларга анда-санда саргылт төс иңеп килә. Көтмәгәндә исеп куйган җил якаларны күтәрә төшәргә мәҗбүр итә. Урамда, паркларда бер эшсез килеп сарып йөрүчеләр саны кыскарганнан-кыскара бара. Һәркем каядыр ашыга, якынлашып килгән кышның хәбәрен ишеткән сыман, табигатьнең бөтен җан иясе, кошы-корты дөнья көтәргә хәзерләнә. Вокзал һәм елга порты тирәләрендә инде күзгә пальто кигән, муенына җылы шәл-шарф салган кешеләр очраса да, сәер күренеш түгел.

Җәйге җылы көндә аерылышкан иде ич ана белән кыз. Инде яфраклар кыштырдаша... Алар очраштылар. Әмма теге чактагы ыгы-зыгыларын искә алмаска тырышты һәр икесе. Гомумән, ана кеше үз баласына үч саклый белми ич ул. Кыз да иманга утырып кайтып килә... Шунысы гаҗәп: ишекне бикләп, кызын барыр юлыннан туктатырга ниятләгән ана булсын, үз әнисен төп башына утыртып китеп барган кыз булсын— һәркайсы үзен гаепле саный иде кебек ул чактагы кыланышлары өчен. Үкенүдән файда юк. Үткәннәрне искә алу — әһәмиятсез. Сүз башласаң сүз иярә сүз китәргә мөмкин. Үткән эшкә салават, диюләре хактыр, күрәсең...

Асия икенче курста укый башлады. Кызы өчен куанып йөрүен дәвам иткән ана тагы баштан-аяк мәктәп мәшәкатьләренә кереп чумды... Икенче курс артыннан ук өченчесе җитәр. Дүртенчесе һәм бишенчесе... Кызы дипломга да ия булып куяр. Өстенә ак халат, башына шундый ук ап-ак крахмалланган башлык киеп, палатадан-палатага йөрер, кешеләргә шатлык алып керер аның кызы. Авырулар: «Бу кемнең игелекле кызы икән...»— ди-ди пышылдашып, рәхмәт укып калыр аның артыннан. Нинди генә мәшәкатьләре булмасын, нинди генә борчуларга тарымасын, шул хакта уйладымы — җиңел булып китә иде анага. Кызының матур киләчәге дәрт бирде, дәрман өстәде аңарга.

Башы эшләгән, өлгерлеге, елгырлыгы булган кеше өчен уку нәрсә?!. Зачет һәм имтиханнарын вакытында тапшыра барды Асия да. Укытучыларыннан шелтә ишетмәде, группадашларыннан читләшмәде. Гаиләдә бердәнбер кыз булып үсүенә дә карамастан, мөстәкыйльлеге дә бар иде үзенең. Кешедән ким-хур булырга күнекмәгән, аерылып алга чыгып та башкаларның саруын кайната торган гадәте юк. Ата-анасын да урынлы-урынсызга борчуга салмый, үзенекен итәргә дә оныт мый,— кыскасы, заман баласы, шәһәр кызы.

Шулай да бу гаиләдә бары да ал да гөл булып китте дисәк, дөрес

леккә хилафлык китергән булыр идек. Кыз торган саен иркенрәк, үз дигәнчә яшәргә тырышты. Бу, үзенең үҗәтлегеннән бигрәк, әнисенең берөзлексез өйрәтүләренә каршы җавабы иде булса кирәк аның. Үз-үзен мөстәкыйль шәхес буларак раслауга омтылышы.

Әнисе холкын да онытмагансыздыр шәт.

— Әниең хакында да уйла инде, кызым. Чыгасың да югаласың, чыгасың да югаласың — кичләр буе берьялгызым утырудан ничек туйганымны белсәң...— дип дәште ул аңар күңнәрнең берендә. Булдыра алган кадәр ягымлы итеп, үз итеп дәште. Кызы аңлар, аңлар һәм хәленә керер дигән өмет белән...

— Берни эшләр хәлем юк, әнием,— дип җавап кайтарды кыз, ике уйлап тормый гына.— Сине саклап утыра алмыйм ич инде. Минем дә үз дөньям, үз дусларым...

— Дусларыңны ташла димим, кызым. Әниеңне дә онытып бетермә, дим.

— Онытмыйм... Ә нигә онытырга...— диде кыз, көзге каршында гамьсез генә толым очларына беркетелгән бигудиларын ычкындыру белән мәш килгән җиреннән. Һәм өстәп тә куйды.— Иптәш кызымның туган көне... Соңга калсам, яисә кайтмый калсам, борчылма, ярыймы, әнием. Алар шәһәрнең икенче почмагында ук яшиләр...

Аркасыннан кырмыскалар чабышып узгандай булды ананың. Ишетмәсәң — ишет, дигәннәре шулайрак буладыр, күрәсең... Кызын гозерләргә кереште ана, үзенә мәрхәмәт сорады... Кызы аңлар, аңламый калмас дигән өмет белән, тәмле телләрен кызганмый аңлатырга тырыша. Урамда караңгы төшеп, өйләрдә ут алгач, дүрт стена артында берьялгызы калып буй җиткән кызын көтеп утырган аналар гына аңлар аның хәлен. Күзләре берөзлексез сәгатьтә булыр ананың. Әледән-әле тәрәзәгә килеп капланыр ул. Баскыч төбендә нидер шылт иттеме, ишек катына йөгереп килә: кызы кайтмаганмы?.. Урамда бер-бер машинаның ачы сызгыру авазы чыгарып, кинәт тукталганы ишетелсә: юл аша чыккан чакта кызы белән бер-бер хәл булмаганмы?! Җилкәсенә мамык шәлен салып, өй тирәләрен кат-кат урап керер ана, якындагы транспорт тукталышын берөзлексез күз уңында тотар. Янә өйгә керер, күзләре әле стена сәгатендә, әле тәрәзәдә, әле ишек катында булыр һаман. Сәгать теле келт-келт иткән саен, дөп-дөп йөрәге тибәр, бәгыре үрсәләнер ананың. Бала гына белми... Өйдә берьялгызы калып кичләрен буй җиткән кызын көтеп чыккан әниләр күңеленә ниләр генә килеп китми икән дә ана бәгырен нинди генә шик-шөбһәләр телгәләми икән?!.

Вакыт белән хисаплаша белмәс яшьлек — кызлар һәм егетләр — ул хакта уйламый, әлбәттә. Уйласа да, күп очракта үзенеке була үзәктә. Янә халык сүзләре килә хәтергә: ана күңеле — балада, бала күңеле — далада...

Кызы авызыннан ишеткән сүзләргә ышанасы килми торды ананың, колакларым ялгышмыймы (?), диде булса кирәк. «Туган көн... Кунып ук кайтырмын...»— дигән сүзләре чайкалып торды колак төбендә. Әнә ничек, моңарчы түзгәннәре өчен рәхмәт ишетәсе урында, тагы ниләр вәгъдә итә буй җиткән кызы. Киткән-киткән, берочтан кунып ук кайтырга җыена. Үз кызының өйдә түгел, башка бер җирдә төн куна калу ихтималын моңарчы уена да кертеп караганы юк иде бит әле аның. Өйдә кунган чакларында да төннәрен уянып кат-кат кызын барлап уза: юрганы ачылмаганмы, сулышы бармы?

— Юк,— диде ул кискен итеп.— Җибәрмим! Ул каян чыккан сүз ул?!.

Кыз, әйтерсең, берни ишетмәде. Ипле генә янә бер кат чәчләрен тарады, иңбашына бөдрәләрен таратып салды. Дәшми-нитми генә гардеробы янына килде, аннан соңгы мода белән тегелгән кыска итәкле кичке күлмәген алып киде. Әнисе буләге! Кыска итәк килешә аның үзенә. Төз һәм таза балтырлары ачылып, яктырып китә кысканы кигәч. Егет-

жиләнне чыгырдан чыгару өчен күп кирәкмени?! Бармак очына манып муен һәм изү тирәләренә французислемае тидереп алды. Бусы әтисе бүләге! Әнисе карашы читкә тайпылган арада тәртеп торган тыгыз кукрәкләренә дә өлеш чыгарып алды ислемайдан. Алтын алкаларын такты, кашлы йөзекләрен...

— Әзерләнмә, кызым... Төн кунарга дисәң, җибәрмим,— дип кабатлады ана. Бая әйткән сүзләренә җавап ишетмәгән иде ич әлегәчә.

Кул сәгатенә, аннан стена сәгатенә бер-бер артлы күз төшереп алды Асия. Соңга калырга ярамый иде, күрәсең... Кашлар сызылган, керфекләр торгызылган, күз кабакларына зәңгәрсу шәүлә сузылып яткан. Тел очы белән иреннәрен сыйпап алды, авыз читеннән өреп, маңгаена төшеп торган бөдрәләрен җилгәрде. Көзге каршысына басып, соңгы мәртәбә бөтерелеп алды да иңсәсенә нәни сумкасын асты.

— Йә, әнием, мин ничек, матурмы бүген?— дип елмайды шунда әнисенә. Әйтерсең араларында моңарчы берниндн сүз булмаган.

Ана өнсез калды. Әмма телсез түгел:

— Синең ямьсез булганың юк, кызым.

— Ә бүген, бүген ничек?..

— Бүген дә матур,— дип килешми булдыра алмады ана.— Тик кара аны, кызым, соңга каласы булма. Тукталышка чыгып көтеп торырмын, унберләрдән калма!..

— Ярар, әнием, ярар,— диде кыз, әнисенең сүзләренә колак та салмыйча. Ишек катына җиткәч, янә бер кат көзге каршыннан урап килде.— Өйгә кайтмый калсам, башыңны ташка орма, килештек, әнием!

Киңәшләрен биреп, аркасыннан сөеп озатып калды ана.

...Иптәш кыз дип, туган көн дип, әйтелә генә инде ул. Моннан берничә көн элек, институттан кайтып килгәндә, бер егет туктатып сүз кушкан иде Асиягә. Урамда очраган бер кызга бәйләнеп, танышлык эзләп йөрүчеләрне башка чакта җене сөймәсә дә, эч пошканнан әңгәмә дә корып торганнар иде бераз.

Теле телгә йокмый егетнең, сүз эзләп кесәгә керә торганнардан түгел. Күзләре елык-елык килә. Өстәвенә бер дигән итеп киенгән, янәшә басып торуы рәхәт үзе белән. Асия дә, һәммә хатын-кызлар кебек, пөхтә, ыспай егетләргә битараф түгел иде. Ирләрнең буе, тазалыгы, тышкы кыяфәте һәм костюмы нинди булса — җаны, кешелеклеге дә шуңарга тиң, дип фикер йөртүчеләрнең берсе иде ул. Әлеге логикага буйсынып фикер йөрткәндә, тормыш өчен яраклашмаган начар һәм дорфа ирләрнең һәммәсе дә, һичшиксез, үтүкләнмәгән чалбар, чистартылмаган аяк киеме, гомумән, төрле сәләмәләр киенеп йөрергә тиеш булып чыга иде...

Шул ыспай егет белән озара танышып, юк сүзне бар итеп тегенемоны сөйләшеп алгач та кызыксыну туган иде Асиядә: бу егет кем булыр икән? Тегесе дә сизгер булып чыкты, әлеге кызыксынуны шундук тоеп алды һәм, ипле генә, кызның кулларын тарткалап карарга керешге... Куллар тырпаймады, мамык сыман йомшак тоелды ахры кыз, шуңа егет турыдан ярды:

— Ресторанга кайчан барабыз соң?

Сорау, беренче карашка, артык туры һәм ашыгычлык белән бирелгән тоелырга мөмкин. Әмма егет тәҗрибәсез түгел, ул белә — заман кызлары урап-әйләнеп сөйләшкәнне яратмый, турысын ярырга кирәк алар белән. Шул бер сорауга җавапта бөтен перспектива ачыла да куя: йә тегеләй, йә болай. Ә вакыт янга кала. Тәмле сүзләр, вәгъдәләр җилгә очып әрәм булмый.

Егетнең соравындагы ашыгычлык һәм беркадәр дорфалыкны кыз аермачык тойды. Әмма аның турылыгы, конкретлыгы күзгә бәрелеп тора. Соң чиктә, иртәме-соңмы, барыбер бирергә тиеш бит ул әлеге сорауткъдимен.

— Белмим шул, барырбыз микәнни?..— дип чаяланды Асия.

— Бик әйбәт дус егетем дә бар.

— Шулай дисәң генә инде... Үзең бер дә әллә кем түгел тагы,— дип рәхәтләнеп көлеп алды кыз. Үз итеп көлде.

— Без үзебез дә төшеп калганнардан түгел. Иптәш кызың бардыр ич?

— Шуннан?

— Үзең кебек үк чибәрме соң?

— Артыгы белән. Мин нәрсә аның каршысында?..

— Килештек,— дип кулын сузды егет. Сыер сатуны хәл итеп, базар почмагында кул бирешүчеләр диярсең.

— Карап карарбыз,— диде кыз, ирен читләрендәге елмаюны яшерергә ниятләгән сыман түбән карап. Бу аның оялчанлыгы яисә тартынуы да түгел, үзенә күрә гадәткә кергән бер көязлеге иде. Әлеге көязлек беренче очрашу, танышу вакытларында бер серлелек өсти төшә хатынкызга.

— Кайчан? Кайда?

— Чакыручы мин түгел ич...

— Димәк, җомга көн,— дип эләктереп алды егет.— Кичке биштә. «Наратлык» рестораны каршысында.

Карарбыз, дигәнне аңлатып, озын керфекләрен кагып алды кыз. Шунда ул китеп барырга да җыенган иде инде, егет сак кына аның кулларына кагылып өлгерде.

— Аннан, «мотор»га утырып, безнең дачаны карап килербез,— диде ул, күзен оятсыз рәвештә кыса төшеп.

Монысы инде артык иде, чамадан тыш. Бер-бер дорфа сүз әйтеп китү ягын гына кайгыртасы калган иде Асиягә болай булгач. Егет кызның уен һәм үз әрсезлеген чамалап өлгерде:

— Вакыт ягын кайгыртырга кирәк булса дип әйтүем,— дигән сүзләре белән сыйпап, шомартып куйды барын да.

Шул сүзләрне, шул мизгелдәге карашы белән яңа житди була белгән егеткә охшап куйды ул.

...Тора-бара «туган көннәр» ишәя төште. Кичке шәһәрнең яңадан-яңа серләре ачыла барды Асия өчен. Иптәш кызлар, таныш егетләрнең исәбе бермә-бер артты. Нинди генә дуслар белән кая гына барып чыкмасыннар, ир-ат һәм егетләрнең игътибар үзәгендә була торган иде ул. Ә моны тою бетмәс-төкәнмәс ләззәт һәм канәгатьләнү китерә. Атналар, айлар уза торды. Вакыт һәм тормыш мәшәкатьләре гүя юл читендә торып калган агачлар гына. Ә ул кызу тизлек белән куалаган машинада киләчәккә узып бара... Егетләр аңар бары ярату турында, аны уйлап ничек газапланулары хакында сөйли. Дөнья тоташ ягымлы сүз һәм ярату, сөюләрдән генә торадыр сыман тоела башлый иде аңар вакыт-вакыт. Бүген кайсы егет янына барыйм икән дип икеләнгән чаклары да булгандыр. Чөнки көнгә икешәр-өчәр егеткә очрашу билгеләгән вакытлары бар иде. Ул түгел, үзләре әрсезләнә, үзләре омтыла ич. Асиягә барыбер, хәтта кызык итеп шобага салган көннәре дә булмады түгел.

Тоташ бәйрәм, тоташ танцы һәм ресторан — үз-үзеңне белешерлек түгел, баш әйләнә. Әйләнмәслекме соң: ул, кая гына барып чыкмасын, игътибар үзәгендә. Ир-атлар һәммәсе кайгыртучан, юмарт һәм итагатьле. Кич җиттеме, үзен шул дәрәҗәдә олылаган, якын иткән тавыш-музыкалы, тапкыр һәм җор сүз, комплиментларга тулып торган компанияләргә атлыгып торды ул. Үзе төсле үк бәхетле, борчу-мәшәкатьләрсез генә яшәргә күнеккән яшьтәшләре янында булды.

Ул бу тормышка шундый күнекте, кайдадыр башка дөнья, җир мәшәкатьләре белән яшәүчеләр бардыр дип уена да китереп карамады хәтта. Кичләр бер-берсенә ике тамчы су кебек охшаш. Егет-җилән һәм ир-атлар да бер үк. Кыз-кыркыннарны да берсен алып, икенчесен куярлык түгел. Сөйләнгән сүз, анекдотлар, шаяру һәм назлар да, дәреслеккә язылган сыман, төп-төгәл кабатлана... Барысы да телгә оста. Очрашыр-

га, танышырга өлгермисең, кунакка чакыралар. Кулларында чәчәк, дипломатта шампан, кесәләрендә шоколад булыр. Аулак өйгә музыка тыңларга чакыралар, тау-тау өеп вәгъдә бирәләр. Сөю, яратулары хакында сөйлиләр... Тәкъдимнәрен кабул итмичә, аз гына карыштыңмы, дорфа сүзләр әйтеп рәнҗетергә дә күп сорамыйлар. Биш минут кына элек «яратам» дигән егет, аяк астыңа төкереп, сүгенә-сүгенә китеп барырга да күп сорамый. Чөнки аны күрше өстәлдә, икенче ресторан ишеге төбендә шундый ук кызлар көтә — берни югалтмый ич ул... «Ярату» һәм «мәхәббәт» сүзләре көненә берничә мәртәбә яңартыла, адресын үзгәртә... Атналар, айлар, еллар дәвамына шулай. Җир әйләнә торгандырмы, ул хакта уйлау юк, ә менә алар хәрәкәттә. Божра эчендәге тиен сыман тик тормыйлар бер дә, берөзлексез йөгерәләр, ашыгалар, әйләнәләр...

Укуда гаме калмады Асиянең. Нәрсә ул уку?! Дөнья болай да әнә ничек матур — тоташ бәйрәм, тантана ич! Институтка барса барды, бармаса — юк. Деканатка чакырып, шелтә бирүләренә дә исе китмәде. Имтиханнарына да кереп тормады. Үзенең институттан чыгарылуы турында приказ эленүе хакында ишеткәч тә, аның дөресме-түгелме икәнлеген белешеп йөрмәде. Барыбер үзеннән врач чыкмаячагын аермачык белә иде инде ул. Кеше эгъзаларына кагылу түгел, бака ботын ярырга кушкачтын да практик дәрестән күзен томалап чыгып йөгерде ич.

Һәммә кешегә дә врач булырга димәгәндер. Ул аралашып яшәгән даирәдә врач булу турында хыялланучы юк иде. Завод-фабрикалардан да түгел аның дус-ишләре, тегеннән йолкып, моннан умырып көн күрә, типтереп яши торган урыннар да тулып тора икән шәһәр җирендә. Беркайда эшләми генә дә менә дигән итеп яшәүчеләр аз түгел. Ул да әтиәнисенә бер кыз ич, ачтан үлмәс әле.

Шулай итеп, укуын ташлады Асия. Әмма бу хакта берәүгә дә игълан итәргә ашыкмады, дөнья рәхәтенә чумып, үз җаена яшәвен дәвам итте. Әмма эче пошкан, эшсезлектән арыган чаклары да булмады түгел. Әнисе — мәктәптә, әтисе елга тирәсендә чуалуын дәвам итә; кыш булса да, үзенә күрә эше табыла аның да. Ә ул өйдә, гел-гел урам һәм рестораннарда йөрү дә туйдыра, йончыта башлый икән ул бер.

Эшләгән эше юк, анысы бер хәл. Дөньясын онытып кемне дә булса ярата да алганы юк, шунысы пошыра эчне. Күпме егет узды кулыннан. Әле булса көн дә килеп аптыратучылары күпме... Әмма кайсы да булса, берсен җан атып яратырга иде шуларның. Юк! Ярата алмый, үз итә алмый ул аларның берсен дә. Карап торышка, менә дигән егетләр, әтиәниләре дә зур-зур урыннарда эшли үзләренең, машиналары, фатирлары бар. Тик алар һәммәсе, үзләре турында уйлый башладыңмы, кызлар бәдрәфеннән бөркелеп чыккан тәмәке төтене сыман, тоныкланып калалар, таралалар, күз алдыннан юк булалар. Ник берсе уелып калсын иде хәтерендә... Бергә кочаклашып биегән чакларында ярыйсы гына егетләр ич үзләре. Аерылырга өлгермисең, онытылалар. Юк, ярата алмый ул аларны. Һәм аларны ярату мөмкин дә түгел. Телләре бер нәрсә сөйләсә, күңелләре һәм күзләре бүтәндә. Ничек ышанып яратырга мөмкин шундыйларны?!.

Икенче карасаң, үзләренең дә артык исләре китми кебек. Күпме йөреп, ник берсенең аңар чынлап торып тәкъдим ясаганы булса икән... Болай, үзләренә кирәк булса яисә сүз иярә сүз чыкса гына инде. Соңыннан оныталар. Искә төшереп сорасаң, көлкегә каласың: син кайдан килдең, кара урман уртасыннанмы әллә, диеп көләргә дә күп сорамаслар.

Тукта, ни өчен соң, кайчан гына үтмә, никахлашу сарае каршысында чират була? Язылышырга, бергә дөнья көтәргә дип чират тора ич алар. Асиянең йөрәге чәнчеп-чәнчеп ала шул чиратны күргән чакларында. Димәк, кемнәрдер өйләнә, кемнәрдер кияүгә чыга. Туйлар булып кына тора. Еракка китеп карыйсы юк: үзеннән бер артык урыннары булмаган таныш-белеш кызлары әллә кай арада кияүле булып беттеләр. Чыгалар да, аерылалар да, тагын табышалар, янә аерылышалар — өз-

лексез хәрәкәт дәвам итә. Кайберләренең бер ел эчендә икешәр туе булды түгелме соң инде?!. Шул туйларда утырганда, башкаларга ияреп, «ачы-ачы» диеп кул чәбәкләп кычкырганда, әллә аның бәгырь чите сыкрап куймыйдыр дисезме?..

Кичләрнең берсендә, үзенә инде байтактан мәхәббәт һәм ярату хакында купшы сүзләр сөйләп йөргән бер егеткә ачыктан-ачык сорау бирде кыз:

— Ә нигә дип син миңа тәкъдим ясамыйсың?!.

— Ясасам да чыкмыйсың ич.

— Иң әлек ясап кара. Ничек җавап бирү — минем эш.

Шаярып-көлеп, дөнья белән кулны билгә таянып сөйләшеп йөргән егет уйга калып торды шунда.

— Юк,— диде ул, кызның күзләренә бертын текәлеп торганнан соң.— Ул хакта уйлаган юк әле.

— Ә кайчан уйларсың? Син уйлаганда — мин булмасам?..

Егет тагы да җитдиләнә төште. Әйтерсең, үзен якасыннан алып өйләндерергә, муенына көчләп камыт кидерергә җыенучы бар.

— Юк, беркайчан да! — диде, ниһаять, ике уйларга урын калдырмыйча.

Җавапка исе китмәде Асиянең. Әгәр «миңа чык» дип торса, үзе дә шәһәр картасында ресторан һәм дискотекалардан башка урын белмәгән бу егеткә ризалык бирергә ашыкмас иде.

Килеш-килбәт, аның киемнәрендә генәмени соң хикмәт? Машинасына да, сурәтле магнитофонына, аерым фатирына да алданмас иде барыбер. Әтисен эштән алсалар, беркем түгел ич ул. Иртәме-соңмы, барыбер буш куык булып калачак...

Сөйләшү бер башланган икән инде, Асия аны ахыргача дәвам итәргә кирәк тапты:

— Шулай да әйт әле,— диде ул, кызыксынуыннан туктамыйча.— Синең фикереңчә, мин шулай ук начар кыз булып чыгаммы?

— Син нәрсә, Асенька, юк! Юк, әлбәттә... Алай димәдем ич.

— Ә нигә өйләнергә теләмисең?

— Ну, Асенька, бу бит бик деликатный вопрос... Бәлки, ул хакта түгел, башка нәрсәләр турында сөйләшергәдер безгә...

— Шул хакта,— дип бүлдерде аны кыз.— Бары шул хакта гына. Бу минем өчен әһәмиятле.

Күз карашы белән көйдереп алды ул егетне, үз итеп карады аңарга. Андый карашка ир-ат буйсынмый кала алмый:

— Йә,— диде егет.— Теләсә нинди соравыгызга да җавап бирергә әзермен, Асия туташ.

— Кабатлыйм соравымны, тыңлагыз: ни өчен әле син миңа тәкъдим ясау мөмкин түгел дип саныйсың?

Кыз егетнең күзләренә текәлде, җавап көтте. Егет тә аңлап алды — аның җавабы ихлас булырга тиешле. Һәрчак уйнап-көлеп кенә йөргән Асияне танырлык түгел иде чөнки. Авызын ача төшеп, сулыш алырга да кыймыйча тынып калган, җавап көтә. Кара инде, егет-җилән теленә «оҗмах кошы» дигән кушаматы белән кергән бу чибәр кыз шулай ук кеше икән ич. Аның да үзенә күрә җаны, өзгәләнергә сәләтле бәгыре бар икән. Егетләрнең үзенә карата мөнәсәбәтен беләсе килү хатын-кыз өчен табигыйдыр, күрәсең. Хәер, кызларда гына түгел, кайчак ир-ат халкының үзендә дә була андый кызыксынулар. Башка җенеснең үзенә карата булган мөнәсәбәтен ачыклау бирү өчен дә артык түгел. Чөнки ул мөнәсәбәт матур сүз, комплиментлар артында кала һәрчак, чаршау артындагы шәүлә сыман...

— Юк, Асенька,— диде егет, бераз икеләнеп торганнан соң. Була шундый чаклар, гомерен ялган сөйләп, алдашып уздырган адәми затлар да, ычкынып китеп, дөресен әйтеп куялар.— Сиңа тәкъдим ясарга мөмкин дип саныйм мин үзем. Мөмкин... Ни өчен дисәң?.. Шуның өчен,

Асенька... Иң элек, син — чибәр. Фигура дисәң, анысы да бар... Акылсыз дип тә әйтә алмыйм мин сине... Була, Асенька, була синең белән...

— Ә тәкъдим хакында?..— дип сорауны хәтергә төшерергә, конкретлаштырырга кирәк тапты кыз.

— Тәкъдимме? — дип, сагая төшеп дәвам итте егет. Дөресен әйтү җиңел түгел, ә ялганларга — уңайсыз.— Беренчедән, минем әлегә берәүгә дә тәкъдим ясаганым юк. Ясарга да җыенмыйм!.. Икенчедән, Асенька, ни бит... мин сиңа барыбер өйләнмәс идем... Чибәр хатын-кызга өйләнү — ул, минемчә, муенга таш бәйләп тишек көймәдә Идел уртасына кереп китү кебегрәк... Һәм, гомумән, Асенька, аннан бит син үзең дә...

— Йә, йә, әйтеп бетер,— дип, егетнең теленнән тартырдай булып, аның соңгы сүзләрен көтте кыз. Хөкем карарын көткәндәй көтте...

— Әйттем ич, син — чибәр...

— Чибәрләр хыянәтчел була дип әйтергә телисеңме?

— Хыянәт дип, Асенька... Анысын белеп булмый. Чибәрләрнең дә төрлесе була... Бер иренә карап торганнары да бардыр. Ә син — башка! Синең күзләрең йөгерек... Һәм, гомумән, син, ну... ничек әйтергә? Болай акыллы гына син үзең... Ну, үпкәләмә, ярыймы, Асенька, күзләрең берөзлексез уйнаклап, чоландагы мәченеке сыман эзләнеп тора синең... Берәүнеке, мисал өчен, әйтик, минеке генә булырга риза түгел синең караш. Малай-шалай булсам, бәлки мин моны аңламас һәм аңлата да алмаган булыр идем. Ну, азмы-күпме тәҗрибә бар ич минем үземдә дә...

Кыз инде чын-чынлап тынгысызлана, кәефсезләнә башлаган иде. Чөнки егет ихластан, онытылып сөйли. Әлеге төр егет-җиләнгә хас булмаганча җитди һәм эчкерсез иде ул...

— Аннары, Асенька, мин үземә сүз бирдем. Кәләшне мин рестораннан эзләмәячәкмен,— дип дәвам итте ул, эчкерсезлеген югалтмаска омтылып.— Юк, әйтмим, ресторанда начар кызлар гына була торгандыр дип. Яхшылары да очрый торгандыр... Шулай да ресторанга сукмак салган хатын-кызга өйләнмәс идем — принцип!..

— Рәхмәт,— әйтте Асия.— Дөресен сөйләгәнең өчен, рәхмәт!

— Син борчылма, Асенька, кияүсез калмассың... Киресенчә, өйдә оек бәйләп утырган кызлар кала кияүсез. Ә синең кебек дөнья рәтен белгән кызлар җаен бер чыгара аның барыбер. Йә бер-бер мәми авызны каптырып куялар, йә хатын аерган бер-бер зур түрәгә үк чыгып куялар... Борчылма, Асенька, борчылма, бер түгел, әллә ничә тапкыр чыгарсың, боерган булса...

Көлемсерәп куйды егет. Кыз исә аның соңгы сүзләрендәге иронияне аңламады. Рәхмәтен әйтте. Әйтүен әйтте, әмма күңелен нәфрәт биләп алган иде инде. Һәр ихласлыкның чиге була, сөйләшү өзелеп калды. Элеккечә үк янәшә утыруларын дәвам иттерсәләр дә, күзләр тоныкланды, бармак очларыннан кайнар кан качты. Күңелләр ерагайды. Ниндидер очраклы бер җилкуар егет, шул рәвешле, чын йөзеңне ачып салсын инде. Шундый сөйләшү-аңлашулардан соң ничек итеп тагы кочаклашып биергә, елмаеп-көлешеп утырырга мөмкин. Сүзләре сүзгә ябышмады, карашлары очрашмады башка... Менә сиңа мә, ихласлык!

Кызның ашыгыч рәвештә өйгә кайтасы булып чыкты. Егет тә ниндидер җитди эшен чак онытып җибәрмәгән... Ресторан каршысында торган өр-яңа машинасына утырып, җилдереп кенә өенәчә озатып куйды ул Асияне. «Хәзергә» — диешеп, бер-берсенә соңгы мәртәбә йөгерек елмаюлар бүләк итешеп аерылыштылар. Башка һичкайчан да күрешмәскә, мәңгегә.

Үз бүлмәсенә кереп бикләнде һәм, караватка йөзтүбән капланып, тынсыз калды Асия. Шул рәвешле, шаулап-гөрләп торган дөнья кинәт тынып калды... Елыйсы килде кызның, күңеле мөлдерәп тулышкан иде. Әмма күзләреннән яшь чыкмады. Ни эшләргә, күңелен, җанын кемгә бушатырга белми борсаланып ятты төнозын. Кемгә дә булса сөйләргә,

кеменең дә булса күкрәгенә башын куеп еларга да еларга, шул билгесез кешенең юату һәм тынычландыруларына да карамастан, үрсәләнеп, күз яшьләрен коярга иде аңарга хәзер... Күзләренә яшь килмәде. Әйтерсең лә, кипкән иде аның күз яшьләре. Гомумән, соңгы елларда аның елаганы да булмаган икән бит. Көлгән һәм көлгән, сөю һәм наз дәрьясында йөзгән... Кайчан һәм кайда елады икән ул соңгы мәртәбә?.. Уч төбенә чигәсен кысып хәтерләргә тырышып та, хәтерли алмады. Дөнья — тоташ бәйрәм, тоташ сөю, тантана, тост һәм комплиментлардан гына тора дип яшәгән түгелме ул?.. Ә кичереш һәм борчу, яну-көюләр гүя булмаган җир йөзендә...

Булсын иде шундый кешең: сине сүзсез дә аңласын иде ул. Көнелдә булганнарның һәммәсен дә төкми-чәчми сөйләргә иде үзенә. Тамчысын калдырмый уртаклашырга иде... Ләкин кемгә?! Кемне үзенә сердәш янсә киңәшче итсен Асия?! Кеме бар аның?!

Тукта, Асия... Дус кызларың, таныш-белеш белән ярты шәһәр тулган... Һәркайсы белән чуп-чуп үбешеп күрешә, серләшеп туймый; аерылышканда, кабат очрашырга вәгъдәләр бирешә торган идең түгелме соң?.. Арадан берсе янына бар, йә булмаса үзен чакыр — һәм сөйлә, уртаклаш, Асия!

Таныш-белеш кызларын күз алдыннан уздырды ул. Кайсы алдында ачылып, кайсысына көнелендәге серен, борчу-шөбһәләрен сөйли, уртаклаша ала соң ул? Кайсысының муенына сарылып елый ала? Арадан хет берсе аның моң-зарларын түземлек белән тыңлый алырмы?.. Күпме генә көнеленнән барламасын, таба алмады. Бәлки монысы, бәлки тегесе ди-ди борсаланды, әмма нәтиҗәсез. Алар тыңларга риза булганда да, үзе ачылып сөйләшә алмас иде ул бу танышлары белән. Шундук көләчәкләр, соңыннан телдән-телгә тапшыра-тапшыра хәбәр җибәрәчәкләр. «Борын чөеп, бик әллә кем булып йөри идең... Әнә, ничек икән»,— дип кәефләнәчәкләр генә. Кеше кичерешләрен ихлас уртаклашыр, бүлешер дуслары юк икән ич аның.

Чү, Асия. Син күбрәк егет-җилән тирәсендә чуалдың. Бәлки алар арасында табылыр үзеңне аңларга сәләтле бер-бер ир-ат?!. Күпме кавалерларың бар! Үзеңә очрашкан саен чәчәк бүләк иткән, чәчләреңнән сөеп иркәләгән, дөньяларын онытып артыңнан йөргән шул егетләр аңлар!.. Хәтерләргә тырыш, Асия, берсе булмаса, икенчесе аңлар хәлеңне?!. Тоташ бәгырьсезләр булмас.

Кавалерлар күп, әмма чын ир булганнары бик аз. Егетләрен бер-бер артлы күз алдыннан үткәрергә кереште ул. Кайсына тукталырга гына белмәде. Карап торышка чибәр дә, тәрбияле дә кебек үзләре, ата-аналары да дәрәҗәле генә кешеләр. Әмма, менә хикмәт, арадан ник берсе «мин монда» дип үзенә тартып торсын икән?!. Бүген монда булса, иртәгесен башка кызларга гыйшык турында сөйли ич алар. Мәзәк итеп үзен сөйләсәләр... Юк, һичбер вакытта да, ир-ат халкына сер сыяр дип, сер сөйләячәк түгел ул! Башка сыймаслык хәл ич бу. Кеше көлкесенә калыргамы?.. Беркайчан да!

Берәүгә дә ышанмый ул. Һәм яратмый да. Үз серләре бары үзенеке генә булып калыр... Мендәргә йөзтүбән капланган көйгә кысып йомарланган йодрыклары белән, үз-үзен белешмичә, урын-җирен төяргә керешкән иде кыз. Дөньяда ул япа-ялгыз...

Баш очында гына җылы, ягымлы аваз ишетелде берзаман. Әнисе!.. Сак кына, иплә генә итеп дәште ул. Әйтерсең кызы алдында гаебе бар иде ананың:

— Чәй эчәргә чыгарсыңмы икән, кызым?.. Син яраткан балан бәлеше пешергән идем...

Бишек җыры сыман ягымлы тавыш сездә генә, әниләр! Әни кеше һәрчак кирәк. Үсә төшкәч, зур дөньяга юл ярганда, сабый чактагыдан да болайрак кирәк була икән ул ана сүзе, ана киңәше, әниләрнең ягымлы бармак очы һәм күз карашы... Яхшы хатын-кызлар була, яманнары да

житәрлек, диләр. Әмма әниләрнең яхшы-яманы юк. Йә бар, йә юк әниләр. Әни дигән изге рухлы зат һәркем өчен берәү генә!

— Әни-и-ием...— дип, ирексездән сузып куйды Асия һәм, үз-үзен белешмичә, чишелеп елап җибәрде...

Әниләр — янында, газиз әнкәң баш очында торып, чәчләреңне сыйпаганда елаудан да бәхетле мизгел, рәхәт күз яшьләре юктыр ул, гомумән.

## 14

Әледән-әле учакка берән-сәрән утын кисәкләре салгалап утырды Арслан. Ә Лев Белялович белән Асия ишеткән-белгән мәзәк хәлләр хакында аңгәмә корып күңел таптылар. Күбрәк Лев Белялович сөйләде. Һәм чираттагы һәр мәзәген сөйләп бетермәс борын ук, дөньясын онытып, иң элек үзе көләргә керешә иде. Көлү килешә иде аңарга. Кызыкмы, түгелме, ирексездән, аңарга ияреп елмаеп куясың.

Инде шактый ук үзләшә төшүенә дә карамастан, әле барыбер ниндидер тартыну, кыенсынудан арына алмаган иде Асия. Көлемсерәп башкаларны тыңлаганда да, иплә генә үзе сөйләгәндә дә ул онытылып китә алмады, үзен тыйнаклык кысасында тотты. Һәм моңарга аның күңеленә инде бая ук, машинадан килеп төшүгә үк кереп оялаган, оялаган һәм бер генә минутка да чыкмый, онытылмый йөдәткән сорау сәбәпче иде булса кирәк. «Түгәрәк»нең чираттагы мәзәк хәлне хәтеренә төшерә алмыйчарак торган чагын туры китерде дә сорап куйды ул көтмәгәндә:

— Матур яшисез, Лев Белялович? Нинди урын соң бу?.. Бездән тыш тагын кемнәр дә булса бармы монда?

Инде үзләшеп килгән, уен-көлкегә тиз арада кушылып киткән Асия авызыннан шундый сорау чыгар дип берәү дә уйламаган иде, әлбәттә. Ир-атлар, сүз берләшкән сыман, берьюлы күтәрелеп караш ташладылар аңар. Асиянең соравы урынсыз гына түгел, ниндидер гайре табигый киеренкелек белән дә бирелгән иде. Кисәү агачы белән чит-читкә таралышкан күмер кисәкләрен учакның уртасына җыеп-өеп утырган Арслан: «Таный алмыйм сине, бу нинди сорау инде тагы?»— дип әйтәдер сыман тоелды.

— Йә инде, Асенька! Һаман да син «Лев Белялович та Лев Белялович»...— дип, сабый сыман үпкәләгән кыяфәт ясап өлгерде «Түгәрәк». Һәм, артыннан куа килүче бүредән эз бутаган куян кебек, урап-әйләнеп аңлатырга, фикер йөртергә кереште.— Йә, Асенька, килешкән идек түгелме: миңа да, үз итеп, «арыслан» дип дәшергә килешкән идек?!. Аңлыйм мин сине, Асенька, бу гайрәтле исем белән бары берәүгә — Арсланга, Арслан Сәхиповичка дәшәргә теләвеңне аңлыйм... Телеңнән тарта алмыйм билгеле, Асенька, әмма кабатлап әйтәм. Юк, үтенеп сорыйм: без монда һәммәбез дә арысланнар. Лев дип, яисә Арслан дип, үз исемем белән дәш син миңа. Ярыймы, Асенька?!.

— Килештек, Лев Белялович...

Асиянең, ияләнгән гадәт буенча, авызыннан ялгыш чыккан мөрәҗәгате кызык булып тоелдымы, янә дөньясын онытып көлеп җибәрде «Түгәрәк»:

— Ай-һай, Асенька, юмор хисе ташып тора үзегездә. Яратам да соң шаяра белгән, шаяруны аңлый алган хатыннарны... Хуш, монысы кызык килеп чыкты, Асенька. Йә, ниндидер сорау да биргән идең түгелме әле, нәрсә дигән идең?..— дип, Асиянең соравын хәтерләргә иткәндәй, уйга калып торды бертын. Сорауны онытмаган иде, әлбәттә, сорауны онытмаганлыгы күзенә чыккан. Ничегрәк итеп җайларга һәм ни рәвешле туры җаваптан тайчынырга дип баш вата иде ул. Ә җавап бирәсең килмәгән сораудан шома балык сыман шуып чыгуның юлы бер генә — беркатлы булып кылану, шаяру...

— Әйе, соравыма җавап көтәм, Лев Беляловnatch.

Янә кычкырып көлеп алды «Түгәрәк», шаяруга күчү өчен кирәкле күперне Асия үзе үк китереп чыгарды ич: тагы «Белялович».

— «Бу нинди шомлы урын бу?» дисез инде, ә, Асенька? — Ул сөйләшүдән читләшкән атлы булып утыручы Арсланга мөрәҗәгать итеп алды.— Син нәрсә анда, Сәхипович, кунакны чакыргансың, ә кайда икәнлекне аңлатып да тормагансың. Шулай килешәме инде?!. Бу — мәхәббәт ярымутравы, Асенька.

— Ә чынлыкта?..

Асиянең болай төпченүе арысланнарның берсенә дә ошамады. Берәве учак тирәсендә кайнашуын дәвам итте. «Түгәрәк»нең исә нияте уен-көлке белән ерып чыгу иде.

— Нәрсә, Асенька, әллә сез җаваптан канәгать түгелме?.. Болай булгач инде, мин түгел, Арслан Сәхипович гаепле. Ха-ха...— Ул Арсланга мөрәҗәгать итеп алган булды янә.— Ишеттеңме, Арслан, мәхәббәт ярымутравы дигәнгә ышанмый Асенька... Тәнкыйть синең адреска, Арслан, ха-ха...

Үзен шулай баласытып сөйләшү, җитди сорауны уенга борулары ошамады Асиягә. Төпченүен дәвам итте ул:

— Капкасына «мәхәббәт утравы» дип түгел, «Балалар өчен профилакторий» дигән язу эленгән...

— Без балалар түгелмени?.. Балалардан безнең кайсы җиребез ким? Аннан, Асенька, безгә бала чакларда мондый оҗмах бакчалары эләкмәде. Сезгә дә шулайдыр дип уйлыйм... Әҗерен кайтарабыз, уйныйбыз-көләбез... Шулай түгелмени, ә, Асенька?.. Ха-ха-ха...— Бер читтәге креслога түнеп сызгыртып йоклавын дәвам иткән кенәрие Гуля-Гөлсинәгә ишарәләп куйды ул, кулай мисал табуына куанып.— Күрәсең ич, уйнап утырган җирдән йокыга да талабыз. Сабыйлардан кай җиребез ким?!.

— Капканың бирге ягындагы таган һәм гөмбәчекләр дә аның өченме?..

— Теләсәң, Асенька, син дә чыгып уйнап керә аласың.

— Таганда атыну сезгә дә килешә торгандыр, шулаймы, Лев Беляловичі!..

Бит уртасындагы симез мускуллары тартышып, тыпырчынып куйды «Түгәрәк»нең. Йөзенә кызыллык йөгерде. «Чын-чынлап кызыксынырга маташуы түгелме соң бу кенәринең?.. Кемне ияртеп килгән бу Арслан?.. Һәм, гомумән, җыен юк-бар сораулар белән аның газиз башын тинтерәтергә кем соң әле ул?!. Чираттагы бер кенәри генә югыйсә, нәрсә кирәк аңар, ни җитми?!.» Җавапсыз да калып булмый:

— Бу — профилакторий, Асенька. Әмма ул әлегә эшләми. Төзелеш мәшәкатьләре бетеп җитмәгән... Шундый җаваптан канәгатьме сез, ә Асенька?..

— Монысы чынга охшаш. Нишлисең, ризалашмыйча да ярамас, Лев Белялович.

Асиягә нигә кирәге чыкты соң әле боларның диярсез?!. Әлбәттә, һәр хатын-кызга хас булган кызыксыну бар иде аңарда да. Әмма бу очракта, кызыксынудан бигрәк, үҗәтлелек әрсезләндерде аны. Һәммәсе өчен зур авторитет булган, үзенең башкалардан өстенлеген һәрдаим тоеп, сиздереп торган, шул өстенлегеннән ләззәт алган Лев Беляловичны, җай чыгудан файдаланып, бераз тинтерәтеп алыйм дип бәйләнүе иде бу аның... Асияне ул үзеннән түбән саный, шуңа соравына да аннан-моннан гына җавап биреп, шаяргалап котылмакчы булды...

Асия әле рәхәтләнеп дәвам итәргә әзер иде үзенең тинтерәтүләрен. Арсланның карашы белән очраклы рәвештә аңлашу гына тукталырга мәҗбүр итте: «Ни эшлисең?!. Сиңа ни җитмәгән?!.» — дип шелтәли иде ул аны.

— Алай бик кызыксынучан икәнсең, Асенька, тагы да төгәлрәк җа-

вап бирергә мөмкин,— дип, «Түгәрәк» эләктереп алды янә.— Бу профилакторийны Совет профсоюзлары төзеде. Ул — төзү оешмаларында эшләүчеләрнең балалары өчен дип күздә тотылган.

— Сезнең әтиегез төзү оешмасында эшлиме? — дип, сорауның үзе өчен дә көтелмәгәнен әйтеп салды Асия.

Ниһаять, «Түгәрәк»нең түземлеге саекты. Торып ук басты, таннәрен язып алды. Аты-юлы белән бер сүгенергә иде бугай исәбе,— дәрәҗә тота җиңнән. Арсланга таба борылып алды ул: «Монда кемне алып килдең! Нәрсә дип терәлеп каттың, кенәри бит синеке!..»— дияргә теләгәндер. Ул да түгел, янә Асиягә карап балкып алды:

— Син миңа ошый башладың бит әле, Асенька. Яратам шундый җор телле хатын-кызларны... Кенәри дисәң дә кенәри ичмасам, ха-ха-ха.

Комплиментлан башланган мыскыллы көлү иде бу. Асия аңышып өлгергәнче, сүзнең кай тарафка китеп баруын тоеп алган Арслан кинәт торып басты. Каршысына өлкән офицер килеп чыкканны соңлабрак күреп алган куштан сержант төсле гәүдәсен турайтты ул. Кулындагы кисәү агачын ничек һәм кая ташларга, кайсы аяктан беренче адымын атларга белмичә югалып калды бер мәл. Асиягә каршы китте.

— Йә инде, газаплама Лев Беляловичны. Тинтерәтмә җыен юк-бар сорауларың белән.

— Лев Белялович түгел, Лева — арыслан! Ул да арыслан,— дип, салпы якка сәлам кыстырырга өлгерде Асия.

Башын артка ташлап көлеп җибәрде «Түгәрәк».

— Менә шулай, Сәхипович... Ишеттеңме, Асеньканың ни дигәнен?

Шаярып әйтелгән шул бер җөмлә уйламаган җирдән туып алган киеренкелекне юкка чыгарды да куйды. Арсланның да йөзенә нур кунды.

Лев Белялович Асия тарафына бер-ике җылы сүз әйтеп алды. Күпне белергә азаплануы белән тәмам шиккә салган иде бит ул аны. Акыллы хатын-кызга аның исе киткәне юк. Гуля-Гөлсинә кебегрәк типлар белән эш итәргә күнеккән. Ә инде юллары кисешкән икән, күпне белергә яраткан хатын-кызны да вакытында коралсызландырганың хәерле. Ни рәвешлеме?.. Соклану һәм мактау сүзләре белән, комплиментлар сибеп кенә йомшартсаң йомшартасың ул хатын-кыз күңелен.

Уйламаган җирдән, вакытсыз уянып алган сабый авазы сыман, Гуля-Гөлсинә тавышы ишетелде:

— Лева... Ну, Лева, кайда йөрисең син?

— Монда, матурым... Монда, акыллым...

Йокыдан уянган сабыен юатырга ашыккан ана кебек җил-җил атлап-чабып ук китте «Түгәрәк». Гүя иңсәләренә канат үскән иде аның. Шул кадәрле юан, килбәтсез гәүдәле ир-атларның бик сирәге генә ия буладыр мондый җиңел хәрәкәткә.

— Мине йоклатканнар да, үзләре генә балдеют,— дип, үпкә белдереп каршылады кенәри. Авызын зур ачып, киерелеп, бер йомарлам һава иснәп алырга да өлгерде.

— Кенәрием минем, сайрар кошым, матурым,— дип такмаклый-такмаклый, килгән шәпкә иелә төшеп ирен очларыннан үбеп алды үзен «Түгәрәк». Кил, күтәрәм дигән сыман, торырга чакырып ике кулын сузды.— Йә, тор инде, житәр, күп йокладың, матурым, тор...

Киерелеп-сузылып, урыныннан торды кенәри. Янә бер йодрык һава иснәп алгач, йокыдан уянган песи баласыдай ипле генә «Түгәрәк»нең култык астына кереп сырпаланырга кереште.

— Мине йоклатканнар да, үзләре генә балдеют,— дип, тагы сүзгә-сүз кабатлады ул.— Ә нигә меня уятмадың, Лева?!.

— Уяндың ич, менә, уяндың, матурым.

— Минем баш авырта... Прямо чатный...— «Түгәрәк»нең култык астыннан томшыгын чыгарып, тагы бер йомарлам иснәп куйды.

— Эчкәнгә ул, матурым...

— Ә мин, киресенчә, эчмәгәнгә авырта дип уйлыйм.

— Сиңа күп эчәргә ярамый, син бит минем, бәләкәй... Кошчык сы-

ман гына, кенәрием...— дип, йомшак итеп, чәчләреннән сыйпап алды «Түгәрәк».— Сайрар кошлар таңда чык тамчысы гына эчә.

— Син нәрсә, бәләкәй дә бәләкәй талдычешь,— дип, көтмәгәндә күкерт кебек кабынып чәпчергә кереште Гуля-Гөлсинә.— Бәләкәй ошамаса, соң,әнә, тап үзеңә берәр корова... Беткәнмени, урамга чыксаң көтү булып йөри коровалар. Мине шушы хәлемдә дә любить итәрләр әле.

— Ух, минем татарочкам! — дип, үзен сөяргә, назларга кереште «Түгәрәк», Башкача җай булмаганлыкны аңлый иде күрәсең.

— Какой-такой татарочка, син нәрсә талдычешь?..— дип турсаюын дәвам итте кенәри.

— Ну, алайса татар кызы,— дип, бераз акценты булса да саф татарчага яраштырып ачыклык кертергә булды түгәрәк кавалер.

— Какой-такой татар кызы?..— дип, аны кабатлады Гуля-Гөлсинә.

— Татар булмый, кем булсын? — дип сәерсенеп калды ир-ат — Фамилияң ничек соң әле, әйт әле, матурым?!.

— Какой-такой фамилия?! Минем фамилияне любить итәргә җыенмыйсыңдыр бит?

— Татар түгел диден, фамилияң ничек, Гулечка?..

Ягымлы сүз каршында теләсә кем көчсез. Кенәриләр — аеруча.

— Кызык син, Лева... Ничә мужикны любить итеп, берсенең дә фамилиям белән интересовать иткәне юк иде әле. Мин — Сепперова.

— Нинди «Сеппер» ул? — дип, ерак түгел генә торган Арслан да сүзгә кушылып алды.— Сәфәрова булырга тиештер бит?

— Какой-такой, синнән сорамыйлар,— дип кенә җавап кайтарды кенәри,— И, вообще, минем фамилиям сезгә нигә кирәк?!

— Шулай да син татар кызы ич, Арслан Сәхипович дөрес әйттеме, ә, Гулечка? — дип, ике якны килештерергә омтылыш ясады «Түгәрәк».

— Татарочкамы-юкмы — какое ваше дело? Мин татарча знать не знаю! И, вообще, белергә дә не хочу! Нәрсәгә кирәге бар ул татарскийның — базарда катык продавать что ли?! Фу-у-у...— диде дә, борыннарын җыерып, «Түгәрәк»нең йонлач күкрәгенә капланды Гуля-Гөлсинә.

— Гөлсинә! — дип, сискәнеп дәште аңар Асия.

— Гулечка, тукта,— диде үзен кочаклап торган кавалер.

Арслан исә аңарга борылып карамады, нибарысы үзалдына әйтеп куйды:

— Гуля да Гөлсинә дә түгел — Кенәри...

— Надоели! — дип аваз салды кенәри үзе дә һәм түгәрәк ир-атның муенына сарылды. Көлке дә, кызганыч та иде ул шул мизгелдә.— Любить итәргә язык кирәкми...

Кочаклашкан хәлләрендә өстәлгә таба үтте алар. Түгәрәк арыслан кенәриенә бокал тутырып шәраб салып бирде. Тегесе ялт кына бушатып та куйды. Һәм, рәхмәт йөзеннән, ирен очлары белән бер «чукып» та алды. Әйе, бу хәрәкәтне «үбешү» дип түгел, «чуку» дию дөресрәк булса кирәк. Пыш-пыш нидер серләшеп алдылар һәм караңгы сукмак буйлап атлап киттеләр. Ә бераздан ачык тәрәз аша кенәринең дөньясын онытып чырык-чырык көлгәне ишетелде.

Берни аңлый алмады, гаҗәпсенүен дәвам итте Асия. Ничек инде Лев Беляловnatural кебек дәрәҗәле ир-ат шундый тиле кызчык белән бәйләнешкә кергән?!. Ни берләштерергә мөмкин аларны?!. Нинди уртак сүз, уртак серләре булырга мөмкин?!. Гаҗәп халык бу ир-ат дигәнең! Акыллы гына дигәннәре дә, соң чиктә, барыбер шыр тиле булып чыга үзләренең... Юк, көнләшү уеннан түгел, болай гына фикер йөртте ул бу хакта. Аның үз Арсланы бар ич!.. Ә шулай да хатын-кызда да бар ул сәер гадәтләр. Мисал өчен, женестәшләренең житешсезлекләрен бере белән генә түгел, икеләтә күпертеп күрә алар. Бер уңайдан үз өстенлеген тоеп ләззәт хисе татый. Бу бигрәк тә ир-ат тирәсендә кабынып китә торган тойгы. Теләсә кайсы парда ир-ат ягын өстенрәк саный әлеге хатын-кызлар. Дөнья күргән авыл агайлары сыман, «Чиләгенә күрә — капкачы»

дип кенә кул селти белмиләр. Нәкъ менә хатын-кыз ягын түбәнсетергә кирәк...

Талгын җылы җил исеп куйды. Аяк астына агач башыннан узган елдан бирле посып яткан ялгыз нарат күркәсе шапылдап килеп төште. Бер-беренә сер тапшыргандай, күл читендә камышлар кыштырдатып алды. Үлән арасында ялгыз чикерткә аваз бирергә керешге. Бака туена әзерлек башланды...

Асия белән Арслан кичке караңгылыкка чума барган табигатьнең сулышына таң калып утырдылар. Шундый мизгелдә бер-береңә сыенмыйча янәшә утыру, гомумән, мөмкин түгелдер ул. Икәүдән-икәү генә булуга җитәме соң!.. Янәшәсендә Арслан булганда дөнья түгәрәкләнә, тормыш мәшәкатьләре тәмам онытыла Асия өчен. Төртмәле сүз, урынсыз сораулар юкка чыга, кача. Арсланның гайрәтле киң иңсәсенә башын куеп, тәүлекләр буе, тәүлекләр генәме соң, мәңге-мәңге шулай утырырга риза булыр иде ул. Башка һичкем кирәк түгел аңарга, бары Арсланы гына булсын! Соңарып, зарыктырып кына килгән бердәнбере ич ул аның! Үз иткәне, җан атканы, акылыннан җуйдырганы... Бу хакта менә ничәнче кат уйлый, уйлана инде ул. Әгәр аны очратмаган булса, ул — кем өчендер яшәү, кемнедер уйлап төннәрен йокламый яту, кемнеңдер һәр хәрәкәтен, сүзләрен кат-кат искә төшереп күңел юатуларның ни икәнлеген дә белми, яшьлеге узып киткәнлекне сизми каласы булган икән.

Асия аның хакында үзе югында, үзен сагынган чакларында гына түгел, берөзлексез уйлый һәм шул уйларыннан ямь табып яши. Әле менә шундый гүзәл табигать кочагында чакта да ул аны уйлый. Югыйсә, янәшә утыралар, ә күңелендә — ул. Вакыт-вакыт аның кочагында чакларында да ул күзләрен йома һәм аны уйлый, аны сагына. Үткәнен, бүгенгесен һәм киләчәген ярата ул аның, куркып, хәвефләнеп ярата. Ул аны көнли дә әле. Хатыныннан гына түгел, һәр очраган чибәр хатын-кыздан көнли ул аны. Хәтта Арслан күрмәгән-белмәгән һәм күрү ихтималы да булмаган хатын-кыздан көнли. Әйтик, бервакыт телевизордан кино карaганда бер чит ил актрисасы канына тоз салды аның. Чибәр! Ярымшәрә кыяфәттә йөри, оятсыз елмая. Ә ирләр мондый елмаюга битараф каламы соң?.. Арслан да шул минутта әлеге киноны карыйдыр кебек тоелды аңарга. Карыйдыр һәм әлеге кино йолдызына карап авыз суын корытадыр. Булса, әнә шундый булсын иде ул сөйгәнең, диядер кебек тоелды аңарга. Әлеге хатынның һәр җире белән аны — Асияне — чагыштырып утырадыр төсле тоелды. «Гәүдә һәм сын яклары чагыштыргысыз анысы, күзләре, күкрәкләре дә сирәк очрый торган дәрәҗәдә гүзәл, килешләләр. Әмма бер чүпрәктер әле!.. Асия кебек ярата, авызына гына карап тора алырмы соң ул Арсланның?!.» Киносы — кино, киче — кич, йокысы йокы булмады ул көнне. Әле дә шул җилбәзәк хатын күз алдына килсә, куллары ирексездән Арсланның карашын капларга омтылалар аның.

...Арслан да уйга чумган. Куллары, ягымлы бармаклары әледән-әле аның беләгенә кагылып ала. Ул да аның турында, аны кайгыртып уйлый булса кирәк. Аңарга дәшәчәк ягымлы, иркә сүзләрен барлап утыра торгандыр.

Тынлык дәвам итте. Хәер, тынлык иде микән соң бу?! Асиянең күңелендә хисләр кайный. Колак очлары, барча тәне ут булып кызышкан, тел очында менә ташыйм, менә ташыйм дип мөлдерәп торган буа суыдай хисләр ташкыны. Аңарга гына сөйлисе сүзләр, аның белән генә бүлешәсе, уртаклашасы серләре... Күңелендәгеләрне түкми-чәчми сөйләп чыгу өчен бу җәйге кыска төн генә түгел, атналар-айлар, бәлки, бөтен гомере дә җитмәс иде аның.

Ниһаять, аңарга йөз белән борылды Арслан. Ничек озак һәм көттереп борылды ул бу юлы... Җитди сүзен ничек башларга белми азапланган сыман, күзләрен тутырып, Асиягә карап торды. Дөм-караңгы урман булуга да карамастан, аның күзләрендәге очкынны шундук сиземләп алды Асия. Ул бит аны сүзсез, һәр хәрәкәте, карашыннан аңларга күнегеп

житте хәзер. Аңлавын аңлый, әмма Арслан беркатлы ир-атлардан түгел, үзен ишетми торып ашыгып нәтиҗә ясарга ярамый.

Әби-бабайлар гадәтен белү кая — туган телеңдә дә бик сирәк сөйләшә иде Асия. Үз татарларың да, туган телеңдә бер сүз әйтсәң: «Аңламадым, русча әйт әле... Мин татарча ни белмяс...» дип тенкәне корытып торалар. Әмма «алла боерса» сүзен аның онытып торганы, теленнән төшергәне юк. Бигрәк тә Арсланга мөнәсәбәтле берәр уй уйласа, ул аны шундук «алла боерса» белән беркетеп куя. Кайчандыр, бик күптәннән, әле сабый чакларында ук, авылда яшәгән бабасыннан ишеткән иде ул бу сүзне. Нәрсә эшләргә керешсә, нинди уй-планнар кора башласа, шул сүзне — «алла боерса»ны кабатлый торган иде аның чигүле яшел түбәтәй киеп йөрегән мәрхүм бабасы. «Алла боерса, диген, кызым, шул сүзне онытмасаң, бәхетле булырсың, алла үзеңне ташламас, бар теләк-хыялларың тормышка ашар»,— ди торган иде бабасы. Асия ышанмый иде, әлбәттә... Ничек инде кешенең теләкләре шул бер сүзгә бәйле булсын?!. Шулай булса икән ул... Үзенең бабасына ошар өчен, Асия әледән-әле шул тылсымлы сүзне — «алла боерса»ны кабатларга өйрәнеп киткән иде. Хәтта, көннәрдән беркөнне, шул «алла боерса»сы өчен әнисеннән эләккәнне дә хәтерли. «Җыен тузга язмаган сүз сөйләп йөрмә, сиңа бернигә дә кирәк түгел ул»,— дигән иде.

Аңлый алмый аптыраган иде сабый — бабасы өйрәтә, әнисе орыша — ул нинди хикмәтле сүз икән ул?!. Бабасы үлгәч, «алла боерса» онытылды. Ләкин соңгы араларда, Арслан турында уйлаганда, аны югалтудан куркыпмы, янә еш кына хәтергә ала башлады ул бу сүзне. Телдән бигрәк, күңеленнән бик еш кабатлады. Аның тормышы бит хәзер тоташ Арсланга бәйле һәм шуңарга бәйле рәвештә ике дәвергә бүленгән. Берсе, озын һәм озак бертөрлелектән гыйбарәте — Арсланга кадәрге яшәү. Ә бер төш сыман булып тоелганы — Арслан алып килгән бүгенгесе. Тоташ сөю, тоташ юксыну һәм көтүдән гыйбарәт шушы бәхетле көннәрен әллә ниләргә дә алыштырмас иде ул.

Ә Арслан әле һаман көттерә, дәшми... Хәер, ул дәшмичә, әнә шулай карап кына торганда да җанга рәхәт. Сүзләр дә, берни дә кирәкми, артык барысы... Шулай үз итеп, яратып ул бары тик аңарга гына карый ич. Тиздән ул авызын ачар һәм калын тавыш үтә нечкә хис һәм назлы сүзләр тезеп китәр. Чү, Арслан нидер әйтергә җыена:

— Чама белергә кирәк!.. Кирәгеннән артык кызыксына башладың,— диде ул, әле генә өзелеп калган әңгәмәне дәвам иткән кеше сыман.

Аңламады... Үзенә юнәлтелгән иркәләү сүзләре дип кабул итте ул Арсланның сүзләрен. Күзләрен йома төшеп тагы да сыенарак төште бердәнберенә.

Арслан җавап көтә иде. Ә җавап юк. Муенына, беләкләренә кайнар ташкын сарылуын гына тойды ул бары. Әрсез иреннәрдән, йомшак беләкләрдән читкә тайпылды ул.

— Мин шаярмыйм, Асия! Шаяра торган урын түгел...

Сүзен тәмамларга, мәсьәләнең җитдилеген аңлатырга ара калдырмады. Күңеле тәмам нечкәрүдән елар хәлгә җитешкән иде инде ул. Күз яшьләрен яшерергә теләп, Арсланга сыенды, күзләрен яшерде. Бәхетеннән, Арслан белән янәшә булу бәхетен тоеп, сулкылдап еларга, күз яшьләрен сыгарга кереште ул.

Хатын-кыз холкын аңлау дигәндә, азау теше чыгарган сирәк ир-атларның берсе иде Арслан. Төртмә сүзләр өчен вакыт түгеллеген әле дә ничек соңлап аңлады соң әле ул?!. Як-ягына карангалап алды — танышбелеш арыслан һәм кенәриләр күптән таралышып беткән. Аларга гына ни булган, нигә алар гына мөнәсәбәтләр ачыклау белән мәш килергә тиеш соң әле?!.

Кайгырту һәм игътибар күрсәтеп, Арслан хатынның тыгыз-йомшак билennән кочып алды. Сукмак караңгылыгы, тәрәзләрендә тычкан уты

да күренмәгән серле һәм иркен бина тартты магнит сыман. Алар атлап үткән чакта тын сукмакта узган елдан калган корыган яфрак, кипкән ылыс кыштырдады. Күл ягыннан искән җилдә тын су өстендә хозурланып йөзгән үрдәкләрнең чупырдашканы, чумып уйнаганы ишетелеп куйды. Кайсыдыр тәрәзәдән Гуля-Гөлсинәнең тилереп көлгәне, такмаклап-такмаклап «Түгәрәк»не битәрләгәне яңгырады:

— Син гел шулай!.. Гел шулай син!..

Аның чәрелдек тавышы тынып торган арада, су читендә яткан ике бака хәбәрләшеп алды...

## 15

Хакыйкать, иртәме-соңмы, барыбер ачыкланырга тиеш иде. Институт белән ара өзүе хакында әнисенә Асия үзе хәбәр итте. Мондый хәбәрнең гаиләдә нинди ыгы-зыгы тудыру ихтималын һәркем күз алдына үзе дә китерә алыр, сөйләп тормыйм. Әмма гаилә белән алыш-биреше булмаган кеше сыман иреккә чыккан Асия шул көннәрдә өйгә ябышып ятты. Кайсы ана баласының кич җиттеме чыгып югалуларыннан туктап, өй мәшәкатьләреннән үзенә бер тәм табып яши башлавын хуплап каршы алмас икән?! Ул — өйдә, беркая җыенмый, ашыкмый, кич җиткән саен яңа төр ялганнар корып маташмый. Үгет һәм киңәшләренә колак та салмыйча үз иреге белән җил сугарып йөргән җиткән кызың кинәт кенә җитдиләнеп калсын әле...

Институт ташлады дип башны ташка орыр хәл юк. Җыен җүнсезлек чыкса — шул студент халкы арасыннан чыга диләр, әнә... Югары белем алып юлдан язган балага караганда, ана сүзенә колак салып, ипле генә бер-бер җирдә эшләп йөргән кызга ни җитә соң?!. Үз-үзен әнә шулай уйлап тынычландырды ана. Күзләренә йокы кайтты, өйгә янә иминлек иңде.

Әмма бу өйдә әле берәүнең дә һәм беркайчан да: «Кая эшкә керергә?» дигән сорау алдында торганы юк иде. Кайда уку, кайсы институтка керү турында бәхәсләр, сүзләр булды; ә менә эш хакында әлегәчә ләм-мим иде. Сорау туды... Аңа җавап та табарга кирәк иде. Кем булырга?.. Шул сорауга җавап табылмый торып, берәүнең дә күңеленә тынгылык иңмәячәк. Туган һәр яңа көн ашыктыра, уйга сала, кабаландыра барды аларның һәммәсен.

Асиягә эш кирәк!.. Буй җиткән кызларына ата белән ана эш эзли. Бер уйласаң, мәсьәләме инде эшкә урнашу? Безнең җәмгыятьтә моның ни кыенлыгы булсын?.. Кайсы оешма, кайсы завод каршысыннан үтмә: «Кабул итeлә», «Таләп итeлә» дигән баш астында дистәләгән һөнәр һәм белгечлекләр санап кителгән. Һөнәрең булмаса, рәхим итеп укы — һөнәр мәктәпләренең ишекләре ачык.

Кая барырга? Кем булырга?.. Кызларын эш өчен дип үстермәгән иде ата белән ана. Хәзер менә шул кызны эшкә урнаштырырга кирәк. Эш җитәрлек тә бит, әмма ата белән ананың да шартлары аз түгел. Кара эш булмасын! Авыр эш булмасын! Җил-салкында булмасын! Өйгә якын булсын! Күзгә зыянлы булмасын!.. Чиге-чамасы юк иде әлеге «булсын-булмасын»нарның. Эш кирәк! Әмма ул эшнең нинди икәнлеген генә белүче юк.

— Бәлки, шунда, үз янында — мәктәп тирәсендә булмасмы бер-бер эш? — дип, киңәш итмәк булды эти кеше көннәрнең берендә.

— Мәктәпкәме?! — булды җавап. Күзләре маңгайга сыешмады мәктәп завучының.

— Соң, алай булгач, үзем белән елгага алып торыйм,— диде чарасызлыктан гаҗиз калган бичара ата.

— Суда батып үләргәме?!

Ә Асия көтә. Бәхәсләргә катышмый ул... Аңа барыбер иң. Тик менә

көннәрне, төннәрне уздыру гына кыенлашканнан-кыенлаша бара. Төшкә кадәр йоклый. Мода журналларын актара, китаплар караштыра, телевизорга күз салгалап ала. Аеруча кич җиткәндә акрын үтә икән ул минутлар... Яшьтәшләре, таныш-белешләре ресторанга җыена торгандыр, урам чатларында очрашып озак-озак сөйләшеп торалардыр. Ул — өйдә утыра. Үткәннәргә кайту булмаячак — Асия шулай хәл иткән иде ич!..

Кайчак мәңге чишелмәстәй тоелган мәсьәләләрне дә тормыш үзе, бер җае килгәндә, ипле генә хәл итеп куя торган була. Асия белән дә шулай килеп чыкты. Бер үк йортта, бер үк катта яшәүче күршеләре Сания апа белән лифтта очрашты ул көннәрнең берендә. Ялгыз хатын, гел көтмәгәндә, аны үз янына чәй эчәргә чакырды:

— Өчпочмаклар пешергән идем, әйдә, авыз итәрсең, ялгызыма гына күңелсез, чит итмәсәң, кер безгә, кызым,— диде.

Үзе тегүче булып эшли икән ул, икенче сменага барасы икән... Ире, инде байтак еллар элек, машинада һәлакәткә очрап вафат булган. Ике ул үстергән. Олысы Чаллыда заводта эшли. Кечесе — Әфганстанда, бәгырьгә уелган яра сыман, хәвеф кочагында хезмәт итә икән. Боларын кирә-керешкә үк сөйләп алды Сания апасы. Гомер күршедә яшәп тә, Сания апаларының бусагасын атлап кергәне юк иде. Гомумән, аның әнисе юк йомышны бар итеп күршегә йөрүне хупламады. Кызын да шул рухта тәрбияләде. Өйләренә бер-бер классташы кереп чыкканда да, шундук аның җиде бабасын, әти-әнисенең кем һәм кайда эшләвен тикшерергә өлгерә иде. Яман тәэсиргә бирелә күрмәсен, урам балаларына иярмәсен, янәсе. Дәрәҗәле, мәртәбәлерәк урыннардагы кешеләрнең кызлары, малайлары белән аралашканны болай хуплый иде үзе тагын. Ә Сания апасы кем?.. Гади бер тегүче хатын, ире салгаларга ярата торган иде. Билгеле инде, аның малайлары белән аралашу катгый тыелган иде Асия өчен.

Ә хәзер ул көннәр буена өйдә берьялгызы, үзенә үзе хуҗа. Пөхтә итеп җыештырылган якты фатир каршы алды Асияне. Үзләрендәге кебек келәм өстендә келәм, бәллүр люстралар, күз явын алырлык чит ил мебеле тулып тормаса да, җанга ятышлы бер җыйнаклык сирпелә иде Сания апасының фатирында. Түрдә, иң хөрмәтле урында, мәрхүм иренең зурайтылган төсле рәсеме эленеп тора. Аның ике ягында — улларының рәсеме. Тәрәзә төпләрендә гөлләр, һәркайсы алсу яисә ап-ак чәчәкләргә күмелгән. Сиртмәле караватка пөхтә итеп өеп куелган мендәрләр өстендә бохар песие йокымсырап-иркәләнеп ята. Монда барысы да гади һәм пөхтә... Терәлеп торган күршеләрендә шундый мөлаем, кунакчыл апа яши торгандыр дип уена да кертеп караганы юк иде Асиянең.

— Түр бүлмәгә әзерлимме, әллә монда — аш-су бүлмәсендә генә утырабызмы? — дип дәште аңа хуҗа хатын.

Тавышы да гади һәм ихлас икән. Асияне ул үз тиңе итеп, үз күреп сөйләшә, кечерәйтми дә, зурайтмый да. Аш-су бүлмәсендәге җыйнак өстәлгә ак ашъяулык китереп япты ул. Барысын да җай белән, әллә ни арада гына эшләде. Ак ашъяулык өстенә чигүле ак шадра тастымал капланган уртача зурлыктагы табак килде. Тастымалны алып, пөхтә генә дүрткә бөкләде Сания апа һәм аны бакыр җәймә өстендә түбәтәйләрен биетеп кайнап утырган самавыр итәгенә куйды. Чигүле озын сөлге алып килде, аны кунак кыз алдына җәеп, икенче очын үзе утырачак урындыкка куеп торды. Стенада эленеп торган ак шкафны ачып, аннан аяз күк йөзедәй зәңгәрсу тәлинкәләр алды. Ак алъяпкыч өстеннән иңсәгә салынган шадра тастымал белән янә бер кат ашыкмыйча гына сөртте, тәлинкәләрнең берсен кунагы каршына, икенчесен үз алдына куйды. Ипле генә, килештереп кенә бал кашыкларын да, чынаяк тәлинкәләрен дә сөртте хуҗа хатын. Алъяпкычы сыман ап-ак савытларга салып, бал һәм вареньелар китерде. Ап-ак чәйнегенә бернichә төрле хуш ис аңкытып торган кыр үләне салып, чәй тамызды. Самавыр борыныннан шаулап кайнар су ага башлау белән үк чәйнектән бу күтәрелеп чыкты. Өй эчenә, борын-

нарны кытыклап торган кайнар өчпочмак исләре белән бергә, болын һәм кырлар сулышы таралды. Сабый чакта, әле бабасы исән чакта ук, ул чапкан печән өстенә утырып ерак басулардан кайткан чакта гына керсә кергән булгандыр Асиянең борынын кытыклап торган мондый да тәмле һәм мул исләр...

Сания апаның куллары өзлексез хәрәкәтләнеп торды. Ашыкмый иде ул, кабаланмый, әмма җитез, тыйнак һәм өлгер үзе. Атлаганда аяк тавышы чыкмас, өстәл хәстәрләгәндә савыт-саба шылтырамас, хәтта сулыш та алмый кебек иде ул. Чәй өстәле тәмам әзер булгач кына, ул алдан ук хәстәрләп куелган урынына утырды. Асиягә таба борылды, бар дөньясы балкып, үзенә тартып тора иде аның. Ул елмаймады да кебек хәтта, әмма күзләрендә таң нурлары, йөзләрендә алсу шәфәкъ, ирен очларында таң чыклары җем-җем килә иде аның. Чигәләрендәге көмеш толымнарына кадәр якты — үзенә тартып, чакырып тора.

— Яле, Асия, әйдә булмаса, Сания апаң пешергән өчпочмаклардан да авыз итеп ал бер,— диде ул.

Өчпочмаклардан авыз иткәнче, хуш ис аңкытып торган чәйгә иреннәрен тидергәнче үк телен йоткан кебек булды Асия. Тәмле сүздән, ягымлы һәм ихлас мөнәсәбәттән онытылып, югалып калган иде ул. Кызның дәшмичә, ризыкларга да кагылмыйча утыруыннан үзенчә нәтиҗә ясап — оялчанлыкка сылтап — хуҗа хатын иң элек өстәлдәге нигъмәтләреннән үзе авыз итеп алды. Чәй каршында дәшми-тынмый утыру да уңайсыз иде булса кирәк аңа.

— Чаллыдагысы үзе янына чакыра,— дип, гүя үзалдына сөйләнгән кебек башлап китте Сания апа.— Киленем дә әйбәт, әни дип өзгәләнеп тора — Апасныкы. Бигрәк тәмле икән ул якның телләре... Икенче бәбиләрен көтәләр. Беренчеләре малай. Бу юлы инде кыз көтәләр. Кыз бала бит ул ата-ана өчен өзгәләнеп тора торган була, җаныкаем...

Бер-ике йотым чәйләп алгач, кулларын ак тастымалга сөртеп, онытылып, үзенең оныгы турында сөйләп китте Сания апа, бер дә тиктормас оныгын мактарга керешә. Асия сүзгә катышмады, ни диярга белмәде. Ә хуҗа хатын, шулай берәм-берәм, Чаллыдагы улын, киленен һәм оныгын мактап чыкты.

Шунда, бөтенләй көтмәгәндә, баш очында гына кош сайраган аваз ишетеп, сискәнеп куйды Асия. Моңарчы тавыш-тыннары чыкмагангадыр, ул аларны абайламаган иде.

— Әй, нинди матур кошларың бар икән, Сания апа! Сайраулары нинди матур...

— Кенәриләр,— дип ачыклык кертте хуҗа хатын.— Әле таң аткандагы сайрауларын ишетсәң иде син аларның...

Урыныннан кузгалып, суыткыч өстендә торган читлеккә таба килде Асия.

— Кенәриләр...— дип кабатлады ул үзалдына. Дөнья белән әле яңа алыш-биреш итәргә өйрәнеп килгән сабый соклануын хәтерләтте аның бу сүзләре.— Нинди матур кошлар! Сайраулары матур...

— Шуларга карап юансам гына инде,— диде Сания апа, кошларыннан бигрәк, күрше кызына сокланып. Ул да түгел, моңсуланып куйды тагы.— Кече улым, беләсең инде, Әфганстанда бит...

Асия — белү кая, ул хакта ишеткән дә кеше түгел. Кайдадыр, Әфганстан дигән ил барлыгы һәм анда ниндидер дошманнар белән кемнәрнеңдер сугышканлыклары хакында ишеткән дә кебек. Һәрхәлдә, кызыксынганы булмады моңарчы. Сания апасының күңеле булсын өчен генә баш кагып куйган булды.

— Ил өчен кирәк булгач, нишлисең, Әфганстанда инде. Малай кеше үскәндә генә ата белән ананыкы бит ул... Унтугызга җиттеме — илнеке. Шулай кирәктер инде, нишлисең, җитәкчеләр белә торгандыр инде... Исән-сау йөреп кенә кайта күрсеннәр инде. Хәвефле диләр бит ул якларда...— Шунда хуҗа хатын, нәрсәдер искә төшереп, капылт кына торып

басты да, түр якка чыгып, нидер алып керде.— Онытып торам икән... Әле кичә генә хаты килгән иде, рәсемнәрен дә җибәргәннәр. Иптәш егете белән төшкән, менә... Монысы — минем малай, таныйсыңдыр... Ә менә монысы — аның иптәше, рус егете, Куйбышев өлкәсеннән икән. Матур егет, шулай бит, Асия. Улым да бик мактап яза үзен, авылдан икән. Авыл кешесе дуслыкның кадерен ныграк белә бит ул. Исән-сау йөреп кенә кайта күрсеннәр инде, балакайлар. Кайткачтын да элекке эшенә барам дип яза, слесарь бит ул.

Улы хакында сөйләргә керешкән ананы туктатырмын димә, телетелгә йокмады Сания апаның. Ә Асия күз чите белән нәни сары кошчыкларны, кенәриләрне күзәтеп утырды.

Хәрби киемдәге ике егет төшкән фоторәсемгә дә күз салды.

— Чибәр егетләр,— диде ул үзалдына. Ихластан әйтелгән сүзләр иде бу. Янәшә утырганнар да, бер-беренә башларын чак кына янтайта төшеп, күзләрен тутырып карап торалар. Игезәкләрмени. Бер анадан туган балалар кук үзләре. Күкрәкләрендәге билгеләренә, значокларына кадәр бер төрле...

— Икесенә дә медаль биргәннәр әле,— дип өстәде Сания апа, шундый әһәмиятле яңалыгын ни гомер әйтми торуына үз-үзен битәрләгән сыман.— Бер-бер батырлык күрсәткәннәрдер...

— Таза, матур егетләр,— дип кабатлады Асия.

Шунда гына Сания апа, сүзнең гел үз уллары хакында баруыннан уңайсызланып булса кирәк, Асиянең үзенә мөрәҗәгать итте:

— Үзеңнең укулар ничек соң, Асия? Каникулларга чыктыгызмы?

Гади генә сорау югыйсә, ә кызны шул сискәндереп җибәрде. Аларның гаиләсенә кырау булып төшкән борчу-мәшәкатьләр хакында Сания апа белми бит.

Хәзерге шәһәр фатирларында бик күп серләр дүрт стена артында туып, шуннан чыкмый кала. Кеше үз гаиләсе, үз көнелендәге серләрнең күрше-күләнгә мәгълүм булуыннан уттан курыккандай шүрли. Дуслар белән уртаклашу, күрше белән бүлешү кебек төшенчәләр, шәһәрдә түгел, авылда да сирәгәеп бара бугай инде. Кеше рухи һәм матди яклардан байый барган саен, ни өчендер, саранлана, торган саен үз эченә, үз фатирына ныграк бикләнә бара. Бер Асияләр гаиләсе өчен генә хас түгел бу сыйфат.

Мондый сорауны көтмәгән иде Асия. Сания апасы өчен барыбер түгелмени — ул укыса ни дә укымаса ни?! Укуын ташлавыннан да сер ясарга җыенганы юк. Әнисе генә баш югалтуга тиң бәла саный моны. Ә күрше-күлән һәм таныш-белешләреннән уттан курыккандай курка. Шул хакта уйлап алды кыз; димәк, күрше хатынга дөресен сөйләү ярамый. Әмма үзе белән шул дәрәҗәдә эчкерсез һәм ихлас мөнәсәбәттә булган Сания апасына ничек ялган сөйләп утырырга мөмкин?!

— Ташладым,— дип кенә җавап кайтарды ул.

Гаҗәпкә каршы, хуҗа хатынның мондый җавапка артык исе китмәде, ипле генә өрә-өрә, чәй эчүен дәвам итте. Әйтерсең, берни булмаган; әйтерсең, игътибарга лаек түгел дәрәҗәдәге бер нәни яңалык иде бу. Кабатлап сораулар биреп тә аптыратмады.

— Мин үзем дә табип була алмас идем,— диде тыныч кына. Һәм янә бер мәртәбә чәй йотып алгачтын өстәп куйды.— Эш бетмәгән... Яхшы кеше булу кирәк, Асия.

Менә ничәнче кат инде сокланып туймый ул бүген Сания апасына. Урта белемле дә булмаган шушы гади генә хатын бер сүздән аңлап алды аны. Хәленә керде. Дөресен сөйләп ялгышмаган, димәк.

— Кайда эшләргә җыенасың соң? — дип сорап куйды ул бераздан, гүя кыз күңелендәгене үтәдән күргән сыман.

— Әлегә белгән юк... Эш бетмәс әле...— дип, артык исе китмәгәнне күрсәтеп кенә котылырга иде кызның исәбе.

Ә Сания ападан алай җиңел генә котылып булмый икән: әйтерсең,

күршеләрен менә ничә көннәр, атналар буена тынгысызлап торган сорауларны ул ишетеп, кичереп торган.

— Бик җаваплы чагың икән,— диде ул, уйга чумып.— Андый чакта алдым-бәрдем генә хәл итәргә ярамый. Урнашсаң, гомерлеккә урнашырга кирәк...

Әлеге ихласлык Асиягә дә тәэсир итми калмады.

— Белмим шул,— диде ул.— Әниләр дә аптырады инде. Көн-төн шул хакта уйлыйбыз...

— Бәй,— дип, нидер хәтерләп, кабынып китте Сания апа.— Тапкансыз баш катырыр нәрсә?! Соң, тот та кил безнең ательега.

— Анда ни эшлиләр?..

— Тегәләр. Кием-салым...

— Минем кулдан килмәс ул, Сания апа.

Кызның сүзен ярты юлда бүлде Сания апа:

— Килмәде ди... Үзем өйрәтермен! Энә тота беләсеңдер бит? Бүген үк әниең янына керәм дә, хәл итәбез аны,— башына шундый уй килүгә үзе үк куанып куйды ул. Эшең бетте, кодагый, кызны кияүле дә иттек дигән сыман, уч төпләрен бер-берсенә шап-шоп суккалап алды.

Ни диярга да белмәде кыз, авызына капкан чәйне йотарга кыймый торды.

— Бәй, җаным Асия, безнең «Йосыф — Зөләйха»га эшкә керү өчен шәһәрнең ярты хатын-кызы җанын фида кылырга йөри. Ишеткәнең дә юкмы әллә?

Ул ательеда кием тектергәне булмаса да, яшьтәшләре телендә аның нинди дәрәҗәгә ия урын буларак искә алынганын белә иде кыз. «Йосыф — Зөләйха» дигәндә, күпләрнең колагы үрә тора. Анда бер-бер танышы яисә туган-тумачасы эшләгән кызларның ничек киенгәнлеген дә белә Асия. Ә нигә, шунда эшли башлый икән, бер дә начар булмаячак!.. Кемгәдер кирәгең була, кемгәдер ярдәм итә ала торган эш урынының дәрәҗәсе үк бүтән. Дөньяның тәртибе шундыйрак ич!.. Әллә аның модалы итеп киенәсе килми дисезме? Кибеттә — юк, ательеда — чират, базаларда — блат, кая, барып бәрелергә белмәссең...

«Блат — начар нәрсә, ул — капитализм калдыгы, кода-кодагыйлык, син — миңа, мин — сиңа принцибы белән яшәү җәмгыятебезнең асылына чит күренеш. Көнбатыш тәэсире»,— дип сөйләгән иде аларны укыткан лекторлардан берәү. Урыны, очраклы рәвештә, алдагы рәтләргә туры килгән Асия әлеге фәннәр кандидатын җентекләп күзәтеп утырган иде шул чакны: аягында Франциядә эшләнгән туфли иде аның, костюмын финнәр теккән, кесәсендә күкеле сәгать-авторучка — японнарныкы, күлмәк кесәсе читенә күп йолдызлы ак флаг төшерелгән, тотып кергән дипломаты Сингапур дигән җирдә эшләнгән... Кыюлыгы җитмәде Асиянең, ул аңардан сорарга ымсынып утырды: «Иптәш фәннәр кандидаты,— диясе иде шунда,— сез боларны каян, Бауман урамындагы кайсы магазиннан алдыгыз?»

— Тәвәккәлләп карыйбызмы әллә? — дип елмайды урыныннан ук торып баскан Сания апасы.— Исеме генә дә ни тора бит: «Йосыф — Зөләйха»!..

— Белмим шул...

— Мин сөйләшсәм — алырлар... Телисең икән, менә бүген үк җитәкләшеп чыгып китәбез дә хәл итеп кайтабыз аны. Әллә иртәгесе көнгә — җомгага калдырабызмы?!

Кичен әлеге сөйләшү хакында Асия үзе җиткерде әнисенә. Борынын җыерган иде башта әнисе, күрше хатын да кереп үгетләшкәч, килешми чарасы калмады — ауды.

Шулай итеп, көтмәгәндә, тегүче булып китте Асия. Кайда эшләве турында кызыксынучыларга, башын югары тотып, «Йосыф — Зөләйха»-да дип җавап кайтара башлады. Бергә бардылар, бергә кайттылар, тегү эшенә дә шул ук Сания апасы өйрәтте... Ә инде егермегә җитеп тә кулы-

на энә белән тегәрҗеп тотарга өйрәнмәгән кызны тегүче итү өчен, күпме түземлек һәм тырышлык кирәк булганлыгын Сания апа үзе генә белә торгандыр. Ике кеше өчен эшләсә эшләде, әмма Асияне кеше алдында көлкегә калдырмады ул. Ни хикмәт — кыз үзе дә теш-тырнагы белән ябышты бу эшкә.

...Беренче сменада эшләгән атналары иде. Кайтып, икесе ике як ишектән кереп китүләренә күп узмады, Сания апа аларның ишеген какты. Дучмак пешергән икән — ялгызына күңелсез булып киткән, чәйгә чакырды. Каршы тора алмады Асия, керде. Кай арада өлгергән диген. Сания апасының өстәле түрендә пар бөркеп, түбәтәйләрен биетеп, самавыр кайнап утыра. Өе җылы, тәмле исләр таралган. Чисталык, пөхтәлегеннән күз камашырлык. Аяк астында сырпаланып йөргән йонлач песиенә тикле сөйкемле, ягымлы бит ул Сания апаның. Читлекләре эчендә сикергәләп, бертуктаусыз сайрашып туймаган кенәриләре турында әйтәсе дә юк...

Эштәге кызык һәм мәзәк хәлләрне искә алып икәүдән-икәү генә чәйләп утырулары иде, ишектә берзаман кыңгырау шылтырады.

— Кем булыр икән?.. Әллә телеграм-фәлән китерделәрме, ходаем,— дип, капылт кына урыныннан сикереп торды хуҗа хатын.

Ачылган ишекнең аргы ягында берәү борынын тартып алды, ир-ат халкы икән.

— Бәй, Фидаил, синмени әле бу,— дип, көтелмәгән кунагын куанып каршылады Сания апа.

— Исәннәрме, Сания апа?! Бер-бер эшең бар идеме әллә, нигә чакырганыең?

— Бәй, кара инде аны, гел хәтердән чыгара язганмын...

— Чәршәмбе көн килергә кушканыең бит...— Килүче оялчан иде булса кирәк, тартынып кына сөйләшә. Үзе әле һаман ишекнең аргы ягында.

— Шулаймыни,— дигән авазы ишетелде Сания апаның.— Чәршәмбе дә килеп җиткәнмени инде, гел онытып торам икән. Әйдә, кер, Фидаил, ишек катында торма... Кунак кызы да бар иде әле өйдә.

. Кунагын чакыра-кыстый торгач, кухня ишегенә үк килеп җитте Сания апа. Ишекне киереп ачты. Аның артыннан, тартынып кына, култык астына бүреген йомарлап кыстырган бер егет ияреп килә иде. Сөзеп, беренче караш ташлауга ук, үтәдән күреп өлгерде аны Асия: уртачадан калкурак, төптән ныгып үскән гәүдә. Урамнан кергәнгәдер, бит урталары алсуланып торган түгәрәк йөз. Төртеп торган яңак сөякләре үзенә ирләрчә бер ныклык төсмере өстәп тора. Борыны курноска тартым. Иң мәзәге — колаклары — локаторлар сыман тырпаеп торалар. Керфек һәм кашлары сирәк һәм тоныклар. Чуалган чәч җитен сыман. Кыскасы, бер дә нечкәләп тормаганнар үзен... Кигән чалбары хәрбиләрнеке, димәк, күптән түгел генә армиядән кайткан булса кирәк.

Болар барысы да беренче карауда ук карашына сыйды Асиянең. Калганы әһәмиятсез, гомумән, егет аның игътибарын җәлеп итүдән шактый ерак иде.

Ниһаять, җиңеннән тарта торгач, әлеге оялчан егетне табын янына утыртты Сания апа. Табыннан түгел, янәшәдә утырган кыздан уңайсызлана иде егет. Чибәр хатын-кыз ул — әрсезләрне генә тарта, ә гадиләр, гадәтиләр коелып төшә андый чакта, үз-үзен кая куярга белми аптырашта кала.

Янә егетнең колакларына күз төшереп алды Асия. Әллә ни арада көзге усак яфраклары төсенә кереп кызарырга өлгергән иде инде алар. Кызның карашын ни белән җәлеп иткәнлеген егет үзе дә тойды булса кирәк.

Шунда гына бер тын игътибардан читтә калып торган Сания апа җил-җил атлап килеп җитте.

— Бездә кунак кызы бар иде бит әле,— дип кабатлады ул. Әллә,

ходаем, ул үзе дә дулкынлана идеме соң?! Менә хикмәт.— Күршебездә яши... Асия исемле.

Ипле генә баш иде кыз — бу мин, янәсе. Аның тартынып куюы, оялчанлык түгел, табигый инстинкттан гыйбарәт булгандыр. Асиянең озын керфекләре йомылып алган арада, ялт кына егет тә төбәлеп алды үзенә. Әмма, урлашып тотылган кеше сыман, үз карашыннан үзе үк янә коелып төште.

— Ә бу — Фидаил,— дип, яшьләрне таныштыруын дәвам иттерде хуҗа хатын.— Безнең авыл егете. Әнисе минем ахирәтем иде... Армиядән кайткач, менә, шәһәргә килеп урнашты. Шофер. Төзү оешмасы җитәкчесен йөртә.

Шулаймыни дигән сыман, кызыксыну белдереп, күзләрен уйнатып алырга өлгерде Асия. Килешле елмайды, үзенең бу танышуга чиксез шат булуын да хәбәр итеп өлгерде ул бер мизгел эчендә. Моның, әлбәттә, ресторан-кафеларда исәнләшкән-танышкан чакларында еш кабатлана торгач тәмам канга сеңгән бер гадәт кенә икәнлеген беркем чамаламады.

Егет кешегә кызлар каршында җебеп төшү, гомумән, килешми. Тартыну, уңайсызлануларны да күрсәтмәгәнең хәерле. Чөнки хатын-кыз көч алдында баш ия, җебеп төшкәнне өнәми. Югалып калуыңны сиздеме, хәтерләп кал, бу өстенлеген ул һичкайчан югалтмаска тырышачак. Үз-үзен кулга алырга ашыккан егет башын күтәрде дә текәлеп сорау бирде:

— Сез тегүче булып эшлисезме?Ниләр тегәсез?..

Сорау түгел, «Сүз булмаганда — сүз булсын, өч көн узгач, исәнме, кодагый» булып чыкты кебек бу. Шул соравы белән, үзен генә түгел, Сания апасының да изге нияттән чыккан ялганнарын чыгарып селкеде түгелме?! Асиянең тегүче булып эшләвен каян белергә тиеш соң әле ул?! Димәк, Сания апасы аларны таныштырырга ниятләгән. «Чәршәмбе»не бутаганнар, имеш...

Шулай да күңелендәген үз эчендә калдыра белде кыз. Берни сизенмәде, янәсе; әнә ич, элеккечә үк оялуын дәвам итеп, тик утыра өстәлнең түр башында. Башы иелгән, озын керфекләре түбәнгә текәлгән...

Сания апа «оялчан кыз»га ярдәмгә килде:

— Әйе, безнең Асия тегүче булып эшли. Бер ательеда эшлибез — «Йосыф — Зөләйха»да. Мактап йөрисең икән, Фидаил, әле менә чәй эчәргә дип утырган гына идек...

Кыз дәшмәде. Керфекләрен күтәрергә «кыенсынып» утыруын дәвам итте. Билгеле инде, андый чакта егет халкы кыюланып китә торган була:

— Әллә кунак кызы телен йотканмы, Сания апа?— дип, шаян-җор сүз кыстырырга да өлгерде ул. Хәтта тешләрен күрсәтеп елмаерга да җитеште әле.

Нәрсә-нәрсә, әмма бу кадәр үк көтмәгән иде кыз.

— Бер дә йотмадым, менә, бар минем телем,— диде ул, чәчәк таҗлары сыман ачылып алган алсу иреннәре арасыннан түгәрәкләндереп телен чыгарып күрсәтте. Гүя, сабыйны үрти иде. Сания апа күрмәгәндә текәлеп карап алырга да өлгерде.

Әлеге карашны күтәрә алмады Фидаил. Кызның куе һәм озын керфекләре арасыннан төбәлгән зур зәңгәр күзләр, төнлә фарасын сүндерми күзне сукырайткан машина сыман тәэсир итте аңарга.

Беркавым тынлык урнашып торды. Яшьләрнең танышып, сөйләшеп китүләренә өмете булган Сания апа берничә кат зал якларын урап керде. Нидер эзли идеме, әллә болай гына — озак кына балконда да югалып торды. Кыз керфекләрен түбән төшермәде башка. Егет кулларына урын таба алмый аптырады... Ниһаять, тәвәккәлләп, өстәлдән дучмак алды һәм бер ноктага текәлеп ашарга кереште.

Уйламаган җирдән пырхылдап көлеп җибәрде кыз, уч төпләре белән авызын каплады. Көлми түзеп кара — егетнең ашаганда ике колагы

да өзлексез селкенеп тора икән.

— Фидаил,— дип дәште ул аңарга.— Синең колакларың, куянныкы кебек, ашаганда бер туктамый селкенеп торалар икән бит!

Авызына капкан ризыгын чәйнәргә онытып, туктап калды егет. Үз колаклары ишеткәнгә ышанасы килмичә, як-ягына карангалап алды. Дәшү кая, авызындагы дучмак кисәген тел очы белән әле бер, әле икенче якка этеп-төртеп йөртте дә, ни чарадан бичара калып, чәйнәп тормый гына йотып җибәрергә мәҗбүр булды.

Кыз бу юлы инде яшерми генә көлде. Туйдым, дигән атлы булып, дучмак салынган тәлинкәне өстәл уртасына шудырды егет.

— Общагада торып... җүнле ризык ашарга да ара юк.

— Соң, өйләнергә кирәк...

— Кемгә?

— Мисал өчен, әйтик, менә миңа...

— Һы...— дип көлемсерәп куйды егет.— Кызык кыз икән син.

— Нәрсә, куркыттыммы әллә?

— Куркытуын куркытмадың... Шулай да кызык...

Сүзләрен бүлдереп, нәкъ шул вакыт Сания апа килеп керде яннарына. Ниндидер хикмәтле сүз әйтергә дип ачылган иреннәре ябылмый торды Асиянең, уңайсызланды. Ә хуҗа хатын, яшьләрнең ашамый-эчми утыруларын күреп, кыстарга кереште.

— Рәхмәт, Сания апа, тәмле булды... Рәхмәт,— диештеләр болар.

Башында башка бер-бер чит уй, борчуы булган кешедәй уйга калып торды Сания апа, аннан Фидаилгә дәште:

— Бакчага барып кайтырбыз дигән идем дә... Әле менә балконга чыккан җирдән, әллә нидән генә, бер сәбәпсезгә башым әйләнеп киткәндәй булды. Барырга бик кирәк иде дә бит, вареньелар да алып кайтасы бар...

— Ярар алай булгач,— дип, ишек катына таба үтте инде бая ук аягүрә торып баскан Фидаил. Тотып кергән бүреген таба алмый аптырады.— Бер җай табып килеп чыгармын әле...

— Сине алай гел-гел борчу уңайсыз шул, Фидаил. Бүген барып кайтканда бик әйбәт була иде дә бит... Әллә тәвәккәлләп карыйкмы икән?

— Нәрсә алып кайтырга иде соң тагы?— дип кызыксынды егет.

— Кыяр-помидоры да кирәк инде аның... Түбәдәге карны төшергәндә дә әйбәт буласы иде... Март уртасы җитеп бара бит...

— Үзем генә таба алмам микән?

— Әле бит син Казанны да җүнләп белеп бетермисең... Табалмассың дип куркам шул.

Балтасын суга төшереп чарасыз калган кеше сыман, бер кулы белән башын тотып торган Сания апа елык кына Асиягә таба карап куйды шунда. Әле узган ялда гына барганнар иде алар анда. Тирән күл янындагы тауда көнозын чаңгы шуганнар иде; аннан, Сания апаның дачасына кайтып, кабыклы бәрәңге пешереп, чәйләр кайнатып эчкәннәр иде... Бу карашы белән ни әйтергә теләде соң Сания апа? Хәйлә корусымы? Әллә, ярдәм итсәң, син генә ярдәм итә аласың инде, Асия, дип, аңарга мөрәҗәгать итәргә кыймый торуымы?

— Соң, алай булгач, әйдәгез, үзем күрсәтим юлны,— дип торып басты Асия.

Сания апа кыздан мондый яхшылык көтмәгән иде гүя, тартынып куйды:

— Уңайсыз булмасмы соң?

— Нәрсәсе уңайсыз булсын, барабыз да кайтабыз.

— Егет кеше белән... Әниең орышмасмы, дим...

Кулындагы бүреген кияргә-кимәскә аптырап торган Фидаил үзен искә алуга ук капылт борылып алды:

— Ашамам әле! Мин кеше ашаучы түгел, Сания апа...

Бу тамашада үз ролен оста башкаручы — хуҗа хатын иде, билгеле. Асия ни дияр бит, дигән сыман янә кызга карап куйды ул. Уңайсыз булмасмы, курыкмыйсыңмы, янәсе...

— Кемнән?.. Моңарданмы?— дип, чак көлеп җибәрмәде кыз. Егет ягына ымлап алды.— Үзе миннән курыкмаса...

Кызлар авызыннан ишетелгән сүзләр мондый чакта үткәрелә, күтәрелә. Фидаил дә ул-бу сиздермәде. Шундый чибәр кыз янәшәңдә утырып, шәһәр читенә үзең белән чыгарга әзер булып торсын әле!..

— Безнең дә курка торган киемнәр тузган инде,— дип авызын ерды ул.— Барабыз дисәң, әйдә, чибәр кыз — тизрәк җыен.

Сания апасының бусагасы төбендә шактый ук кыюлана төшүенә дә карамастан, юл буе дәшмәде егет. Хәтта кыз утырган тарафка күз салырга уңайсызланып барды. Әмма сөйләшәсе, һич булмаса, бер-ике сүз кушып карыйсы килә иде аның кызга. Ничек һәм нәрсәдән башларга белми азапланды. Асиягә исә шул җитә калды, өлгерлек күрсәтеп, үзе башлады ул әңгәмәне. Егетнең оялуы, уңайсызлануыннан файдаланып — дөресен әйтергә кирәк, мондый егет белән очрашканы юк иде аның әлегәчә — теленә ни килсә, шуны сөйләргә кереште. Үзенең булган һәм булмаган егетләре хакында хикәят итте. Шул егетләрнең ничек, дөньяларын онытып, үз артыннан йөрүләре хакында сөйләде. Бүгенгесе көндә тәкъдим ясаган, җавап көтә торган егетләрем бер дистәдән артып китте инде, дип тә шапырынып алды. Кинәшкә мохтаҗ кеше атлы булып, сораулар биреп тә аптыратты:

— Баш каткан инде,— дигән булды.— Берсе — яшь, чибәр; икенчесе — хатын аерган, башында чәче юк, ләкин акчасы күп; тагы берсенең — буе озын; әтиләре яхшы урында эшләгәннәре дә бар... Киңәш итәр идең, Фидаил?!

Кызның үртәп сөйләшүен аңлау кыен түгел иде, билгеле. Ләкин ул сорауларда дөреслекнең дә булуы бик ихтимал. Асия кебек кызларның артларыннан йөрүче аз булмый.

— Акыллысын сайларга кирәк,— диде ул, күзен юлдан алмый гына.

— Акыллы икәнен каян белергә?

Егет уйга калып барды бертын. Асиянең сораулары гына түгел, үз күңелендәге каршылыклы уйлар көрәше дә аптыраткан иде аны: «Кыз — чибәр... Әмма аңарга өмет баглау файдасыз булачак!.. Ә күңел берөзлексез тартыла үзенә... Нишләргә?» Сикәлтәле һәм бормалы урман юлы белән барганда дөньяңны да онытып булмый бит әле тагы...

— Ә, Фидаил?— дип кабатлап сорады кыз.— Акыллы икәнлеген каян белеп була ул егетләрнең?..

— Кем булуына карыйсың инде...

— Колакларыннан билгеле түгелме икән?— диде дә шундук, үз сүзләреннән үзе кызык табып, пырхылдап көлеп тә алды кыз.

— Андый сәләтең булса, колагыннан да белә аласың,— дип сер бирмәде егет.

Үзалдына көлемсерәп барды кыз, егетнең үпкә белдермәве сәер тоелды. Хәтта Фидаил аңарга ошап та куйды шул мизгелдә, авызында кара кан булганда да кеше каршында төкермичә түзеп торган заттан икән ич ул.

Юлның ераклыгы сизелми дә калды. Сания апаларының бакчачылык җәмгыяте капкасы төбенә килеп туктадылар. Алга таба, тирән кар ерып, җәяүләп керергә туры килде. Фидаил алдан барды. Юл өйрәтеп килгән Асия аңарга иярде.

— Карале, Фидаил,— диде кыз, ишекне ачып, баз сыман салкын, караңгы бүлмәгә килеп кергәч тә.— Монда ике кеше йоклый торган карават та бар икән бит!— һәм, йөгән күрмәгән яшь тай сыман, йөгереп барып тимер сиртмәле караватка сикерде.

Ачык ишек каршында катып калды егет, ишетмәгәнгә сабышты. Колагы ишеткәннәр башына сыешмады: кыз кешегә ничек инде шулай

шаярырга мөмкин... Балта алып, тышкы яктан тәрәз капкачларын ачарга чыгып китте ул.

Тәрәз капкачларын ачкан атлы булып, байтак кына озак кайнашып керде. Ул кергәндә дә әле кыз сиртмәле караватта иде. Урта бер җиренә менеп утырган да рәхәтләнеп атынып мы атына, риясыз сабый бала сыман. Егет, кереп, баз капкачын ачты. Ә Асия сиртмәле караватта атынуын белә, шаркылдап көлә үзе, кулларын чәбәк-чәбәк итеп ала.

— Фидаил, син өйләнгән кешедер инде, шулаймы?!

— Нигә алай дисең, Асия?

— Теләмичә генә сөйләшәсең... Шаярырга да теләмисең.

— Нигә?.. Юк, алай түгел, Асия...

— Хатыны бик усалдыр инде моның, шуңардан куркып дәшми торгандыр, дип уйлап килдем!

— Өйләнергә ара булмады шул әле,— диде ул ихластан. Асия белән сөйләшкәндә көлә дә, шаяра да алмый иде.

— Йөргән кызларың күптер...

— Барын бар иде...

— Ул ничек була инде?

— Армиягә тикле йөргән идек. Авылга кайтсам — юк.

— Һе, кызык...

— Кемгә ничек инде, Асия.

Исе китми генә янә тибрәнүен дәвам итте кыз. Егет, башын тыгып, баз эченә күз төшереп алды, сызгырып куйды:

— Бар икән монда хәлләр..

Кызның үзенеке — ипле генә сорап куйды ул егеттән:

— Мине ошатасыңмы соң?

Әйе дисә — көлке, юк дисә — ялган булыр иде, дәшми калуны артык күрде егет. Шуның өстенә эш белән мәшгуль чагы, баз авызыннан түбәнгә төшеп барышы ич... Ниһаять, ул инде тәмам күмелде, кыштырдаганы гына ишетелеп тора. Озак та үтмәде, баскыч буйлап арлы-бирле йөренеп, Сания апа сораган банкаларны берәм-берәм югары күтәрергә кереште. Сиртмәле караваттан аерылган кыз шул савытларны ишек катына тигез бер рәт итеп тезә торды.

— Җавабыңны ишетмәдем, Фидаил?— дип, соравын кабатлады ул, җаен китереп.

Баз эчендә йөрегән егет бу юлы да ишетмәгәнгә сабышты, үзалдына сызгырынуын дәвам итте.

Ниһаять, кирәк әйбер баз эченнән чыгып бетте, Фидаил башын күтәрде. Баз авызы каршына ук килеп утырган кыз текәлеп үк карады егеткә.

— Ошатмасаң, турысын әйт, үпкәләмим...

— Кемне?

— Мине!

— Мин бит сине бик аз беләм, Асия.

— Ә бер күрүдә?..

— Бер күрүдә яратуга ышанмыйм мин.

— Ә мин ышанам!

— Нәрсә, әллә мине бер күрүдә ошаттыңмы?— дип әйтеп салмасынмы шунда егет.

— Ошатмаган ди, әбәү!— дип пырхылдап көлеп алды кыз. Бармак очлары белән сак кына кагылып, Фидаилнең чәчләренә кунган тузанлы чүп кисәкләрен кагып төшерде.— Идән асты килешә икән үзеңә...

Чынлыкта да Асия аның сабырлыгын, күндәмлеген ошатып өлгергән иде инде. Эш белән дә хисаплашмый булса кирәк. Асияне куалап та төшерә алмаслар иде идән астындагы базга. Җитмәсә, чит кеше базына. Ә ул ике дә уйлап тормады... Кирәк сүзне ишетә, кирәкмәсен үткәрә белә — монысы да матур сыйфат безнең көндә.

Сак кына баз авызын япты егет. Себерке алып, идәнгә коелган ту-

зан, чүп кисәкләрен себереп куйды. Шуннан соң, яшереп кенә, кызга күз салып алды:

— Сания апа сине әйбәт кыз дип мактаган иде...

Егетнең ихласлыгы һәм эчкерсезлегенә, ялганлый белмәвенә, аңарга ялган сүзнең килешмәвенә байтактан инанган иде инде Асия. Шул рәвешле житди итеп, уңайсызланып карап торганда ул хәтта үзенең йөз чалымнары, карашы белән, ошап та куя иде аңарга. Асия күргән-белгән егетләрдән үзгә иде ул, аларның берсенә дә охшамаган, бөтенләй башка... Сания апа да юкка гына аңар үзе хакында сөйләмәгән, күрәсең...

— Сания апа мактый дисең инде алайса, ә?..

— Сания апа кешене таный ул.

— Ә үзең нинди нәтиҗәгә килдең?

— Әйтә алмыйм... Әллә тагы...

— Ничек, ничек?..

— Син уйныйсың, юри ирештерәсең кебек мине. Ә үзең, Асия, мин күреп торам... Үзең андый түгел син.

— Нинди?.. Йә, әйт әле, үземнең кем икәнлегемне беләсем килә ич минем дә.

— Сәер кеше бугай син,— дип, иңсәләрен сикертеп алды егет. Һәм төртелеп калды.

— Йә, инде, йә, нигә әйтеп бетермисең аны? Әйт, тәрбиясез диген, бозык диген. Әйтеп бетер барысын да...

— Алай дип уйламыйм, Асия... Син мине үзеңә тиң санамыйсың... Үзеңне өстен куясың... Шул гына!

— Ә син башкача уйлыйсыңмы, егетем,— диде кыз, егетнең туры сүзләренә кәефе кырылып, иреннәрен турсайтып алды.— Әллә син үзеңне миңа лаек, тиң дип саныйсыңмы?..

Фидаил аны тыңлап бетермәде, Сания апасының мунча себеркесе алып кайтырга дигән үтенечен хәтерләп, тар баскыч буйлап чарлакка менеп китте.

Егетнең бу кыланышы ошап бетмәде кызга. Бер-бер дорфа сүз әйтеп туктатмакчы иде ул аны, сүз таба алмый аптырады. Ә шул арада егет күздән дә югалды, тынып калды. Чарлакның ерак почмагына житеп, югарыга кыстырылган көрәк сабына эленгән җирдән дүрт пар каен себеркесе алды да пычкы чүбе җәелгән түшәмгә утырды. Бертын хәл алырга, үз уйлары белән генә калып ял итәргә иде исәбе. Юкса, әлеге кызның һәр сүзе шөпшә чаккан кебек тәэсир итә иде аңарга... «Житте,— диде ул үз-үзен битәрләп.— Нигә буй житмәс агачтагы җимешкә ымсынам соң әле мин? Ул — рәхәткә чыдый алмый үскән шәһәр кызы, ә мин — авыл малае. Өстәвенә артык чибәр дә тагы үзе!.. Үз-үзенә бәяне артыгы белән белә. Ә син кем? Гап-гади бер эш аты... Таяныр кешең, аркаланырлык туган-тумачаң, таныш-белешең булса икән!.. Асия — башка, ул үз ишен табар... Үзенә тиңне. Акча, фатир, машинага ия ыспай шәһәр егетләре азмы?! Боларның синдә кайсы бар?.. Булмаса — булачакмы?.. Һәм кайчан булачак? Үз чамаңны белү кирәк, Фидаил дус! Сания апа карар кылган, таныштырган дип кенә барып чыгарга охшамаган бу эш... Кыз — чибәрен чибәр, әмма ул башка берәү өчен туган, синең өчен түгел!..»

Ә шулай да Асияне ошаткан иде ул. Бик, бик-бик ошаткан иде. Мондый матур кызны әле гомерендә дә очратканы, күргәне булмагандыр аның. Аннары бит, гел битараф та түгел кебек ул аның үзенә... Юкса, чәчләренә кагылып, тузан кагар идемени? Ә нинди кайнар аның учлары!.. Тамак төбенә авыр төер килеп тыгылды, егетнең, чигәләре кызышты. Юк, еларга җыенмый иде ул. Фидаил күнеккән, язмышның беренче һәм соңгы сынавы гына түгел бу аның өчен. Кимсенү, кыерсытуларны аз күрмәгән, тамак төбенә тыгылган төерләрне дә аз йотарга туры килмәгәндер...

— Ә-ә-әй, син кая югалдың анда?.. Пәри кызларын очраттыңмы

эллә?— дигән чая тавыш ишетелде югарыга алып менгән баскыч ягыннан. Якты зәңгәр караштан күзләре чагылып китте Фидаилнең.

Сак кына атлап якынаеп ук килә иде инде кыз. Әледән-әле, маңгаена төшеп торган чәч кәдрәләренә өреп-өреп ала. Гәүдәләре чайкалып-чайкалып куя, иреннәре йомык. Йомык булсалар да, чык тамчылары кунгандай, елык-елык килә, көлә, елмая сыман үзләре. Кимсетергә теләп түгел, үз итеп, якын итеп елмаю иде булса кирәк бу...

Фидаилнең каршысына ук килеп басты Асия. Чүгәләде... Һәм өелеп торган себеркеләр өстенә утырды.

— Кара, монда җылы икән ич,— диде ул үзалдына. Фидаилнең чәченә кунган кипкән яфракларны үрелеп алды.— Үзеңә генә күңелсездер, дидем.

Кинәт, ул утырган себеркеләр ишелеп китте һәм кыз, җайсыз янтаеп, Фидаилнең кочагына авып төште. Егет аны тотып калды һәм күтәрергә итте. Күзләр очрашты шунда... Карашлары бер-беренә тартылды... Иреннәр калтыранды... Юк, хет үтер, бер-береннән читкә этәрелә алмадылар. Шайтан котырттымы, нинди дә булса башка бер-бер көч сихерләдеме үзләрен — тарту көче барын, хәтта дөньяларын оныттырды. Рәхәт урман исе, каен шавы, яфраклар кыштырдавы урап алган иде үзләрен... Дөнья матурлыгына, дөньяның камиллегенә исең-акылың китәрлек...

## 16

— Сәгать ничә икән?— дип сорады Арслан. Стенага таба борылып әле яңа гына йокыга киткән иде ул. Ни өчендер сәгать кирәк булган — тынгысызлана.

Өлгеләре капланмаган зур тәрәзәдән төшеп торган ай нурларыннан уңайсызланып, ябынып яткан ак җәймәне күкрәгенә тарта төшеп, өстәлгә үрелде Асия. Кармалана торгач, кулына ирләр сәгате эләкте. Ай яктысына каршы куеп, озак кына карап торды сәгатькә.

— Кемнән ояласың?

— Ай нурларыннан...

— Тапкансың!..

— Ай һәм йолдызлар бездән күбрәк күрә, беләсең килсә...

— Юкны сөйлисең, Асия. Сәгать ничәне күрсәтә анда?

— Әллә тагы,— диде хатын.— Бәхетлеләр сәгатькә карамый диләр түгелме?!

— Син бәхетлеме?

— Бергә чакта без икебез дә бәхетле, шулай бит, Арслан...

— Куй әле!.. Сәгатьне сорыйм ич.

— Уникенче ярты.

— Мине йокы баса башлады. Әллә нәрсә булган — күз йомыла, ә күңел йокламый.— Сөяркәсенә якынрак килеп ятты Арслан. Кулын аның шәрә җилкәсенә салды.— Тагы ун-унбиш минуттан торып киенергә кирәк булыр. Монда тәртип каты. Уникедә ишек һәм капкалар ачыла. Ә тагы ун минуттан Җантимер овчаркаларын бәйдән җибәрә, бернигә карамый. Кеше сүзенә колак салмый, сәгать механизмы кебек эшли ул безнең...

Йөзтүбән ятып, терсәкләренә таянды Асия. Арсланны күзәтә башлады. «Йоклый алмыйм ди, ә күзләре йомык»,— дип уйлап куйды үзалдына. Әнә, йоклаган вакытында да нинди мәһабәт аның арысланы, ир-ат халкында сирәк очрый торган кырыс матурлыкка ия бит ул. Бишенче дистәгә чыкканына да байтак икән үзенең, ындыр табагыдай киң маңгаенда — ник бер җыерчык, кәдрәләнеп торган чем-кара чәчләрендә ник бер чал бөртек булсын. Куе кара кашлар, үзенә килешеп торган кара мыек, яссы саллы ияк. Ияк очындагы сөйкемле уентык... Чәч кәдрәлә-

ре артына посып торган килешле колаклар... Уртачадан аз гына калкурак борын... Яратса да яратыр икән үзен табигать! Өстәвенә тагы, йоклаган чагында да үз дәрәҗәсен белеп, текә муенын туры тотуларына исең китәр... Тәрәзәдән шулай ай нурлары төшеп торса, ул аңарга черем дә итмиенчә төн ката сокланып утырырга әзер булыр иде. Шулай икәүдән-икәү генә кал иден дә гомер кичер идең аны... Сәгатькә дә карама, көнгә янсә төнгә дә карама, һәрчак бергә бул идең. Эшен һәм ирен дә онытырга әзер булыр иде ул. Хәер, болай да искә алмый ул аларны аның белән янәшә булган чакларында. Хәтта бердәнбер улын да оныта... Арслан гына исән булсын, аның арысланы...

— Бераз шампан кабып алмыйбызмы?— Күзләре йомык булса да, мыек астыннан чыккан бу сүзләрне Арслан әйтте.

— Төн куна каласы булсак, риза,— диде хатын, сөйгәненең күзләре йомык чакта да үзе хакында онытмавына куанып.

— Нәрсә, ирең өйдә түгелмени?

— Булса соң!..

— Колагыңнан борыр.

— Бормас... Ул синең кебек усал түгел,— диде хатын. Үз шаяруын юарга теләгәндәй, ирен очы белән арысланын үбеп алды сак кына.

— Көнләшмиме?

— Көнләшми, ышана...

— Димәк, ышандыра беләсең... Оста ялганлыйсың.

— Ялгансыз булмый торгандыр...

Стенага таба борылып ятты Арслан, юрган эченә җыелып, бөгәрләнеп ятты:

— Сезнең халыкка артык ышанырга да ярамый шул.

— Син булсаң, миңа ышанмас идеңме?

— Мин сине асып куяр идем!

— Нәрсә-ә-ә?!.

— Асып куяр идем, дидем. Бәхетең, минем хатын булмагансың.

— Кызганмас идеңме?..

— Әйтә алмыйм... Синең ирең хәленә кереп караганым юк!

— Үзеңә-үзең артык ышанмыйсыңмы, дустым,— диде хатын, елмаерга итенеп. Һәм Арсланның ачыла төшкән аркасыннан чәбәкләп алды.

— Җитәр... Йокларга бирмисең!

— Өеңә кайткач, хатының янына яткач йокларсың, ярыймы, арысланым...— Хатын җәт кенә сөйгәне өстендәге юрганны ачып атты.

— Каныкма әле... Нишлисең син?!.

— Син яратмыйсың мине... Шуңа ышанмыйсың да.

— Яратам. Ләкин ышанмыйм.

— Ә бергә яши башлагач ышанырсыңмы?..

Моңарчы кояш нурларында кызынган бохар песиедәй изрәп яткан Арслан иренеп кенә күзләрен ачты: «Нәрсә сөйли?.. Чынлап хыяллана мы әллә ул?..» Һәм, еларга җыенган сабыйны юаткандай, Асияне чәчләреннән, шәрә иңбашларыннан сыйпап алды.

— Алмаган ат. Тумаган колын. Атланма, улым, билен сындырырсың, диләр, Асия...

Беразга тынлык урнашты... Арсланның күкрәгенә башын куеп, стенага эленгән натюрмортка күз төшереп алды Асия. Миләш тармаклары, гөмбә тулы кәрҗин, пычак һәм бер шешә аракы төшерелгән иде анда. Ай нурларында һәммәсе аермачык күренеп тора. Хәтта аракы шешәсенә ябыштырылган кәгазьдәге «Столичная» дигән язуына кадәр укырлык. Миләш тармаклары... Гөмбәләр... Пычак... Аракы шешәсе... Шешәсез натюрморт булмыйдыр, күрәсең, балалар өчен дип җиткерелгән пансионатка шундый рәсем элмәсләр иде.

Үзенең бу уйларын Арслан белән уртаклашып тормады, борчыйсы килмәде аны. Көнелне кузгаткан вакыйгалар бүген болай да җитәрлек

иде бит. Мисал өчен, классташы Юлия белән очраштылар — менә сиңа очрашу! Ул аны еш искә ала торган иде. Аның ничек яшәгәнлеген, ничек киенгәнен күрәсе килгән чаклары булды. Юлия аның күңеленә мәктәп елларыннан ук бер борчусыз, рәхәт яшәүче бәхетле кыз булып кереп калган. Соклана иде ул аңарга һәм көнләшә иде... Бер карасаң, Юлия әле дә шул ук, аны-моны уйламыйча, борчу-хәсрәтсез чырык-чырык килеп яшәвендә дәвам итә икән. Шәһәрнең бик атаклы галименә тормышка чыккан дип ишеткәч, ул аны эреләнгән, борынын югары чөеп кенә йөри торган ханымдыр дип күз алдына китерә иде... Ә Капкаев? Монысы хикмәт дисәң дә хикмәт инде. Исең-акылың китәр, мәктәптә беренче булган Юлия шул Капкаев белән йөрсен инде! Юлиядән дә бәхетле кеше юк диярсең!.. Дөньясын оныткан.

Юлия дә күрше бүлмәләрнең берсендә ич хәзер. Авызын жыя алмый торган шул җәенке борын белән ни хакында сөйләшәләр икән... Әлбәттә, үзен бик, бик тә кызыксындырган бу сорауга Асия бервакытта да җавап таба алмас. Укучы каршы килмәсә, без ул якка да күз салып алабыз.

Капкаевлар оялаган бүлмә. Шәрә ботын ботка куеп, өстәл каршысында Юлия тәмәке тартып утыра. Капкаев караватка сузылып яткан, ул да авызыннан тәтен өрә. Юлия нидәндер канәгать түгел ахры:

— Без, Капкаев, алай да килешмәгән идек синең белән... Яраткан җирдә бурычка кермиләр... Юкса, исеңдә тот: мин — сине, син мине белмәячәкбез!

— Соң, Юлия, әле кайчан гына үзеңә тун бүләк иткән идем...

— Бәлки син, тотып килгән чәчәкләреңне дә язып барасыңдыр, ә, Капкаев?!

— Соң, Юлия, бөтен кибет сиңа эшли бит инде болай да... Бар тапканым — сиңа китә... Дусларга...

— Дусларыңда минем эшем юк, Капкаев. Шуны гына киртләп куй колагыңа: байыйсың килә икән — очрашмыйбыз башка! Шулай хәл итәбез.

— Ашыкма әле... Син алай тиз генә хәл итмә әле, Юлия. Соң, синсез мин нишләрмен?..

— Бу хакта башка сөйләшмибез, Капкаев! Ә мин ни эшләргә кирәклеген беләм.

— Нәрсә беләсең?

— Базардан үзеңә очсызракны эзләрсең, ярыймы, матурым... Синең буш вәгъдәләреңнән туйдым, җитәр.

— Юлия... Йә инде, Юлия,— дип, сузылып, хатынның түгәрәк шәрә ботларыннан сак кына сыйпамакчы иде Капкаев. Тегесе өлгеррәк булып чыкты: читкә тайпылып, Капкаевның кулына төкерде.

— Әнә,— дип, чөйдәге киемнәренә күрсәтте ул.— Йә хәзер үк кесәгә саласың, йә миңа тырнак очың белән дә ягылмыйсың бүтән. Ярыймы, матурым!..

— Ашыкма, Юлия, ул тикле акчаны ничек инде мин кесәмдә йөртим. Син бит артык күп сорыйсың... Бирәү дә чыгармый мин чыгарган акчаны... Лев Белялович булып, ул да...

— Һе,— дип, сигаретына төкереп, идәнгә ыргытты Юлия.— Акчаңны кызгансаң, бар, син дә аның кебек үк вобла кимереп йөр, кипкән балык суыр!.. Ихтыярың, Капкаев!

Тирән сулыш алды Капкаев. Сирәк тешләре арасыннан саркылып төтен чыкты аның... Уйлап ятты-ятты да, бетән баш беткән диган сыман, тәвәккәлләп урыныннан сикереп торды.

...Гомере озын булыр, шул мизгелдә Асия дә Капкаев белән кызыксынып, сорау бирде Арсланга:

— Ул Капкаев дигән кеше кайда эшли?

— Гастроном директоры.

Аңлашылды, дигән сыман, ireннәрен турсайтып, баш кагып куйды Асия. Юлия юкка гына вакыт уздырмас шул...
— Ә Борис дигәне?
— Ул — халык контроле,— диде Арслан иренеп кенә. Йокымсыравында дәвам итә иде әле ул.
— Ә түм-түгәрәге?.. Түгәрәк арыслан...
— Телеңә салынма, Асия! Үлчәп сөйләш!..— диде ул, сискәнүне хәтерләткән кискен хәрәкәт ясап. Шаярасыңмы, әллә чынлапмы, дигән сыман, сөяркәсенең күзләренә карады.
— Әллә зур шишкамы?..
— Җитәр, Асия!— диде Арслан пышылдауга күчеп.— Мин сиңа шуны әйтим, җыен юк-бар белән кызыксына торган гадәтеңне ташла!.. Бала-чага булып уйнама!
— Уйнамыйм... Кызыксынам гына, Арслан.— Бу юлы ул, гадәтенчә, йомшак һәм ягымлы итеп дәште.
Арсланның йокысы тәмам качкан иде инде. Асиянең күзләренә текәлеп карады ул:
— Асия, монда кемнең кайда эшләвен ачыклау өчен түгел, ял итәргә... Кабатлап әйтәм, ял итәргә киләләр.
— Ял итәргә...— дип, уйга калды хатын, сөйгәне авызыннан чыккан сүзләрне янә бер кат барлап.
— Сиңа ошамады ахры?..
— Ошады. Искиткеч урын, урман... күл,— һәм шул урында үзалдына көлемсерәп алды.— Арысланнар һәм кенәриләр... Бүген генә үземнең кенәри икәнлегемне белдем!
— Ярар, ташла! Шаярып әйтелгән сүз генә... Кенәри — читлек кошы. Ә сез — иреклеләр. Ирекле затлар...
— Ә мин үпкәләмим. Хак сүзгә үпкә белдермиләр.
Кинәт канәгать көлемсерәп куйды Арслан. Ирен читләренә, иякләренә мин-минлек чигелеше кунды:
— Барысының да арыслан буласы киләме?.. Ха-а!..
— Мине тагы чакырырсыңмы соң монда?
— Тәртибеңә карарбыз!
— Хатының булгач та калдырмассыңмы?
Сорауның монысы көтелмәгән булды кебек, җавап бирергә белми уйга калып торды Арслан. Шулай да, тәвәккәлләп, турысын әйтергә булды:
— Монда газиз хатыннарны алып йөрмиләр йөрүен,— диде ул. Шулай да, кистереп кенә кире дә какмады — ике төрле уйлар өчен урын калдырды. Әңгәмәне дә артык дәвам итәргә җыенмавы аермачык иде, күзен сәгатькә төшереп алды, Асияне дә ашыктырырга кереште.
Кунаклар һәммәсе дә алгы бүлмәдә җыелышканнар иде инде. Лев Беляловнч Капкаевка мөрәҗәгать итте:
— Җырлыйсыңмы әллә берне?
Капкаевның кәефләр артык шәптән күренми, шулай да ул «шеф» сораганда баш тартырга күнекмәгән. Гаепле кеше сыман, Юлия тарафына күз салып алды ул: «Җырлыйммы?» дип киңәшүе иде булса кирәк. Ә Юлия, эре генә, иреннәрен турсайтып куйды: «Синең авызга мин хуҗа түгел, ихтыярың», янәсе.
Авыз гармунын чыгарып, бер кычкыртты да җырлап җибәрде Капкаев. Кәеф төшенкелеге булмаган диярсең:

Барган идем Әсмаларга,
Кер чайкый басмаларда,
Барыбер сөям шул Әсманы —
Колактан ассалар да...

Күкрәкләрен киереп, башын артка ташлап, иң элек Лев Беляловнч дөньясын онытып көлеп җибәрде, гомер ишетмәгән мәзәккә

юлыккан диярсең. Аның ачык түшеннән ишелеп чыккан корсагына ышкылып, кенәрие Гуля-Гөлсинә сикергәләп алды. Башкалар да көлгән атлы булды — зур хуҗа көлгәндә, берүзең читтә калу килешми, әлбәттә.

— Ну-у, Капкаев,— дип, дәртләнеп китеп, җырлаучының маңгаеннан барып үпте «Түгәрәк».— Талант! Чын тала-а-ант бар синдә... Синең репертуар белән югалмаска була!— Янә бер кат кулын кысты ул аның һәм әйләнә-тирәдәгеләргә мөрәҗәгать итте.— Сәгать ничәне күрсәтә?

— Тагы ике минут ярым бар әле,— диде Арслан, өлгерлек күрсәтеп.

Сәгатьләренә башкалар да карашып алды һәм һәркайсы үз сәгате күрсәткән вакыт турында хәбәр итте. Берәүдә тулы өч минут булса, икенче берсендә минут ярым гына калып бара икән инде. Шулай да вакыт бар икән әле...

Кемнең сәгате дөрес дигән бәхәсне, билгеле инде, янә дә килеп Лев Беляловнч йомгаклады, түгәрәкләп куйды:

— Бәхәсләшмәгез, иң төгәл вакыт...— мәгънәле пауза ясап алды ул.— Иң төгәл вакыт кемдә дип уйлыйсыз?

— Сездә... Миндә...— дигән бигүк аек булмаган җаваплар ишетелде.

— Түгел! Төгәл вакыт бер генә монда — Җантимердә. Ул кайчан әйтә — шунда кузгалабыз. Җантимер хаталанмый! Җантимер сәгать механизмы кебек эшли безнең!

Көлештеләр. Дөрес-дөрес, диештеләр. Шефларның тапкырлыгына сокландылар. Ә Гуля-Гөлсинә «Түгәрәк»нең иреннән үк үбеп алды: «Монда мин дә бар әле, мине дә исәптән төшермәгез... Хуҗагыз бүген минеке...»— дия иде ул гүя.

Лев Беляловичның кәеф тагы күтәрелде, бит алмалары алсуланып, иреннәре җәелеп китте. Көләчлегенең чиге-чамасы юк иде.

— Капкаев,— дип әйтеп салды ул кәеф күтәренкелегеннән канатланып очып китәрдәй булып.— Тагы берне җырлап җибәрәсеңме әллә, әйдә булмаса, Капкаев!

Башын салындырып, бер читкә китеп баскан Капкаев сискәнеп куйды, җитди уйларыннан бүлдерделәр ахры:

— Нәрсә?..— диде, сорауны аңлап бетермичә.

Рәхәтләнеп онытылып көлеп алды Гуля-Гөлсинә, аның бу уңайсыз хәлдә калуын күреп. Ә Юлия исә иреннәрен генә турсайтты.

— Җырлыйк булмаса...

«Түгәрәк»нең әйтеп бетерүе булды, Капкаевның авызында гармун иде инде. Таныш аккорд һәм таныш сүзләр кабатланды:

> Барган идем Әсмаларга,
> Кер чайкый басмаларда,
> Барыбер сөям шул Әсманы —
> Колактан ас...

Җырын тәмамларга өлгермәде Капкаев, тышкы яктан шалтырап йозаклар ачыла башлады. Гуля-Гөлсинә, сикергәләп, кулын чәбәкләргә керешге:

— Ур-ра, минеке дөрес, минем сәгать дөрес!.. Төгәл унике тулды!

Онытылып, йокымсырап, яңа танышларын, әлеге сәер кешеләрне күзәтеп торган Асиягә гел юктан гына эсселе-суыклы булып китте шунда. Сәбәбен үзе дә аңлый алмады, әмма зеңләп нидер өзелгәндәй булды күңелендә. Шундый матур, күңелле кич булды, югыйсә... Җаны үз иткән Арслан янында булды. Ә барыбер, күңелдә ниндидер кыл зеңгелдәде... Ишек аръягындагы шомлы дөнья, сәер каравылчыны хәтерләдеме ул, аңышырга өлгермәде, әмер ишетелде:

— Иң элек сез кузгаласыз, Арслан Сәхипович...

«Ә нигә без?— дигән сорау чыңлап куйды Асиянең чигә читендә.— Нигә башкалар түгел? Әйтик, Капкаев белән Юлия яисә Борислар?»... Шунда «Түгәрәк»нең, юмарт елмаеп, үзе артыннан карап калуын той-

ды Асия, һәм шул караш аның тәненә беркадәр җан иңдерде... Ә башкаларның аларда гаме юк иде, хушлашырга да теләмәделәр хәтта. Бу битарафлык шулай ук сәер тоелды — арысланнар һәм кенәриләр дөньясының үз тәртипләре бар иде, күрәсең...

Юлия бөтенләй аркасы белән борылып басты. Кулларын болгыйболгый, Капкаевка нәрсәдер төшендерергә азаплана иде ул. Ә тегесе, әйтерсең лә кипкән каен әкәе, гел бөкшәеп калган, ниндидер хәлиткеч карарга кылә алмый тинтерәгән. Борислар бер як читтәге урындыкларга кунаклаган, тыныч кына, мыш-мыш килеп, ирен ялашалар. Гуля-Гөлсинә үз авызыннан чыккан сигарет төтененең ни рәвешле бөжра-бөжра булып түшәмгә күтәрелүен онытылып күзәтә.

Асия белән Арслан атлап узган сукмакка биек наратлар артына поскан шымчы Ай нурлары гына төшеп тора. Үз арысланына сыена төшеп, артка калудан җан калтырап, ашыгып-кабаланып атлады Асия. Күзияләшә төшкәч, як-якларында тезелеп киткән чәчәк түтәлләрен күрде. Арырак, эшләпә киеп юлга якынлашып килгән юлбасарлар сыман, гөмбәчекләр торып калды. Менә-менә кузгалып китәрләр дә каршыларына йөгереп чыгарлар, йә булмаса куа килерләр төсле тоелды алар.

Капкага җитәрәк, өрми дә, селкенми дә, баскан урыннарында муеннарын бора төшеп, ике овчарка шәүләсе озатып калды. Тимер капканың аргы ягында аларны китергән машина шәйләнде.

— Башкалар ничек кайта соң?.. Аларга машина буламы?

— Башка кайгың булмаса, борчылма!

— Безнең янда урын кала бит әле дип әйтүем...

— Җантимер оештырган эш таркалмас, Асия. Барысы да сәгать механизмы кебек төгәл монда...

— Җантимер дә мондамы?

— Тагы сораулар бирә башладың!.. Җантимер анда да, монда да. Асия, башыңны юкка катырма.

Арткы ишек ачылгач та, иң элек Асия керде, аның янәшәсенә — Арслан... «Волга», үкереп, урыныннан кузгалды. Шунда гына бер читтә үзләрен күзәтеп торган кара шәүләнең, кул фонаре яктыртып, чираттагы машинага булса кирәк, сигнал бирүен күреп калды Асия. Һәм, ниһаять, үзенең бу шом тулы кара урман эченнән исән-сау китеп котылуына ышанып булса кирәк, авыз-борын аша сулыш алып куйды.

Урман эчендәге борылмалардан, ярыш автомобиле сыман, зур тизлек белән куып китте машина. Куып барган көйгә, кинәт сызгыртып, тормозга басу дисеңме, шул арада янә алгы аякларын чөеп кузгалган аргамактай ыргылумы — мондый тизлек, тавыш һәм киеренкелекне, күрсә дә, бары детектив киноларда гына күргәне булгандыр Асиянең... Гомумән, машинада зур тизлек белән йөргәнне яратмый иде ул, шуңа таксига да бик сирәк очракларда, башка чарасы булмаганда утыра. Ә монда... Шоферның кыланышларына күз иярерлек түгел. Ирексездән, бар гәүдәсе белән үз арысланына сыена барды ул һаман.

— Кая ашыга ул шулай?.. Әллә артына ут капканмы?.. Эчкәнме әллә?— дип Арысланның үзенә генә ишетелерлек итеп пышылдап алырга да өлгерде.

— Шофер үзе белә...

Арсланның да аны тынычландырыр арасы юк иде: бер кулы белән чәтердәп — югарыдагы тоткычка, икенчесе белән Асиягә ябышкан. Як-якта шомлы кара урман. Алда — сикәлтәле, бормалы юл. Ә аркаларын шундый ук тизлек белән куып килгән икенче бер автомобильнең фаралары ялый. Күңеленнән үзенчә нәтиҗә ясады Асия: шофер үзләрен куып килгән машинага тоттырырга теләми, шуңа ашыга, кабалана булса кирәк. Күрәсең, машиналар янәшә барырга тиешле түгел бу юлда, ул машиналарның шоферлары да очрашырга тиешле күренми. Ә бәлки, күрше машинада кемнәр икәнлеге сер булып калырга тиешледер? Үзләрен озатып калган Җантимер юкка гына берәм-берәм чакырып, ае-

рым-аерым озатып калмагандыр бит аларны. Сер өстенә сер, кая инде ул Асиягә шуларның һәммәсен үтәдән күрү...

Саграк йөргәндә дә зыян итмәс иде бит аңарга — улы бар. Арслан белән бергә чакта улын сирәк искә төшерә иде ул; ә бүген, ни өчендер, аны да уйлап-хәтерләп куйды. Үзе генә түгел, бала хакына да кирәк икән ич әле аның сәламәт булуы. Икенче уйласаң, хафаланырга да урын күренми, янәшәсендә — Арслан. Тагы, күп булса, ярты сәгать булырлар юлда, шәһәргә кайтып җитәрләр һәм икесе ике якка китеп аерылырлар. Кайчан очрашасыларын да белми аерыла алар. Арслан китеп барыр; ә ул, улын кочаклап, йокыга ятар. Янәшәсендә... Хәер, Арслан белән бергә минутларын шулай кадерсезләргә ярыймы соң инде?! Вокзалда сөйгәнен озаткан кеше сыман, комсызланып, аның кочагына ташланды ул, аның иреннәренә сарылды...

Олы юлга чыккач, арлы-бирле үтеп торган машиналар арасында алар утырган «Волга» эреп югалгандай булды. Шофер да тизлекне киметте, ипле генә кайтуын дәвам итте. Асия дә, ниһаять, иркен сулыш алды. Арслан, баш очындагы каеш тоткага ябышкан кулын бушатып, янәшәсендә сөйгәне утырып кайтканлыкны искә төшерде. Бер кулы белән аның биленнән сак кына кочаклап алды ул, икенчесен күлмәк аша беленеп торган тыгыз бот өстенә шудырды... Шулчак, Арслан урынында икенче берәү булып, кулларына әлегедәй ирек куйса, көт тә тор, ул әрсезнең яңагыннан утлар чәчрәр иде. Ә Арсланның һәр хәрәкәте Асия тарафыннан наз, иркәләү буларак кабул ителде. Чөнки ул — аның бердәнбере...

Күзләрен мөлдерәтеп, карашы белән иләсләндерерлек итеп карап куйды ул Арсланга, аның кочагына янә дә сыена төште. Бердәнберем, арысланым син минем, дип әйтүе иде бу аның.

Шунда, һич көтмәгәндә, шофер егетнең мыгырданганы ишетелеп калды. Аның машинада булуы, барлыгы гел онытылган иде инде.

— Нәрсә булган?.. Шашканнар инде әллә?!

Арслан кыюлана барган кулын тартып алды. Асия, сискәнеп, читкәрәк тайпылды, бердәнберенә текәлде: бу ни дигән сүз инде бу? Арслан да югалып калган иде: чынлап та, кемгә дәшә соң бу шофер егет?.. Әллә йокларга җыена, саташамы?!

Ул да түгел, шоферның күзе сул яктагы тәрәзәдә булуын чамалап өлгерделәр. Хәтта кемгәдер бармак та янаган кебек булды ул. Аларга адресланган сүз булмады, димәк. Арсланга киредән сыена төшеп, шофер бармак янаган машинага күз төшереп алды ул. Һәм җан керде:

— Юлия... Капкаев...— дип, утырган җиреннән талпынып китте. Чаяланып, үзләре белән гел янәшә үк барган машинага бармак аша ирен сәламе тапшырып елмайды. Юлның як-ягына тезелгән баганалардан төшеп торган тонык ут яктысында Капкаев белән Юлиянең ян тәрәзәгә сыланган йөзләре аермачык танылырлык иде. Икесе дә бәхеткә күмелгән: килешкәннәр, димәк...

— Нәрсә, тилергәннәрме әллә!— дип мыгырданучы Арслан иде бу юлы. Янәшә барган машина, чынлап та, узарга да, калышырга да теләми, магнитланган сыман тартыла, якыная гына бара иде аларга. Байтак ара бардылар янәшә. Каршы яктан прицеплы КамАЗ күренгәч кенә калышырга, юл бирергә мәҗбүр булдылар. Шул мизгелдән файдаланып, бу уенны күңеле өнәп бетермәгән Арслан шоферына әмер бирде:

— Әйдә, кызулый төш!

Машина алга ыргылды. Ләкин, тегесе дә калышырга җыенмый, анасы тирәли чабышлы уйнаган колын сыман, янә килеп басты. Арткы рәттә кочаклашкан көйгә тәрәзәгә сыланган пассажирлар, куыш-узыш дәртенә кереп, баягыдан да бәхетлерәк елмая, куллары белән ян тәрәзәне төяләр иде инде.

— Акрынайт, узсыннар,— диде Арслан. Бу уен теңкәсенә тия башлаган иде инде аның.

Лəкин тегеләр дә тизлекне киметә төште, ашыкмадылар. Ике «Волга» җитәкләшкән сыман янәшә баруларын дәвам итте.

Моны күреп торган Арсланның кәеф кырылды:

— Торгаш!.. Юка баш!..— дип, Капкаевны эттән алып, эткә салып сүкте.

— Шаяралар гына бит... Юкка хафаланма, Арслан,— дип аны тынычландырырга ашыкты Асия. Үзенә дә кызык булып киткән иде әлеге куышлы уен. «Пәп» итеп, арысланын үбеп тә куйды.— Шаярсыннар, әйдә...

— Юл — мич башы түгел! Юлда шаярмыйлар. Шуны аңларга акылы җитми юкабашның!..

Янә, тынгысызлануын дәвам иткән арысланын тынычландырасы килеп, иреннәрен эшкә җикте Асия. Ягымлы һәм йомшак итеп аны баш-аркаларыннан кочып үпте:

— Капкаев мәзәк кеше инде... Син аны ачуланма, Арслан...

Хатын-кыз кайгыртучанлыгы ир-атка тәэсирсез калмый, тәрәзәгә битарафлык күрсәтергә дигән карарга килде Арслан. Күрмәгәнгә сабыш-салар, йә узып китәрләр, йә калышырлар әле бер... Асияне ике куллап кочаклап ук алды.

Лəкин, ул уйлаганча килеп чыкмады. Күп тә узмады, кинәт, кискен хәрәкәт ясап, тормозга басарга мәҗбүр булган шофер аты юлы белән сүгенеп үк җибәрде. Дүрт тәгәрмәч ачы чыелдау авазы чыгарып байтак кына шуып барды. Кювет читенә терәлеп янтая башлаган машина аздан аумый калды.

— Шакаллар! — дип кычкыра алды агарынып каткан Арслан. Асияне кочаклаган куллары салынып төште.

— Дөнья белән хушлашкан идек... Бәхетебез, тизлекне киметкән чак булды,— дип, уң яктагы тирән чокырга ымлады шофер, ниһаять, тирән сулыш алып.

Очраклы рәвештә, Арсланның кочагында көе генә, күзен янәшәдәге машинага төбәп алган Асия шулай ук тынсыз-өнсез калган иде. Көтмәгәндә тизлеген арттырып каршыларына чыккан һәм, үзләре утырган машинаны читкә тибәреп, артын уйнатып китеп барган кара «Волга»ны аермачык күреп калды ул. Шул мизгелдә яшен ташы сыман нидер телеп үтте аның чигәсен. «Ах!» дип кычкырырга ачылган авызыннан сүз чыкмады. Таныды... Номерларына кадәр аермачык күрде һәм хәтерләп калды әлеге машинаны: Фидаил бу, Фидаил! Ул йортта торган машина!.. Димәк, руль артында аның ире булган — башка сыймаслык хәл!.. Каян килеп чыккан ул монда?! Капкаев белән Юлиягә аның нинди мөнәсәбәте бар?.. Менә сиңа мә — очрашу...

## 17

Төнозын күзләренә йокы иңмәде Фидаилнең. Бүлмәләренә кайтып кергәч, ут та кабызып тормады, креслога барып ауды. Асия өйдә юк. Хәер, каян килеп өйдә булсын, үз күзләре алдамагандыр ич... Әле дә булса бөтен тәне дер калтырый. Күкрәк читлегенә сыеша алмаган йөрәк, субай кагалармыни, дөп-дөп... дөп-дөп килә — тынычланырга уенда да юк. Үз-үзен кулга алырга теләп, чигәләрен ике уч төбенә салды да хәрәкәтсез калырга тырышты Фидаил.

Нәрсә булды?.. Дөньялары шундый ипле, матур иде ич әле... Ничек болай килеп чыкты соң бу?.. Өнеме, әллә соң төштә генәме болар?! Чига чынлый, чигә кыса... Ничек, ни рәвешле башка сыйдырырга боларны? Үз күзләре белән күргән, үзенең күз алдында булып узган вакыйгаларны хәтерләргә, барларга тырышты Фидаил. Нинди барлау, нинди хәтерләү, онытыйм дисә дә — арына алмый, арына алмаячак ич ул әлеге шул

тетрәндергеч мизгелләрдән. Әмма барысын да эзлекле итеп күздән кичерү, рәтен-рәткә салып бәяләү дә мөмкин түгел. Берсе өстенә икенчесе менеп тартыша башындагы уйлар...

Эче пошып, бер юаныч тапмаммы дигән өмет белән, каршысында торган телевизор кнопкасына басты. Тын бүлмәгә тоньк зәңгәр яктылык таралды һәм, кызган күмергә су сипкәндәгедәй чыжылдау авазы ишетелә башлап, шул тавыш көчәйгәннән-көчәя барды. Телевизорда берни дә юк һәм булмаячак та иде — вакыты узган. Төн уртасы узып барганда нинди телевизор?! Сүндерде. Зәңгәр яктылык сүнде, әмма чыжылдау авазы колак очында эленеп калды... Әллә чигә кысуыннан баш шаулыймы шулай?..

Аларның бу бүлмәсендә, креслога килеп утырсаң, урыныңнан тормый гына да һәр почмакка үрелеп җитәргә мөмкин. Кулын сузып, суыткыч ишеген ачып җибәрде. Сусавын басар, җанын тынычландырырдай бер-бер әчемлек-фәлән табу иде нияте. Әмма целлофан капчыкка төрелгән сөяк кисәге, берничә йомырка һәм шешә төбендә калган көнбагыш маеннан тыш әйбер юк иде анда. Әйтерсең, суыткыч гаепле аларның шулай яшәвенә — аягы белән генә шапылдатып япты ул аның ишеген.

Креслода сузылып, киерелеп алды, башын артка ташлап, чигәләрен кыскалады. Нәрсәдән, ни сәбәпле килеп чыкты соң әле бу?.. Барысын да үз тәртибе белән һәм яңабаштан барларга кереште.

Фидаил Капкаевны бер бүген генә белми, хуҗасының күптәнге әшнәсе ул. Кирәкләре чыкканда бер-беренә ярдәм итешеп яшиләр. Әллә кем үк булмаса да, гастроном директорының да бер чыкмаса, бер чыга аның кирәге. Кунак-төшем булганда, бәйрәм якынлашканда, хуҗасы юньле азык-төлекне аңардан ала. Затлы колбаса, маркалы вино, ысланган балык, икраның карасы һәм кызылы салынган тартмаларны Капкаев кабинетыннан бер генә тапкыр күтәреп алып чыгарга туры килмәде Фидаилнең үзенә дә.

Ә инде төзү материалларына ихтыяҗ туса, аның хуҗасы янына Капкаев үзе килеп җитә. Магазинын җиһазларга кирәкме? Кирәк! Каян тапсын, бер җирдә дә «мә» дип сузып тормыйлар андый яхшы, затлы төзү материалын. Капкаев өчен табыла, чөнки аның кара уылдыгы һәм ысланган балыгы бар. Өй ремонтларга кирәк! Дача җиһазларга кирәк! Дефицитың булгач, бары да бар, һәммәсе табыла. Дефицитың юк икән, кайтарып бирер әйберең юк икән, ник шунда министр булмыйсың — кадак та таба алмый аптыравың ихтимал. Дөньяның әнә шул яклары бар ич аның.

Капкаевныкы кебек җиһазланган кабинет булмас, эзләмәгез. Кара уылдык, ысланган балык табармын дип тә өметләнмәгез башка кибетләрдән. Файдасыз! Дефицитның бер билгеле урыны була аның... Әйе, төзү материалларында тукталып калган идек. Гастроном директорының әле аның төзү кирәк-яракларыннан тыш та үтенече төшә торган була. Дөреслек юк инде ул... Булса, гастроном директорларына персональ машина бирерләр иде аны. Дөреслек юк! Мисал өчен, культура министрын гына алыйк... Нәрсә таба ала ул? Һәм, гомумән, теленнән башка нәрсәсе бар аның? Ә гастроном директоры — зур кеше. Зурлыктан да бигрәк кирәкле кеше! Чөнки, һәркемнең авызы бар, авызы бар кеше ашамыйча тормый. Ашыйсы килгән кеше кая бара? Гастрономга! Шулай булгач, гастроном директоры булган кешегә ничек итеп яшәргә кирәк бу дөньяда? Юк ул дөреслек!.. Җәяү йөрергә тиешме ул, йә булмаса, завод-фабрика эшчеләре рәтендә трамвай, троллейбусларда этенеп-төртенеп иза чиксенме?! Йөрми, әлбәттә, этенми-төртенми... Бөтен таныш-белеше — «зам»нар, «пом»нар, цех җитәкчеләре — махсус машинада йөргәндә аңа ни кала?!.

Гастроном директоры гына түгел, ашханә һәм склад мөдирләре, баш бухгалтер, базар директоры, хәтта ит чабучыларга кадәр махсус машинада җилдерә. Тегеннән таба, моннан таба. Инде тегеннән дә, моннан

да таба алмаса, соң чиктә бер-бер шәхси машина иясен, таксистны булса да җайлый-иялә штерә.

Бигрәк тә үзләренең сәүдә оешмаларына — торгка киңәшмә ише нәрсәгә барганда җәяү йөрүдән бик гарьләнә иде Капкаев. Бу хакта Фидаилгә үзенең сөйләгәне бар:

— Җәяү йөргән кибет директорын кешегә дә санамыйлар аны. Үзең уйлап кара: һәммә директорлар махсус машинага утырып килгәндә, ничек итеп инде берүзең теркен-теркен җәяү йөрергә мөмкин?! Иң элек, үз ишләрең кычкырып көлә. Аннан килеп, житәкчеләрнең дә «үзенә бер транспорт та көйли алмагач, бу кем инде?» дип уйлавы мөмкин. Әйтүен әйтмәсәләр дә, борыннарын гына җыерып сөйләшәләр... Тагы бит әле коллектив та бар! Сатучылар каршындагы авторитет!.. Ишек төбенә машинада сызгыртып килеп туктарлык рәтең дә булмагач, синең белән кем хисаплашсын да кем санлашсын инде?! Хатын-кызның да күзе чос була андыйларга... Кыскасы, Фидаил дус, мин уйлап чыгармаган, дөньяның аның үз тәртибе шулай,— дип, тәм табып, авызларын чәпелдәтә-чәпелдәтә сөйләгән иде Капкаев.— Син менә күзәтеп йөр әле: һәр сишәмбе район, исполком биналарында иртән сәгать-сәгать ярымлык киңәшмә сыман нәрсәләр була. Шунда җыелып торган машиналарга күз сал. Очыкырые юк машинаның. Ә санап чыксаң, закон буенча бирсенә дә машина каралмаган... Тәк-чту, Фидаил дус, балык башыннан бозыла дип юкка әйтмәгәннәр аны...

Дөрес, Капкаевны бер Фидаил генә йөртми. Үз машинасы булган бер доценты бар аның. Һәм дә килеп, махсус таксисты да бар. Доцентның да, таксистның да тамак бар, балалары ашарга сорый. Тәмле ашыйсы килүчеләр бар ул, ник булмасын!.. Шулай да, җаваплы йомышлары төшсә, бигрәк тә чибәр туташ һәм ханымнар тирәсенә барасы булса, Капкаев Фидаилнең хуҗасына мөрәҗәгать итә.

— Такси — такси инде ул, доцентның машина шөкәтсез, иске мәскәвич. Интеллигент халкына бик ышанып та булмый, тамагы туйса, гастроном директорын гына түгел, анасын да сатар...— дип сөйләнә иде Капкаев. Ә Фидаилгә ышана.

Бүген дә, әле иртән үк, хуҗасы кисәтеп куйган иде Фидаилне:

— Өйләдән соң Капкаевка барырсың,— дигән иде.

Хуҗасы әйткәч, шоферга ни кала — буйсынмый чарасы юк. Житәкчене йөртүче шоферның һәр боерыкка «җә» һәм «ярар»дан башка җавабы булырга мөмкин түгел. Тыңламыйсың икән, башка эш урыны эзләргә кала... Ә Фидаилнең бар карап торганы — хуҗасы. Башкаларныкы кебек, әти-әнисе дә, туган-тумачасы да юк аның кайгыртып торырга. Шул хуҗаның авызына карап яшәп яткан көне. Өйләнгәч тә, яхшымы-яманмы, зур булмаса да үзеңнеке булыр дип, тулай торактан менә шушы бүлмәне җүнәтеп бирде. «Боерган булса, тагы бер-ике елдан аерым фатир җаен карарбыз», дип тә өметләндерә иде. Кулны — кул, ике кул битне юа, дип юкка гына әйтми торганнардыр. Төзелештә, йә булмаса йөк машинасында эшләп, бар, хыялланып кара син дүрт-биш ел эчендә аерым фатирлы булу турында.

Төштән соң, хуҗасы кушканча, Капкаевның эшенә барды Фидаил. Кибет директоры аның кулына адрес тоттырды. «Шунда сине шундыйшундый бер асыл кош — «кенәри» көтеп торыр», диде. Барып, шул «кенәри» дигәннәрен утыртып килде Фидаил. Аннан Капкаевның үзен алырга кагылды. Йөкчеләр багажникка тартма-тартма ашамлык-эчемлек төяделәр. Аккош күле читендәге ярымутрауга барып кайтты. Беренче кат кына йөргән юлы түгел. Кайтышлый, балалар бакчасына кагылып, улы Алмазны алды. Җәт кенә аны әбиләренә кертеп чыкты. Асия икенче сменада эшләгәндә ул ала баланы һәрчак. Балалар бакчасыннан соң да әле аның эше житәрлек: башта — хуҗаның хатынын, аннан үзен кайтарасы бар өйләренә. Юл җае төшүдән файдаланып, Асиянең дә эшенә кагылып узган иде. Үзенең бүген соңга калуы хакында искәртү нияте

белән Асияне профсоюз киңәшмәсендә диделәр. Соңгы арада ул шулай еш кына профсоюз киңәшмәләренә йөри торган булып китте, җәмәгатьчелек эшләренә хатын-кыз тартыла бит хәзер... Асиягә тапшыру өчен дип, Сания апасына кәгазь кисәге калдырырга да онытмады.

Сәгать сигезенче киткәндә янә әбиләренә кагылып, бераз тамак ялгап алды. Тиз өстенә атландырып, Алмазны сикертеп алды: «Һоп-һоп, һоп итә... Аягында ботинка... Кулларында чабата... Башында киез ката... Һоп-һоп»,— дип, такмаклый-такмаклый сикертте.

Улы «Кечкенә әкиятләр» карый калды, ә әтисе — янә баранка артына. Төнге уникегә кадәр байтак ара бар иде бит әле, «шәһәрне айкап алырга» да була. «Шәһәрне айкап алу» — бу таныш-белеш шоферлардан ишеткән сүз. Аңлаешлырак итеп әйткәндә — чумара буладыр. Шулай итмәгәндә, йөз дә ун тәңкәгә ничек итеп гаилә туендырырга, көн күрергә мөмкин. Баланы да үстерергә кирәк, хатынны киендерергә... Барлы-юклы эш хакына карап, көнозын руль артында йоклар чагы түгел шул әле аның. Тегесе кирәк, монысы кирәк дигәндәй, яңа тормыш көтә башлаган чаклары.

Кинәт, уйларыннан бүленеп, чарасызлыктан чәчен йолкыгандай хәрәкәт ясап куйды ул. ГАИ күзенә чалынмаска тырышып, шәһәрне аркылыдан буйга гизеп, хәер эстәгәндәй, ни рәвешле берлек һәм өчлекләр җыеп йөрүен хәтерләде ул үзенең. Кесәсенә тыгылды, анда — шул акчалар... Йомарлап алырга иде дә үзләрен, тотып болгарга иде тәрәзәдән, югалсыннар иде күз алдыннан, очсыннар иде. Әйтерсең, шулай итсә, аның хәле җиңеләеп калачак...

Уникегә туларга унбиш минут кала — билгеләнгән урында иде инде ул. Аның белән бер үк вакытта диярлек, тагы өч машина килеп туктады. Күл биреп исәнләшкәннәре юк, күргән-белгән шоферлар түгел. Күл читендәге элеге аулак урында әнә шундый таныш булмаган шоферлар белән бергә-бергә еш кына шулай Җантимердән әмер көтәргә туры килә иде Фидаилгә.

Төнге пассажирлар, гадәттәгечә, шактый ук кәефле иделәр. Дөрес, Фидаилгә — барыбер, аның аларда эше юк. Илтергә һәм алып кайтырга кушылган — ул шуны үти. Капкаевның кенәри дигәне бүген гадәттәгедән дә кәефлерәк иде. Урынында тик кенә утыра алмый кыбырсып кайтты. Урман юлыннан, гадәттәгечә, зур тизлек белән куаладылар. Җантимер шулай куша: «Юл читендә чуалган гөмбәчеләр номерларыгызны танымасын!» Капкаевның элгәреге кенәриләре куркуларыннан почмакка посып утырырлар иде мондый чакта, ә моңарга тизлек җитми, тизлек кирәк. Олы юлга чыккач та алдагы машинаны куып тотарга әйдәүче шул булды иң элек. Кулын чәбәк-чәбәк итеп, уен коткысына бирелде. Капкаев та ашыктыра: «Әйдә, куып тот шул база күсесен! — ди.— Кенәриләр сүзен тыңларга кирәк»,— ди. Фидаилнең дә соңлап йөрисе килми, җәтрәк өйгә кайтканы хәерле — хатыны һәм улы көтә торгандыр анда...

Куып җитү генә түгел, узып та киткән булырлар иде. Чит машина пассажирларына күз төшерә торган гадәте юк... Фидаилнең кемдә ни эше булсын?! Илтте. Һәм алып кайта. Инде узып китәм дигәндә, машиналар тигезләшеп җиткәндә, арткы рәттә үбешеп кайткан кенәри, Капкаевның муеныннан арынып, чырайлап кычкырып җибәрмәсенме:

— Карале, кара — үбешәләр,— дип, тәрәзәгә иң элек ул сыланды.— Ася, Асенька...— дип кычкыра-кычкыра, уч төпләре белән пыяланы төяргә кереште.

База мөдиренең кенәриләре арасында мондый исемдәгесе юк иде кебек әлегәчә. Исеме дә килде-китте генә түгел — Асия. Бу исемгә битараф кала алмады Фидаил, гади бер кызыксыну белән, узып барган җирдән, ул да уң тарафка күз салып алды.

Карады... Һәм күзләренә ышана алмады. Күп булса, бер метр ара ераклыгында, башка ир-ат кочагына чумып үзләренә кул изәп баручы кенәри Асия булып чыкты. Аның Асиясе!.. Аермачык күрде, әмма ыша-

насы килмәде. Мөмкин идеме соң моны күз алдына китерергә, шуңа ышанырга?! Ул бит аның Асиясе, аның бердәнбере... Бер түгел, мең кеше Асия хакында яман сүз сөйләсә дә, ышаначак кеше түгел иде Фидаил.

Башы әйләнеп китте аның шул чакны, кулыннан рульне ычкындырып җибәрә язды. Каршы яктан зур тизлек белән куып килгән КамАЗга чак кына бәрелмичә калдылар. Ничек тормозга басып, ничек уңга каерырга өлгерде — үзе дә хәйран калып утыра менә. Арткарак калыша төшкәч тә икеләнә калган иде ул — булмас, булырга мөмкин түгел. Асияне бит профсоюз киңәшмәсендә диделәр, аның эш вакыты, ул икенче сменада бүген, ди-ди кире уйлады. Үз-үзен шул уйларына ышандырырга теләде. Һәм, «Ул түгел!» дигән ышанычын ныгытырга теләп, янә дә куып җитте алдагы машинаны: «Кенәриләр арасында Асия булмас! Нигә аның хатыны шундый түбәнлеккә төшсен әле!..»

Кызганычка каршы, күрше машинадан текәлеп диярлек үзләренә таба кул болгаучы, елмаючы Асия булып чыкты. Бер мизгелгә, Капкаевларга түгел, руль артында утырган ирен танып алып, ул аңарга елмая, аңарга кул изидер төсле тоелды хәтта. Ә үзе башка ир кочагында... Хәтта өстендәге күлмәгеннән үк таныды Фидаил аны. Әле күптән түгел генә, туган көненә дип, үзе бүләк иткән күлмәк. Үзәк универмагта эшләүче бер товаровед ханымнан ике бәя түләп алган иде.

...Шуннан ары үзенең ни эшләгәнен анык кына хәтерләми иде инде Фидаил. Ничек шәһәргә кайтып җиткән?.. Пассажирларын ничек озаткан? Машинасын кайда калдырып, ничек бүлмәләренә кайтып ауган?.. Әле булса шул аңгы-миңге халәтеннән чыга алмый иза чиккән чагы...

Ниһаять, торып, бүлмәдә ут кабызды. Яктылык аның күңелен биләп алган саташу һәм эңгер-меңгерне дә куып таратыр төсле тоелды. Буеаркылысы өч-дүрт адымнан узмаган бүлмә буенча арлы-бирле йөренергә кереште. Тынычлану гына юк... Стенага асылган нәни китап шүрлегенә текәлеп туктап калды бераздан. Шул шүрлекнең пыяласы артына кыстырылган фоторәсем җәлеп итте игътибарын. Төсле фото... Уллары Алмазга өч яшь тулган көн истәлеге. Аермачык хәтерләде Фидаил: шимбә көн иде. Шәһәрдә яз иде. Май урталары. Шәһәр урамнары яшеллек, алма һәм чия чәчәкләре исенә тулышып торган мәл. Күңелләрнең канатланган, хисләрнең мөлдерәп ташыган чагы... Улларын икесе ике кулыннан җитәкләп, яңа төзелгән киң проспект буйлап фотографиягә барды алар. Уң яктан — әнисе, сулдан әтисе атлады. Сабый — әле әнисенә карап елмайды, әле әтисенә күз нурларын төбәп сикергәләде. Аякларын күтәреп, ике кулда асылынып барудан бер кызык тапты. «Кош булып очам, тотыгыз, әни!..»— диде ул, кабат-кабат югарыга талпынып. Бала бәхете ата белән анага да күчкән. Фидаилгә карап елмая, күз кыса Асия. Фидаил үз хатынын күреп туя алмый, тәүге очрашулары диярсең... Хисләр ташкынына буйсынып, сүз берләшкәндәй йөгереп китә алар кинәт: «Әнә, Алмаз ничек оча, у-у-ух!.. Үскәч космонавт була ул, у-у-ух!..» дип кабатлый Фидаил.

— Космонавт булырсыңмы, улым?

— Космонавт ул кошмы?..— дип, сорауга сорау белән җавап бирә сабый.

— Космонавт оча, кош кебек еракларга оча, улым...

— Мин дә очам бит!..— дип шаркылдап көлә сабый.— Әнием — бер канатым, әтием — икенче канатым!..— нәкъ зурларча әйтеп, үзе өчен яңа ачыш ясый.

— Очыртырбыз, улым, очыртырбыз... Кош сыңар канатлы булмый...

...Янәшәдә — икенче фоторәсем. Фидаил белән Асиянең язылышкан чаклары, никахлашу йортында төшерелгән. Асия ап-актан киенгән, ак кош сыман ап-ак. Оялчан карашын түбән иеп, аның каршысында басып тора. Фидаил аның бармагына балдак кидерү белән мәшгуль. Чиксез бәхетле үзе, әмма искиткеч дулкынланган да чагы. Әле дә хәтерендә: кулы, тез буыннары калтырады аның шул мизгелдә, аздан гына кулындагы

балдакны төшереп җибәрмәде... Соңгы минуткача Асиянең: «Сиңа чыгарга ризамын...» — дигән сүзләренә ышанып җитмәгән иде бит ул. Өйләнешеп, бергә яши башлагач та алар еш кына әлеге фоторәсемгә карап, анда мәңгеләштерелгән мизгелләрен искә ала торган булып киттеләр. Шул чакта бер-берсенең ни уйлаганы, ничек дулкынланганына кадәр беләсе, ачыклыйсылары килеп төпченгән чаклары булды. Язылышкан чакта һәм туйда төшерелгән фоторәсемнәр һәркемдә җитәрлек хәзер. Ләкин алар арасыннан берсе, бары тик берсе, һәр ике якка да кадерле һәм үз була. Йә бер, йә икенче кимчелек табыла үзләреннән, йә авыз ошамый, йә күз дигәндәй, кай очракта аякларың да бигүк уңышлы куелмаган чагы әләгә. Берәү дә үзен түгел, рәсемгә төшерүчене гаепле саный. Фоторәсемдәгегә караганда матурракка чыгарабыз шул без үзебезне. Күзгә каршында торганда килешлерәк күренәбез үз-үзебезгә. Шундый сәбәпләр белән, туй рәсемнәре сирәгәйгәннән-сирәгәя барды аларның альбомында. Ә монысы өй түрендә, күз алдында тора. Чөнки һәр икесенә дә бер дәрәҗәдә ошый иде ул...

Шул фоторәсем нәфрәт чыганагы булыр дип кем уйлаган? Фидаилнең аны йолкып аласы, вак кисәкләргә ерткалап, тәрәзәдән очырасы килде. Асия киеп алган бөркәнчек һәм күлмәкләрдәге ак төс җанын әрнетә иде аның. Тапланган, беркайчан да берничек тә юып чистарта алмаслык булып керләнгән инде ап-ак туй күлмәге...

Утка ягаргамы?.. Эх, шул сурәттән үч алып кына төзәлә торган булса иде ул...

Төнге юлда туктап калган машинаны искә алды ул кинәт. Исәннәрме икән алар?.. Кюветка тибәрелгән машинаның язмышы ни белән тәмамланды?.. Нәфрәт һәм ачу шулкадәрле булган, ташыган, күрәсең, хәтта күтәрелеп күзгегә карауны да кирәк тапмаган ул...

— Минә кызык, чын детектив!..— дип, күңеле булып, аның колагы төбендә үк кулларын чәбәкләп чырыйлаган хатын-кыз тавышы гына эленеп калган колак очында. Капкаев куенындагы кенәри авазы.

— Аяк арасында буталмаслар... Үзләре килеп керде,— дип, шоферны тынычландырмак булып җөпләгән иде Капкаев та.

Ә бераздан алар үбешә башлады. Фидаилгә күзгегә күз салу уңайсыз иде инде.

...Тагы ишекле-түрле йөренергә кереште ул. Бу юлы тәрәзгә килеп төртелде. Төнге шәһәр кайчак матур була, ә бүген ямьсез һәм шөкәтсез иде ул... Кешеләр йоклый. Каршы яктагы тугыз катлы йортның бары бер тәрәзәсендә генә тонык ут елкылдый. Әллә анда да аның кебек үк берcharacters бәхетсез бичара җанын кая куярга белми бәргәләнә микән?.. Әллә, киресенчә, куанычтан, олы шатлыгыннан йокы керми микән күзләренә?.. Ул да түгел, тузанлы тротуар читендә бер эт пәйда булды. Башын түбән салындырып, бире таба хәрәкәтләнә иде ул. Фидаилдә дә шул эт язмышы түгелме икән?.. Ул да шыр ялгызы бит бүген бу дөньяда. Тротуардагы эт тә ашыкмый беркая. Күренә, аның да барыр, кайтыр кешесе, дусты юк булса кирәк. Каршысына йөгереп чыгарга һәм, кулына алып, үзе белән бергә өйгә алып керергә әзер иде инде Фидаил аны. Суыткычтагы соңгы сөякне кызганмас иде... Ләкин эткә әллә күз тиде шунда, ул да кәефен кырып китте Фидаилнең: гамьсез генә килде дә, нәкъ аларның тәрәзәсе каршысына җиткәч, туктап калды. Тимер-бетон баганага елышты. Нидер эзләгәндәй, борынын сузып, бер кат әйләнеп чыкты баганаы. Тәмам туктады. Башын югары күтәреп, як-ягына карангалап алды. Фидаилләр тәрәзәсенә дә күз салды кебек. Әмма аны күреп исе китмәде, багана төбендә «сәлам хаты» калдырып, бер-ике тырманды да, койрыгын болгый-болгый, үз юлы белән китеп барды.

«Эт язмышы...» дип күңеленнән генә әйтеп куйды Фидаил һәм кинәт сискәнеп китте. Әйтерсең, ул бу сүзләрен әлеге йолкыш эткә түгел, нәкъ менә үзенә төбәп әйткән иде. Чыннан да, кешеләрнең генә түгел, этләрнең дә үз язмышы була түгелме соң? Язмыш дигәнең, синең нинди җан

иясе булуыңа карамастан, бертигез дәрәҗәдә ээзрлекләмиме?

Шулай тоелды Фидаилгә: аны язмыш балачагыннан бирле эзәрлекли, рәнҗетә, кимсетә, мыскылларга һәм түбәнсетергә тырыша кебек иде. Әйтерсең, язмыш аның кеше булып яшәвен теләми, бу дөньяга кеше булып яралуын кичерә алмый, үч ала, эт ачуы белән үчләшә. Шулай уйлады Фидаил һәм, шулай уйлап, бер мизгелдә үзенең бөтен язмышын күзаллап чыккандай булды...

Пионерга кергән көннәре иде. Кызыл галстук тагып, шуның кызыллыгыннан бетмәс-төкәнмәс дәрт тоеп, атлап түгел, очып йөргән көннәре... Һәр яңа көн галстукны ничек дөресрәк һәм килешлерәк итеп бәйләү турындагы мәшәкатьтән башлана. Мәктәптә тәнәфес вакытларында сүз күбрәк шуның дәвамы була. Дәрес вакытларында, онытылып китеп, галстугы белән уйнап утырган малай һәм кызларга берөзлексез шелтә эләгеп торган чаклар. Фидаил дә, мәктәптән кайтып керүе була, галстугын китаплар арасына кыстырып куя, шулай иткәндә ул бөгәрләнми, киләсе көнгәчә, үтүкләнгән сыман, пөхтә тора. Моны аңар өлкән классның тәҗрибә туплаган малайлары өйрәтте. Юкса, пионервожатый күзенә бөгәрләнгән галстук белән чалына калсаң, ул аны муеныңнан тартып алырга да күп сорамый икән. Бөтен класс кызыл галстуклы чакта, кикриксез этәч сыман йөрерсең берүзең...

Мәктәп коридорында бер зур көзге бар. Шул көзге каршысы һич буш тормый иде ул көннәрдә. Күбрәк кызлар көязләнә анда. Малайлар да үткән-сүткән чакларында күз чите белән генә булса да карамый китмәде. Һәркем олыгаеп киткәндәй хис итә иде, үзен. «Ул инде бала-чага түгел, пионер ич хәзер... Җәмгыятьнең иң алдынгы вәкиле булырлык яшьтә. Алар яшендәге пионерлар туган ил һәм халык өчен җаннарын кызганмый көрәшкән...»

Март ахыры идеме икән, апрель башларымы — урамда әле шикәр сыман уалып торган ап-ак кар ята иде. Төннәрен суыта, ә мәктәп тәрәзәләреннән көнозын язгы кояш китми. Тәнәфесне белдереп кыңгырау шылтырадымы, малайлар-кызлар дәррәү ишегалдына чыгып йөгерә. Йомарлап кар атышалар... Түбәләрдән сузылып төшкән боз сөңгеләреннән тамчы тама. Итәк очларын көяз генә тарткалап, мәктәп ишегалды буйлап кызлар йөренә. Кар атышлы уйнаган малайлардан, билгеле инде, аларга да шактый ук өлеш тия. Чырыйлап көлә-көлә йөгерешә, ыгы-зыгы килә кызлар, класс җитәкчесенә әйтү белән куркыталар...

Әле яңа гына озын тәнәфес тәмамланган чак иде. Өс-башына кими генә, йөгереп өйләренә кайтып, бер кабартма яисә ипи кыерчыгы эләктереп килергә гадәтләнгән Фаяз исемле бер малай класска бераз соңарып килеп керде. Нык йөгергән, кызару гына түгел, тирләп үк чыккан. Үзе мыш-мыш сулый. Фаязны мышнатырга һәм тирләтергә ай-һай бик күп кирәк,— шундук игътибарны җәлеп итте ул. Дәрес дип тормады, укытучыдан да тартынмады, класска хәбәр салды:

— Малайлар, авылга эт атучылар килгән!.. Кыралар гына...— һәм шундук, кире борылып, чыгып та йөгерде.

Дәрес өзелде, рәт араларында ыгы-зыгы башланды. Укытучының тавышы бөтенләй күмелеп калды, аны ишетүче юк иде инде. Фаяз артыннан ук ишеккә ташланган малайлар белән этешә-төртешә, Фидаил дә чыгып йөгерде.

— Кайсы урамда?.. Кайда эт кыралар?..— дип кычкырды ул, Фаязны мәктәп коридорында ук куып җитеп.

— Сезнең турыга җитеп киләләрие!..

...Ул елларда эт атучының кем булуын авыл малайларына сөйләп торасы юк. Елның-елына шулай яз башында көтмәгәндә килеп төшәләр дә авылга, бер-ике сәгать эчендә кыралар да бетерәләр этләрне. Шуның алдыннан гына, әллә каян, авылда хуҗасыз этләр күбәйгән, котырганнары да бар икән, дигән хәбәр салына. Сылтавы булгач, һичкемнең ай-

ваена карамыйлар, урам уртасында шарт-шорт аталар да, гәүдәләрен атлы чаналарга төяп, район үзәгенә китеп баралар.

«Сезнең турга җитеп киләләр!..» Фидаилнең яраткан эте бар, Юлдашы... Алны-артны, уңны-сулны белми йөгерде Фидаил. Гомер булмаган сәрсәнлек белән дөньясын онытып йөгерде. Иртән уалып торган кар инде көпшәкләнгән. Бәйләнгән йон оекбаш белән кигән галошлары таеп-таеп китә. Кыш буе җигүле атлар йөргән юлдагы нәни генә ямаулыкларны хәтерләтеп торган урыннарны сикереп кенә узды. Ачык изүеннән җил бәрде. Муенындагы өр-яңа кызыл галстукның телләре җилфер-җилфер итеп йөзенә, күзләренә килеп сарылды.

Тизлеген аз гына да киметмичә, мәктәп урамын үтеп, үзләре чатына борылды Фидаил. Югарочтан бирегә таба төшеп килгән ике җигүле ат җәлеп итте игътибарын иң элек. Йөкләре авыр иде ахры, атлар авырлык белән генә киләләр, әледән-әле пошкырыналар. Чаналарның як-ягыннан телогрейка өстеннән икесе дә бер үк төрле сары кожан кигән мылтыклы кешеләр атлый. Таза гәүдәле агайлар... Ә өченче берәве, юл читендәге карга бата-чума, тегеләр янына ашыга. Кулындагы таягы белән төртеп-төртеп, Фидаилләр өе ягына күрсәтә, нәрсәдер аңлатырга тели.

Атлар туктап калды. Әлеге ир-атлар да үзара нидер киңәшеп алдылар. Ә тегесе — өченчесе — ул арада Фидаилләрнең капкасын тарткаларга керешт. Капка бикле булгангадыр, ни өчендер, коймаларына суккалады таягы белән, капка асларын кәшәкәләргә керешт. Бер-ике мәртәбә тибеп тә алды капкага.

— Юлдашка тимәгез! Кагылмагыз Юлдашка!...— дип кычкырып җибәрде таяклы кешенең ниятен аңлап алган малай. Ул бит аның ишегалдындагы Юлдашын урамга чакыра...

Үзе җан-фәрман йөгерә, үзе кычкыра ул әнә һаман. Ни сәбәпледер, тавышы начар чыга, кай арада карлыгырга да өлгергән:

— Тимәгез!.. Ти-и-имәгез!.. Тимәгез Юлдашка!..

Җигүле атларның алдагысыннан төшеп, алгарак чыгып баскан ир-атларның берсе, иңбашындагы мылтыгын шудырып төшереп, кулына алды. Урамда Фидаилнең эте күренми иде әле күренүен, әмма көпшәсе белән алга каратылган мылтык аның күңелендәге шомны бермә-бер арттыра төште. Бәлки, Юлдаш капка астыннан котыртучыга өрә торгандыр.

— Юлда-аш! Тимәгез Юлдашка!..

Шулай оран салуы белән мылтыклы кешеләрнең игътибарын үзенә җәлеп итү, соң булмаса, шул рәвешле дустын һәлакәттән коткарып калу иде аның уенда. Этнең бәйдә түгеллеген ул яхшы белә. Аларның авылында, гомумән, этләрне бәйдә тоту гадәте юк иде. Юлдаш — ишегалдына, урамга чыгып киләп салып йөри торган эт түгел ул.

Капка каршында әле дә булса этне котыртырга теләп таягы белән кизәнүен дәвам иткән кешенең чәрелдек тавышы яңгырады:

— Монда!.. Этләре монда!.. Хәзер чыга ул... Мылтыгыңны төзәп тор!..

Дөньясын онытып этне ишегалдыннан урамга чыгарырга тырышкан бу кешене чәрелдек тавышыннан таныды малай. Авыл советында йомышчы булып көн күргән Куштан Закир иде бу. Үз вакытында бер бармагын өзеп сугыштан калган, инвалидлык алган Закир гына шулай әрсезләнә ала.

— Котыртма этне!.. Тимә... Тимә, Куштан Закир тәре!..— дип кычкырды Фидаил. Һәм, аягы таеп киткәнен сизмичәрәк калдымы, язгы нурлар җылысыннан изелгән ат «алмалары» өстенә сузылып барып төште.— Юлда-а-аш...— дигән әрнүле тавышы чыкты аның янә.

Дустының шул тавышын ишеткән эт, аңарга ярдәмгә ыргылуы булдымы, койма өстендә күренде. Капка бикле, барлык чыгар юллар томаланган булу сәбәпле, башка юл юк. Бер мизгелдән эт урамда иде инде... Соңрак тагы шул кадәресе дә билгеле булды: авылга эт атучылар кил-

гән дигән хәбәрне ишеткәч тә, амбарда язгы чәчүгә орлык хәзерләүдә булган әнисе, тиз генә өйләренә кайтып, капкаларны бикләп килергә өлгергән. Юлдашны оясына ябып, оя авызындагы тактаны көрәк сабы белән терәтеп куйган. Фидаилнең әрнүле тавышын ишеткән эт әнә шул киртәләрне җимереп ярдәмгә ташланган икән.

— Әнә этләре, әнә, качырма!.. Тизрәк ат, нәрсә карап торасың! — дип, зур эш майтаргандай, янә сикергәли-кычкыра башлады Куштан Закир.

Малай, егылган җиреннән торып, яңадан йөгерергә керешкән иде инде. Мәтәлгән чагында як-якка очып киткән галошларын да эзләп тормады, Юлдашка таба ашыкты... Яланбаш һәм оекчан йөгерә иде малай. Муенында кызыл галстук җилферди. Каршысына, койрыгын болгый-болгый, дустын танып алган Юлдаш томырыла. Күп булса, унбиш-егерме адым ара калган булгандыр. Юлдаш белән Фидаил өчен нәрсә инде ул унбиш адым, бер мизгел нибарысы. Ә арада — сары кожан кигән кеше. Юл читендәге карга тезләнгән. Тезләнгән дә, бүреген бер якка кыйшайта төшеп, сулыш та алмыйча тынып калган.

— Атмагыз Юлдашка!.. Атмагы-ы-ыз!..— дип соңгы мәртәбә ачыргаланып кычкырырга өлгерде малай. Ишегалдында качырылган этне чакырып ялгышканлыгын, үзенең төзәтә алмаслык хата ясаганлыгын чамаламый иде әле ул. Чөнки ярдәмгә ашыга... Әнә, ул инде каршысына килгән Юлдашының сулышын да тоя кебек. Күп булса, тагы бер ыргым кирәк икесеннән дә. Аннан берәүгә дә, һичкемгә дә бирмәячәк инде ул Юлдашын.

Кинәт гөрселдәү авазы яңгырады. Урам икегә аерылды, гүя урталай ярылып китте. Баш очында язгы кояш чайкалып куйды. Томанлы пәрдә артына качарга теләгәндәй, өйләр, каралты-куралар, хәтта телеграф баганалары тоныкланып калды, атынып-тулганып алдылар... Толпар аттай җилкенеп, кош сыман талпынып, алга, үзенең дусты — хуҗасы кочагына ыргылган эт сөрлегеп алды, куырылды. Гүя, стенага килеп бәрелде, канатларын каерды... Әмма егылмады, бахыр, арткы аякларында гына калып янә алга омтылды. Бер адым... Ике... Өстенә сикерә дип уйлады булса кирәк: мылтыклы кеше, тезләнгән җиреннән җәт кенә торып, читкә йөгерде, җигүле атлар артына ышыкланырга ашыкты. Чана үрәчәсенә абынып, чак кына егылмый калды.

Юлдаш өчен әллә бар, әллә юк иде бит ул, югыйсә. Эт дустына каршы томырыла. Иң соңгы сикереш ясарга дип терәлгән аяклары йомшап, көпшәк кар сыман уылып төште Юлдашның. Агымсуга йөгереп килеп кергән сыман, гәүдәсе белән ак карга елышты. Аннан, табан аслары җирне тоймый башладымы, тынып калды. Гүя талгын сулы тугай өстеннән агып китте...

Шунда, атлар артында качып, барын күзәтеп торган Куштан Закир таягын болгый-болгый килеп җитте:

— Ну, имансыз,— диде ул, исән түгелме икән дигән сыман, таяк очы белән күпереп торган йонлач аркасына төрткәли-төрткәли. Җаны тынычлангач, канәгать елмаеп, сары кожанлыларга таба борылды.— Утыз алтынчысы булдымы?.. Әйттем ич, планны, дим, арттырып үтибез инде аны!..

Сары кожанлыларның берсе, дәшми-нитми генә килеп, этне арткы аякларыннан эләктереп, чанага, ишләре янына өстерәргә кереште.

Шартлау авазы яңгырагач та кадакланган сыман катып калган иде Фидаил... Җай гына исеп куйган җилдә галстугы җан биреп алды. Мышык-мышык борын тартудан башка чарасы калмаган. Җиң очы белән күз төпләрен сөртеп куйды. Әнисе белән икәү генә яшәгән яклаучысыз ятим малай ни кылырга сәләтле иде соң тагы?..

Янәшәсенә, җәт-җәт атлап, Куштан Закир килеп баскан:

— Сөрт борыныңны,— дип, кулындагы таягын болгый-болгый өйрәтергә, шелтәләргә кереште ул аны.— Харап икән, берәүнең этен аткан-

нар... Малай кешегә шулай мәлҗерәп төшү килешәме инде?! Аталар икән, димәк, шулай кирәк. Дәүләткә кирәк, аңлыйсыңмы?! — һәм, ботларын чабып, гаҗәпләнгән булды.— Күрми дә торам, кара инде, үзеңне пионерга да алганнар икән бит әле...

— Алсалар соң! — дип, түбәннән сөзеп, күз яшьләреннән кызарып чыккан нәфрәтле карашын төбәде аңар малай.— Синең ни эшең бар?..

— Карале, кара, ничек сөйләшә?! Соң, син, юеш танау, кем белән сөйләшкәнеңне беләсеңме соң?!

— Куштан Закир белән...

— Карале, кара, ничек сөйләшә,— дип башлады ул тагы, кыбырсырга керешеп. Таягын да болгап алды малайның борын турысыннан.— Син, энем, авыл советы вәкиле белән ничек сөйләшергә икәнлекне белмисең икән бит әле!.. Белмәсәң, өйрәтербез!

— Юлдашның сиңа ни зыяны тиде, Куштан Закир тәре?!

— Ничава,— дип, таягы белән янап алды Куштан.— Куштан Закирены күрсәтермен әле мин сиңа, хәерче калдыгы...

Җигүле атларның алдагысы авырлык белән генә пошкырып куйды. Кузгалдылар... Камыт бөятләре шыгырдады. Чана табаннарының ачы чыелдау авазы белән сыкранып сукранганы ишетелеп торды... Түбән очка таба борылдылар. Атларны юл читеннән узып, җепшек карга батачума, иң алга янә Куштан Закир барып чыкты...

Оекчан басып торган малай борынын тарта-тарта карап калды. Галстугына чәчрәгән кар тамчыларын сыпырып төшерде, тагын бер кат күз төпләрен уып алды. Калтыранган иреннәре дәшмәде...

Нигә дип әллә кайчан булып онытылган вакыйгаларны искә ала соң әле Фидаил?.. Аның бүгенге хәленә боларның ни кагылышы бар?! Нәрсә өчен әле үткән, онытылган күңел җәрәхәтләрен яңартырга кирәк булды икән тагы? Бүгенгесе дә чамадан тыш җитеп ашкан түгелме?!

Ишек катына үтеп, яктылыктан уңайсызлангандай, утны сүндерде ул. һәм, чишенеп тормый гына, пөхтә итеп җыештырылган караватка барып ауды. Күзен йомды. Ә күңеленә тагы сорау килде: «Алар утырган машинага ни булды икән?.. Кайсы тирәдә булды соң әле болар?..» Ул юлдагы һәр сикәлтә, һәр борылыш кына түгел, юл читендәге һәр баганага кадәр таныш ич аңарга. Әйе, шәһәргә җитеп киләләр иде бугай. Соңгы үр алдындагы борылыш, анда узышу тыела дигән юл билгесе дә эленеп тора... Йөрәге жу итеп куйды — түбәндә ерганак ич анда!.. Нинди тизлек белән баралар иде икән? Ничек, ни рәвешле ул аларга бәрдереп узды? Бәрелешү ул кадәр каты булмады кебек үзе, чөнки машинаның чак кына чалулап алуыннан тыш берни тоймады ул. Андый гына бәрелүдән тәҗрибәле аек шофер машинасын чокыр төбенә җибәрмәс! Шулай да... Юк, җибәрергә тиеш түгел!

Тукта, нигә дип баш вата соң әле ул?.. Кемнәрне кызганып шулай борсалана?.. Үзенә хыянәт итүчене, үзен бөтен шәһәр һәм таныш-белешләре каршысында кеше көлкесе, адәм хурлыгына калдыручынымы? Ир-ат өчен «хатыны йөри», «хатыны хыянәт иткән...» дигән сүзләрдән дә зуррак нинди газап булырга мөмкин?..

Юк, күпме генә яратмасын, җанына никадәрле генә үз һәм якын булмасын, бөтен язмышын, хыялларын, гаилә тынычлыгын шулай җиңел генә челпәрәмә китерә алган кешене кызгана алмый ул. Мәңге гафу итә алмаячак!

«Димәк, Арслан Сәхипович... Арслан Сәхипович...»— дип, бу исемне отып калырга теләгәндәй, кат-кат үзалдына кабатларга керешүен дә абайламый калган... Беренче тапкыр күргән кешесе түгел. Елдан артык белә иде бугай инде ул аны. Беренче очрашканда ук ошатмады. Эрелеге, үзен әллә кемгә куеп сөйләшүе һәм мактанчыклыгы өчен яратмады... Аңардан күпкә дәрәҗәлерәк, зур-зур урыннарда эшләүче кешеләрне күргәне, утыртып йөргәне бар Фидаилнең. Белә: түрәләрнең дә төрлесе була. Аларның беришесе, кем белән очрашып сөйләшмәсен,

уртак тел таба, үзен әңгәмәдәше белән бертигез куярга омтыла. Икенчеләре исә, авызын ачканчы ук инде, «Кем белән сөйләшкәнлегеңне беләсеңме?! Менә мин кем!..» дип, үзенең синнән өстенлеген расларга, кабартырга керешә. Әлеге Сәхипович шундыйларның берсе иде инде.

Хуш, ул якларында аның эше дә булмасын ди. Шул «Сәхипыч»ны ничәмә-ничә кенәри белән күргәне бар иде инде Фидаилнең. Еш алыштырып тора ул аларны... Әнә кемнәр исәбенә кергән аның Асиясе...

...Уйлар һәм кичерешләр... Кичерешләр һәм уйлар. Берсеннән бер файда булса, җиңеллек килсә икән?! Һәркайсы хыянәткә илтә, барысы да хыянәтне хәтерләтә. Күзләрен четердәтеп йомды да йокыга китәргә тырышты ул. Онытылып, бераз йоклап алырга иде аңарга хәзер. Азга гына, вакытлыча гына булса да җанын телгәләгән, күкрәген изгән уйлардан арынып торырга иде. Күпме һәм ничек кенә бәргәләнмә — буласы булган, үткәнне кире кайтару мөмкин түгел. Йокларга иде... Йомарга иде күзләрне, һәм онытылырга... Ул дигәнчә буламы соң?! Берсен икенчесе төртешеп, бүлдерешеп ябырылган уй һәм хатирәләр.

...Унөч-ундүрт яшьләр чамасы булгандыр аңа. Аларны — авыл малайларын — район үзәгендә урнашкан хәрби комиссариатка алып бардылар. Иртәдән кичкәчә кабинеттан кабинетка йөртеп, сәламәтлекләрен тикшерделәр. Ап-ак халатлы шәһәр апалары тезелешеп утырган бүлмәләргә, анадан тума чишенеп, гөнаһсыз авыл малае килеп керсен әле... Һәм шул мизгел ничек итеп хәтергә уелып калмасын икән! Уен-көлке, төрле мәзәк хәлләрнең очы-кырые, чиге-чамасы юк, әлбәттә. Имеш, бер күрше авыл малае трусигын салмый кергән икән. Әйтеп-әйтеп тә тыңламагач, ике-өч кызыл иренле кыз, моны урап алып, үзләре эшкә керешкән. Малай тегеләрнең өчесен өч якка селтәп ташлаган да ачык тәрәзәдән урамга ук чыгып качкан. Ә дәү борынлы, кызыл яңаклы Илфат исемле бер малай үзен артык кыю тоткан. Кызлар каршына баскан да, авызын җәеп, оятсызланып тора икән. Шунда бер марҗа апа тезгә суга торган резин чүкеч белән Илфатның кай җирен әдер берне китереп кундырган, ди... Шуннан ары авызын ермаган ди Илфат...

Иң соңыннан гына аларны хәрби комиссариатның подвалында урнашкан «Тир»га алып төштеләр. Агач мылтыктан башканы күрмәгән малайлар өчен монысы инде чын бәйрәмгә әверелде: чиратка басып, шарт та шорт атарга керештеләр.

Шунда малайларның һәркайсына бишәр патрон өләшеп, ничек төзәргә, ничек атарга кирәклекне өйрәтеп торган озын гәүдәле ир-ат Фидаилнең игътибарын җәлеп итте. Үзен тыныч һәм ипле генә тоткан бу кешене кайдадыр очратканы бар кебек иде аның. Кайда һәм кайчан икәнлеген генә хәтерли алмый иза чикте. Йөз чалымнары, гәүдә тотышлары таныш кебек, әледән-әле күзләрен челт-мелт йомгалап торуы да хәтергә уелган төсле...

Теге чакта сары кожан киеп аларның авылына эт атарга килгән кешеләрнең берсе түгелме соң бу?.. Әле дә булса малайның төшләренә кереп йөдәткән Юлдашын арт аякларыннан эләктереп чанага ыргыткан адәм. Шул! Күзли торгач, аермачык хәтерләде ул аны, бу адәмне башка кешеләр белән бутау мөмкин идеме соң?! Кулыннан биш патрон һәм мылтык алганда, янә күз чите белән усал карап куйды аңар Фидаил. Чиркануын яшерә алмады.

Теге адәм дә сизенде үзенә булган бу сәер мөнәсәбәтне, дәшми калалмады:

— Мылтыктан атканың юкмы әллә бер дә?.. Куркытамы?— дип сорады ул, кайгыртучанлык күрсәтеп.

«Кирәге юк мылтыгыңның... Үзеңне дә, мылтыгыңны да күрәсем килми,— дип әйтәсе килде малайның.— Эт атучы түгел бит мин!..»— дип тә өстисе килгән иде. Дәшмәде.

Ә инде Фидаил мылтыгын сабыр гына куеп китеп барганда теге адәм аны туктатырга кирәк санады:

— Шәп аткансың,— дип, аркасыннан сөйде. Иң төз аткан берничә малай исәбендә, аның да уч төбенә өстәмә патроннар салды.

Боларын Фидаил, төзәмичә генә, кая әләкте шунда атты. Тир хуҗасына күтәрелеп карамады. Ә теге исә, киресенчә, аның һәр хәрәкәтен җентекләп күзәткән булып чыкты. Инде китеп котылам дигәндә генә, малайның беләгеннән тотып алды:

— Нигә алай ашардай булып карыйсың син миңа?..— диде.

Туры сорауга туры җаваптан башка чарасы юк иде Фидаилнең:

— Син — минем Юлдашны аткан адәм!

— Юлдашыңны?..— дип кабатлап сорады ир-ат. Күзләре ирексездән йомылып куйды. Тавышы калтыранды.— Нәрсә, этең бар идемени?

— Син минем Юлдашны аттың! — дип кабатлады малай, кысылган тешләрен күрсәтеп.

— Тукта... Алай усал булма әле син,— диде ир-ат һәм беркавым, ни дияргә белми, сүз таба алмый аптырап торды.— Тукта, син кайсы авылдан соң әле?

— Нурлы Аланнан.

— Синең этне дә аткан бызмы?

— Син аттың! Син үтердең минем Юлдашны... Ботыннан тотып чанага ыргытучы да син!

— Тукта, тукта, шул гомердән бирле син мине хәтерлисеңме?..

— Күралмыйм мин сине! Сез... Син — дөньядагы иң-иң әшәке кеше минем өчен... Фашисттан да болай!

Моңарчы ягымлы гына сөйләшеп торган ир-ат артка таба чигенеп куйды. Кеше-кара күрмиме, ишетеп тормыймы дигән шик белән, як-ягына карангаларга кереште. Әмма ачуланмады малайга, тагы да иплерәк итеп мөрәҗәгать итте ул аңарга:

— Энем,— диде.— Син алай дисең дә бит... Мин дә үз теләгем белән түгел. Эшем шундый иде. Эшең шундый булгач, атмый да чараң юк.

— Эшем шул...— дип, усалланып, ир-ат артыннан кабатлады малай.

— Син яшь шул әле, аңламассың мине барыбер. Ләкин карама миңа алай усал итеп, Карама...

— Син Юлдашны аттың... Син мине Юлдашсыз калдырдың... Син мине иң якын кешемнән — этемнән аердың! Кансыз кеше син, абзый...

— Җитәр, җитәр, тынычлан,— дип, кулын сузып, малайның җилкәсенә кагылырга талпынды Эт атучы. Тегесе аңардан җәт кенә читкә тайпылды:

— Кагылма миңа, синең кулың пычрак, Эт атучы...

— Аңладым, энекәш. Җитәр, җитәр... Тынычлан, ярыймы.

— Синең аркада минем ышанычым юкка чыкты, Эт атучы! Кешеләргә, дөреслеккә ышанычым.

— Тукта, энекәш, тукта... Син инде бигрәк... Кешеләргә ышанырга кирәк. Кешегә ышанмый яшәп булмый дөньяда.

— Этләрен атып, малайларны елатучы — кеше буламы?.. Эт атучы син!

— Чү... Ярар, синеңчә булсын, Эт атучы булсын!.. Мин аларны үз белдегем белән аткандыр дип уйлыйсыңмы?.. Кешегә җылы итекләр кирәккәнгә атылгандыр...

— Кыргыйлар, әнә, ялан аяк йөргән... Әмма эткә тимәгәннәр...

— Яшь шул әле син,— дип куйды ир-ат үзалдына.— Кыргыйлар тимәгәндер... Китаптан укып кына беләсез тормышны...

— Барыбер, синең кебек этләр атып йөрмәм... Җибәр мине...

Малай никадәрле дорфа һәм кискен сөйләшмәсен, ир-ат үзен тыныч тотарга тырышты. Үзенә яшь этәч сыман очып кунарга торган яшүсмерне аңлый иде ул, өлкән кеше буларак.

— Кешеләрне дә эттән болайрак кырган чаклар булды,— диде ул үзалдына. Һәм, теләсәң нишлә, үз юлыңда бул, дигәндәй кул селтәп, читкә китеп барды.

Аның соңгы сүзләренә Фидаил игътибар да бирмәде ул чакта. Ә барыбер колагына чалынып калган... Ярымподвал ишеген каты ябып, үзенең ничек чыгып йөгергәнен дә хәтерләми...

Хәзер дә шулай ишекне бәреп ябып кына чыгып йөгерергә, котылырга иде барысыннан... Теләсә нинди авыр хәлдән, бәла-казадан, әшәкелектән арына, котыла ала кеше. Мәңге төзәлмәс тоелган тән җәрәхәтләре төзәлә, авыр сүзләр онытыла... Хыянәт тә онытыламы икән?! Кичерә аламы кеше хыянәтне?.. Йә, әйтегез, кем җавап бирә ала, әйтегез... Бер-бер чара күрегез, ярдәм итегез Фидаилгә!?

## 18

Шул ук шәһәрнең икенче бер почмагында, шул ук минутларда, икенче берәүнең дә күзләренә йокы керми тинтерәтте. Йомшак урын өстендә борсаланып ятучы ул кеше — Асия иде.

Ире янына кайтырга җөрьәт итмәде ул. Ничә ел бергә яшәп, кул күтәрү кая, үзенә авыр сүз дә әйтмәгән Фидаил янына кайтырга кыймады... Күпме генә уңайсызлык кичерсә дә, ата-ана фатирына кайтып баш төртергә мәҗбүр булган иде.

Әтисе уянмады. Әнисе йөгереп килде ишеккә. Төн уртасында бусага төбендә кызын берьялгызы күреп, борчуга төште ана:

— Нишләп йөрүең, кызым? — диде.— Фидаил кая соң? Әллә бер-бер хәл булдымы үзе белән?..

Юк, дигәнне аңлатып, баш чайкады кызы һәм, берни дәшми генә, кайчандыр үзенеке саналган бүлмәгә кереп китте. Керде... һәм, идән астына поскан тычкан сыман, тынып калды.

Әнисе, кухня якка узып, өстәл әзерләргә кереште. Аның шырпы сызып газ кабызганы, никадәрле иплe булырга тырышмасын, плитәгә чәйнек утыртканы ишетелеп торды. Ипи савыты ачылды, суыткыч ишеге берничә кат ачылып ябылды... Чәй тәлинкәләре челтерәшеп алды. Кызын дәшәргә ашыкмый иде әле ана. Чишенсен, өстен алыштырсын, хәл алсын, үз вакыты белән чыгар әле бер, дип көтте.

Газга утыртылган чәйнек кайнап чыкты, ниһаять. Өй эче берәзгә тәмам тынып калды. Кызының чыгарга җыенмавын чамалаган әнисе, сак кына атлап, аның ишеге катына якынлашты. Дәшәргә ашыкмады, колак салып торды бертын. Сүзен дә, чәйгә чакырудан түгел, читләп башлады:

— Алмаз да бездә иде, кызым...

Җавап кайтаручы булмады анага. Йокыга талмагандыр ич?

— Кияү-балакай кайда соң, Асия? — дип дәвам итте ана, шундый ук иплe пышылдавы белән.

Иреннәрен турсайтып куйды Асия. Бу аның «Кияү-балакай...»га мөнәсәбәт белдерүе иде булса кирәк. Өстен чишенеп, урын җәяргә кереште ул.

Кызының хәрәкәтләрен, ишекнең аргы ягында ни эшләвен үтәдән күреп тора иде диярсең, әнисе артык каныкмады.

— Ярар, йокла алай булгач,— дигәне ишетелде аның һәм җай гына атлап ерагайды. «Ире белән әрләштеләрме икән?..» дигән сорау туган иде аның күңелендә. Андый чакта каныкмаганың яхшы балага, йокласын тынычлап, боерган булса, таңга кадәр барысы да көйләнер, онытыла төшәр...

Үзен биләп алган күңел төшенкелегенең сәбәбен аңлый алмый аптырады Асия. «Нәрсә булды? Ни дип җебеп төштең? Нинди бәлагә тарыдың? Нәрсә югалттың?..» дип, үз-үзен битәрләде ул, чуалган җеп очын таба алмый изаланган кеше сыман. Каш ярылып, күз чыкмаган лабаса...

Кияүгә чыкканына дүрт ел. Яратып чыкмады. Кая ул, кемне дә булса, кайчан да булса яратырмын дип уена да китереп карамаган

көннәре иде бит. Гомергә ата-ана янында калудан гына курыкты ул... Яше егерме икедә генә булса да, «сазаган кыз булып калу», киләчәгенең билгесезлеге торган саен ныграк борчый башлаган иде аны ул көннәрдә. Егерме ике яшь... Бер карасаң, күп тә булмаган икән. Шулай да, унжиде-унсигез дә түгел инде ул егерме ике! Әллә ни арада үсеп житеп, егетләр белән җилдерергә керешкән, ул гынамы, менә дигән егетләрне, тилгәннәр сыман, берәм-берәм Никах йортына таба чүпләргә тотынган яшь кызлар кагылды аның авырткан җиренә. Үз яшьтәшләре һәм хәтта ирдән кайткан хатыннар тирәсендә чуалып тәҗрибә туплаган егетләрнең шул кыз-кыркынга капланып төшүе сискәндерде. Берәм-берәм өйләнергә керештеләр. Бергә-бергә ресторганнарда җилдергән яшьтәш кызлар торып кала түгелме соң дип уйларга исләрендә дә юк...

Шундый уйлар җанын телгәләгән чакта Сания апасын очратты. Аннан — Фидаилне... Уйнап кына танышканнар иде кебек... Шул егетне беренче күргәндә кем дә булса аңар, ирең шул булачак, дигән сүз әйтсә, ышанмас, ышанмас, ышану кая, кычкырып көлгән булыр иде Асия. Кайчандыр үзе артыннан йөргән егетләргә аз гына да охшамаган иде бит ул. Андыйларның сәламен алганы да, җавап кайтарганы да булмагандыр. Төс-кыяфәте, киеме-салымы булса икән! Белеме дисәң — белеме, һөнәре дисәң — телгә алып сөйләрлек һөнәре юк. Торган җире — тулай торактагы сиртмәле тимер карават. Шыр ятим дә бит әле өстәвенә, ярдәм кулы сузарга бер-бер туган-тумачасы булса икән?! Әтисен Фидаил үзе дә хәтерләми иде: ул, Фидаил сабый чакта ук, хатыны белән улын ташлап, каядыр китеп олаккан. Әнисен, улы солдат хезмәтендә чакта, ындыр табагында бодай җилгәргән җирендә ләх исерек шофер таптаткан. Кызганыч, билгеле... Ләкин бит, аның ятимлегенә Асия гаепле түгел! Әтисенә дә, әнисенә дә ул зыян кылмаган. Шулай булгач, аның бәхетсезлеген нигә әле, башка берәү түгел, Асия уртаклашырга тиеш?!

Фидаилне ул яратмады һәм яратмаячак та. Нәрсә-нәрсә, әмма үз бәясен, үз кадерен белмәс дәрәҗәдә үк томана түгел бит әле ул! Аны күргәндә ир-атларның күзе ничек яна башлаганны, эштә булсын, урамда булсын,— үзе артыннан сокланып калучыларның хисапсыз икәнлеген чамаламый, тоймый иде дип уйлыйсызмы әллә?..

Ни уйлап кияүгә чыктымы? Ике уйлап тормады, тотты да чыкты. Фидаил тәкъдим ясады, ә ул чыкты. Чөнки аңар шул көнгәчә чынлап торып тәкъдим ясаучыны очратырга туры килмәде. Кабык астына кереп оялаган корт сыман, кимсетеп, рәнҗетеп кимерә иде аны әлеге ялгызлык... Башка егетләргә үч итеп чыкты, күрегез, берегезнең дә кирәге юк миңа, диде ул гүя бу адымы белән. Сания апасы егетне гел мактап кына торды. Әти-әнисе дә, хәерлегә булсын, диде. Үзе дә, алга таба күз күрер, яшь башлагачтын, бәлки, күнегеп тә китәрмен әле дип өметләнгән иде.

...Иргә чыгып, ир хатыны булып яшәүнең ни икәнлеген белә инде хәзер. Дүрт ел узды. Дүрт ел җилгә очты... Еллары нинди бит әле аның!.. Йә, нигә ия булды ул шул дүрт ел эчендә?.. Торырга дисәң, кешенеке төсле фатирлары юк. Юлия, әнә, дүрт бүлмәле дип кенә сөйләшә. Ә бит аның шушы шәһәрдә гомер итеп, дүрт бүлмәле фатирның нинди булуын да күргәне юк. Фидаилгә ябышып яшәсә, күрмәячәк тә. Кем бирсен гади бер шоферга шундый фатирны? Тоттырганнар ди, көт! Төн йокламый кеше ташып җыйган берлекләренә кайчан да булса бер бүлмәле кооператив алып керә алса, артыңа биш тибәрсең шатлыгыңнан...

Торып кара коры хезмәт хакына! Йөз егерме тәңкәгә аша да, киен дә, бала да тәрбиялә, имеш. Торагың өчен дә түлә, тормыш кирәк-яраклары, өй җиһазлары ал... Кеше төсле киногa йөр, театрга, җәйләрен җылы якка барып ял итеп кайт! Шуларның барысына да

житкер. Нәрсә алыйм дисәң, «житми» һәм «юк»тан башканы белмәде ич алар... Ә башкалар таба, житкерә, әйттереп яшәп яткан көннәре бик күпләрнең. Асиядән кай җирләре артык аларның?! Әллә аның шулар төсле типтереп яшисе, үз дигәнчә ял итәсе, күңеле ятканны киясе килми идеме?

Арслан — башка дөнья кешесе. Үзе ничек яши! Хатыны, кызы ничек яши, ничек киенә! Ательеда аның хатынын күреп хәйран калмаган очракта, белеп булмый, аның каршысында шулай эреп төшкән булыр иде микән әле Асия?! Арслан хатынының тәкәбберлеге, горурлыгы, үз-үзенә булган ышанычы әле дә күз алдында аның; әле дә, шырпы сыман, бавырына кадалып тора. Теге чакта, ательеда күргәч тә, аны иң элек биләп алган тойгы, сорау нинди булгандыр дисез?.. Минем болардан кай җирем ким?! Ни өчен мин түгел — алар шулай үз дигәнчә киенеп-ясанып, бар кешенең игътибарын җәлеп итеп яшәргә тиеш әле?! Чишендереп куйсаң, кай җирләре артык?! Әнә, шул рәвешле, тәүге күргәч тә туган соклануы көнләшүгә сәбәп булды. Көнчелек әрсезлек һәм үҗәтлеккә юл ачты... Шуңа, Арсланны янәшәсендә күргәч тә, йөрәге җилкенде аның. Хатыны, кызы барлыкны үз күзләре белән күргән булса да, аңарга омтылды. Өлешенә чыккан бердәнбер һәм соңгы ышаныч, мөмкинлек булгандыр ул, бәлки?

Арсланда ул үзенең гомер буе эзләгән, эзләп-эзләп тә таба алмаган, көтә-көтә көтек булган мәхәббәтен очратты. Асия аны ярата, аңсыз яшәүне күз алдына да китерә алмый хәзер. Арслан да аңарга битараф түгел. Яратмаса, шулай иң якын дус-ишләре янында йөретмәс, аларга күрсәтмәс иде. Иртәме-соңмы, алар барыбер бергә булачаклар. Чөнки бер-берсеннән башка яши алмый алар. Үз ягыннан шулай икәнлеккә Асиянең һич шиге юк! Арсланны да горурлыгы, дәрәҗәсе генә тотып тора бары... Арслан — чын ир-ат, ул — көчле кеше. «Яратам» дип, дөньясын онытa, мәлҗерәп төшә торганнар токымыннан түгел. Үз бәясен ул яхшы белә. Хисләре ташкынына ияреп башын югалта торган беркатлы зат түгел, хисләрен ул авызлыклый белә...

Инде, гаилә корып, бергә яши башласалар — бөтенләй башкача булачак. Теләгән җирдән фатир алып, җаны теләгәнчә киенеп, җәй життеме — диңгез буена яисә чит илләргә сәфәр тотып яшәячәк алар. Һәммәсе — аларның киләчәге! Арслан — биргән вәгъдәсен, әйткән сүзләрен онытып, аяк астына салып таптый торган затлардан түгел. Дуслары, таныш-белешләре дә зурдан сөйләшә, дәрәҗәлеләр...

Фидаилне Арслан янәшәсенә куеп чагыштыру мөмкин түгел — монысы көн кебек ачык. Кай яктан гына килмә, алар үзара чагыштырмаслык дәрәҗәдә төрле, бер-берсенә охшамаган. Арслан — аның хыялы, бүгенгесе һәм киләчәге! Ә Фидаил? Фидаил аның хатасы булса кирәк...

Дөрес, Фидаилгә дә ачу яисә үпкәсе юк иде Асиянең. Аңарга да начарлык теләми ул. Чөнки үзенең дә Фидаилдән яманлык күргәне юк. Фидаил, гомумән, ачулана белми. Үз-үзен битәрли белә, борчыла белә, ә кемне дә булса башка берәүне гаепләми... Аерылышырлар. Бер алар гына аерылышмый ич хәзер. Иң элек Асия аңарга яхшылык белән аңлатырга тырышыр. Аңламый икән, үзенә карасын... Гомер һәркемгә бер генә тапкыр бирелә, шулай икән, кеше — шул бердәнбер гомерен генә булса да үзе теләгәнчә яши аладыр бит. Фидаил ятим үскән, аның барып таяныр, аркаланыр кешесе юк дип кызганып, үз-үзен бәхетсез итә алмый ич инде... Берара күңелсезләнеп йөрер-йөрер дә, күнегер. Аннан, тора-бара, кем белә, ул да табар, тапмый калмас әле үз ишен...

Күзләрен йомса, күз алдында Арсланның мәһабәт гәүдәсе калыкты Асиянең. Күзләрен йоммаган чагында да уенда ул гына иде. Ул монда — эниләрендә — берьялгызы борсаланып ятканда, Арсланның башка җирдә, башка хатын янәшәсендә булуына эче пошты аның.

Юк, болай дәвам итә алмый — Арсланның һәрчак үзе янында, үзе белән бергә булуын тели ул. Аның башка җирдә аерым көн күрүен, бүтән хатын белән яшәвен теләми һәм күтәрә дә алмаячак. Язмышның бу ялгышын — аерымлылыкны — тиз арада төзәтү зарур. Арслансыз яшәү юк аңарга. Сулга әйләнеп ятса да, уңга борылса да, түшәмгә текәлсә янсә мендәренә капланса да, күз алдында Арслан булды. Аның иркә карашы, кара бөдрә чәчләре, җитди һәм эшлекле йөз чалымнары гүя Асиянең бәгыренә кереп оялаган. Башка һичкем хакында уйлый алмады ул, төн ката күз алдында Арслан булды, колак төбендә — аның тавышы, билләрендә — кул җылысы...

Ни хикмәттер, хәтта улы Алмазны да искә төшермәде. Инде таң беленеп, бүлмәгә иртәнге нурлар тулгач кына күрше бүлмәдә саташып уянган сабый авазын ишетте ул. Шунда гына Алмазын хәтерләде. Улы да бар бит әле аның... Әмма, аңарга карап кына, үз бәхетеннән баш тартмас Асия. Баланың ничек үскәнен сизми дә каласың аны, диләр. Үсәр әле, әнә ич, әниләре ничек ярата аны... Арсланга да әйтеп тормаячак ул аның дөньяда барлыгы хакында. Нигә кирәк өстәмә каршылыклар тудырырга. Ә тора-бара һәммәсе дә ачыкланыр һәм үз эзенә кайтып төшәр...

Келт итеп төнге урман юлындагы хәлләр килеп төште аның хәтеренә. Фидаилнең әлеге дә баягы кыланышлары бернинди акылга да сыймый, әлбәттә. Нигә шулай этәчләнергә иде инде? Күргән ди, шуннан нәрсә? Аңлашырлар иде әле өйләренә кайткач... Бу кыланышлары белән үзе өчен өстәмә кыенлыклар гына тудыра ич. Онытырлар, җиңел генә гафу итәрләр дип беләме?..

Асиягә ачулансын да ди инде... Ә башкаларның ни гаебе бар?! Арслан белән шофер егет бу хәлне башларына да сыйдыра алмадылар ич. «Менә сиңа йомыкый... Менә сиңа мокыт...»— диештеләр. Үз күзләренә үзләре үк ышанмадылар булса кирәк алар. Бер-берсенә карашып, авызларын турсайттылар, иңсәләрен сикерттеләр... Ә Асия дәшмәде. Тик тыңлап утырды үзләрен: сез, ир-атлар, үзегез ачыклагыз, үзегез чара күрегез. Мин берни дә белмим һәм белергә дә теләмим, янәсә...

Юлдагы ул хикмәтләрнең Асиягә мөнәсәбәте бардыр диеп берәү дә уйламады, башына да китермәде, әлбәттә. Алар арасында ул — яңа кеше, берсе белән дә алыш-бирешкә кергәне юк. Капкаевлар утырган машина шоферы аның ире булып чыгар дип кем уйласын?! Шулай дип раслап торучылар булганда да ышанмас иде Арслан. Фидаил кем дә Асия кем?.. Икесен дә күреп белгән кеше ялгышып та ул хакта гөман кылырга кыймас иде...

Кыскасы, буласы — булган. Сабый түгел Фидаил дә, үзе майтарганнары өчен үзе җавап бирерлек яшьтә инде. Нигә дип әле Асия борчылырга, уйланырга тиеш ул хакта! Берәүне дә якламаячак, бер сүзгә дә катышмаячак — карары шул...

## 19

Алдагы бүлекләрнең берсендә Фидаилне авыл җирендә туып-үскән егет дип таныштырган идем. Әйе, Казаннан йөз илле чакрымнар чамасы ераклыкта урнашкан Нурлы Алан исемле татар авылыннан ул. Кайтып-китеп йөрү өчен юллары артык мактанырлык булмаса да, чишмәләре, су буйлары, урманнары белән дөньяның башка бер төбәгенә алыштыргысыз ямьле як... Авыл каршысында буйдан-буйга сузылган тау башына менеп бер күз салсаң, Нурлы Алан шундук күңелеңә мәңге чыкмаслык булып уелып кала. Аркылыга-торкылыга сузылган урам һәм тыкрыкларын, су буена тикле яшел алъяпкыч сыман салынып төшкән бәрәңге бакчаларын, көтүдән качып, чәбе-читән читләрен-

дәге кычыткан, тигәнәкләр арасында хуҗа булып йөргән кәҗәләрен, инеш буендагы тугайлыкларда канат кагынган каз-үрдәген, чиләк-көянтә асып чишмә суына төшкән әнисеннән арттарак калып, каурый җыеп йөргән сабыйларын, белмим, оныту мөмкинме икән ул авылның?! Мондагы егетләр элек-электән тирә-як Сабан туйларында бераүгә дә бил бирмәгән. Кызлары да — уңганлыклары белән булсын, һәм дә сылулыклары белән булсын — әйләнә-тирәдә тиңдәшсез санала...

Туган төбәк, туган авылны сайлап алмыйлар. Һәркемгә дә үз авылы, үз ягы аеруча ямьле тоела торгандыр. Әмма Нурлы Алан — башка, Нурлы Алан бер генә! Махсус сайлап эзләгәндә дә андый авылны табу, белмим, мөмкинме икән?!

Соң, шулай икән, шундый ямьле авылны ничек ташлап китәргә дә ничек онытырга кирәк диярсез... Билгеле инде, Фидаилне күрсәтәсез. Ул егет ни өчен дип әле туган авылын ташлап киткән дә типсә тимер өзәрлек чагында, эт типкесендә үк димәсәк тә, шәһәр читендәге тулай торакның кысан бүлмәләрендә вакытлы «пропискалары» белән газап чигеп йөри?.. Өйләним дисә, туган авылында кызлар беткәнме? Нурлы Аланда әллә шофер һәм механизаторларга кытлык юкмы?..

Нурлы Алан... Исеме белән үк әкиятне хәтерләтеп куйган шул авыл турында ишеттеме, Фидаилнең әле булса йөрәкләре «жу-у» итеп куя, тәннәреннән кырмыска өере чабып уза. Гомеренең иң матур истәлекләре туган авылы белән бәйләнгән аның. Матур истәлекләре... һәм бигүк матур булмаган истәлекләре дә... Шулай да беренчеләре өскә чыга, авылын һәм авылдашларын иң яхшы, кабатланмас яклары белән генә хәтерләргә тырыша иде ул. Нурлы Алан берөзлексез үзенә тартып, сүздә әйтеп, кешегә аңлату мөмкин булмаган яклары белән ымсындырып торды аны...

Әмма, барыбер, ни генә булмасын, ул анда кире кайтачак кеше дә түгел инде хәзер. Алыш-биреш беткән, аралар өзелгән. Истәлек һәм хатирәләрдә генә яши аның өчен хәзер Нурлы Алан. Балачак хыяллары томан артында калды, үсмер елларда корылган хыял-өметләр челпәрәмә килгән. Чыбыгочларын искә алмаганда, йөрешерлек, кайтып хәл белешерлек туганнары да юк анда хәзер. Өйләре торган урында тигәнәк һәм шайтан таяклары үсә. Ичмасам, әнисе кабере шул авылда булса икән?! Күрше авылдан килен булып төшкән әнисен, хәвефле үлеменнән соң, әби-бабалары янына — Югары Сөн зиратына илтеп җирләгәннәр иде.

Аралар өзелеп, кайтыр юлларына әрем үссә дә, туган авыл онытылмый, юк, онытылмый икән барыбер дә. Үзе әчеп үскән чишмәләр үксез калганнар төсле тоела иде Фидаилгә. Яланаяк йөгереп йөргән тау битләре, коры елга сукмаклары да аны юксыналар кебек. Ел да язларын ул ясаган ояларны эзләп кайта торган сыерчыклар кайда бала чыгара икән хәзер?.. Әнисе белән икәү утырткан миләш агачлары да үсеп җиткәндер. Көзгә кергәч ут сыман балкып утырган шул миләшләрне чукырга чыпчыклар җыела торгандыр. Юлдашы белән куыша-куыша качышлы уйнап туймый торган Җәке каенлыгы чын урман булып үскәндер инде.

Юлдаш... Тагын искә төшерде ул аны. Аклы-каралы шул эт белән күпме сукмак һәм юллардан үтте икән алар?.. Әле алга чыгып, әле бераз калыша төшеп, хәзер дә аның янәшәсеннән атлый-чабадыр кебек ул. Нурлы Алан табигатен Юлдашыннан башка күз алдына китерә алмый иде ул әлегәчә. Кече басу астына балыкка төшкән чаклары яңарып алды хәтерендә, көрт ерып, Әтәмән планына чаңгы таягы алырга менгән кышкы көннәр... Юлдаш әле дә исәндер, әле дә аның янәшәсендә... Әнә алар, көрт ерып, кышкы урманда сәяхәт итәләр. Койрыгын болгый-болгый, Юлдаш көртлек оялары эзләп йөри. Муеныннан көрткә чумган үзе, шулай да бирешми, өермә булып алга ыргылуында һаман.

Ап-ак аркалары, чем-кара колаклары кышкы урманда аеруча матур тоела аның.

— Әни, этләр озак яшиме икән?— дип сораштыра иде ул әледән-әле. Шул ук соравы белән тимерче Мөхәммәтхан абзыйны да тинтерәтеп бетерә торган иде. Аучы Төхфәт абзасы белән дә сөйләшкәне булды бугай. Җаваплары хәтердә калмаган берсенең дә. Чөнки һәммәсе этләрнең гомере кешенекеннән кыскарак булуы хакында әйткәндер. Ә Фидаилнең андый җавап ишетәсе килми иде, шуңа канәгать түгел иде ул аларның җавапларыннан. Берсе дә төгәл генә белми, шуңа тегеләй дә болай да уйларга ара калдырып сөйләшәләр...

Юлдаш турындагы уйларын читкә куды Фидаил. Искә алырга рәхәт булса да, белә ич, ахыры матур тәмамланмый ул хатирәләрнең.

...Мәктәп. География дәресе. Гомумән, аның үзенә географиядән дә кирәклерәк фән юктыр сыман тоела иде. Күңеленә шулай уелып калган. Мәктәп директоры, сугыш ветераны Мәхмүт абыйлары укыта иде географиядән. Хәер, ул елларда «ветеран» дигән сүзне белмиләр иде әле. Сугышта булган — бетте-китте. Өлкәнрәк яшьтәге ирләрнең һәммәсе сугышта булган...

Чаларган аксыл чәчләрен сыпырып алгач, башын артка ташлый төшеп, күрсәтү таягын картага төбәп сөйләп китә Мәхмүт абый:

— Карпат дигән таулар бар... Әле сугышка кадәр үк хезмәт итәргә туры килде миңа шул якларда. Без Карпатка кергән чакта җәй иде Карпатта. Әй, ул җәйләрне...— дип, күзләрен серле кысып, хәйран калуын белгертергә теләп, башын болгап куя укытучы.— Карпаттагы җәйләр... Тау битендә йөзем куаклары үсә, бакчаларда — черешня... Авызыңны ачсаң, койма читеннән, менә өзелеп төшәм, менә өзелеп төшәм, диешеп, шәмәхәләнеп торган сливалар күз кысыша.— Шул урында янә туктап, пауза ясап куя Мәхмүт абый. Болай да чия-черешняларның тәмен күрсәтеп, юешләнеп торган иреннәрен сыпырып ала иплә генә.— Ул абрикос, гранатлар, мин сиңа әйтим, кайсын телисең — өзеп ал да аша гына...

Татар авылы илленче-алтмышынчы елларда да әле бакчасына бәрәңге, суган, кишер һәм чөгендердән башканы утырта белми иде. Дөньяларын онытып, шул кадәрле дә тәмле җиләк-җимешләр турында хыялланып утырган класс тирән сулыш ала — ухылдап куя. Виноград, сливалардан авыз итеп карау кая, исемнәрен беренче кат ишетүләре. Ә Мәхмүт абый дәвам итә, тагы да тәмлерәкләре калган икән әле...

Тыңлап утыручылардан берәү, башлаган җөмләсен дә тәмамларга ирек бирми Мәхмүт абыйсына, төкерекләрен йота-йота сорап куя:

— Абый, ул слива, чиршинә дигәннәрен ашап та караганың булдымы әллә? Тагы бер кат сөйлә әле, абый?..

Сорау бирүчегә гаҗәпләнгән сыман карап ала укытучы. Тел очы белән иреннәрен ялтыратып куя юри.

— Кызык син, Фатыйхов... Соң, үзең уйлап кара, ашап карамыйча, тәмен каян белим ди инде мин аның?! Чиләге бер тәңкә иде ул җимешләрнең.

— Хәзер тагын да очсызрак микән, абый?..

— Белмим, Фатыйхов, барып күргәч әйтермен, ярыймы...

— Берсен генә авыз итсәң иде аны...

— Ярый, житәр Фатыйхов, бер тамагыңа хужа да була белергә кирәк. Дәресне дәвам итәбез,— дип, хыялланып, түшәмгә таба киерелгән малайның җилкә чокырын таяк очы белән кашып ала укытучы.— Карпаттан арырак китәбез...

Әле узган дәрестә генә Кавказ турында сөйләп, андагы әкәмәтләр белән шаккатырган иде Мәхмүт абыйлары. Әфлисун, мандариннар, хөрмә җимешләре хакында сөйләгәне хәтергә уелып калган. Әстерхан карбызлары. Бохара кавыннары турында да беренче тапкыр география

дәресендә ишетте Нурлы Алан малайлары, кызлары. Барысын да үзе күргән, үзе татып караган укытучыны хәйран калмый тыңлап кара! Мәхмүт абыйларының, ничә ел укытып, «монда булганым юк, боларны күрергә туры килмәде» дигән сүзен ишетмәде алар. Котыпка да үз аяклары белән барып чыга иде Мәхмүт абый, океандагы ерак утрауларга да. Берәүнең дә, тукта, бу кадәр илләрне, җирләрне гизәргә бер түгел, биш гомер дә җитми торгандыр ич, дип шиккә калганы булмагандыр. Күрмәгән, белмәгән илләр турында шулкадәрле ышандырып ничек сөйләргә мөмкин, югыйсә?..

Мәктәп директоры булганга күрәдер инде,— башка бер-бер укытучы авырып китсә, аның урынына Мәхмүт абыйлары керә торган иде дәрескә. «Урра» кычкырып каршылыйлар иде үзен. Кайсы дәрес өзелгән булса, шуны укытты.

Тарих дәресләрендә малайлар кәгазьдән үзләре ясаган самолет очыртып уйный, кызлар хат алыша торган иде күбрәк. Рим императорлары, Мисыр фиргавеннәре хакында сөйләп кенә шаккатырып була димени соң авыл балаларын? Монда да әмәлен тапты, авызына каратып торды Мәхмүт абыйлары:

— Борынгы Мисырда булырга туры килмәсә дә, Каһирәне аркылыдан-буйга ураганым, Нил елгасы ярында чүгәләп, уч тутырып, Нил суын эчкәнем бар,— дип башлап китте ул чираттагы тарих дәресен.— Без Мисыр башкаласы Каһирәгә килеп кергән чакта...

Самолет ясарга дип хәстәрләп куелган кәгазьләр шундук онытылды, кызларның кулларына алган ручкалары идәнгә тәгәрәде. Класста чебен очкан аваз да ишетелмәде башка. География дәресләрен хәтерләтеп, ара-тирә Нил суы буенда үскән җиләк-җимеш бакчаларына да кереп чыга иде ул, банан һәм ананас плантацияләрен урап уза. Тыңлап утыручыларның күзе, укытучы кулындагы очлы таякка ияреп, дөнья картасын айкый, ә җиләк-җимеш плантацияләре хакында сүз чыкканда, классның әле бер почмагында, әле икенче почмагында тирән сулыш алган авазлар ишетелеп куя...

— Абый, ул Мисыр дигән җирдә коммунизммы соң әллә? — дип, урыныннан калкынып куя, башкалардан элегрәк тәкатен җуйган Зәки атлы малай.

«Коммунизм»— житди сүз. Андый очракны игътибарсыз калдырмый гадәттә Мәхмүт абыйлары. Ипле генә атлап, сорау бирүче янына килә һәм, үз итеп, аның колагына чиертеп ала:

— Анда — колбиләүчелек, Фатыйхов,— ди ул житди итеп.— Кара инде, Фатыйхов, тарихны син бөтенләй дә белмисең икән бит...

— Ник белмәскә... Беләм, абый!

— Колбиләүчелек белән коммунизмны бутыйлармы инде?..— Күзләрендә очкын уйнап ала укытучының. Туп-туры атлап, карта каршына әйләнеп кайта ул һәм классның иң ерак почмагына караш төбәп уйга кала.— Мин өлгерерменме, юкмы, Фатыйхов, ә менә син... син, һичшиксез, коммунизмда яшәячәк егет.

— Алла боерса, диген, абый!..

Класс дәррәү көлеп җибәрә шунда. Укытучы сөйләгәннәрдән түгел, бер теленә хуҗа булмый утырган Зәкидән көләләр.

— Әби-бабаң өйрәткәнне онытырга вакыт, Фатыйхов,— дип шелтәләп ала мәктәп директоры. Әмма ул кадәр үк зурдан кубып түгел, күзләре, ирен читләре ачуланмый үзенең — әллә каян күренеп тора.— Ә үзең, Фатыйхов, коммунизмның кайчан буласын да белми торгансыңдыр әле.

— Беләм, абый, беләм... Алла боерсаны да мин, коммунизм тизрәк житсен дип кенә әйтәм, абый...

— Белсәң, җә, әйтеп кара?..

Үзенең белдеклелеген күрсәтүгә җай чыкканга куанып, читтән, урап башлый малай җавабын:

— Тагы биш елдан җан башына ит, сөт, җон һәм күкәй җитештерү буенча Американы куып тотабыз һәм узып китәбез, абый!..

— Тәк-тәк-тәк...— дип куәт бирә шулчак укытучы.

— Ә тагы ун елдан коммунизм, абый,— дип очкынланган күзләрен елкылдатып, утырып тора алмыйча, торып ук баса малай.

Укытучы аңарга гына канәгать түгел, малайның белем тирәнлеген сыный һаман:

— Төгәлрәк, Фатыйхов, төгәлрәк сүзләргә кирәк... Җә?..

— Соң, абый, ун елдан «минимум», ә җегерме елдан «максимум» инде. Миңа утыз дүрт тулганда, чын коммунизм килеп җитә... Соң, абый, кем белми инде аны?.. Клубның буеннан-буена язып куелган бит...

— Мәктәп капкасында да бар,— дип ачыклык кертә арткы рәтләрдән берәү.

Дөрес, дигәнне аңлатып, Зәки баш кага һәм борынын сызгыртып куя...

— Беләсең икән, Фатыйхов,— дип, малайга кире утырырга куша укытучы. Тимер тешләрен елкылдатып көлеп тә ала... Игътибарын, бераз күттерә төшеп, Зәкинең аркасына төртә-төртә чыш-пыш килергә керешкән укучыларга юнәлтә ул бераздан:

— Әйе, сезгә әйтәм, Мөгътәсимов... Монда, карта янына чыгыгыз әле. Сиңа да кагыла, Фәйзуллин. Әйе...

Малайлар, арканларга алып барган бозаулар сыман, теләр-теләмәс кенә, класс түренә узалар. Каршыга чыгып баскач, шулай да, укытучы күрмәгәндә, елмаеп алырга да өлгерәләр. Карап утыручы кызлар өчен монысы: әнә без нинди батыр йөрәкле, директор үзе ачуланганда да сер бирмибез, янәсе.

Укытучы күрми дип уйлыйлар. Ә Мәхмүт абый күрә, күз чите белән яшертен генә күзәтеп тора ул аларны.

— Без монда, пнимаетте ли, Фатыйхов белән киләчәкне кайгыртабыз... Ә сез?.. Ничек оят түгел сезгә? Сез ни эшлисез?!.

— Бернәрсә дә эшләмибез, абый...

— Ипидер, абый, тыңлап кына утырадырыек...

Мәхмүт абый бер — класска, бер малайларга караштырып ала. Аптыраштa калган, ышанырга мы боларга, юкмы, янәсе...

— Җә, Фәйзуллин, синнән башлыйбызмы?.. Әйт әле, әнә теге кесәңдә нәрсә бар анда синең?.. Безгә дә күрсәт әле, Фәйзуллин!

— Җук бит, абый...

— Ә мин әйтәм — бар. Оялма, күрсәт әле, Фәйзуллин. Син батыр егет ич, күрсәт!..

Берни эшләп тә булмый, теләр-теләмәс кенә өстәл өстенә әлеге дә баягы шул кесәсеннән рогатка чыгарып салырга мәҗбүр була Расих.

— Ә синеке?

Мәктәп директоры икенче малайга таба борылып сүз башларга өлгерми, теге җәт кенә ике чалбар кесәсенең эчке ягын әйләндереп куя. Ә Мәхмүт абыйның гаме юк аның буш кесәләрендә.

— Синеке парта астында калды, шулай бит, ә, Мөгътәсимов!?.

Наилнең танымый чарасы юк, башын түбән ия:

— Каян беләсез аны, абый?

Һәм ул үз рогаткасы артыннан йөгереп китеп бара.

— Соң, Мөгътәсимов, Мәхмүт абыең шуны да белмәскә?!. Синең ише ташбашларны беренче ел гына укытуы түгел ич аның,— дип мактанып ала мәктәп директоры. Наилне дә рәнҗетүе түгел бу аның, сөйләшүе шундый, тәрбия итүе.— Бәлки әле мин синең бүген иртән нәрсә ашаганлыгыңны да белә торганмындыр?!.

Белмисез лә, арттырып җибәрәсез, дигән сыман башын чайкап куя малай. Ул инде елмая, өстәл өстенә китереп салган рогаткасы да кызганыч түгел аңа, укытучының үзе белән шулай сөйләшүе ошый.

— Бүген иртән...— дип, уйга калган атлы булып тәрәзәгә күз төшереп ала директор.— Бүген иртән Мөгътәсимов дигән малай ике кыерчык ипи һәм әрчеп пешерелгән кайнар бәрәңге ашаган.— Дөреслекне ачыкларга теләп, малайга сынаулы караш ташлап куя. Һәм дәвам итә.— Ә менә анаң ясап куйган бер чокыр сөтле чәеңне эчеп бетермәгәнсең...

— Абый-ый, каян беләсез аны?— дип телсез кала малай. Күзләре чак маңгаенда түгел.— Әүлия инде әллә сез?!.

Ашау хакында озаклап сүз куертып тору, билгеле, директорга килешә торган нәрсә түгел. Шуңа сүзен тизрәк читкә бора:

— Нәрсә, Мөгътәсимов, коммунизм ул Фатыйхов өчен генә киләмени?...

— Безнең өчен дә...

— Ә болай, дәрестә рогатка ясап утыручылар белән төзеп булырмы икән соң ул коммунизмны?..

— Була, абый! Төзеп булмый торган булса, клубка язып элмиләр дә инде аны...

— Мәктәп капкасына да...— дип өстәп куя моңарчы борынын гына сызгыртып торган Расих.

Мәхмүт абый Мөгътәсимов һәм Фәйзуллин белән артык сүз куертып тормады. Рогатка ясаучылар белән ни сөйләшергә мөмкин янәсе, сүзен дәвам итте:

— Кырык дүртенче елның апрель ахырлары иде... Без Берлинга бәреп кергән чакта...

Фидаилләрнең өе Мәхмүт абыйларының йорты белән бер урамда иде. Аның төпчек улы Илдус белән (Илдус бер класска түбәнрәк укыгандыр) җәйләрен ындыр артындагы кукуруз басуында үлән җыя иде алар. Хәзер ничектер, ул елларда, Сабан туеннан башлап кара көзгә кадәр, авыл кешесе — яше, карты — печән-үлән җыю мәшәкатьләреннән арынып тормый иде. Болыннар сукалап атылган. Су буе һәм вак кына ерганакларга кадәр көтүлеккә бирелгән. Каравылчы-фәлән белән танышлыгың юк икән, урман юлына да аяк атларга ярамый. Икмәкнең хезмәт көненә, күп булса, бер кило чамасы бирелгән еллары. Авыл кешесен хәтта салам да бирми тинтерәтәләр иде. Булмаганлыктан түгел, басу тулып череп кала иде ул елларда салам, язларын ут төртәләр иде салам эскертләренә. Ә авыл кешесенең мал асрыйсы килә, итле һәм сөтле, йонлы һәм тиреле буласы килә. Авызыннан кара кан китсә китә, әмма сыерсыз торуны хуп күрми иде берәү дә...

Хәтерләүчеләр бардыр — чатлама суык кышны, буранлы төндә кәҗәсенә бер кочак салам алырга дип басуга менгән әбидән көлеп шигырь язды шагыйрьләр дә ул елларда. Ул ялгыз әбинең ире (бәлки, уллары да) ватанны саклап, сугыш кырында ятып калган булгандыр.

Кәҗәбезгә печән беткән,
Колхозныкы хәләл микән?..

— шундый юллар белән башланып киткәне әле дә җуелмаган хәтердән. Башка чарасы калмаган әби, ни эшләсен, күрше малаен ияртеп, караңгы төндә җир читендәге басу түренә, чана тартып, көрт ерып, салам эскерте юллап чыгып китә. Фидаилгә таныш күренеш иде бу, чөнки бер тапкыр гына үтәргә туры килмәгәндер аңарга да андый хәвефле сәфәрләрне.

Сәмигулла, балакаем,
Син карап тор, мин йолкаем.

— дигән юлларын да хәтерли. Нәкъ Нурлы Алан хатыннары сыман ягымлы итеп әйтелгән ул сүзләрне ничек онытмак кирәк?..

Кара төндә салкын кырда кача-поса шулай салам йолкып яткан әби белән малай янына берзаман атлы каравылчы килеп чыга... Шунданмы?.. Шуннан — шул инде, шигырьнең юллары барысын да ача да сала. Талантлы халык бит ул шигырь чыгаручылар:

«Атам!»— диде, мәхәббәтсез,
Әби калды тәһарәтсез...

Шул «шигырь»не өлкә газетасында бастырып чыгардылар иң элек. Шуннан күчереп, район газеталары кабатлады. Берничә ел рәттән Казанда татар телендә чыга торган «численник»та да бастырып чыгардылар үзен. Тегеннән-моннан килгән үзешчән һәм профессиональ артистлар концерты да ул шигырьсез узмады... Халыкка нәрсә? Кызык ич, укыган саен, ишеткән саен көлә иде халык. Тол калган ялгыз апалар көлә иде эчләрен тотып, без — малай-шалай — көлә идек, «Нәкъ безнең авылдагыча икән бу» дип... Халык үз-үзеннән көлдерергә генә түгел, үз-үзеннән көләргә дә тәмам өйрәтеп җиткерелгән булгандыр, күрәсең...

Нәкъ шул елларда булды бу хәл: Мәхмүт абыйның Илдус атлы төпчек малаен ияртеп, Фидаил ише берничә «ташбаш», һәр яңа көн туган саен, ындыр артындагы кукуруз басуына юнәләләр. Кукурузны үстереп күрсәтәләр иде ул елларда... Аның арасында эт эчәгесе, сары тәтәй, зәңгәр тәтәй (бу үләнне күкчәчәк дип тә йөртәләр) кебек төрле чүп үләннәре үсә. Чүп үләннәр, гомумән, күкрәп үсә иде колхоз кырларында. Ә үзләрен җыярга ярамый, җир — колхозныкы. Бәрәңге һәм карабодай басуына кереп булмый — әллә кайдан күреп алалар үзеңне, ә кукуруз саклый, ул биек булып үсә. Шулай итеп, малларның көтүдән кайтуына үлән әзерлим дисәң — ул да булса кукуруз басуыннан. Йөрү өчен рәт аралары да киң була торган иде кукурузның. Ун бармак белән җир тырнап җыясың да җыясың эт эчәгесен, җыясың да җыясың. Биләр сызлый, үрмәләп йөри-йөри тез башлары кызарып чыга, тырнак астына үзле каты балчык кереп тула, ә син һичнигә карамыйсың — узыша-узыша чүп үләне йолкуыңны беләсең.

«Синең ике култык асты тикле дә булмаган, ә Галәвич әнә тау тикле итеп өеп куйган (Миңлегаязны, этисе Галәү исемле булганга, шулай атап йөртәләр. Чөнки Миңлегаязлар өй борынча иде Нурлы Аланда. Бар, аерып кара син аларны кушаматсыз гына!..) Бакчабаш Миңлегаяз аны да уздырып җибәргән...»— дип коткы сала арадан берәү. Шуннан башлана инде — калышасы килми, үҗәтлек җитәрлек. Уңнысулны белми сикергәләп җыюыңны беләсең, баш күтәрер ара да юк. Дөньяңны онытып сикергәләп йөргәндә, үч иткәндәй, бер-бер таш-фәлән яисә кантарга абынып, әйләнеп барып та төшәсең. Каешланып беткән, мунча ташына әверелгән ялан аягыңның баш бармагы канап чыга. «Тьфү!»— дип, аякка төкерәсең дә үзле балчык белән сылап куясың. Аяк турында уйлый торган чакмыни, үлән йолкыйсы бар, калышасы килми башкалардан!..

Иң рәхәте — җыйган печәнеңне сырлы тәгәрмәчтән үзең этмәлләгән тратайкага төяп юлга чыгу. Төяү — үзе сәнгать. Әйтик, берәүләр юк кына печәнен дә тау кадәр итеп өеп куя — күрсәтә белә. Кулыңнан килми икән, дөнья кадәр җыеп та, кеше көлкесенә калуың ихтимал. Чөнки, печәннең күплеген йөккә салгач бәялиләр. Тыкрыклар аша авылга да керәсе бар бит әле...

Әмма авылга җиткәнче «фронт сызыгын» узасы бар. Кукуруз басуы белән бәрәңге бакчалары арасы малайлар телендә шулай атала торган иде. Һәм бер дә юкка гына түгел: чөнки андагы юлдан берөзлексез басу каравылчысы йөреп тора. «Бәхетең» булса, председательнең үзенә үк килеп капканыңны сизми дә каласың.

Тратайкаларны куеп торып, басу читеннән юлны күзәтү башлана. «Тарантасына басып, персидәтел Сафин килеп чыга күрмәсен!.. Пләвәй

Закир күренмиме?..» Теге чакта авыл советы йомышчысы булып йөргән Куштан Закир җәй житсә «пләвәй» — басу каравылчысы булып китә торган иде... Тәүлекләр буе төшми ат сыртыннан. Көненә ике-өч малайны тотып ишмәсә, күңеле булмый. Борчак басуына таба үткән кеше күренмиме?.. Шулай да иң каныкканы — кукуруз басуыннан эт эчәгесе җыйган малайлар!

Такыр итеп кырылган йомры башлар җиргә ятып тыңлый, үрелеп-үрелеп күзәтәләр юлны — пләвәй күренмиме?.. Бу эш күп вакытта Фидаилгә йөкләтелә торган иде: колаклар шәп аның — локаторларың бер читтә торсын.

Сулыш та алмый, башта бер якны, аннан икенчесен күзәтте Фидаил. Хәрби задание кебек җаваплы эш бу, ялгышу ярамый. Ул-бу ишетелми иде кебек. Этләр өргәне дә ишетелми... Чөнки, якын-тирәдә пләвәй Закир күренсә, авылдагы һәммә эт, сүз берләшкән сыман, өрергә тотына... Кукуруз басуыннан десант сыман басып чыга малайлар. Кулларында тратайка сабы, тәгәрмәчләр көпшәк җиргә бата — җиңел түгел. Ашыкмыйлар, һәммәсе житди — күзәтәләр. Шулай да җәһәтрәк булганың хәерле андый чакта, ялан аяклар кая басканны белмиләр...

Ул да түгел, җир астыннан калкып чыккан төсле, Куштан Закир пәйда булмасынмы?! Атка атланган!.. Авыл читендә, Мыкра Юнысларының бакча башындагы иске мунча артына качып сагалап торган. Эт өргән авазларның да ишетелмәве гаҗәп түгел: ул урамда, көчек затын да калдырмыйча, шул кышта гына эт аттырган иде Куштан Закир.

Ике уйлап торыр ара юк, атакага ташлангандай, авылга таба ашыга малайлар. Теге килеп житкәнче, бер-бер кешенең бәрәңге бакчасына яисә басуга мал чыкмасын өчен киртә белән тотылган тыкрыкка кереп шылу исәпләре.

Пләвәйләрнең ат шәп була. Куштан Закир да үзенең атына кукуруз чәкәне генә ашата ди. Томырылып, канатлы ат сыман очып килә, малайларның борынын кисәргә исәпләп, туры өсләренә йөз тота.

Үч иткәндәй, юлның урта бер җирендә Фидаил тратайкасының күчәре килеп чыкмасынмы!.. Җыйган-төягән үләннәр аяк йөзен күмеп торган тузанга капланды. Андый чакта баш кадерле, тратайканы ташлап, печән хакында да онытып, ул да бүтәннәр артыннан элдерде... Бакчабаш Миңлегаяз сикерде иң элек бәрәңге бакчасына. Аның артыннан ук Фидаил белән Галәвич тә шуып төштеләр. Күлмәк ертылу, тән сыдырылуише вак-төяк турында уйлап торды юк инде — үлән төялгән тратайкаларны аргы якта калдырдылар... Бәрәңге сабаклары арасыннан ызан буйлап бер читкәрәк үрмәләделәр дә күзәтергә керештеләр.

— Һаа-ай, аналарыгызны!— дигән кыргый аваз яңгырады якында гына. Ат пошкырганы ишетелде.

Ничек шулай килеп чыккандыр, буйга башкалардан һич кайтыш булмаган Илдус чәбе аша сикерергә өлгерә алмый калган. Кушаяклап томырылган көйгә үз өстенә чабып килгән аттан, аттан бигрәк, чыбыркысын яман болгый-болгый җанвар авазлары чыгарып кычкырган пләвәйнең үзеннән куркып чырылдап җибәрде Илдус:

— Әти-и!— диде. Башка малайлар андый чакта йә дәшми, йә әнисен чакыра торган була. Ә Илдус, директор малае булуын искәртергә теләптер инде, әтисен искә алды.

Бәрәңге бакчасында качып ятучыларның күз — маңгайда, сулыш — табан астында, билгеле.

— Нишләтә инде?— дип, мыш-мыш шуышып, Бакчабаш янына килә Галәвич. Янәсе, «Бер-бер чара күрү кирәкмиме?.. Арабызда син — иң өлкәне...» Фидаил дә янәшәдә генә, аерым-аерым ятулар шүрләтә.

— Илдус — директор малае... Илдуска тимәс...— диде Бакчабаш. Тыныгыз чыкмасын дигәнен аңлатып, йодрыгын да күрсәтеп алды. Куштан Закирдан барын көтәргә мөмкин, кеше бакчасына кереп тә

чыбыркысы белән бер-икене сыдырып чыгарга күп сорамас.

...Илдусны ул чәбе башына менеп җиткән җиреннән кире тартып төшерде. Һәм ат өстендә көе генә, яман кизәнеп, күн итеге белән берне тамызып та алмасынмы?! Чәбе читендәге кычыткannar арасында ятып калган тратайкаларның кайсынадыр абынып, сөрлегеп китте директор малае һәм канауга йөзтүбән капланды. Ә Куштан Закир:

— Таптатам мөртәтне!.. Таптатам едриона!.. Калхуз кукырузы...— дип кычкырып, бервәзлексез сүгенеп, авызлыкланган атын һаман малай өстенә таба борырга азапланды.

— Закир абы-ы-ый!..— дигән тонык аваз ишетелеп алды канау төбеннән. Бәрәңге бакчасындагы малайларның йөрәк кысып куйды, «Нишлибез?» дигәндәй, Бакчабашка таба карап алды һәммәсе.

— Калхуз кукырузын!.. Ах, едриона!..

Атының һаман үзен тыңламавы, малайны әйләнеп, әле бер, әле икенче якка тартылып, бер урында тик биеп торуы ошап бетмәде Куштанга. Як-ягына карангалап алды да җиргә сикерде ул, һәм, иң элек, күн итеге белән атның касыгына китереп типте. Аннан, чыбыркысын яман болгап, малай өстенә турылап китте. Куштан Закир кебек җидесигез катлы итеп «грамытны» сүгенүчене ишеткәнегез дә юктыр — буразнага сеңгән малайлар, ни еларга, ни көләргә белмәде, өнсез калдылар:

— Тор, анаңны!.. Тор диләр сиңа, едриона!.. Нәрсә монда, колхуз кукырузын...

Аркасын чыбыркы телеп узгач, башын калкытмый чарасы юк иде Илдусның. Теләр-теләмәс кенә торырга да мәҗбүр булды бераздан, «егылганны — кыйнамыйлар» дигән гыйбарәне бар дип тә белми чөнки теге.

Пләвәй директор малаена иң элек тратайкалардагы һәммә үләнне бер урынга өйдерде. Фидаилнең юл тузаны өстендә ятып калган үләнен дә өстерәп алып килде Илдус.

— Тизрәк маташ, җен камалаган нәмәрсә!..— дип куалады аны Куштан.

Үзе нәрсә әйтсә, шуны үтәп торган малайга янә бер тапкыр чыбыркы сабы белән китереп кундырды да, ниһаять, эшкә керешге ул. Иң элек канау читендә яткан зур ак ташка бәреп, тратайкаларны йомычкага әйләндереп чыкты. Чыбыркысын күн итек кунычына тыгып, кесәсеннән пәке тартып чыгарды, бауларын туракларга керешге малайларның. Баудан да кадерле нәрсә юк иде ул елларда, каештан үрелгән бау — малайларның куанып туймас хәзинәсе. Шуларның юкка чыгуын күреп торган малайларның бәгырьләре өзелмәгәндер дисезме?!. Эшен тәмамлап, пәкесен кесәсенә кире тыкты да дүрт малайның көне буе тырманып җыйган һәм бергә өйгәч нәни генә чүмәләгә охшап калган үләне өстенә менеп басты Куштан Закир.

— Нишләргә җыена бу?— дип пышылдады Галәвич.

Бакчабашның күзләре яшьләнгән иде. Шуны яшерергә теләүдәндер инде, читкә борылды ул:

— Хәзер күрерсең...

Күрәсезме мине, дигән сыман, канәгать киерелеп, як-ягына каранып торды Куштан бераз. Кем дә булса күрер дип уңайсызлану юк: чалбарын тезенә кадәр төшерде дә печән өстенә чүгәләде...

— Куштан тәре!..— дип, узалларына уфтанып ухылдарга гына калды малайларга. Йомарланган йодрыклары белән бәрәңге буразнасын төйде Фидаил.

Ә бераздан, атын ипле генә атлатып, сызгырына-сызгырына китеп барды басу каравылчысы. Шул көннән башлап Илдус гомергә тотлыга торган булып калды.

Пләвәйнең явызлыклары аның белән генә бетмәде. Ялгыз карчыкларның коры елга үзәненә арканланган бозауларын җыеп кайтып, ат сараена кертеп япты ул. Икешәр-өчәр тәүлек ашарларына, эчәрләренә

бирми тотты шунда. Бозаулары кычкыруга түзә алмаган хатыннар шул сарай ишеге төбендә төн кундылар, әмма файдасызга... Авыл читенә чыккан каз-үрдәкләрне тузгытып, канатларын сындырып кайтарды ул. Кыр эшеннән кайтып килгән хатыннарны сагалап торып, тегеләрнең әллә кай төшләрен тентегән дип тә сөйләделәр...

Нәрсә генә эшләмәсен, ниләр генә кыландырмасын, җил-яңгыр тимәде Куштан Закирга, аңарга сүз әйтергә базмады берәү дә. Дистә еллар дәвамына тәмам куркытылган халык аның явызлыклары хакында үзе югында гына сукрана торган иде. Чөнки беләләр: Куштан Закирның исеме колхоз җитәкчеләренең теленнән төшми, рәсеме — район үзәгендәге мактау тактасында...

Ә менә хикмәтле дәресләре белән Нурлы Алан малайлары-кызларының күңелләрен биләп торган мәктәп директоры Мәхмүт абый авылдан чыгып китәргә мәҗбүр булды. Фидаил кебек малайларга бу китүнең һәммә нечкәлекләре мәгълүм булмады, билгеле. Шулай да Куштан Закирның этлекләре белән бәйле икәнлеге аермачык иде. Имеш, больницадан-больницага йөреп-йөреп тә, улының тотлыгуы бетмәгәч, бер аулак урында очратып, Куштанның арт сабагын укыткан икән ул:

— Без Берлинга таба барган чакта синең ише корткычларны менә болай итеп ала идек тә, менә болай итеп арт шәрифләренә берне китереп ямый торган идек,— дип, шуларның барысын төгәл башкарып күрсәткән.

Куштан Закир берни дәшмәгән, чиелдап кына куйган аулактагы бу очрашу вакытында. Аның каравы, соңыннан сасыткан дөньяны. Иң элек авыл советында сөйләгән төкреген чәчеп. Аннан колхоз идарәсенә чакырттырган мәктәп директорын.

— Малае корткычлык кылып, кукыруз таптый едрионаның!...— дигән.— Корткычлык иткән малаен тәрбия итәсе урында, каравылчыга кул күтәрә!— дигән.

Аның белән генә дә чикләнмәгән, райкомга җиткергән эшне, «Юкса, Абкумга язам, Мәскәүгә җитәм»,— дип янаган... Мәхмүт абыйны директорлыктан төшерделәр. Бераздан ул бөтенләй укытмый да башлады. Ике-өч ай үткәндерме, анда сугылып, монда сугылып йөргәннән соң, дүрт-биш баласын ияртеп, авылдан да чыгып китәргә мәҗбүр булды.

Жигүле ат артыннан ияреп, авылны чыгып барганда, яшьтәш малайларына каршы очраган Илдус, җиң очы белән күз яшьләрен сөртеп, болай дигән:

— Ми... ми... минем а... ар... када бу... бул-ды,— дигән.

Авыл каршындагы артыш куаклары үскән тау башына менеп җиткәч, тукталып, атлары хәл алган арада, озак кына бөтен гаиләләре белән Нурлы Аланга карап торганнар. Ни уйлап торганнардыр, күңелләрендә ниләр булгандыр — бары үзләренә генә мәгълүм. Ат җигеп, тимер юлгача озата барган мәктәп конюхы Мәхмүт абыйның бер генә җөмләсен отып калган:

— И-их,— дип әйткән ди Мәхмүт абый, авылга карап торган чагында.— Шунысы җәлке, Фатыйховлар кала... Фәйзуллин һәм Мөгътәсимовлар кала,— дип әйткән ди.

## 20

Арсланның элек-электән килгән бер мавыгуы, йомшаклыгы бар. Ул да булса — детектив. Китап укуны — күз сукырайту, театрны — вакыт уздыргыч, музей һәм күргәзмә залларын — эшсезләр йөри торган урын дип санавына да карамастан, детективка мөкиббән киткән кеше. Телевизордан караганы — детектив. Укыганы — детектив. Газеталарны да ул, тегеләр август-сентябрь тирәләрендә «подписка» ягын кайгыртып, детектив әсәрләрдән өзекләр бастыра башлагач кына кулына ала

торган иде. Ашау-эчү, киенүгә үтә нәзберек һәм таләпчән булса да, детектив әдәбиятны ул, талымсыз рәвештә, очраган берсен укып бара. Чит ил детективымы, Юлиан Семеновныкы яки Мәгъсүм Насыйбуллинныкымы — аның өчен барыбер. Урласыннар һәм үтерсеннәр генә... һәм, билгеле инде, эзләсеннәр. Тоту-тотмау — аларның эше.

Кулына детектив әсәр килеп эләксә, кабинетына кереп бикләнеп, көннәр буе телефон трубкасын да алмый онытылып укый ала ул. Битарафлык белән түгел, борчылып, янып, бар вакыйгаларны үз башыннан уздырып укый. Хәер, детектив яратучылар һәммәсе шундыйлар... Тик Арслан Сәхиповичның бер үзгәлеге бар. Ул күңеле белән һәрчак эзләүче, эзәрлекләүче ягында түгел, ә бәлки качучы, эз югалтырга тырышып, хәйлә артыннан хәйлә коручы ягында. Тегеләр эз югалта белсә, кәефе күтәрелә аның. Ә инде, аның карашынча, ахмаклык эшләп куйсалар, тотылсалар, тиргәргә керешә үзләрен. «Мин булсаммы, мин булсаммы?.. Ахмаклар!...»— ди-ди тирги ул аларны. Болай итәр идем дә тегеләй итәр идем дип, үз вариантларын корып карый.

Әсәрләрен укырга яратса да, детектив язучыларның үзләрен сөйми, өнәп үк бетерми иде ул тагы. Дөресен язмауда, ялганда һәм дә караклык дөньясының нечкәлекләрен белмәүдә гаепли ул аларны. Каракларны, үтерүчеләрне гел-гел ямьсез, дорфа, эчкече итеп сурәтләүләре белән дә килешми. Тормышта бит киресенчә дә була.

Детектив ул — тормыш мәктәбе дә әле тагы. Әйтик, детективлар дөньясыннан мәгълүматлы булмаса, хәзер ни эшләр иде икән ул?!. Шактый кыенга туры килгән булыр иде. Теге көнге хәлләрдән соң аның үз тормышы да детективка әверелә түгелме соң?!. Кемдер аны эзәрлекли, кемдер аңарга янарга тели... Ләкин кем?.. Ялгызы калган чакта колак төбендә берөзлексез шомлы музыка яңгырагандай ишетелә. Артыннан, үзенә сиздерми генә, кемдер эзәрлекләп килә кебек, читтән генә үзен берөзлексез күзәтәләрдер сыман... Кулыннан эш качты, төннәрен күзенә йокы кермәде. Ишек ышанычлы бикләнгәнме, балконда бер-бер шикле күләгә күренмиме ди-ди, әллә ничә мәртәбәләр урыныннан торып, тикшереп чыгарга мәҗбүр булды. Йокларга ятканда, өйдәгеләргә күрсәтмичә генә, мендәре астына нәни балта салып куя. Хатыны ясаган чәйне дә шикләнеп кенә эчә, башта бер йотып ала да, көтә, ул-бу салынмаганмы — баш әйләнмиме, күңелне болгатмыймы?..

Капкаев хакында уйлады ул еш кына. Әмма шик уятырлык мөнәсәбәтләрнең алар арасында булганы юк кебек. Хикмәт тирәндәрәк яшеренгәндер төсле тоелды аңар. Җеп очы кая яшерелгән — һич аңлармын димә!.. Бар эшнәләрен кат-кат күздән, күңелдән кичереп чыкты. Соңгы арада кылган эшләрен, очрашкан, сер уртаклашкан танышларын барлады, энә күзеннән уздырды барын да.

Берәүдән дә шикләнергә сәбәп юк кебек. Ә икенче уйласаң, бар да кебек. Бәлки, кемгә дә булса ул артык тоела башлагандыр, аны юлдан алып ату кирәк булгандыр? Сәбәпләре дә табылырга мөмкин... Әйтик, ул эшләгән базага директор булырга хыялланучылар булырга мөмкинме? Ничек кенә әле!.. Әйләнә-тирәсендә: «Арслан Сәхипович та Арслан Сәхипович...»— дип бөтерелүчеләр арасында икенең берсе шундый хыял белән яши торгандыр әле. Кулыннан киләме, юкмы — ул турыда уйламый, ә дәрәҗәле, төшемле урынга менеп кунаклау уе белән төн йокыларын йокламаучы аз түгелдер. Кабинетка кереп утырса, эш үзеннән-үзе барыр төсле тоеладыр аларга?! Сәүдә оешмасында эшләүнең атынып торган канат-бау өстеннән йөгереп йөрүгә тиң икәнлеген белмиләр шул.

Ә база... Универсаль база — шул бау аша йөрүчеләрнең музыканы туктатып, утны кыса төшеп башкара торган иң соңгы дәрәҗә киеренке номерлары кебегрәк ул. Җитмәсә, шул базага баш хуҗа булу. Мыжгып торган күселәр арасында ит-май, колбасаише нәрсә саклап буламы икән?!. Ә универсаль база директоры очын-очка ялгап бара әлегә.

Теге, бау аша йөрүчеләрнең дим, алар егыла-нитә калса, саклык чаралары булмый калмас. Ә сәүдә дөньясында бердәнбер таяныч — үзең! Егыла-нитә калсаң, кул сузучы булырмы икән?!. Сузса, үзе яна-чак ич ул! «Капкан — капсын, чукынып катсын шунда» дип, тагы да тирәнгәрәк батырырга торучылар гына табылуы ихтимал. Үз урынбасар-лары һәм склад мөдирләреннән шикләнде ул аеруча...

Хикмәт эш урынында гына да түгелдер, бәлки? Кемнең эче нигә пошканлыгын каян белмәк кирәк. Әйтик, берәүнең аңардагы буй-сынга көнчелеге килергә мөмкин. Көдрә чәч, кара мыегы ошамый торгандыр, бәлки? Ә өченче берәүнең аның дәүләт машинасында утырып йөрүенә яисә иркен һәм уңайлы фатирда яшәвенә эче көя торгандыр. Хатыны да чибәр, кенәриннең дә теләсә кемгә тәтеми торганын тапкан чагы...

Капкаевны алмага җибәрелгән машина кайтып та житте. Юл читендә аерылышканнарыннан соң тәүге очрашулары. Килүченең авыз колак тирәсенә житә язган иде.

— Капкаев...— дип, үз-үзенә мөкиббән китеп исәнләште ул.

— Капкаев икәнеңне беләм. Житәр, кыланма!..— усал һәм сынаулы караш ташлады Арслан Сәхипович ишектән керүчегә. Детектив кинолар-да, әйтик, майор Томин яисә Джигарханян гына карый шулай үзәгеңне өзеп.

— Берәүләрнең башы авырта ахры,— дип, артык исе китми генә сөйләнә-сөйләнә, бер почмакта торган өстәл янына барып утырды Капкаев. Өстәл өстенә кесәсеннән сигарет чыгарып куйды. Зажигалкасын алды. Аяк өстенә аягын атландырып алгач, кабызып җибәрде.

— Шамакайланма, Капкаев!..

Артык күп сөйләргә ярамый мондый чакта, Арслан яхшы белә. Детектив киноларны аз карамаган. Инде менә үзенә дә сорау алырга кирәк. Ничегрәк башлыйлар иде соң әле?..

Капкаевның тынычлыгына исең-акылың китәрлек, әйтерсең берни булмаган алар арасында. Бу — сагаерга мәжбүр итте Арсланны. Аның уенча, бу очрашуга Капкаев, гомумән, килми калырга тиешле иде. Баксаң, килү генәме, аның түр башына ук үтеп, әнә, ботны-ботка атландырып, рәхәтләнеп, уен-көлке сөйләп утыра. Үзеңне әлеге шартларда шулай иркен тоту өчен, йә шыр тиле булырга кирәк, әй каршыңдагы кеше алдында үзеңнең зур өстенлегең барын тоярга... Капкаев тиле түгел. Авызын ерып, тилемсәгә салынып йөрсә дә, ни эшләгәнен, кайда һәм кем белән сөйләшкәнлеген аңламаслык кеше түгел. Исәп-хисапны яхшы белә, олыны-кечене аера белә...

«Димәк...— дип нәтиҗә ясады Арслан, детектив киноларның төп геройлары сыман,— болай булгач, минем үз хәлләрем дә әллә ни шәптән булмаска охшый. Ачыкларга кирәк, беткән баш беткән: монда ул тикшерүчеме, әллә аның үзен эзәрлеклиләрме?.. Эзәрлекләү булса, аңа сүз сөрешен иплерәк итеп алып бару хаерле...»

«Кем?.. Кайчан?.. Һәм ни өчен?..» кебек шомлы сораулар шөпшә оясындагы сыман ыгы-зыгы килде аның чигә тирәсендә. «Булсын да ди, ә причем соң әле монда Капкаев?!. Бер-бер хәвеф килү ихтималы булса, Капкаевтан элегрәк, Лев Белялович белергә тиеш түгелме соң ул хакта?!. Белмәс! Белсә, ул аңардан яшерер идемени?!. Әйтмәгән тәкъдирдә дә, «шеф»ның аңарга мөнәсәбәтендә чагылмый калмас иде бу. Башка сыймас хәлләр, менә сиңа детектив дисәң дә детектив!..

Капкаев дәшмәде. Әнисенең имчәгеннән тартып-тартып имгән ач чучка баласыдай, тик суыра сигаретын. Түшәмгә төбәп, бер ямь табып, авыз һәм борыныннан божра-божра төтен өрә.

— Йә, Арслан Сәхипович, теге көннән соң кәефләр ничек?— дип сорарга да өлгерде ул авыз-борынын сигареттан аерган арада.

Чынлыкта, Капкаевның булуы-исерүе житкән иде ул көнне, юлда булган вакыйгаларны ул хәтерләми. Шуңа, бәйрәмнән соң кунак озаткан хужа сыман, иркен тота үзен.

Арсланга да үзен ипле тотарга иде бит. Әмма куллары калтырый, тез турыннан аяклары сыгылып-сыгылып куя. Ишекле-түрле йөрүеннән туеп, өстәл янындагы кунак каршысына барып утырырга мәҗбүр булды. «Күзәтергә килгән... Башын тилемсәгә салып, сынарга маташа,— дип нәтиҗә ясады ул, тәҗрибәле детектив буларак,— Димәк, сынатмаска кирәк! Арслан Сәхиповичны бик җиңел генә юлдан алып атарга исәп тоткансыз әле сез, барып чыкмас! «Кәефләр ничек»,— имеш... Һич югында «теге көннән соң»ын искә алмаса иде... Күзгә карап, керфек тә селкетми елмаеп утыруын гына кара әле син аның!..»

— Кабызып җибәрик булмаса,— диде ул да, Капкаевның кулындагы сигаретка ымлап.

— Мин белгән Сәхипыч тартмый...

— Дәү кунак хөрмәтенә ни эшләмәссең...

«Яхшы килеп чыкты»,— дип нәтиҗә ясады ул үзалдына. Тынычлана төште булса кирәк, елмаюы да уңышлы чыккан булырга тиеш.

Кесәсеннән елкылдап торган сигарет кабы чыгарып, бер көязлек белән шуның арт ягына чиертеп алды Капкаев. Капның очындагы ачык урыныннан «мә, мине ал» дигәндәй, сары томшыклы сыңар сигарет борынлады. Зажигалкасына басты. Анысы да андый-мондый гына түгел, хикмәтле. Чертләгән аваз артыннан шәп-шәрә хатын сыны пәйда булды. Һәм шул сынның әллә кай җиреннән генә гөлт итеп ут бөркелмәсенме! Хәтта бермәлгә сигаретын сузарга кыймый уңайсызланып калды Арслан.

— Синдә булмаган нәрсә юк, Капкаев,— дип соклануын белдерде ул бераздан. Капкаев ише ир-ат заты таныш аңар: үзләренә игътибар җәлеп иткәнне, башкаларның исе киткәнне яраталар.

— Капкаев...— дип баш иде зажигалка хуҗасы. Аннан, кет-кет көлеп тә алды. Адәм баласын бәхетле итү өчен, әнә шул да җитә...

— Кая әле, кая, үзем дә басып карыйм?..— дип, Арслан кулын сузгач, теге тәмам тәкатьсез калды, авыз хуҗасын онытты.

Кнопкага басып карады Арслан да. Менә бит хикмәт, икәүләшеп көлешеп алдылар...

— Сат үземә, күпме тора бу?..

Юк, Арслан үзенең хәле әлеге зажигалкага терәлеп калмаганын яхшы белә — онытмады. Капкаевның күңелен күрүе, аны йомшартырга омтылуы иде бу аның.

Кабалана төшеп, зажигалканы кулына алды Капкаев, һәм кесәсенә шудырды. Күренеп тора: кадерле әйбер ул аның өчен.

— Капкаев,— диде күзен кысып,— Капкаев изге әйберләр белән сату итми...

Ниһаять, үгезне мөгезеннән алыр чак җиткән иде булса кирәк. Байтакка сузылган паузадан соң, мәгънәле итеп әңгәмәдәшенең канәгатьлек хисеннән тулышып торган күзләренә текәлде Арслан:

— Йә, дустым, җитәр... Инде эшкә күчик... Теге хәлләрне ничек аңларга боерасыз?!.

Арсланның соравындагы кинаяне аңлый алмады Капкаев. Җитмәсә, куе кашлары җыерылып-куырылып чыкты, саллы ияге урталай сынып бөкләнгәндәй итеп алды бит база мөдиренең.

— Нинди хәлләр?.. Аңламадым, Арслан Сәхипыч...

— Маташтырма, Капкаев! Аңлыйсың!

— Ипидер, аңламыйм... Капкаев берни аңламый!

— Кем кушты?!

Куллары белән өстәлгә таянып торып ук басты Арслан. Гайрәтле кыргый арысланнан һич кайтыш булмагандыр ул шул мизгелдә — менә-менә өстеңә ташланырга һәм ботарлап атарга әзер.

— Аңламыйм дигәч аңламыйм, Сәхипыч... Кешеләрчә сөйләшикме әллә?..

Шулай итеп Капкаев та үзләре арасында нindидер җитди сөйләшү

көтелгәнлекне аңлауга иреште. Тик тавыш күтәрергә, каш җыерырга сәбәп булмаган кебек иде бит әлегә... Хак анысы — Арсланны яратмый ул. Сәбәбен үзе дә белми, яратмый. Әллә текә муенын, эреләнеп, үзеннән әллә кем ясап, башкаларны түбәнсетеп сөйләшүен өнәми ул аның?.. Ләкин бу хакта бит аның берәүгә дә сүз катканы юк, һәммәсен үзе генә белә. Әллә соң салган баштан бер-бер сүз ычкындырылганмы?..

— Кешеләрчә имеш!— дип нәфрәтләнеп карады аңар Арслан. Утын тукмагыдай йодрыгы белән өстәлгә китереп сукты. Тәмәке көле сала торган пыяла савыт өстәл өстендә мәтәлчек атып куйды. Капкаев креслога сеңде...

— Ипидер дим, Сәхипыч, ипидер, берни аңлый алмыйм...

Аягүрә торып басты Арслан. Нәтиҗә ясалган иде: Капкаев шүрли калды. Димәк, хәлләр начар түгел. Детектив әсәрләрдәге тикшерүчеләр сыман, иплəп кенә дилбегәне үз кулына чорнап тотарга да вакыт!

— Өченче көн кайда булганыңны хәтерлисеңдер шәт?..

— Хәтерләми... Бергә булдык инде...

— Ачык сөйләш, кемнәр белән булдың!

— Сәхипыч?!.

— Ул каян килгән «Сәхипыч» ул?!.

— Арыслан Сәхи-по-ви-ич...

— Сорауга җавап бир диләр!

— Кемнәр дип, үзегез беләсез ич... Арысланнар һәм кенәриләр инде...

— Кайчан һәм ничек кайтырга чыкканлыгыңны хәтерлисеңме?..

— Анысы миннән тормый, беләсез... Җантимер бит...

— Машинада кемнәр бар иде?

— Кенәри... Шүфир... Ну, тагы мин инде...

— Нинди тизлек белән кайттыгыз?

— Ну-у, Сәхипыч...— дип, янә җанланып куйды Капкаев.— Боларның кемгә кирәге бар инде?.. Сез, теге, прокурорлар төсле тикшерә башладыгыз...

Арсланның каны кызды. Утын пүләне сыман берни аңламаганга сабышып утырган Капкаевны тибеп очырасы, бугазыннан эләктереп дер селкетәсе иде дә... Түзде. Ашыкмады.

— Юлда нинди машиналарны уздың?

— Хәтерләмим...

— Кемнәргә бәрдереп уздыгыз?

— Хы, хәтерләмим...

— Үзеңнең кем икәнлегеңне хәтерлисеңме соң син?— дип аздан кабынып китми калды Арслан.

— Ну-у, Капкаев. Кем булсын, Капкаев инде...

Өстәл артындагы креслога кереп поскан Капкаев тагы да кечерәеп, бөрешеп калган кебек тоелды шул мизгелдә. Күренеп тора: аның белән өстәл төеп сөйләшүдән файда чыкмаячак. Хәлләре болай да мактанырлык түгел. Нидер хәтерләргә тырышып, күзләрен челт-мелт йомгалап алды ул әнә, уч төпләре белән чигәләрен ышкырга керешге. Бармак очлары белән тар гына маңгаендагы сырларны сыпырып-сыпырып куйды. Бу, үзенчә, хәтер капчыгыннан нидер тартып чыгарырга маташуы иде аның.

— Нидер булган да кебек,— дип куйды ул үзалдына.— Берни хәтерләмим барыбер...

— Хәтерләмәсәң, тыңла, Капкаев,— дигән көчле тавыш яңгырады кабинетта.— Ул көнне син мине теге дөньяга озата яздың. Боргаланма — кем кушты? Кем әмерен үтәдең?..

— Сәхипыч-ч-ч,— дип әйтә алды тәмам сыгылып төшкән Капкаев.— Мине кемгә саныйсыз, Сәхипыч?..

— Алай булгач, мин утырган машинаны бәрдереп узу кемгә кирәк булды?

— Бәрелгәндер инде...

— Бәрелмәгән, бәрдергән, Капкаев!

— Хәтерләмим.

— Шоферың салмыш идеме әллә?

— Юк-юк, Фидаил грамм да эчми...

— Әллә кенәриең минем белән кызыксындымы?..

Бу сорау бөтенләй көтелмәгән иде Капкаев тарафыннан, ул сискәнеп куйды хәтта. Егетлегенә дә тиде булса кирәк.

— Кызыксынмый... Ник кызыксынсын?.. Синдәге акча — миндә дә бар!

— Менә нәрсә, Капкаев,— дип, тирән сулыш алып, өр-яңадан аңлатырга кереште Арслан.— Мин бүген, таң белән торып, тагы бер кат урап кайттым ул тирәләрне. Юлның иң хәвефле урынын табып, алдан уйлаган, исәпләнелгән план белән эшләгәнсез...

Арслан, җавап ишетүдән өметен өзеп, кабинеты буйлап ишеклетүрле йөренергә кереште. Сүзне дәвам итүнең мәгънәсез икәнлеген белеп, кискен рәвештә Капкаевка борылды берзаман:

— Утырма, күзле бүкән сыман! Бар, шоферыңны эзлә, тап. Ачыкла! Шуны бел — мин болай гына калдырачак түгел моны!

Авырлык белән генә урыныннан торып, ишек катына узды Капкаев.Ниләрдер булган да кебек иде түгелме соң? Кенәрие чырык-чырык көлде... Тоткага үрелгән җиреннән туктап калды ул һәм йөз белән кабинетка борылды:

— Хәтерләдем кебек,— диде ул җиңел сулыш алып.— Хәтерләдем... Ул бит, болай, уйнап кына узышу иде... Кенәриләр күңелен күрү өчен генә...

Арслан дәшмәде. Капкаевның башын тилелеккә салып сөйләшүе соң чиккә җиткән иде түгелме?..

Бу дәшмәүне яхшыга юрап, елмаерга итте гастроном директоры. База мөдире белән ара өзүнең һич кирәге юк иде бит аның өчен. Арсланның танышлар күп, мөмкинлекләре дә чикләнмәгән. Хәтта Лев Беляловичның үз кешесе... Үз теләге белән кем шундый әшнәлектән баш тартыр икән?!.

— Уен гына иде бит ул.. Шаяру гына...— дип, каршы ук килергә талпынды Капкаев кулын сузып.

— Түгел!— дигән сүздән тәрәзә пыялалары зеңгелдәде. Аннан кулы белән ишарәләп ишеккә, чыгар юлга күрсәтте база мөдире.— Бар! Башың белән җавап бирерсең, Капкаев!..

*Ахыры киләсе санда*

# Нәби Дәүли

## Гаепләү сүзе

*Әләкчеләргә*

Син кайдадыр әле
Яшисеңдер,
Хатының да бәлки исәндер.
Ак чәчләрен
Кара төскә манчып,
Японский халат киядер.

Ә квартираң
Житмеш метр буйлы,
Дәрәҗәңә шулай тиешле.
Бер бүлмәдә
Урын-җирен салып,
Сакчы итеп тоттың бер этне.

Син пенсионер хәзер,
Персональный.
Шау-шулардан инде тынгансың.
Акчаңны да
Китереп тапшыралар,
«Калҗа»ны да чумыра торасың.

Тыныч кына шулай,
Мыштым гына
Уздырасың булыр көнеңне.
Гөлләреңә
Сулар сибәсеңдер,
Бик шәфкатьле санап үзеңне.

Әле генә
Белеп алдыңмыни
Гөлләр сусыз шиңеп беткәнен.
Ә нигә син
Искә төшермисең
Бер тоткынның үлем көткәнен? —

Кап-караңгы,
Салкын камерада
Ул да шулай сусаган иде.
Сулышының
Соңгы минутында
Бер тамчы су сораган иде.

Саф җанлы ул,
Бер гаепсез иде,—
Тугры иде юлы тормышта.
Туган иле өчен
Канын биреп,
Куяр иде башын кылычка.

Ә син аны:
— Илгә дошман,— диден,
Әләк язып кәгазь буядың.
Ничек кенә
Бер дә тартынмыйча
Имза салды синең кулларың?

Ничек кенә
Шушы куллар белән
Оялмыйсың икмәк тотарга.
Икмәк бит ул
Изге зат дөньяда,
Намус диләр аны татарда...

Кем йөзенә
Кара тап ташладың?
Яла иде синең һәр сүзең.
Син дошманны, имеш,
Фаш итәсең,
Җинаятьче идең син үзең.

Син үзеңне
Яхшы кеше диеп,
— Мин коммунист,— диеп йөргәнсең
Үз анаңның
Моңсу күзләрендә
Шик тудырган караш күргәнсең.

---

Нәби ДӘҮЛИ *(1910) — өлкән шагыйрь, прозаик һәм публицист, күп санлы шигырь, проза һәм публицистика китаплары авторы. Казанда яши.*

— Кызганырга, имеш,
Хакыбыз юк,
Сыйнфый көрәш әле барганда.
Бала, имеш,
Атасына каршы,
Ата, имеш, каршы балага.

Менә шундый
Фикер иде синдә,
Кызганмадың хәтта дустыңны.
Син үзеңнең шулай
Намусыңны
Аяк аска салып уздыңмы?..

— Шулай куша,— дидең,—
Иптәш Сталин,
Кирәк,— дидең,— уяу торырга.
Син бит әле
«Бурыч» алган идең
Үз йортыңда шымчы булырга.

Үз сүзеңне
Телең оныттымы?
— Сталин сүзе — канун,— дидең син.
Үз йөрәгең синең
Юк идеме,
Үз вөжданың кайда иде соң?..

Гөл артына качып
Маташсаң да,
Без йөзеңне синең күрәбез,
Хак сүз белән
Сине гаепләргә
Суд залына бүген керәбез.

Ә суд залы,
Бөтен-бөтен ватан,
Кешеләр, ташлар бире килгәннәр.
Тоткыннар бит безгә
Шул васыятьне
Соңгы кабат әйтеп үлгәннәр.

Барыбыз да
Чыктык трибунага,
Әләкчене атап хурларга.
Корбаннарның
Якты исемнәрен
Һәйкәлләргә язып куярга...

Ә син әле
Гөлгә су сибәсең,
Яфраклардан тама тамчылар.
Елый кебек алар
Бу минутта...
Сүз атмыйча сиңа кем чыдар?

Әле генә
Белеп алдыңмыни
Гөлләр сусыз янып сулганын.
Ә нигә син
Искә төшермисең
Чын кешенең һәлак булганын?

*Июль, 1988*

# Рәдиф Гатауллин

## Остаз турында аллегорик әкият

Әкият сөйлим сезгә:
«...Арабызда
Аксакал бар — Өлкән Атабыз...
Ә картларны әзәрлекли Патша
(Вакыт та бит дошман чал картларга!),
Без атаны яшереп тотабыз
Явыз Патша ачуыннан...
Яши
Әле тере Тарих булып ул;
Көлгә калган шанлы гөл-нигездән
Күңелләргә безнең сузып юл,
Асыл хакыйкатькә чакыра һаман:
Онытылмасын үткән, борынгы —
Аксакалның бар теләге шушы:
Бабайларга лаек булыгыз!

Уяу яшәтегез Аңны, Җанны...
Ата янына без «куышка»
Җыелабыз төрле сорау белән,
Җавап бирә остаз, булыша —
Акыл бирә безгә, аермыйча,—
Алып, Тимер, Камыр батырга
Киңәш, дәрес бирә... Кешелекле,
Зур максатлы юлга чакыра!

Ә без дан эзлибез:
— Су төбендә
Алмаз күренә...
Булсын миңа! — дип,
Омтылабыз һаман... (Дан артыннан
Упкынга күп башлар чума бит!)
Төптә — нуры, тик алмазын чумып
Алалмыйбыз. Нигә?
...Елмаеп
Әйтә остаз: — Ә ул суда микән?
Уйлыйк, оланнар, ди, баш белән.
Бәлки югарыдан төшә нуры?! —
Бәлки бер-бер агач башында
Алмазыгыз!? Ярда тирәк бардыр,
Кош оясы. Менеп күрегез...
Дан да шулдыр: ымсындыра нуры,
Үзе — биектә гел... Белегез!
Онытмагыз бабайлардан калган
Тәҗрибәне; алмаз, алтын — ул!
Ерак баралырсыз, җуймасагыз
Ил мирасын — халык акылын...
Шундый остаз! Яши — күп яу күргән,
Ысланган, тик исән дастандай...

---

Рәдиф ГАТАУЛЛИН *(1941) — шагыйрь, «Гөлләр су сорый», «Ирләр булыйк», «Мәхәббәткә — мәрхәмәт» һ. б. татар һәм рус телләрендә дөнья күргән уннан артык шигырь китабы авторы. Казанда яши.*

Без дәвалый беләбезме җанын? —
Низаглардан, талаш, үч-сүзләрдән
Саклыйбызмы — тугры калкандай?!
Явыз Патша — комсыз Вакыттан соң
Калырбызмы саклап, бирмичә
Ахыргача? Маңгай, йөздә — сырлар...
Моң эзләре... Инсаф белмичә,
Дөрес аңламыйча юлыбызны,
Картайтмыйбызмы аны үзебез —
Шатлык урынына, әрнү биреп? —
Бәлки чынлап кадерен белмибез?!

Бер көн, искә килеп, тетрәнербез,
Кичер безне, Ата, диярбез;
Әле безнең арабызда остаз...
Бүген — һәр сүзенә аның мохтаҗ,
Бөек Ата
Акылыннан нур алган ирләр без!

Әкияттә без бүген...»
Бетте сүзем!

## «Дворян»нар

Талбазыга
Яңа Мортазадан
йөреп укый иде
Сухов, Еникеев, Мамлиевлар —
яңгыраулы фамилияләр! —
«дворяннар»:
күтәртмәле чабаталы,
әмма илленче елларның
иң купшы егет-кызлары...
Якын дусларым!
Әле дә күз алдында:
алар мәсьәләләр чишә,
нечкә «к» авазын сузып
шигырь ятлый...
Кайчак, качып дәрес вакытында,
төелә-төелә,
арыш ипие ашый...

Әкрен тавыш белән
Гакифә апа «замечание ясый»...

Узган күпме гомер!
Чакырыйм гына хәтеремә мәктәбемне,
шул елларны...
Яңгырап алар тавышы килер:
— Ни хәлләрдә яшисең, дус?!
Без һаман да сине онытмыйбыз!
Бәхетле бул, максатыңа ирешә күр!
Теләктә без:
Сухов, Еникеев, Мамлиевлар —
Фәүзәт, Әлиф, Ильфир...
Сания, Фәния, Альмиралар...

Яңа Мортазадан — «дворян»нар!

❁

«Дөнья ваклыгыннан өстен калыгыз!»
Шулай яздым Ялтадан мин
остазыма...
Шул хатыма
Җавап алдым. Менә, танышыгыз:

«— Бу мәлләрдә сездә яздыр, кояштыр.
Бездә әле
Карның эри башлаганы да юк.
(Ә киңәшләрем турында ләм-мим.
Кызык!)
Иртә килгән язың белән котлыйм,
Һәм уңышлар телим.
Ә кар... бездә дә бер эрер әле».

Остазымның шушы хатын —
Моңсу шигырен мин
Ул чакта диңгез ярында,
Хәзер гомер уртасында —
яттан укып йөрим...

Йә, нинди яңа чынлык син,
Әйт, гасыр нәтиҗәсе?!
Үстеме кешелек бәхете?! —
Якынча хакыйкате
Түгелме хыялның фәкать?!
Без бәхет-сәгадәттә
Антик дөньяны уздыкмы? —
Әллә ул безне көтә —
Биеклектә? Атом чоры
Нигә калыша аннан?!
Якынаймыйдыр матурлык
Ах-ах! дип кабатлаудан?..

Нинди көч, язмыш читли соң,
Чикләнгән безнең җан, уй...
Янабыз дип сөйлибез дә...
Тик сүздә генә яну?!

Югыйсә, гасыр ахыры,
Бихисап тәҗрибәсе...
Синең дә, халкым, рухының
Якынча тәрҗемәсен
Укыйлар түгелме?
Уйлан...
Ни булыр нәтиҗәсе?
Әй, гасыр хакыйкате!

Нинди мәгънә эзлим әле
Синең сүзләрдән?! —
Санаулы үзләре — укыйм...
Һаман үзгәрә
Яңа мәгънә, төсмерләрдә...
Язмыш хөкемен укыйммы
Синең сүзләрдән?

Хөкем булса сөюемә?
Һаман үзгәрә

Көннәр монда... Кояш сүрән,
Болыт — күзләрдә.
Сүнсә Сөю — Хыял, кемнәр
Чыгар эзләргә?!

Шуңа җавап бардыр кебек,—
Хатта эзләнәм:
Мәңгелекне укыйм гүя
Синең сүзләрдән.
Укыйм... үзгәрәм...

## Мадрид. Дон Кихот һәйкәле янында

«Ялгыз — булмый!
Кумәк кирәк хәзер,
«Дус-иш кирәк дөнья күтәргә»:
Шәхесеңне калкытырга дисәң,
Биек, мәртәбәле итәргә,
Булсын көчле яклаучыларың да! —
Заман карурманын үтәргә...

Буйсын корыч көчкә — ихтыярга,
Башың иеп, кил бер мафиягә...
Хыял, Хискә Җирдә урын юк...
Җирдә Намус һәм Чын җиңә алу —
Бер онытылган әкият,
борынгы...
Таулар калка икән юлында, бел,
Үзе өчен йөри Алып та:
Ул хәзинә кумә... Алданса да
«Безгә җир казый», дип халыклар.
Шәхси мәнфәгатьләр чоры хәзер,
Һәм мафия итә хакимлек,
Аның сүзе — канун...

Ялгыз йөргән —
Беркатлы ул яки фәкыйрь тик...
Кушылмаса бер шайкага — бетте...
Ә кушылса, ул да өлешле...
Буйсынган һәм гауга чыгармаган
Акыллылар — шулар үз кеше!
...Без дә кумәк яклы,
Ялгыз — булмый,
Безнең мафиягә, әйдәгез!» —

Мадрид! Синдә
Шундый язу кебек һәрбер чатта...
Ә Дон Кихот әнә уйга баткан,
Аты — арык, үзе хәйләсез:
— Кеше
Кешегә дус!
Дульсинея —
гыйффәтле кыз!..—
Йә, ни әйтәсез
Үзгәрмәгән шушы хыялыйга?!
Мәңгелек Рух — Намус, Сафлык, Моңга?!
Үтереп буламы аны?
Әйдәгез?!
Атом чоры җиңә алмас Җырга
Нәрсә аңа сезнең мафиягез?!

❂

*Факиһәгә*

Еш кайтамсың Сәрмәсәнгә, сеңелем?!
Куркам: саегуын Сәрмәсән
Бездән күреп, Бүздәк даласында,
Яки «Топорнино» тарафында,
Ташлап киттегез, дип әрләсә?

Сәрмәсәннән үзең сулар алсаң,
Сәрмәсәннән күңелең моң алган:
Безнең әнкәйләрнең яшьлеге бит
Шул суларга төшеп югалган...

Халкың күргән кайгылар да аккан
Сәрмәсәннән, гүя боз булып...
Якты, матур еллар көткән сине,
Ләкин уйчан, моңлы кыз булып
Үскәнгәме — үткәннәрнең моңы
Күңелеңнән чыга ургылып?..

Син — башланган төбәгеннән аның,
Ә мин — койган... Бер үк Сәрмәсән.—
Безнең җанга күчкән елга хаклы,
Әгәр, оныттың, дип әрләсә:
Моңнар бер көн ташлап китсә безне,
Кайгысыннан кибәр Сәрмәсән...

# Рәшит Гәрәй

## МИНЗӘЛӘ ШИГЫРЬЛӘРЕ

### Аермагыз мине кырлардан

Нәрсәсе бер шушы Минзәләнең,
Нәрсәсе, әй, тарта үзенә?!
Кабат кайтмам, диеп китәмен дә
Тора гына алмыйм сүземдә.

Аерылуыма өч-дүрт көн дә үтми,
Сагынып та инде өлгерәм.
Сагынмаслыкмыни... ул бит минем
Моңнарга бай туган җир генәм.

Газиз әнкәмнең бит бишек җырын
Шунда ишеткәнмен таңнарда.
Беренче кат шунда үрелгәнмен
Инеш читендәге талларга.

Чирәменә ятып аунаганмын
Кайгыларга тарыган чагымда.
Камылларның пышылдавы аша
Җир җылысы күчкән җаныма.

...Нәрсәсе бар шушы Минзәләнең,
Нәрсәсе, әй, якын күңелгә?!
Уйларымда сихри урманнарга
Әсир булып йөрим бүген дә.

Үзләренә дәшеп күз кысалар
Аланнарда янган тын утлар.
Хуш ис бөркеп, җилдә тирбәләләр
Күпереп чәчәк аткан шомыртлар.

Гомер юлларымны шушы җирнең
Ап-ак чәчәкләре нурлаган.
Уҗым булып шыткан көннәрем бу,
Аермагыз мине кырлардан.

Аермагыз... Телим хисләремне
Тургай моңнарына төрергә.
Җылы буразналы басуларның
Улы булып калыйм гомергә.

### Чулпан йолдыз калыкканчы

Камыллы, сөзәк үрләргә.
Кичке эңгер кунган.
Шул эңгергә уралырга
Борылып керәм юлдан.

Эскерт түбәсенә ятып
Тирбәләсем килә.
Бер гөнаһсыз сабый кебек
Кинәнәсем килә.

Иснәп кенә туярлыкмы
Саламының исен!
Башаклары назлап кына
Битләремнән сөйсен.

Әнкәм кулларының назын
Тоярмын мин шунда.
Аның җырын ишетермен
Кырлар сулышында.

Кирәксә, төн уздырырмын
Чалкан яткан килеш.
Ай да эскерт куенына
Төшеп йоклый, имеш.

Серләшеп таң аттырырбыз,
Безме мохтаҗ сүзгә...
Чулпан йолдыз калыкканчы
Җитәрлек ул бездә.

Туйганчы бер сайрашма да
Сөеп-сагынып кайт та.
Туган җирем, сүзебез булыр
Бары синең хакта.

---

Рәшит ГӘРӘЙ *(1931) — шагыйрь, «Уйланган минутлар», «Үзеңә чакыр мине», «Синдә калам» һ. б. егермегә якын шигырь китабы авторы. Татарстанның атказанган культура хезмәткәре. Казанда яши.*

## Инешем

Чәчәкләргә сәлам бирә-бирә
Ерак юлдан кайтып килешем.
Озак күрешмичә торсак та без,
Таныйсың күк мине, инешем.

Мин үзем дә, гүя, әүвәлгечә
Уйнап йөрим синең буеңда.
Хисләремнең тоям тирбәлүен
Ак болытлар йөзгән суыңда.

Агышыннан туктап ял ит азрак,
Алҗуларың бераз кимесен.
Озын көннәр, моңсу төннәр буе
Юлда бит син һаман, инешем.

Тынгылыкның белми ни икәнен,
Дулкыннарың кага ярыңа.
Назламакчы булып, тамчылары
Талларыңа килеп сарыла.

Күпме тереклеккә җан өрәсең,
Кайнардыр шул йөрәк тибешең.
Сай булсаң да җырга, моңнарга бай
Дәрьяларга тиң син, инешем.

Сусаганда, ятып ярларыңа,
Кемнәр генә суың эчмәгән!
Ә үзең бит агып чыгасың син
Уч төбедәй нәни чишмәдән.

## Кунак кына булган икәнсез

Күзләр искә төште, сезнең белән
Саубуллашыр көннәр җиткәндә.
Шулай моңсу була торган иде
Күзен кыр казлары киткәндә.

Күзләргә бит әле бик-бик ерак,
Сез нишләп соң иртә китәсез?
Озаккадыр, дисәм... мәктәптә сез
Кунак кына булган икәнсез.

Кодрәтемнән килсә, беркая да,
Юк, җибәрмәс идем мин сезне.
Туган йорттан китеп, чит җирләрдә
Яшәүләре җиңел дисезме?

Янындагы якын бәхетеңне
Эзләү кирәк микән еракган...
Биләүдән үк шушы җирнең җиле
Иркәләгән сезне, юаткан.

Бәхәсләшмим, кайда булсагыз да
Янарсыз сез көрәш утында.
...Вак таллардан йомшак итеп үргән
Бишегегез кала бит монда.

Нигә безне ташлап китәсез, дип
Төнбоеклар боега күлләрдә.
Үзегезгә сердәш ак каеннар
Сезгә дәшә, әнә, үрләрдә:

Бер карасаң, сез бит һәммәгез дә
Авылыгызда калыр кебекләр.
Фермаларга узар сеңелләр сез,
Буразналар сызар егетләр.

Онытылмасын, туган-үскән җирдән
Аерылмабыз, дигән антыгыз.
Соңламагыз... кыр казлары тезелеп
Кайткан кебек, җыелып кайтыгыз.

## Син бер генә

Яңа көнне сөенеп каршы алу
Күптән инде кергән гадәткә.
Басып торам Игәт тауларында
Кояш чыгып килгән сәгатьтә.

Аска карыйм... Бөтен күңелемне
Биләп ала чиксез горурлык.
Күкрәп үскән иген кырларында
Җырга сыеп бетмәс хозурлык.

Хиссезләр дә гашыйк булыр монда
Тургайларның сихри моңына.
...Ә бер якта Чулман җәелеп ята
Дулкыннарын кагып тын гына.

Диңгезгә тиң сулар тоташтыра
Ярлар белән ярлар арасын.
Ерак сызылып киткән офыкларны
Иңли алмый минем карашым.

Ниләр генә вәгъдә итмәсеннәр,
Үз ягымны ташлап китәлмәм.
И туган җир! Синдә яшәвемә
Гомерем буе сөенеп бетәлмәм.

Бар җырларым сиңа булсын минем,
Бар моңнарым синдә түгелсен.
Урталайга бүлмим хисләремне,
Бу дөньяда икәү түгел син.

## Бөгелмә, Бөгелмә

Бөгелмә... Бөгелмә... Ник исемә
Төшердең ут йоткан көннәрне?
Вокзалың аша син сугышка
Озаттың икән, әй, кемнәрне?!

Эшелон-эшелон солдатлар
Килүен көткән шул ил синнән.
Килгәннәр... юл тулып килгәннәр
Сарманнан, Минзәлә, Мөслимнән.

Һәм безнең авылдан килгәннәр
Әсәтләр, Насыйфул, Мәҗитләр.
Санамыйк... Исәннәр күңеленең
Ярасын кузгатмыйк... йә... җитәр.

Бөгелмә... Бөгелмә... Әткәм дә
Булган бит шул ирләр сафында.

Исемең язылган — вокзалдан
Җибәргән иң соңгы хатында.

Вокзалның аллары таш кына...
Эзләрен каян соң табасың?
«Туган як, хуш!» — дигән сүзләрен
Барын син ишетеп калгансың.

— Бер кайтып килерләр,— дигәнсең,—
Елмаеп чыгарлар вагоннан.
Аннары бер-берсен кочаклап
Еларлар аерылыр алдыннан.

Болары матур бер хыял тик...
Төш күрү... төш кенә юрау шул.
Йолдызлы вагоннар тагылган
Поездның юллар урау шул.

## Җаны юклар гына...

Кыр казлары булып беттек инде,
Яз кайтабыз, көзен китәбез.
Нигә һаман шулай бер урында
Яши алмас кеше икәнбез.

Күпме кабатладым: «Туган якта
Таңнар ата көлеп-алланып».
Ник соң үзем һаман чит җирләрнең
Кояшына йөрим алданып?

Ерактагы кояш җылы дипме...
Юк, андый сүз килмәс телемә.
Туган якның нәни учагы да
Кояштан ким янмый күңелемдә.

Гомерем ахырынача шул учакны
Алыштырмам һичбер кояшка.

Кояшта да туңам, җаным әгәр
Шул учакның җылысын тоймаса.

Күзләр җитте исә әнкәм сүзен
Искә төшерәм мин гадәттә:
«Кыр казлары үтте баш өстеңнән
Син һавага баккан сәгатьтә.

Кечкенәдән киек каз юлында
Булды, улым, синең күзләрең.
Шуңа, ахры, кыр казлары кебек
Юлда уза язың-көзләрең».

Күз җиткәндер тагын... Очар кошлар
Юкка гына канат кагынмас.
Кыр казлары кауры койган җирне
Җаны юклар гына сагынмас.

# Илдус Гыйләҗәв

## Тынлык эчтәлеге

Сокланалар килгән кунакларым:
— Рәхәт,— диләр,— сездә, тып-тыныч.
Бездә, малай, шау-шу, ыгы-зыгы,
Төнлә йөрүләре куркыныч...
Алар сөйли, ә мин шул арада
Күп нәрсәне торам искәреп.
Кайберәүләр әле белмидер дә —
Тынлыкта да була эчтәлек.
...Түбән очта капка шыгырдады,
Шәрип абзый чыга урамга.
Йөткергәләп, кояш югалганчы,
Утырачак әле ул анда.
Гаҗиз булып — иске ялгыз өйгә
Оялаган шомлы тынлыктан,—
Көн дә көтә, киткән малайлары
Килеп чыкмасмы дип тыкрыктан.
...Күрше өйдә комган шылтырады,
Капкачымы төште тәгәрәп?
Белеп торам, ахшам намазына
Мәчтүрәтти ала тәһарәт.
Ул да ялгыз. Читтә кызлары күп,
Бәгырьләрең ничек көймәсен?!
Исемнәрен кат-кат саныйдыр ул,
Торткан саен дисбе төймәсен.
...Бер хыялым җанны чеметтерә,
Башкаларын читкә тибәреп.
Гөрләсәнче, авыл! Тынлыгыңны
Кунакларга биреп җибәреп...

*

Яңгыр үткән ярыкларны эзләп,
Өй түбәмдә йөрдем аптырап.
Чолан якка төшеп кергән идем,
Бөтенесе күренә ялтырап...
Өстә йөреп күпләр ялгышалар,
Белеп яшәгәннәр сирәктер.
Үз илеңдә «яңгыр үткән» җирне
Шулай тикшерү дә кирәктер...

## Ятим зиратлар

Басу уртасында яшел утрау,
Учма-учма каен, наратлар...
Яшел сагыш булып сибелгәннәр
Авылларсыз калган зиратлар.
Ялгызлыктан арган агачкайлар
Басар төсле чыгып каршыга.
Ник кешелек атлап килгән юлын
Бетерергә болай ашыга?
Үз тарихын үзе онытканнар
Таба микән җирдә кадерне?
Йөрәк өши, күрсәң — онытылган,
Алабута баскан каберне.
Күлмәкләрен — ауган коймаларын
Ямарга соң юкмы ир-атлар? —
Ятим бала төсле, дәшми генә
Еламсырый ялгыз зиратлар.

---

Илдус ГЫЙЛӘҖӘВ — *«Җир китабы» исемле шигырьләр җыентыгы авторы. Ул Татарстан АССР Верховный Советы депутаты. Азнакай районында яши.*

ПУБЛИЦИСТИКА

## Әхмәт Рәшитов

# НАМУСЫҢНАН СОРА

Бөтенесе бүгенгедәй хәтердә... Без университетның антик амфитеатрларны хәтерләткән борынгы аудиториясеннән, гадәттәгечә, шау-гөр килеп, этеша-төртешә түгел, бер-беребезгә юл саба-саба, уйчанланып, җитдиләнеп һәм хәтта бераз моңсуланып та чыктык. Кайчандыр биредә Рим хокукы буенча лекцияләр укылган, законлылык һәм демократия турында кызу бәхәсләр барган. Ә без, ике сәгать дәвамында, тын да алмый диярлек, тыңлаган сүзләр исә бөтенләй башка, алар акылга сыймастай, кеше ышанмастай, гайре табигый хәбәр иде, һәм ул безгә аяз көнне яшен суккан кебек тәэсир итте. Без, риясыз, алдашусыз, һәр сүзгә ышанучан, саф күңелле, беркадәр егетләр һәм кызлар, әле генә дәүләтнең иң биек һәм иң хөрмәтле урындыкларында утырган кешеләрнең халыктан яшерен һәм пычрак эшләре турында белдек. Безнең факультет комсомолларын КПСС Үзәк Комитетының Беренче секретаре Н. С. Хрущев егерменче партсъездның ябык җыелышында ясаган доклад белән таныштырдылар. Ул Сталинның шәхес культы һәм аның нәтиҗәләре турында иде.

Без биредә ишеткән һәр сүзне диярлек күңелгә сеңдереп, бер билгесезлек томанына уралып, урамга атладык. Әле генә ишеткән ачы хакыйкать җанны актара, авыр йөк булып иңгә баса, зиһенне томалый, әле акны карадан төгәл генә аерырга мөмкинлек бирми иде. Ләкин анда, тормышта, без барасы юлларда әле бик күп үзгәрешләр буласы көн кебек ачык иде инде.

Без кинәт кенә кысан һәм бөркү булып калган бинадан берәм-берәм урамга — Ленин урамына чыктык. Һәр тарафта яз тантана итә, өй кыекларыннан тамчылар тама, назлы җилләр исә, безнең алда бөтенләй башка ягы белән ачылып киткән дөнья исә бер үк вакытта иске дә, яңа да иде.

Акрынлап-акрынлап студентларның эшләре «җиңеләйде». Уку программаларыннан «даһи юлбашчы»ның әсәрләре төшеп кала башлады. Имтиханнарга әзерләнү чорында күпме йокысыз төннәргә, стипендия алырга җитәрлек тиешле белге куелмау аркасында, күпме күз яшьләренә сәбәпче булган атаклы «Марксизм тел белеменә карата» брошюрасы да, Сталинның рухи варисы булган Мао Цзедун хезмәтләре дә кирәксезгә әйләнде.

Ләкин Сталин барыбер күңел мөнбәрендә иде әле. Хәер, моның нәрсәсенә гаҗәпләнәсең?! Еллар буе өзлексез, иртәсен-кичен исеме докладларда һәм җырларда, газеталарда һәм китапларда, радиода һәм кинода гел-гел кабатланып торсын да, һәр зур эш алдыннан бисмилла урынына гел «Сталин», «Сталин», «Сталин» дип кабатласыннар да, ничек инде аның бөек юлбашчы, җиңелмәс пәһлеванлыгына, ә үзеңнең ул әйткәннәрне тиз һәм төгәл үтәүче икәнеңә инанмыйсың. Безнең бик күп бәләләр әнә шул бер кеше авызына карап торудан, мөстәкыйль фикерне читләтеп курып, алдын-артын уйламаска күнегүдән, күндәмлектән, мокытлыктан, рухи коллыктан башланды.

«Алла» сүзе азрак әйтелгән саен, аның урынын «Сталин» ала барды. Ул әтидән һәм әнидән дә, туганнардан һәм балалардан да газизрәк, аның күңелдәге сурәте кичен безнең белән бергә йокларга ятса, иртәгесен, «бишьеллык планнарны срогыннан алда» үтәү өчен, җилтерәтеп уята, эшебезгә, укуыбызга, ялыбызга күзәтчелек итеп тора, өйрәтә, орыша, җәзалый, әмер бирә иде. Бюрократик команда-административ система калканы аны һаман-һаман халыктан, ил мәнфәгатьләреннән аера барды. Нәкъ менә Александр Твардовский поэмасындагыча:

*Җанлы көе аны җанлылардан*
*Кремль диварлары аерып торган...*

Соңгы елларда чыккан күпсанлы истәлекләр аның чыннан да реаль тормышны белмәве, күпертелгән рапортларга, ялган мәгълүматларга ышанып яшәве турында сөйли. Ә халык?.. Хәер, бу турыда, кемнәрдер язганча һәм сөйләгәнчә, «аталарча кайгыртты» микәнни ул?! Сталинның яшьлегендә язган бер гыйбрәтле шигыре бар.

Әйе, әйе, Сталин тарафдарларын сөендерә алам — булачак «юлбашчы» ерак яшьлегендә шигърият белән мавыккан. Аның талантын хәтта грузин әдәбияты классигы Илья Чавчавадзе да таныган, «Бәләкәй Сосо»ның әсәрләрен хрестоматияләргә һәм антологияләргә керткән. Әле генә телгә алынган шигырендә ул вакыттагы И. Джугашвили, халык турында борчылудан бигрәк, кешеләрнең «ялгыз геройны» аңламаулары өчен «аһ» ора:

*...Гел йөрде ул шулай өйдән өйгә,*
*Гел ят ишекләрне шакып йөрде.*
*Иңендәге иске пандурие,*
*Ихлас җыры аңа юлдаш иде.*

*Эределәр хәтта таш йөрәкләр,*
*Таш йөрәкләр хәтта ярсып типте.*
*Уятты ул аңын бик күпләрнең —*
*Аңны каплап торган чал төн үтте.*

*Ләкин шөһрәт һәм дан урынына*
*Кешеләре ул яшәгән җирнең*
*Мескен мәхлугына бу дөньяның*
*Бары касә тутырып агу бирде.*

*Һәм әйттеләр аңа: «Мә, эч, мәлгунь,*
*Агу чөмер — шунда тынар күңел;*
*Җырың да ят синең безнең өчен,*
*Хак сүзең дә синең кирәк түгел!*

*(Тәрҗемә — авторныкы).*

Еллар үткәч, «ялгыз герой» данны һәм шөһрәтне кирәгеннән артык тапты. Ул хәтта генетика һәм кибернетика буенча да галимнәрнең үзләреннән күбрәк «белүче» бердәнбер фикер иясенә, даһи политик стратегка, җиңелү белмәс генераллиссимуска, алыштыргысыз дипломатка, тагын, тагын, тагын әллә кемнәргә әверелде. Җырчылар, акыннар, ашуглар, чәчәннәр аны хәтта колшиның үзенә тыңладеләр, аның рәсеме медальләргә сугылды, һәйкәлләре шәһәрләрнең һәм авылларның иң үзәк мәйданнарын «бизәде». Яшь шагыйрьнең яшерен хыялларын карт политик һич тартынусыз чынбарлыкка ашырды. Моңа гына канәгатьләнмәстән, Ежов һәм Берия, Вышинский һәм Ульрих кулы белән үзен олылаган, үзенә инанган халык йөрәгенә канлы хәнҗәр батырды, башкаларга да җәлладлык чире йоктырды. Бөтен ил күләмендә ваба авыруыннан да яман чир башланды. Намус дигән, аек акыл дигән асыл сыйфатлардан мәхрүм бәндәләр өчен чын мәгънәсендә «эш фронты» ачылды; җәмгыятебез өстендә шик, әләк, ялган, яла шәүләләре бии башлады.

Мин әнә шул чорлар турында уйланам, моннан кырык-илле еллар элек чыккан газета-журналларга күз салам да хәйран калам:

*Ничек инде шулай була алган,*
*Безнең илдә... безнең заманда?!*

Мәкаләләрнең исемнәре генә дә, дәһшәтле, җан тетрәткеч: «Стенага терәргә!», «Еланнарны сытарга!», «Үлем җәзасына!», «Шакаллар өере», «Яшәргә хаклары юк!». Мине барыннан да бигрәк кем тарафыннан язылган булуы кызыксындырды. У-у, аларның исемнәрен әйтергә дә оят. Без ничә еллар буе баш игән, без хөрмәтләп олылаган ил агалары, хезмәт алдынгылары, стахановчылар, эдипләр, шагыйрьләр, рәссамнар, композиторлар, артистлар... Аларның шулай зиһеннәре томаланган булды микәнни соң?! Канга сусаган булдылар микәнни? Әллә баш залимга тугрылык хисләрен белдерәселәре килдеме? Бу акылга сыймаслык, сәер, аңлаешсыз фаҗигане булдырмаска мөмкин түгел идемени?! «Совет әдәбияты» журналының 1937 елгы бер санында сәер шигырь бар. Поэмага тартым озын бу әсәрнең исеме — «Нарком Ежов». Авторы — Максуд Сөндекле. Сталинны мактап язган шагыйрьләрне мин күпмедер дәрәҗәдә аңлыйм — аларның ихлас булуын да инкарь итеп булмый диярлек. Ул — ихластан ялгышу. Әмма инде ул вакытта ук одиоз фигурага әйләнгән җәлладка дан җырлау — бик начар фал иде ләбаса. Куркыныч «фаш итүләр», «халык дошманнары»на төртеп күрсәтүләр, ачыктан-ачык һәм яшерен шымчылык шулай башланды. Архивларда эшләүче кешеләр тагын бер нәрсәгә хәйран кала: әлеге газета-журналлар туракланып-кискәләнеп беткән. Күрәсең, 37 нче ел «батырлары», асларына су керүне сизеп алгач, үзләренең куркыныч «автографларын» тизрәк юк итәргә ашыкканнар.

Әдәбият белеме өлкәсендә эшләүче бер танышым бу уңайдан ничек итеп бер мәкалә артыннан «чапканын» сөйләгән иде. Татарстан фәнни китапханәләрендә һәм

хәтта китап палатасындагы тупләмәләрдән ул мәкаләнең кем тарафыннандыр кисеп алынган булуын күргәч, галимебез Мәскәүгә, аннан Ленинградка юл тоткан — тагын шул ук хәл икән. Беркемнең дә кулы тимәгәндер әле, дип Уральск якларына командировка алса — бередә дә... аннан алдарак өлгергәннәр. Әйе, ашыкканнар, тизрәк эз югалтырга тырышканнар. Аерым кулларда сакланып калу мөмкинлекләрен генә искә алмаганнар. Ә андый шаһәдәтнамәләр бар... Хәтәр елларда бөтен татар совет классикасын тар-мар итеп, Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, Ф. Бурнаш, Х. Туфан кебек әдипләр йөзенә кара ягып, әдәбиятыбызның тамырына балта чапкан ул кешеләрнең кайберләре исән әле. Бәлки бу иске гөнаһларны искә төшереп торырга кирәкмидер дә!.. Ләкин ялган сукмактан киткән хак юлга керерме соң?! Республикабызның культура җәмәгатьчелеге бүгенге демократия һәм плюрализм шартларында тарихыбыздагы, әдәбиятыбыздагы, гомумән, рухи мирасызыбыздагы «ак тапларны» бетерү өчен эшчәнлек җәелдергән бер вакытта алар да тик тормыйлар — трибуна даулыйлар, һаман да иске җырны сузалар — сүзнең Сталин өрәге алкышлардаен, аның арсеналыннан алынганын сөйлиләр. Матбугатта басылган мәкаләләре исә, әйтерсең лә, дүрт-биш дистә ел өстәл тартмасында онытылып ятканнар да, хәзер генә дөнья күргәннәр. Аларның шәхес культы һәм торгынлык елларында кырган эшләреннән бүгенге көнгә кадәр кара күләгә сузылып килә: тарихны яңабаштан язасы, гаделлек һәм хакыйкать эталоны белән үлчисе бар.

Үткәндәгеләр өчен бар гаепне хәзер бер Сталин өстенә өябез. Ләкин Сталиннан да куркынычрак нәрсә бар. Анысы — сталинизм. Кемнәрдер Сталинны сүгә-сүгә сталинизмны саклап калырга тырыша, үткәннәрне сагына, заманның иң четерекле мәсьәләләре хәл ителгән чакта, трибунага менә, кичәге фикерләрне бүгенге формада үткәрмәкче була.

«Прогресс» нәшрияты чыгарган «Иного не дано» дигән китапта бик акыллы мәкалә бар. Л. Карпинскийның «Сталинизм ни өчен аренадан китми?» исемле мәкаләсе ул. Анда шундый гыйбрәтле сүзләр бар: «Сталинизм — Сталин гына түгел һәм аның шәхесенең культы гына түгел, сталинизм — социаль бәйләнешләрнең бик зур бер йомгагы, еллар дәвамында бөтен җәмгыятьтә тотрыклы урын алган экономик, политик, идеологик һәм мораль чыганакларның өлешләре бер-берсенә нык укмашкан агломераты ул»... Уйланырлык фикер.

Чыннан да, безнең бүгенге бәлаләребезнең башы шунда, шиксез үткәннәрдә шул! Әнә шуңа күрә дә бүген киңәш итеп, гомер буе инанган хакыйкатьләргә барлау үткәрү, алар арасыннан киләчәк өчен ярардаен, кешелеклеләрен, гуманнарын сайлап алу — бөтен җәмгыять өчен иң зур ихтыяҗ. Юл өстендәге ташны вакытында алып ташламасак, аңа без генә түгел, бездән соң киләчәк буыннар да сөрлегәчәк. Әлбәттә, бу җиңел эш түгел. Монда аек акыл һәм намус кына түгел, шактый дәрәҗәдә батырлык та таләп ителә.

Минем бу язмаларым — озак елларга сузылган газаплы уйлануларым нәтиҗәсе. Әйе, әйе, мондый фикергә кинәт кенә килмәдем мин. Югарыда телгә алынган «яшерен доклад» үзенә күрә бер импульс кына иде — ул җәмгыятьтә урнашкан карашларны бөтенләй үзгәртмәде диярлек. Ул вакыттагы җитәкчелек, җитәр, шуннан артыгы ярамас, дидеме, әллә үз гөнаһлары да ачылудан курыктымы — фаш итүләр тәгәрмәче кире якка әйләнә башлады. Әлбәттә, шәхес культын тәнкыйтьләү бөтенләй нәтиҗәсез калды, дип әйтергә җыенмыйбыз. Бу чорда вакыйга булырлык яңа рухлы әсәрләр дә туды. А. Твардовскийның »За далью даль», Г. Николаеваның «Битва в пути», И. Эренбургның «Оттепель», В. Дудинцевның «Не хлебом единым» кебек әсәрләре — шул бәрәкәтле чор җимеше. Рус шигъриятенә Е. Евтушенко, Р. Рождественский, Б. Окуджава, Б. Ахмадуллина кебек шәхесләр килсә, татар әдәбияты Р. Фәйзуллин, Рәшит Әхмәтҗанов, Р. Мингалим, Зөлфәт, М. Әгъләмов исемнәре белән баеды. Куанырдай нәрсәләр, әйе, бар иде. Әмма шәхес культын, бюрократик, команда-административлык системасын тәнкыйтьләү эзлекле һәм ахырынача алып барылмау аркасында, без икенче баткаклыкка — торгынлык сазлыгына кереп чумдык. Бөтенесе ул заман иллә дә рәхәт иде: җитәкчеләргә фимиам җырлый-җырлый орденнар өләшәбез, тапканыбызны ашап-эчеп бетерә барабыз, кыскасы, «дөнья — диңгез, без — корабль, шапылдатабыз гына». Шапылдаттык, күп нәрсәне күрмәмешкә салыштык, үзебезне барысы да әйбәт, дип инандырдык. Баксаң, ул арада «Сталин бабабыз» автомобиль тәрәзәләренең иң түренә менеп утырган, баксаң, мәшһүр полководецларның мемуар китапларында иң мөхтәрәм урынны алган, баксаң, матур әдәбият һәм нәфис фильмнар да аннан башка яши алмый башлаган — «халыклар юлбашчысы»ның «яңадан тууы» иде бу. Һәм моның соңы нәрсә белән бетәсен алдан әйтү мөмкин түгел иде.

Менә шушы «Шәхес культының икенче дулкыны» халыкның төпле фикерен чуалтты да куйды инде.

Узган җәйдә миңа туган якларымда — Буа районында шактый еш булырга туры килде. СССРның 60 еллыгы исемендәге, «Коминтерн», «Маяк» колхозларында кеше-

лар белән очрашып сөйләштем. Сүз бүгенге үзгәрешләргә, аңа каршы эш алып баручы көчләргә. Сталин шәхесенә килеп ялгана иде.

— Нәрсә инде бу? Кибеттә каткан прәннек тә калмады. Күп сөйлибез, тәртип юк. Сталин вакытында, ичмасам, тормыш күзгә күренеп яхшыра башлаган иде...— Кайбер фикерләрнең сөземтәсе шуңа охшый. Илдә барган үзгәрешләрне бөтен халык бердәм яклый дисәк, менә сиңа мә!

Бер әби сөйли:

— Гомере буе ул Сталин безнең өчен тырышты, үзенең өстенә кияргә шул каткан бер шинель иде инде...

Олы яшьтәге бер абзый минем шул шәхес культы чорындагы репрессияләр хакындагы сүзләремә каршы:

— Утыртса, начальствоны гына утырткан ла ул, эш кешесенә тимәгән,— дип җавап бирде.

Нәрсә әйтергә?! Минем бу соравым башкаларга мөрәҗәгать итүдән бигрәк, үземә, үземнең укыган-белгәннәремә, үземнең тормыш тәҗрибәмә. Мин ул сорауны үз-үземә күптәннән биргән идем инде, мин күптәннән аңа җавап эзлим.

Нәкъ җырда җырланганча:

*...Төннәр буе йоклый алмый ятам...*

Бер мин генә түгелдер, заманы шундый — башкалар да уйлана торгандыр. Без хакыйкатькә газаплы кичерешләр аша киләбез. Уйлардан башлар чатнар төсле. Бүген безгә йөзләгән, меңләгән сораулар тынгылык бирми. Ничек яшәдек соң без моңарчы? Юлыбыз, мәсләгебез кая илтә? Без инанган, без табынган ул кеше — кем? Җәлладмы? Тиле фанатикмы? Аның Иван Грозныйга охшарга тырышуын ни белән аңлатырга? Ник соң әле һәлакәтне вакытында күрмәдек? Моңарчы ил ирешкән казанышлар өчен 50 миллион корбан артык күп түгелме соң? Мин, мәсәлән, ул, абсолют власть яулап алгач, моннан үзенә ләззәт тапкандыр һәм шуның белән бик бәхетле тойгандыр дигән фикердән ерак торам. Мин бары без кичергән фаҗиганең асыл сәбәпләрен аңларга тырышам. Миңа калса, ул үзе үк — фаҗигале һәм бәхетсез шәхес. Алкоголик әтисенең исереп сугышканда һәлак булуын, физик яктан зәгыйфьлеге аркасында яшьтәшләре тарафыннан кыерсытылып үсүен күз алдыннан кичерәм. Яшьлегендәге сынаулар. Аннан сөргеннән-сөргенгә куылып йөргән елларда хатыны Е. Сванидзе үлеп, өлкән улы Яковның кеше кулына калуы. Утызынчы еллар башында икенче хатынының үз-үзенә кул салуы, улы Василийның алкоголиклыгы, кызы Светлананың бер ирдән икенчесенә күчеп йөрүе. Чын дуслары, якын туганнары юк: кайсыларын ул аттырган, кайсылары үзләре аннан йөз чөергән. Бар белгәне — дәүләт эшләре, шыксыз кабинет тынлыгы һәм... рухи ялгызлык. Тирә-юньдәгеләр бөтенесе хыянәтчеләрдер, аны үтерергә генә уйлап йөриләрдер төсле. Юк, шундый шартларда үзен бәхетле тоя алмагандыр ул кеше.

Ләкин без — гуманистлар, кешенең бәхетсезлегеннән көлмибез. Без кичергән фаҗига үткәннәрдә калсын, безнең белән киләчәккә бармасын, дибез. Шуңа күрә бу кешенең идея буларак, символ буларак тагын бер кат «яңадан тууын» теләмибез. Чөнки ул социализмның кешелекле рухына сыя алмый, чөнки ул — төрмәләр, кимсетүләр, коллык, үлемнәр чагылышы.

...Үземнең бала чагымны искә төшерәм дә сискәнеп китәм. Сугыштан соңгы авыр еллар. Күлмәк ертык, итек тишек, тамак ач. Укытучылар безне — хәлсез мескеннәрне аягүрә бастыралар да бәхетле балачак турында җыр җырлаталар. Ул җырларда без «шатлар, алсу йөзлеләр, акыллылар, җитезләр», без «бөек атабыз Сталинга» рәхмәт әйтәбез, әйтәсе килмәсә дә, «үпкәләр авыздан күренеп торса да», әйтәбез.

Шул елларда минем белән булган бер мәзәк хәл. Нииндидер бәйрәм алдыннан укытучы безгә җыр өйрәтте. Ә малайларның — сүзләрен белмиләрме, әллә башка сәбәпме — җырлыйсылары килми. Шулай буласын сизенепме, укытучы җыр башлаучыга бер кап печенье вәгъдә итә. Минем инде ничә көннәр рәтле ризык капканым юк, кызыктырды, каһәр. Һәм мин, «колагыма аю баскан» булса да, «солистлыкка» алынам — мәктәп ишегалдында минем ялгыз чырылдавык тавышым яңгырый:

*...Шауласын, гөрләсен безнең җыр,*
*Еракка яңрасын безнең җыр,*
*Күкләрдә күкрәсен безнең җыр,*
*Безгә җыр, безгә нур бирде Сталин.*
*Яшә, даһи Сталин!*

Укытучы вәгъдәсендә торды — бүләкне бирде. Әй, белсәгез иде сез ул печеньенең тамактан ничек үткәнен, гарьлектән, кимсенүдән яшьләремә буыла-буыла ашыкпошык йотуымны! Бу трагикомедик хәл искә төшкән саен, мин әле дә кызарып куям.

Без татлы хыяллар белән яши идек, «коммунизм» дигән гаҗәеп чорларга тиз генә барып җитү өчен теләсә нәрсәгә ышанырга, теләсә нинди газап татырга, хәтта гомер белән санашмаска, үлемне санга сукмаска әзер идек. Безнең хакта хәтта шагыйрьләр:

*Кадак ясасаң бу кешеләрдән,*
*Ныграк кадак булмас иде җирдә,—*

дип язды. Ләкин безнең тормыш укытучылары — «бөек юлбашчыларыбыз» үзләре вәгъдә иткән тәмле-томлыны бирергә ашыкмадылар.

Безгә киләчәккә барасы, һәр адымда абынмас өчен, юлдагы түмгәкләрне күрү өчен рухи офыкларыбызның ачык булуы зарур. Без үткәннәрне хурлау, каралту, бөтенләй инкарь итү өчен түгел, ачысын, фаҗигасен тәмам аңлау өчен, шуннан сабак алу өчен тагын бер кат искә төшерәбез. Шагыйрь дустым Рәшит Әхмәтҗанов бик дөрес язганча: «Каберләрдән ирләр үч алмый...» Үткәннәр сабагы безгә бүген өчен кирәк. Үткәннәр, бүгенге һәм киләчәк — бер чылбырның буыннары. Шуңа күрә карашлар бүгенге проблемаларга юнәлтелгән. Кайдан соң ул мирасларның безгә кирәкмәгәне, юлга аркылы ятырдае?!

Утызынчы, кырыгынчы, илленче елларның лозунгларын, теләсә кайсы рәсми документка, фәнни хезмәткә, әдәби әсәргә нигез булып яткан канатлы сүзләрне искә төшерик, кайбер шигъри юлларны уйдан кичерик. «Большевиклар алмаган крепостьлар юк», «Бөтенесен кадрлар хәл итә» (И. Сталин), «Әгәр дошман бирелмәсә, аны юк итәләр» (М. Горький), «Безнең чорда барлык юллар коммунизмга илтә» (В. Молотов), «Без табигатьтән рәхимлекләр көтеп тора алмыйбыз, аларны аннан алу — безнең бурыч» (И. Мичурин)...

Ләкин һәр лозунг артында — эш-гамәлләр ләбаса! Ә алар нинди иде соң? — шул турыда бергәләп уйлашыйк әле. Кем иделәр соң алар — бөтенесен хәл итүче кадрлар? Бөтенесен дә хәл итәргә аларның белемнәре һәм тәҗрибәләре җитә идеме соң? Ак диңгез-Волга каналын, Норильск металлургия комбинатын, Сталинград трактор заводын һәм башка индустрия гигантларын төзүдә тоткынга әйләндерелгән югары интеллект һәм профессиональ әзерлекле кадрларыбыз әрәм булды, үзләрен чагыштырмача ирекле хис иткән гражданнар да шундый ук язмышка юлыгудан гарантияләнмәгән иде. Менә-менә сугыш башланырга торганда, Кызыл Армия даны булган полководецлар, нахак бәла тагылып, юк ителде. Социализм эшенә чын күңелдән бирелгән миллионлаган кешеләр — партия, совет, комсомол, профсоюз, хуҗалык җитәкчеләре, илнең алтын фонды, интеллектуаль хәзинәсе саналган галимнәр, язучылар, рәссамнар, композиторлар, артистлар Берия концлагерьларында иң игелексез, иң авыр, иң пычрак эшләрне үтәделәр. Сталин вакытында соң чиккәчә үзәкләштерелгән, бар инициативаларны буа торган, теләсә нинди энтузиазм чаткыларын сүндерергә сәләтле, катгый кануннарга һәм кагыйдәләргә буйсындырылган административ-командалык итү системасы туды. Ул бүген дә исән. Без көн тәртибенә куйган күпме матур башлангычлар әле дә аның таш диварына барып бәрелә.

Без бүген әхлак нормаларының какшавы, гаиләнең тотрыксызлыгы, тәрбиясез һәм йөгәнсез балалар турында ачынып сөйлибез. Нидән башланган соң ул — шул турыда уйлыйбызмы?

Утызынчы елларның Павлик Морозов исемле мәшһүр герое бар. Атасын фаш итеп дан алган ул малайны без ничек кенә идеаллаштырмадык, ата-ана белән бала арасына ничек кенә тыкшынмадык?! Бүген Казан урамнарында, ата-ана сүзен санга сукмыйча, бер-берсенә каршы үтерешкәнче сугышучы яшүсмерләр турында укыганда, минем күз алдына әнә шул «атаклы» Павлик Морозов килеп баса.

Бөек Ватан сугышының авыр көннәрендә кабул ителгән бер указ бар. Баласы булмаган кешеләрдән налог түләтү турында ул. Бу указның хатын-кызлар өчен нинди хурлыклы булуын уйлаганыгыз бармы икән? Сугыш вакыты бит, һәр ир кеше исәптә — теләсә кем муенына барып асылынасыңмыни? Өйләнер кеше юк, ә син бала тап... яки налог түлә. Ул елларда зинадан туган балалар — әнә шул указ җимешләре дә. Әгәр без бүген таркалган гаиләләр, атасыз балалар, төнге күбәләкләр — фашихәләр турында сөйлибез икән, сүзнең бер очы шул елларга барып тоташмыймыни?!

Безнең буын гомер буе дөньядагы иң гадел җәмгыять — коммунизм турында хыялланып яшәде. Чын күңелдән ышанып, көчен һәм канын кызганмыйча якты киләчәк өчен көрәште. Еллар үткән саен идеаллар җимерелә барды, сүз белән эш арасында әрма зурайганнан-зурайды. Димәк, барлык юллар да коммунизмга илтмиләр икән. Шуны аңлау иманнарны какшатты, ышанычны җимерде, бүгенге җинаятьчел битарафлылыкны тудырды.

Без табигатьтән рәхимлекләр көтмәдек. Без бу канатлы сүзләрне үзебезчә аңладык. Җирне харап итә торган әллә никадәр комбинатлар төзедек, елгаларны буып,

балыкларның юлын бүлдек, урманнарны таладык, җир асты байлыкларын әрәм-шәрәм иттек. Бүген экологик үлем куркынычы турында сүз алып барабыз.

Сталин үзе «безнең иң зур капитал» дип игълан иткән кешеләрнең бары анык бөеклеген мактарга, ул кушканны эшләргә, ул төртеп күрсәткән «халык дошманын» гаепләргә генә хакы бар иде. Хәтта паспорты да булмаган колхозчы агай — авылдагы бәләкәй сталинның һәр әмерен үтәүче, бар тормышы җитәкчеләрнең мөнәсәбәтенә тулаем бәйле хокуксыз бәндә иде.

Без «халыклар төрмәсе» булган иске Россиянең «милләтләрне тату гаиләгә» берләштергән бөек Советлар иленә әверелүен зур горурлык хисе белән тәкрарлый идек. Ә шул ук вакытта кырым татарларының, чеченнәрнең, ингушларның, Идел буе немецләренең, калмыкларның, карачайларның туган җирләреннән сөрелүләренә көенә идекме соң?

1969 ел җәендә Үзбәкстанның Чырчык дигән шәһәрендә бер очрашу һич кенә дә хәтердән чыкмый. Сеңелемнең күршесендәге бер әби белән сөйләшеп киттек. Кырым татары икән. Мин аннан бу якларга ничек килеп чыгуларын сораштым. Карышмады. Сөйләде. Аларны 1944 елның маенда терлек вагоннарына дыңгычлап төягәннәр дә ерак сәфәргә озатканнар. Ач көе, хәтта бер йотым суга тилмереп, ярты айдан артык барганнар алар. Картлар, карчыклар, сабыйлар, ваба авыруыннан кырылгандай, җан биргәннәр. Ә аннан чәнечкеле тимер чыбыклар артында көн итү. Үзем тыңлыйм, үземнең күзләремнән яшь ага. Бу да безнең заман хакыйкате.

Без дистәләгән еллар буена алдана-алдана алгы көнгә карадык. Инде тәүбә итәр көн җитте. «Бездә милли мәсьәлә тулысынча хәл ителгән» дип попугайларча кабатлаучыларны Карабах хәлләре, Алма-Ата һәм Якутия вакыйгалары, Балтик буе халыкларының хәрәкәте ни дәрәҗәдә уйландыргандыр — анысын әйтүе кыен, әмма бу хәлләр — сталинизмның иң авыр мирасы икәне бәхәссез.

Мин еш кына Сталинның 1936 елгы Конституция проекты турында ясаган докладыннан бер өзекне искә төшерәм: «Мисал өчен Башкортстан яки Татарстан республикасын алыйк. Әйтик, бу автономияле республикаларны союздаш республикалар разрядына күчерделәр, ди. Алар логик һәм фактик яктан үзләренең СССРдан чыгулары турында мәсьәләне куя алырлар идеме? Юк, куя алмаслар иде. Ни өчен? Чөнки алар бөтен яктан да совет республикалары һәм өлкәләре белән уратып алынганнар һәм, әйтергә кирәк, алар СССРдан беркая да чыга алмыйлар (гомуми көлү, кул чабулар)».

Шул юлларны укыйм да, республикабызның, халкыбызның бүгенге хәле турында уйлыйм, нефть һәм җир асты сулары белән пычранган кырларны, болыннарны, зәһәр төтен эчендә утырган индустрия гигантларын, елдан-ел таркала барган авылларны, туган телен, җырын-моңын белми үскән егетләрне һәм кызларны, ни булды эле заманга, дип безгә мөлдерәп караучы Акбабайларны һәм Акъәбиләрне күздән кичерәм, колагымда әлеге дә баягы шул «гомуми көлү» яңгырагандый тоела.

Сталинизмның мондый кара мирасларын санап чыгу да бик күп вакытны алыр иде. Күп алар, күп. Партиянең XIX Бөтенсоюз конференциясе аларның кайберләрен генә көн тәртибенә куйды әле. Алда әллә никадәр борчу-мәшәкатьләр, алда — икеләнүсез, аяусыз көрәш, алда — перспективалар. Без — оптимистлар. Тәүбә иткәннән соң күңел сафланган кебек җәмгыятебез авыруларының асыл сәбәпләрен белгәч ук җиңел булып китте. Бу инде илдә үзгәртеп коруларның һичшиксез тормышка ашачагына зур ышаныч уята. КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре М. С. Горбачев, безнең бүгенге уйларны чагылдырып, конференция трибунасыннан: «Кешеләр үз җаваплылыкларын тойдылар, апатиядән һәм читләшкәнлектән арына баралар. Яңарыш җиле халыкның әхлакый сәламәтлеген чыныктыра. Демократияләштерү фикерләрнең, эмоцияләрнең, инициативаларның куәтле ташкынына ирек куйды. Хакыйкать һәм хәбәрдарлык урнашу иҗтимагый атмосфераны сафландыра, кешеләрне канатландыра, аңны азат итә, актив эшчәнлекне көчәйтә»,— диде. Бу сүзләрне без намусыбызның гомерлек программасы дип кабул итәргә тиешбез.

Тарих идеяләребезне һәм идеалларыбызны сынады. Без сталинизм өермәләре аша уздык. Хрущев волюнтаризмына буйсынып, хакыйкать карурманнарында адашып йөрдек. Брежнев идарә иткән торгынлык еллары сазлыгын ерып үттек.

Заман безне һаман сыный тора. Заман, безнең күзләргә текәлеп, әллә нинди четерекле сораулар бирә. Узган гомеребездә нишләдек без? Без бүгенге көндә кемнәр? Без әле кая барабыз? Безгә алгы көнгә карап барасы, безгә кешелекле Кешелекне дәвам итәсе бит. Сорау кискен, аяусыз: нишләргә? Ә җавабын һәркем үткәннән һәм бүгенгесеннән сорасын, намусыннан сорасын!

*Ноябрь, 1988 ел.*

## Фәйзи Галиев

# АВЫЛЫМ ГАДӘТЛӘРЕ

### Төнге уйлар

Шулай бер көнне янгын сарае янына ирләр җыелган, көлә-көлә сөйләшеп торалар: Котдус Мөнирәсе яңадан аерылып кайткан икән. Икенче көнне кич, эштән кайтканда, Мөнирә апа янына тукталдым. «Мөнирә апай, ни хәлләрең бар, ничек яшисең, сәламәтлегең ничек? Синең йортыңда ут булгач, урам ямьләнеп киткән»,— дидем. Ул, яулык почмагын тотып алды да, ихтыярсыз елап җибәрде:

— Булмады инде, энем, берничә тапкыр барып карадым кияүгә, яңадан кайттым. Бер дә ияләнә алмыйм шул. Минә шушы йорт, авылым, күршеләрем сагындыра...— дип сөйли башлады.— Энем, миңа пенсионерларга бүленә торган икмәкне бирерсез микән?..

Мин: «Барлык үтенечләрең дә үтәлер, иртәгә, әйберләреңне алып кайтырга машина булыр, икмәкне дә иртәгә үк алырсың, иртән сәгать җидегә идарәгә кил»,— дидем. Өченче көнне Мөнирә апаның капка төбендә ап-ак тузларын ялтыратып бер машина каен утыны ята иде. Капкасыннан бер ат әзе дә кергән. Алай икән, бодайны да алып кайткандыр, машина эзе дә бар, урын-җирен дә алып кайткан икән,— дип тынычланып куйдым.

Сугышка кадәр, мин әле үсмер малай чагында, минем әтиләрнең төп йорты белән Мөнирә апайның килен булып төшкән йорты кара-каршы иде. Мин еш кына ул йортка — әбиләргә дип төшә торган идем. Мин шулай бер төшкәндә, бик матур итеп бизәлгән, тарантаска җигелгән ат белән Габделхак абый Күәм авылыннан кыз алып кайтып, капкадан кереп китте. Тарантаслы ат артыннан бирнә әйберләре төягән атлы арба да керде. Ул аттан берничә кыз төшеп, арба янында туктадылар. Тарантаслы ат килеп кергәч, ат башында утырган егет җиргә сикереп төште, аның артыннан Габделхак абый төшеп, яшь киленне кулыннан тотып җиргә төшерде. Килен төшкән урынга мендәр китереп салдылар. Өйдә яшь киленнең кулын онга тыгалар, бөтен ипине башлап кистерәләр икән. Янәсе, ашлы-сулы булсын, бәхетле, мул яшәсен.

Иртәгесен күрше кызлары су юлы күрсәтергә дип, яшь килен белән бергә чишмәгә киттеләр. Мөнирә апай озын куныччлы туфли кигән иде. Сокланып карап тордык. Һәрчак шулай: килен төшсә, аны бөтен авыл карап-күреп калырга тырыша. Без, малайлар, Габделхак абыйга кызыгып карый идек. Озын шинель кигән, башында — яшел фуражка, аягында — хром итек, итек үкчәсе артында ялтырап торган тимере бар иде. Ул чик сакчысы булган икән...

Мөнирә апайның уйлап утырам. Габделхак абый белән аларның тормыш юлы әнә шулай башланган иде. Алар үзләренә йорт салдылар. Габделхак абый ферма мөдире булып эшләде, ә Мөнирә апай колхозда төрле эшкә йөрде. Өч балалары булды. Бер кызы, ике улы. Шулай яшәгәндә сугыш башланды. Габделхак абый сугышка китте, шунда үлеп калды.

Бу гына җитмәгән, Мөнирә апайның бер улы җәй көне суга батып үлде. Икенче улы Рүзәл әтисе кебек таза, нык булып, чибәр булып үсте. Колхозда эшли, әнисенә ярдәм итә иде. Аның өчен сөенеп кенә йөргәндә, тагын бер фаҗига бу хатын өстенә ишелде. Шулай бер көнне ишегалдында йөри идек, ачыргаланып кычкырган хатын-кыз тавышына тынып калдык. Нәрсә булды икән дип мин тавыш килгән

---

Ахыры. Башы 3 санда.

якка йөгердем. Карасам — безнең бакча башында, инеш буендагы агачлыкта, Мөнирә апай елый-елый чабып йөри, сүзен әйтә алмый, кулы белән агачлыкны күрсәтә. Рүзәл авылның бер кызы белән танышкан, аннан ничектер бер-берсеннән сүрелеп торганнар. Рүзәл, сакау булган өчен яратмый, дип, Мотаһара фермага сыер саварга бара торган юл өстендә, аңа үч итеп, асылынып үлгән.

Мөнирә апай бердәнбер кызы белән яши башлады. Ул кыз фермада сыер савып, ярыйсы гына көн күрәләр иде, көннәрдән бер көнне ул кызы да авырып үлеп китте. Мөнирә апай япа-ялгызы торып калды. Аның яңадан кияүгә чыгып йөрүен уйлагач, бер гыйбрәтле хәл искә төшә.

Бер вакыт хатыны үлгән Лотфулла абыйга, элеге дә баягы янгын сарае янындагы ир-атлар: «Лотфулла абый, яшь хатын белән яшәүләре рәхәттер, ә?» — дип, сорау биргәннәр. Лотфулла абый бер хәлне сөйләп киткән. Әтнә базарында аның бер танышы очраган, ул да, хатыны үлгәч, яшь хатын алган икән. «Хәлләрең ничек, ничек яшисең, яшь хатыныңнан уңдыңмы?» — дип сорагач әйткән: «Әй, Лотфулла, син сорама, мин әйтмим, бар да яхшы, хатын да бик акыллы, балаларны да какмый, ризык пешерергә дә иренми, ләкин бер урында сигез аяк йоклыйбыз?», дигән. Аптырый Лотфулла: ничек инде ул сигез аяк? «Урын-җир янына килгәч тә, иң элек беренче өйләнгән хатын, куеныма беренче кергән кыз искә төшә. Яшь хатын да элекке ирен уйлый торгандыр. Менә шулай итеп без бер урында сигез аяк йоклыйбыз, бу хәл бик авыр икән», — ди.

Менә мин дә Мөнирә апай тормышында килеп чыккан бара-кайта йөрүне Лотфулла абый сөйләгән кыйссага туры килә дип беләм. Кешенең хәленә керүне, аны аңлауны җитәкченең беренче бурычы дип исәплим.

Уйландыра толлар. Өйгә кайтам — Шәрифә апай Гатауллина йортында ут бар, якты, әле ул таза-сау, димәк. Аның каршысындагы Хәнифә апай йорты ябылган, үзе генә тору мөмкинлеге булмагач, Әтнәдәге кызына китеп барды. Алар янында гына Факия апай Садретдинова йорты, ул да ялгыз.

Авылның әхлакый климаты әнә шундый кешеләрнең тормышына битараф карамаудан да килә. Халык ихтирамлы — толларның күршеләре утыннарын кертеп, ярып, кисеп бирәләр. Әйтәсе килгән сүзем шул: авыл халкында соңгы елларда бик матур гадәтләр барлыкка килде. Әле генә мин әйтеп киткән, фронтта ирләре үлеп калган карчыкларга колхоз ярдәме белән беррәттән күршеләре, туганнары да ярдәм кулы суза.

Идарәдә эшемне бетереп, урамнан кайтып килəм, җәйнең матур көне, урамда беркем дә юк. Капка төбендәге Сәхибулла абыйның хәл-әхвәлен сорадым. «Әй, энем, минем хәлне сорама инде, — дип офтанды. Сөйләп китте: — Бүген авылда иң зур бәйрәм ич. Колхоз кешеләргә печән бирде. Барлык кеше болында печән чаба, җыйный, берсе-берсенә булыша, берсенекен чабып, кабартып бетергәч, икенчесенә ярдәмгә керә. Мин генә шул кешеләр янында була алмыйм, булыша алмыйм, шуңа күңелем тулып утырам», — диде.

Сәхибулла абый Бөек Ватан сугышыннан ике күзе дә күрмәс булып, мина кыйпылчыгы тиеп, сукыраеп, кайтты. Янына утырдым. Ул миңа авылыбыз халкының матур яшәвенә соклануын әйтте. Берсе белән берсе тату, кычкырышу юк. Элекке шикелле, басудагы ызан өчен сугышу юк. Барысы да бар, барлыкларының кадерен беләләр, ди. Кешеләр печән чаба. Эшләре беткәч, болында, ашъяулыклар җәеп, кемдә нинди ризык бар, шуны табынга куеп, чәйләр эчеп, ял итеп кайтырлар. Татулык дөньяны матур итә. Көз көне сугым вакытында, берсе икенчесенә кереп, без ит мактарга кердек, дип, күңелле итеп, чәй эчү гадәте дә картка ошый икән. Сугым суйган көнне иртәдән кичкә кадәр казанда ит пешә, самавыр кайнап тора. Утын алып кайткач, аны яру, салам алып кайткач, аны өю, йорт-каралты эшләткән чакта өмә ясау — борынгыдан килгән матур йола. Тик аларны аракы белән генә бозмаска кирәк.

Сәхибулла абзый тынычлангач, мин өйгә кайтып чалгы алдым да печәнлеккә киттем. Болын өсте чуп-чуар, ире-хатыны, баласы-чагасы, картлар-карчыклар — барысы да болында иде. Үзенә дигәндә кеше шундый күтәренкелек белән эшли, әнә шул оешканлыкны колхоз тормышына да күчерәсе иде.

Кешеләрнең болында эшләвен карап тору да күңелне кузгата. Еракларга җәелеп киткән зур болын, биек, куе печән бер хәзинә булса, болын тулы кеше, эшкә сәләтле, сау-сәламәт кеше — иң зур хәзинә. Сәхибулла абыйның капка төбендә, бөтен халык эшкә китеп беткәч, моңаеп утыруы юкка түгел шул.

Авыл урамыннан узганда, йортларга игътибар итәм. Һәркем үзенчә төзи каралтыны. Мин йөргән урамда өч кешенең йорты өч төрле. Мәгъсүмов Мөнир — йортын нарат бүрәнәсеннән, ике ягын таслап, борыс ясап салды. Биек аның йорты, калай түбәле, зур капка, урам буенда — мунчасы, рәшәткәләре үзенә бер бизәкле. Аның күр-

шесе Галиев Җаббар йорт кыегына чарлак ясаган, өе рәшәткә артында түгел, урамга ук чыгып тора, урам буенда мунчасы, ишегалдында бакчасы, бакчада умарталары бар. Ә Фатыйхов Равил йорты йомры агачтан салынган, ул да түбәсенә чарлак чыгарган, аныкы бөтенләй икенче төрле. Мунчасы, гаражы, келәте бар. Бу каралтыларның һәркайсына калын тактадан сукмак салынган. Хәлиуллин Расих исә машина гаражын биек итеп күпер салып урамга чыгарды. Аларның дүртесенең дә каралты-курасы, тормыш яхшырган саен, үзгәрә барды. Элек урам буена алтыга-алты метрлы итеп бер йорт һәм өйалды салдылар. Тормыш яхшыра төшкәч, өстәп кухня ясадылар. Соңгы елларда кухняның икенче башына, алты метрга алты метр иттереп ак өй җиткезделәр. Элегрәк әйтеп киткәнемчә, тазарак тормышлы кешеләр, уртасына өйалды корып, өч көрле итеп, аш өе, ак өй, йокы өе (кечкенә өй) булдырганнар. Менә хәзер өйалдын уртага эшләмичә, йортларны тоташ салу гадәткә керде. Түбәле зур капканы хәзер барлык йортта да очратасың. Коймаларны нәкышләп эшлиләр. Мунчалар да элек, күбесенчә, кара була иде, ягъни миченең морҗасы юк. Төтен мунчага тула, стеналар кап-кара корым була, киенгәндә корымга буялып бетә идең. Ә хәзер тормышлар яхшыргач, ак мунча салалар. Ул мунча ике бүлемнән тора — берсе юыну-чабыну өчен, икенчесе киенер өчен. Хәзерге мунчалар бик чиста, рәхәтләнеп ял итә торган.

Хәзер мал-туарны да бүрәнәдән мүклəп күтәргән яки шлактан ясалган җылы абзарларда асрыйлар. Ул абзарларда савым сыеры, симертә торган хайван, сарыклар, бәтиләр һәм бозаулар, тавыклар өчен аерым-аерым бүлемнәр ясала. Хуҗалыкта кар базлары да саклана. Аларын таш яки кирпеч белән эчлиләр. Баз өсте чиста, үзе бер келәт.

Күнгәр авылыныкы Хәйретдин абыйның яшьләргә сөйләгән бер хикмәтле мәзәге хәтердә. Алар авылының бер егете кыз белән танышкан да, әти мине өйләндер әле, дигән. Атасы риза булмаган. Гадәттә бит авыл халкы туйларны эш беткәч, көз көне ясый. Ә бу язын өйләнмәкче икән. Әтисе үзенекен әйтә, егет — үзенекен. Ахыр килеп, әти кешенең ачуы чыккан. Малайны өйләндергәннәр. Карт бик үткен кеше булган, хатынына әйткән: син киленне ашау-эчү тирәсендә йөрт, ә мин малайны үз янымда эшләтәм, дигән. Малай эштә эт булып арый. Ә килен өйдә, әнекисе янында, ашап-эчеп, чибәрләнеп киткән, егетне елмаеп кына каршы ала икән. Бер көнне егетнең чабатасы тишелгән. Ул, эштән кайткач, чабатасын ямарга утырган, ул арада өйдә яшәгән бозау егетнең кулына тибеп киткән. Егет калыплы чабата белән бозауны кыйный башлаган. Атасы әйткән, нишләп кыйныйсың, аның һич гаебе юк, дигән. Егет җавап итеп: «Бик сикерсә, өйләндерермен әле менә!» — дигән. Икенче бер көнне егет авыл урамыннан көтү кайтканны карап тора. Иң азактан гына зур мөгезле бер тәкә аңгыраеп кайтып бара икән. Малай карап торган-торган да, бу мескен тәкә дә өйләнгән ахрысы, дигән. Шул сүзне ишетеп торган атасы: «Хатын, шаулама, малай өйләнүнең кайчан әйбәтрәк икәнен аңлаган булса кирәк»,— дигән.

Безнең авылга күрше авыл марилары утын сатарга килә торган иде. Шулай бер көнне кибет янында бер мари бәләкәй генә итеп төягән коры утын сатып тора икән. Безнең авылның Мифтахи дигән кеше утын сатулашырга килгән. Озак сатулашкан. Мари үз сүзендә торган. Әй, дигән Мифтахи, чанасы-ние белән күтәреп китәрлек утының бар, шуңа дөнья бәясе сорыйсың, дигән. Мари әйткән, күтәреп кара, әгәр күтәрә алсаң, чанасы-ние белән бирәм, дигән. Базарда торучыларга кызык була: «Әй, булмаса булган икән, күтәр дә кит, Мифтахи!» диләр. Авыл халкы белә: Мифтахи көчле. Ярар, дигән Мифтахи. Атны туарып, түшлек-аркалык белән тәртәләрне кысып бәйлиләр. Мифтахи ике табан арасына керә, чананы җилкәсенә күтәрә дә китә башлый. Йөк хуҗасы кинәт көлүеннән туктый: «Чанасын гына булса да калдыр!» — дип ялына башлый. Утынны, әлбәттә, кайтарып бирәләр. Мари, сөенеченнән, утынын арзанга гына сатып киткән, имеш.

Авыл халкының нинди уй, нинди теләкләр, нинди гадәтләр белән яшәвен белү, гадәт-йолаларның уңайлысын сайлау, тагын да үстерү-баету, җитәкченең көндәлек эшендә чагылыш табарга тиеш. Кешеләргә авыр хәлдә калганда ярдәм итү, җылы сүз белән юату җитәкчегә карата ихтирам уята. Гореф-гадәтләрне, халкыбызның матур йолаларын саклый белгән җитәкче беркайчан да оттырмый, ота гына.

## Күмү йоласы

Безнең авылларыбызда авыру багу, мәет күмү йоласы элек-электән нык сакланып килә. Кеше каты авырый башласа, күршеләре, туганнары хәлен белеп торган, ул йорттан кеше өзелмәгән. Авыру янына кереп утырып, аның хәлен сорау гадәти хәл булып киткән, авыруга нәрсә ярдәм итә, нинди дару, нинди үлән ярый — һәммәсе

сөйләшенә, фәлән авылда фәлән кеше тазарган, тазарасың әле,— дип, авыруны төшенкелеккә бирелүдән саклый. Тавык шулпасы, мичтән генә чыккан кайнар кабартма, сумса алып кереп, авыз итеп кара әле дип, кыстый-кыстый ашатырга тырышалар. Бала-чагасы булса, аларга да күчтәнәч алып киләләр. Авыру янында озак-озак утырып чыгалар. Күп очракта бу эшне картлар, карчыклар башкара. Алар авыру кешегә яшь вакытларын, бергә эшләп йөргән чакларын күңелле итеп сөйлиләр, аңарда яшәү өмете уяталар.

Авыру үлсә, моны бөтен авылга хәбәр итәләр. Мәрхүмнең йортына туганнары, күршеләре, өлкәннәр җыела. Карчыклар күмүнең борынгыдан килгән йолаларын саклыйлар. Мәрхүмнең гәүдәсен авылда пөхтәлеге белән дан алган, мәеттән курыкмаган кешеләр юа. Юылган мәетне ак тукыма белән кәфенләп җылы юрганга төреп, зиратка алып киләләр. Мәет салган кабыкны зиратка кадәр күтәреп баралар. Анда баргач, җиргә куеп, озата килгән кешеләр саубуллашу йоласын үткәрәләр. Мәетне иңдергәч, зиратка килгән кешеләр кабергә берәр уч туфрак сала. Бу инде — күршеләре тарафыннан бирелгән соңгы ризалык, ихтирам билгесе. Ризалык димәктән, авыру кеше, хәле начарлана төшкәч, күршеләренә һәм барлык туганнарына «мин сездән бик риза-бәхил» дип кулын биреп саубуллашып чыга. Олы кешенең риза-бәхиллеген ала алмау — йорттагы кешеләр өчен бик начар. Карчык киленен бәхилләмәгән, килен бик рәнҗеткән икән дип сөйләгәннәрен ишеткәнем булды. Ләкин мондый хәлнең безнең авылда булганы юк. Кайдадыр менә шул малай атасының ризалыгын ала алмаган дип сөйләшкәнне генә ишеткәнем бар. Гадәттә безнең авылларда олы кешене хөрмәт итәләр. Йорт эчендә иң дәрәҗәле урында олы кеше йоклый, табын янында иң түрдә олы кеше утыра. Эти-әнисен чиста, пөхтә йөртү, матур киендерү — безнең якларда табигый хәл.

Соңгы елларда авылларыбызда вакытсыз үлгән, Бөек Ватан сугышында катнашкан дәрәҗәле кешеләрне күмгәндә, колхоз, профсоюз оешмасыннан кешеләр катнаша. Миңа да, шул исәптән, күп кенә кешеләрне күмүдә катнашырга туры килде. Мәсәлән, бер бик яхшы тракторчыбыз Хәйруллин Әгъләмне, бер комбайнчыбыз Сибгатуллин Әлтафны, Бөек Ватан сугышында катнашкан Гомәров Гыйләҗне, колхозыбызның комсомол оешмасы секретаре Гыйбадуллина Фирдинәне, колхозыбызда озак еллар минем белән бергә хисапчы булып эшләгән Җәләлиева Һадияне һәм башка бик күпләрне күмүдә катнаштым. Бу очракта мәетнең гәүдәсе салынган табутны ишегалдына алып чыгып, аны урындыклар өстенә куеп, мәрхүмнең тормыш юлы, аның яхшылыгы хакында кешеләр алдында сөйләп озатабыз. Кайбер очракта бу хәл зиратта да үтә. Безнең авыл халкында хатын-кызның зиратка керү йоласы булмаганлыктан, хатын-кызлар анда бармыйлар. Шуның өчен мәрхүм турында сөйләүне аның барлык туганнары булган җирдә, үзләренең ишегалдында сөйләүне дөресрәк дип табабыз.

Авыл халкы үз теләге белән кабер казырга җыела. Кабер казу, мәет юу әсбаплары зиратта махсус бинада саклана. Авылның дәрәҗәле бер карты бу әйберләр өчен җаваплы санала. Кабер казып ләхет алгач (ләхет — каберне казып төшкәч, кырыйга казып керү), мәетне күмәләр. Мәетне кабергә иң якын туганнары иңдерә (улы, абыйсы, кияве һ. б.). Кабер өстенә (баш ягына) каен, имән, чыршы, нарат, миләш, шомырт кебек агачлар утырту гадәткә кергән. Шуннан соң, кабер казучылар, читкәрәк китеп утырып, тагын бер кат саубуллашалар. Йортта мәетне төнәтүчеләргә, мәрхүмнең истәлеге итеп, яулык яки исле сабын өләшенә. Алар, йорт хуҗаларын юатып, тынычландырып кайтып китәләр. Бик якын кешеләре, мәрхүмнең туганнарының кайгысын уртаклашып, берничә көн шул йортта калалар. Ә күршеләре өчесенә кадәр, бу йортка кергәләп, хәл белеп торалар. Кайбер кешеләр мондый югалтуны бик авыр кичерәләр, үзләренең дә авырып китү очраклары була. Ир-ат, кайгымны басам, дип, эчүгә сабышырга мөмкин. Мондый очракларда да күршеләр күз-колак булып тора. Өченче көнне йорт хуҗасы якыннарын ашка чакыра. Шунда үлгән кешенең әйбәт якларын искә алалар, йортта калган кешегә, мәрхүмне исән чакта тәрбияләгәне өчен, авыл халкы исеменнән рәхмәт әйтәләр. Җиденче көнне, төн чыккан хатын-кызларны чакырып, шулай ук мәҗлес ясап, мәрхүмне искә алалар. Кырыгынчы көнендә иң якын туганнары килә, мәрхүмне тагын искә алу кичәсе ясыйлар. Елы тулган көнне дә барлык туганнары, күршеләре җыйналып искә алу үткәрәләр. Бу мәҗлесләрдә ирләр, хатын-кызлар аерым җыела. Берсендә ирләр булса, икенчесендә хатын-кызлар була. Искә алу мәҗлесләрендә, күмәргә килгәндә аракы эчү тыела, бу — мәрхүмнең истәлеген мыскыллау булып санала.

Зиратлар безнең колхозның җиде авылында да рәшәткәләр яки коймалар белән әйләндереп алынган. Зиратка хайван кертелми. Аның печәне, авыл Советы рөхсәте белән, зиратны саклау чыгымнары өчен сатыла. Һәр елны язын авыл халкы җыйналып, зиратларны ауган, кипкән, корыган агачлардан чистарталар. Каберләргә таш,

чардуган куелә. Безнең авылларның зиратлары, читтән караганда, урманны хәтерләтә. Авыл халкының үлгән кешеләрнең истәлегенә игътибарлы булуы — күңелле матур күренеш. Бер үк вакытта ул яшьләрне өлкәннәргә ихтирам рухында тәрбияләү өчен дә кирәк.

Мәет күмү, зиратларны пөхтә итеп саклау — социаль мәсьәлә, аңа җитәкчеләр аеруча игътибарлы булырга тиеш.

## Үз-үзеңне тоту гадәтләре

Иң беренче сүзем итеп безнең колхоздагы гаиләләрнең тотрыклылыгын, таркалу очракларының бик аз икәнен әйтергә кирәк. Яшьләрнең гаиләсе бозыла башласа, өлкәннәр үгет-нәсихәт белән, киңәшләре белән шундук килеп җитәләр. Бу әйбәт гадәт безнең авылларда күптәннән килә. Өйдә олы кешегә ихтирам бик зур. Алар йортның иң дәрәҗәле бүлмәсендә яшиләр. Аларның киемнәрен киленнәре, балалары чистартып, юып, урын-җирләрен, мунча яккан саен, алыштырып торалар. Мунча шимбә яки якшәмбе көнне ягыла. Туганнар яки күршеләр, бер атнада берсе, бер атнада икенчесе мунча ягып, йортта тәмле-тәмле ризыклар пешереп, чәй эчеп, төрле хәлләр хакында сөйләшеп, көлешеп, күңелле итеп кич утыралар.

Олы кеше акча байлыгы белән идарә итә. Бик сирәк йортларда гына акча янчыгы килен яки малай кулында була. Пенсия яшендә булган олы кеше балаларының балаларын (оныкларын) карауны гадәттә үз өстенә ала. Әнеки карый баланы, әтеки эшкә өйрәтә. Бездәге киленнәр кияүнең анасына — әнеки, атасына — әтеки дип әйтәләр. Өлкәннәр йорт эшләрен карый, мал-туарны тәрбияли, кош-кортларны туйдыра, ишегалларын себерә, яшелчә үстерә. Көченнән килгән шундый эшләрне башкарып, улы, килене алдында ихтирам казана. Эштән арып кайтканда, йорт эше эшләнеп беткән булса, улы белән киленен табында кайнар ризык көтеп алса, белеп тор — бу гаилә тату яши.

Минем әнинең йорт тоту гадәтләре үзеннән-үзе миңа һәм хатыныма күчте. Элек, без яшьрәк чакта әни көнгә өч мәртәбә ризык пешереп, эштән кайтканда безне көтеп тора торган иде. Минем эшем исәпләнмәгән, вакытсыз да кайтам, ләкин, кайчан кайтсам да, ашарга әзер була иде. Хатыным укытучы булганлыктан, кичләрен дәфтәрләр күтәреп кайтып, өйдә шуны тикшереп утыра, ягъни йорт эшләре белән шөгыльләнергә әллә ни вакыты калмый. Әни, 85 яшенә җиткәнче, һаман булышып килде. Аның матур гадәтләре минем хатынга күчте. Ул оныкларыбызны карый. Аларга оекбашлар, кофталар бәйли, мамык шәл бәйли, җылы киемнәр тегеп киертә, ертык-тишекне ямый. Ашарга әзерли, гомумән, йортның хуҗабикәсе булу табигый рәвештә әнидән аңа күчте. Акча янчыгын да аңа тапшырдык. Ә мин, иртүк торып, мал-туарны карыйм. Хатыным чәй кайната, ризык әзерли. Киленебез, улыбыз белән бергәләп иртәнге чәйне эчеп, эшкә китәбез. Көндез яңадан хатыным ризык әзерли. Бакчада бергәләп эшлибез, умарталарны хатыным белән икәү карыйбыз. Без үзебез дә, авыл кешеләре дә шушы тәртипне хуплыйбыз.

Соңгы елларда бу гадәтләр үзгәрә башлады. Безнең авылның бер егете атасыннан аерылып чыгып, хатыны белән икәү генә аерым яшәүне кулай күрде. Килен дә шуны хуплады. Әти-әнисен чакырып сөйләштем: «Улың башка чагарга җыена, колхоздан йорт сорады, ул сезнең килешенгән эшегезме, нишлик?» — дидем. Абзый уйланып торды. «Без сөйләштек, киңәштек, аерым яшәп карасыннар», — диде.

Көннәр үтте. Бу абзый безнең урамда тора. Шулай беркөнне сөйләшеп киттек. «Менә, энем, утыныбыз юк, малайга әйткән идем дә, кайтарып бирә алмый әле. Синең яныңа барам әле, саламым бетте, сыерга ашатырга кирәк, малай онытты, син берәрсенә әйтеп, китертә алмассыңмы?» — диде. Тагын да бер көнне, эшкә барганда, абзыйлар турысыннан уза идем, мотоцикл тавышы читкә тайпылырга мәҗбүр итте. Мотоциклда әлеге егет, хатынын, кызын утырткан, аталары янынннан җилләр уйнатып узып китте. Әтисе капка ярыгыннан карап тора. Исәнләштек. «Нишләп чыгып карамадың?» — дим. «Әллә нишләп уңайсызланам шул, — диде ул. — Улымны күрәсем килә. Бигрәк тә улымның кызын сагындым, бик сирәк керәләр», — дип елап та җибәрде.

Егет белән сөйләшергә туры килде. Олы кешенең күңеле нечкә булуы, төп йортка ешрак кереп йөрергә, кызын аларга ияләндерергә кирәклеге хакында киңәшләр биреп җибәрдем. Кереп чыгу белән генә олы кешенең күңелен тынычландыру читен икәнен белсәм дә, киңәштән артыгын эшли алмадым. Егет бик эшчән, акыллы, яхшы механизатор, килен дә эшчән, тәрбияле. Авыл халкы барыбер егетне дә, киленне дә яратмый.

Борынгыдан килгән гадәт буенча, олы ир бала, башка чыгып, яңа тормыш кора, ә төпчек дигәне, иң соңыннан туган ир бала, ата-ана йортында торып кала. Башка

чыгучыларга бер бозауны тана итеп үстереп бирәләр, бер-ике сарык бәтие, йорт өчен кирәк-ярак, бер елга җитәрлек ризык (он яки ашлык), бәрәңге биреп чыгаралар. Башка чыгучыларга барлык туганнары, күмәк көч белән, йорт салып бирә. Хәзерге чорда безнең колхозның үз тәртибе барлыкка килде. Башка чыгарга теләгән кешегә, әгәр ул үзе йорт салырга теләмәсә, колхоз йорты бирелә. Беренче елны квартир хакы түләмиләр. Икенче елны гына ил күләмендәге тариф буенча түли башлыйлар. Менә бу язмаларны язган көннәрдә генә Шиһапов Зыязый абыйның өченче малаена,— Шиһапов Фердинантка йорт бирдек. Галиәскәров Таһирга, Закиров Фарель, Ганиев Хөсәен, Әхмәтҗанов Ваис, Шәяхмәтов Гаделҗаннарга да колхоз йортлары бирелде. Шулай итеп, электән яшәп килгән матур гадәтләрне колхозның гомуми көче белән тагын да ямьләндереп җибәрдек. Шулай да без яшьләрнең йортны үз көчләре белән салуын яки булганны сатып бирүне хуплыйбыз. Кадерлерәк була. Хәзерге яшьләргә тир түгеп табылган мал кадерен аңлатасы бар әле.

Авыр физик хезмәтне техника башкару аркасында, кешеләр хезмәт хакын җиңелрәк ала башладылар. Аннары, шәһәрдәге күп төрле конторaларда кәгазь белән генә эш итүчеләрне күрү авыл яшьләрен калага тарта. Авылда ни дисәң дә эш бик күп. Кырда да, хуҗалыкта да. Эш хакы түләүнең дә тәртибе юк иде.

Тракторчы егет белән кырда сөйләшеп торабыз. Егетем әйтә: «5 гектар җир сөрәм — 6 сум түләнә. Мин эшләгән җирдә бер гектардан 28 центнер уңыш чыкты, ә менә күрше колхознықында — 15 центнер гына. Тракторчысы шул ук 6 сумны ала, колхозның үз акчасы җитмәсә, аңа дәүләт бирә. Бу хәл дөрес түгел дип исәплим мин»,— диде.

Аннан соң колхозларны аякка бастыру өчен дип кабул ителгән хөкүмәт карарлары да, уйламыйчарак кулланганда, авыл халкын боза. Мәсәлән, төрле колхозларны төрле категориягә кертүләр, һәм бер үк байлыкка төрлечә түләү. Җиңелрәк табылган акча хисабына яшәргә өйрәнүчеләр арта. Безнең колхоз нулевой вариантта төп бер төсле хак ала, ә күрше колхоз барлык продуктларны да безгә караганда 50 хәтта 70 процентка кыйммәтрәк сата. Безнең колхоз бер ел эчендә 1 миллион 28 мең сумлык табыш ясады. Күрше колхоз 700 мең сумлык табыш ясады, ә бит шуның 500 меңе колхозга өстәмә түләүдән килде. Икенчедән, ул — налог та түләмәде, безнең колхоз дәүләткә авыл хуҗалыгы налогын, страховой, пенсия фондына, дип, 500 мең сум акча бирде. Бу хәл хезмәткә ялгыш караш тудыра.

Хезмәткә түләүне дә дөрес оештыру кирәк. Безнең колхозда моңа нык игътибар ителә. Мәсәлән, сыер савучының берничә сыйфаты искә алына. Сыерны тәрбияләгән, буазландырган, бозауны исән-сау алган, сауган, сөтнең күләме, майлылык, аның чисталыгы, терлек азыклары ташыган, тоз һәм башка өстәмәләрне кушкан, озак еллар эшләгән һәм класслы савучы булганы өчен. Механизаторларга да шулай. Планнан тыш продукция җитештергән өчен өстәмә түләү тәртибе керттек. Өстәмә түләү ел азагында бирелә. Бер группада смена белән эшләүче ирле-хатынлы Сәвия һәм Газиз Вәлиевләр мең сум өстәмә түләү алдылар.

Безне, дөньяда иң изге әйбер — икмәк, дип өйрәттеләр. Кечкенә вакытта әниемнең әйткән бер вәгазен китерү урынлы булыр дип уйлыйм. Шулай бер көнне мин, шакмаклы ашъяулыкка төреп куйган ипине алып ашаганнан соң, аны элеккечә төрмәгәнмен. Шул хәлне күргән әни: «Икмәкне нишләп элеккечә итеп төреп куймадың, аны бит җен ялап китә, әгәр син шул ипине ашасаң, эчең күбә, алай эшләмә икенче»,— диде. Шунда мин тагын байтак нәрсә белдем: ипинең валчыгын да әрәм итәргә ярамый, кисеп алган телемеңне ашап бетерергә кирәк һ. б. Борынгы заманда бер карчык чәй эчеп утырганда, аның янына мәче килгән, карчык мәчене куган, китмәгәч, аңа ипи катысы белән суккан. Шул көннән башлап карчыкның ипи белән суккан кулы корый башлаган... Әни мине әнә шулай куркыта торган иде. Көннәр узу белән бу сүзләрнең риваять икәнен дә беләсең, ләкин бала чакта кергән, олыгайгач та, күңелдән чакмый.

Шулай бер көнне, СССР Верховный Советы депутаты вакытта, Мәскәүдә сессия эше беткәч, кайтып китү өчен әйберләрне чемоданга тутырып ятканда, күрше бүлмәдән бер иптәш керде дә, минем әйберләр арасында катып беткән ипи сыныгы күреп, гаҗәпләнде. Бу — Мәскәүгә барганда, юлда барганда, юлда ашарга дип алган, ашалып бетмәгән ипи калдыгы иде. Күршем әйтә: «Тапкансың сөйрәп йөрер нәрсә?!» — ди. Бер генә җирдә дә ипи калдыра алмыйм, өйгә алып кайтам. Бу юлларны укыган кайберәүләргә әлеге гадәтем сәер тоелыр. Икмәкне изге әйбер дип өйрәнеп, сугыш вакытында, аның бер телемен күрә алмыйча, еллар буе бәрәңге, үлән ашап яшәгәнгә, ачтан шешенгән авылдашларымның, үлә алмыйча, калтыранып яткан балаларын күргәнгә һәм бөтен гомеремне икмәк үстерүгә багышлаганга икмәкне кадерсезләгән бәндәләрне явыз дошманым саныйм. Әти-әниемнән килгән гадәтләрне балаларыма да күчерергә тырыштым. Алар өчесе дә авылда, икмәк үстерәләр. Аларга да икмәк изге булып калырына ышанам.

Безнең авылда ир — баш, хатын — муен дигән әйтем бар. Элекке чорда ир балалар мәдрәсәдә укыган, ә кыз балалар абыстай йортына йөргәннәр. Ягъни аерым үскәннәр. Хатын-кыз, борынгы мөселман гадәте буенча, ирләр яныннан битен каплап үтә торган булган. Мин белгәндә, андый гадәт беткән иде инде. Шулай да ялан сыйрак йөрү безнең авылда тыелган иде. Барлык хатын-кызлар да оек киеп йөриләр иде. Кыш көне — тула, көз-язда — йон, җәй көнендә Мәскәү оегы дип аталган юка оек кияләр. Олы кешеләр тәнне күрсәтми йөрү — ир белән хатынның интим тормышы өчен сакланган гадәт, дип аңлата иде. Хәзер ир-ат белән хатын-кыз тигез хокуклы, бергә эшлиләр, бергә бәйрәм итәләр. Ир өстеннән башка ир белән йөргән хатынны авыл халкы өнәмәгән. Атасыз бала табуны да авыл халкы бик зур оят исәпләгән.

Элек хатын-кыз йорт эшендә генә катнашкан, кешеләр белән әллә ни аралашмаган. Авыр эшләр ир җилкәсендә була: иген игә, акча табу өчен читкә китеп тә кайта. Ир — гаиләне туйдыручы. Бәлки шуңа күрәдер, семья таркалу очрагы сирәк булган. Сугышка кадәр ир кеше әйткән сүз гаилә өчен закон иде. Балалар үстергәндә дә, атаң нәрсә әйтер, атаң белән сөйләшербез, дип, балада атага карата хөрмәт, аны олылау хисе тәрбияләнә иде. Начар гадәт түгел дип исәплим мин.

Соңгы вакытларда хатын-кыз белән ир-ат бертигез эшләп, бер дәрәҗәдә акча тапкач, элекке гадәтләр үзгәрде. Бер йортта ир башлап йөри, икенчесендә — хатыны. Олы кеше булмаган йортта акча янчыгы да төрлесендә булырга мөмкин. Ир-атның үзен дөрес тота белмәве кайбер очракларда йортта башбаштаклык китереп чыгара. Әнисе балалары белән бергә: «әнә теге (ягъни атагыз) дуңгыз булып, тыгынып кайта инде»,— дип тәрәзәдән карап торса... Бу очракта балалар тәрбияләүдә дә, ир белән хатын арасында да бозыклык килеп чыга. Кайбер очракларда балалар ятим дә кала. Ятим баланың кабат бозык юлга басуы да ихтимал.

Авылдагы җитәкче оешмалар: колхоз идарәсе, авыл Советы бу очракларны өйрәнеп, белеп торырга тиешләр. Бу — авыр эш. Ватылган тракторны төзәтү, артта калган эшләрне рәтләп җибәрү, булмаганны булдыру җиңелрәк, таркала башлаган гаиләне тәртипкә салу — бик авыр. Авыл халкының серенә керә алган җитәкче халык тарафыннан таныла, керә алмаса, чит-ят булып кала. Ә аның өчен җитәкче үзе үрнәк булырга тиеш. Шул чакта гына ул башкаларга хөкем чыгарырга, киңәш бирергә хаклы.

Колхозлар берләшеп, җиде авыл бергә яши башлагач, төрле авылларның төрле гадәтләре белән очрашырга туры килде. Көннәрдән бер көнне, бер авылга баргач, ат җигүче бер кеше белән сөйләшеп торганда: «Син бик ябыккансың, нәрсә, тормышыңда уңайсызлык бар мәллә, әллә ашарыңа юкмы?» — дип сораша башладым. Теге әйтте: «Әй, Фәйзи абый, җан тынычлыгым юк, хатыным икенче берәү белән «йөри», очрашалар, миңа тәрбия юк, мене бүген дә үзе янында йоклатмады, өсне дә чишенмичә идәндә аунадым...» — дип зарланды. Авыл Советы председателе, партия оешмасы секретаре, мин — өчәү киңәшеп, яшь хатынның үзе белән сөйләштек, нәтиҗәсе булмады. Шуннан фактларны җыеп, иренә себерке белән сукканы, ямьсез сүзләр әйткәне өчен, авыл халкы алдында, җыелышта хөкем чыгарырга дигән фикергә килдек. Җәйнең бик матур бер көнендә игълан ябыштырып, клубка халыкны җыйдык. Хатынның атасы, ирнең әнисе чакырылды. Мин, авыл Советы председателе, партия оешмасы секретаре президиумга чыгып утырдык. Теге ир белән хатынны алгы рәткә утыртып, элек ирен сөйләттек, аннан хатынының сөйләвен таләп иттек. Алардан соң егетнең әнисе, күршеләре сөйләде. Аңлаштык. Авыл тулысынча егетне яклады, кызның әтисенә бик күңелсез булды. Берсен дә җәберләмәдек, хөкемне киңәш тәртибе белән бетердек. Җыелыштан соң бер ят кеше мине туктатты да: «Энем, менә шулай эшләп бик яхшы иттегез, бу авылның тәртипсезлеген шундый юл белән генә төзәтеп була,— диде.— Мин шушы авыл кешесе, Үзбәкстанга күчеп киттем, кайбер тәртипсез кешеләр мине авылдан чыгып качарга мәҗбүр иттеләр. Менә шулай халык алдына куеп, җитешсезлекләр, тәртипсезлекләр, кимчелекләр төзәтелсә, мин дә авылдан чыгып качмаган булыр идем. Без бит утызлап гаилә чыгып китәргә мәҗбүр булдык»,— диде.

Халык нәрсә әйтер бит әле, кешенең шәхси тормышын авылга чыгарганны өнәрме-юкмы, дип борчылыбрак йөри идем, ул-бу булмады. Еллар үткәч, очраштык. Теге ир такта яру җайланмасы янында такта төяп, бау белән бәйләп тора иде. Кыяр-кыймас кына минем янга килде: «Фәйзи абый, бер дә үзеңне туры китереп булмый, күптәннән бирле сагалап йөргән идем. Сиңа бик зур бурычлы бит мин,

тормышыбызны җайга салуда ярдәм иткәнең өчен бик зур рәхмәт»,— диде. Үз авызыннан ишеткәч, эшләгән эшебезнең хаклыгына тагын бер мәртәбә ышандым.

## Җирдән файдалану

Җир — барлык байлыкларның да нигезе. Колхозларның миллионлаган бурычка батуы, кешеләрнең колхоздан бизүе кебек яман хәлләрнең барысы да безнең җир белән эшли белү-белмәүгә барып тоташа.

Безнең колхоз бер ягы белән дә күршеләрдән аерылмый. Арча районы җиренең егәрлеге уртача 53 балл. Безнең колхозныкы да 53 балл. Район колхозларының дәүләткә 65 миллион сум бирәсе бар. Бу — колхоз саен уртача 2 миллион сум туры килә. Безнең колхозның дәүләткә бер тиен дә бурычы юк. Колхозның бүгенге көндә 8 миллион сум төп байлыгы бар. 25 ел буена дәүләттән акча алганыбыз юк. Ел саен бер миллион күләмендә саф табыш керә. Моннан кырык ел элек эшкә яраклы бер мең кеше бар иде, хәзерге көндә дә шул хәтле. Дәүләт биргән җирдән акыл белән файдалану нәтиҗәсе бу. Җир, кояш энергиясе һәм су — барысы бергә адәм баласының фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә, иң кадерле ризыкны — икмәкне барлыкка китерә.

Мин җирдән файдалана белмәгән кешеләргә гомер буе аптырап карыйм. Бигрәк тә җитәкчеләргә. Җир өчен ил белән ил сугыша, крестьян белән крестьян канга батыша. Җире булмаган кеше ачтан үлгән. Нишләп без, кешеләр, шул изге җирне ташлап качарлык хәлгә җиттек? Моны кемнәр эшләде?

Авыл белән шәһәр арасындагы әле һаман яшәп килүче аерма — шәһәрдәге җиңелрәк тормыш — кешеләрне шәһәргә тартып торды. Авылда исә хезмәткә түләү системасы озак еллар буена камилләштерелми торды. Хуҗасыз калган басуларда төрле экспериментлар ясау, колхозларны эреләндерү, әмма алар белән идарә итәрдәй җитәкчеләр әзерләнмәү хезмәт кешесе белән җитәкчелек арасын ераклаштыра барды. Җир һәм крестьян — бер-бөтен хакыйкать артка чикте. Ә без әйләнә-тирәдә шушындый гаделсезлекләр булган сурәттә дә кешеләребездә җиргә мәхәббәт тәрбияләргә тырыштык. Авыр елларда да, башкалар сукыр тиенсез калган чакта да, менә быел фәлән кадәр икмәк бирәбез, моңа без җирнең кадерен белү аркасында ирештек, дип төшендерә килдек.

Җирнең теле булса, үзенә карата күрсәтелгән гаделсезлекләрне әйтер иде, әмма ул кисәтеп-нитеп тормастан да сине ач-ялангач калдырырга күп сорамый. Безнең авылда колхозлашканга хәтле басу әйләнеше булган. Беренчесе — чиста пар, икенчесе — уҗым ашлыгы (нигездә арыш), өченчесе — сабан ашлыгы. Колхозлашканнан соң биш әйләнешле система керде, миңа шуның буенча эш башларга туры килде. Ул чорда да башта чиста пар, аннан арыш һәм аз-маз көзге бодай игелә иде, өченче басу сабан культураларыннан, гадәттә — бодай, арпа, дүртенче басу — сызма культуралардан бәрәңге, фураж культураларыннан күпьеллык үләннәр, соңгы басу солы була торган иде. Элек өч басу белән эш иткән кешеләр биш басулы системага күчүне дә өнәп бетермәделәр.

Көннәрдән бер көнне безне районның авыл хуҗалыгы бүлегенә чакырдылар да күп басулы чәчү әйләнешен тәкъдим иттеләр. Басуларыгызны күп басуга бүләбез, менә сезгә шушы кеше аны башкарыр, диделәр. Күңгәргә җир төзүче Бариев Нургали, безнең Чулпан колхозына Хисамов Гыйльметдин дигән иптәшләр килеп (без телибезме, юкмы) бер җәй эчендә күп басу ясап киттеләр. Аны колхозларда кертә барып, үләннәр чәчеп файдалана башлаган гына идек, бер заман, ул система ярамый икән, басуның күп өлеше үлән астында торып, җир әрәм була икән дигән теория чыгардылар. Күпьеллык үлән басуларын саклап калу авыр булды. Басуларны бүлеп, яңа системаны көчләп тага башладылар. Басулар саны иллегә җитте. Чөнки вак колхозлар берләштерелгән иде. Ул буталчыклардан аз гына булса да арынып, үзебезчә эшли башлаган идек, ниһаять, 1982 елда интенсив технология буенча эшләү өчен дип, районга колхоз председательләрен, агрономнарны җыйдылар. Хәзерләнергә кушылды, Казаннан галимнәр килә, имеш.

Галимнәр озак көттермәде, өелеп килде, алар белән бергә, төрле институтлардан студент егетләр, кызлар килеп, җирләрне бүлеп киттеләр. Җир-бичаракайны, минем кырык ел колхоз председателе булып эшләү дәверемдә, биш мәртәбә бүлделәр, телделәр, турадылар. Боларның барысы да җирдән читтә торучылар тарафыннан башкарылды, аның өчен хак түләнде.

Укучы: «Ә колхоз җитәкчеләре нәрсә карады?» — дип сорарга мөмкин. Мин фикеремне бер чорда әйтеп карадым, яңалыкка каршы баручы дигән яман исем алдым.

Нишләргә? Үзебезчә эшләргә туры килде. Ике-өч басуны бер итеп, колхоз агрономының һәм минем блокнотларда гына аерым схема ясап, басу әйләнешен үзебезчә алып бардык. Шуның белән җирне җәберләүдән өлешчә саклап кала алдык.

Соңгы елларда басу әйләнешләрен фәнни нигездә эшләү, җирне яхшырту, аның уңыш бирү сәләтен арттыру өчен бик әйбәт чаралар билгеләнде. Алдыйк интенсив технология белән җир эшкәртүне. Игеннәргә үсү өчен уңай шартлар булдыру, минераль ашламаларны үсемлекнең фазасына карап кертү билгеләнгән анда. Ә нигездә эш алай бармый. 1985 елны безнең колхозыбызда 1800 гектар арыш культурасы чәчелде. Башка елларны арыш җирен без самолеттан 100 процент күләмендә азот белән ашлап чыга торган идек. Интенсив ысул белән 800 гектар үстерелергә тиеш дип планлаштырылган иде. Әле ул система белән түгел, элеккечә гектарына бер центнер исәбеннән ашлау өчен дә ашлама җитми. Күпъеллык үләннәргә, бәрәңгегә башка елларда ашлама кертә идек, 1985 елны аларга бер грамм да ашлама булмады. Бу эш производство планында каралган, аның өчен акча күчерелгән, ашламага дип җибәрелгән күп кенә машиналар кире кайтып торды. Колхозда ашлама куллану буенча тәҗрибә тупланды, кешеләр дә бар, техника да җитәрлек. Ашлама гына юк! Артта калучы колхозлар дип яманаты чыккан хуҗалыкларга ашламаны теләсә-теләмәсә көчләп тагалар, нәтиҗәсе күренми, чөнки алар аңа әзер түгел. Мондый эшне җирнең үзендә эшләүче белгечләр планлаштырса, файдасы күбрәк булыр иде.

Җирне эшкәртү кораллары да үзгәрде. Элек авыл халкы атлы сука белән җир сөрә иде. Көне буе ике атлы сабан белән гектар ярым җир сөрү өчен крестьян 30-35 чакрым ара узарга тиеш иде. Аннан аны тырмалау, кул белән чәчү, урак белән уру... Крестьянның җир эшкәртүгә карашы бик игътибарлы иде. Чөнки яхшы эшкәртмәсә, ул ач кала, балаларын туйдыра алмый бит. Күмәк хуҗалыкка күчкәч тә, җирдән нәрсә алынса, шул хезмәт көненә бүленеп бирелә иде. Бу — җиргә игътибарны саклый торган алым иде. Акчалата түләүгә күчү, итекченең дә, игенченең дә ризыкны кибеттән сатып ала башлавы игенче хезмәтенең дәрәҗәсен бераз киметте.

Хәзер колхозларда төрле машиналар күбәйде. Техниканы сатып алу, машина-трактор парклары булдырып, аны саклау мөмкинлеге туды. Бу хәл игенчелекне тагын да алга җибәрергә зур йогынты ясады. Элек басу эшләре озакка сузыла, уңыш, өлешчә, югала иде. Техника үзе белән мәшәкать тә алып килде. Колхозында әзерлекле кадрлар булмаса, техника тиешле нәтиҗәне бирми. Авыл халкының техника белән идарә итүен камилләштерү җиңел түгел иде. Җитәкчеләр алдына яңа бурычлар куелды. Әле күптәнмени авылга кайткан беренче велосипед, мотоцикл, трактор, комбайн авыл кешеләрен таң калдыра иде?! Хәзер, космос дәверендә, нинди техника белән дә кешеләрне гаҗәпләндерә алмыйсың. Шулай булырга тиеш дип карый хәзер халык. Без моңа ирешүнең нәрсәләр бәрабәренә булганын яшь буынга аңлатырга тиеш! Революция, гражданнар сугышы, авылларны күмәкләштерү, фашизмны җиңү — бүгенге заманның куәтле техникасын булдыру өчен әнә нинди этаплар узарга туры килде. Бөек Ватан сугышында безнең «Искра» колхозына тупланган җиде авылдан 835 кеше катнашып, шуның 580 е һәлак булды. Авылга соңгы елларда газ, телефон, телевизорлар керү авыл халкының аңы, карашы үсүгә китерде. Ләкин алар, югарыда әйткәнемчә, үзеннән-үзе генә килмәде. Намуслы хезмәт, шуңа гадел түләү, кешенең һәм җирнең кадерен белү аркасында ирештек без моңа.

Колхоз эшендә авыр физик хезмәтне бәйрәмгә, күмәк өмәгә әйләндерә белү бик мөһим. Мәсәлән, печән өсте җитә. Ул эш безнең авылда элек-электән бәйрәм төсен ала. Кешеләр аерым хуҗалыкта чагында ук болынга матур киемнәрен киеп төшкәннәр. Самавырлар куеп, бергәләп чәй эчкәннәр. Чишмә суыннан әйрән ясаганнар, берсенә берсе булышырга кергәннәр, шунда яшьләр танышкан. Кемнең булдыклы, кемнең ялкау икәне күзгәдәге кебек күренгән. Колхозлар оешкач, печән өсте тагын да матур, дәртле итеп үткәрелә башлады. Безнең авылда болынга барлык атларны җигеп, печәнчеләрне төяп, гармуннар уйнап, җырулар җырлап төшәләр иде. Эш беткәч, инештә су коенып, чыр-чу килеп уйныйлар, сөенәләр, янә дә атларга утырып, караңгы төшкәч кенә авылга кайталар иде. Бу гадәт әле дә саклана. Тик хәзер техника белән эшләгәнлектән, бөтен бригаданың болынын бер тракторчы чабып бетерә, шуңа күрә печән өсте элекке шикелле үк тантаналы була алмый. Бәйрәм гадәтен тизлек алмаштыра бара. Уракка төшкәндә дә элек барлык авыл халкы күтәрелеп чыгып, басуда шалашлар корып, куна эшләү гадәте бар иде. Хәзер алай түгел, элек 200-300 кеше урган басуда хәзер ун-унбиш механизатор эшли. Кешеләрнең күбесе басу эшен күрми дә кала. Хезмәт авырлыгын тәненнән чыккан тир белән күңеленә сеңдермәгән кеше игеннең кыйммәтен тиешенчә бәяли алмый, әлбәттә. Борынгы матур гадәтләр урынына бүгенге көннең үз гадәтләрен уйлап чыгарырга туры килә.

Безнең колхозыбызда язгы чәчү һәм урып-җыю алдыннан игенчеләр көне үткә-

релә, аңа шул эштә катнашучы барлык кеше чакырыла. Сөйләшәбез, киңәшәбез, ел үзенчәлекләрен искә алабыз. Истәлек бүләкләре, кызыксындыру премияләре бирәбез. Ул көнне колхоз буенча бәйрәм игълан ителә, берәү дә эшкә чыкмый.

Урып-җыю башлана. Иген эшенең быелгы үзенчәлекләрен эш барышында сөйләшәбез. Кырларда булуның, кешеләр җыйналып торган җиргә килеп, халык сүзенә колак салуның үз хасияте бар. Халык үткенәйде, җитәкчелекнең яхшымы-яманмы эшләвен ул уен-көлке аша әйтеп бирә. Ә син шуларны мыегыңа урап, тиешле нәтиҗә ясый барасың. Эш вакытында туктап калган кешенең хәлен сорашмыйча, син фәлән дә, син төгән дип кычкырына башласаң — абруең беткәнне көт тә тор. Сүзең бармы — тыныч кына сөйлә, туктап торуның сәбәпләрен сораш — менә булырсың җитәкче. Кискен чараны, шунсыз мөмкин түгел икәнне халык аңларлык очракта гына кулланырга ярый.

Эш беткәннән соң йомгак ясала. Моны колхозчылар белергә, хәтта көтеп алырга тиеш. Коллектив хезмәттә коллектив акылдан файдалану ул — җитәкчегә зур ярдәм. Йомгак вакытында эшнең күләменә, сыйфатына карап бүләк тапшырыла.

Сүз дә юк, кешеләрнең күпчелеге колхозда тәрбияләнгән матур гадәтләргә риза булып эшли, әмма әле кайбер кешеләрдә ят гадәтләр дә туып тора. Тәҗрибәм юк чагында, көрәк белән бәрәңге алучыларның җирен карарга килдем. Бер кешенең җирендә киселгән бәрәңге сабаклары күренгәли. Ни өчен шулай? Әйбәтләбрәк карасам, ул бәрәңгенең берсен ала, берсенең сабагын гына кисеп бара икән. Хезмәт хакы бәрәңге казып алган мәйданнан чыгып түләнелә иде. Бу электән шулай килгән. Шуннан соң мәсьәләне идарәгә куеп, бәрәңге алучыларның хезмәт хакын казыган җир мәйданыннан түгел, казып алынган бәрәңге күләменнән түләүне керттек. Баягы начар гадәт шуның белән бетте. Бер очракта мин болай эшләдем. Печән җыючылар янына барып, уен-көлке белән аларны туктаттым да, бераз сөйләшеп торгач, бер тырманы алып, 26 хатын-кыз эшләгән кишәрлектә тырма сабы белән һәркайсының җирен үлчәп чыктым. Күңелемдә инде кемнеке күпме буласы билгеле иде, чөнки мин түбәннән үк бу эшне карап-барлап килдем. Шул 26 хатын-кызның берсенең җире ярты метрга кимрәк, икенчесенеке 20 сантиметрга кимрәк. 20 сантиметрны исәпкә кертмәдем, анысы ялгыш кына да булырга мөмкин, ә ярты метр булганын җентекләп тикшердем. Башта хатын-кызлардан: ничә тапкыр уздыгыз дип сорадым, өч тапкыр әйләндек инде, диделәр. Ягъни алты юл булган, алты юлга, яртышар метрдан, бу кеше өч метр җирне эшләмәгән. Димәк, ул 9 метр ара узып, 12 метрга акча алачак. Мин моңа рәсми төс биреп, шушында ук җыелыш ясап, ни өчен син иптәшләреңнән көләсең, ни өчен кеше көченнән файдаланырга чамалыйсың, дип, җитәкче хокукыннан тулысынча файдаландым. Бу очракта ничек әйтсәм дә, минем яклаучыларым бар, аларга минем башлап җибәрүем генә кирәк иде.

Күп кенә начар гадәтләр эчүчелек аркасында килеп чыга. Безнең колхозда хатын-кызлардан аракы эчүче юк. Ирләр арасында да ул гадәт соңгы елларда гына ишәя башлаган иде. Техника белән эшләүчеләрне сакларга тырышабыз. Бигрәк тә югары тизлек белән машина йөртүче шоферларны. Алар кеше йөртә. Безнең колхозда 45 машина бар. Шулар белән идарә итү өчен 81 шофер тотабыз. Иөк машиналарына ике шофер куябыз. Беренчесе — төп шофер, икенчесе йөк төяүче. Әгәр төп шоферның тегенди-мондый эше сизелсә, аны йөк төяүче алмаштыра. Безнең колхозда һәммә кеше үзе башкарган эш белән горурлана, эшен югалтасы килми. Эштән бушату иң кискен чара булып исәпләнә. Күптән түгел Галиәскәров Таһир, сыер савучыларны җәйләүгә алып төшкән чакта, аракы эчкән булган. Машинаны, рөхсәтсез икенче шоферга биреп торган. Шуның өчен аны, гаепле дип исәпләп, эшеннән бушаттык. Гаепнең күләмен билгеләү җитәкчедән гадел булуны таләп итә. Кыш көне шулай шәһәрдән соң гына кайтып килгәндә буран вакытында, күрәм, бер машина юл кырыена ауган. Утыннары чәчелгән. Карасам — Фазлыев Гомәр. Янына килдем, үзенең хәлен белештем. Ул-бу юк, әмма шофер курыккан, каушаган, мин дә очрагач, шикләнеп китте. Якынрак килеп сөйләштем (аракы исе килмиме?) Юк, эчүдән түгел. Күперне чыкканда, карлы юлдан таеп, читкә өстерәгән икән. Бу очракта да, мин, җитәкче кеше, машинаны ник түнтәрдең, син тегеләй, син болай, дип сүгенә башласам, ул рәнҗер иде. Мин: «Ярар, энем, машинаны торгызырга трактор җибәртермен, борчылма, юлда андый хәл була инде ул»,— дип китеп бардым. Иртәгесен механикка да әйттем, машинасын карарга булыштылар, үзенә бер төрле дә чара күрелмәде, кәгазь-мазар язылмады, икенче юлы карабрак йөр, яме,— дидек.

Урлашу кебек начар гадәтләрне бетерүдә дә җитәкченең роле зур. Шулай бер көнне районнан партоешма секретаре белән кайтып киләбез, мегезле эре терлекләр комплексыннан бер трактор чыкты, күңелгә салып куйдым. Кара-каршы узганда, трактор арбасында бер ак әйбер күренде. Узып киткәч, шикләнеп, кире борылдым, артыннан барып, тракторны туктаттым. Комплекска терлек азыгы ташучы Садриев

Фаил, котельныйда эшләүче Һидиятов Ринат трактордан төштеләр. «Арбада нәрсә ул?» — дип сорадым. «Цемент алган идек»,— диделәр. «Хәзер үк складка бушатыгыз, иртәгә сөйләшербез»,— дип әйттек тә китеп бардык. Илтеп бушатканнар. Иртәгесен аларны колхоз идарәсенең ачык утырышына чакырдык. Бригадирлар, белгечләр барысы да килде. Тыңладык тегеләрне, үзләрен гаепле санадылар. Без дә бу эшнең ярамаганлыгын әйттек. Колхоз милкен урлаучы дип икесен дә эшләреннән бушаттык. Түбән эш хакы ала торган урынга күчердек. Әгәр киләчәктә дә шушындый хәл кабатланса, колхоздан чыгарачагыбызны әйттек. Безнең колхозда урлау өчен бер төрле дә җирлек юк. Кирәкле бөтен әйбер, закон нигезендә, бирелә.

Тәртип бозу гадәттә аракы эчүдән килеп чыга. Безнең өстенлегебез шул: кешеләрне эчкечелектән саклап кала алдык.

## Төзелеш эшләрен алып бару

Авылларыбызның төзек булуын, таза йортлар салуыбызны әйткән идем. Терлекләр өчен колхозның үз акчасына комплекс төзелде, анда барлык эшләр дә уңай корылган. Техника паркыбыз иркен, җылы, кешеләр анда өс киемнәрен салып эшлиләр. Ләкин әле эшлисе эшләр дә күп. Йортларга газ кертүне төгәллисе бар. Юллар мәсьәләсе аннан да кыен. Акчабыз да җитәрлек, ун елдан бирле юл салучы оешма таба алмыйбыз. Авылларабызның урамнарын асфальтлау — алда торган кичектергесез эшебез.

Элек төзелеш белән аерым осталар шөгыльләнә иде. Кышлау дигән күрше авылда төзүче осталар күп иде. Кое казу да шул осталар өстендә иде. Мичне Ташчишмә авылының барлык кешесе дип әйтерлек чыгара белә, кирпечен дә үзләре сугалар иде.

Колхозлашканчы да, сугышка кадәрге чорда да төзелеш эшләре гел агачтан гына булды. Югары Көек авылы такта яру осталарына бик бай, безнең авылда да Зыя Шакиры белән Гыйлемхан Закиры гел такта ярдылар. Алар картая башлагач, авылның яшьләреннән Газизов Абдулла белән Шагалиев Зөлкәрнәйләрне такта яру осталыгына өйрәттек. Соңгы елларда бу эш техника кулына күчте. Төзелеш эшендә элек балта, ышкы, өтерге, борау кебек кораллар кулланыла иде. Тактаны махсус станда кулдан яралар, шомарталар иде. Сугыштан соңгы елларда бу һөнәрләр бетә барды. Авылга цемент, таш, тимер, тимер-бетон, толь, шифер, калай кайта башлады. Авыл халкы өй түбәләреннән саламны төшереп, такта ябарга кереште, тактадан калайга, шиферга күчте. Хәзер авылларда өй, лапас, мунча түбәләрендә дә салам бетте. Кирпеч салырга, таш өяргә, измә ясарга башта үзебез өйрәндек, аннан соң кешеләрне өйрәтә башладык.

Шул заманнардагы бер очрашу истә калган. Арча управлениесеннән безгә бер көнне партия оештыручысы Гыйматдинов Габбас Кыямович килде. Минем белән исәнләшкәннән соң, китапханәгез кайда, дип сорады. Алып бардым. Китапханәдә ул минем карточканы озаклап карады, аннары, нәрсәләр төзергә уйлыйсыз дип сорады. Мин сөйләп биргәч, планнарыгыз зур икән, диде. Нигә алай дип соравын аңладым: китапханәдән алып укыган китапларым арасында матур әдәбият белән бергә, төзелешкә караган кулланмалар да бар. «Бу иптәш колхозда төзелеш белән шөгыльләнү өчен иң әүвәл үзен әзерли икән»,— дигән нәтиҗә чыгарган. Үз фикерен райком секретаре Җиһаншин Госманга әйтеп киткән.

Югары оешмаларда эшләүчеләр, минемчә, беркайчан да ашыгыч нәтиҗә ясамаска тиешләр. Кил, кара, фикер тупла — аннары әйт сүзеңне. Менә бу гадел була. Кешеләр соңгы елларда бик катлауланды. Үзенә тәнкыйть сүзе әйткән кешедән үч алырга гына торалар. Бу очракта, Габбас Кыямовичның шул шаблоннан ерак торуы миңа ошады.

Авылда төзелеш эшләрен алып бару буенча күп нәрсә үзгәрде. Яшьләрне иң элек таш түшәү, силос чокырларының эчен тышлау, агач биналарга таштан нигез кую һөнәренә өйрәттек. Саман һәм кызыл кирпеч суга башладык. Иң әүвәл бута ташыннан кибет салдык. Матур чыкты. Төзелеш китабы кесәдә йөрде. Измә өчен күпме ком, күпме известь, цемент, су кирәклеген практикада эшләп карап белдек. Сыланган стеналарны көн саен иртән, кеше-кара килгәнче, үзем карап чыга торган идем. Никтер штукатуры тонлә коелып төшәр күк тоела. Шул рәвешле таш түшәргә, сыларга, буярга өйрәндек. Аннан түбәләргә калай кайтара башладык. Калайны ябу тәртибен Ташчишмә авылыннан Галиев Гарифҗан күрсәтте. Тәрәзә рамы ясау, тәрәзә кую эшләрен Галиев Һади, Саммасов Хәтәмнәрдән өйрәндек. Мич чыгаручы юк иде. Хәбибуллин Әхмәтша һәм Касыймов Мәрдән күрсәтеп калдырган кешеләрдән файдаландык. Кирпечтән, бута ташыннан абзарлар салырга гадәтләндек. Беренче

кирпечләрне ничек салырга икәнен район авыл хуҗалыгы бүлегенең төзү эшләре белгече Вәлишин Газиз өйрәтте. Эюпов Рафаэль һәм Госманов Равил җитәкчелегендә кирпеч салучы ике бригада, алардан соңрак Сәфәрҗанов Һидият җитәкчелегендә унар кешелек өч бригада төзедек. Алар икешәр катлы йортлар, кибетләр, клублар сала башлады.

Соңгы елларда район авыл хуҗалыгы бүлегендә төзүче-техник штаты булдырылды, белемле кешеләр килә башлады. Элегрәк, берәр каралты төзергә кирәк булса, колхоз идарәсендә карар чыгара идек тә, акча хәзерләгәч, урынын барып карый торган идек. Эшчеләр белән сөйләшеп, иңен-буен, биеклеген үлчәп, нинди материалдан эшләргә икәнен сөйләшәбез дә, иртәгесен эшне башлап та җибәрәбез. Хәзер шул ук каралтыны төзү өчен, бер ел алдан, проект төзү оешмасы билгеләнә. Колхоз председателе, фикерне рәсмиләштерү өчен, иң алдан район архитекторына, янгыннан саклаучы инспекторга, санитарга, авыл хуҗалыгы бүлегенең төзүче инженерына мөрәҗәгать итәргә тиеш. Комиссия төзелә. Су торбасы, электр кабеле, телефон кабеле ни хәлдә, аста казылма байлыклар юкмы?.. Әллә нинди оешмалардан белешмә җыйный башлыйсың. Проект институтларына чиратка языласың. Аннары гына, иң тиз дигәндә, бер ел проект төзиләр. Колхозга газ кертү буенча проект артыннан йөрүләрем үзе генә ни тора?! Комплекс өчен кирәкле заказ өч ел ятты. Хәзер колхозларның үзләрендә төзүче инженерлар бар, алар үзләре проектлый алалар, күргәзмә проектлар бик күп институтларда аунап ята, алар да шул типовой проектлардан гына күчерәләр югыйсә. Без үзебезнең колхозда силикат кирпечтән ике катлы кунак йорты һәм ашханә салдык. Буе — 24, иңе 12 метр. Кыш көне силикат кирпеч хәзерләп, кибетләрдән цемент алып, Мари республикасыннан агач кайтартып куйдык та, язга чыккач, эшкә тотындык. Эш башлаганда мин Казанда, больницада идем әле. Минем янга төзүчеләр бригадасы бригадиры белән председатель урынбасары килделәр. Больница коридорында булачак бинаның планын сыздык. Күпме материал китәчәген чутлап чыгардык. Яз көне төзү эшләрен башлап җибәрдек. Материал хәзерләүгә — бер кыш, төзүгә бер җәй китте. Ун ай дигәндә, бина әзер булды. Әгәр мин әйткән оешмалардан проект, подряд эзләсәк, бу бинаны төзүгә кимендә 5 ел вакыт кирәк булачак иде.

Шәһәрдә утырган кешеләр авылга ни кирәген белми, эшләре чамадан тыш озакка сузыла, төзелеп беткәннән соң да әле аны төзәтергә туры килә.

Безнең колхозда, башта әйтеп киткәнемчә, сыерлар өчен 800 баш терлеккә комплекс төзелде. Без аны сала башлаганчы, барлык уңайлыклары булган комплексларны Татарстаннан да, Мари АССРдан да карап чыктык. Аларның тулысы белән күчереп алырлыгын тапмадык. Проект ясаучы оешмалар әйтте, һәр каралтыны төзү билгеле күрсәтмәгә нигезләнә, һәр заказчының аерым тәкъдимен үтәп булмый, шуңа риза булсагыз, кул куясыз, булмаса — юк, диделәр. Риза булмасам да кул куйдым. «Безгә әле бу юлда бик күп йөрисе, күп кешеләр белән үпкәләшәсе бар икән, проектны яңабаштан үзгәртергә кирәк икән»,— дип уйладым.

Төзү өчен урын билгеләдек. Бу очракта иң әүвәл җил юнәлешен искә алдык. Ферма исе, җил искәндә, авылдан читкә китәргә тиеш. Яңгыр сулары да җыелып утырмасын, ул сулар авылга таба түгел, басуга таба аксын. Ул урын өстәвенә дүрт авылдан да йөреп эшләргә уңай булсын. Проект төзи башлагач та, мәйдан бүлеп куеп, аны кирпеч баганалар белән, рәшәткә белән әйләндереп алдык. Проект кайтты, аны бик җентекләп өйрәндек, үсеп утырырга тиешле агачларны койманың тышкы ягына утырттык. Бу — проектка керткән беренче үзгәртүебез. Агачлар рәшәткәнең эчке ягына утыртылса, эш вакытында төзүчеләр аны таптап бетерә. Проектта агачны, төзелеш беткәч кенә утырту каралган. Ә төзелешнең озак барасы безгә тәҗрибә буенча билгеле иде инде. Уебыз дөрескә чыкты, төзелеш беткәндә, агачларыбыз биек үк булып үсеп җиттеләр. Проектта рәшәткәләрне фигурасыз итеп, тимер-бетон баганаларга төзү каралган иде. Без баганаларны силикат кирпечтән матур итеп ясадык, рәшәткәләрен дә бизәдек. Капкаларын да үзгәртеп чыктык. Өченчесе: проектта эчке юллар вак таштан салыначак, 60 мең сумлык гади юл булачак иде. Без ул юлны ярты метрга күтәрттек, тимер-бетон плитә җәйдек, терлек азыклары өчен мәйданнар ясадык, барлыгы 380 мең сумга төште. Комплекстан тиресне кырга чыгару планлаштырылган иде. Аның өчен бетон мәйданнар ясап, анда сыек тиресне салам калдыклары белән кушып, компост хәленә китерү өчен, өстәмә рәвештә, 350 мең сумлык эш башкардык. Ягъни комплексның эчендәге юлларны һәртөрле һава шартларында да йөрерлек иттек. Торакка керә торган төштә бетон плитәләрнең астына тимер торбалар салып калдырдык. Су җыйналып тормасын өчен, аларның башларын кирпеч белән матурлап ныгытып куйдык. Һәр торакка, юл чатларына тимер баганалар утырттык. Сыерлар чыга торган кардаларны киртә белән генә әйләндереп алу каралган иде. Аны такта рәшәткәләр белән әйләндереп алдык. Сыерлар кыш көне кар

өстеннән сикереп, эчләрен имгәтмәсен өчен, рәшәткә очларын төреп чыктык. Сыерлар йөрү өчен ясалган кардаларның идәне балчык булырга тиеш иде. Без аны 20 сантиметр калынлыгындагы бетон белән түшәдек. Монысына да өстәмә чыгым кирәк булды.

Комплексны җылытучы котельный проектта күмергә көйләнгән иде. Казаннарның икесен ташып яга торган газга, берсен сыек ягулыкка, берсен күмергә көйләдек. Кайсы төр ягулык бетсә дә, шундук икенчесен җибәрү мөмкинлеге туды. Кешеләргә санитария пункты бер генә катлы итеп каралган иде. Ул бинаны, бөтенләй үзгәртеп, ике катлы итеп салдык: аста — юыну бүлмәсе, өске катына кухня, ашханә, медпункт, кибет, ял итү урыны, 100 кешелек тамаша залы эшләдек. Ул бинага проект төзегәндә, кешеләр тору өчен бүлмәләр рөхсәт ителми, дигәннәр иде. Ә без кайнар һәм салкын су үткәрдек. Тәүләгесез ике мәртәбә ашау, кирәк-яракны алу өчен кибет, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү бинасы, медицина ярдәме, ял бүлмәләре, кухня, ашханә булдырдык. Болар проектта каралмаган иде. Гаражны да ун берәмлеккә үзгәрттек. Терлек азыгы әзерли торган бинаны да зурайттык. Терлекчеләр иркендә эшләсеннәр, дидек. Шуның янына катнаш азык ясау өчен ОКЦ-15 дигән агрегат сатып алдык, проектта каралмаган тагын бер бина ясадык. 700 центнер ашлык сыярлык склад эшләдек. Терлек азыгы эшкәртү бинасының арт ягына, тупас азыклар кар астында ятмасын өчен, калайдан 18 метрга 50 метр итеп, янә бер бина эшләдек, анысы да проектта каралмаган иде. Шуның янына ук АВМ агрегаты куеп, аңа да бина булдырдык. Бу бина 150 мең сумга планлаштырылган иде, без аны җиңеләйтеп, 15 мең сумга җиткердек. Печән оны склады проектта бөтенләй юк иде. Проектта кирпечтән салырга дип планлаштырылган туалет бина-ларын тактадан эшләдек. Силос манарасы урынына, проект төзегәндә үк, силос, сенаж саклагычлар ясадык... Кыскасы, инженерлар төзеп биргән проектны колхоз тормышына яраклаштырдык. Моның өчен Казаннан, Госбанктан килеп, миңа 400 сум штраф салдылар. Икенче елны яңадан бер ревизор килеп, шул ук оешмадан тикшереп, акча проекттагыча тотылмаган, артык тотылган дип, миңа һәм колхозга берничә мең сум штраф булачагын әйтеп китте. Безгә ярдәм иткән «Татколхозстрой» оешмасының юллар төзүче ПМК җитәкчеләре дә штрафка тартылудан куркып калдылар. Шуннан үзем Казанның Госбанк җитәкчеләренә кереп, мәсьәләне аңлатып бирдем. Бүлек начальнигы актны укып чыкты. «Ник тәртипне боздыгыз? Бозгансыз икән инде, җавап бирүдән дә курыкмагыз, җавабыгыз — штраф»,— диде. Шуннан мин салкын кан белән, СССР Верховный Советы депутаты булуымнан да файдаланып: «Нишләп колхозның үз акчасын үз кирәгенә тотарга рөхсәт итмисез?» — дидем. Бүлек начальнигының күзе шар булды: «Ничек инде ул үз акчагыз?» — ди. «Менә шулай, мин әйтәм, без дәүләттән 25 ел инде ссуда алмыйбыз, барлык төзелешләр дә үз акчабызга салына, әле дә бер ярым миллион акчабыз бар»,— дим. Күршесендә утыручы комиссия члennарыннан: «Нәрсә, безнең республикада үз акчасына төзелеш алып баручы, ягъни өч миллион сумлык комплекс төзердәй хуҗалык бармыни?» — дип сорады. Белештеләр, барлыгына ышангач: «Бу хәл мәсьәләне үзгәртә, ярар, штрафсыз, кисәтү белән генә калдырабыз»,— диделәр.

Партиянең XXVII съездында Михаил Сергеевич Горбачев ясаган докладны мин шатланып укыдым. Партия эшне хәзер яңача куя, урындагы оешмаларга, колхоз-совхозларга мөстәкыйльлек бирә. Әйтә башлагач, эшебез хакында әйтеп бетерим. Комплекс төзелеп беткәч, безнең колхозга уңайлыкларны өйрәнергә, республикабызның зур җитәкчеләре, РАПО начальниклары, зоотехниклар, баш агрономнар, күрше районнарның колхоз председательләре килде, бөтенсоюз семинары уздырылды. Шушы комплексның уңайлыкларын исәпкә алып, проект институтларына да аны өйрәнергә, файдаланырга кушылды. «Искра» колхозы тәҗрибәсен телевизион фильмга төшереп, илебез экраннарында күрсәттеләр. Шуны карап утырганда, күңелдән уй уза, аны төзү өчен күпме кыенлык күрдек, күпме сәламәтлекне югалттык, авылдашларым күпме көч сарыф итте. Рухи яктан кыйбатка төште безгә комплекс. Әмма ул безгә яңадан-яңа һөнәр ияләрен җитештерде. Хәзер безнең һәрбер эш өчен үз осталарыбыз бар. Мин алар белән горурланам.

**Индус Таһиров,**
тарих фәннәре докторы, профессор

# КЕМ УЛ СОЛТАНГАЛИЕВ?

Кем соң ул Солтангалиев, нәрсә ул солтангалиевчелек? Әле күптән түгел генә бу сорауга җавап бик ансат иде. «Солтангалиевчелек — ул гомуммилли буржуаз контрреволюцион хәрәкәтнең пролетариат диктатурасы шартларында Октябрьга каршы, ...ул биргән легаль мөмкинлекләрдән файдаланып көрәшүне үзенә максат итеп куйган яшерен бер отряды...»— дип язган Г. Касыймов 1930 елда чыккан «Солтангалиевчелек һәм аның тарихи тамырлары» исемле китабында.

Солтангалиевчелекнең тарихи тамырлары итеп туранизм, пантюркизм һәм панисламизм күрсәтелә. Әлеге китап беренче битеннән алып соңгысына кадәр шушы «тарихи тамырлар»ны тасвирлауга, М. Солтангалиев һәм аның көрәштәшләре иң куркыныч милләтче булганнар дип раслауга, укучыны шуңа инандыруга багышланган. 1929—1930 елларда солтангалиевчелеккә багышланган мәкаләләр, китаплар рус һәм татар телләрендә шактый дөнья күргән. Аларда М. Солтангалиев исеме милләтчелек синонимына әверелдерелгән. Ул гына да түгел, Донбасс шахталарында, Ленинград судно төзү трестындагы корткычлыклар, Кытай-Көнчыгыш тимер юлында совет гражданнарын хыянәтчел үтерүләр, кулакларның дәүләткә икмәк тапшыру эшләрен өзәргә маташулары, аларның шәһәр халкын ачлыктан интектерергә ниятләнүләре,— имеш, болар барысы да, ничек кенә булса да, солтангалиевчелеккә дә барып тоташа итеп тасвирлана. Газета-журнал битләре әнә шундый мәкаләләр белән тула. «Красная Татария» газетасының 13 октябрь санында: «Солтангалиевчеләр, командованиесе Лондонда урнашкан һәм бөтендөнья хезмәт ияләренә империалистик изү китерүче армиянең состав өлеше, Чан-Кай-Ши, Мисыр партиясе «Вафд», Кемаль Төркиясе, Риза хан диктатурасы — болар бар да солтангалиевчелек белән чагыштырмалы төшенчәләр... Солтангалиевчеләр Англия Генераль штабы заданиесе белән эшләүчеләр, алар совет строен эчтән шартлатучылар»,— дип игълан ителә. Кыскасы, ул вакытта нинди генә корткычлыклар, тайпылулар, хаталар булмасын, болар бар да солтангалиевчеләр эше итеп күрсәтелә.

Чыннан да, кем соң ул бөтен дөньяга шаулаган шәхес? Нигә соң әлегә кадәр аның белән кызыксыну кимеми?

Мирсәет Хәйдәргали улы Солтангалиев Уфа губернасының шул ук исемдәге өязендә, волость үзәге булган татар авылы Кырмыскалыда 1892 елда укытучы гаиләсендә дөньяга килә. Башлангыч белемне авыл мәктәбендә ала. Балачактан ук дөньяны танып белүгә омтылган, кызыксынучан табигатьле булып үсә. Татар халкының ярлылыгын, хокуксызлыгын, милли һәм дини изелүдән җәфа чигүен көндәлек тормышта ачык күрә ул. Җирсезлектән, мохтаҗлыктан аптыраган, йөдәгән крестьяннарның алтын прискаларына, завод-фабрикаларга агылуына да шаһит булган Мирсәет.

Белемгә омтылу Мирсәетне Казанга китерә. Ул монда Татар укытучылар мәктәбендә укый. Аның Казанда яшәгән чагы турында әлегә мәгълүматлар бик аз. Ләкин аның Казанда беренче революцион чыныгу мәктәбе үтүе ачык билгеле. Беренче буржуаз-демократик революция дулкыны аны ирек өчен көрәшүчеләр сафына бастыра. Ул укытучы, китапханәче булып эшли, көндәлек татар матбугатында языша башлый һәм үзен талантлы публицист итеп таныта. Солтангалиев мөстәкыйль рәвештә белемен күтәрү белән дә шөгыльләнә, үзен мөселман дөньясын шактый яхшы белүчеләрдән саный. Күрәсең, бу — хакыйкатьтән ерак булмаган, югыйсә аны һич тә өнәмәгән Карл Грасис: «Солтангалиев Көнчыгыш дөньясын яхшы белә иде һәм бу өлкәдә күп мәгълүматлы кеше иде»,— дип әйтмәгән булыр иде.

Бишенче елгы революция җиңелгәннән соң, күп кенә татар революционерлары, Бакуга китеп, андагы нефть промыселларында эшләгән берничә мең милләттәше ара-

сына барып сыена. Алар арасында революцион агитация һәм агарту эшен җәелдереп җибәрә. Мирсәет тә Бакуга килә. Ул монда татарлар белән генә түгел, азәрбайҗаннар, руслар белән дә якыннан аралаша. Бакуда да Мирсәет укытучылык эшен ташламый, китапханәче булып та эшли. Биредә ул сыйнфый көрәшнең мөселман массаларына тирән үтеп кергәнлегенә тәмам ышана. Беренче буржуаз-демократик революция елларында Бакуда мөселман эшчеләрен берләштергән «Гөммәт» һәм «Әдәләт» исемле оешмалар барлыкка килә. Февраль революциясеннән соң татар эшчеләре «Берлек» исемле социаль-демократик оешмага берләшәләр. Актив оештыручысы Хәнәфи Терегулов сүзләренә карагында, әлеге оешмага йөз иллегә якын кеше кергән. Татар эшчеләре алдында татар телендә Нариман Нариманов һәм башка большевиклар чыгыш ясаган. Бакуда, моннан тыш «Идел буе татарлары советы» җәмгыяте дә була. Аңа Сәнгатулла Ибраһимов җитәкчелек иткән. Бу ике оешма арасында кискен бәрелешләр дә булып ала. Әмма бу оешмалар икесе дә үз тирәсенә милләттәшләрен туплыйлар, аларның политик аңлылыгын үстерүгә ярдәм итәләр. Әлбәттә, М. Солтангалиев тә моннан читтә булмаган. Ул инде Бакуда чагында ук, нигездә революционер-большевик булып җитлегә. Нариман Наримановның аңа биргән югары бәясе һич тә юкка түгелдер.

Мирсәет Солтангалиевнең күз алдында һәм аның катнашында Бакуда революцион хәрәкәт колач җәя бара. Февраль революциясеннән соң ул Бакудагы көндәлек мөселман матбугатында актив чыгыш ясый. Азәрбайҗан милли азатлык хәрәкәте эшлеклеләре Рәсүл-задә, Гомәр Фаик, Талип-задә, Касыйм-задә һәм башкалар белән тыгыз элемтәдә эшли. Шул ук вакытта аның мәкаләләре Гаяз Исхакый редакторлыгында чыккан «Сүз», «Ил», Оренбургта Фатих Кәрими редакцияләгән «Вакыт», Уфадагы «Тормыш» газеталарында да еш басылган. Заманында ул, әлбәттә, милләтчеләрдән һәм милләтчелектән дә читтә йөрмәгән. Исламчылык, төрекчелек чирләре белән дә авырып алгандыр, бәлки. Ләкин, М. Солтангалиев 1917 елдан бирле большевиклар партиясе члены, татар халкының батыр улы, ленинчы Мулланур Вахитов белән берлектә Мөселман социалистик комитетын оештыручыларның берсе була. Ул чын күңеленнән, ихлас ышанып, социалистик революциянең җиңүенә бөтен көчен куя, армый-талмый эшче-солдат арасында революцион агитация эше алып бара һәм шуңа күрә дә аларның мәхәббәтен яулый, ышанычын казана. Аның бу дәвердә язган барлык мәкаләләре татарларда сыйнфый көрәш мәсьәләләренә багышланган һәм татарлар бердәм халык, аларда берничди сыйныфлар да юк дигән уйдырмаларны фаш итүгә юнәлдерелгән була. Шул ук вакытта үзен милләт дошманы итеп күрсәтергә тырышучыларга болай дип яза: «Тигезсезләр арасында ике исем бар: аларның берсе — «татар», икенчесе — «мөселман». Болар иң күп изелүчеләр, иң күп тапталучылар. Һичкем, һичнәрсә моны минем күңелемнән тартып алачак түгел, ни генә булса да, ул бетәчәк түгел.— Үзем беткәндә генә, үзем белән сүнәчәк». Шунысы кызык: Солтангалиевне Октябрь революциясенә кадәр ук милләтен саткан, большевикларга койрык болгаучы кеше итеп күрсәтергә тырышулар була. Мондый ялага ул болай дип җавап биргән: «...Алар янында мин тәлинкә ялар өчен йөрмим. Мине күңелемә чыкмаслык булып кереп урнашкан халкыма булган мәхәббәт уты өстерәп йөртә. Мин анда милләтем сатар өчен, аның «канын эчәр өчен» йөрмим, юк, юк!» («Кояш», 1917, 1193 сан).

Февраль революциясеннән соң Солтангалиев Бакуда озак тормый. Май аенда Мәскәүдә булып узган Бөтенроссия мөселман съездына киткән җиреннән ул Бакуга кире әйләнеп кайтмаган булса кирәк. Ул милли азатлык һәм гомум революцион хәрәкәткә чума, съездда сайланган Бөтенроссия мөселман советында эшли.

Солтангалиев Казанга 1917 елның июль аенда кайта, большевиклар партиясе сафына баса. Казанда булып узган шау-шулы мөселман съездларында актив катнаша. Нәкъ шул вакытта ул Мулланур Вахитов белән якыная һәм аның якын көрәштәшенә әверелә.

Казанда Октябрь революциясе көннәрендә ул һәрвакыт Мулланур Вахитов белән бергә була. Солдатларны һәм эшчеләрне оештыруга шактый зур өлеш кертә. Соңыннан ул Казандагы Октябрь көннәренә югары бәя бирә, революциядә татар эшче һәм солдатларының уйнаган ролен һәрвакыт тәкъдир итә. Бу фактка аеруча басым ясыйсы килә, чөнки соңрак аны, имеш, татарлар революциягә өлеш кертмәде, анда катнашмадылар, дип әйтүдә гаеплиләр.

М. Вахитов һәлак булганнан соң ул үзен күренекле революционерның эшен дәвам итүче итеп саный. Ул М. Вахитов урынына Үзәк мөселман комиссариаты председателе һәм Үзәк мөселман хәрби коллегиясе председателе итеп билгеләнә. Соңрак Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк бюросы председателе итеп сайлана, шуның өстенә Федераль җир эшләре комитеты председателе итеп тә билгеләнә. Бу уңайдан аның М. Вахитов исеменә һәм эшенә турылыклы булуын, бөек революционерның якты истәлегенә тап төшерүчеләргә каршы көрәш алып баруын истән чыгармаска кирәк. М. Вахитов һәлак булуга ук, аның турында дошманнары тарафыннан төрле имеш-мимешләр таратыла. 1919 елда Көнчыгыш халыклары коммунистик оешма-

ларының I съездында И. Ш. Рәхмәтуллин М. Вахитов коммунист түгел иде, Октябрь революциясендә катнашмады, мөселман коммунистик оешмаларына һәрвакыт каршы торды, дип сөйли. Моңа дәлилләрем күп дисә дә, үзе бер дәлил дә китерә алмый. Аңа каршы чыгыш ясаучы И. Фирдәвес[1] һәм М. Солтангалиев Мулланурның революциягә керткән өлеше турында сөйләгәндә: «Әгәр дә Мулланур Вахитов булмаган булса, бу эшләр, шул исәптән монда сөйләнгән докладлар да, берсе дә булмас иде»,— дип Рәхмәтуллинның һәм аның иярченнәренең авызын томалыйлар. 1919 елда Казанда шундый оятсыз уйдырмаларга җавап итеп ялкынлы революционерның көрәштәшләре «Шәрыкның бөек революционеры» исемле истәлекләр җыентыгы чыгаралар. Шул ук вакытта М. Вахитовка һәйкәл кую кампаниясе җәелдереп җибәрелә, махсус комиссия төзелә. Ләкин Г. Шәмгулов бу комиссияне үз белдеге белән тарата. Бу хәбәрне алуга, Мәскәүдә эшләүче М. Солтангалиев партиянең Үзәк Комитеты аша комиссияне яңадан торгызырга рөхсәт ала һәм шул турыда урыннарга телеграмма җибәрә. 1920 елда вакытлыча куелган һәм соңрак «үзеннән-үзе» юкка чыккан бюстны исәпкә алмаганда, чын һәйкәл Мулланур Вахитовның 100 еллыгын билгеләгән көннәрдә генә ачылды. Шулай булса да, бу игелекле эшнең гамәлгә ашуында М. Солтангалиевнең өлешен, ул куйган хезмәтләрне танымау дөрес булмас иде.

Әйе, М. Солтангалиев М. Вахитовтан соң гомерен ул башлаган эшләрне дәвам итүгә багышлый. Ул үзенең эшчәнлеген ике юнәлештә алып бара: Россиядәге мөселман халыкларының милли яшәешен совет нигезендә үзгәртеп кору һәм Көнчыгыш халыкларын халыкара революцион процесска тарту, андагы империализм хакимлеген бетерү өчен көрәш. Билгеле ки, бу һәр ике юнәлешнең күптармаклы икәнлеген истән чыгармаска кирәк. Шуңа күрә илдәге татарларга һәм, гомумән, мөселман халыкларына кагылышлы кайсы гына зур масштаблы вакыйгаларны алмыйк, аларның һәрберсендә диярлек М. Солтангалиевнең катнашы барлыгын күрербез. Гражданнар сугышы башлангач М. Солтангалиев М. Вахитов, Ш. Усманов, М. Конов, Я. Чанышев, Ю. Ибраһимов һәм башка бик күп татар революционерлары, хәрби эшлеклеләре белән берлектә мөселман халыкларыннан Кызыл Армия өчен милли частьлар төзүгә зур өлеш кертә. Үзәк мөселман хәрби коллегиясе җитәкчесе буларак та, 2 нче Армиянең Реввоенсоветы члены буларак та ул бу юнәлештә актив эш алып бара. Үзәк мөселман хәрби комиссариатының эшен бәяләп, Солтангалиев болай язган: «Аның тырышлыгы аркасында 1 нче, 2 нче Аерым татар укчы бригадалары, ике Аерым укчы полк һәм берничә Аерым батальон төзелә. Казандагы Аерым запас батальон гына да бер ел эчендә Төркстан фронтына җитмешкә якын маршевый рота җибәрде» (Султангалиев М. Татарская автономная республика.— «Жизнь национальностей», 1923, 1 сан, 31 б.).

Мирсәет Солтангалиев татар хәрби эшлеклеләрен хәзерләүдән тыш, башка төрки халыклардан да хәрби кадрлар әзерләүгә зур игътибар бирә. Ул Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының үзәк бюросы исеменнән казахлардан Җиксәнбаевны, Бөкәйхановны, осетин Салакаевны һәм башкаларны Генераль штаб академиясенә кабул итүне сорап югары хәрби органнарга мөрәҗәгать итә[2]. М. Солтангалиевнең төрки халыклардан хәрби эшлеклеләр хәзерләүгә куйган хезмәте заманында башка кешеләр активына языла килде. 1920 елның 19 сентябрендә Мәскәүгә М. Солтангалиев һәм РВСР председателе урынбасары Э. М. Склянский исеменә Казан һәм Мәскәү мөселман кавалерия курслары исеменнән телеграмма җибәрелү үзе үк күп нәрсә хакында сөйли. Нәбиулла Вахитов һәм И. Борындыков кул куйган телеграммага түбәндәге сүзләр язылган: «Без, Татреспублика хезмәт ияләре һәм хезмәт сөючән Дагстан хезмәт ияләре, бер тавыштан игълан итәбез, безнең лозунг — пролетариатның тулы җиңүенә кадәр алга, артка юл — тик безнең мәетләребез аша гына»[3]. Мондый телеграммаларның М. Солтангалиевкә адресланган булуы аның хәрби һәм милли дәүләтчелек төзүдәге хезмәтләрен, ролен тану дигән сүз.

Тарих фәнендә Татар-Башкорт республикасы төзүнең барлык аспектлары да әлегәчә тәфсилләп тикшерелмәгән. Бу катлаулы мәсьәләне кайбер чит ил галимнәре йә тамырдан дөрес булмаганча яктырталар, яисә «татар милләтчеләренең авантюрасы» дип кенә карыйлар. Бүгенге көндә мондый карашлар беркемне дә канәгатьләндерә алмый, әлбәттә.

Билгеле булганча, ике тугандаш халыкның уртак республикасын булдыруга Мулланур Вахитов зур тырышлык куя. Бу изге омтылышның нигезендә ике халыкның гасырлардан килгән дуслыгы, тел, дин, гореф-гадәт уртаклыгы яткан. Шунлыктан уртак дәүләтчелек идеясе ике халык арасында да шактый таралган булган. Шуның нәтиҗәсе буларак, 1918 елның мартында Совет хөкүмәте тарафыннан чыгарылган «Татар-башкорт республикасы турындагы положение» дөньяга килә. Әмма уртак республика үе белән

[1] И. Фирдәвес — егерменче елларда Кырым АССР Юстиция Халык Комиссариаты комиссары.

[2] Марксизм-ленинизм институты каршындагы үзәк партия архивы, 583 ф., 30 эш, 73, 110 бб. (алга таба — ЦПА ИМЛ).

[3] ЦПА ИМЛ, 583 ф., 33 эш, 84 б.

янган татар-башкорт эшлеклеләре шул ук вакытта башкортлар арасында аерым автономия идеяләренең дә таралыш ала барганын тиешле рәвештә искә алмаганнар, күрәсең.

«Татар-башкорт республикасы турындагы положение» Уфада узган Милләт мәҗлесе карарлары нигезендә 1918 елның мартында Казанда II Бөтенроссия мөселман хәрбиләренең съездында игълан ителергә тиешле Идел-Урал штатларына каршы юнәлдерелгән була. Кем белә, бәлки Татар-башкорт республикасы (ТБР) проекты әйтеп үтелгән Идел-Урал штатларын «мәтәлдерү» өчен генә дөньяга тугандыр. Мәкерле Сталинның коточкыч кара эшләре — мәгълүм нәрсә. Бу проект-положение дә аның җитәкчелегендәге Милләтләр эшләре буенча Халык Комиссариаты аша үткән. М. Вахитов та, М. Солтангалиев тә, кызганычка каршы, аңа нык ышанганнар. Татар-башкорт республикасы каршында бер киртә артыннан икенчесе туып кына торган. 1919 елда Колчак гаскәрләре составындагы башкорт хәрби частьләре Советлар ягына күчкәннән соң Халык Комиссарлары Советы белән килешү нигезендә Башкортстан АССР төзелә. Аның составына «Кече башкортстан» дип йөртелгән җирләр кергән, башкаласы итеп Стәрлетамак игълан ителгән. Халкының шактый өлешен татарлар тәшкил иткән Уфа губернасы Башкортстан АССР составына кермәгән. Шунлыктан Совет хөкүмәте исеменнән БАССР хөкүмәте белән сөйләшүләрдә катнашкан М. Солтангалиев һәм башка бик күпләр гамәлгә ашкан Башкорт автономияле республикасы белән беррәттән әле һаман ТБР төзергә мөмкин дип санаганнар. БАССР Халык Комиссарлары Советы председателе З. Вәлиди принципта элеккеге Казан һәм Уфа губерналары территориясендә республика төзүгә каршы чыкмаган, аны тик «Татар-башкорт» дип түгел, ә бәлки «Татарстан республикасы» дип атарга кирәклеген алга сөргән һәм Совет хөкүмәтенә шул хакта телеграмма да җибәргән.

Татар-башкорт республикасы төзү мәсьәләсе Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының II съездында карала. Съезд ачылу алдыннан, 1919 елның 21 ноябрендә РКП(б) Үзәк Комитетында В. И. Ленин җитәкчелегендә киңәшмә уздырыла. Икенче көнне Метрополь кунакханәсендә Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының II съезды ачыла. Аның эшендә 80 делегат катнаша. Ун көн дәвам иткән съездга В. И. Ленин да килә, делегатларны һәм кунакларны канатландырган ялкынлы нотык сөйли. А. И. Микоянның әйтүенә караганда, съезд Көнчыгышның милли эшлеклеләре өчен яхшы мәктәп була (Микоян А. Мысли и воспоминания о Ленине. М., 1970, 49 б.). Съездда М. Солтангалиев Татар-Башкорт республикасы турында бай мәгълүматлы һәм тирән эчтәлекле доклад белән чыгыш ясый. Әлбәттә, докладның йомшак яклары да булган. Ләкин шунысы ачык, М. Солтангалиев 1919 елда төзелгән Башкортстан АССРны юк итәргә өндәми. Ул, әгәр дә теләге булса, бу республика да ТБР составына керә алачак ди. Өстәмә докладны И. Борындыков ясый. Аның чыгышы ТБРның территориясен ачыклауга багышланган була. Ләкин ике доклад та тиешле югарылыкта булмыйлар. Чөнки, беренчедән, тәҗрибә җитешми, икенчедән беркемнең интересларына кагылмаган принципларны табу, күрәсең, мөмкин дә булмагандыр. Шуңа күрә докладларны уңнан да, сулдан да тәнкыйтьлиләр. Кече Башкортстан вәкилләре М. Һ. Таһиров һәм И. Ш. Рәхмәтуллин һәрбер халыкның үзенә аерым республика кирәклеген алга сөрәләр. Г. Шәмигулов, азәрбайҗан коммунистлары Исрафилбәков һәм Бунният-задә Сардаров кебек милли нигилистлар исә республикалар бөтенләйгә кирәк түгел диләр. Г. Ибраһимов М. Солтангалиев докладын тыңлаганнан соң мәсьәләне өлгергән дип санап булмый, «чөнки анда республика игълан итәрлек какшамаслык дөрес нигез бирелмәде» ди. Ул моңа халыкларның теләген, территория составын, экономик хәлне кертүен әйтеп, «докладчы андый нигезләрне күрсәтә алмады» дип билгеләп үтә. Ә И. Борындыков докладын ул бары тик географик картага гына нигезләнгән һәм «монысын алабыз, монысын бирәбезләрдән генә тора» дип бәяли. Съездда Н. Нариманов та кызыклы чыгыш ясый. Принципта ул да «Гөммәт» вәкиле Исрафилбәков кебек милли республикаларны кирәк түгел дип саный. Мондый республикаларны төзү, аның фикеренчә, политик чара гына, шунлыктан аларны игълан иткәндә, республикалар башында Солтангалиев һәм Фирдәвес кебек коммунистлар торырга тиеш, дип саный ул. Н. Нариманов татар-башкорт мөнәсәбәтләре мәсьәләсенә бөтенләй кагылмый. Солтангалиевнең докладын С. Сәетгалиевкә дә ошап бетми. Ул докладчыны меньшевиклыкта гаепли.

Ун көн дәвам иткән съездда фикер алышуның нәтиҗәсе түбәндәгечә була: Татар-Башкорт республикасын тормышка ашырырга кирәклеген таныган резолюция 48 тавыш җыя, 18 кеше каршы тавыш бирә.

1919 елның 13 декабрендә РКП(Б) ҮК Политбюросы бу мәсьәләне төрле яктан тикшергәннән соң андый республика төземәскә һәм бу хакта пропаганда алып бармаска дигән карар кабул итә. Шулай итеп ТБР мәсьәләсе көн тәртибеннән төшерелә.

Партиянең 1919 елның декабрендә булып узган VIII конференциясендә М. Солтангалиев делегатларны Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының II съезды исеменнән котлый. «Мөселман халыкларының коммунистлары үз укытучылары — рус комму-

нистлары кулыннан алган кызыл байракны Көнчыгышка китереп җиткерерләр һәм моңарчы йоклаган Көнчыгышны уятырлар»,— ди ул (Микоян А. Мысли и воспоминания о Ленине. М., 1970, 53 б.).

Көнчыгыштагы революцион процесс М. Солтангалиев һәм аның көрәштәшләрен аеруча кызыксындырган мәсьәлә була. Алар хәтта Совет хөкүмәте составында Шәрык илләре белән элемтәләр өчен аерым тышкы эшләр комиссариаты оештырырга кирәк дигән тәкъдим белән чыгалар. Бу хакта РКП(б) Үзәк Комитеты исеменә җибәрелгән гаризада түбәндәгеләр язылган: «...Совет хөкүмәтенең эшлекле эчке һәм тышкы политикасы, шиксез, колониаль Шәрыкны халыкара империализмга каршы күтәрелүенә китерер иде һәм шуның белән дөнья социалистик революциясен өчтән икегә булмаса да, яртылаш хәл итәр иде. Шәрыкта моның өчен тиешле туфрак әзер һәм үзен сөрүчесен генә көтә». Бу документта Совет хөкүмәтенең Көнчыгышта алып бара торган политикасы тиешле югарылыкта түгел, дип күрсәтелә һәм махсус комиссариат төзергә кирәклеге алга сөрелә. Комиссариатка җитәкче итеп хөкүмәт составында эшләгән абруйлы кеше куелырга тиеш дигән фикер үткәрелә. «Безнең тирән ышануыбызча, андый кеше Милләтләр эше буенча Халык Комиссары иптәш Сталин була алыр иде. Ул үзенең ачык, туры һәм тәвәккәл политикасы белән Советлар Россиясендәге барлык милләтләрнең киң халык массаларын үзенә җәлеп итте һәм алар арасында зур авторитет яулады». Бу хатка кул куйган М. Солтангалиев, С. Сәетгалиев, Ш. Измайлов, А. Мөхетдинов, әгәр дә шушы «туры һәм гадел политика» алып баручы кеше тарафыннан тудырылган система нәтиҗәсендә җәзаланачакларын белсәләр, болай язмаган булырлар иде, әлбәттә. Аянычка каршы, алар һәм башка бик күпләр шул вакытта ук Сталинга бик нык ышанган булалар...

Солтангалиев Көнчыгышның социализм өчен әзер булмаганлыгын яхшы күрә. Шунлыктан ул анда бүгеннән үк социализм төзүне якындагы максат итеп карамый. Социализм төзү өчен анда башлап нигез булдырырга кирәк, дип саный. Ул нигезнең төп асылы, аныңча милли бәйсезлек яулау була. Милли бәйсезлек яулаганнан соң социализм өчен көрәшнең төп коралы,— бүгенге терминологияне кулланып әйтсәк, милли демократия дәүләте. Бу нәтиҗәгә Солтангалиев Россиядәге милли азатлык хәрәкәтен өйрәнү нигезендә килә. Империализм көчләренә каршы тору, аларны Көнчыгыштан кууның алшартларын ул милли тупланганлыкта, Көнчыгыш халыкларының берләшүендә, аларның Советлар Россиясенә таянуында күрә. Әлбәттә, бу фикерләр ленинизм тәгълиматына һичничек тә каршы килмиләр, алар аны конкретлаштыралар һәм тулыландыралар гына. Хәер, монда фантазиягә бирелүнең һич тә кирәге юк. Ләкин шунысы ачык: Сталин мондый фикерләрнең ниндидер бер татардан чыгуына риза була алмаган. Татар эшлеклеләренең Көнчыгыштагы революцион хәрәкәттәге бәхәссез лидерлыгы да аны чыгырыннан чыгарган. Чөнки ул аларны яратмаган һәм аларга каршы мөмкин булган этлекнең барысын да эшләгән. Ул гомере буе Көнчыгыш халыкларының дусты булып күренергә тырышса да, нигездә аның эшчәнлеге белән капма-каршы фикер җитәкчелек иткән. Бу турыда атаклы тәрҗемәче Семен Липкин «Огонек» журналының быелгы 2 санында басылып чыккан истәлекләрендә ачык әйткән. Аның сүзләренә караганда, Сталин иң зур афәтне татарлардан күргән, «иң начарлары татарлар» дип санаган. Имеш, татарлар үзләре турында әллә нәрсәләр уйлыйлар, революциягә кадәрге стажлы большевиклары белән мактаналар. С. Липкин фикеренчә, Сталин үзенең геноцид политикасын юкка гына татарлардан башламый.

Көнчыгыш халыкларын революцион хәрәкәткә тарту җәһәтеннән караганда, егерменче еллар башында М. Солтангалиев һәм аның тарафдарларының төп игътибарын Төркия җәлеп иткән. Чөнки бу еллар Төркиядә революция башланып, монархия урынына республика туып килгән еллар була. Шул ук вакытта Беренче Бөтендөнья сугышы елларында Россиягә әсир төшкән төрек хәрбиләре арасында да җанлану башлана. Патша хөкүмәте бәреп төшерелгәннән соң аларның революцион оешмалары барлыкка килә. Ә инде Октябрь революциясе җиңгәч, коммунистик оешмалар да үсеп чыга. Төрек хәрби әсирләре арасында революцион эшне җәелдереп җибәрүдә Мөселман социалистик комитеты һәм Милләтләр комиссариаты составындагы Эчке Россия мөселманнары эшләре буенча комиссариатның роле зур була.

Тарихи әдәбиятта бу мәсьәлә дә әлегә тиешенчә яктыртылмаган. Шунысы ачык, Көнчыгыш халыкларын революцион көрәшкә тартуга Мулланур Вахитов зур әһәмият биргән. Төрек коммунистик оешмаларының барлыкка килүендә дә аның турыдан-туры катнашы бар. М. Солтангалиев исә аның иң якын теләктәшләреннән берсе була. М. Вахитов фаҗигале рәвештә һәлак булганнан соң, аның эшен дәвам иттерү Солтангалиевнең максатына әверелә. Төрек коммунистлар партиясенә нигез салган Мостафа Сөбхи дә берара Үзәк Мөселман комиссариатында эшли. Аның редакциясендә чыккан «Ени дөнья» газетасы һәм ул үзе дә комиссариат һәм М. Солтангалиевнең эшлекле ярдәмен тоеп яшиләр. Мостафа Сөбхи Үзәк Мөселман комиссариатының гыйльми кол-

легиясе председателе итеп билгеләнә. М. Солтангалиев кул куйган документларның берсендә Төркиядә пролетариат восстаниесе оештыру максаты белән Комиссариат составында Мостафа Сәбхи җитәкчелегендә халыкара пропаганда бүлеге төзелүе хәбәр ителә һәм Сәбхинең шәхси дошманнары корткычлыгы нәтиҗәсендә эш бераз тоткарланды диелә[4]. Бу уңайдан шуны әйтеп үтәргә кирәк: Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының 1918 ел ноябрендә булып узган I съездында ук төрек коммунистлары фракциясе үзенең резолюциясендә: «Көнбатышта җәелгән социаль революция белән Көнчыгыштагы шундый ук революцион хәрәкәт арасында әзлекле элемтә бар һәм бөтендөнья революция факелы кабынсын өчен империалистларны Кавказдан куарга, ә аның өчен Төркиядә революция булдырырга кирәк» дип күрсәтелгән[5]. Мирсәет Солтангалиев катнашында Одесса һәм Кавказ аша Төркиягә фракция членнарын җибәрү мәсьәләсе карала һәм төрек коммунистик отряды төзергә, аңа хәрби әсирләрне дә кушарга кирәк дип табыла. Бу эшләрдә И. Фирдәвескә зур өметләр баглана. Кайбер документларда ул төрки-татар халыкларының милли азатлык хәрәкәтен экспортлау теоретигы дип тә атала. Төркиядә эш алып бару өчен Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк комитеты Революцион Хәрби Советның Кыр штабына хат җибәреп, Төркиядән алынган агентур мәгълүматларны сорый. «Үзәк бюрога халыкара хәлне, бигрәк тә Көнчыгыштагы хәлне белү мәгъкуль, шунлыктан былтыргы һәм быелгы яшерен пакет һәм агентур мәгълүматларны председатель Солтангалиев исеменә җибәрүегез сорала»[6], дип язылган ул хатта. Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмалары үзәк бюросының тагын берничә документына күз салыйк. 1919 елның 13 мартына караган бер документта Казандагы Мөселман коммунистик оешмалары бюросы әгъзасы Рәҗәп Сабрига ярдәм күрсәтү сорала. Төркиягә җибәрелергә дип Кырымда төзелгән революцион көчләр составына кертелгән бу төрек коммунистын Казаннан озату өчен ярдәм кирәк була. Ул революцион көчләр төрек хәрби әсирләреннән торган. Мондый эчтәлектәге хатлар, телеграммалар башка шәһәрләргә дә җибәрелә[7].

Билгеле булганча, Төркиягә революция экспортлауга тырышу фаҗигале тәмамлана. Төрек властьлары Россиядән кайткан революционерларны кулга алалар, шул вакытта Мостафа Сәбхи дә һәлак була. Әмма моңа карап кына М. Солтангалиев Шәрыкта революция уты кабызу уеннан һич тә ваз кичми. Ул Россиядәге мөселман халыклары арасыннан хәрби кадрлар әзерләү эшенең бер тармагын шушы юнәлештә алып бара. Әлбәттә, бу хәрби кадрлар иң беренче чиратта Кызыл Армиядәге мөселман хәрби частьләрен командирлар белән тәэмин итү өчен әзерләнә.

Әнә шундый катлаулы эшләр белән мәшгуль булган Солтангалиевкә көнләшеп караучылар да була. Күрәсең, алар арасында Солтангалиев өстеннән донос язучылар да табылган. Кыскасы, аның бу күпкырлы эшчәнлеге озын гомерле булмый.

РКП(б) Үзәк Комитетының Дүртенче милли киңәшмәсе Солтангалиев карьерасына киртә куя. 1923 елның 9—12 июнендә Мәскәүдә үткәрелгән бу киңәшмәдә үзәк Комитетның 17 члены, 3 членлыкка кандидаты, Үзәк Контроль комиссиясенең 6 члены һәм урыннардан чакырылган 58 делегат катнаша. Киңәшмәдә ике доклад тыңлана. Солтангалиев «эше» турындагы докладны В. В. Куйбышев ясый. Сталин партиянең XII съездында кабул ителгән милли мәсьәлә турындагы резолюцияне тормышка ашыруга багышланган доклад белән чыгыш ясый. Бу киңәшмәдәге чыгышларга декларативлык, дәлилсезлек һәм ниндидер бер серлелек хас. Бер генә дә ачык исбат ителгән факт китерелми. Ярым-йорты, гомум контексттан йолкынган фактлар «бәхәссез» дәлил булып хезмәт итәләр. Киңәшмәдә катнашучылар «солтангалиевчелек»нең ни икәнен чынлап аңламаганнар булса кирәк. Чөнки моннан соң «солтангалиевче» ярлыгын теләсә нинди мөселман коммунистына тага башлыйлар. Киңәшмәдә Фрунзе, Орджоникидзе, Мануильский чыгышлары да тыңлана. Алар бар да Солтангалиевне «фаш итәләр» һәм бу эш Татарстан һәм Башкортстаннан еракка җәелә дип такрарлыйлар. Шуның белән алар «солтангалиевчелек»нең тамырларын башка төбәкләрдә дә эзләү мөмкинлеген тудыралар.

1923 ел башында ОГПУ органнары М. Солтангалиевнең Иран политик эшлеклесе Таҗи Бакши һәм БАССР Халык Комиссарлары Советы председателе М. Д. Халиковка җибәргән хатларын кулга төшерә. Моны Сталин әмере белән эшләгән эш диярге була. Бу хәлләрдән бер ел алдарак, ул чакта Кырым АССР Халык Комиссарлары Советы председателе булып эшләгән С. Сәетгалиев ГПУ органнарына И. Фирдәвес артыннан күзәтү башларга әмер биргәнлеген Кремльгә хәбәр итә. Әлбәттә, монда да Сталин кулы уйнаганлыгы сизелә. Татарстанның ГПУ председателе А. А. Денисов та Мәскәүгә

---

[4] ЦПА ИМЛ, 583 ф., 1 тасв., 35 эш, 249 б.
[5] Шунда ук, 196 б.
[6] Шунда ук, 32 эш, 15 б.
[7] Шунда ук, 205, 308 б.б.

мөселман мәктәпләрендә белем алган мөселман-коммунистларның шиктые буржуаз җәмгать эшлеклеләре белән элемтәдә тора, дип хәбәр итә. Кыскасы, Солтангалиев камалышта кала, аның һәрбер адымы Сталинга җиткерелә. Мәскәүдәге мәҗлесләрнең берсендә Сталин Солтангалиевкә аның хатлары ГПУ кулына эләккәнлеген әйтә, шулай булса да аны кулга алырга рөхсәт бирмәвенә басым ясап, киләчәктә сак булырга куша. Димәк, Сталин бер яктан Солтангалиевкә сак булырга кирәк ди, икенче яктан, аның артыннан күзәтүне дәвам итәргә боерык бирә. Сталин белән Солтангалиев арасындагы мөнәсәбәтләр әле бүген дә чишелмәгән табышмакны хәтерләтә. Бер яктан Сталин тарафыннан Солтангалиевкә карата ниндидер дустанә мөнәсәбәт тә сизелә кебек. Бәлки аларның революциягә кадәр Бакуда яшәгән дәвердә ниндидер уртак эшләре, уртак танышлары да булуы мөмкин. Югыйсә, Мәскәүгә эшләргә килгәч, хатын-кыз намусына кул сузган бер адәмне атып үтергән Мирсәетне һичшиксез төрмәгә утырткан булырлар иде. Ә Сталин аңа җил-яңгыр тидертми, Солтангалиев үз эшендә эшли бирә. Ә менә 1923 елда Сталинның Солтангалиевкә булган мөнәсәбәте үзгәрә башлый. Бәлки, Мирсәет Сталинның милли политика өлкәсендә командалык итү һәм администрациячелек ысулларына күчә баруын сизеп, нинди дә булса ризасызлык белдергән булгандыр. Чыннан да, СССР төзелгәннән соң автономияле республикаларга караш үзгәрә, аларның хокуклары бик нык чикләнә башлый. Солтангалиев исә Төркстан, Татарстан, Башкортстан, Төньяк Кавказдагы Тау автономияле республикаларының тулырак хокуклы булуын алга сөрә, аларны ниндидер формада берләштерергә кирәк дигән тәкъдим белән үзәк органнарга мөрәҗәгать итәргә теләгән булса кирәк. Егерменче еллар башында Солтангалиевнең санап үтелгән республикаларның җитәкчеләре белән элемтәсе активлашуын шуның белән аңлатырга мөмкин. Нәкъ менә шушы вакытта М. Солтангалиев һәм милли республикаларның җитәкчеләре артыннан күзәтү көчәя бара. ГПУ органнарына Солтангалиевнең Башкортстан АССР Халык мәгарифе комиссары А. К. Әдһәмов исеменә язган хаты килеп керә. Хатта Солтангалиев моңа кадәр булган язышу материалларын юк итүне үтенгән. Ләкин хат авторы өчен иң куркыныча түбәндәге сүзләр була: «...Төркстанда, Бохарада басмачылык хәрәкәте ныгый. Язга алар оешкан рәвештә чыгарга җыеналар дигән хәбәр бар. Шунлыктан Үзәк милли мәсьәләдә шактый ташламалар ясый. Зәки Вәлидов белән элемтә урнаштыр, ләкин зур саклык кирәк — тере элемтә яки шифр белән»[8]. Дүртенче милли киңәшмәдә бу фактлар да игълан ителә. Солтангалиев үзенең дөрес эшләмәгәнлеген танып, болай ди: «Мин иптәш Әдһәмовка Вәлидов белән тере кеше аша яки шифр белән элемтәгә керергә тәкъдим ясап, бу фактны, Милләтләр эше буенча Халык Комиссариаты коллегиясе члены буларак, үзем член булган Совет хөкүмәтеннән яшереп законсыз эшләгәнемне таныйм». Танымаска мөмкин дә булмый. Чөнки бу киңәшмәгә кадәр үк, 1923 елның 4 маенда Мирсәет Солтангалиев эш урынында кулга алына. Шул ук көнне РКП(б)ның Үзәк Контроль комиссиясе тарафыннан партиядән чыгарыла. Айдан артык сак астында утыра һәм киңәшмәгә дә төрмәдән китерелә. Солтангалиевнең хаталары булмагандыр дип әйтеп булмый. Шул ук вакытта ул СССР төзелгән елларда ук Сталинның милли кадрлар белән эшләү методларына каршы була, милли республикаларның яңа федерация составында киңрәк хокуклы булуын яклый. Татарстанда, Башкортстанда, Төркстанда үзенә фикердәшләр эзли һәм «уң» группировканың лидерына әверелеп, милли республикалардагы «сул» интернационалистларны кысрыклый. Шунысын истән чыгармаска кирәк, Солтангалиев кебек милли республикаларның хокукларын кысуга каршы чыгучылар партиядә аз булмый. Хәзер киң мәгълүм булган «грузин эше», РКП(б)ның XII съездындагы дискуссия, аерым алганда, шул съездда Украина Халык Комиссарлары Советы председателе Х. Г. Раковский ясаган чыгыш һ. б. моның ачык мисалы. Әлбәттә, Солтангалиевнең хатасы риза булмауда түгел, шул ризасызлыкны тормышка ашыру методларында. М. Солтангалиевнең З. Вәлидов белән элемтәгә керергә тырышуы турында төрле версияләр бар. 1923 елда тикшерү вакытында ул моны басмачылар һөҗүмен тыныч юл белән булдырмый калу өчен эшләнде, ди. Ә 1928 елда моның Туран дәүләтен төзүгә юнәлдерелгән адым икәнлеген «таный». Әле бүген дә кайберәүләр, имеш, Солтангалиев үзенең вәкаләтләреннән чыгып, чит илләр белән элемтәгә кергән, диләр. Моңа дәлил итеп Солтангалиевнең Дүртенче милли киңәшмәдә Совет хөкүмәтеннән яшереп һәм Коминтернга сиздермичә чит илдәге кешеләр белән пароль ярдәмендә элемтәдә торуын «таныганлыгын» китерәләр. Ләкин Дүртенче киңәшмә вакытында аны беркем дә шпионлыкта, Совет иленә, коммунистик идеалларга хыянәт итүдә гаепләми. Ә бит соңыннан андый гаепләр дә тагыла аңа. Һәм бу очраклы түгел. 1923 елда әле мондый ярлык тагу тәҗрибәсе булмый. Ул соңрак барлыкка килә. Чит илләр белән элемтә тоту, билгеле булганча, М. Солтангалиевнең рәсми вазифаларына кергән һәм ул чит илләрдәге революцион хәрәкәткә йогынты ясау максаты белән эшләнгән. Ә менә шул элемтә-

[8] КПССның Татарстан өлкә комитеты архивы, 36 ф., 3 тасв., 303 эш, 18 б.

ләрнең тора-бара яшеренгә әверелүе — икенче мәсьәлә. Анысын да аңлатып була. Артыннан күзәтүнең көчәя барганын сизеп Солтангалиев пароль системасына күчәргә мәҗбүр була, үзе дә сизмәстән милләтчелеккә дә ташламалар ясагандыр, күрәсең. Ләкин, бүген шуны ышанып әйтергә була, ул заманнарда тикшерү вакытында гаеп «тану» чын фәнни аргумент була алмый. Мәгълүм ки, Сталин һәм аның нарченнәре кеше ышанмаслык документларга әллә кемнәрнең имзаларын куйдырганнар, гомер эшләнмәгән эшләрне эшләдек, дип әйттерә торган ысулларны кулланганнар.

Әлбәттә, М. Солтангалиев бернинди «туранчы» да, бернинди төрекче дә булмаган. Ул үзен Советлар илендәге төрки халыкларның вәкиле, аларга хезмәт итә алырдай кеше, дип саный. Һәм бу шулай булган да. Кулга алынганнан соң да аны почетлы президиумнарга сайлау, аның исеменә котлаулар җибәрелү, әлбәттә, юкка гына булмаган. Татарстанның күренекле җитәкчеләре, аерым алганда, Халык Комиссарлары Советы председателе К. Мохтаров, Татарстанның Үзәк Башкарма Комитеты председателе Р. Сабиров 1923 елның 8 маенда Л. Б. Каменев, Г. Е. Зиновьев, Л. Д. Троцкий, Н. И. Бухарин, К. Б. Радек, В. В. Куйбышев исеменә язган хатларында «иптәш Солтангалиевнең Көнчыгыштагы республика һәм өлкәләрнең төп милләт коммунистларына һәм партиясезләрнең киң массаларына зур йогынтысын» күрсәтеп, аны нинди дә булса ээрлекләүләрдән коткарып, аңа поручительство бирергә әзер булуларын белдерәләр. Бу хат авторларының язмышы хәзер инде билгеле: алар шәхес культы корбаны булдылар.

Мәскәүдәге Дүртенче милли киңәшмәдән соң Казанда да милли мәсьәләгә багышланган киңәшмә уздырыла. 1923 елның июль аенда уздырылган бу киңәшмә тулысынча Солтангалиев һәм аның тарафдарларын «фаш итүгә» багышлана. Төп доклад белән РКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты секретаре Д. Е. Живов чыгыш ясый. Докладта Мәскәүдәге киңәшмә турында тулы информация бирелә. Әмма солтангалиевчелекнең нәрсә икәнлегенә монда да объектив бәя бирелми. Хәтта, гадәттә һәрбер вакыйга һәм күренешкә төрле яктан уйлап объектив бәя бирә торган Г. Ибраһимов та аны «татар меньшевизмы» дип бәяли. Бу билгеләмә шул көенчә әдәбиятка да кереп китә һәм бер китаптан икенчесенә күчеп безнең көннәргә дә килеп җитте. Г. Ибраһимовка ияреп, Ш. Әхмәдиев тә солтангалиевчеләрне муллалар белән әвәрә килүдә, карагруһчыларга кушылуда, хәтта Төркия һәм Персия агентлары белән эш итүдә гаепли. Р. Мөслимов дигән берәү солтангалиевчелекне фашизм дип атауга кадәр барып җитә. (Кара: «Стенографический отчет национального совещания». Казань, 1923, 63—65 бб.) Киңәшмәдә солтангалиевчеләрне фаш итүне дәвам иттерергә һәм Татарстанның барлык коммунистлары солтангалиевчелек калдыкларын бетерү өчен көрәшергә тиешләр дигән карар кабул ителә. Әгәр дә бу фаш итү киңәшмәсендә катнашучылар 13—14 ел эчендә теге яки бу тайпылышта гаепләнеп шәхес культы корбаны буласыларын белсәләр, бу кадәр үк кыланмаган булырлар иде, әлбәттә.

1929 елның октябрендә РКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты «Солтангалиевчелек турында» махсус карар кабул итә. Ул «солтангалиевчелек хәрәкәтен» тар-мар итүне хуплап, аның тарафдарларына карата «оештыру чаралары» күрүне таләп итә. Газета-журналлар фаш итү кампаниясен куерткannan-куерта баралар. Солтангалиевчелек хәрәкәте турындагы мәсьәлә 3—9 ноябрьдә партиянең Татарстан өлкә комитеты пленумында яңадан тикшерелә. Кабул ителгән карарда болай диелгән: «Пленум барлык партия членнарын артта калган массалар арасындагы милләтчелек калдыклары белән көрәшне көчәйтергә, безнең аппараттагы әлегәчә яшәп килгән солтангалиевчелек идеологиясен конкрет үткәрүчеләрне фаш итәргә чакыра» (Аршаруни А. Идеология султангалиевщины.— «Антирелигиозник», 1930, № 5, 22—29 бб.).

Сталинның татар коммунистларына һәм гомумән татарларга булган мөнәсәбәте «Солтангалиев эше»ндә бигрәк тә ачык чагыла. Л. Д. Троцкийның сүзләренә караганда Политбюро членнары соңыннан М. Солтангалиевне кулга алырга ризалык бирүләренә үкенгәннәр. Л. Б. Каменев моны күренекле партия членнарын кулга алуның беренче очрагы икәнен күрсәтеп, «Сталинга кан тәме ошады» дигән. Чыннан да, моннан соң Татарстан партия оешмасында зур чистарту булып уза. Соңрак ул Башкортстанга, Горький, Мәскәү, Урал өлкәсе, Үзәк промышленность районы, Донбасс һәм башка өлкәләргә дә җәелә. Солтангалиевчелек шаукымы белән Татарстанда 1930 елда гына да 2056 кеше партиядән чыгарыла. Бу ул чактагы республика партия оешмасының 13,4 процентын тәшкил итә. Шуның өстенә 329 кеше урыннарыннан алына, 2273 кешегә шелтә бирелә («Кызыл Татарстан», 1930, 20 апрель).

Солтангалиев Мәскәүдәге милли киңәшмәдән соң азат ителә һәм төрле эштә эшли, эшсез чаклары да була. Андый вакытларда элеккеге дусларыннан кайберләре аңа бишәр сум акча җыеп бирүләре дә мәгълүм. 1923 елдан соң ул потребкооперация өлкәсендә эшли, «Кооперативная жизнь» газетасында мәкаләләр бастыра. Кыскасы, тормышы җиңел булмый, үзе иректә, ә «солтангалиевчелек» тыелу астында. Күпләр, шул исәптән, аның белән таныш булмаганнар да, солтангалиевчелектә гаепләнәләр. Солтангалиевкә каршы мәкаләләр, аерым китаплар дөнья күрә. Имеш, Солтангалиев

татар хезмәт ияләренең социалистик революциядә катнашуын инкарь иткән, революциянең җаваплы көннәрендә милләтчеләр белән бергә булган һ. б., һ. б. Боларның берсе дә дөрес түгел. Моны аңлар өчен М. Солтангалиевнең «Жизнь национальностей» журналының 1923 елның беренче санында дөнья күргән «Татарская автономная республика» исемле мәкаләсенә күз ташлау да җитәр иде. Анда ул татар хезмәт ияләренең революциядә һәм гражданнар сугышында актив катнашуын тасвирлый һәм Октябрь революциясе татарларга нәрсә бирде дигән сорауга «барын да» дип җавап бирә. Мәкаләсен ул болай дип тәмамлый: «Бөтен дөньяда хезмәт ияләренең властен ныгыту өчен... бүген татар укчысы Социалистик Совет Татарстанындагы барлык хезмәт ияләре белән үзенең пролетар аңын очлый һәм үзенең пролетар ихтыярын чүки. Һәм бернинди Исхаковларга һәм Максутовларга, бернинди «хәзерге Тамерланнарга»-Әнвәрләргә һәм аларның мескен дәвамчыларына бу аңны һәм ихтыярны үзгәртү мөмкин түгел». (39 б.)

Егерменче еллар ахырында «күренекле солтангалиевчеләр»нең исемлеге барлыкка килә. «Красная Татария» газетасының 1929 ел 16 октябрь санында дөнья күргән мәкаләсендә С. Борһан бу исемлеккә түбәндәге шәхесләрне кертә: М. Бөдәйли, В. Исхаков, И. Борындыков, К. Мохтаров, А. Енбаев, Р. Сабиров, Г. Мансуров һ. б. С. Борһан фикеренә караганда алар Татарстан, Азәрбайҗан, Үзбәкстан, Таҗикстан, Казахстан, Кыргызстан, Башкортстан, Чувашстаннарны үз эченә алган Туран буржуаз дәүләте төзеп, империалистик илләр белән дуслашырга ниятләгәннәр, имеш. 1929 елның 4 ноябрендә «Правда» газетасы Таболовның «Социалистик һөҗүм һәм буржуаз милләтчелекнең активлашуы» исемле күләмле мәкаләсен басып чыгара. Мәкалә «1923 елга кадәр Солтангалиев күренекле татар коммунисты иде» дип башлана һәм «үз артыннан татар һәм башкорт коммунистларының шактый өлешен ияртკән солтангалиевчелек 1929 елда тар уң милләтчеләр һәм реакцион империалистик интеллигенция юлбашчылары түгәрәгенә әйләнде»,— дип тәмамлана. «Солтангалиевчелек хәрәкәте»н автор элек арттa калган республика һәм өлкәләрдәге социалистик төзелеш, индустриализация һәм коллективлаштыру уңышларына кулакларның, байларның һәм мөселман руханиларының реакциясе дип аңлата. Мәкаләдә солтангалиевчелекнең программасы барлыгы да әйтелә. Әмма бүгенгә кадәр берәүнең дә ул программаны кулына тотып караганы юк. Шуңа карамастан, әлегә кадәр ул «программа»ның эчтәлеге турында сүз алып баралар, төп тезисларын тәнкыйтьлиләр. Бу программада, имеш, СССР мәңгелек түгел, шуңа күрә анда пролетариат диктатурасы түгел, ә метрополия өстеннән колонияләр һәм ярымколонияләр диктатурасы, ә көнчыгышта Советлар системасы урынына, әйтеп үтелгән Туран дәүләте булырга тиеш дип күрсәтелгән. Имеш, 1929 елга солтангалиевчеләрнең махсус яшерен конференцияләре билгеләнгән булган. Димәк, кулакларны сыйныф буларак бетерү солтангалиевчелекне тар-мар итү бурычы белән юкка гына бер үк елларга билгеләнмәгән икән дип әйтә алабыз. Андый яшерен конференциянең бары тик Сталин тарафыннан гына уйлап чыгарылганы хәзер инде ачык мәсьәлә. Кулакларны кырганда, авылны тар-мар иткәндә милли кадрларны да юк итү кулай күрелгән. Шул сәбәпле солтангалиевчелек «сәгыйдуллинчылык»[9] дигән яңа бер уйдырма белән тулыландырылган, киңәйтелгән. Яңа исемгә бәйләп кулга алынучылар даирәсен тагын да киңәйтүгә юл ачылган. Ниләр генә уйлап чыгарылмый ул заманда! Имеш, алар империалистик дәүләтләрнең генераль штаблары белән, Пилсудский белән, тагын әллә кемнәр белән элемтәдә торганнар һ. б., һ. б. 1930 елның августында ОГПУ органнары шау-гөр килеп әдәбиятчыларның «Җидегән» исемле «яшерен оешмасын фаш итәләр». «Җидегәнчеләр» Солтангалиев идеяләрен таратканнар, имеш. Алар, имеш, татарларның 99% хезмәт иясе халкы, шуңа күрә татар авылындагы сыйнфый көрәш ул уйдырма гына дигәннәр. Бу «оешма» эзеннән Башкортстанга да барып чыгалар һәм анда да «солтангалиевчеләр»не табалар. 1931 елда Г. Касыймовның Мәскәүдә коммунистик академиянең Дингә каршы көрәш советының үзәк Советы берләштерелгән утырышында ясаган доклады аерым китап булып басылып чыга. Бу китапта да М. Солтангалиевне фаш итүгә урын табыла. Анда Солтангалиевнең 1922 елда дингә каршы пропаганда алып бару методларына караган тезислары тәнкыйть утына тотыла. Авторга Солтангалиевнең муллаларны ике категориягә бүлүе ошамый. Касыймов фикеренә караганда, бернинди кызыл муллалар да, кара муллалар да булмаган. Чынбарлыкта исә бу дөрес түгел. Революция елларында муллалар арасында да халык мәнфәгатьләренә хезмәт итүчеләр табыла. Мәсәлән, Саратов губернасыннан мулла Ваһапов партия члены була, партиянең Үзәк Комитеты һәм Е. Д. Стасова белән хат алышып тора. Әлбәттә, барлык муллалар да партия члены булмаган. Ләкин алар арасында да революциядә катнашучылар булмый түгел. Алдынгы карашлы муллалар арасында революциядән соң Совет властена хезмәт итүчеләр дә булган. Г. Касыймов Солтангалиевнең «без бернинди дингә каршы көрәшмибез, тик үзебезнең атеистик фикерләребезне генә таратабыз» дигән тезисы

[9] М. Сәгыйдуллин — егерменче-утызынчы еллар башында журналист, совет-партия хезмәткәре.

белән дә килешми. Солтангалиев исә бу фикерне алга сөрүен «әгәр дә без дингә каршы көрәшсәк, халыкны партиядән һәм революциядән читкә тибәрү куркынычы» барлыгы белән аңлата. Асылда, бу — тормышның үзеннән килеп чыккан зарурият. Революция елларында дингә ышанган халык массаларын революциягә тарту өчен сыгылмалы тактик алымнар кулланылган. Мәсәлән, мөселман съездларында большевикларга кайвакытта, хәтта, кул күтәреп дога кылырга да туры килә. Шунысы игътибарны җәлеп итә, Г. Касыймов дингә мөнәсәбәтле теләсә нинди хатаны Солтангалиевкә кайтарып калдырмакчы була. 1922—1923 елларда Татарстан Юстиция Халык Комиссариаты каршында ислам дине галимнәреннән шәригать комиссиясе төзелә. Республика югары органнары тарафыннан кабул ителәчәк һәрбер закон, һәрбер декрет шушы комиссиядә тикшерелеп, аның шәригать кануннарына туры килүе ачыкланганнан соң гына игълан ителергә тиеш булган. Ләкин, монда Солтангалиевнең нинди катнашы бар соң? Автор моңа бернинди дәлил китерми. Хәтта, бу сорауны куймый да, чөнки аның өчен мәсьәлә болай да ачык: бу солтангалиевчеләр эше (Касимов Г. Очерки по религиозному и антирелигиозному движению среди татар до и после революции. Казань, 1932, 26—27 бб.).

Тарих фәне өлкәсендә дә шундый ук хәл күзәтелгән. 1931 елда Х. Хәсәнов «Тарих фронтында буржуа милләтчелегенә каршы» исемле китап чыгара. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, югарыда телгә алынган Г. Касыймов бу китапта «пантюркизмга хезмәт итүче» тарихчылар Кәрим Иделгуҗин, Габдулла Әдһәмов, Исхак Казаков һәм башкалар исемлегенә кертелгән. Ул вакытта кемне дә булса берәүне пантюркизмда гаепләсәләр, бу инде аны солтангалиевчелектә дә гаепләү булган. Х. Хәсәнов китабында М. Солтангалиев П. Н. Милюков, Н. А. Бердяевлар белән бергә атала, чөнки аның фикеренчә, «җирле милләтчелек, пролетариат диктатурасын җимерүгә юллар сызуда... рус шовинизмасы белән якынлаша». (8 б.) Тарих фәнендә Солтангалиевнең беренче агенты итеп автор... чуваш Шивлыны атый. Имеш, аның РСФСР составында рус өлкәләреннән рус республикасы төзеп, аңарга башка автономияле республикалар белән тигез хокук бирергә кирәк, дигән тәкъдиме Солтангалиевнең «туранына» таба баруда зур адым атлау булыр иде. Тарих фәнендә Солтангалиевнең икенче агенты итеп Г. Мансуров атала. Х. Хәсәновка бу авторның, әле бүген дә үз әһәмиятен югалтмаган, «Татар провокаторлары», «Беренче революциядә татарлар» исемле хезмәтләре ошамый. Х. Хәсәнов «тарих фронтында» М. Солтангалиевнең калган «агентларына» номер сукмый. Күрәсең, ул номерларны тиешле урында бирерләр дип уйлагандыр. Бигрәк тә күренекле тарихчы һәм язучы Газиз Гобәйдуллин каты тәнкыйтькә дучар ителә. Ул «туранлык» нигезендә яткан алтай теориясен күтәреп чыгучы, «бөек төрек дәүләте», «бөек төрек милләте» идеяләренең авторы итеп күрсәтелә. Җамал Вәлиди, Әхмәтзәки Вәлиди, Зыя Камали, Габдулла һәм Гобәйдулла Бубилар, Муса Бигиев, Рәшит казый Ибраһимов, Фуат Туктаров, Гаяз Исхакый һәм башкалар милләтчеләр исемлегендә аталып, йә солтангалиевчелеккә нигез салучылар, яисә аны дәвам иттерүчеләр итеп күрсәтеләләр.

Кыскасы, 1923 елдан башлап Татарстанда социализм төзүдә нинди генә хата-ялгыш булмасын, бар да Солтангалиевкә, солтангалиевчелеккә сылтана килде. Һәм бу традициягә әверелде. Солтангалиевне күрү түгел, кем икәнен белмәгәннәргә дә «солтангалиевчелек» ярлыгы тагыла башлады. Әйе, социализм төзү кебек бөек эш белән мәшгуль булганда ул хаталар да ясагандыр. Әмма һәрбер хата өчен кешене халык дошманы дип игълан итү — ул үзе коточкыч җинаять, гафу ителмәслек гаеп.

Теге яки бу тарихи шәхеснең кылган гамәлләренең яки хаталарының тарихи сәбәпләрен ачыкларга тиешбез. Юкса беркайчан да кешене гаепләүдән, кешене җәзалаудан башыбыз чыкмас. Шәхеснең революциягә килгән юлын, алдына куйган максатын тарихылык принцибы нигезендә яктыртырга тиешбез. Мирсәет Солтангалиевнең дә революциягә килгән юлы гади һәм җиңел юл булмаган. Ул татар халкының милли азатлык хәрәкәте белән тыгыз үрелгән. Ул большевизмга милләтчелек аркылы килә. Күп еллар вак буржуаз позицияләрдә тора. Ләкин тормыш чынбарлыгы аңа большевизмның социаль гаделлеккә омтылышның иң дөрес юлы икәнлеген күрсәтә. Солтангалиев фикеренчә, патша Россиясендә гаделлеккә иң мохтаҗ халыклар — изелгән һәм мыскылланган мөселман халыклары, шулар исәбендә иң беренче чиратта — татарлар. Шул ук вакытта, ул татарларны Россиядән аеру турында уйламый да. Минем тирән ышануымча, ул бернинди дә Туран дәүләте төзү фикере белән йөрмәгән. Ул бары тик бердәм демократик һәм социалистик Россия составында төрки һәм мөселман халыкларының бер гаиләдә, туганнарча мөнәсәбәттә яшәвен теләгән. Ул моны табигый дип санаганга күрә беркемнән дә яшермәгән. Теге яки бу кардәш халыкларның, шул исәптән төрки халыкларның бертуганнар кебек яшәргә омтылулары пантюркизм буламы? Әйтерсең лә без бүген рус халкының украин һәм белоруслар белән бер гаилә булып яшәвенә шатланмыйбыз. Әллә без шушы халыкларның болгарлар, поляклар, чехлар, словаклар, Югославия халыклары белән якынлашуын, аларның үзара аралашуын панславизм дип әйтә алабызмы? Юк, әлбәттә.

Мирсәет Солтангалиев тә халыкларны үзара сугыштыру уе белән янмаган, аларның

дус булуын алга сөргән. Рус халкына карата тирән ихтирам хисе саклаган, аның алдынгы культурасы казанышларын халыкка җиткерү өчен шактый күп эшләгән журналист, политик һәм җәмәгать эшлеклесе ул. Аның белән кызыксыну чит илләрдә дә артканнанарта бара. Мәшһүр революционер, соңрак Алжир республикасының президенты булган Әхмәт Бен Белла азатлык хәрәкәтенең фундаменталь принципларын нигезләгәндә Солтангалиевнең милли азатлык хәрәкәтенең этәргеч көчләре концепциясенә таянган. Безнең көннәрдәге милли демократия дәүләте концепциясендә дә Солтангалиев идеяләре бик ачык чагыла. Көнчыгыш илләрендә киң җәелгән милли азатлык хәрәкәтләрен җентекләп өйрәнгән Вальтер Лакер 1958 елда «Нью лидер» газетасының 3 февраль санында «Бүгенге көндә Солтангалиевнең фикерләре күрәзәлектәй яңгырый», дип яза. Шуңа охшашлы фикерләр А. Беннигсен, Ш. Келькеже, Р. Гароди һәм башка чит ил авторларының әсәрләрендә дә ачык чагыла. А. Беннигсенның моннан берничә ел элек «Солтангалиев —өченче дөньяның идеологы» исемле хезмәт чыгаруы юкка гына түгел, әлбәттә. Бу кызыксынуның тирән объектив сәбәбе бар. Солтангалиев яшәгән һәм эшләгән елларда әле Шәрык халыклары уянып кына килә иде, алар әле бөтендөнья тарих мәйданына чыгарга әзерлексез иде. Солтангалиев күпләр белән бергә әнә шул уянуны сабырсызланып ашыктырырга тырышкан, кулыннан килгәнчә Көнчыгыш илләрендәге революцион хәрәкәткә ярдәм итәргә, хәтта чатккы ташлап бөтен Шәрыкта революция ялкыны дөрләтүдән дә баш тартмаган. Ләкин болар барысы да ул чакларда нәтиҗәсез чаралар була. Тик безнең көннәрдә генә, бүгенге буын күз алдында колониаль империяләр чәлпәрәмә килеп, Шәрык халыклары алдында социаль прогресс перспективасы ачылды. Нәкъ менә шундый вакытта тарих сәхифәләренә мөрәҗәгать итү, аннан тиешле сабак, тәҗрибә алырга тырышу объектив мәҗбүриятькә әверелде.

Шулай итеп М. Солтангалиев шәхес культының иң беренче корбаннарыннан була, илдә иң беренчеләрдән булып аңа империализм агенты дигән ярлык тагыла. «Солтангалиевчелек» дигән төшенчә илдә иң беренче политик уйдырмалардан саналырга тиеш. Бүген шунысы ачык, бу исем астында хәрәкәт иткән бернинди агым да булмаган. Бары тик революциягә искиткеч катлаулы һәм авыр юл белән килгән, революциянең үз халкына биргән мөмкинлекләренең тулырак һәм мулрак булуын теләгән татар большевиклары булган. Аларның күпчелеге шул юлда корбан да була. Мирсәет Хәйдәргали улы Солтангалиев шуларның иң беренчеләреннән.

Аның кайчан һәм ничек үлүе турында әлегә ышанычлы мәгълүматлар юк. 1929 елда ул яңадан кулга алына һәм бернинди ачык суд үткәрелмәстән ун елга төрмәгә хөкем ителә. Аның эше буенча тикшерүләр алып барыла, ул тикшерү материаллары сакланган булырга тиеш. Бүгенге көндә Мәскәүдә яшәүче СССР Фәннәр академиясе член-корреспонденты химик И. З. Торбов 1938 елны репрессиягә эләгә һәм Казанда төрмәдә утыра. Аның сөйләвенә караганда, ул төрмәдә М. Солтангалиевне очраткан. Бер-берсенә моң-зарларын сөйләгәндә Солтангалиев үзеннән төрле ысуллар кулланып тоташ егермешәр сәгать сорау алганнарын әйткән. Сорау алулар вакытында ул берничә тапкыр аңын югалтып егыла, әмма күзен ачуга сорау алу яңадан дәвам иттерелгән. Әмма И. З. Торбов әйтүенчә, ул рухи ныклыгын югалтмаган. Бәлки Торбов күргән һәм аның белән бер ай чамасы төрмәдә бергә булган кеше чыннан да Мирсәет Солтангалиев булгандыр? 1952 елда М. Солтангалиев әле исән булган, Мәскәүдә Сталин тарафыннан бирелгән махсус бүлмәдә яшәгән һәм аңа ниндидер материаллар әзерләү белән шөгыльләнгән дигән версия дә бар. Өченче версия буенча, имеш, срогын тутырып кайткач, ул Саратовта яши, хәтта язучылар союзына алуны үтенеп гариза да язган. Бу версияләрнең дөреслеге яңа тикшеренүләр дәвамында ачыкланырга, М. Солтангалиевнең соңгы көннәре төгәл яктыртылырга тиеш.

Хәбәрдарлык, үзгәртеп кору дәвере күп нәрсәгә ачыклык кертте. Шәхес культы чорында законсызлык корбаннарының исемнәре әйтелде. Ләкин алда эш күп әле. Солтангалиев трагедиясендә дә бер Сталин гына гаепле түгел. Бу эшкә төрле яла ягучылар, палачлар, көнчеләр җәлеп ителгән. Киләчәктә аларның кара эшләрен фаш иткән хезмәтләр дә халыкка җиткерелергә тиеш.

# БӘЯНЕ ДӨРЕС БИРИК

«Заман һәм шигырь» рубрикасы астында «Казан утлары» журналында барган бәхәсне бик кызыксынып күзәтәм. Журналның быел килгән беренче саны белән танышуны да нәкъ шушы рубрикадан, ягъни шагыйрь Нури Арслановның «Ачыктан-ачык әйтсәк» һәм Мәскәү каласыннан Вахит Юнысовның «Кая киткән тыйнаклык?» дигән язмаларыннан башлап җибәрдем.

Аңлавымча, журналда барган бу әдәби дискуссиянең максаты татар шигърияте хәленә дөрес бәя бирү, аны яхшырту юлларын эзләүдән гыйбарәт. Ә бүгенге ике автор исә бу хакта онытып, күбрәк язучыларның үзләрен тикшерү белән мавыкканнар. Менә Нури Арсланов Илдар Юзеевның «Казан утлары» журналында (1987 ел, 7 сан) басылган «Сез кабызган утлар» поэмасына анализ ясый. «Поэма гадәттәгечә оста язылган, сүз дә юк,— дип сак кына башлана тәнкыйть.— Шагыйре әйбәт, поэмасы шома, ә әсәрнең эчтәлеге нәрсә турында сөйли соң?» Шулай дип сораса да, Н. Арсланов үз соравына үзе җавап биреп тормый, ә бәлки шунда ук хөкем фикере чыгарып куя. Билгеле, поэма кадәр поэманың «эчтәлеген» мәкаләдә сөйләп бирү мөмкин булмастай эш. Хисләр, кичерешләр өермәсе ул. Һәм бу очракта аның җитди сәбәбе дә бар: шагыйрьнең туып-үскән йортын сүтеп, зират йорты итеп куярга ниятлиләр. Кем үзенең туган нигезе туздырылуына риза булып торыр икән? Бу афәтне булдырмас өчен И. Юзеев өенә кайта, учак дөрләтеп төн үткәрә, йортның гыйбрәтле тарихын гына түгел, кешеләр, заман турында уйланып поэма иҗат итә. Ләкин Нури Арсланов шагыйрьне тыйнаксызлыкта гаепли. «Ачыктан-ачык әйткәндә,— ди ул,— шагыйрь үзенә, яки Юзеевларга музей-йорт ачуның кирәклеге турында борчылып яза». Ну, кешеләр...

Инде Мәскәүдән килгән язма турында бер-ике сүз. Вахит Юнысов дигән кеше анда Әхсән Баяновның «Казан утлары» журналында (7 сан, 1988 ел) басылып чыккан «Юкәдәге чикләвекләр» исемле мәкаләсен тәнкыйть итә. Итсә итәр иде әле, аңа карап минем ул мәкалә турында калган иң яхшы фикерем барыбер үзгәрмәде. Ләкин монда да кешенең үзәгенә үтәрлек сүзләр бар: «Бәрәкалла, машалла, иң зур бөркет Ә. Баянов үзе икән ләбаса!» Алга таба да мыскыллап көлү сизелеп тора. Нигә кирәк шул кадәр пычак теллелек, кешенең әхлагында казыну?

Бу мәкалә миңа ирексездән «Ну, погоди»ның кайсыдыр сериясендәге бер күренешне хәтерләтте. Бүре елга аркылы йөзеп баручы Куян артыннан кармак ыргыта. Шул кармак иллә дә зәһәр, мәкерле ыжлап оча да инде!

Кыскасы, әйтәсем килгәне шул: безнең әдәби тәнкыйтьтә кешегә Бүре кармаклары ташланмасын иде. Ә тәнкыйть уклары исә сызгырып очып, әдәбиятта булган кимчелекләрне юк итсеннәр.

Илдус **МИННЕХАНОВ**,
Кама Аланы.

# ШАГЫЙРЬНЕҢ ТЫЛСЫМЛЫ МОХИТЕ

Мин сөйләргә теләгән йорт та, андагы фатир да юк инде хәзер.

Бүлмәләрнең яктылары да, эңгерләрәкләре дә бар иде анда. Эреле-ваклы төрле чор җиһазлары... Узган вакытлардан калган бер утрау диярсең. Әйе, гадәти түгел иде бу торак — чын мәгънәсендә мемориаль иде ул. Минем әниемнең беренче ире — мәшһүр татар шагыйре, классигы Һади Такташ яшәгән йорт хакында сүз бара. Куйбышев урамындагы 37 нче йортның өченче катында безнең гаилә шагыйрьнең эш бүлмәсен кадерләп саклады. Әллә ни зур бүлмә түгел иде ул. Тәрәзәләре ишегалдына карап тора. Әнием Гөлчирә Такташеваның сөйләгәннәрен хәтерлим: өй җиһазларын шагыйрь үз куңеленә хуш китерердәйләрен сайлап, үзе сатып алган булган. Чөнки аның беренче хатыны аерылышкан чакта соңгы урындыкка кадәр үк үзе белән алып киткән — Мәскәүгә барып урнашырга карар кылган. Шагыйрь һич карусыз барысын да биреп җибәргән. Ике тумбалы, галәмәт зур өстәлне генә алып калган. Хәер, аны ташып-күчереп йөртүе дә уен эш булмаган, әлбәттә. Тәрәзә каршысында менә шул өстәл тора. Ә өстәл янындагы кәнәфи миңа гаҗәеп булып тоела иде. Утырырга йомшак булмаса да, кысаларына соклангыч бизәкләр уеп эшләнгән иде ул. Терсәк белән таяныр урыннары да каты үзенең. Ләкин минем өчен ул барыбер гаҗәеп иде — шагыйрь эшләгән урын лабаса! Өстәлдә язу кирәк-ярагы. Утә күренмәле пыяладан ясалган ике кара савыты авыр, кара мәрмәргә утыртылган. Шагыйрь яраткан кара һәм яшел каралар юк иде инде анда. Ул чакта ук ялтырап торган авторучкалар пәйда булган. Һәм кара савытлары тимер шлем кигән сакчылар шикелле җыйнак кына борынгы бер касәне саклап торган шикелле тоелалар иде. Аждаһа сурәте төшерелгән ул касә коеп ясалган иде бугай. Аңа каләмнәр, нечкә иттереп очланган карандашлар тутырып куелган. Хәтта каурый каләм дә бар. Аска таба нечкәреп төшкән юан бер каләмне «Такташ каләме» дип әйтәләр иде. Шагыйрь шуның белән язарга ярата иде дип сөйләде әнием... Кара күн белән тышланган, нишләптер, шомлырак кыяфәтле бинһаят зур диван да бар иде анда. Шагыйрь шунда ял итәргә яраткан. Кысалары чикләвек агачы төсенә кертеп эшкәртелгән ул диван миңа бик тә могтәбәр һәм тантаналы булып тоела иде. Бүлмәдә тагын баш-башлары ялтыравык тимердән ясалган карават тора. Шушы әллә ни йомшак булмаган ятакта шагыйрь үлгән. Караватт өстендә Һейненың портреты төшерелгән бәләкәйрәк кенә бер гравюра. Ул караватта абыем йоклаган чакта, аның зәвыгына карап, сурәтләр үзгәрә торды: Байрон пәйда булды, аны Лермонтов алмаштырды. Аннары абыйның күңелен кузгаткан чибәр кызларның фоторәсемнәре барысын да алыштырды. Мине һаман үзенә ымсындырып торган бу бүлмәгә шагыйрь улы үзен хуҗа итеп саный иде шул...

Диван өстенә ябылган уттай кызыл бизәкле тар келәм аерата якты булып балкып торды. Шул диван өстендә үк Шагыйрьнең зур портреты эленеп тора: җилкенеп киләкилешкә тукталган да, зур күзләрен текәп, сагышланып, җавап сорап миңа текәлгән...

Язмыш Шагыйрьне кызганып тормаган. Әнием һәм әбием, Шагыйрьнең кыз туганы сөйләгәннәрне, аның 37 елдан һәм Бөек Ватан сугышыннан исән калган азмы-күпме дусларыннан ишеткән истәлекләрне тыңлаганнан соң, күңелемдә Шагыйрьнең бүтән сурәте яралды. Ул сурәт Такташ хакында юбилей тантаналарында һәм мәкаләләрендә тәссезләндерелеп бетерелгән образга охшап та бетми...

Бусын калдырып торыйк. Хатирәләрнең серле эңгеренә күмелгән бүлмәгә әйләнеп кайтыйк. Зур портрет янәшәсендә җыйнаграгы да бар иде. Ул портретны зур оста эшләгәне күренеп тора (Фешин булырга тиеш, дип исәпләнелә). Портрет тәмамланмаган килеш калган. Аның янында әниемнең фоторәсеме эленеп тора иде. Кызганыч, рәссамнар аның яшь чактагы портретын ясарга өлгермәгәннәр. Ул беркайчан да гүзәлләрдән саналмаган, әмма аның саргылтзәңгәр күз карашларында, азрак калку сыртлы борынында, нәфис сызыклы нечкә иреннәрендә тумыштан килгән затлылык сизелеп тора иде. Яшьлегендә аны бик тә мөлаем, шат күңелле һәм бераз гына кыланчыграк булган, дип сөйлиләр. Хәким ага Сәлимҗанов шулайрак сөйли иде. Әниемнең балалык чорлары узган Орск шәһәрендә алар бергәләп һәвәскәрләр сәхнәсендә уйнаганнар. Аның тавышы әллә ни көчле булмаса да, матур тембрга ия

булган. Лирик-драматик сопранодыр, мөгаен. Әнием сәхнәдә үзен иркен хис иткән. Шуңа күрә дә Габдулла Кариев үзе әниемнең әтисен — Орск халык училищесы директоры Хәйреланам Мансуровны кызын актриса итәргә күндермәкче булып караган. Ләкин, бик алдынгы карашлы кеше булуына да карамастан, бабам әниемне сәхнәгә җибәрмәгән.

Мин исә әнине бөтенләй бүтән кеше буларак белдем: сабыр, басынкы, йомыграк холыклы иде ул. Үз гомерендә күп кайгылар кичерергә язган аңа: әтисе һәм ире бик иртә үлеп киткән, икенче тапкыр кияүгә чыгып уңмаган, утызынчы елларда күп туганнарын һәм якыннарын югалткан...

Әтисе ягыннан ике агасы да — бертуган Мансуровлар Татарстанның беренче халык комиссарлары булганнар. Аларны 30 нчы еллар башында ук «халык дошманы» дип игълан иткәннәр. Ул еллардагы күпләгән күренекле кешеләр шикелле үк, алар да — яшьтән үк үзләрен революциягә багышлаган большевиклар — серле рәвештә юкка чыкканнар.

Гөлчирә Такташева-Мансурованың Алабуга педагогия техникумында, Ленинградтагы интернат-мәктәптә, рабфакта бергә укыган якын дуслары да берәм-берәм гаип булганнар. Алар арасында зыялы гаилә балалары гына түгел, ә бәлки иң ярлы катлаулардан чыккан кешеләр, элеккеге батраклар, халык арасыннан күтәрелеп, республиканың югары урыннарында эшләгән талантлы шәхесләр дә бик күп булган.

Такташның вафатыннан соңгы чорларда әнием микробиология, генетика белән шөгыльләнә башлаган һәм Казан университетының медицина факультетыннан биология факультетына күчкән. Россиянең генетика мәктәбе чәчәк аткан чорлар була бу. Такташева үзенең дипломын тәмамлап килә. Аны аспирантурада калдыру мәсьәләсе карала. Нәкъ шул вакытта профессор Ливанов җитәкчелегендәге генетика кафедрасын кулга алалар. Соңыннан профессорны ирекkә чыгаралар чыгаруын, әмма кафедраның яшь галимнәре — аларның күбесе Мәскәү университетын тәмамлаган була — бүтән кире әйләнеп кайтмыйлар. Хәтта лысенкочылык шашып тантана иткән чорларда да әнием аларны намуслы, иманлы һәм талантлы кешеләр итеп искә ала, сагына иде. Ул алар белән бергә Ак диңгезгә, Карелиягә экспедицияләргә барып йөргән. Аны инде ул көннәрдә үк классиклардан саналган мәшһүр шагыйрьнең тол хатыны булу гына бу афәттән коткарып калган. Ни үкенеч: әнием бүгенге мәкаләләрнең, Дудинцевның «Ак киемнәр» әсәренең якты дөньяга чыккан көннәренә кадәр яши алмады. Ә ул көннәрдә эни фәннән киткән һәм мәктәптә балалар укыта башлаган...

Әни мәгърур түрәләрдән, аларның хатыннарыннан һәрвакыт читләшә иде. Аның азмыкүпме дуслары арасында гади укытучылар, исем-дәрәҗәләрсез язучылар, врачлар гына булган. Аның каравы, чын мәгънәсендә зыялы, рухиятле кешеләр булган алар. Кызганычка каршы, аларның барысы да мәгърифәт һәм мәдәният өлкәсендә ул чорларда хакимлек иткән эшлеклеләрнең җимергеч надanлыгы, тупаслыгы каршысында яклаусыз, чарасыз калганнар. Ә андый түң маңгайлар 37 нче елгы югалтулардан һәм Бөек Ватан сугышыннан соң гөмбә шикелле үрчегәннәр. Әле дә хәтеремдә: үпкәм шешеп, туберкулез мәсьәләсендә шик тугач, әнием мине каратырга үзенең күптәнге танышы — Гадел Кутуйның хатыны Галимә апа Кутуеваны чакырган иде. Холыклары бөтенләй төрле булса да кайчандыр бик якын дуслардан тол калган ике хатын төнгә кадәр сөйләшеп утырдылар. Хатирәләре авыр, моңсу... Ул чагында да тормышлары бик рәхәттән түгел иде шул аларның.

Әмма без тагын Шагыйрь бүлмәсенә әйләнеп кайтыйк әле. Әнием ягыннан абыем өйдән чыгып киткән чакларында һәрвакыт искәртә иде: «Минем бүлмәгә керәсе булма!» Әмма, борынгылар әйтмешли, тыелган җимеш татлырак була шул. Баскычта аның аяк тавышлары тынарга да өлгерми, мин — серле бүлмәдә! Өстәл һәм кресолдан тыш, каккалап-суккалап кына, дигәндәй кучкыл агачтан ясалган зур шкаф кызыктыра иде мине. Шыплап китаплар тутырылган аңа: Гоголь һәм Марк Твен, Шекспир һәм Лопе де Вега, Сервантес һәм Гофман — кыскасы, үзе бер дөнья! Арада Шагыйрьнең шәхси китаплары да бар: латин шрифтында басылган Һейне, куе-кызыл тышлы Ленин, 20 нче елларда чыккан Есенин, Брюсов, Блок, Маяковский... Гарәп шрифтында басылган китаплар бик күп. Мин гарәп хәрефләреннән җемелдәп торган журналларны актарырга ярата идем. Нинди генә көлкеле рәсемнәр юк иде анда! Карикатураларның күбесе Такташның үзенә багышланган: Шагыйрь лото уйный, Шагыйрь газеталардан тегелгән кием киеп алган... Мин моңа бик тә гаҗәпләнә идем. Әнием исә миңа аңлатып бирә: Шагыйрь үз гомерендә тәнкыйтьчеләрдән, күнче әдипләрдән күп тукмалган, газеталарда аны кем дип кенә атамаганнар! Әмма аны студентлар, крестьяннар, эшчеләр яшь зыялылар яраткан. Әнием сөйләвенчә, шул ук тәнкыйтьчеләр Шагыйрь үлгәннән соң аңа мәдхия җырлаганнар. Зур Шагыйрь иҗатыннан үзләренә исем даулаганнар. Кайчандыр шушы бүлмә тәрәзәсеннән Шагыйрьгә хәтта атканнар да. Әмма Такташ язмышка ышанган һәм өстәлне тәрәзә янынннан күчермәгән. Гомумән, ул үзенең иртә янып бетәсен алдан сизгән...

Такташ ачу саклый белмәгән, юмарт күңелле, азат җанлы булган, бик авыр чакларында да беркем алдында да баш имәгән. Нахак тәнкыйтькә дә шактый тыныч караган. Хәер, аның ваклыгына, сайлыгына, теләсә

нинди ярлык тагарга әзер торуына еш кына гаҗәпләнә торган булган. Тәнкыйть аңа: я глобаль сәяси темага гына яза, дип, яки казлар темасына гына күчте, Такташ үлде, дип кычкыра торган, ә Шагыйрь татар шигърияте өчен яңа юллар эзләвен дәвам иткән.

Пушкин шикелле үк, аңа да өлгергәнлек чоры балкышына кадәр үк барып җитү насыйп булмаган. Такташ 31 яшендә үлгән, әмма күпме эшләп өлгергән!

Шигырьләр өчен аз түләгәннәр һәм Такташ үзенең акчасызлыгы өчен яшь хатынының бик ояла торган булган. Бервакыт әбием үзенең Ленинградтагы ике улыннан — Рәшит белән Камилдән акча алган. Такташ моңсуланып әйтеп куйган: «Ә менә мин үземнең Сыркыдыдагы әниемә берни дә җибәрә алмыйм!..» Ул чакта Такташның дуслары әлләни күп булмаган. Бу хәл Шагыйрь вафатыннан соң бигрәк тә сизелде. Шагыйрьнең үзеннән соң пәйда булган «дуслары»на карата әни һәрвакыт тыенкы булды, аралашмаска тырышты. Әмма Такташка иң якын кешеләрнең берсе Туфан сөргеннән акланып кайткач, сөенеченең чиге булмады.

Үзенең әйтүенә караганда, Туфан иң башлап дустының йортына килгән. Чәчләре тәмам чаларып беткән, өстендә соры костюм. Шул кыяфәтендә ул гаять нәзакатьле һәм күркәм иде. Ул элекке замандагыча, иелеп, әниемнең һәм минем — беренче курс студенткасының — кулларын үпте. Шагыйрь чорыннан, вакыт төбеннән кетмәгәндә пәйда булган могҗизага карагандай карап тордым мин аңа. Икенче мәртәбәсендә ул безгә Галимҗан Нигъмәтинең тол хатыны Җиһан ханым Нигъматн белән бергә килде. Хатирәләргә күмелделәр, күз яшьләре дә күренде...

Тиздән Язучылар съезды булып узды. Анда Хәсән Туфанны сәламләделәр. Шунда өч язучының исеме атап әйтелде (әгәр аларны язучы дип әйтергә яраса!). Талантлы һәм намуслы кешеләр өстеннән донос язып ятканнар икән алар. Алар мактаулы пенсиягә чыктылар һәм берсе дә үзенең котсыз эше өчен җавап бирмәде...

Такташ исән булса, иң беренчеләрдән булып кулга алыныр иде, дип сөйләгәнен хәтерлим әнинең. Шагыйрьнең ачык күңелле, туры сүзле, азат фикерле һәм талантлы булуы бюрократларның, мещаннарның һәм тар карашлы бәндәләрнең һәрвакыт җанына тиде, дип әйтә иде ул.

Җиһан ханымның съездда үксеп елаганын хәтерлим. Аның ире ялганны үз имзасы белән раслауга караганда, ачтан үлүне хәерлерәк күргән. Җиһан ханымның үзен озак вакытлар буена берниндн эшкә дә алмаганнар һәм ул үзенең ике баласы белән бергә ач-ялангач килеш җан асрарга мәҗбүр булган.

Безнең өйдә, нишләптер, күбесенчә, рус телендә сөйләшәләр иде. Әнием һәм әбием хәзерге һәм борынгы татар телен бик яхшы беләләр иде, югыйсә. Соңыннан, бу мәсьәләдә миннән үпкәләп әйтелгән сүзләр ишеткәч, әнием аңлатып бирде: Галимҗан Ибраһимов белән бергә аның туганнары да бәлагә юлыккан икән. Әтием исә әдипнең дусты булган. Шуңа күрә ул вакытта борынгы татар әдәби телен өйрәнү гаиләне игътибар үзәгенә куйган булыр иде...

Гаҗәеп җепләр бәйли чорларны! Минем әтием Гыйндулла Кодрәтов, үз заманында гражданнар сугышының чая комиссары булarak, Фрунзе, Блюхер җитәкчелегендә басмачыларны тар-мар итеп йөргән. 30 нчы еллар башында, Шамил Усманов кебек гражданнар сугышы каһарманнары юк ителә башлагач, ул куркынычсызлык органнарыннан киту җаен табып, котылып кала. Югыйсә, ул кеннәрдә Уралда, Идел буенда, Урта Азиядә Совет властен урнаштыруга үз вакытында зур көч куйган кешеләрне буржуаз милләтчеләр итеп игълан итәргә тотынган булалар. Намусын саф килеш саклап калган хәлдә, Гыйндулла Кодрәтов үзенең данлы үткәненнән баш тарта. Элеккеге чекист Кодрәтовны юрист Кудрецкий алмаштыра. Ахыргача нык тора алмаганнары өчен без аларны гаепләргә тиеш түгелбез. Әнием әйткәнчә, әти үзенең калган бөтен гомерен «үзе теләп алган сөрген»дә — Ерак Көнчыгышның яшәү өчен ифрат кыен булган төбәкләрендә уздырган. Гөлчирә Такташеваны һәм Геннадий Кудрецкийны һәр икесе кичергән югалтулар якынайткан, әмма Шагыйрь рухы хакимлек иткән фатирда әти яши алмаган: залда да, йокы бүлмәсендә дә дивардан Шагыйрьнең акыллы һәм моңсу карашын тою аның өчен гаять авыр булган. Әни Шагыйрьне калдырып ерак китә алмаган, әти исә монда үзен чит кеше итеп сизгән. Ниһаять, август аеның бер көнендә ул үзенең Сахалиндагы дуслары янына бөтенләйгә китеп барган. Ә без әнием белән икебез әлеге мемориаль фатирда яшәп калганбыз. Аннан соң әти безне берничә тапкыр Сахалинга да, Николаевск-на-Амуре шәһәренә дә чакырып карады. Ләкин Шагыйрь җылысын саклаган диварлар әниемне ахыргача беркая да җибәрмәде.

...Толымнарын нечкә генә итеп үргән ябык бер кызый креслода утыра. Бүлмәдә серле зәңгәрсу эңгер. Еллар томаны үтәли мин аны аермачык күреп торам шикелле. Абый бүлмәне үтә дә тәртипле итеп тота, һәрнәрсәне шүрлекләргә тезеп, капларга тутырып куя. Миңа исә Шагыйрь үзе исән чакта барысы да бүтәнчә булгандыр сыман тоела. Кәгазьләрне өстәлгә таратып ташлыйм, шкафтагы китаплар диванга, караватка күчә... Кайчакларда вакытка җан кергән сыман тоела башлый: бүлмәдә шигырь юллары, хәтта шигырьләр үзләре очып йөри сыман булып китә... Менә хәзер портретка җан керер дә, Шагыйрь, кысалардан кубып, урыныннан кузгалыр төсле... Әмма... ишек катында абыйның сукранганы ишетелә. «Җинаять» эзләрен тиз генә бетерергә кирәк! Тылсым юкка чыга...

Әмма ул минутлар гомерлеккә истә калдылар.

Еш кына безнең фатирга бөтенләй таныш түгел кешеләр килә иде. Алар шагыйрь иҗат иткән эш бүлмәсен күрсәтүебезне үтенәләр. Без моңа бер дә гаҗәпләнми идек: Шагыйрь тормышына орынып карау тылсымын бүтән берни белән дә алмаштырып булмый лабаса! Шагыйрьнең йорты, аның китаплары, әйберләре — барысы да иҗатның үлемсез серенә кагылышлы бит...

Әмма Шагыйрь яшәгән урын ул эш бүлмәсе белән генә чикләнми. Бүлмә ишеге залга чыга. Урта бер урында Һади Такташның тагын бер портреты тора. Кайчакларда ул, өйдәге хәлләрне күреп, бераз киная белән генә елмаядыр шикелле тоела иде. Залдагы искиткеч матур өстәлнең аяклары Екатерина II чорындагыча нәфисләп, бөгеп ясалган. Диван аркасына да шундый ук нәфис бизәкләр уелган. Шунда ук фигуралап эшләнгән тумбочка. Анысы Такташның азмы-күпме акчалы чагында яшь хатынына — студенткага алып биргән гарнитурдан. Тагын иДәннән түшәмгә кадәр җиткән көзге бар иде. Кысасы чикләвек агачыннан уеп ясалган. Көзгенең бәләкәй өстәлендә бик нәфис фаянс ваза утыра. Бусы да Шагыйрь бүләге. Кыскасы, залда да Шагыйрь рухы, әни әйтмешли, «Һадый» рухы яши иде.

Тагын Такташның атынмалы урындыгын искә алып үтәсем килә. Кучкыл агачтан ясалган бу зур урындык та баштарак эш бүлмәсендә торган, соңыннан аны зур бүлмәгә алып чыкканнар. Шагыйрь үлгән чакта анда чиратлашып шәфкать туташы, әни, әби утырып торган. Ә без исә сугыштан соңгы фатирларда бик сирәк очрый торган шундый реликт җиһазда рәхәтләнеп атына идек. Кайчакларда чөйкәлеп барып төшә идек тә, тагын атына башлый идек...

...Элеккеге Рыбноряд, хәзерге Куйбышев урамында ул 37 нче йорт юк инде. Андагы фатир да, Шагыйрь үзенең «Гасырлар һәм минутлар» поэмасын иҗат иткән эш бүлмәсе дә юк... Такташның кайбер өй җиһазларын музейга тапшырганнар. Мин бервакыт очраклы рәвештә генә шунда күңелемә гаять тә якын булган язу өстәлен һәм креслоны күрдем. Алар галәмәт зур залның биек диварына ятимнәр шикелле сыенганнар. Алар монда чит-ят... Аларның беркемгә дә кирәге юк... Яраткан, якын кешеләремне кызганган шикелле кызгандым мин аларны. Шагыйрь рухы, Шагыйрь җаны сүнгәндер сыман тоелды аларда... Һәм балачактан ук җаныма сеңгән ул әйберләрне бер түбә астына җыясым килде. Куйбышев урамында бер үк төрле итеп салынган сәүдәгәр йортларының барысы да сүтелеп бетмәгән ләбаса! Нариманов урамында шагыйрьнең сеңлесе Хәнифә ханым озак еллар буена гомер иткән элекке йорт та исән бит әле. Истәлекле әйберләрне шунда тупларга да мөмкин булыр иде. Бәлки, Һадиның хөр рухы аларга кабат кайтыр иде...

Бәлки... Шагыйрьнең бер генә байлыгы булган. Ул да булса — халык мәхәббәте. Халык аны үзенең җырчысы итеп тойган, аның белән горурланган. Такташ үзе беркайчан да эшчеләрнең «үз агайнесе» булып кыланырга яратмаган (югыйсә ул чагында андыйлар да җитәрлек булган!). Шигъри рухы, илһамы белән матур булган ул. Чибәр, күркәм итеп киенеп йөрергә яраткан. Шуның өчен совбюрократлар аны «буржуй иярчене» дип сукканнар. Әмма гади кешеләрнең сизгер күңеле Шагыйрьнең илаһиятын, хакыйкатен бик дөрес тойган. Рухи затлылык ягыннан ул Блокка тартым...

Һади Такташны соңгы юлга бөтен Казан озата барган. Алар арасында татарлар гына түгел, руслар, чувашлар, поляклар да атлаган. Чын мәгънәсендә милли шагыйрь бәйнәлмиләл шагыйре дә булган.

Минемчә, әле шәхси әйберләре исән чагында революция җырчысы Һади Такташның яшәгән мохитен терелтергә вакыт җитте. Ул мохитне бөртекләп хәтерләүче кешеләр дә әлегә исән.

Менә шул чакта утлы җырлар иҗат иткән бунтарь шагыйрьнең бөек рухы безгә тагын да якыная төшәр иде. «Гасырлар һәм минутлар», «Киләчәккә хатлар», «Алсу», «Мокамай», «Урман кызы» иҗат ителгән чорларны кире кайтарып булмый. Әмма алар дөньяга килгән мохитне терелтергә, мәңгелек өчен сакларга мөмкин. Әле соң түгел.

**Эльвира КУДРЕЦКАЯ**

# Гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку-язу

## Сигезенче дәрес

Иске татар телендәге борынгы кульязмаларны уку-өйрәнү дәверендә гарәп язуының төрләре турында да азмы-күпме мәгълүматлы булу сорала. Чөнки язу төрләре турында иң кирәкле мәгълүматлардан да хәбәрсез булган очракта кульязмаларны дөрес уку мөмкин түгел.

Гарәп язуының тарихы гаять бай һәм тирән эчтәлекле. Бу язуның иң әүвәл үсеш алып, башка өлкәләргә тарала башлаган җире Сәгуд ярымутравының көньягы. Ул гарәпләр арасында ислам дине тарала башлаганчы ук кулланышта була.

Гарәп язуының ике төп төре — куфи һәм нәсех. Алар чама белән бер үк вакытта барлыкка килә. Куфи төре нигездә сынган туры сызык рәвешендә булуы белән аерылып тора. Бу монументаль характердагы язуда түгәрәк һәм туры элементларның нисбәте гарәп каллиграфиясендә кагыйдә итеп алынган масштаб буенча 1:5 рәвешендә (соңрак иҗат ителгән нәстәгълик төрендә бу нисбәт 5:1 тәшкил итә). Нәсех исә күбрәк тиз язуга көйләнүе сәбәпле башкарак рәвеш алган. Баштарак чорларда куфи язуында нокталар да, хәрәкәләр дә куелмый, аларны VII гасыр урталарыннан куллана башлыйлар.

Вакыт узу белән гарәп язуының яңа төрләре барлыкка килә. Аларны иҗат итү һәм камилләштерү өстендә гарәп дөньясының иң мәшһүр хаттатлары (каллиграфлары) Ибне Мокла, Ибне Бәүваб һәм Якут әл-Мөстәгъсими эшлиләр. Рәсми хатларның (почеркларның) «классик» дип йөртелгән «алтылыгы» формалаша: нәсех, сөлес, рәйхани, мохаккак, тәукыйгъ һәм рикъка. Соңыннан бүтән төрләр дә иҗат ителә: тәгълик, нәстәгълик, дивани, шикәстә һ.б. Гомумән алганда, гарәп язу стильләренең саны дистәләрчә.

Борынгы болгарлар арасына гарәп язуы якынча VIII-IX гасырларда, ислам дине белән бергә үтеп кереп тарала башлый һәм рун язуын кысрыклап чыгара.

Әлегәчә сакланган иң борынгы гарәп хәрефле болгар язулары 903—907 елларга карый. Алар — тәңкәләрдәге язулар. X гасыр ахырынача диярлек Болгар илендә сугылган бу тәңкәләрнең язулары куфи белән башкарылган. Археологик казулар вакытында табылган башка кайбер әйберләрдәге язулар да нигездә куфи стилендә. Ләкин бу куфи асылда башка мөселман илләрендә кулланылган стильгә иярә. Чын мәгънәсендәге «болгар куфие» дип аталырлык стиль XIII йөз азагы-XIV йөз башы кабер ташлары язуларында күзәтелә. Әлбәттә, ул да тамырсыз булмый, аның нигезендә X-XI гасырларда күчерелгән Коръән нөсхәләрендәге «кармат куфие» дигән исем астында мәгълүм булган стиль ята. Шулай да ташка уеп язучы болгар осталары бик үзенчәлекле куфи рәвешен барлыкка китерәләр. Шунысын да әйтергә кирәк: Болгар иленең төрле төбәкләрендә куфи кайбер үзенчәлекле сыйфатларга ия була.

Кабер ташлары шулай ук сөлес төре белән дә языла. Кайбер композицион үзенчәлекләр һәм детальләр җәһәтеннән ул Харәзем (Үргәнеч) «сөлес»енә тартым.

Алтын Урда дәверендә (XIII-XV йөзләр) җирле язу рәвешләренә яңа тенденцияләр һәм элементлар өстәлә. «Дүрткел куфи» исемле стиль мөһерләрдә кулланыла башлый. Ул шулай ук XVI гасыр Сәхиб-Гәрәй хан ярлыгында да урын алган. Ханнар диваныннан (канцеляриясеннән) чыккан ярлыклар дивани (җәли дивани) һәм сөлес белән башкарыла.

XV-XVI гасырлар тирәсендә гарәп графикалы милли язуыбыз яңа үсеш дәвере кичерә. Моны ташлардагы өсъязмалар һәм сакланып калган аерым

язулы кәгазь үрнәкләре мисалында күрергә мөмкин. Бу дәвердә сөлес һәм тәгълик стильләре өстенлек ала.

XVI гасыр урталарыннан алып, милли дәүләтчелегебез җимерелү сәбәбе белән, мәдәниятнең бер өлеше булган милли язу да торгынлык чоры кичерә, төгәлрәк әйткәндә, сәнгать төре буларак күздән төшә. Шулай да рухи тормыш дәвам итүдән туктамый, әлбәттә. XVII-XIX йөзләрдәге кулъязмалар төрле эчтәлектәге китапларны күчереп язу әдәбиятыбызның шедеврларын саклап калуга, рухи-мәдәни традицияләрне югалтмауга хезмәт итә. Әлеге кулъязмалар — язуыбыз тарихының беренче кул чыганаклары.

Кулъязмаларның сыйфаты хакында сүз йөрткәндә шуны истә тоту зарури: милли дәүләт булмау, идарәче һәм зыялы катлау вәкилләренең күпләп һәлак булып, юкка чыгуы һәм шул сәбәпле югары сәнгать дәрәҗәсендәге кулъязмаларга ихтыяҗның ифрат нык кимүе хаттатлар продукциясенең таралу мәйданын бик нык чикләгән. Әлбәттә, мондый шартларда югары дәрәҗәдәге, тиешле зәвык белән язылган китаплар юк дәрәҗәсендәге сирәк күренешкә әверелә. Әмма бу авыр шартларда да укымышлы кешеләр катлавы арасыннан шактый күренекле хаттатлар пәйда була: Илми Үтәмеш улы, Сәйфелмөлек Зәйнетдин улы, Кадермөхәммәт Шаяхмәт улы (XVII-XVIII йөзләр), Гобәйдулла Болгари, Әбу Шәрәф Болгари, Габделгафур Болгари, Мөхәммәтгали Мәхмүдов (XVIII-XIX йөзләр) һ.б.

Кагыйдә буенча, гарәп язуында һәр заманда камыш каләмнән файдалану өстен күрелә; бездә исә алда әйтеп үтелгән сәбәпләр аркасында, күбрәк каурый каләмне эшкә җиккәннәр. Ул исә камыш каләмнән һәрьяклап калыша.


Кулъязма китаплар һәм документлар төрле язу стильләре белән башкарылган. Иң еш кулланылганнары — «нәстәгълик-шикәстә» (гадәттә аны «нәстәгълик» дип кенә йөртәләр) һәм Коръәннәр күчерү өчен үрнәк саналган «нәсех». Сирәгрәк «сөлес» һәм «шикәстә»дән файдалану да күзәтелә. Күп кенә кулъязмалар үтә дәрәҗәдә индивидуаль стильле булып, аларны төгәл сыйфатлау мөмкин дә түгел.

Күпчелек кулъязмаларның йөзен билгеләүче язу төре — «нәстәгълик-шикәстә». (Бу терминның мәгънәсе болай: язу асылда нәстәгълик булса да, аңа сизелерлек дәрәҗәдә шикәстә элементлары кушылган). Аның өстенлек итүе, әлбәттә, һич очраклы түгел. Нәстәгълик, XIV гасыр азагыннан тизлек белән тарала башлый, Иран, Азәрбайҗан, Урта Азияне яулап ала. Билгеле булганча, Урта Азия дәүләтләре һәм Болгар йорты арасында тыгыз элемтәләр борын заманда урнашкан. Каллиграфик информация XVII-XVIII гасырларда да безнең җирләргә Урта Азиядән килә. Анда исә XV-XIX гасырларда бөтен кулъязмалар диярлек (Коръән күчермәләреннән башка) нәстәгълик белән башкарыла. XVII-XVIII йөзләрдә бу стиль инде әкренләп «нәстәгълик-шикәстә»гә әверелә. Шуны искәртү зарур: татар хаттатлары, Төркиядәге традициягә ияребрәк, бу стильне «тәгълик» дип кенә йөрткәннәр.


Әһәмияте буенча кулъязмаларыбызда икенче урын биләүче стиль — «нәсех». Әмма ул да башлыча үзенең классик рәвешендә түгел, ә бәлки башка төр язу (нигездә, нәстәгълик, сирәгрәк куфи) элементлары белән баетылган хәлдә кулланылган. Бу стиль — нәсех — күпмедер дәрәҗәдә XIX йөз башында Казанда басма гарәп шрифтына нигез була.

Инде безнең Идел буенда таралыш тапкан кулъязмаларга хас кайбер төп үзенчәлекләргә тукталыйк. Алар, кагыйдә буларак, тиз язуга омтылыш белән аңлатыла.

1) Күп очракта кайбер язылышларның гарәп графикасы кагыйдәләренә сыешмавы белән очрашырга туры килә. Мәсәлән, әлиф, даль, рә, зи, уау хәрефләре еш кына сульяк хәрефләргә кушыла.




2) Кайбер очракларда (бигрәк тә документларда) сүзне, гәрчә анда сулдан кушылмый торган хәрефләр булса да, тоташ итеп, каләмне кәгазьдән алмыйча язганнар:



3) Кульъязмаларда «кяф» шәкеле язылышының төрлелеге белән аерылып тора, мәсәлән:

ﻙ, ﻙ, ﻙ, ﻙ һ.б.

4) нун хәрефенә игътибар итәргә кирәк, аның да язылышы төрле рәвештә булырга мөмкин; гадәти ن шәкеле белән бергә ... яки ... вариантлары очрый;

5) ләм-әлиф бик еш ... формасында языла;

6) һи хәрефенең сүз башындагы вариантлары берничә:

... һ.б.


7) йай хәрефенең башкарылу нечкәлекләре аеруча игътибарга лаек: Төп шәкелләр түбәндәгечә: аерым — ..., ..., ..., ...; азакта — ..., ...

Иске язуыбыздагы янә бер мөһим үзенчәлекне нокта куелу рәвешләре тәшкил итә. Тиз язуда алар кәкре сызыкны хәтерләтә: ( ... = ∴ ) , йә хәрефкә тоташтырыла: ... (چ), ... (شا) һ.б.


Әлеге үзенчәлекләр, билгеле, кульъязма язуының сыйфатларын өлешчә генә күз алдына бастыра. Ләкин кимендә аларны да белми торып, кульъязманы уку шактый авыр. Күрсәтелгән шушы төп хосусиятләр укучыларыбызга кульъязмаларны укуда беркадәр ярдәм итәр дип ышанабыз.

## ЯЗУ ТӨРЛӘРЕ

### Болгар куфие



### Нәсех




Сөлес

طبع اولندی قزانده مطبعهٔ کریمیه‌ده

Нәстәгълик-шикәстә

Дивани



*Дәресләрне Җәүдәт Миңнуллин һәм*
*Рәшит Кадыйров алып бара.*



# *Татар халык музыка уен кораллары*

*Соңгы елларда халкыбызның традицион музыка уен кораллары белән кызыксыну шактый артты. Матбугат битләрендә басылып чыккан мәкаләләр, редакцияләргә килгән хатлар да шул хакта сөйли. Әлеге юнәлештә эзләнүче талантлы галимнәребез үсеп җитте (Мәхмүт Нигъмәтҗанов, Рәгъде Халитов, Шамил Монасыйпов, Валерий Яковлев һ. б.). Сәхнәләрдә һәм телевизор экраннарында сорнай, думбра, гөслә, тел курае, җәя-кубыз кебек сирәк очрый торган милли музыка уен коралларының күренә башлавы да аеруча сөендерә.*

*Республикабызның төрле төбәкләрендә бүгенге көндә дә шундый уен коралларын ясаучы осталарыбыз бар. Мәсәлән, Чүпрәле районында Хәйрулла Сөләйманов, Тәтеш районында бертуган Антоновлар, Алабуга шәһәрендә Илдус Салихов, Арчада Ринат Алмаев, Әгерҗедә Григорий Волков, Казанда Ифрат Хисамов, Салих Шәйдуллин, Хәйдәр Искәндәров, Геннадий Макаров һ. б. шундыйлардан. Түбәндәге язмада музыка уен коралларының эшләнеше, сызымнары шушы осталарның өйрәнүләре һәм язма истәлекләре буенча бирелә. Киләчәктә дә бу юнәлештә эзләнүләр дәвам итәр дип ышанабыз, чөнки әле халык музыка уен коралларының бик азы гына өйрәнелде.*
*Бу яңа рубрикадагы язмалар милли уен коралларын үзлегеңнән ясау, аларда уйнарга өйрәнү максатыннан тәкъдим ителә.*

## ДУМБРА ҺӘМ САЗ

Думбра — борынгы болгарлар, ә инде соңрак казан татарлары арасында аеруча киң таралган уен коралы. Моны күп сандагы тарихи истәлекләр, галимнәребезнең хезмәтләре һәм халык авыз иҗаты әсәрләре дә раслыйлар.

1768—1839 елларда яшәгән күренекле татар шагыйре һәм галиме Таҗетдин Ялчыгол әл-Болгари кульязмаларының берсендә шул чорда Казан татарлары арасында киң кулланылган дүрт төрле музыка уен коралы: 24 кыллы гөслә, думбра, скрипка, әрилә (ягъни тәгәрмәчле лира) турында бик тәфсилләп яза һәм сызымнарын да сызып калдыра. Сызымыннан күренгәнчә, борынгы думбра — өчпочмаклы, озын саплы, ике кыллы уен коралы. Аның 7—8 лады булган.

Вафа Бәхтияров Сембер (хәзерге Ульяновск) яклары этнографиясенә багышланган кульязмасында авылдан-авылга, думбра сугып, такмак әйтеп, аю биетеп йөрүче татарлар турында язып калдыра.


Соңгы елларда татар думбрасының көндәлек кулланылышта булмавы, аның киләчәгенә үзен бик нык сиздерә башлады. Шуңа күрә дә кайбер энтузиастлар думбраны үзлегеннән ясый һәм аңарда уйнарга да өйрәнә башладылар. Моннан бер-ике ел элек Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты гыйльми хезмәткәре Геннадий Макаров беренче тапкыр яңадан татар думбрасын ясый һәм аңарда уйнарга өйрәнә. Инде хәзер думбра Казан шәһәре Сәүдә хезмәткәрләре культура йортының «Сорнай» фольклор ансамблендә һәм аерым уйнаучылар арасында да күренә башлады.

Думбраның тавышы көчле, йомшак. Тембры — күңелгә ятышлы, ягымлы. Уйнау мөмкинлекләре чикләнмәгән.


Думбра ясау өчен матералны агач суты ага башлагач, май аенда хәзерли башлыйлар. Агач кәүсәсен 3—4 мм калынлыкта балта белән телергә кирәк. Әзер такталарны 1 айдан 2 елга кадәр кояш төшми торган коры, җиләс урында киптерәләр. Аннан соң балта, ышкы яки өтерге белән юнып калынлыгын 2—3 мм га калдыралар.

Козау (кузов)ның ян-як һәм аскы такталары өрәңге агачыннан, ә өске тактасы

ак чыршы агачыннан ясала. Өске тактага диаметры 1,5 см лы тавыш тәрәзәсе тишелә. Боргычлар, күтәртмәләр каты агачтан (каен, алмагач, имәннән) төрле рәвешләрдә ясала. Думбраның сабын өрәңге, алмагач яки каеннан ясыйлар. Аның козауга тоташкан урыны түбәндәге рәсемдә күрсәтелә.




Думбраны җыйнау түбәндәге тәртиптә башкарыла: башта коры, калын агачтан думбраның калыбын эшлиләр.




Калып ярдәмендә думбраның сабы белән арткы стенасына аскы тактаны тоташтыралар, ә аннан соң ян такталарны калыпка кысып беркетеп яки бәйләп куялар.


Тиешле зурлыкта алдан ук хәзерләп куелган такталарны ябыштыру өчен агач яисә казеин җилеме кулланалар. Биш-алты сәгать кипкәннән соң калыпны алалар һәм өске тактаны ябыштыралар. Тагын кысып бәйләп биш-алты сәгать киптерәләр.





*Думбраның үлчәмнәре. Сызым Г. Макаров ясаган думбра буенча бирелә.*

Әзер думбраны бер-ике көн кипкәннән соң бик яхшылап агачның үз төсе калганчыга кадәр чистарталар, шомарталар һәм кайнамаган салкын суга изеп хәзерләнгән сыек көрән төстәге материя буявы белән буйыйлар. Аның өстеннән төссез лак белән лаклыйлар һәм бер-ике көн җил керми торган, коры, 17—20 градус җылылыктагы бүлмәдә киптерәләр. Лак тигез, матур төшмәсә ике-өч тапкыр шул тәртиптә кабатларга була.

Ладларны грифка 0,6 мм лы капрон җепне чорнап ясыйлар. Аның өчен ике метрлап парлы капрон кыл алына. Аның бер башын грифның боргычлар урнашкан күтәртмә төбеннән ныгытып бәйлиләр һәм гриф буйлап козауга таба үрә башлыйлар.



Барлыгы 14—16 лад булырга тиеш. Лад араларын төгәл урнаштыруга аеруча игътибар итәргә кирәк. Чөнки тавышны дөрес көйләү уен коралының сыйфатын билгели.




Лад араларының үлчәме якынча бирелә.


Тарттырылган кылның калынлыгына һәм нинди материалдан булуына карап ул үзгәрергә дә мөмкин.

Аннан соң кылларны кирәкле тавыш югарылыгына тарттырып көйлиләр. Кыл урынына 0,8—0,9 мм лы кармак җебе файдаланырга була. Астан беренче кыл — беренче октаваның соль тавышына, өстәге кыл — беренче октаваның ре тавышына көйләнә. Әгәр дә кыллар дөрес тавыш югарылыгына тарттырылган булса, беренче кыл белән өстәге кылның бишенче лады тавышлары буенча тәңгәл килергә тиеш. Әгәр тавышлар тәңгәл килмәсә козау өстендәге күтәртмәне шудыртып көйләргә кирәк. Ике күтәртмә арасы 66 см булырга тиеш.

Думбрада утырып та, баскан килеш тә уйныйлар. Ике кылны да тигез итеп имән бармак белән дә, берьюлы дүрт бармак белән дә өстән-аска, астан өскә таба сугалар. Уйнаганда уң кул чугы беләзектән аз гына уйнаучыга таба бөгелгән була һәм өстән аска кул чугы гына йөри. Уйнау алымнарын, төрле штрихларны көйнең характерына карап уйнаучы үзе сайлый.

Әйтеп киткәнчә, думбраны сугып уйныйлар. Ул җырларны, бәетләрне, мөнәҗәтләрне көйләп укыганда, шулай ук төрле зурлыктагы ансамбльләр, оркестрлар составында аккомпонемент буларак кулланыла.

Думбрага охшаш тагын бер халык музыка уен коралы белән танышып үтик. Ул — саз дип атала. Сазда гадәттә көйне думбрадан аермалы буларак медиатор белән чиертеп уйныйлар.



Саз — төрки сүз. Ул халык арасында ике мәгънәдә кулланыла: беренчесе — музыка уен коралы, икенчесе — тавыш, яңгыраш, ягымлы көй. Мәсәлән, Нәкый ага Исәнбәт:

*Моңланып ай нурларында*
*Син сазыңны уйнадың;*
*Нинди кыллар чиртте, бәгърем,*
*Ул матур яшь кулларың?...*

— дип, уен коралы турында яза.

Саз элегрәк Болгар илендә, соңрак казан татарлары арасында киң кулланылышта булып, хәзергесе вакытта төрле сәбәпләр аркасында Татарстан җирендә бөтенләй кулланылыштан төшеп калган. Читтә яшәүче татарлар арасында сазны хәзер дә очратырга мөмкин. Мәсәлән, Кырым, Әстерхан татарлары, Үзбәкстанда, Дагстанда, Азәрбайҗанда яшәүче татарлар арасында саз хәзер дә киң кулланылышта. Мәскәү шәһәрендә М. Глинка исемендәге халык музыка уен коралларының Дәүләт музеенда сазның татарлар яшәгән төрле төбәкләрдән җыелган берничә төре саклана.

Саз ике өлештән тора. Сап өлеше һәм козау (кузов) өлеше. Ясау өчен материалларны нәкъ думбра ясагандагы кебек хәзерлиләр. Халык арасында яшәүче осталар сазны ике төрле ысул белән ясыйлар. Беренче ысул — сап өлеше дә, козау өлеше дә тоташ агачтан чокып ясала. Икенчесе — һәр ике өлешне аерым-аерым ясап, җилем белән ябыштыру.

Беренче ысул: 90 см озынлыктагы кипкән өрәңге агачыннан сазның формасын ясыйлар. Сап өлеше бик калын булмасын, сул кулның уч төбе иркен йөрергә тиеш. Козау (кузов) стеналары 2—3 мм калынлыкта ясала һәм бик яхшылап шомартыла.

Икенче ысул: Алдан козауның билгеле үлчәмдә калыбын эшләргә кирәк. 2—3 мм калынлыктагы билгеле бер формадагы һәм үлчәмдәге такталарны хәзерләп куялар. Өрәңге агачыннан ясалган әлеге такталарны кайнар суга салып пешеклиләр һәм бөгәләр. Аннан соң калыпка козауны (кузовны) җыйный башлыйлар.

Козауның (кузовның) өстенә ак чыршы агачыннан ясалган 2 мм калынлыктагы такта куялар. Уртасына резонатор өчен тактаны тишеп бизәк төшерәләр. Сазның ике күтәртмә арасы 60 см. Өстендә 12—16 лад урнашкан. Ладларны 6 мм лы парлы капрон кыллар белән үреп яки металл пластинканы иңдереп эшлиләр. Лад араларының үлчәме думбраныкы кебек.

Сазга ике металл кыл тарттырыла. Кылларны парлап та тарттырырга була.

Астан беренче кыл, беренче октаваның ре тавышына өстәге кыл кече октаваның соль тавышына көйләнә.

**Ринат ГЫЙЛАҖЕВ,**
Татарстан АССР Культура министрлыгы
фәнни-методик үзәгенең музыка секторы мөдире.

# ГАЛИМ АРХИВЫ — ХӘТЕР САНДЫГЫ

Бүгенге көндә тарихның «ак тапларын» бетерү мәсьәләсе бөтен кискенлеге белән калкып чыкты. Әдәбият һәм культура өлкәләрендә дә тарихның бик күп сәхифәләрен яңадан язып чыгу сорала. Әмма моны әйтүе генә җиңел. Ничек язарга аны, нинди мәгълүматларга, чыганакларга ышанырга һәм таянырга? Үзгәртеп кору турындагы документларда тарихны яктырткында халык хәтерен, акылын һәм тәҗрибәсен нигез итеп алырга кирәклеге бик ачык әйтелә. Димәк, без дә моңа кадәр кул тимәгән язмаларны: истәлекләрне, хатларны, көндәлекләрне, биографик һәм башка документларны җыярга, яңабаштан барлап, бәяләп чыгарга тиешбез, аерым шәхесләрнең тарихи кыйммәтле хатирәләрен язып алу, бастырып чыгару эшенә җитди игътибар бирергә тиешбез.

Бу юнәлештә эшләүче иң актив авторларның берсе Хәсән Гобәйдуллин. Сәнгать фәннәре кандидаты, театр белгече буларак күпләргә таныш бу өлкән кеше хәтерендә нинди генә кыйммәтле мәгълүматлар юк. Яшь чаклары Уфа культура учакларында үткәнгә, Казанга килгәч музыка һәм театр дөньясында кайнаганга, аның күргән-белгәннәре милли мәдәниятебезнең әлегә кадәр беркая да теркәлмәгән кыйммәтле сәхифәләре булып торалар. Еллар үтә тора, ә шуларны язып алучы, тарихка теркәп куючы табылганы юк әле. Кызганыч, бездә андый язып алынмаган байлыклар гомумән күп. Аспирантларны, студентларны мәҗбүри таләп куеп, шундый хатирәләрне яздыруга тарту гаять актуаль бурыч. Журналистлар, туган як тарихы белән кызыксынучы укытучылар, укучылар мондый хатирәләрне түкми-чәчми, үзгәртми-шомартмый гына язып алырга, кыйммәтле факт-хәбәрләр итеп саклауны кайгыртырга тиешләр. Бу яктан Хәсән Гобәйдуллин эшчәнлеге гыйбрәтле. Тарихи документларны ул ерак шәһәрләрдән, авыллардан да эзләп таба. Аларның кадерен белгәнгә, үзенә хат белән дә җибәрәләр. Аның архивындагы йөзләгән шундый документларның кайберләренә укучының игътибарын юнәлтик.

Мәсәлән, Бишенче елгы революция вакыйгаларына багышланган «Беренче таң» һәм башка сәхнә әсәрләре авторы Габ-



делрәүф Ниязбаев (1881—1920) тормышы һәм иҗаты турында яңа документлар, фото. Бу фоторәсемдә ул хатыны Мәхбүбә ханым белән.

Тарихи документ буларак, Г. Ниязбаевның Беренче революцион армиянең политбүлегенә пьесасын тапшыру турында «Обязательство»сы игътибарга лаек. Политбүлекнең пьесага тулы хокук алуы, авторлык хокукы мәсьәләсенең торышын күрсәтә торган кызыклы гына документ бу.

Х. Гобәйдуллин бу язучыбыз иҗатын һәм биографиясен өйрәнү буенча күптәннән эшләп килә иде. «Казан утлары» журналының 1967 ел 4 санында ул чыгарган тарихи-биографик документлар шуның дәлиле. Бу яңалары шуларны тагын да тулыландыралар.

Галим архивында артист һәм беренче

татар театрын оештыручы Ильяс Кудашев-Ашказарский эшчәнлегенә караган бик мөһим документлар бар. Бу фидакарь театр эшлеклесенең моңа кадәр басылмаган фотопортреты да игътибарны җәлеп итә.



*И. Кудашев-Ашказарский*

Мәгълүм булганча, И. Кудашев-Ашказарский театрының үзенчәлекләреннән берсе — аның музыкаль театр булуы. Шуңа күрә ул татар музыкасы проблемаларын кузгатмый кала алмаган. Татар җыр-көйләрен, моңнарын пропагандалаганда мәсьәләгә бик җитди карашы бүген дә гыйбрәтле. Ул татар музыкасын яздырып алучы, грампластинкада уйнату мөмкинлеге табылды дип тиз генә ризалашмый. Аны сыйфат мәсьәләсе борчый. Шуңа күрә һәртөрле халтурадан саклану чараларын күрә.



*В. Апанаев*

Бу архивта татар халкының фидакарь артистлары тормышы һәм иҗаты турындагы материаллар аеруча күп. Менә атаклы «Шәрык клубы» кыллы оркестрының дирижеры Вәли Закир улы Апанаевның фоторәсеме. В. Апанаев (псевдонимы Фәраби) «Сәйяр» труппасы эшенә актив катнашкан шәхес. Әлеге оркестрның уңышлары турында «Казан мөхбире» газетасында (1908, 31 март) мәкалә дә басыла. В. Апанаевның иҗаты һәм тормыш юлы турында мәгълүматлар аз иде. Хәсән Гобәйдуллин бу бушлыкны шактый тулыландыра. В. Апанаевның бертуган сеңлесе Әсма Апанаева 1961 елда язып калдырган истәлеге бу шәхеснең биографиясен шактый ачыклый.

«Вәли Закир улы Апанаев 1889 елны туып 1922 елның җәендә Казанда вафат була. Ул бала чагында ук музыкага һәвәс булып, үзлегеннән төрле гармуннарда уйнарга өйрәнә. Үсә төшкәч һәртөрле кыллы музыка коралларында уйный башлый. Скрипкада уйнарга музыка училищесында өйрәнә. «Шәрык клубы» ачылгач, кыллы оркестр оештырып, дирижерлык итә. Бу оркестр чыгышын белдереп язган программаларда «Оркестр Вәли Фәраби тәхте рияСәтендә уйнаячак» диелә.



*Ә. Кулалай*

Менә Хезмәт батыры Нури Сакаев турындагы язмалар. Актерның 1926 елда язылган автобиографиясендә мондый юллар бар: «Татар сәхнәсенә кечкенә генә хезмәт күрсәтү фикере белән, рухымны төшермичә, киләчәктә татар сәхнәсенең зур адымнар белән алга атлавы юлында каһарманнарча хезмәт итеп килдем. Хәтта бер тиенсез кал-

ган айлар да булгалады. Менә шундый вакытларда да һичбер артка чигенмичә, һаман алга, яңалыкка таба атлап, үземнең алган юлымнан читкә тайпылмый килдем. Яшәсен пролетариатның кызыл сәхнәсе! — димен».

Әхмәт Кулалаев (Ишморатов, 1887—1924). Хәсәения мәдрәсәсе шәкерте буларак И. Кудашев-Ашказарский труппасына беренчеләрдән булып (1907) катнашкан һәм 1913 елга кадәр «Сәйяр»да эшләгән Әхмәт Кулалаев турында замандашлары кулы белән язылган истәлекләр бик бай һәм эмоциональ булулары белән аерылып торалар. Шунда ук сәхнә тарихында Кулалай буларак мәгълүм артистыбызның мәһабәт фоторәсеме. 1911—1912 еллар тирәсендә төшерелгән бу фотоны Хәсән агага актерның замандашы, дусты һәм язьтәше Д. С. Абдразаков 1961 елда тапшырган.

Шунда ук артист, режиссер һәм җәмәгать эшлеклесе Зәки Баязитский (Вәлиев) иҗаты һәм тормыш юлына караган материаллар. Бу «фонд» аеруча бай. Галимнең аның белән шәхси танышлыгы да биредә зур роль уйнагандыр. Үзенең хатирәләрендә Хәсән ага болай яза: «Мин Зәки ага белән яхшы таныш идем. Әңгәмәләребезнең берсендә ул Г. Кариевтан үрнәк алып, оештыру эшләренә төп игътибарын бирүгәнне сөйләгән иде. «Кариев татар культурасы дөньясында титан иде. Ул барысына өлгерде. Мин, зур артист булмасам да, Кариев мәктәбенә лаек кеше булырга омтылдым. Шуңа шактый ук ирештем дә бугай»,— дип сөйли иде Зәки ага».

Әйе, Хәсән аганың саргайган папкаларында гаять кыйммәтле тарихи мәгълүматлар бар. Аларны актарган саен актарасы, караган саен карыйсы килә.

**Назим ХАНЗАФАРОВ,**
филология фәннәре кандидаты

## *Безнең календарь*

# РИНАТ РӘХИМОВНЫҢ ТУУЫНА 50 ЕЛ

Аңа мартта 50 яшь тулган булыр иде...

1972 елдан СССР Язучылар союзы члены булган шагыйрь Ринат Рәхим улы Рәхимов 1939 елның 17 мартында Татарстан АССРның Арча районы Урта Сәрдә авылында туа.

1956 елда Биектау районындагы Мүлмә урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, бер ел туган колхозында эшли. 1957—1962 елларда ул М. Горький исемендәге Казан авыл хуҗалыгы институтының агрономия факультетында укый. Аннары Питрәч районында — Ильич исемендәге колхозда баш агроном, 1965 елдан 1973 елга кадәр колхоз председателе була. 1966 елдан КПСС сафларында булган Р. Рәхимов 1973—1984 елларда шул ук районның авыл хуҗалыгы идарәсендә өлкән агроном-мелиоратор, мелиоратив берләшмәнең баш агрономы, председателе, соңыннан янә баш агроном вазифаларын башкара.

Р. Рәхимовның әдәби иҗат юлы урта мәктәптә укыганда башлана. Студент елларында исә ул «Татарстан яшьләре» газетасы каршында әдәби түгәрәккә йөри, газеталарда шигырьләрен бастыра; 1961—1963 елларда аның исеме күмәк җыентыкларда күренә. «Социалистик Татарстан» газетасының 1962 ел, 28 март санында Сибгат Хәкимнең берничә яшь шагыйрьгә, шул исәптән аның шигырьләренә дә хәерле юл теләгән мәкаләсе басылган. Бераз соңрак өлкән шагыйрьнең Р. Рәхимов иҗатын характерлаган «Җир шагыйре» исемле мәкаләсе дөнья күрде («Казан утлары», 1971 ел, 9 сан). Шулай ук аның турында иҗатының башыннан ук күзәтеп барган Г. Хуҗиев та җылы сүзләр язып чыкты («Социалистик Татарстан», 1966 ел, 24 февраль саны).

1964 елда шагыйрьнең «Тормыш атомнары» исемле беренче мөстәкыйль җыентыгы басылды. Аннары «Сабан тургае», «Туган җирем» һәм рус телендә «Тепло земли» исемле шигырь китаплары дөнья күрде. Аларның барысына да — тормышны, туган җирне ихлас ярату, авыл үзгәрешләрен, яңалыкларны сизгер тою, заман проблемаларына тирән үтеп керергә омтылыш хас. Шагыйрьнең яраткан геройлары да уйлый, ярата белүче, хезмәт сөючә, кырыс һәм ягымлы, гади җир кешеләре. Әйе, ул чыннан да җир, авыл шагыйре иде.

Ринат Рәхимов 1984 елның 16 августында вафат булды.

# *Культура тормышы көндәлеге*

## ЮЛБАШЧЫ МУЗЕЕНДА

24 февральдә Питрәч районының Ленино-Кокушкино авылында В. И. Ленин Мемориаль музееның 50 еллыгына багышланган фәнни-практик конференция булды. Аның эшендә Татарстанның партия, совет, комсомол, профсоюз работниклары, Казан шәһәре галимнәре, Куйбышев, Уфа, Ульяновск шәһәрләрендәге В. И. Ленин Мемориаль музейлары хезмәткәрләре катнашты.

Конференциядә катнашучылар Володя Ульянов һәм М. А. Ульянова һәйкәлләренә чәчәкләр куйдылар.

Шул ук көнне район хезмәт ияләренең музейның ярты гасырлык юбилеена багышланган тантаналы җыелышы булды.

Конференция эшендә һәм тантаналы җыелышта КПСС өлкә комитеты секретаре Р. Р. Идиатуллин катнашты һәм чыгыш ясады.

Ленин идеяләрен пропагандалау, хезмәт ияләрен В. И. Ленинның тормышы, эшчәнлеге һәм Ульяновлар гаиләсе үрнәгендә тәрбияләү буенча зур һәм нәтиҗәле эш башкарганы өчен, Ленино-Кокушкинодагы В. И. Ленин Мемориаль музее КПСС өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

## ТАТАР ИҖТИМАГЫЙ ҮЗӘГЕ СЪЕЗДЫ

17—18 февральдә Казанда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Татар иҗтимагый үзәгенең оештыру съезды булып узды. Анда республиканың төрле шәһәр һәм районнарыннан, илебезнең күпчелек союздаш һәм автономияле республикаларыннан, Мәскәү, Ленинград, Әстерхан, Саратов, Куйбышев, Ульяновск, Свердловск, Төмән шәһәрләреннән, башка өлкәләрдән, шулай ук Финляндиядән — барлыгы 31 төбәктән делегатлар һәм кунаклар катнашты. Татар иҗтимагый үзәгенең урыннардагы бүлекләре һәм теләктәшлек төркемнәре сайлаган 600 дән артык делегат арасында күренекле галимнәр, эшчеләр, колхозчылар, мәдәният, мәгариф, матбугат, радио-телевидение хезмәткәрләре, дин әһелләре бар иде.

Съездны Татар иҗтимагый үзәгенең оештыру комитеты председателе — Казан дәүләт университеты доценты М. А. Мөлеков ачты. Аннары ул оештыру комитеты башкарган эшләр һәм иҗтимагый үзәкнең максатлары турында доклад ясады.

Съездда комитетның милли дәүләтчелек комиссиясе председателе Казан культура институты проректоры Р. Хәкимов, милли тел комиссиясе председателе профессор В. Хаков, экономика комиссиясе председателе С. Дәүләтшин, демография комиссиясе председателе Д. Исхаков, сәнгать һәм мәдәният комиссиясе председателе М. Нигъмәтҗанов, экология комиссиясе председателе М. Җиһаншин, мәгариф комиссиясе председателе Х. Гарданов, хатын-кызлар һәм балалар комиссиясе председателе Ф. Бәйрәмова докладлар белән чыктылар.

Съездда киң фикер алышу булды.

Съезд эшендә ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов катнашты һәм чыгыш ясады.

Съезд Татар иҗтимагый үзәгенең Уставын һәм платформасын кабул итте, Татар иҗтимагый үзәгенең идарә органын — вәкилләр советын сайлады.

18 февральдә көннең икенче яртысында В. И. Ленин Үзәк музееның Казан филиалы конференц-залында съезд делегатлары өчен матбугат конференциясе үткәрелде. Аны КПСС өлкә комитетының идеология бүлеге мөдире О. В. Морозов алып барды.

Конференциядә КПСС өлкә һәм Казан шәһәр комитетлары җаваплы хезмәткәрләре, республика министрлыклары җитәкчеләре съезд делегатларының күп санлы сорауларына җавап бирделәр.

## ФӘННИ КОНФЕРЕНЦИЯ

Моннан 50 ел элек республикабыз сәнгать эшлеклеләрен бер тирәгә туплау, театр сәнгатен тагын да үстерү һәм камилләштерү максатыннан Бөтенроссия театр эшлеклеләре җәмгыяте бүлеге төзелгән иде. (Хәзер ул Татарстан Театр эшлеклеләре союзы дип атала).

23 январьда Актерлар йортында шушы уңайдан «Бөтенроссия театр эшлеклеләренең Татарстан бүлегенә — Татарстан Театр эшлеклеләре союзына — 50 ел» дигән темага фәнни конференция үткәрелде.

Анда республикабыз театрларында эшләүче артистлар, илебезнең күп кенә шәһәрләреннән килгән кунаклар, сәнгать белгечләре катнашты. Алар театр сәнгатенең үткәне, бүгенгесе турында җанлы әңгәмә алып бардылар. Киләчәктә театр сәнгатен тагын да үстерү турында кызыклы фикерләре белән уртаклаштылар.

Татарстан Театр эшлеклеләре союзына 50 ел тулу уңае белән үткәрелгән фәнни конференциядә ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов, ТАССР культура министры М. М. Таишев катнашты.

## РИЗА ФӘХРЕТДИНЕВ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Шәхес культы чорында һәм торгынлык елларында исеме онытылып торган зур галим, әдип, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Риза Фәхретдиневнең тууына 130 ел тулу уңаеннан СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында 13 февральдә фәнни конференция үткәрелде. Конференцияне институт директоры профессор М. З. Зәкиев ачты. Анда Р. Фәхретдиневнең иҗат мирасын өйрәнүнең актуаль мәсьәләләре, аның иҗат методы, әдәби-эстетик һәм педагогик карашлары, журналистлык эшчәнлеге, билгесез хатлары турында докладлар тыңланды.

Конференция эшендә ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов һәм Риза Фәхретдиневнең кызы Әсма ханым Шәрәф катнашты.

Шул ук көнне юбилей тантанасы К. Тинчурин исемендәге татар драма һәм комедия театры бинасында дәвам итте. КПССның Казан шәһәр комитеты, Татарстан Язучылар союзы идарәсе һәм СССР ФА Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты оештырган бу кичәне филология фәннәре кандидаты, Татарстан китап нәшрияты директоры Р. С. Мөхәммәдиев алып барды. Р. Фәхретдиневнең тормышы һәм эшчәнлеге белән тарих фәннәре докторы, Казан дәүләт университеты профессоры М. Г. Госманов таныштырды.

Кичәдә ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов катнашты.

## ФАТИХ КӘРИМНЕҢ ЮБИЛЕЙ КИЧӘСЕ

30 январьда К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры бинасында татар совет поэзиясенең күренекле вәкиле патриот шагыйрь Фатих Кәримнең тууына 80 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булды. Аны кереш сүз белән шагыйрь Р. Фәйзуллин ачты.

Юбилярның тормышы һәм иҗат юлы турында шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов, филология фәннәре кандидаты З. Мәҗитов сөйләде. Тамашачылар шагыйрьнең кызы Л. Кәримованың әтисе турындагы истәлекләрен игътибар белән тыңладылар.

Ф. Кәрим юбилеена багышланган кичәдә КПСС өлкә комитеты секретаре Р. Р. Идиатуллин, ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов катнашты.

Тантаналы кичәнең рәсми бүлегеннән соң республиканың сәнгать көчләре катнашында концерт булды.

## ШӘҮКӘТ БИКТИМЕРОВКА 60 ЯШЬ

СССРның халык артисты, РСФСР һәм ТАССР Дәүләт премияләре лауреаты, СССР Верховный Советы депутаты Шәүкәт Биктимеровка алтмыш яшь, иҗат эшчәнлегенә кырык ел тулды. Шул уңайдан 5 февральдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында юбилярның иҗат кичәсе булды. Анда катнашучылар Ш. Биктимеров катнашында «Ат карагы» (Т. Миңнуллин әсәре) исемле яңа спектакль карадылар. Кичәне кереш сүз белән театрның баш режиссеры, СССРның халык артисты М. Сәлимҗанов ачты. ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов юбилярга КПССның Татарстан өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советының Мактау грамотасын тапшырды, аңа иҗат уңышлары теләде.

Ш. Биктимеровны ТАССР Театр эшлеклеләре союзы идарәсе председателе Р. Таҗетдинов, ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин, КПССның Саба район комитеты беренче секретаре И. Нигъмәтуллин, М. Гафури исемендәге Башкорт дәүләт академия театры режиссеры В. Сәйфуллин, күп санлы тамашачылар котлады.

Ш. Биктимеровның иҗат кичәсендә партия өлкә комитетының беренче секретаре Г. И. Усманов, ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ш. Ә. Мостаев катнаштылар.

## Т. МИҢНУЛЛИН ПЬЕСАЛАРЫ — КАЗАХСТАН СӘХНӘСЕНДӘ

Драматург Туфан Миңнуллинның «Диләфрүзгә дүрт кияү» комедиясе өченче ел инде Алма-Атадагы Казах дәүләт балалар һәм үсмерләр театры сәхнәсендә уйнала. Бу пьеса ике ел элек Сакен Сәйфуллин исемендәге Караганда казах драма театрында куелган иде.

Ә быелның январенда Алма-Атада Т. Миңнуллинның «Әниләр һәм бәбиләр» әсәре буенча куелган спектакль премьерасы берьюлы ике театрда — Уйгур дәүләт музыкаль комедия һәм Корея дәүләт музыкаль-драма театрларында булды.

## ЯҢА КОНЦЕРТ БРИГАДАСЫ

Башкорт дәүләт филармониясендә танылган җырчы Фән Вәлиәхмәтов җитәкчелегендә татар бригадасы төзелде. Бөтенроссия конкурсы лауреаты җырчы Ф. Сәфәргалиева, җырчы Ә. Солтанова, биючеләр Я. Зәйнуллина һәм БАССРның атказанган артисты Р. Зәйнуллин, нәфис сүз остасы Р. Дашкина, баянчы Х. Сәрвәров һ. б.ны берләштергән бу концерт бригадасы Күмертау, Стәрлетамак шәһәрләрендә, Тәтешле, Яңавыл, Борай районнарында, Уфа шәһәренең культура сарайларында дистәләрчә концертлар биреп, тамашачыларның мәхәббәтен казанырга өлгерде. Бу турыда безгә журнал укучыбыз Р. Фаязов хәбәр итте.

# КИТАП БИЗӘҮ СӘНГАТЕ

Татар халкының бу сәнгате мең еллык тарихы булган әдәбият белән үрелеп үскән. Идел буе Болгар дәүләтенең югары язма культурасы, инде XIII гасырда ук «Кыйссаи Иосыф» кебек әдәби җәүһәрләр тууы әдәбият ихтыяҗларына җавап бирердәй башка төр сәнгатьнең дә үсүен таләп иткән. Китап тышлыгы ясау, аны бизәү, матур язу — каллиграфия сәнгате — әнә шул рәвешле камилләшә барган.

XII—XVI гасырларда эшләнгән алтын һәм көмеш китап тышлыкларының, китап капларының бизәкләрен чүкеп ясалган төрле сурәтләр, язулар хасил иткән. Кайбер китап савытлары асылташлар белән дә бизәлгән. Шушы затлы капларда хаттат-каллиграфлар тарафыннан күчереп язылган гаҗәеп кулъязмалар сакланган.

Кулъязма китап күчерү — ата-бабалар тәҗрибәсен килер буыннарга калдыруның ышанычлы бер юлы, сәнгать дәрәҗәсенә күтәрелгән ысулы булган. Авыл җирендә дә, шәһәр җирендә дә уку-яза белү киң таралганлыктан, татарларда китап күчерү гаять дәрәҗәле эш саналган. Матур һәм килешле итеп яза белүгә — хаттатлык эшенә — балаларны кечкенәдән үк өйрәткәннәр. Китап күчерү савaплы һәм алла тарафыннан макталган бер шөгыль буларак кабул ителгән.

Китапны сәнгатьле язу белән күчерүдә, әлбәттә, төрле ысуллар кулланылган. Әйтик, төгәллеккә һәм монументальлеккә омтылган борынгы язу стиле — куфи, нәфис бизәкләргә бай — сөлес, тыйнаклык һәм җыйнаклык белән өретелгән—нәсех, ярсулы, җитез — тәгълик... Татар язуында әлеге ысулларның үзара аралашуыннан хасил булган нәстәгълик аеруча киң таралган. Бу стиль башлангыч мәктәпләрдә, мәдрәсәләрдә укытылган.

Кулъязма китаплар аша безгә атаклы хаттатларның исемнәре дә килеп җиткән. Мәсәлән, Кысна авылыннан Сөбхан Мәрҗани (XVII йөз) алтмыштан артык китап күчереп калдырган. Мөфти Өммәти, Гобәйдулла әл-Болгари әл-Казани әл-Сулбаши, Туйчи Күчемкол, Исламкол ибне Габделкәрим әл-Каргали, Мостафа Чутаи һәм башкалар — болар барысы да үз заманының фидакарь кешеләре, халыкның рухи тәҗрибәсен яңа буыннарга калдыру өчен бик күп йокысыз төннәр уздырган, каллиграфия эшен сәнгать дәрәҗәсенә күтәргән шәхесләр.

XVIII—XIX гасырларда китап төпләү эше тагын да киңрәк колач ала. Ул, китап бизәү кебек үк, зур сәнгать булып исәпләнә. Бу эшнең дә үз осталары булган. Шунысы да игътибарга лаек: узган гасырда китап тышлыгы өчен картыгы, күн, агач, тукыма, бизәкле кәгазь кебек җирле материаллар гына түгел, ә бәлки читтән — Урта Азиядән, Төркиядән һәм башка яклардан кайтарылган экзотик материаллар да киң файдаланылган.

Китап күчерү, китап төпләү эше махсус остаханәләрдә генә түгел, халык арасында да нык таралган була. Нәкъ менә шуннан чыгып, татар китабының тагын бер үзенчәлеге күренә: киң халык арасында туган, күчереп язылган һәм тышланган кечкенә дәфтәр-китапчыкларның бизәлеше кулдан килгән мөмкинлекләрдән чыгып башкарылган. Монда инде төрле төстәге кара белән язу да, күчереп язылган текстны төрле яктан сызыклар белән урап алу да кулланылган. Күчереп язучы мондый китапта үзенең тәрҗемәи хәлен дә әйтеп үткән, башка искәрмәләр дә өстәп барган. Әйтик, китапны күчерү ничек барган, ничә көн дәвам иткән, күчерүче бу вакыт эчендә ничә шәм яндырган һәм башкалар. Кулъязма текстның эчтәлегенә карата да күчереп язучы үз уйлануларын әйтеп калдырган, тәэсирләре белән уртаклашкан. Ул гына да түгел, китап күчерү вакытында аның улы яки кызы туса, башка бер яңалык булса, анысын да искәртеп үтәргә онытмаган.

Гомумән, мондый кулъязма дәфтәр-китаплар күчереп язучының үзенчәлекле бер көндәлеге, сердәше, киңәшчесе булган.

Ә инде татар китабының бизәлешенә, тышлыгындагы сурәтләренә Көнчыгыш культурасының зур тәэсир ясавын әйтергә кирәк. Журнал тышлыгында бирелгән рәсемдә узган гасырның билгесез бер авторы тарафыннан күчерелгән кулъязма китапларны күрәсез. Анда каллиграфиянең һәм китап тышы бизәүнең узган гасырның икенче яртысына хас үзенчәлекле төсмерләре чагыла.

Узган гасыр азакларында китапны кулдан күчерү кими, тышлыгын кулдан бизәү нигездә туктала, аларны үсеп килүче «ташбасма», бүгенге китап басу һәм бизәү сәнгате алыштыра.

**Р. ШАҺИЕВА,**
Татарстан сынлы сәнгать музее
фәнни хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** язгы ташу вакытында Казан күренеше. XIX гасыр. Инглиз рәссамы Э. Турнерелли эшеннән репродукция.

**Ю. ФИЛИМОНОВ** фотолары.

# Игътибар!

Халкыбызның күп гасырлы катлаулы һәм гыйбрәтле тарихы, әдәбият мирасы бар. Әмма 1930-40 елларда ике тапкыр әлифба-язу алыштыру нәтиҗәсендә күпләребез ул кадерле, изге мирастан аерылган. Шуны истә тотып «Казан утлары» журналында 1988 елның сентябреннән гарәп әлифбасына нигезләнгән татарча уку-язу дәресләре бирелә башлады. Кайберәүләр хәзер үзләре үк гарәп хәрефләре белән хатлар язалар. Шул ук вакытта күп кенә укучылар гарәп әлифбасына нигезләнгән татар язуын өйрәнгәндә төрле кыенлыклар тууы, журналның кайбер саннарын табып булмавын һәм язган язуларын тикшереп киңәш бирүче юклыгыннан зарланалар. Тарихыбызны, милли культурабызны сөюче иптәшләргә журнал редакциясе каршында оешкан «Мәгариф» кооперативы үз ярдәмен тәкъдим итә. Укырга-язарга өйрәтү читтән торып укыту ысулы белән алып барылачак.

Кадерле дуслар! Әгәр дә сез ата-бабаларыбызның өмет-хыяллары, күңел җылылыгы, моң-зарлары сеңгән кулъязмаларны һәм китапларны укырга теләсәгез, «Мәгариф» кооперативына мөрәҗәгать итегез! Хат язганда үзегезнең элемтә бүлеге индексын, тулы исем-фамилиягезне, белемегезне һәм яшегезне күрсәтеп төгәл адресыгызны язарга онытмагыз.

*Безнең адрес: 420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2. Редакция журнала «Казан утлары» — кооператив «Мәгариф».*

Шунысын да исегезгә төшерәбез: редакция китаплар һәм журналның элеккеге саннарын укучыларга җибәрү белән шөгыльләнми.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



**КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)**

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)